

Нурихан Фәттах

# АКЛАН

**Роман**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-312.9
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Ф96

**Фәттах Н.С.**

Ф96 Аклан: роман / Нурихан Фәттах. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. — 399 б.
ISBN 978-5-298-01782-4

«Аклан» — Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахның тәмамланмый калган соңгы әсәре. Бик күп фәнни-популяр әдәбиятка нигезләнеп язылган бу романында автор әдәби образлар аша Атлантида язмышын сурәтли һәм халкыбыз язмышы турында тагы бер кат уйланырга этәрә.

УДК 821.512.145-312.9
ББК 84(2Рос=Тат)-44

ISBN 978-5-298-01782-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Фәттах Н.С., 2009

— Алар изгеләр булганнар. Аларны туфан харап иткән. Өйләре, байлыклары җир астына күмелеп калган. Балталары, пычаклары җиздән булган. Тимер шеш белән җиргә төртеп карадың исә, шыкы-шыкы иткән тавыш килә, ди. Теләсә кемгә ишетелми икән. Ятим балага гына ишетелә, ди. Әткәй сүләй торганые, элек җиз табаклар, алтын-көмешләр тапканнар, дип...

*Бүә буенда, Очлы тау башында Изгеләр чишмәсе янында Урта бабай Мәхмүтҗан белән сөйләшүдән*

1961 ел, 30 апрель. Яңа Уртавыл

# I

Борын-борын заманда, җир белән күк бер-берсеннән аерылып, якты дөнья туып килгән бер вакытта, Аклан утравының тау үзәнендә — үзән уртасындагы Түгәрәк тау башында ирле-хатынлы ике кеше яшәгән. Дөньяда болар иң беренче, иң әүвәлге кешеләр булганнар. Аларның тагын Дикә исемле кызлары булган. Кыз буйга үсеп җиткәндә, ирле-хатынлы кешеләр бер-бер артлы дөнья куйганнар. Бөтен тау башында, бөтен үзәндә, хәтта бөтен дөньяда кеше затыннан булган Дикә берүзе торып калган. Ул бик кайгырган, курыккан һәм ничек тә үзенең куышыннан чыкмаска тырышкан. Ләкин эчендә җаны булган сау-сәламәт кеше куышта гына ята алмаган. Аңа әледән-әле чишмәгә — суга, урманга утынга барырга туры килгән. Чишмә шактый еракта, тау астында булган, урман да бик үк якын түгел икән. Урман ягы аеруча куркыныч тоелган. Караңгы төшү белән аннан берсеннән-берсе ямьсез тавышлар ишетелгән, кемнәрдер сугышкан, чинаган, үкергән. Шатыр-шотыр китереп юан

агачларны сындырганнар, акыртып-бакыртып кемнәрнедер бугазлаганнар да шомлы рәвештә кинәт тынып калганнар. Кайчагында, дөп-дөп басып, якыннан гына, куыш яныннан гына, иләмсез зур филләр, арысланнар, юлбарыслар узып киткән.

Төннәрен ялгыз Дикә рәтләп йоклый да алмаган — тирә-якка колак салып, куркып, дер-дер калтыранып чыккан. Куышта, идән уртасында, өзлексез ут янган. Дикә ничек тә шул утны — әтисеннән-әнисеннән калган бердәнбер дустын, булышчысын, яклаучысын сүндермәскә тырышкан. Куыш эчендәге чокырда аның тагын әтисеннән-әнисеннән калган арпасы, бодае, борчагы булган. Арпа да, бодай белән борчак та ул вакытларда кыргый үлән белән аралашып үскән. Арпа, бодай, борчак үсә торган җир аста — тау итәгендә булган. Шуңа күрә Дикә, тау астына төшәргә куркып, чокырдагы арпасын да, бодаен, борчагын да саклап кына тота икән.

Тау башындагы ялгыз куышта шулай яшәп ятканда, көннәрдән бер көнне, язга таба, диңгез уртасындагы Аклан утравына каяндыр бер ялгыз кәмә килеп туктаган. Калку борынлы җиңел кәмәдән озын буйлы яшь бер егет төшкән. Үзе шундый чибәр, ди, бер бите — ай, бер бите кояш кебек балкып тора, ди. Унике толымга үрелгән чем-кара чәчләре атлаган саен артыннан җилбердәп, тирбәнеп, сузылып килә, ди. Егет кулына көмеш җәя тоткан, биленә кызыл садак таккан, садагы тулы бөркет каурыйлы алтын ук, ди.

Көне буена бу яшь аучы үзәндә кошлар, киекләр атып йөргән. Кичкә таба, арып-алҗып, яңадан кәмәсе янына килгән, ярдан беркадәр читтәрәк учак ягып кошларын, үрдәкләрен кыздырып ашаган. Кәмә туктаган җирдән якындарак челтерәп чишмә агып ята икән. Тамагы туйгач, ят аучы иелеп чишмәдән су эчкән дә, чишмә буендагы чирәмгә башын төртеп, шундук йокыга талган.

Икенче көнне иртән, таң атып кояш чыгу белән, Түгәрәк тау башындагы Дикә чишмәгә суга дип киткән. Кыз үз күңелен үзе күтәреп җырлый-җырлый бара икән. Җыры бик тә моңлы да, дәртле дә икән. Ул чакларда әле иген игү булмаган кебек, җитен игеп, киндер сугу да булмаган, агач-таштан, балчыктан савыт-саба ясау да булмаган. Дикә үлән сабакларыннан үрелгән чыпта сыман алъяпкыч бәйләп куйган икән дә кулына эче алын-

ган зур гына кабак тоткан икән. Чыпта алъяпкычы да, суга йөри торган буш кабагы да, моңлы җыры да Дикәгә, әлбәттә, әнисеннән калган булган.

Дикә бик чибәр булган. Кыргый утрауда ялгыз башы яшәп ятса да, бераз гына көяз дә икән. Ул да озын кара чәчләрен өч толымга үреп, толымның икесен күкрәгенә, берсен аркасына салындырып куйган. Ике яклап чигәсендә беркадәр кодрә чәч бөртекләре калдырган, ди. Нәфис муенына — диңгез буендагы асылташлардан тезелгән муенса, нәни генә колакларына ялт итеп торган бакыр алкалар таккан, ди. Сызылып киткән нәзек кашлары кара, иреннәре яңа өлгергән чия кебек, ике як бите кызарып пешкән алма кебек, ди.

Ят аучы йокы аралаш Дикәнең җырын ишеткән дә уянып киткән. Тау өстеннән төшеп килүче ике аяклы, ике куллы яшь кызны күреп, аучы егет бик гаҗәпләнгән. Ул, күрәсең, бу утрауда адәм затыннан беркем юк дип исәпләгән. Кыз да моны күреп алган. Күреп алган да искәрмәстән кычкырып җибәргән. Әтекәем-әнекәем! Бу ни бу? Дөньяда аңа, аның мәрхүм әтисенә-әнисенә охшаган башка җан ияләре дә була микәнни? Әнисеннән бигрәк ул аның — Дикәнең әтисенә охшаган. Нишләп йөри ул? Ни кирәк аңа монда?

Куркудан кызның кулындагы буш кабагы төшеп киткән, аяк астындагы очлы ташка туры килеп кабак ярылган. Дикә моңа, әлбәттә, бик кайгырган — куышта аның бүтән савыты булмаган. Иелеп, ярылган кабак кисәкләрен бер-берсенә беркетмәкче булып азаплана икән бу. Кабак кисәкләре бер-берсенә берекмәгән. Дикә еларга тотынган.

Яшь аучы моңа карап торган-торган да, кызның күз яшьләрен күреп, аягына баскан, Дикә янына килә башлаган. Кыз исә, ватылган кабагын ташлап, куркып, куышына таба йөгергән.

— Дикә, курыкма миннән! — дигән шул чакны яшь аучы, телгә килеп, чын безнеңчә, лелегчә итеп.

Ул моны шундый ягымлы итеп, якын итеп әйткән, үзе дә сизмәстән Дикә туктап калган, борылып караган.

— Каян беләсең син мине? — дигән ул, шаккатып.

— Беләм инде, — дигән аучы.

Аяк астында аунап яткан кабак кисәкләрен кулына алган, ике кисәкне бер-берсенә якын китергән, беркеткән дә бөтен килеш кызга биргән. Яңадан элекке хәленә кайткан кабак кисәкләренең ялганган җирендә

җөе дә калмаган, ди хәтта. Сөенеченнән Дикә көлеп җибәргән.

— Син... кем? — дигән ул, яшь аучының йөзенә туры карап.

— Мин? — дигән аучы.

— Син шул, син! — дигән Дикә. — Мин, синең исемең ничек, димен.

— Мин, — дигән аучы, күзләреннән шаян нурлар сирпеп.

— Нишләп йөрисең монда... минем утраудa? — дигән кыз, ачуланасы килеп.

Ул, билгеле, ачулана алмаган. Юри генә ачуланган булып күренергә тырышкан. Кызлар бит гел шулай: аларның ачулы сүзләре дә яшь егеткә мактау булып ишетелә.

— Нинди чибәр син, Дикә! — дигән яшь аучы да, соклануын яшерә алмыйча.

Ипләп кенә ул кыз янынарак килгән, аның кулыннан тотып алган. Шул чакны ятимә кыз Дикәнең күңеленә гыйшык уты үрләгән. Куанып ул тагын көлеп җибәргән. Якында гына сандугачлар сайраган, аяк астында кызыл гөлләр калкып чыккан. Күктән исә, сөенеп, мәңге яшь, мәңге тере кояш көлеп торган.

Шуннан соңмы? Шуннан соң ни булганын Акланда белмәгән кеше юк. Шуннан соң Ту анабыз Дикә үзенең олы кунагын чыбыктан үрелгән, балчык белән сыланган ярлы гына куышына алып кайткан. Шунда алар бергә-бергә тора башлаганнар. Үзен Мин дип атаган кунак көн дә ауга йөргән — урманнан киек, күлдән кошкорт, диңгездән балык алып кайткан. Ул кайтуга Дикә ут-учакта ашарга пешергән, өен бизәгән, үзе бизәнгән. Ул үзендә гаҗәеп бер үзгәреш барлыкка килүен сизгән. Дөньяда бар нәрсә аңа хәзер искиткеч матур һәм ягымлы булып тоелган. Ул инде хәзер беркемнән, бернәрсәдән курыкмаган да, шикләнмәгән дә. Урман ягындагы төрле тавышлар да, якын-тирәдә лап-лоп килеп, чинап, үкереп, йөгереп йөрүләр дә үзеннән-үзе тынып калган. Дикәнең гел җырлыйсы, көләсе, елмаясы гына килеп тора икән.

Үзендә генә түгел, бөтен тирә-якта, бөтен тау башында гаҗәеп үзгәрешләр күреп, анабыз Дикәгә әледән-әле таң калырга туры килгән.

Беркөнне иртән торып тышка чыкса, куыш янында гына пешкән җимешләрен көчкә күтәреп, зәйтүн агачы

үсеп утыра икән. Икенче көнне исә зәйтүн агачы янында кузы чикләвеге, инҗир куаклары үсеп утыра, имеш. Өченче көнне торып караса, элек нindидер ташлар аунап яткан ташландык бер җирдә, яшел яфраклар арасында, кыяр, карбыз, кавыннар тәгәрәшеп ята, ди. Тагын беркадәр вакыттан соң анабыз Дикә, кабак савытын күтәреп, тау астындагы чишмәгә суга дип барган икән, кабакка чишмә суы ага башлау белән, күз алдында савыт ялтырап торган, чыңлап торган көмеш чүлмәккә әверелгән, ди.

Икенче көнне бу көмеш чүлмәген тотып янә суга киткән. Куышыннан чыгып җырлый-җырлый тау астындагы чишмәгә төшеп килгәндә, анабыз Дикә якында гына, аяк астында гына, челтерәп аккан чишмә тавышын ишетеп туктап калган. Караса, моңарчы барлыгы-юклыгы беленмәгән куышлы бер җирдән, ак, кара ташлар арасыннан, гөлдер-гөлдер көйләп, сөйләнеп чишмә агып ята, ди. Анабыз Дикә көлеп җибәргән, башта чишмәнең суын эчеп караган. Аннан көмеш чүлмәген тутырып алган да куышына кереп китмәкче булган. Кайту ягына борылу белән, сукмакның икенче ягында тагын бер чишмә күреп, анабыз Дикә тәмам аптырап калган. Кызыксынып ул икенче чишмә янына килгән, эчеп караган. Монысының суы кап-кайнар, ди, төмендә дә нindидер ят, сәер тәм бар, ди. Шулай да тәмсез түгел икән.

«Менә кызык!» — дип уйлаган анабыз Дикә үзалдына. Салкын сулы көмеш чүлмәген куышына алып кайтып куйган да: «Туктале, кайнар су да алып кайтыйм», — дип уйлаган. Шулай дип уйлап бетермәгән, салкын сулы көмеш чүлмәк янында икенче бер савыт барлыкка килгән. Монысы саф алтыннан, ди, эче буш, ди. Шулай итеп, алтын чүлмәген алган да анабыз Дикә кайнар су алырга киткән. Чишмәдән кире борылып, үзенең ярлы, тәбәнәк куышына керим дисә, ни күрсен — түгәрәк куыш урынында матур итеп киселгән, шомыртылган, кызыл таштан төзелгән ике катлы биек сарай калкып утыра, ди. Чишмәләр ягыннан сарайга кадәр аяк астына тигез итеп ак һәм кара ташларны аралаштырып таш җәелгән, ди. Сукмак буенда, як-якта таш савытларда ят гөлләр үсеп утыра, ди.

Бу юлы анабыз Дикә гаҗәпләнмәгән. Ул бары сөенгән генә. Үзәндәге, тирә-яктагы үзгәрешләрнең барысы да иренең хикмәтләре булырга тиешлеген ул инде күптән сизенгән. Чыннан да, аның серле һәм куәтле ире кеше кыяфәтенә кергән диңгез алласы булган.

Алар бик дус, тату яшәгәннәр. Яшь хатынын яратканга, атабыз Мин аның барлык теләкләрен үтәргә тырышкан. Анабыз Дикәнең күңелендә берәр төрле теләк, хыял туып өлгерү белән, атабыз Мин аны шундук тормышка да ашыра икән. Үзләренең Түгәрәк тау башындагы куышларын-сарайларын гына түгел, бөтен Аклан утравын атабыз Мин дөньядагы барлык утраулардан яхшырак, күркәмрәк һәм Адәм затындагы кешеләргә яшәү өчен җайлырак итеп үзгәртергә тырышкан.

Аклан утравы җылы диңгез уртасында утырса да, элегрәк кышын-көзен анда да салкын җилләр үтеп кергән. Салкын җилләр белән бергә салкын яңгыр ияреп килгән һәм өзлексез коярга тотынган. Мондый чакта мәңге яшел агачлар, үләннәр бөрешеп калганнар, гөлләр саргайган, сайрар кошлар каядыр качышып беткәннәр, хәтта киекләр, ерткычлар да урман-тау араларында тынып торганнар. Шундый бер кичне анабыз Дикә, иңбашына каплан тиресе ябынып, учак янында елап утыра икән, күңеленнән үзе, кайчан җылы язлар җитәр дә, кайчан гөлләр чәчәк атар, дип уйлана икән. Ул төнне көтмәгәндә нишләптер бик каты күк күкрәгән, җир селкенгән. Кайдадыр ялт-йолт килеп яшен яшьнәгән. Анабыз Дикә уянып киткән, куркып, шомланып тирә-якка колак салып яткан да озакламый тагын йокыга талган. Иртән торып тышка чыкса, яңгыр да яумый, күк тә күкрәми, җир дә селкенми икән. Зәңгәр диңгез өстеннән балкып кояш чыгып килә, таш савытларда елмаеп аллыгөлле чәчәкләр үсеп утыра, куакларда шатланып кошлар сайрый икән.

Сөенеченнән анабыз Дикә көлеп җибәргән, җырлап җибәргән һәм, сарайдан тиз генә көмеш чиләген алып, чишмәгә суга килгән. Чишмә ягына борылганда, утрауның төньягында башлары күккә тигән ниндидер тауларга, кыяларга күзе төшкән моның. Аклан утравының уртасындагы Түгәрәк таудан башка элек монда бернинди тау да, кыя да булмаган. Димәк, атабыз Мин ул тауларны-кыяларны бер төн эчендә шулай үстереп, күтәртеп куйган! Ни булса булган, шул төннән соң беркайчан утрауга салкын җилләр дә үтеп кермәгән, күктән салкын яңгыр да яумаган. Җәй көнендә монда эссе, коры булган, йомшак кына җылы яңгыр яуган, диңгез ягыннан шифалы, талгын җилләр искән. Шулай итеп, Аклан утравында мәңге кояш, мәңге җылы, рәхәт булган. Ел тәүлеге буена агачларда татлы, туклыклы җимешләр өлгергән, аяк астында яшелчәләр үскән, үзәндә, тау буй-

ларында арпа, тары, бодай, борай ише игеннәр җитешкән.

Анабыз Дикә иң әүвәл ике игезәк бала тапкан. Балаларның икесе дә ир затыннан булган. Икенче мәртәбә анабыз Дикә янә дә ике игезәк тапкан. Балаларның болары да ир затыннан булган. Анабыз Дикә барлыгы биш игезәк ир бала китергән. Малайлар бик таза, көр булган, ай үсәсен көн үскәннәр, ел үсәсен ай үскәннәр, аталары белән бергәләп ауга йөргәннәр, аталарыннан, берберсеннән күрмәкче төрле һөнәргә өйрәнгәннәр.

Уллары үсеп җитү белән, атабыз Мин ауга йөрү, иген игү эшләрен тулысынча аларга тапшырган да үзе исә, ал-ял белми, утрауны тәртипкә китерә башлаган. Иң элек ул арык җибәреп үзән уртасындагы Түгәрәк тауны су боҗралары, җир боҗралары белән әйләндереп алган. Су боҗралары — өч, җир боҗралары ике булган. Җир өемнәрен атабыз Мин таш киртәләр белән ныгыткан. Түгәрәк тауга кадәр диңгездән турыга тагын бер арык ерган. Тау башында сарайлар, каравыл өйләре, корбан, садака өйләре салган һәм шуларның барысын да алтын койма белән әйләндереп алган. Бит ул заманнарда алтынны да, көмешне, җизне, бакырны да каяндыр таулар арасыннан эзләп табарга, ташлар ватып, кайнатып, эретеп табарга кирәк тә булмаган — барысы да аяк астында аунап яткан!

Озакламый Акланның даны чит җирләргә, чит илләргә таралган. Аклан турында ишетеп, төрле яктан кешеләр килә башлаган.

Бу вакытта инде игезәкләрнең беренчеләре үсеп буйга җиткәннәр. Аларның да үзләренә аерым җир алып, сарай салып, башка чыгып яшиселәре килә икән. Иң беренче улы Атласка атабыз Мин кәми кызын, икенче улы Кадиргә мис сар кызын алып биргән. Икенче пар игезәкләрнең өлкәненә атабыз Мин кар кызын, кечерәгенә луки сар кызын алып биргән. Өлкән улы Атласка атабыз Мин изге тауны, андагы барлык байлыкны мирас итеп калдырган. Кадир улына, башка барлык улларына үзәндә җирләр-сулар бүлеп биргән дә әйткән: «Һәркайсыгыз үз җирегездә үзегез баш, барыгызга да агагыз баш», — дигән. Аннан соң тагын шундый сүзләр дә әйткән: «Киләчәктә киңәясегез килсә, һәркем үзе торган җирдән турылап читкә китсен, яңа җир ачсын, җир эшкәртеп иген иксен, мал-туар асрасын», — дигән.

Шуннан соң атабыз Мин Түгәрәк утраудагы алтын койма эчендәге сарайлар, каравыл өйләре янына, иң кал-

ку җиргә биек таш утыртып куйган, ташны уеп, киләчәк буыннар өчен үзенең изге сүзләрен — юсык-юрык кагыйдәләрен язып калдырган. Акланның киләчәк сарлары, аксөякләре, карасөякләре әлеге ташка уеп язылган, өстенә кайнар җиз коеп мәңгеләштерелгән изге сүзләргә ярашлы рәвештә яшәргә тиеш булганнар.

Бүгенге лелегләр — менә шул атабыз Мин белән җир кызы Дикә анабызның уллары. Лелегләр — дөньяда иң изге кешеләр, лелегләр — дөньяда иң өлешле, иң батыр, иң бай һәм куәтле кешеләр. Тора-бара мака сарның да, аның энеләренең дә биләмәләре арткан, халкы күбәйгән. Җитез кәмәләргә утырып, алар диңгезнең әллә нинди җирләренә барып чыкканнар, якын-тирәдәге утрауларны, төньяктагы, көньяктагы, көнчыгыштагы, көнбатыштагы кыргыйларны үзләренә буйсындырганнар. Лелегләр — кояш уллары — бер генә сугышта да җиңелмәгәннәр. Алар һәрвакыт җиңүче булганнар. Шуңа күрә дә барлык кыргыйлар — барбарлар — алардан куркып, котлары алынып торалар. Шуңа күрә дә алар лелегләргә баш ияләр, көнләшәләр, сокланалар. Шуңа күрә дә Аклантита утравына төрле яктан көне-төне кәмәләр килә, кәмәләр белән мал-туар килә, коллар килә, байлык килә, алтын килә.

Боларын да Акланда белмәгән кеше юк. Тик шулай да монда әле беркем белмәгән-күрмәгән, белеп-күреп тә, күптән инде онытылып беткән нәрсәләр дә җитәрлек.

Атабыз Мин белән анабыз Дикә нәселеннән булган мака сарлар Түгәрәк тауны, Акланны бизәү, матурлау өчен шактый көч куйганнар. Ата сүзен истә тотып, яңа юллар ясаганнар, арыклар ерганнар, елгалар аркылы күперләр салганнар. Утрауның әле бер төшендә, әле икенче төшендә җир ачып, таштан, агачтан йортлар, туралар төзегәннәр. Вакыт узу белән утрауда, биләмәләрдә кеше дә күбәйгән. Игенчеләр иген иккән, терлекчеләр малтуар асраган, чүлмәкчеләр чүлмәк ясаган, тиречеләр тире иләп күн ясаганнар. Таш баганадагы изге сүзләрне истә тотып, изге сарлар Акланнан читтәге, ерактагы җирләргә күченеп утырганнар. Яңа җирләрдәге кыргыйларны һөнәргә, аң-белемгә өйрәткәннәр.

Аклан кешеләре бик тырыш һәм эшчән булганнар. Ләкин алар гел эш белән генә дә мавыкмаганнар. Буш вакытларында җыйнаулашып күңел ачканнар — җырлаганнар, биегәннәр, каравыл өйләрендә, келәү өйләрендә Изге атабызга, Изге анабызга багышлап корбан бир-

гәннәр, садака биргәннәр. Ятсалар да, торсалар да аллаларга, изгеләргә зекер әйткәннәр, үзләренең барлык эшләрен, барлык уй-теләкләрен атабыз Мин һәм анабыз Дикә сүзләренә ярашлы рәвештә башкарганга күрә, бер яктан ун агай-эне — мака сарлар, сакалар, икенче яктан ил-көн һәм каралар арасында беркайчан, бернинди дошманлык булмаган. Акландагы, биләмәләрдәге һәркем үз язмышыннан үзе риза булып, дөньяда үзен иң бәхетле, иң өлешле кеше диеп исәпләгән. Ул чакларда, имеш, кешеләр арасында авырулар да, яралы һәм гариплэр дә булмаган. Ызгыш-талаш, ялган сөйләүне, комсызлыкны, җәбер-золымны әйткән дә юк. Берсе дә булмаган!

Бар бозыклык, комсызлык һәм җәбер-золым... сарлардан башланган. Әйе, әйе, дөньяда алла урынына калган мака сарлардан башланган. Моңа хәтта ышанасы да килми, ләкин ышанмыйча да булмый, чөнки дөресе шулай.

Кемнең нинди бозыклык эшләве турында сүз чыкканда, иң элек мака сар Карунны искә төшерәләр.

Мака сар Карун эретеп кайнар җиз коелган таш баганадагы алла сүзләрендә моңарчы беркем күрмәгән төгәлсезлек тапкан — тыелган нәрсәләрне бер-бер артлы тезеп саный барганда, Изге атабыз Мин әллә онытып, әллә башка бер сәбәптән байлык җыюның язык икәнен әйтми калдырган.

Мака сар Карун моны күреп алган, уйлана башлаган һәм, уйлана-уйлана, тиешле нәтиҗә дә ясаган. Башкаларга сиздермәскә тырышып, мыштым гына бу алтынкөмеш, затлы ташлар җыярга тотынган. Алтын-көмешне, затлы ташларны, билгеле, элегрәк тә җыйганнар, ләкин булган берен кирәккә тота барганнар. Мака сар Карун болай гына, кызык итеп кенә җыйган. Аның бу кыланышы күзгә чалынмый калмаган, әлбәттә. Баштарак моңа кешеләр көлеп кенә караганнар. «Тиле таш җыяр!» — дигәннәр. «Бала-чага да матур ташларга кызыга», — дигәннәр. Кайберәүләр, куркып: «Безнең сарның акылы җиңеләйմәде микән?» — дип уйлаганнар. Мака сар Карун чынлыкта комсыз, хәйләкәр һәм бар нәрсәне алдан уйлап эшли торган аек акыллы кеше булган.

Белгәнебезчә, элегрәк дөньяда иң кадерле, иң кыйммәтле таш көмеш булган. Алтын көмештән арзанрак саналган. Алтынны борынгылар җизнең бер төре дип белгәннәр. Шуңа күрә алтыннан савыт-саба, корал, кирәк-ярак эшләгәннәр. Мака сар Карун алтынның

көмештән затлырак, кыйммәтлерәк икәнлеген аңлаган. Аның иң зур бозыклыгы менә шул булган, ахрысы. Бер елны, илдәге юсыкны үзгәртеп, ул казнага бирелә торган һәртөрле салым, түләү өчен көмеш урынына алтын сораган. Моңарчы көмеш таба алмый интеккән кешеләр бик теләп, сөенеп үзләрендәге барлык алтыннарын мака сарга ташый башлаганнар. Сарайдагы амбарлар, базлар алтын табаклар, чүмеч, тарак, аел, шөлдер ише нәрсәләр белән тулган.

Мака сар Карун ярым караңгы, салкынча, тын амбарларында, базларында үзенең алтынын, затлы ташларын карап йөрергә ярата икән. Шулай бервакыт моның күңеленә «Акландагы барлык алтын-көмешне, җиз-бакырны, затлы ташларны үз кулыма алсам, нинди бай булыр идем мин!» дигән уй килгән, имеш. Алтын-көмеш матур гына, чыдам гына түгел, анда көч-куәт бар. Алтын-көмешең, затлы ташларың күп булса, корал кулланмыйча, теләсә кемне буйсындырып, теләсә кемне яулап, юк итеп була. Иң элек буйсынмас, баш бирмәс аксөякләрне буйсындырасың, аннан соң туганнарыңны, тора-бара ерактагы күршеләр — чит илләр ягына да күз атарга була!

Менә шундый көннәрнең берсендә мака сар Карун сараена, таякка таянып, бер саилче карт килеп кергән. Чынлыкта ул саилче дә булмаган, Карлы тау келәүлегендә, изге тау куышында аллаларга зекер әйтеп яшәүче, күктәге айның, кояшның, йолдызларның күченешен өйрәнүче олы галим Сабир ата булган. Аның инде күптән илбашы мака сар Карун белән күзгә-күз очрашып сөйләшәсе-аңлашасы килә икән. Үзенең кемлеген һәм ни өчен килүен әйткәч, сарай сакчылары аны туп-туры Карун янына алып барганнар. Аллаларга якын изге кеше буларак, Сабир ата иң элек мака сар алдында бил бөккән, кулларын күтәреп, илгә-көнгә, мака сарга иминлек теләгән һәм, тәхеттә кукраеп утырган Карунның таштай йөзенә туры карап:

— Син бик зирәк булып чыктың, мака сар, — дигән.

Мака сар Карунның беркайчан Сабир ата белән очрашканы булмаган. Беренче карашта ук саилче аңа ошамаган — әрсез, оятсыз һәм комсыз бер бәндә булып тоелган. Бит сарлар, көч-куәт иясе, үзләренә охшаганнарны да, охшамаганнарны да яратып җиткермиләр. Ләкин саилченең мактау сүзләре Карунның күңеленә сары май булып яткан. Ул көлемсерәп куйган, ләкин,

ниндидер өтәләнгән, чыныккан саилче алдында йомшаклык күрсәтеп байлыгыма зыян килмәсен дигәндәй, йөзендәге елмаюын яшергән дә бу, теләр-теләмәс кенә:

— Минем зирәклегем нидә күренә? — дигән.

Карун чыннан да үзен дөньядагы барлык кешеләрдән акыллырак, зирәгрәк дип уйлаган. Шулай да хәзер аның үзенең зирәкме-түгелме икәнлеген беләсе килмәгән, хәзер аның бу картны, кыен хәлдә калдырып, түбәнсетеп, сараеннан тизрәк куып чыгарасы килгән. Бит бер оятсызга юл куйсаң, аның артыннан икенчесе, өченчесе килеп чыгарга, сиңа төрле мактау сүзләре сөйләгән булып, синең сереңне алырга, базыңа, амбарыңа кулын сузарга да күп сорамаслар. Ләкин, никадәр акыллы һәм зирәк булмасын, Сабир атага сорау биреп, «әрсезләргә», оятсызларга киң юл ачуын Карун сизмичәрәк калган.

— Син аны беләсең, мака сар, — дигән Сабир ата, бирелгән сорауга җавап итеп. — Белмәсәң, син зирәк түгел, белеп тә белмәмешкә салынсаң, син — икейөзле.

Мондый сүз ишетеп Карун корт чаккандай сикереп торган, ярсып, ачуына буылып:

— Син!.. Син!.. — дигән.

Саилчегә аның нинди дә булса усал, ямьсез сүз әйтәсе килгән, ләкин үз алдында иелгән башны күреп, тынычлана төшкән. Каяндыр таш арасыннан, тау куышыннан килеп чыккан, акылга таман сынык картка ачулану, тупас сүз әйтү, бөек сар өчен түбәнлек булыр иде, әлбәттә.

— Мин кемме, нәрсәме? — дигән Сабир ата, мака сар тынычлана төшкәч. — Ялган сөйләсәм, башымны чаптыр, ялган сөйләмәсәм, әйтәсе сүземне тыңлап бетер, мака сар!

— Сөйлә, — дигән мака сар, ачуын йотып.

— Изге Карлы тау келәүлегендә, исәпсез-хисапсыз тау куышларының берсендә бер таш такта бар. Тактага язу язылган, — дигән Сабир ата. — Анда әйтелгән: Аклан илендә йөз елга бер тапкыр корылык, корылыктан соң ачлык килә, диелгән. Ачлык өч елга, хәтта җиде елга сузыла, диелгән. Корылык булыр алдыннан илдә каерылып иген уңар, җыеп алган ашлыкны кая куяр урын табылмас, диелгән…

— Тукта! — дигән мака сар Карун, бөтен йөзе белән балкып.

— Әйттем бит, син зирәк кеше, бөек сар! — дигән Сабир ата, чын күңелдән сөенеп, һәм, башка берни әйтмичә, борылып чыгып китмәкче булган.

Хәзер инде мака сарның моны тиз генә чыгарып җибәрәсе килмәгән.

— Ашыйсың, эчәсең киләдер, саилче ата? — дигән ул, үтә дә ягымлы итеп.

— Мин сиңа ашарга-эчәргә килмәдем, серемне әйтергә килдем, — дигән Сабир ата, түбәнчелек белән Карун алдында бил бөгеп.

— Ул борынгы тактадагы борынгы язуны синнән башка тагын укыган кеше бармы? — дигән Карун.

— Миннән башка аны беркем укый алмый, мака сар, — дигән Сабир ата, уйлангандай итеп.

— Андагы син әйткән сүзләрне тагын берәрсе беләме? — дигән Карун.

— Белә. Ул — син, — дигән саилче ата.

Мака сар Карун җиңел сулап куйган. Беркадәр эндәшми торганнан соң әйткән:

— Минем сарайда да бер язулы таш такта бар. Беркем укый алмый. Шуны син укый алмассың микән, Сабир ата? — дигән Карун.

Беренче мәртәбә ул аңа шулай исеме белән олылап «Сабир ата» дигән.

Язулы таш турында сүз чыккач, Сабир ата икеләнеп калган. Баш тартса, мака сар аның башын чаптырачак, баш тартмаса, анысын әлегә белеп булмый. Сабир ата шулайрак дип фикер йөрткән һәм:

— Син миннән дә зирәгрәк, мака сар, — дигән, көрсенеп.

Мака сар усал итеп көлемсерәп куйган.

Шул ук көнне Карун очсыз гына бәягә икмәк сатып ала башлаган. Бөтен илдән — еpoints ерактан, якыннан — башкалага ашлык төялгән кәмәләр, олаулар агылган. Мака сарның амбарлары, чокырлары, базлары ашлык белән тулган. Тиз арада Карун тагын бер амбар салдырган. Бер айдан анысы да тулган. Кешеләр гаҗәпкә калганнар. «Әле таш җыя, әле икмәк җыя — чыннан да акылы җиңеләйгәндер моның» дип уйлаганнар Аклан кешеләре. Ни өчен дигәндә, алар бит үзләрен беркайчан кайгы-хәсрәт, ачлык булмый торган илдә яшибез дип уйлаганнар. Йөз ел элек илдә корылык булуын, ачлык булуын алар, билгеле, башларына да китереп карамаганнар.

Икенче елны бәхетле Аклан иленә корылык килгән. Ул елны кыш көне дә, яз көне дә күктән бер тамчы яңгыр төшмәгән. Әүвәлгечә көн-төн кояш кыздырган. Елгалар, инешләр саеккан. Чәчкән иген тишелеп чык-

кан да, үсеп буйга китә алмыйча, катып калган. Корылыктан болыннарда үләннәр саргайган, агач яфраклары бөрешеп, куырылып калганнар. Беренче елны ачлык бөтенләй диярлек сизелмәгән — амбарларда, чокырларда әле былтыргы ашлык булган. Икенче елны ачлык сизелә башлаган. Өченче елны ачлык үзен бик нык сиздергән. Агачлар корыган, урманнарда киекләр, кош-корт калмаган. Терлек-туар кимегәннән-кими барган. Дүртенче елда бөтен илдә чын-чынлап ачлык хөкем сөргән. Акланда гына түгел, Кәмидә, Акайда, Килмәттә, тагын әллә кайларда ул елларда кешеләр, яңгыр теләп, әледән-әле күккә караганнар, әледән-әле елгаларны, инешләрне күзәтеп торганнар һәм, аллалар алдында үзләрен языклы санап, әле анда, әле монда корбан биргәннәр, келәү әйткәннәр.

Икмәкнең бәясе башта ике мәртәбә, аннан соң биш-алты, хәтта ун мәртәбә күтәрелгән. Ун мәртәбә күтәрелгәч, Карун икмәк сата башлаган. Бөтен Акланның алтын-көмеше, энҗе-мәрҗәне Карун сараена агылган. Аклан иленнән генә түгел, мака сарга ерак-еραклардан ач кәмәләр килгән.

Ачлык җиде елга сузылган. Җиде ел буена Карун икмәк саткан һәм менә шул елларда чын-чынлап баеп калган да инде ул. Тирә-яктан агылган байлыгы җир өстендәге, җир астындагы сарайларга сыймый башлагач, бу җир астын казып кереп, еракта, тирәндә, иркен итеп амбарлар салдырган һәм иген сатып алган барлык алтын-көмешләрен, барлык затлы әйберләрен шул амбарларга, чүлмәкләргә тутырткан.

Дөрес, боларның барысы да имеш-мимеш кенә. Сабир ата белән Карунның сүз көрәштерүе дә имеш-мимеш. Ләкин монда шунысы хак: атаклы Сабир ата — Карун заманында, атаклы Карун Сабир ата заманында яшәгән. Сабир ата чыннан да бер мәртәбә Түгәрәк таудагы изге сарайда — Карун янында булган. Акланда йөз елга бер мәртәбә корылык, корылыктан соң ачлык булуын да ул әйткән.

Кайберәүләр әле һаман мака сар Карунны комсыз булган, ач күз булган, катмыш-саран булган дип яратмыйча сөйләсәләр дә, Карлы тау келәүлегендәге изгеләр аны бары яхшы яктан гына телгә алалар. Ни өчен дигәндә, мака сар Карун Карлы тау келәүлеге өчен күптин-күп изгелекләр эшләгән. Карунга кадәр келәүлекнең җире бик аз булган, мака сар келәүлекнең җирен арттырган, иркен тигез үзәнлекне бүлеп биргән. Аннан

соң келәүлекне биек таш койма белән әйләндереп алган. Элегрәк, Карунга кадәр, келәүлекнең җире һәр яктан ачык булган чакта, изгеләрнең байлыгы күптер дип, Карлы тауны әледән-әле диңгез юлбасарлары талап китә торган булганнар. Элегрәк бит Акланның яр буйларында кәмәле, кораллы сакчылар йөреп тормаган. Теләсә каян килеп чыккан диңгез юлбасарлары, берниндн каршылыксыз ярга чыгып, ярга якын теләсә нинди авылны, торакны талый, яндыра алганнар. Келәүлекне биек койма белән әйләндереп алгач, мондагы кешеләр аллаларга зекер әйтеп, иркенләп, тынычлап яши башлаганнар. Тагын шул, мака сар Карун Карлы тау келәүлегенә ярашлы итеп төп капка баганасына юсык яздырган. Элегрәк келәүлеккә кайчагында хатын-кызлар да аяк баса алган булса, моннан соң монда хатын-кызның аяк басуы тыелган. Шул ук вакытта келәүлеккә «азил» хокукы бирелгән. Диңгездә һәлакәткә очрап исән калган кешеләр, качкын коллар, җинаятьчеләр тәүлекнең теләсә кайсы вакытында килеп капка кага алганнар һәм аларны берсүзсез келәүлеккә кертергә тиеш булганнар. Капка ачып кергән һәркем монда изге санала башлаган.

Аннан соң, көне-төне яна торган нәфит утын да Карун яшь чагында җайлап куйдырган, дип сөйлиләр. Очлы кыя башындагы түгәрәк көн өен дә, кыялардагы баскычларны да, тагын әллә нинди куышларны да шул ук заманнарда ясаганнар, имеш. Тау тарлыгы каршындагы буар елан да әле яшь булган, бала гына булган. Ул шундагы таш-тау арасыннан шуышып чыккан да болын уртасындагы яшь туйрага уралган. Кешеләр моны күреп алганнар һәм таяк тотып үтерергә килгәннәр. Шул чакны көпә-көндез күк күкрәгән, яшен яшьнәгән, кайдадыр якында гына тау башыннан ташлар ишелеп төшкән. Кешеләр куркып качыша башлаганнар. Имәнгә уралган еланның изге ия булырга тиешлеген Сабир ата шундук чамалап алган һәм икенче көнне, таң атар-атмас торып, агач күбәтәгә баллы сөт салып, зекер әйтеп, буйсынган кыяфәттә буар елан янына киткән. Имән янына Сабир ата килгәч, күк тә күкрәмәгән, яшен дә яшьнәмәгән, шулай ук тау-ташлар да җимерелмәгән. Имәнгә уралып яткан елан, башын күтәреп, Сабир атаны каршылагандай җиңелчә генә ысылдап алган һәм күбәтәдәге баллы сөтне эчкән дә, «рәхмәт» дигән сыман, тагын бер мәртәбә ысылдаган да, шуышып шундагы ташлар арасына кереп киткән. Көн дә иртән аңа баллы сөт бирү менә шуннан калган.

Мака сар Карун, байлыкка алданып, комсызлык юлына басса да, шулай да әле ул алланы бер дип белгән һәм ничек тә изгеләр сүзеннән чыкмаска тырышкан. Аның заманында Изге анабыз, Изге атабызга багышлап корбан, садака бирүләр дә, келәүлекләрдә келәү әйтүләр дә, зекер әйтүләр дә тукталмаган. Аннан соң мака сар Карун байлыгының уннан бер өлешен ярлыларга, ятимнәргә һәм Акландагы келәүлекләргә, каравыл өйләренә, им өйләренә, ир өйләренә биреп барган. Ачлык елларында икмәген кыйммәт бәягә сатса да, күптәнге тәртипне, юсыкны бозасы килмичә, турадагы ачларга бушлай икмәк тараткан.

Үзеннән соң килгән сарлар белән чагыштырганда, мака сар Карун, беләсегез килсә, алланың иң изге бәндәсе булган. Җир астына салынган амбарларындагы байлыгын да ул үзе өчен түгел, Аклан өчен, иле-көне өчен җыйган. Йөз елга бер килә торган ачлык кебек бөтен илгә килә торган кырап килүе ихтималын күз алдында тотып җыйган. Бит ул чакларда Аклан әле артык көчле булмаган, бай булмаган. Тирә-якта, диңгезләрдә көнчел күршеләр, кыргыйлар, диңгез юлбасарлары тыз-быз йөргәннәр, таларга, яндырырга, ватарга-җимерергә җай чыгуын көтеп кенә торганнар.

Карагыз әнә бүгенгеләрнең эшенә, кыланышына. Ниләр генә эшләмиләр дә ниләр генә кыланмыйлар алар! Алтын-көмеш сарайларда яшиләр, балда-майда йөзәләр. Аллаларны, изгеләрне оныттылар, ярлы-ябагайны кешегә дә санамыйлар. Бөтен ил, алар өчен бил бөгеп, ирекле баштан кол хәленә төште. Аларга көн дә бәйрәм, көн дә туй. Көне-төне күңел ачалар да чагыр эчеп уйнаш кылалар. Анысы гына җитмәгән, Түгәрәк таудагы Салкын чишмә белән Кайнар чишмәне, таш киртә белән әйләндереп алып, ил-көн күзеннән ябып куйдылар. Турадагы аксөякләр өенә көпшәләрдән кайнар суы да, салкын суы да килеп тора. Үзләре юынудан, атларын, хатыннарын, балаларын коендырудан калган суларын оятсызлар бакчаларга җибәрделәр. Шуны алар турыдан-туры чишмәләрдән килә дип аңлаталар. Чишмәләр киртәләп алынгач, ул суларның каян килгәнен үз күзләрең белән күрмәгәч, ничек ышанмак кирәк моңа?

Түгәрәк таудан чыга торган шифалы Салкын чишмә белән Кайнар чишмәдән башка тагын икенче бер чишмә дә булырга тиеш бит әле. Анысы — Изгеләр чишмәсе. Ту әниебез Дикә белән Ту атабыз Минне кавыштырган

чишмә. Ту әниебез Дикәнең кабак савыт күтәреп суга йөргән чишмәсе. Ул кайдадыр шунда, Түгәрәк тау буенда, диңгез ярына якын җирдә булган, диләр. Ту атабыз Мин беренче мәртәбә Ту әниебез Дикә белән очрашкан төшкә үз кулы белән сырлап-бизәп таштан куыш ясап куйган, куыш эченә, чишмә өстенә шулай ук үз кулы белән ясап, Ту әниебез Дикәнең таш сынын утыртып куйган. Гомер-гомергә Аклан кешеләре Изгеләр чишмәсенең суын эчкән. Салкын чишмә белән Кайнар чишмә генә шифалы булмаган, Изгеләр чишмәсе дә шифалы булган. Беркайчан монда кеше өзелеп тормаган. Аклан иленең, биләмәләренең барлык төбәкләреннән монда Ту әниебез Дикә, Ту атабыз Мин рухына багышлап корбан бирергә килгәннәр. Монда шулай ук авырулар, гарип-горабалар да килгән. Аксаклар таякка таянып килсәләр, үз аяклары белән кайтып китә торган булганнар. Изгеләр чишмәсеннән бер-ике тамчы су эчү белән, яраланган, җәрәхәтләнгән төшне чылату белән, сукырлар күрә башлаган, саңгыраулар ишетә башлаган, бөтен яралар күз алдында төзәлеп юкка чыккан. Килгән бер кеше чишмәгә көмеш тәңкәләр салып китә икән.

Хәзер боларның берсе дә юк. Ни өчен дигәндә, чишмә юк. Изгеләр чишмәсе юк. Аннан да бигрәк, Изгеләр чишмәсенең кайдалыгын белүче дә юк. Алай гына да түгел, кайберәүләр хәтта Ту анабыз Дикәне, Ту атабыз Минне дә онытып бетергәннәр.

Менә шундый эшләр. Бөтен дөньяга атаклы Аклан йортында, илнең үзәгендә, турада, көпә-көндез дигәндәй чишмә югалган. Әллә үлән басып киткән, әллә тау-таш җимерелеп, таш астында калган, әллә инде Җәпәй йоткан.

Чишмәнең онытылуына, югалуына үз вакытында пошынучы да булмаган, ахрысы. Бит дөньяда башка төрле кайгылар, борчулар да булып тора. Аклан иленең төньягыннан бик зур яу килгән, сугыш каты булган. Каяндыр салкын яклардан, Буран иленнән кубып чыккан һәм Изге утрауга каршы корал күтәрергә батырчылык иткән ак тәнле, аксыл-саргылт чәчле, сусыл-зәңгәр күзле кыргыйларның берсен калдырмый турап диңгезгә тутырганнар. Аклан ягыннан да үлүчеләр шактый күп булган. Күрәсең, яу белән мавыгып, кешеләр үзләренең изге аталарын-аналарын, йолаларын исләреннән чыгарып ташлаганнар.

Ни булса булган, Изгеләр чишмәсе югалган. Ту анабыз Дикәнең сыны да, чишмәсе дә юкка чыккан.

Беркадәр вакыттан соң чишмәнең югалуына игътибар иткәннәр, эзләнә, төпченә башлаганнар, картрак, хәтерлерәк кешеләрдән сораштырып караганнар. Шуннан соң галимнәрдән сораганнар. Аклан илендә, изгеләр илендә Изге чишмәнең кайдалыгын әйтеп бирерлек бер генә кеше дә табылмаган. Нинди хурлык!

Аның Түгәрәк тау астында, диңгез яры буенда булырга тиешлеген һәркем чамалаган, ләкин төгәл итеп әйткәндә, кайда, кайсы төбәктә — беркем белми икән. Кайбер кыюраклар, башсызраклар алтын койма белән уратып алынган һәм аркылысы-буе берәр чакрым чамасы булган Түгәрәк тау ягына да үтеп кергәннәр. Анда аларны, билгеле, шундук кулга алганнар. Ни генә булмасын, анда капкадан түгел, койма аша үтеп кергән беркемнең дә кире чыга алганы юк әле.

Бит алла тарафыннан утыртылган язулы баганада Аклан йортының ун биләмәгә бүленгән булуы, унның һәркайсы үзенчә яшәргә, унның берсе икенчесен кол итмәскә, түбәнсетмәскә тиешлеге, тик шулай да олы киңәштә унның тугызы ага сүзенә, ягъни мака сар сүзенә колак салырга тиешлеге турында әйтелгән. Изге атабыз исәпләгәнчә, Аклан патшалары гына түгел, җирдәге барлык илләр, барлык патшалар, шулай олыны олы итеп, кечене кече итеп, үзара тату яшәргә тиешләр.

Анысы шулай. Һәркем үзенчә яшәргә тиеш. Мака сар Карун, турыдан-туры алла теләгенә каршы бара алмаганга күрә, күңелендәге хыялларын хәтта ялгыз чагында да кычкырып әйтергә курыкса да, эше-гамәле аның барыбер көфер булган. Иблис юлына кереп киткәч, Карун хәзер һич тә комсызлыгын тыя алмаган.

Шуннан соң күпләр моңа кул селтәделәр. Соңгы елларда Изге чишмәне, Изге ананы, Изге атаны хәтта искә дә төшерми башладылар.

Ләкин көтмәгәндә, былтыргы яз Аклан илендә Мәсәви дигән бер исем ишетелә башлады. «Үлсәм үләрмен, Изге чишмәне барыбер табармын!» — дип әйткән, ди, ул, имеш.

## II

Иртән-иртүк еракта, шәүлә генә булып күренгән күксел таулар арасыннан көндәгечә көлеп-елмаеп кояш чыгу белән, агачларда кошлар, җирдә кортлар, бөҗәкләр уяну белән, Актау юлында бер саилче күренде. Төнне ул олы юлдан читтә зур гына калкулык итәгендә куй көтүләре янында үткәрде. Кичәгенәк кичкырын эңгер-

меңгер төшә башлаган бер вакытта, якында гына ят кеше исен сизеп, көтүчеләрнең усал этләре алып-биреп өрергә тотындылар һәм, барысы бердәм кубып, ят кешегә каршы ташландылар. Көтүчеләр сагая калды. Ни булыр бу? Кем булыр бу? Ләкин алар аны-моны искәреп өлгергәнче, этләр тынып калды, берсе — Өрек дигәне — хәтта, кире борылып, хуҗалары янына килә башлады. Шул ук вакытта кичке эңгердә теге ят кешенең нидер кычкырганы ишетелеп калды. Ул әлеге этләргә кычкырды ахры. Этләр исә, аның шул кычкыруына буйсынып, өрүләреннән туктап калдылар бугай. Монысы инде бик тә гаҗәп иде. Бүрене бугазлый ала торган этләрне дә буйсындыра, юашландыра ала торган нинди кеше ул? Ни кычкырды ул?

Күп тә үтмәде, ят кеше үзе күренде. Кыскарак буйлы, төз гәүдәле, шәрә тәнле чандыр гына бер карт иде бу. Уң кулында — таяк, сул ягында — күн янчык, билендә — иске генә алъяпкыч. Озын аксыл чәчләре таралып иңбашына салынып тора. Артыннан, яныннан башларын иеп, койрыкларын болгап ялагайланып этләр килә. Туктале тиле-миле... изге Мәсәви түгелме соң бу? Кошларның телен белә, этләрне түгел, арыслан-киекне тез чүктерә, дип сөйлиләр иде, чын микәнни? Менә хикмәт! Үзе карт, үзе яшьләрдән яшьрәк, дәртлерәк. Каядыр барып җитәргә ашкынган кебек, кызу-кызу атлап килде дә бу көтүчеләргә ике-өч адым кала кырт туктап җиргә чүкте, тезләнде һәм, кулындагы таягын биленә таба шудырып, ике учын битенә якын китерде һәм югары карап зекер әйтте:

— Илгә — иминлек, сарга — байлык! — диде. Бу аның бердәнбер зекере иде, ул башкача зекер әйтә белми иде бугай.

— Шулай булсын! Амин, — диделәр көтүчеләр, теләртеләмәс кенә.

— Кичкә калгансың. Курыкмыйсың да үзең, Мәсәви баба, — диде шунда яшьрәк бер көтүче.

Саилче башын калкытып яшь көтүчегә карады, шомарып беткән таягын яңадан учына алды да җиңел генә аягына басты.

— Учагың ягылганмы? — диде.

— Учак ягылган, түрдән уз, Мәсәви баба. Карама юкбар сүзгә, — диде көтүчеләрнең өлкәнрәге.

— Түрең күренми, — диде Мәсәви баба һәм үз-үзеннән канәгать булып көлеп куйды.

Шуннан соң ул таягын селкеп алды. Шул чакны,

якындагы сарык-бәрән тавышларын күмеп, чыңлаган, чылтыраган, шакылдаган тавышлар ишетелеп китте. Мәсәвинең таяк башына, җепкә бәйләп, җиз, бакыр кисәкләре һәм аллы-гөлле тасмалар бәйләнгән иде.

Көтүчеләр, изге картның хәтерен калдырудан курыккан сыман, артык сүз куертып тормыйча, агыл ягына кузгалдылар. Анда инде бер-ике көтүче, туктаусыз кычкырып, нидер таләп иткән һәм бөтен тирә-якка ачы-төче исләр аңкыткан куйларын, сарыкларын капкадан куалап кертеп яталар иде. Агылга терәп салынган, киселмәгән, шомартылмаган ташлардан өелгән иркен куыш уртасыннан теләр-теләмәс кенә төтен чыгып тора иде. Мәсәви баба, беркемнең әйтүен көтмәстән, туры куышка юнәлде. Көтүчеләр капкадан кереп бетмәгән терлекләрне кертеп бетерделәр дә йомры агачлардан әмәлләнгән капканы ябып куйдылар. Агылның эчке ягында калган көтүчеләр, учак янына, басылып, искереп беткән чыптага килеп утыргач, Мәсәви баба янчыгын алып читкә куйды, таягын исә ике куллап тотты да учактагы утка карап тынып калды.

— Таягыңны бер дә кулыңнан ычкындырмыйсың — урларлар дип куркасыңмы әллә? — диде бер яшь көтүче, шаяртмакчы булып.

— Анабыз Дикәдән көлмә, — диде Мәсәви баба, җитди итеп.

Куыштагы көтүчеләр бер-берсенә карашып алдылар. Чынлап сөйлиме соң бу, шаяртамы югыйсә?

— Бу... Дикә анамыни? — диде яшь көтүче, йөзенә бәреп чыккан шаянлыгын томаларга тырышып, һәм, аның чыннан да Дикәме-түгелме икәнлеген белмәкче булган сыман, Мәсәви бабаның таягына якынрак килде.

— Ас анабыз Дикә, — диде саилче, тантаналы итеп. — Менә чәче, менә алкасы, муенсасы.

«Чәче» дигәндә ул аллы-гөлле тасмаларга катыпкорышып беткән бармак битләре белән кагылып алды, «алка» дигәндә — җиз кисәкләренә, «муенса» дигәндә таш, тәтәй кисәкләренә кагылгалады. Көтүчеләр янә үзара карашып алдылар, ләкин беркем дә тиле-миле саилчедән көләргә батырчылык итмәде. Бары яшь көтүче генә бәйләнчек чебен кебек һич тә тынычланырга теләмәде һәм, таяк «башы»на үрелеп, шулай ук «Дикә ана»ның чәчен, алкасын, муенсасын тотып карамакчы булды. Мәсәви баба шундук таягын тартып алды.

— Тотынма, кулың юылмаган, — диде ул аңа, тупас кына.

Барысы да тынып яшь көтүчегә карадалар.

— Сезнең дә чишмәгез тау башыннан агып төшә икән, — диде шул чакны саилче, тора салып.

— Тау башыннан дисәң дә ярый... Шунда, якында гына, бер зур таш астыннан чыга ул, — диде өлкән көтүче. — Төне-көне чанга агып тора. Шуннан сугарабыз.

— Анабыз Дикә кабак савыт белән су алган чишмә тау астында булган, төшә торган таш баскычлары булган, баскычлары ашалып беткән. Чишмә янында баскыч сыман таш юкмы? — диде Мәсәви баба.

— Син теге... Изге чишмәне әйтәсеңдер, Мәсәви баба, — диде өлкән көтүче, уйчан гына. — Минем дә ишеткәнем бар аны. Безнең чишмә аңа туры килми. Анда бернинди таш баскыч та юк, утырып ял итеп алырдай таш та юк. Җайсыз җирдән чыга ул.

— Үләр алдыннан әннәкәвем әйтте: Ту әниебез Дикәгә багышлап садака бирермен, дип, яшь чагымда нәзер әйткән ием, диде. Биралмадым. Изге чишмәнең кайдалыгын белүче табылмады, диде. Нәзерем синең өстә кала, эзлә, тап, көмеш йөзегемне Изге чишмәгә тапшыр. Сүземне үтәмәсәң, миңа тынгы булмаячак теге дөньяда, диде. Менә шуны эзлим. Изге чишмәне. Алай-болай ишетелгәне юкмы бу тирәдә?

— Юк, ишетелгәне юк, Мәсәви баба, — диде өлкән көтүче, уйчан гына. — Мин дә уйлыйм аны еш кына. Үзебезнең чишмәне дә әледән-әле карап, тикшереп торам. Бу тирәдәге кешеләрдән дә сорашканым бар — бу якта булмаган ул. Диңгезгә якын җирдә булган. Атабыз Мин кәмәгә утырып килгән дә кәмәсен яр буенда калдырган. Якында гына чишмә агып яткан. Анабыз Дикә шунда су алырга килгән. Ишеткәнем бар. Диңгез монда ерак. Түгәрәк калкулык та юк бу тирәдә. Монда булмас ул, Мәсәви баба.

— Юк сүздер ул — бернинди Изге чишмә дә булмаган, Дикә дә, Мин дә булмаган, — диде шул чакны яшь көтүче, сүзгә катышып.

Ашап утырганда бу шундый көтмәгәндә һәм тупас рәвештә әйтелде ки, көтүчеләр дә, саилче дә ашауларыннан туктап калдылар.

— Телең корыр, сүләнмә! — диде Мәсәви баба, усалланып.

— Булмаса, ил-көн сөйләмәс иде, — диде өлкән көтүче, шулай ук яратмыйча.

Көтүчеләр куышында сүз төн урталарына кадәр дәвам итте. Учакка утын кертеп өстәделәр дә, урын җәеп-ни-

теп тормыйча, шунда учак тирәсенә ничек туры килде, шулай ятып йокыга да киттеләр.

Мәсәви баба көтүчеләр белән бергә торды, бергә ашады. Көтүчеләр мал-туар янына агылга керделәр, саилче, таягына таянып, яңадан олы юлга чыкты. Тигез итеп таш җәелгән олы юл сар каладан төньякка — Актау якларына сузыла һәм, үзәннәр, калкулыклар аша үтеп, текә тау сыртларына бер менеп, бер төшеп, Актау артындагы диңгез ярына барып чыга иде. Олы юлдан як-якка таррак юллар китә. Алар, шулай ук яшел үзәннәр, калкулыклар аша үтеп, ак, кара, кызыл ташлардан матур итеп салынган биек туралар, калалар, салалар, авыллар ягына барып чыгалар, яңадан каядыр еракка күксел кырлар һәм башы болытларга тигән таулар ягына үрмәлиләр. Анда да шаулап елгалар, челтерәп чишмәләр ага. Анда да ялгыз келәүлекләр, Изге атабыз, анабызга багышланган каравыл өйләре бар, таш багана утыртып куелган изге сыннар бар...

Мәсәви төрле җирдә булды. Юл кая китә, шунда барды, кайда туктый, шунда туктады. Кешеләр белән танышты, сөйләште. Ашатсалар, ашады, кундырсалар, кунды, тыңласалар, атабыз Мин, Ту анабыз Дикә турында сүз башлап җибәрде һәм җайлап кына сүзне Изге чишмәгә китереп ялгады. Кайберәүләр аны бик бирелеп тыңладылар, кайберәүләр теләр-теләмәс кенә тыңлады. Кайда гына булмасын, кем белән генә сүз башлап карамасын, беркайда Мәсәви эзләгән нәрсәсенең эзенә төшә алмады. Аның, билгеле, күңеле кырылды. Шундук ул сүзне икенчегә борды, хак диннең онытыла баруыннан зарланды. Мондый зарларга да теләктәшлек белдерүчеләр әллә ни күп булмады. Иң ахырда ул изге таудагы алтын-көмеш сарайларда яшәүче, байлыкны үз кулларына алып, балда-майда йөзүче аксөякләрне искә төшерде. Алар турындагы имеш-мимешләрне кабатлады. Фәлән кеше фәләннең яшь чибәр хатынын аертып алган икән. Фәлән сатучы мака сар кызының алтын сынын ясаткан икән дә шуны сарга бүләк итеп биргән икән, диде. Беләсезме күпме тарткан мака сар кызының алтын сыны? Төп-төгәл ярты батман, ди. Шуның өчен мака сар фәлән сатучыга диңгезгә якын җирдә, арык тамагында, басма күпер төзетергә ризалык биргән, ди.

Шундыйрак имеш-мимешләрне Мәсәви үзе дә тәмләп-тәмләп сөйләде, тыңлаучылар да бик теләп тыңладылар. Алтын-көмеш турында сүз чыктымы, һәркемнең колагы үрә торды, күзләрендә дәрт һәм очкын кабын-

ды. Мәсәви баба бик яхшы белеп торды — талап, алдап алган, урлап алган байлыкны, ләззәтне сүздә беркем хупламады. Кем генә булмасын, аллаларны онытып, үз рәхәте өчен генә яшәгән аксөякләрне хурларга, гаепләргә тырыштылар. Ләкин күңеленнән һәркемнең нәкъ менә шундый бозык, комсыз, бай һәм бәхетле кеше буласы килде.

Көне-төне юлда булган, көне-төне изгелек чыганагын эзләгән саилче мондый чакта кешеләргә нәрсә әйтсен? Ул бары авыр итеп көрсенде дә тынып калды һәм шуннан соң бөтенләй сөйләшмәс булды. Аңлаган кеше аңлады, аңламаганы авызын ерып юк-бар нәрсә лыгырдады.

Көтүчеләр яныннан чыгып, олы юлга төшкәч, Мәсәви баба таягын җәя сыман итеп аркасына асты да, ике кулын селтәп, җиңел генә элдерә башлады. Юл буена ул уйланып барды. Әле генә төн кунып чыккан куыш турында, көтүчеләр һәм алар белән сөйләнгән сүзләр турында уйлады. Аннан соң кичә, өченче көн кунган кешеләр һәм алар белән сөйләнгән сүзләрне исенә төшерде. Кояш күтәрелгәннән-күтәрелә барды, көнне җылыта, ныграк яктырта барды. Иртәнге салкынлык юкка чыга барган саен, никтер уйланасы да, элеккеләрне искә төшерәсе дә килмәде. Хәзер инде уйланыр уйлар да, хыяллар да калмаган иде бугай. Дөньяда инде ул күп яшәде. Аның өчен хәзер монда бернинди сер дә калмады кебек. Изге чишмәне исәпләмәгәндә, әлбәттә. Кайчагында аның да бернинди сере юктыр кебек. Кайчагында аның да барысына да кул селтисе, юл буенда берәр күләгәгә кереп ятасы да беркайчан тормаслык итеп йокыга таласы килә. Арыды, ялыкты инде ул. Туйды, җиләде бу дөньядан. Бары шул Изге чишмә генә йөртә бугай аны. Шул гына — Ту эниебез Дикә генә әйдәп, омтылдырып, нәрсәгәдер ымсындырып йөртә бугай аны.

«Кайтырга да кирәк» дип уйлады ул бераздан. Туптуры олы юл белән турага кайтып китәргә кирәк. Бу тирәдә бернинди чишмә дә юк, ни дә юк. Мондагы чишмәләрне ул инде элегрәк тә карап-тикшереп үтте. Арытты. Аяк атлар хәле дә калмады. Гел җәяү бит. Таугa мен, таудан төш. Әнә байлар яхшы ат җигелгән кәрендәсләргә утырып кына йөриләр, кәрендәскә утырмаганы атланып йөри.

Чыннан да шул чакны каршыга олы юлдан кызу чабып килгән атлар күренде.

Ике тәгәрмәчле кәрендәскә, аякларын аерып, ике яшь ир кеше баскан иде. Яшь ирләрнең берсе ике куллап

дилбегә тоткан, икенчесе уң кулын аның иңбашына салган. Яшь, кара тере чәчләре җилдә җилферди, күкрәкләр таза, беләкләр нык. Билләрендә — садак, аяк асларында, кәрендәстә — җиз калканнар. Кая баралар болар бу вакытта? Нинди яшьләр, нинди кыюлар!

Мәсәви саилче шулайрак дип уйларга өлгергәнче, атлы-кәрендәсле яшьләр җилдәй җилеп килеп тә җиттеләр. Мәсәви тиз генә читкә тайпылды, ашыгу-кабаланудан кинәт егылып китте һәм юл читендә егылган килеш яшьләрнең артыннан карап калды. Таулар ягына ауга баралар булыр дип уйлады ул. Шул ук вакытта диярлек арттан тагын шаулап, һай-һулап килгән атлы яшьләр күренде. Мәсәви карт, урыныннан тормыйча, боларын да күзе белән озатып калды. Ул хәтта алар арасындагы бер-ике яшь егетне танығандай да булды. Узып барышлый гына, әллә танып, әллә танымыйча болай тиеләнеп кенә, аңа да кул болгап, нидер кычкырып үттеләр.

Карт саилче шәп, көчле яшьләр артыннан озак кына карап утырды да, торып, яңадан кузгалып китте. Нишләптер аның хәзер диңгез буендагы үзәнгә, үзән уртасындагы алтын сарайлар ягына түгел, әлеге яшьләр артыннан Актау иле якларына, таулар-кыялар һәм калын урманнар ягына китәсе килде. Ләкин күн табанлы чабаталы аяклары, алмаш-тилмәш атлап, аны һаман шат яшьләрдән ары алып китте. Шул чакны юлның сул ягында түгәрәк итеп юнылган акташ багана — чакрым баганасы чалынып калды. Изге турага — мака сар турасы каласына — төп-төгәл илле чакрым калган иде. «Илле чакрымны бер көндә кайтып булмас» дип уйлады Мәсәви карт үзалдына. Тагын берәр җирдә төн кунарга туры киләчәк. Бу юлы ул «кайда кунарга?» дип баш ватып тормады. Моннан унбиш чакрым ераклыкта уңга тагын бер юл китәчәк. Анда, фәлән авылда, аның бер танышы бар. Яшьрәк чагында, бу якларда йөргәндә, ул анда ешрак керә торган иде. «Нәрсә, яшьләргә, аксөякләргә генә шау-шу килеп шәпләнеп йөрергә дигәнме әллә? Без дә төшеп калганнардан түгел әле! — диде ул үз-үзенә, күңеле күтәрелеп. — Яшь булмасак та, бер дә алардан ким дә түгел».

Күңеленнән шулай шәбәйсә дә, баштарак җиңел атласа да, кояш югары күтәрелеп көнне кыздыра барганда саилче арый, йончый башлады. Юлда аңа тагын берике атлы-арбалы җайдак очрады. Алар барысы да яшьләр, тазалар иде, барысы да кәрендәскә утырып ба-

ралар һәм нишләптер барысы да саилче барган юнәлештән кирегә баралар иде. Яхшы атларга утырып барган шәп яшьләр кала ягына барсалар да, барыбер аны — таяклы, янчыклы, йончыган, өтәләнгән саилчене — үзләре янына утыртып алып бармаячакларын ул бик яхшы аңлады. Каршы очраган яисә арттан куып җитеп выжт кына узып киткән атлы, арбалы, көчле, бәхетле кешеләрне инде ул үз гомерендә күп күрде. Аларның барысы да бер — алар каядыр ашыгалар, кемнедер, нәрсәнедер куып җитәргә, тотып алырга, үзләренеке итәргә тырышалар. Бер үк юнәлештә барсаң да, алар белән барыбер юллар капма-каршы якта була.

«Дәмия дә картайгандыр инде. Онытып та бетергәндер», — дип уйлады ул, яшь чакларын исенә төшереп. Исән микән, түгел микән — кем белә аны? Аннан соң, аны анда бик үк көтеп тә тормыйлардыр. Урак җитте. Кызу эш вакыты. Әнә юлның кайсы ягына карама, үзәннәрдә, иген кырларында ашлык уралар, ашлык ташыйлар. Аларда хәзер синең кайгың юк. Көтүчеләр генә киң күңелле.

Кырыгынчы чакрым баганасын узып киткәч, тигез итеп таш җәелгән туры юл Тирән елгасына якынайды. Елга буенда күпереп, зур булып үсеп утырган күләгәле яшел агачларны, куе куакларны, биек агачлар, куаклар арасындагы ак-кызыл, кара ташлардан матур итеп салынган җыйнак йортларны, каралты-кураларны, яшел чирәмдә чабышып йөргән бозауларны күреп, саилченең күңеле күтәрелә төште. Көянтә сыман сыртын кабартып ятучы таш күперне чыккач, уң якта Саба авылы булырга тиеш. Сабада саилченең Сәрмиядәге Дәмиясе кебек үк якын кешесе булмаса да, шулай да бу авыл да аңа яхшы таныш. Аның монда сугылмый узганы юк. Кешеләрен дә, тирә-яктагы чишмәләрен дә биш бармагы кебек белә. Эшчәннәр, тырышлар, байлар. Ләкин бераз гына корыраклар. Олы юл буенда булгач, саилче дә, килүче-китүчесе дә күптер инде.

Саилче Мәсәви түбәндә шаулап аккан елгага каранакарана юл читенә чыкты, таныш сукмактан яр астына төште. Ташлы яр буенда агым суда кер чайкаган бер хатыннан башка беркем юк иде. Хатын күлмәк итәген бил турысыннан ук күтәреп кыстырып куйган да, тездән эттәре су эченә кереп, ике куллап авыр керен уңга-сулга йөртеп чайкый да чайкый. Саилче елга буена төшкәнче аны күрмәгән дә иде. Кинәт үзенең күз алдында шундый күренешкә тап булып, ул башта каушап-апты-

рап калгандай булды. Хатын яшь иде. Матур булып кояшта янган тулып торган аяклары, беләкләре таза һәм нурлы иде. Саилче үзенең барлыгын белдереп тамак кырды, хатын ягына бик үк карамаска тырышып, шулай да аяк астындагы вак ташларга абына-сөртенә узып китте дә, «куркыныч» төшне үткәч, сүз кушарга кирәк тапты.

— Илгә — иминлек, сарга — байлык! — диде. — Эшең авыр икән. Дикәбез куәт бирсен, килен.

Кер чайкаучы хатын, якында гына ниндидер тавыш ишетеп, билен турайтты, әйләнеп карады һәм, үзенә сүз катучының кемлеген күреп, берни әйтмичә яңадан керенә тотынды.

— Эшең бик тыгыз икән! — диде саилче, хәтере калып.

Хатын барыбер җавап кайтармады, кызу-кызу чайкавында булды.

— Саилчегә эндәшмәү — киберлек. Саилче — алла бәндәсе, — диде Мәсәви, аңсыз хатынга аңлатырга кирәк табып. — Каргасам, мәңге үкенерсең, килен!

— Яшь балам йоклап калды. Ул уянганчы кайтып җитәргә кирәк, Мәсәви баба, — диде хатын, җавап бирергә кирәк табып.

Хатынның йомшый төшүе, җитмәсә, исеме белән эндәшүе саилченең күңеленә хуш килде. Артык бәйләнеп тормыйча, ул ары китеп барды, куе куләгәле куак янына барып утырды да таягын, күн янчыгын җиргә куйды, күн чабатасын салды һәм аякларын сузып җибәрде. Якында гына су исе, яшел агач исе һәм басулар ягыннан өлгергән ашлык исе килде. Су буенда рәхәт, бик рәхәт иде. Саилченең чишенеп суга керәсе, коенасы, коенгач бераз ял итеп аласы килде. Ләкин якында гына кер чайкаучы хатын никтер аңа комачаулый сыман тоелды. Ул хәзер аңа арты, аркасы белән түгел, ян-ягы белән күренә иде. «Эшен бетереп китсен инде», — дип уйлады саилче һәм, хатын киткәнне көтеп, су буендагы ташлыкка сузылып ятты. Яткач та ул әледән-әле хатын ягына күз төшереп алды. Яткач, кер чайкаучы хатын башкачарак, алгы яктанрак күренгәндәй булды. «Яшь тә, чибәр дә икән» дип уйлады саилче. Яткан килеш ул көрсенеп куйды. Яшьләр, чибәрләргә шул читтән генә карыйсың инде. Сәрмиягә барып җитсә, Дәмияне күрә алса, аңа шул җиткән. Көтүчеләр дә әнә үзләре белән хатын-кыз йөртәләр. Аның гына юк. Гомергә ялгыз. Ялгызын ялгыз, шулай да менә рәхәт. Талгын гына җил исә, кояш кыздыра, кошлар сайрый. Якында гына

өйләр, кем ничек яши инде. Саилче — алла бәндәсе. Саилче...

Шулай ята торгач, ул йоклап киткәнен сизми дә калды. Берзаман күктән, болытларданмы, кошлар сайраган, агач башыннанмы килгән кебек булып, колак төбендә генә ягымлы һәм якын бер тавыш ишетелде. «Мәсәви ага! Мәсәви ага!» — диде кемдер, яратып, өзгәләнеп. «Дәмия бугай» дип уйлады саилче, үзенең Сәрмия авылына барырга тиешлеген исенә төшереп. Ул чакыра, ахрысы. Кире уйлаганны белде дә, чакыра әнә, кил, ди, йоклап ятма, ди. Ләкин шул ук вакытта бу Дәмия дә түгел, теге күпер янында кер чайкаган хатын да кебек.

Ярым уяу килеш ул шулай уйлангалап ята бирде, күз кабагын кузгатты, ләкин күзен ачасы килмәде. Күзен ачты исә, янында беркем юклыгын күреп, күңеле кырылачагын ул бик яхшы аңлады. Ягымлы, йомшак тавыш тагын ишетелде. Бу юлы бу тавыш саилчегә өндәге сыман тоелды. Ирексездән ул күзләрен ачты һәм якында гына чүгәләп торган теге кер чайкаучы хатынны күрде, аптырап китте. Хатын баягыча чыланган һәм ярым шәрә түгел иде. Өстенә ул озын итәкле, кыска җиңле яңа күлмәк кигән. Изүе ачык, муенында өч катлы муенса. Күлмәк итәге белән тезен каплаган, тезләрен җыя төшкән. Шулай да күлмәк аша ымсындыргыч сылулык, байлыгы — бары таза, төгәл сынлы хатыннарда гына була торган гүзәл байлык булуы бөркелеп тора иде. Саилче, көзән җыергандагы кебек, ирексездән бөтен тәне белән куырылып куйды. Нишләгәнен үзе дә аңламыйча, кулларын сузып хатынга таба омтылды. Аның аны хәзер кочып аласы, яратасы, суырып үбәсе килде. Шундый сагынган, шундый сусаган иде ул үзенең Дәмиясен күрергә!

Чибәр хатын күзләрен түбән төшерде, чак-чак кына читкә тайпылгандай итте.

— Арыгансыңдыр, ачыккансыңдыр дидем, Мәсәви ага, — диде ул, күгәрчендәй гөрләп. — Менә мин сиңа садака китердем. Баягы тупаслыгым исемә төште дә, йөрәгем жу итеп китте. Каргый күрмә, Мәсәви ага! Каргышың улыбызга төшсә, яшисе дә юк бу дөньяда. Әтисе дә, мин дә үлеп яратабыз улыбызны. Кер чайкап кайтканчы уянмаган — шундый акыллы ул безнең улыбыз. Әтисе ялланып урак ура. Урак өсте бит хәзер.

Ул шулай туктаусыз сөйләнде дә сөйләнде, үзе әле ялынып саилчегә карап алды, әле алдындагы төенчеген чишкәндәй итте. Төенчек эченнән зур гына йөзем тәл-

гәше, бодай көлчәсе, бер йомарлам эремчек, сөт савыты күренеп тора иде. Саилчегә бер мәртәбә тамак ялгап алырга артыгы белән җитәрлек бу. Ләкин хәзер ул ашау турында уйлый да алмады.

— Мин сине... каргаганыем шул инде, килен, — диде ул, яткан урыныннан торып.

Ул моны мөмкин кадәр шомлы һәм куркыныч итеп әйтергә тырышты. Яшь хатынның шундук йөзе бозылып китте.

— Каргышыңны кире ал, Мәсәви ата! — диде ул, ялварып һәм таләп итеп.

— Әйткән сүзне кире алып булмый, килен, — диде саилче, коры гына. — Шулай да каргышның сихерен юкка чыгарып була. Моның өчен нишләргә кирәклеген үзең дә беләсеңдер.

— Юк, белмим, Мәсәви ата, — диде килен, пышылдап, күз карашын түбән төшереп.

— Моның өчен, анабыз Дикә исемен әйтеп, көр ана исемен әйтеп, улыңның йөзенә сур өрергә кирәк.

Хатын, башын иеп, беравык тынып утырды.

— Кайда? — диде ул бераздан.

— Им өендә! — диде мосафир Мәсәви. — Ләкин анда Ту әниебезгә садака калдырырга кирәк булачак. Минем садакага бирерлек бернием юк — менә таягым да янчыгым. Матур муеныңдагы менә бу матур муенсаңны калдырсаң гына инде.

Хатын, күлмәк итәген әвәләп, озак кына уйлангандай итеп утырды, аннары башын калкытып як-ягына каранды да:

— Әтисе басуда куна-төнә эшли, — диде, серле пышылдап. — Бодай өлгерде. Тизрәк урып-җыеп алырга кирәк, ди. Хәзер мин кайтам. Караңгы төшкәч ындыр артлап килерсең. Кырыйдагы икенче өй булыр, — диде.

— Бигрәк чибәрсең икән, килен! Исемең ничек? — диде саилче, хатынның кулыннан тотмакчы булып.

Хатын көлеп җибәрде, шаянланып җиңел генә кулын тартып алды һәм сәлли кебек җиңел генә аягына да басты.

— Исемем? Исемемне оныткаммын, — диде ул, көлә-көлә, һәм яр өстенә менеп куаклар артында юкка да чыкты.

Мәсәви саилче кымшанмыйча урынында утырып калды. Аның инде яңадан йокыга да китәсе килмәде, торып суга да керәсе килмәде. Әле булса күз алдында яшь хатынның серле төс-кыяфәте торды. «Менә кемнәр аз-

дыра безне» дип уйлады ул бераздан иренеп кенә. Күпмедер вакыт тынып кына утыргач, ул, «аздыручы» хатынны тагын бер мәртәбә күрмәкче булып, өйләр ягына борылып карады, ләкин хатыннан инде җилләр искән иде. Ул тагын алдына борылды да, елга аша юл, күпер ягына карангалап, тик кенә утыруында булды.

Ул арада ачлык тойгысы да уянды. Саилченең борынына яңа пешкән бодай көлчәсе исе килеп җитте. Шат, чибәр хатынның төсен күз алдыннан җибәрергә теләмәгәндәй, ашыкмыйча гына ул садакага дип китерелгән төргәккә үрелде, төргәктән бөтен бер көлчәне тартып чыгарды да тәмләп-тәмләп ашарга тотынды. «Көлчәсе дә тәмле, үзе дә уңган, ахрысы» дип уйлады ул «аздыручы» хатын турында.

Онытылып, ләззәтләнеп ашап кына утырганда, юл буенда кинәт бер-бер артлы тезелешеп килгән яшүсмерләр төркеме күренде. Алар Актау ягыннан киләләр, таш күпергә җитәргә дә ерак калмаган иде. Саилче аларны моннан бер ай чамасы элек очраткан иде инде. Анда алар каядыр таулар ягына баралар иде бугай. Барлыгы унбишләп-егермеләп кеше булыр. Яшьләре белән барысы да бер чамарак — ундүрт-унбиш яшь. Җиде-сигез яшьтән аларны шулай көтүгә туплыйлар да язарга, укырга, җырга-биюгә өйрәтәләр. Аннан да бигрәк алар сугыш һөнәренә өйрәнәләр. Үсә төшкәч, алар күбрәк ауга йөриләр, биек тау башларына менәләр, сазлы, чытырлы җирләрдән чыгалар, яланаяк ташлы сукмаклардан үтәләр һәм кайда туктасалар, шунда ятып йоклыйлар. Соңгы елда алар тулысынча үз тамакларын үзләре туйдыралар — ауда атып алган киекләрен кыздырып, пешереп ашыйлар яисә, базарда сатып, шуңа башка төрле азык-төлек алалар. Кайчагында алар берәр бай хуҗага ялланып көтү көтәләр яисә урак вакытында урак уралар, башак җыялар. Эшләп табу өчен аларга барысы да рөхсәт ителә, аларга тик урлашу рөхсәт ителми дә садака алу рөхсәт ителми. Аларны бар яктан да батыр, кыю һәм куркусыз итеп, теләсә нинди шартларда да каушап, аптырап калмый торган аучылар, сугышчылар итеп тәрбияләргә тырышалар. Төркемнән чыккач, аларны турыдан-туры кораллы сакчылар итеп алалар.

Алар арасыннан берсе — тазарагы, көчлерәге — көтүче итеп сайлана. Төркемдәге һәркем көтүчегә буйсына. Шул ук вакытта аларның өлкән яшьтәге бер тәрбиячесе — пир аталары була. Монда Акландагы теләсә кем баласын алырга тиеш булсалар да, үзенең йорт-җире

булган таза тормышлы кешеләрнең һәм сакчыларның, сугышчыларның балаларын теләбрәк алалар. Шуңа күрә көтүчеләр, һөнәрчеләр, игенчеләр сабый чагыннан ук корал асып, телен салындырып, сакалын селкетеп тик йөргән балаларны, үсмерләрне бик үк өнәп тә җиткермиләр. Җиде-сигез яшьлек чакларында алар әле кызганыч тоелса, үсә төшкәч, соңгы елларына якынлашкач, ямьсез тавышлар белән кычкырып үзара чәке-чәке сугыша торган үсмерләрне чын күңелдән яратмый башлыйлар.

Мәсәви дә аларны яратмады. Бала вакытында ул аларга көнләшеп, кызыгып карады, яшүсмер чагында алардан бераз гына шүрли торган булды һәм шулай ук яратмады. Әтисе, әнисе үлеп калгач, ул үзенең бәхетле яшьтәшләрен генә түгел, әти-әниле, коллы кешеләрне дә яратмый башлады. Ятим калгач, ул төрле кешегә эшкә ялланып карады, ләкин бер эшкә дә күңеле ятмады. Бер кышны ул тураның ир өендә уздырды, анда вакытларын уздыручы төрле сукбайлар, саилчеләр белән танышты. Шуннан соң менә таягын тотты да, күн янчыгын асты да ил гизәргә чыгып китте. Ил-көн алдында ул үзен алышынган итеп, изге итеп күрсәтте, әрсезләнеп, ялган изгелек белән каплап, «алла бәндәсе» булып ил өстеннән туена бирде.

Күпергә якынлашып килүче үсмерләр төркемен ул эчке бер тынычсызлык белән күзәтте. Узып китәрләрме, әллә елга буена төшәрләрме? Төшми булмас. Төшсәләр, тынлык та, ялгызлык та юкка чыгачак. Шаулашып, кычкырышып су коеначаклар. Яр буенда сузылып ятачаклар. Булмады бу. Ичмасам, караңгы да төшми тизрәк. Чакырган җиргә китеп барыр иде. «Әллә караңгы төшкәнне көтеп тормаскамы соң?» дип уйлады ул үзалдына, бер-бер артлы тезелеп килгән яшүсмерләрдән күзен алмыйча.

Менә төркем күпер өстенә килеп менде. Барысы да югарыдан аска — су өстенә карадалар. Күперне чыктылар. Иң алдан килгән көтүче уңга каерды һәм, кулларын бутап, бар көченә кычкырып, түбән таба ыргылды. «Булмады бу!» дип уйлады саилче һәм тиз-тиз генә әйберләрен җыештырды да якындагы агач арасына кереп китте. Аның хәзер аларга бөтенләй күренәсе килмәде. Күренде исә, никтер артыннан кычкырырлар, туктатырлар сыман тоелды. Агач арасыннан ул яр башына менеп җитте һәм, артына карамаска тырышып, тәбәнәк таш киртәләр, каралтылар ягына китте. Ләкин кырыйдан икенче йортның ындыр артына якынлашкач, икеләнеп калды. «Иртәрәк

әле, ярамас, ахрысы» дип уйлады ул һәм, кырт кына борылып, яңадан елга ярына таба китеп барды.

Ул арада яшьләр көтүләре белән яр астына төштеләр, яр буена, ташлы, тигез җиргә таралып, шаулашып-кычкырып, коралларын, биштәрләрен, капчыкларын салып куйдылар да шап та шоп суга сикерә, чума, йөзә башладылар. Яшүсмерләр кебек үк үрелгән озын чәчле һәм алар кебек үк кояшта янган кара тыгыз тәнле, тик яшьләрдән калкурак, өлкәнрәк пир ата төркем коелганда яр буенда бераз карап торды да, бер үсмерне сакта калдырып, үзе дә суга керде.

Саилче исә яр буена ук төшеп утырды һәм күпер ягына, яшьләр ягына карана-карана яңадан ашарга тотынды. Ләкин аңа монда да тынычлык булмады. Яшүсмерләр бераз вакыт суда ыгы-зыгы килделәр дә, йөзделәр, чумдылар, узыштылар да, үзара куышып, яр өстенә чыга башладылар. Дөп-дөп басып, өсләреннән су чәчрәтеп һәм җитлекмәгән ямьсез тавышлар белән кычкырып, Мәсәви саилченең яныннан гына узып киттеләр йә булмаса якында гына туктап, әүмәкләшергә, көч сынашырга керешеп киттеләр. Кайберәүләр каршы яктагы яр өстенә чыктылар, кычкырдылар, чинадылар һәм текә, биек ярдан түбән таба суга сикерештеләр.

Берзаман искәрмәстән дигәндәй саилче янына пир ата үзе килеп җитте. Мәсәви саилче аны ничектер күрмичәрәк калды. Пир ата ярга борылды да, озын чәч толымнарыннан су агызып, ташлы ярга аяк басты һәм беренче сүзе итеп исәнлек-саулык сорашты. Аннан соң муенына уралган толымын аркасына ташлады һәм туптуры саилче янына — яр буена килеп утырды. Пир атаның исәнлек-саулыгына каршы саилче үзенең күнегелгән сүзләрен кабатлады:

— Сарга — байлык, илгә — иминлек, — диде ул, ашавыннан туктамыйча һәм пир ата ягына карамаска тырышып.

Пир ата су өстендәге үсмерләргә карангалап утырды да болай гына сөйләнгән кебек әйтеп куйды:

— Сәрмиядә уракка төшкәннәр икән дип ишеттек. Чын микән? — диде.

— Чындыр, — диде саилче. — Әлерәк кенә бер хатын әйтте: ирем уракта, диде.

— Төнне шушында кунарбыз да иртәгә Сәрмиягә китәрбез, ахрысы, — диде пир ата, үзалдына сөйләнеп.

Саилче эндәшмәде. Авызына капкан соңгы кисәк көлчәсен килен китергән куе, тәмле сыер сөте белән ка-

тыштырып йотып җибәрде дә авыз читен сөртеп куйды, сөт савытын күн янчыгына утыртты һәм тезен кочаклап тынып калды. Ике арада рәтләп сүз ялганып китә алмады. Шул ук вакытта ике өлкән кеше, бер-берсен белгән дә кебек булган, ерак юл йөргән ике кеше, нәрсәдер сөйләшергә, гәпләшергә дә тиеш иде сыман. Саилче, пир атаны ишетеп һәм читтән генә күреп белсә дә, аның белән якыннан таныш түгел иде. Пир ата исә Акландагы һәркем кебек Мәсәви саилчене тиле-милерәк дип, ил өстеннән туена торган алла бәндәсе дип белә иде, шуңа күрә аның белән акыллы сүз сөйләшеп булмый дип, сөйләшергә туры килсә дә, аның кемлеген һәрвакыт истә тотып сөйләшергә кирәк дип исәпли иде. Шуңа күрә дә алар арасында тиз генә сүз ялганып китә алмады. Шулай да пир ата янә сүз кузгатып карады:

— Сине, Мәсәви ага, Ту әниебез Дикәнең Изге чишмәсен эзли икән дигән сүз йөри. Чынмы шул? — диде ул.

— Изге чишмәне аны син дә эзлисең, пир ата Мәттин, — диде саилче, туры гына җавап бирмичә.

— Минем эзләгәнем юк, — диде пир ата, уйланып.

— Эзләгәнең булмаса, шуның өчен мактанып утырасы түгел! — диде саилче, шактый тупас итеп.

Пир ата, телен тешләп, тынып калды.

— Мин бит мактанмыйм. Болай гына әйтәм, — диде ул бераздан, аңлатырга кирәк табып.

— Болай гына да әйтмә, — диде саилче, — Ту әниебез Дикә минем анам гына түгел, ил-көн анасы. Изге чишмәнең онытылуы, югалуы бөтен илгә зарар китерде. Кая карама уйнаш, зина, бозыклык. Атабыз Мин түзеп торыр-торыр да, ачуы килсә, бер китереп сугар! Уйладыңмы шул турыда, пир ата?

— Уйлыйм мин, уйлыйм, Мәсәви баба, — диде пир ата, саилчегә ярарга тырышып.

— Уйлагач, нишләп миннән сорыйсың Изге чишмәне? — диде саилче, кырлы-мырлы.

— Болай гына әйтүем, үпкәләмә, Мәсәви баба! — диде пир ата һәм, бу тиле-миле бәндә белән рәтләп сөйләшеп булмаячагын аңлап, торып китәргә үк җыенды.

— Болай гына да әйтмә! — диде киребеткән саилче. — Көне-төне ил гизәсең, тауларда, үзәннәрдә буласың, үзең көтү башлыгы. Изге чишмәне аны син үзең табарга тиеш идең, пир ата Мәттин. Изге чишмәне иң элек үз күңелеңнән табарга кирәк. Күңелеңдә булса, табыла. Табылыр, алла бирсә!

Шул чакны үзара болагайланган яшүсмерләрнең берсе, өлкәннәр сүзенә кысылып:

— Табылган бит инде ул Изге чишмә! — диде.

Саилче Мәсәви дә, пир ата Мәттин дә икесе берьюлы артларына борылып карадылар. Алар янында өч-дүрт үсмер туктап калган һәм, колакларын торгызып, олылар сүзен тыңлап торалар иде.

— Син... каян беләсең аны? Кем әйтте?! — диде пир ата, әкрен генә беркадәр шомлы итеп.

Аның озынча какча йөзе үзгәреп калган, кыяфәтендә каушау сизелә иде. Саилченең дә йөзе тынычсызланды. Изге чишмә табылган, имеш! Йөз елга якын инде Акланда күпләр шундый сүз ишетергә зарыгып яшиләр, ләкин әлегә кадәр беркемнең авызыннан ялгыш кына да андый сүз чыкканы булмаган!

— Беркем әйтмәде, үзем күрдем, — диде үсмер, җиңел генә.

— Кайда?! Кайчан?! — диде пир ата, аның янына ук килеп.

— Былтыр күрдем, — диде малай, бер дә исе китмичә. — Безнең күрше Әмәкләрне беләсездер ич? Аларның бакчасында бер төш гел сазланып тора. Кайчагында шуннан су да алалар. Фалияне карыйм дип киртә аша үрелгән идем, Әмәк белән кызлары шул сазлыкта казынып яталар. Үзем күреп тордым, балчыктан ниндидер таш сын башы таптылар. Ишетеп тордым: «Анабыз Дикә түгел микән?» — диде кызлары. Әмәк әйтте: «Андый сүзне кычкырып әйтмә, ишетә күрмәсеннәр, — диде. — Ниткән Дикә булсын бу, ир кеше башы ич!» — диде. Шуннан соң берни ишетмәдем, өйләреннән Фалия килеп чыкты да, аннан соң...

— Бакчага су каян килә? Изге таудан түгелме? — диде саилче дә.

— Көпшәле су безгә килеп җитми ич, — диде үсмер, аңлатып. — Без бит Әмҗе бистәсендә, Бакыр койма янында. Каян килсен ул безгә Изге таудагы кайнар чишмә? Суны без коедан алабыз. Әмәкләрнең үз сулары бар.

— Алайса, ул да шул бозылган кое суыдыр инде, — диде пир ата, гамьсез генә, һәм бераздан әйтеп куйды: — Ишетсен колагың, моннан соң андый сүзне сөйлисе булма, — диде һәм аның янындагы үсмерләргә карап өстәп куйды: — Сез дә киртеп куегыз, теләсә нинди сазлыкны Изге чишмә дип сөйләп йөрсәгез, алла сугар! — диде.

— Ярар, сөйләмәбез, пир ата, — диде үсмер, теләр-теләмәс кенә, бөтенесе өчен җавап биреп. — Мин

күргәнемне-ишеткәнемне генә әйттем. Каян белим мин аны.

«Әмҗе бистәсе... Әмәк... Фалия...» дип уйлады саилче үзалдына, әлерәк кенә ишеткән исемнәрне ныграк хәтерендә калдырырга тырышып. Шул ук вакытта ул тынычсыз үсмерләр ягыннан күзен дә алмады. Барыннан да бигрәк әлеге үсмерне күзәтте. Ул исә башкалардан калкурак, тазарак, күкрәкләр киң, куллар-аяклар нык. Зур башлы, эре сөякле. Тоткан җирдән өзә торган үзсүзле, кире булырга тиеш. Үсмерләр төркеменең көтүчесе булса кирәк. Яшьтәшләре янында ничек тә үзенең өстенлеген, көчлелеген күрсәтергә тырыша — әле тупас кына берәрсенең сүзен бүлдерә, әле берәрсен шаярткан булып этеп, төртеп җибәрә, чәченнән тарта.

Шау-шу килеп, ары-бире чабып, үзара болагайланып, үсмерләр бер ярты сәгать чамасы су керделәр дә, пир атаның боерыгы булу белән, ярга чыгып җыелдылар, киенә, җыена да башладылар. «Кичкә кадәр Сәрмиягә барып җитмәкче булалардыр» дип уйлады саилче. Аның үзенә дә җыена башларга, каядыр китеп барырга кирәк иде дә, ләкин менә һич тә кузгаласы килми. Әйтерсең кемдер утырган урынына беркетеп, бастырыклап куйды. Дөнья кинәт кенә үзгәргән кебек булды. Көннең, күк йөзенең, су өстенең, каршыдагы яр буйларының — бөтен нәрсәнең төсе, яме, барлык исләре үзгәреп калды, колак төбендә туктаусыз гүләп, чыңлап, безелдәп торган тавышлар ишетелмәс булды. Аның хәтта ашыйсы да килми башлады. Авызына капкан азыгының тәме, туклыгы кинәт кенә юкка чыкты. Күз алдына исә бөтенләй икенче күренешләр, икенче кешеләр килде һәм хәзер менә шулай утырган килеш кенә, кодрәт белән генә, шул икенче кешеләр, икенче күренешләр янында буласы килде.

Ләкин, билгеле инде, утырган җирдән генә күз ачып йомган арада икенче бер төшкә илтеп куя торган ниндидер кодрәт бу дөньяда юк. Һичьюгы, бүгенге көндә юк. Андый кодрәтне элек кенә булган диләр. Күктән ниндидер канатлы арбаларга, кәрендәсләргә утырып, ниндидер изге җан ияләре төшкәннәр, җирдәге кешеләр белән аралашып, аларның тормышы, көнкүреше, ашаганы-эчкәне белән кызыксынып йөргәннәр. Кайберәүләр әйтә, алар, имеш, иң беренче аллалар булган, ди, җиргә утны, имеш, алар алып килгән, ди. Кыргый ата балаларын иген игәргә, мал-туар асрап, җир астыннан затлы ташлар казып чыгарырга, затлы ташларны утта эретеп

төрле нәрсәләр кыландырырга алар өйрәткәннәр, ди. Алар кешеләрне шулай ук хак дингә, тәртипкә, әдәпкә өйрәткәннәр. Аллаларны, ата-аналарны олыларга, изгеләргә багышлап корбан, садака бирергә өйрәткәннәр.

Кайберәүләргә... бик ышынычлы кешеләргә, алар яшәешнең — үлү-тууның, җир-суның, кояшның, йолдызларның мәңгелек серен дә әйтеп калдырганнар. Сабир ата әйтә, утлы, канатлы арбаларга, кәрендәсләргә утырып оча торган серле җан ияләре әле дә җиргә төшәләр, ди! Кеше сирәк яши торган аулак урыннарга, Карлы тау башларына төшәләр икән дә, кеше кыяфәтенә кереп, авылларга, тураларга баралар, юлда йөриләр, диңгез буйларына барып чыгалар икән. Сарларның, аксөякләрнең бозыклыгына, байлык колына әйләнеп, хак динне, изгеләрне оныта баруларына бик нык борчылалар икән. Эшләр гел болай барса, югарыдагыларның, изгеләрнең җирдәге кешеләргә бәла-каза салулары ихтимал икән. Сабир ата әлегә бу хакта беркемгә әйтмәскә кушты. Ни өчен дигәндә, мондый хәбәр ишетеп, илкөннең бик нык куркуга төшүе, илдә чуалышлар башлануы бар, ди ул. Ул әйтә, әле соң түгел, ди. Югарыдагылар өлгергәнче, безнең үзебезгә өлгереп калырга кирәк, ди. Моның өчен барыннан да элек Изге чишмәне табарга, чишмә янында Ту әниебез Дикәнең әүвәлге сынын табарга кирәк, ди. Ил-көн, каралар элеккечә изгеләрне олылый башласалар, яңадан хәер-садака, корбан бирә башласалар, югарыдагыларның күңеле йомшар, җиргә, Акланга бернинди бәла-каза, куркыныч янамас, ди.

Моннан бер ай чамасы элек, Аксау дип аталган таулы-ташлы төбәкнең диңгез ягына карап торган биек кыя башындагы таш өйдә Сабир ата белән Мәсәви саилче арасында шундыйрак сөйләшү булды. Сабир ата бик ныгытып әйтте: Изге чишмәне ничек тә табарга кирәк, диде. Ул монда, Аклан утравында гына булырга тиеш, диде. Ил-көн хәтерендә әле ул исән, шулай булгач, ул чынлап та исән булырга тиеш, диде.

Мәсәви саилче белән ул кара-каршы утырып сөйләште. Ләкин сөйләшкәндә никтер күзен күтәрмичә, карамыйча, әкрен, ничектер йомшак хәлсез бер тавыш белән сөйләде. Кинәт ул башын калкытты һәм Мәсәви саилчегә туп-туры карап алды.

— Тапсаң, бөтен илгә даның таралыр, исән чагында изге дигән исем алырсың, — диде һәм бераз тынып торгач өстәп куйды: — Миннән соң... минем урынга калырсың! — диде.

Мондый сүз ишетеп, Мәсәви саилченең башы-күзе әйләнеп китте. Ул хәтта үзенең кайда, кем янында утыруын да онытkандай булды. Сабир атаның сүзләре аңа хәтта төштәме — каядыр болытлар арасындамы ишетелгәндәй булды. Тик шулай да ул Изге атаның үзенә төбәп караган уттай күз карашын да бик яхшы хәтерендә калдыра алды. Яше инде туксанга якынлашып килсә дә, карар күзгә хәлсез, дәртсез бер сынык карт булып тоелса да, Сабир ата әле яшьләрдәй дәртле, куәтле һәм көчле иде бугай. Аның турында шундый имеш-мимешләр йөри иде. Алар анда, тау башында, кешене мәңге яшәтә торган ниндидер үләннәр, дарулар тапканнар, дип тә сөйлиләр.

Икенче көнне икәүдән-икәү генә калгач, Сабир ата белән Мәсәви саилче арасында тагын ачыктан-ачык сөйләшү булды. Кыя башында, диңгез ягына караган манаралы таш өйдән якын гына, астарак ат сырты сыман батыбрак торган ачык җир бар. Монда, түбәндә, тагын таш өйләр, каралтылар урнашкан. Анда кемнәрдер яшәп ята. Шунда ук, тау буенда, куйлар чемченеп йөри, җимеш агачларында — җимешләр, түтәлләрдә яшелчәләр үсә, басуда игеннәр саргаеп утыра. Тау башына менүе бик кыен. Моның өчен әллә нинди тар сукмаклардан үтәргә, ташка чукып ясаган куркыныч баскычлардан үрмәләргә кирәк. Монда күпме кеше яшәве, кемнәр яшәве билгеле түгел. Кемнәр генә булмасын, алар — изгеләр, алар — аллаларга якын кешеләр. Алар барысы да ирләр, ир затындагылар, яшьләр берән-сәрән генә. Картлар күбрәк keләү, зекер әйтәләр, яшьләр көтү көтә, иген үстерә, җимеш, яшелчә үстерә. Алар шулай ук мондагы серләргә, дини йолаларга өйрәнәләр.

Тау башына, изгеләр янына, теләсә кем кертелми. Кыя башындагы манаралы өйгә исә изгеләрнең дә теләсә кайсы керә алмый. Монда бары изгеләрнең изгеләре генә — Сабир атаның иң ышанычлы тугыз яраны гына кертелә. Алар монда төне буе йолдызларны күзәтәләр, Айның, Кояшның, Җирнең торышын, хәрәкәтен билгелиләр. Һәм барысын да үзләренең серле китапларына язып теркәп баралар. Еш кына алар анда җыйнаулашып Җиргә, Айга, Кояшка һәм йолдызларга кагылышлы фикерләре белән уртаклашалар.

Икенче мәртәбә сөйләшкәндә, Сабир ата саилчене шунда югарыдагы манара башына алып менде. Шома таш җәелгән идән уртасындагы камыш чыптага аякларын бөкләп утырып, алар шактый озак серләштеләр.

Биектән, түбәдәге зур ачыклыктан бүлмә эченә бөркелеп яктылык төште. Тышта, югарыда, тынычландыргыч талгын җил исте, ачыклык турысыннан әледән-әле канатларын җилпеп, сызгыртып ниндидер кошлар очып китте. Бу исә мондагы биеклекне, яктылыкны һәм күккә, аллаларга якынлык тойгысын көчәйткән кебек булды.

Манарада чыпта өстендә, таш кубәтәгә салынган ниндидер ят исле кипкән җимеш сыман нәрсәне капкалап, әкрен генә, ашыкмыйча гына сөйләшеп утырганда, Сабир ата саилчегә үзенең тагын бер серен чиште. Безгә алмашка, булышка өлкән яшьтәгеләр генә түгел, яшьләр дә кирәк, диде. Өйләнмәгән, чибәр үсмер яшьләр, диде Сабир ата. Үсмер чибәр яшьләрнең ни өчен кирәклеген саилче бик яхшы аңлады, шуңа күрә ул төпченеп тормады. Акланда сөйләнелә торган имеш-мимештән ул мондагы хәлләрне болай да чамалый иде. Сабир ата белән аның яраннары арасында күптән инде үзара тартыш бара. Сабир ата изге кеше, дин кешесе өйләнмәскә, бөтен гомерен аллаларга зекер әйтеп үткәрергә тиеш дип исәпли. Шуңа күрә дә ул ятак өчен яшүсмерләрне файдалану изге эш дип белә. Ләкин аның кайбер яраннары икенче төрлерәк фикер йөртәләр: аллалар ирне — кыз өчен, кызны ир өчен яраткан, аллалар теләгенә каршы килү — язык, диләр.

Бу бәхәснең, тартышның очы-кырые күренгәне юк. Шулай да, тартыша торгач, Сабир ата үзенең кайбер яраннарына кызлар белән якынлык кылырга рөхсәт иткән, диләр. Шулай да хатын-кыз затыннан булган беркемне дә тау башына алып менәргә ярамый икән. Тыелган кыек эштә тотылган бер яранны һәм яшь бер хатынны моннан биш ел элек, имеш, аякларыннан агач башына асып куйганнар. Аларның гәүдәләре җилдә, яңгырда, кояшта торып кибеп, корып беткән, тәннәрен кошлар чукыган, бөҗәкләр кимергән. Соңга таба сөякләре бер-берсеннән аерылып, өзелеп агач төбенә төшеп беткән. Ул якка хәтта изгеләр үзләре дә әйләнеп карарга да куркалар, имеш.

«Әмҗе бистәсе... Әмәк... Фалия...» — дип уйлады яңадан саилче, үзенә кирәкле исемнәрне исенә төшереп. Менә бу кыю малайны алып барганда яхшы булыр иде, диде ул аннары, төп фикеренә кире кайтып. Изге чишмә турында ул әйткән сүз дөрес була-нитә калганда, аңа хәзер ил-көн арасында калырга да ярамый. Шулай җиңел генә сөйләнә торган булгач, аның тагын башка җирдә сөйләнүе дә бар. Әйе, аны ничек тә туры юлга юнәлдерергә кирәк.

Сабир атаның ике теләген дә үти алса, һо! ул чагында! Ул чагында дөньядагы бик күп серләр аның кулында булачак. Ул чагында аның белән мака сар Карун да исәпләшә башларга мөмкин. Ул чагында тагын...

Юк, әлегә ул хакта хыялланмыйк әле. Анда күз күрер. Тик менә Сабир атаның «изге кеше хатын-кызлар белән якынлык кылмаска тиеш» дигәне генә эчне тырнап тора. Бер дә андый нәрсә белән килешәсе килми. Аны бит әле бүген кич караңгы төшкәч көтеп торалар. Билгеле, ул үзе дә көтә — зарыгып, тәкатьсез булып көтә. Мондый теләкне бетереп тә, яшереп тә булмый.

Ярар, нишләргә соң болай булгач? Чакырып торган яшь хатын янына кермичә, хәзер үк, төнгә каршы, Актау ягына китеп барыргамы, әллә соң алтын сарайлар ягына Саркелгә китәргәме? Турага хатын янына кереп чыккач та китәргә була. Анда беркем тыймый, агач башына аягыңнан асып кую белән дә янамый — тотылма гына! Аннан соң, анда да Изге чишмә белән кызыксынучылар, Изге чишмәне тапсаң, алтынга-көмешкә күмеп ташлармын дип әйтүчеләр бар түгелме соң?

Бернинди карарга килә алмыйча үзалдына уйланып ул шулай утырды да утырды. Үсмерләр, бер-бер артлы тезелеп, авыр коралларын, капчыкларын күтәреп һәм бердәм рәвештә җыр җырлап, Сәрмия авылы ягына юнәлделәр. Узып барышлый барысы да саилче ягына борылып карады, үсмерләр генә түгел, көтү сакчысы да «сау бул» дигән кебек җиңелчә генә кул болгап алды. Алар китеп яр буенда үзе генә калгач, саилче су керде, юынды, киенде дә, күн садагын аркасына асып, таягын алып, олы юл ягына таба кузгалды. Ул, ахрысы, үзенең икеләнүен җиңә алды бугай. «Ашыгырга кирәк... кем дә булса берәрсе өлгергәнче, күрергә кирәк» дип уйлады саилче үзалдына.

Ул ашыкмыйча гына таш юлга чыкты, күпер ягына борылды. Ләкин күпер уртасына җиткәч, күңелендә яңадан икеле-микеле уйлар көчәя башлады. «Нишләп әле мин чакырган җирдән качып китеп барам?» дип уйлады ул, үз-үзен шелтәләп. Кемнән курка икән соң ул? Дәмиядәнме, пир ата Сабирданмы? Моңарчы аның Дәмияләрдән, Сәвияләрдән курыкканы булмады кебек. Пир атадан да куркып торасы юк. Озакламый ул үзенең биек манарасына менәр, зурайткыч пыяла аша йолдызларны күзәтер. Бәлки әле, хәзер дә үзенең яраннары белән киңәшәдер. Кем белә, бәлки, чибәр үсмерләр турында хыялланып утырадыр. Ни генә булмасын, саилче

Мәсәвине исенә дә кертеп чыгармыйдыр. Якында гына кемдер сине көтеп ятсын да, төнгә каршы тагын юлга чык, имеш! Аның бит әле каргышның көчен дә юкка чыгарасы бар. Килен кайгырып, борчылып ятадыр. Юк, болай булмый. Иң элек әйткән сүзеңне үтәргә кирәк, аннан соң инде... анда күз күрер...

Күпер уртасыннан ул әкрен генә кире борылды, яңадан түбән төште дә ялгыз куак янына килеп утырды. Ул монда караңгы төшкәнне көтәргә булды. Хәер, көтәргә күп тә калмады бугай. Көндезге кызулык инде сүрелә төште, тирә-якка рәхәт талгынлык тарала башлады. Озакламый авыл ягыннан кечке тавышлар ишетелде: елга буендагы болын ягыннан шау-шу килеп көтү кайтты, шыгырдап капкалар ачылды, кайдадыр усал итеп, абалап этләр өрде.

Саба авылы өстендәге калкулыкларга якынайганнан-якыная барган кызгылт кайнар кояш, уртадагы очлы тауга җитеп, аскы ягы белән тау сыртына орынгач та, күк читеннән каралҗым таплар сузылып чыкты. Көн яктысы кими төште, күз бәйләнә башлады. Шул ук мәлдә дип әйтерлек кичке корт-бөҗәкләр җанланды. Җим эзләп ераккарак очкан бал кортлары, керәшәләр тизрәк үз ояларына кайтып китәргә ашыктылар.

Саилче урыныннан торды һәм яр астыннан авылга таба кузгалды. Бу мизгелдә ул пир ата Сабирны да, аңа әйтәсе яңалыкларын да, хәтта изгеләрдән дә изгерәк Ту әниебез Дикәне дә исеннән чыгарып җибәрде. Аның өчен хәзер дөньяда бары бер генә төрле изгелек һәм бары бер генә ана кеше — җанлы, тере, яшь хатын гына торып калган иде. Менә хәзер килешенгән вакытта аны күрмәсә, аның белән очрашып үзенең тәкатьсез теләген үтәмәсә, дөнья кинәт җимерелер, таулар-ташлар башаяк килеп, елгалар, диңгезләр ярларыннан чыгар сыман иде.

Саилче Мәсәви тиешле өй турысында яр өстенә менде, ачык калдырылган җилкапкадан ындырга керде һәм ярым караңгыда шәйләнгән җимеш агачлары, куе куаклар арасыннан ничегрәк узып китәргә белмичә туктальбрак калды. Шул чакны, караңгы куаклардан аерылып, кемнеңдер якынаеп килгәне күренде.

— Әйдә... менә моннан, — диде Кәфия, калтыраган-каушаган бер тавыш белән.

Яшь хатынның кулы саилчегә кайнар, хәтта кирәгеннән артык кайнар тоелды. Ялгыш утлы кузга кагылып киткәндәге кебек, аның кинәт кенә кулын тартып аласы килде, ләкин тартып алмады — яшь хатынның

кулы утлы куздай булса да көйдермәде, яндырмады — йомшак, татлы һәм җылы май булып бөтен тәненә таралды. Тәмам буынсыз калып, буйсынып ул хатын артыннан иярде.

Ят бусагадан атлап кергәндә, саилче искәрмәстән анабыз Дикәне, Әбетине исенә төшерде, ярым пышылдап, ашыгып келәү әйтте. Кәфия келәүнең «илгә — иминлек, сарга — байлык» дигән сүзләрен генә ишетеп калды.

Таш өйнең эче иркен генә иде. Өй уртасында түшәмне, түбәне тоттырып шомарып беткән юан багана — караулы агач сузылып утыра. Баганадан читтәрәк яссы ташлар белән түгәрәкләп алынган учакта сүнәр-сүнмәс ут яна. Учактан төшкән кызгылт яктылыкта исә дивар буенда ике якта ике ятак — сике калкып күренә. Сикенең берсендә, ак мендәргә батып, аяк-кулларын як-якка ташлап, анадан тума ап-ак тәнле яшь бала йоклап ята.

— Улым йокыга да китте... бигрәкләр акыллы! — диде Кәфия, улын мактап, көлештереп.

Саилче таягын, күн садагын ишек төбенә җайлап куйган арада, хатын шыпырт кына каядыр чыгып китте. Үз-үзе белән булашып, саилче аның шулай кинәт кенә юкка чыгуын искәрмичә калды. Ныклабрак караса, каршыда гына ачык калдырылган ишек барлыгын шәйләп алды. Күп тә үтмәде, авыр гына агач табак күтәреп, ишектән Кәфия килеп чыкты. Бөтен өй эченә кыздырылган тәмле ит исе чыкты. Табакны Кәфия учак янына идәнгә, ашъяулык өстенә китереп куйды. Шуннан соң ул яңадан икенче якка чыгып китте һәм аннан бора чүлмәге белән бер көмеш касә алып килде. Саилче, төкерекләрен йотып, борынын тарткалап, каш астыннан гына хатынның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырды. Аның шулай бер генә касә алып килүен күрде дә түзмәде, сорап куйды:

— Үзең утырмыйсыңмыни? — диде.

— Утырырмын, — диде Кәфия, күндәм генә, ләкин үзе утырырга ашыкмады. Бер дә юктан улы янына барып әйләнде, аның өстенә ябып куйды. Шуннан соң, нидер эшлисе эше бар кеше сыман, тышкы ишек ягына карап алды.

— Миннән шикләнмисеңдер ич, килен, — диде Мәсәви, йомшак, ягымлы итеп.

— Шикләнүен шикләнмим, — диде хатын, телгә килеп, һәм, егылып китә күрмим дигән сыман, караулы агачка тотынган килеш, иләп кенә идәнгә чүгәләде. — Бераз гына куркам бугай. Чит ир кеше белән утырып ашау-эчү язык булмасмы дим... Әбети анабыз ни әйтер

дип тә уйлыйм. Җир куенына кергәч, мәңге утта янарга туры килсә, нишләрмен дип тә кайгырам.

— Юкка кайгырасың икән, килен, — диде саилче, майлы каз ботына үрелеп. — Әйтсәм әйтим, мин сиңа чит кеше дә түгел. Мин күптәнге алла бәндәсе. Алла бәндәсе ул, беләсең килсә, никахлы ире юк чагында теләсә нинди тиши янында куна ала. Бу безнең изге йолабыз.

— Ишеткәнем бар, — диде Кәфия.

— Шулай булгач? — диде саилче. — Бар әле икенче касә алып кил.

— Көмеш касәм... бер генә шул, — диде Кәфия, кызарынып. — Анысын да әле иремнең төсе итеп кенә саклыйм.

— Ireңнең төсе итеп?! — диде саилче, аңлап җитмичә. — Ирем уракта куна-төнә эшли, дидең түгелме соң?

— Дигәнием, — диде Кәфия, теләр-теләмәс кенә. — Көмеш касә... беренче иремнең бүләге.

— Беренче иремнең?.. — диде саилче, үзалдына сөйләнгән сыман.

Ул башка төпченеп тормады, ашавында булды. Аның мондый тәмле, майлы каз итен инде күптән ашаганы юк иде. Алар шулай беравык берни эндәшмичә ашауларында булдылар.

— Курыкма да, кайгырма да син, — диде бераздан саилче, хатынның күңелен тәмам тынычландырмакчы булып. — Менә әле изгеләрнең изгесе пир ата Сабир яныннан кайтып киләм. Сабир мине үзенең яраны итеп алмакчы, шул турыда сүз булды.

Пир ата Сабир турында ишеткәч, Кәфия кинәт ашавыннан туктап калды.

— Сабир ата изгесен изге инде ул, — диде. — Аны бит хатын-кызны яратмый икән диләр, чынмы шул?

— Чын, — диде саилче, ашыгыбрак, һәм, ник әйткәненә үкенеп, шундук телен тешләргә мәҗбүр булды.

— Син дә... шундыймыни?! — диде Кәфия, куллары майланып беткән, ашаудан башка берни белән кызыксынмый сыман тоелган саилченең йөзенә туры карап.

— Мин дә?.. Минме? Хи-хи!.. — диде Мәсәви, көлеп ык-мык итеп. — Мин, юк, андый түгел.

— Котымны алдың, — диде хатын, үзе дә сизмәстән һәм җиңел сулап.

Икенче көнне иртән, кояш чыгып дөнья яңадан төнге йокыдан уянгач, беренче булып Мәсәви күзен ачты. Күзен ачу белән, гадәтенчә, ярамаган нәрсәне күрәсе

килеп, яшертен генә Кәфия ягына карап алды. Әвәләнеп, борчылып беткән урын-җирдә таралып сылу тәнле яшь хатын ята. Озын кара чәчләре тузгыган — бер толымы бер якка, икенче толымы икенче якка салынып төшкән. Янында, куенында, кечкенә улы ята. Бала нәни аягын югары күтәреп, әнисенең юан боты өстенә салган, нәни кулы белән исә әнисенең тулып, бүлтәеп торган күкрәгенә үрелгән.

Менә шушы күренешне күрү белән, шундук саилченең күз алдына Сабир ата килде. «Нишләп шулкадәр яратмый икән ул хатын-кызны?» — дип уйлады Мәсәви. Тау башында ятып аның беркайчан яшь, сылу тәнле кызлар күргәне дә булмагандыр. Шуңа күрә менә аңа үсмерләр-фәләннәр кирәк тә. Үсмер... ул да бар бит әле дөньяда. Онытыла да язган. Әмҗе бистәсе... Әмәк... Фалия... Сабир ата әйтә, ил-көн бозылды, бозыклыкка бирелде, ди. Изгелекне онытып бара, ди. Изге кеше нинди булырга тиеш икән соң? Аның кебекме? Барлык изгеләр дә бары бер-берсен генә яратсалар, балаларны кем табар да кемнәр иген игәр, кемнәр көтү көтәр, кемнәр таш кисеп йортлар, сарайлар салыр?

Мәсәвинең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Дөресрәге, элек тә үзенә тынгы бирми торган төрле уйларын-борчуларын ул яңадан исенә төшерде. Ләкин бу мизгелдә, янында гына шундый якын да, аңлаешлы да, ләкин шул ук вакытта серле дә тоелган җан иясе... җан иярәре булган чакта, шушы тын, аулак өйдә, Актау ягындагы күңелсез корыган изгеләр турында озаклап баш ватасы да килмәде. Ипләп кенә ул хатынның тәненә кагылды, дәрте уянган бармаклары белән аның хуш исле йомшак тиресеннән сыйпады. Хатын уянгандай итте, ярым йокылы бер хәрәкәт белән гәүдәсен якындагы ир ягына авыштыра төште, йөзе белән борылды һәм шул ук вакытта улын кочаклаган кулын саилчегә күчерде. Күзләрен ачмыйча һәм бер сүз әйтмичә, ул капшанып кулын түбән шудырды.

— Каян килеп чыктың син?! — диде ул, серле пышылдап, кайнар ирене белән ирнең иренене үрелеп. — Син чыннан да изгедер. Күктән төштеңме, Актаудан төштеңме — минем өчен барыбер. Төннәр буе мин сине төшемдә күрдем, сагыштым, сагынудан нишләргә белмәдем.

Таң атып, көтү куылгач, бөтен авыл аякка баскач һәм җиңелчә генә ашап-эчеп алгач, саилче юлга җыена башлады. Ашаганда-эчкәндә дә, юлчы үзенең барлы-

юклы әйберләрен барлап азапланганда да, Кәфия үпкәләгән сыман берни эндәшмәде. Мәсәви инде кузгалып китәм дигәндә генә, алар арасында кыскача гына сөйләшү булып алды.

— Китәсең дәмени? — диде хатын.

— Китәм, — диде Мәсәви саилче.

— Каргышыңны кире алмадың, — диде Кәфия.

— Эх, оныткканмын! — диде саилче.

Кулына алган таягын, иңбашындагы садагын ишек төбенә куйды да тынып калган хатын янына килде, ике куллап аның беләкләреннән тотып алды һәм, авыз эченнән келәү әйтеп, аның йөзенә тынын өрде.

— Улыма да шифалы тыныңны өр, — диде хатын, таләп итеп.

Бала инде уянган иде, аяк кулларын бутап, көлеп, үз-үзе белән «сөйләшеп» ята иде. Саилче балага да иелде, авыз эченнән генә аңа да зекер әйтте һәм соңгы мәртәбә аның йөзенә таба шифалы тынын өрде.

— Китимме инде? — диде саилче, эшен бетергәч.

— Әллә китмисеңме? — диде Кәфия, ялвару катыш таләп итеп.

— Ничек... «китмисеңме»? — диде Мәсәви, аптырап, һәм ишек төбендә туктап, тоткарланып калды.

— Шулай. Ирем булырсың. Бергә-бергә торырбыз. Улыма — ата, миңа таяныч булырсың.

— Ирең? Мин синең ирең булырмынмы? — диде саилче, берни аңламыйча. — Урактагы ирең кайтып төшсә, ни диярсең?

— Юк минем ирем. Беркемем юк, — диде Кәфия, кистереп. Моннан бер ел элек... Актау ягында Бики бәк белән ауга баргач... арыслан ботарлаган аны. Без — Бики бәк каралары. Бер елдан миңа кияүгә чыгарга ярый. Кем алыр? Алырмы Бики бәк, үзенең сөяркәсе ясармы? Белмим. Көне-төне теләсә кайда, теләсә кем ишек төбендә каңгырап йөргәнче, торыр урының булыр, тамагың тук булыр... Беләм, син изге... алла бәндәсе. Эшкә күнекмәгәнсең. Берни эшләмичә, тик кенә утырсаң да, янымда гына булсаң да, иркәләп, яратып кына торырмын. Теләсәң, якын-тирәгә йөрерсең, имләрсең, зекер әйтеп, караларны туры юлга өндәрсең. Бики бәк белән сөйләшеп, келәүлек салдырырга була. Шунда изге эш эшләрсең.

Мәсәви, башын иеп, кулындагы таягын селкеткәләп, тын гына тыңлап торды. Кәфиянең соңгы сүзе Мәсәвинең күңеленә хуш килде.

— Менә монысы булыр кебек! — диде ул, дәртләнеп. — Нишләп әле keләү йортлары кеше аягы басмаган биек кыя башларында гына булырга тиеш? Кешеләр күбесенчә түбәндә яши. Аларга изге сүз кирәкмимени?! Аларның да аллалар серен беләсе килмимени?!

— Алайса, китмисең, — диде Кәфия, Мәсәвине кочаклап алып. Шулай тотып алып калмакчы булган кебек озак кына кайнар каты кочагында тотып торды, аның чәчләрен, аркасын сыйпады, битеннән, иреннәреннән үпте. «Карале, нинди дәртле, нинди үзсүзле хатын икән бу!» дип уйлады саилче. Юл йөргәндә, анда-монда төн кунганда ул төрле хатын күрде, ләкин мондыйны әле күргәне юк иде бугай. Сәрмиядәге Дәмия генә шундый ук дәртле иде, ахрысы.

— Мин инде сине... сагындым да, — диде Кәфия, пышылдап, саилчене үз артыннан ияртеп.

— Минем күрәсе-сөйләшәсе кешеләрем бар, — диде Мәсәви, хатынның теләгенә бик үк каршы килмичә. — Шуларны күргәч, сөйләшкәч, үз эшләремне җайлагач... берәр айдан килеп җитәрмен. Ризамы?

— Ярар, мин көтәрмен, — диде Кәфия. — Алдасаң, каргышым төшәр. Мин каргасам, бик каты каргармын. Син изге булганны, мин дә... изге. Ту әниебез Дикәгә мин нәзер әйттем. Тик менә нәзеремне генә үти алмыйм. Үти алмасам, мин болай да им өенә китәргә, үлгәнче шунда калырга тиешмен. Минем анда китәсем килми, ирле булып, иркәле булып яшисем, улымны үстерәсем, тагын уллар-кызлар табасым килә. Аңлашылмыймыни?!

— Барысы да аңлашыла! — диде Мәсәви саилче. — Мин сиңа сүз бирдем — бер айдан мин синең янында булырмын.

Олы ташлы юлга ул таныш җирдән — ындыр эченнән, яр буеннан барып чыкты. Юлга чыккач, артына борылып карады. Еракта, таш киртәнең ачык капкасы янында кул болгап Кәфия басып тора иде. Бу мизгелдә саилче яңадан пир ата Сабирны исенә төшерде. «Хатын-кыз ул иблис токымыннан. Хатын-кыз ирләрне аздыру өчен генә яратылган», — дигән иде Сабир ата бервакыт, хатын-кыз турында сүз чыккач. Чыннан да шулай икән. Китәргә кирәк моннан, качарга кирәк тизрәк. Ләкин кайсы якка? Бу вакытта ул, аны-моны уйламыйча, күпер уртасына килеп җиткән иде. Күңелендә шик тугач, ул кичәгечә урталыкта туктап калды. Беравык бер урында таптанып торды да кырт кына артка борылды һәм җитез-җитез атлап алтын-көмеш сар

сарайлары булган бәхетле турага — Аклан иленең башкаласы ягына юнәлде.

Саба авылыннан ераклашканчы ул шактый җитез атлады. Аңа ничек тә тизрәк Алтын турага кайтып җитәргә, андагы күрәсе кешеләрне тизрәк күрергә кирәк сыман тоелды. Ләкин, атлый торгач, күңелендә башка төрле уйлар-теләкләр уяна башлады. Нигә шулкадәр ашыгырга соң әле? Аңа беркем, шул вакытка кайтып җит, тизрәк шул кешене күр, димәде. Шулай ук анда аны беркем дә зарыгып көтеп тормый. Аннан соң яңалык дип уйлаган яңалыгы да әллә ни ышанычлы түгел. Андый гына яңалыкларны ул инде әлек тә ишеткәләде. Тикшереп, төпченеп карагач, барысы да чыш-пыш булып чыкты. Монысы да шулай булмас дип кем әйтә ала?

Бераз вакыт ул шулай үз-үзен юатып, ничек тә үзен бәйсез һәм ирекле итеп тоярга тырышты. Бүген, бүгенге иртәдә, төнне Кәфия белән үткәргәннән соң ул үзен беркайчан булмаганча бәхетле итеп сизде. Ул яшь хатынның яратып әйткән сүзләрен, күз карашларын, көлүләрен исенә төшерде. Хатын аны калырга, мәңге үз янында бергә калырга өндәде. Ир кеше өчен дөньяда шуннан да зур бәхет булырга мөмкинме?! Туктале, нишләп соң ул гомергә каңгырап йөрергә, таң ату белән каядыр чыгып китәргә, нидер эзләргә, теләнергә, сорانырга тиеш? Бәлки, иң дөресе чыннан да шунда төпләнеп калыргадыр? Таудагы, урмандагы киекләрнең дә, кошларның да, бөҗәкләрнең дә — һәркайсының үз куышы, үз оясы бар. Киекләр дә, кошлар да, бөҗәкләр дә яратышалар, бала тудыралар, ничек тә, нинди шартта да нәсел калдырырга тырышалар. Менә ул саилче Мәсәви изгемен дип уйлап, дөресрәге, галимнәргә, изгеләргә якынмын дип уйлап, үзен-үзе алдап, көне-төне нидер эзли, нидер тапмак була. Нәрсә эзли, нәрсә тапмак була?

Ул аны белә. Бик белә. Адәм баласы барыннан да элек үзенә бәхет дигән нәрсә эзли. Яшьләр өчен бәхет бер-берсен табышу, кавышу булса, картлар өчен бәхет — саулык, тазалык. Үлем түшәгендә ятучылар өчен бәхет — изгелек һәм изге килеш, языклардан арынган килеш җиңел генә теге дөньяга күчү.

Элегрәк ул шулай булган. Бүген исә бәхетне... байлык белән бутыйлар. Алтын-көмеш белән, җиз-бакыр, тимер белән, затлы әйберләр, затлы савытлар, кием-салым белән бутыйлар. Анысы гына җитмәгән, сөюне, яратуны, шәрә тәнле хатын-кызны байлык чыганагына

әйләндерәләр. Тау башында, ялгыз манарада сөйләшкәндә, пир ата Сабир нәкъ шулай диде.

Таштан, агачтан салынган өйләр, сарайлар белән, биек-биек коймалар, кәмәләр, күперләр — тагын әллә нәрсәләр белән бутыйлар.

Менә ул кайдан башлана бүгенге бозыклык! Кешеләр арасындагы кансызлыкның, гаделсезлекнең, үзара талаш-ызгышның нигезе менә кайда ята! Менә кайда ул бүгенге кешенең ялгышы!

Күп кеше моны белми, уйламый. Әйтергә кирәк, күзен ачарга кирәк бүгенге кешенең. Туры юлга юнәлтергә кирәк аны. Җимерергә кирәк алтын сарайларны, манараларны. Таудай биек таш киртәләрне җимереп диңгезгә тутырырга кирәк. Кеше яңадан үзенең элекке хәленә кайтырга тиеш. Иген игеп, терлек-туар асрап, әнә теге көтүчеләр кебек, иркендә-болында, урман-тау буйларында яшәргә тиеш. Юкса харап булабыз. Таш эченә бикләнеп, бер-беребезне күрми башладык, Изге атабызны, анабызны онытып барабыз, аларның әйткән сүзләрен күптән оныттык. Ту әниебез Дикә чишмәсен инде әйткән дә юк...

## III

Ул көнне Җәбир, иртәнге ашны ашагач та, гадәтенчә бакчага чыкты. Бакчада әле эш чын-чынлап башланмаган да иде. Барыннан да элек арыкларны чүп-чардан, иске яфраклардан арындырасы, койма буендагы карт алмагачка, яңа арык ерып, су җибәрәсе бар. Лелег булган кеше, мака сар башкаласында яшәгән иреклe кеше, әлбәттә, үзе җир казып, арык ерып булашмый. Мондый эшне аның өчен коллар эшли. Ләкин ярлы булсаң, кайчагында менә үзеңә дә эшләргә туры килә икән шул.

Җәбир үзен белә-белгәннән бирле аларның коллары шул ирле-хатынлы ике карадан артмады. Элек алар яшьрәк, тазарак иде. Теләсә нинди авыр эшне башкардылар. Ләкин хәзер инде алар да картайды. Җитмәсә, икесен дә эти-әнисе үзләре янындарак тоталар.

Телисеңме-теләмисеңме, үзеңә эшләргә туры килә. Җәбир беркайчан бакча эшен яратмады. Күршеләрдән дә уңайсыз. Болай да инде аларның ярлы дигән даннары чыккан. Болай да инде алардан җае чыкса да, чыкмаса да көләргә генә торалар. Әйтәсе дә түгел, кыен, бик кыен ярлы кешегә бу дөньяда яшәве.

Бакчага чыккач ул, төрле уйларга бирелеп, тигез таш җәелгән сукмактан бакчаның аргы башына юнәлде. Анда таш койма буендагы таш утыргыч янында эш кораллары сөяп куелган иде. Җәбир, яңа яфрак чыгарган агач ботаклары арасыннан иелештереп, ашыкмыйча гына таш утыргыч янына килеп җитте дә никтер утырасы итте. Нишләптер бүген аның эшкә кулы бармады. Күңелдә ниндидер таш бар сыман иде. Бик-бик кыен иде аңа.

Бүтән вакытта шулай бик кыен булганда ул үзенә берәр төрле эш табып, эш белән мавыгып онытыла торган иде. Бүген алай булмады. Хәтта шомарып беткән саплы кәтмәннәр, көрәкләр ягына әйләнеп тә карыйсы килмәде.

Шул чагында ул өй алдында кол карчык Сусине күреп алды. Карчык анда-монда каранып алды да туры Җәбир янына килә башлады.

— Инәң чакыра, — диде ул, койма янына килеп җитәр-җитмәс туктап.

Җәбир эндәшмәде. Ямьсез, җирәнгеч караның йөзенә бер күтәрелеп кенә карады да күзен читкә борды. Кайчагында аның бу кол карчыкны үз куллары белән ботарлап ташлыйсы йә булмаса бернинди кызганусыз диңгезгә ыргытасы килә иде.

— Нишләп утырасың? Әкълимәләр китә бит бүген, — диде Суси, Җәбирнең эндәшмәвенә хәтере калып.

Шулай диде дә, иелгән авыр башын күтәрергә тырышып, ялан аякларының аксыл табаннарын ялтыратып китеп тә барды. Җәбир шундук урыныннан торды, кол карчыкны куып җитте дә, аның иңбашыннан тотып, тар сукмактан тиз генә узып китте.

— Оныткансмын, — диде ул Сусигә.

Әйе, онытткан. Сеңлесе Әкълимәне дә, аның менә бүген китәргә тиешлеген дә оныткан, имеш... Юк, ул аны беркайчан онытмады! Оныта да алмады. Ул аны һәм аңа бәйле кайбер нәрсәләрне оныта алмаганга да шулай бар нәрсәне оныткан булып кыланды бугай. Шуңа күрә дә ул бүген менә бакчада агачлар арасында качып калырга тырышты да бугай. Ләкин үз-үзеңнән, ярлылыгыңнан, үзеңнең бәхетсезлегеңнән, күрәсең, алай гына качып котылып булмый торгандыр ул.

Җәбирнең эти-энисе таш йортның ике тәрәзәсе дә көнчыгышка, диңгез ягына караган иркен бүлмәдә торалар. Әкълимәнең дә бүлмәсе шунда — этисе-энисе бүлмәсеннән бер бүлмә аша бакча ягында. Җәбир үзе каралар тора торган тар гына, кысан кетәк янындагы иркен генә бүлмәдә тора.

Ул ачып куелган тышкы ишектән өйалдына килеп керде. Өйалдының тигез итеп таш җәелгән идәнендә камыш чыпта ята. Өйгә керә торган тәбәнәк баскыч шомартылмаган озын ташлардан ясалган. Ләкин йөри-йөри баскыч ташларының урта бер җире җиңелчә ашалып, шомарып беткән. Баскыч янындагы тигез итеп сыланган, агартылган таш диварга күк буяу белән диңгез дулкыннары һәм дулкыннар арасында йөзеп йөргән кызыл канатлы балыклар ясалган. Икенче якта идән белән түшәмгә чаклы диварның ишектән кала барлык буш урыннарына озын кәүсәле, зур яфраклы агачлар, ботактан ботакка сикереп уйнаучы маймыллар, куак арасында булачак корбанын күзәтеп яткан арыслан сурәте ясалган.

Өйнең түбәсендә, нәкъ уртада, киң генә дүрткел ачыклык калдырылган, шунлыктан көне буена өйгә кояш яктысы төшеп тора. Учактагы төтен, өйдәге төрле ачытөче исләр шул ук югарыдагы ачыклыктан өскә күтәрелә. Үзләре ярлы булсалар да, аларның өе бер дә ярлыларча түгел. Бу өйне моннан йөз ел чамасы элек Җәбирнең бабасының танышы бай кәмәче салдырган. Аның унлап кәмәсе булган һәм ул бөтен гомерен диңгездә йөзеп, сәүдә иткән. Мал сатып, мал алган, байлык туплаган. Ләкин ул ниндидер илгә киткәннән соң, давылга туры килеп, чит җирләрдә үлеп калган. Өйгә кәмәченең улы хуҗа булып калган. Ләкин аның улы атасы кебек булдыклы булып чыкмаган. Ялкаурак, мактанчыграк булган. Эчәргә, тәтиләр белән чуалырга, ашык уйнарга яраткан. Башта ул малларын, колларын оттырган, аннан кәмәләрен. Иң ахырда... тора торган өен оттырган. Юк, өен ул оттырмаган. Биш мең сум оттырган да, сатар нәрсәсе калмагач, менә шушы өен сатарга мәҗбүр булган. Җәбирнең этисе дә яшь чагында кәмәче булган. Утраудан утрауга йөреп, ерак илләргә — Кәмигә, Акайга, Әбләгә йөреп шулай ук мал, байлык җыйган. Диңгезгә якын урнашкан җиз бакыр койма урамында өй сатып алу турында ул күптән хыялланган булган. Менә шул җай чыгу белән, артык сатулашып та тормыйча, әлеге таш өйне суккан да алган.

Алар инде монда егерме беренче ел торып яталар. Агалары Мирзый бу өйгә күченеп килгәндә биш яшьтә булган. Шуннан соң менә Җәбир туган. Җәбирдән соң иң кечесе — түкәнәге Әкълимә туды. Ул — җиткән кыз. Изге анабыз Әбетигә багышлап садака биреп кайтачак та шуннан соң инде кияүгә барачак... үзенә кияү сайлаячак. Аннан соң, телиме-теләмиме, Җәбиргә дә өйләнергә,

үзенә оя корырга туры киләчәк. Ләкин ничек итеп оя кора алыр икән соң ул, тәңрем? Әтисе иң элек Мирзыйны өйләндергән, аңа үз җиренең яртысын бүлеп биреп, калымын түләгән, өен салышкан. Шуннан соң менә инде ничә елдан бирле ул, һәр сумын кысып тотып, түкәнәгенә бирнәлек өчен акча җыйды. Садака биреп кайтканнан соң аны кияүгә бирергә, башкалар кебек зурлап туй ясарга туры киләчәк. Иң ахырда менә Җәбир кала. Калымга да, туй уздырырга да аның бернинди байлыгы юк. Менә шушы таш өй дә, аркылысы-буе биш дилбегәлек җире, бакчасы, каралты-курасы, карт, авыру әтисе-әнисе дә, шулай ук карт ике колы. Аннан соң арыкта, таш койма буенда, ун кеше сыешлы бер кәмәсе.

Бөтен байлыгы менә шул. Өйләнергә исәпләсәң, йә, өеңне сатып, койма тышындагы балчык камыш куышка күченәсең, яисә калым сорамаган бирнәсез бирәр ярат- маган карт кызга өйләнәсең. Менә шул, икенең берсе.

Бүген дә, кичә дә, моннан элекке көнне дә... күптән, бик күптән Җәбирне менә шундыйрак уйлар борчый. Уйларның әле берсе көчәя, әле икенчесе көчәя һәм аңа тынычлап йокларга да, тынычлап эшләргә дә комачаулый иде. Ләкин моңарчы әле ул үзенең язмышы, үзенең хәле турында уйлаганда да ничектер читтәге, ерактагы нәрсә турында уйлый иде кебек. Бүген исә, хәзер менә борчулы уйлар һәм күңелсез киләчәк турыдан-туры аның күзенә карый сыман тоелды. Ничәнче ай инде менә урын өстендә яткан карт атасы булып, һәрвакыт уйчан, моңсу кыяфәтле анасы булып, алардан да бигрәк буй җиткән, яшь, таза, чибәр сеңлесе булып карый сыман тоелды.

— Кайда йөрисең? Киен яхшылап, — диде әнисе, баскычтан ашыкмыйча гына менеп килгән улына каршы атлап.

— Киенермен, инәй, — диде Җәбир, карусыз гына. Ләкин ул киенергә үз бүлмәсенә кереп китмәде, ачык ишектән түр бүлмәгә узды. Бүлмә сары, кызыл, күк төсләрне аралаштырып, матур итеп буялган, түшәме агартылган һәм түшәм почмагына өй әйләнә калку итеп очлы яфрак сыман бизәкләр тезелгән. Идәнгә сугылган бизәкле йомшак палас җәелгән. Җәбир әтисенең ятагы янына килде, аның баш очында туктап калды. Әтисенең күз карашы белән очрашкач, кинәт аңа әтисе бик-бик кызганыч булып китте. Ул менә урыныннан да кузгала алмый. Аяклары йөрми. Ашавы-эчүе дә, башкасы да шунда — урын өстендә. Нинди кыендыр аңа! Акайлар илендә, салкын якта, аңа зәхмәт кагылган. Имче шулай диде.

Зәхмәт кагылган җиргә барып корбан бирергә кирәк — шунсыз китмәс, диде. Ләкин аның үзеннән башка кем белә ул зәхмәт кагылган җирне? Кем алып барсын аны анда? Җәбир бай булып, кимендә бер илле ишкәкчесе булса, атасын ничек тә алып барыр иде шул каргалган салкын якка. Яисә ул аны күтәреп йөртү өчен яшьрәк, тазарак коллар сатып алыр иде.

— Без кайтканчы ялыкмассың микән син, этәй? — диде Җәбир этисенә. — Бакчага чыгарыйкмы әллә?

— Озак булырсыз микәнни анда? — диде этисе, ике як терсәгенә таянгандай итеп.

Җәбир, тиз генә аның баш астына кулын тыгып, изелеп беткән мендәрен агач ятак кырыена бастырыбрак куйды.

— Белмим шул, — диде Җәбир.

— Суси монда каладыр ич? — диде этисе.

— Калмыйча! Барыбыз да киткәч, син монда нишләрсең берүзең? — диде энисе, улы белән иренең нәрсә турында сөйләшүен ишетеп, күрше бүлмәдән.

— Ярар, минем өчен тоткарланмагыз. Болай да соңга каласыз бугай, — диде ата кеше.

Өстенә яңа күлмәк, күлмәк өстеннән кыска җиңле камзул киеп куйган энисе, нидер эзләнеп, авыру карты яткан зур бүлмәгә килеп керде.

— Соңга каласыз дип, ни... иртәсе-соңы юк инде аның, — диде ул, иренә җавап итеп, үзалдына сөйләнгән сыман. Аннары ул, Җәбирнең нишләптер ашыкмавын күреп, җиңелчә генә аңа кычкырынып алды: — Нәрсә булды соң сиңа, йокың туймаган кеше кебек катып тик торасың? — диде.

Җәбир сүзсез генә этисе бүлмәсеннән чыгып китте. Ул бүген чыннан да йокысы туймаган кеше кебек иде. Дөресен әйткәндә, аның беркая барасы килми. Энисе белән, Әкълимә белән, карт кол белән урамнан, бөтенесенең күз алдында җәяүләп барасы килми. Юлда танышлар очраячагын һәм кызганып, мыскыллы караш ташлап китәчәкләрен бик яхшы белде. Аннан да бигрәк ул анда баргандамы, баргачмы... Талияне, Талиянең инәсен, туганнарын, караларын очратачак иде. Алар инде сыңар колны ияртеп җәяү килмәячәкләр. Алар анда яхшы итеп бизәлгән арбага яхшы итеп бизәлгән атлар җигеп киләчәкләр! Менә нәрсә куркыта иде чынында Җәбирне!

Этисенең дә, энисенең дә кәефләрен кырмас өчен ул аларга бу турыда, билгеле, берни дә әйтмәде. Үзләренең

хәлләрен алар болай да бик яхшы аңлыйлар. Шулай да аның Әкълимәне күреп, аңа бер-ике сүз дә әйтәсе бар. Чынында ул монда шуның өчен генә керде дә бугай.

Җәбир ярым ачык ишекне каерып ачты да, берни әйтми-нитми, сеңлесе янына керде. Әкълимә, ике кулын тезләре өстенә куеп, аркалы урындыкта тыйнак кына көтеп утыра иде. Тәрәзә каршысында, кечкенә өстәлчектә аның төзәнү-бизәнү әйберләре — буяулары, эскәкләре, таштан, көмештән ясалган уймак кадәр генә савытлары тезеп куелган. Бүлмәгә җиңел хушбуй исләре чыккан. Төзәнгәч, ясангач, сеңлесе Җәбиргә башка вакыттагыга караганда чибәррәк булып күренде. Буйга ул уртачадан калкурак, гәүдәсе төз, яшь күкрәге матур булып кабарып тора. Аккошныкы кебек ак түгәрәк муены гадәттәгедән озынрак булып күренә. Яшел, күк, ак һәм кызгылт ташлардан кырып, шомартып ясалган муенса аңа аеруча килешә. Колагында — бал корты сыман итеп ясалган юка алтын алкалар, беләгендә — бизәкле көмеш беләзек. Кара чәчләре көлтә кебек күпереп тора, кашлары кара. Озынча битенә кершән ягылган, бит очларының ике ягында да алсу миңнәр. Иреннәренә кызыл сөрткән, күзләренә сөрмә тарткан. Алтын сарай кызларыннан бер дә ким түгел. «Шулай да... шулай да Талия матуррак» дип уйлады Җәбир.

Әкълимә үзен ничек тотарга да белми иде бугай. Ул кайгылы, борчулы күренергә тырыша, ләкин шул ук вакытта эчтән генә сөенә һәм каушый да иде бугай. Абыйсын ул кергәннән артык моңсу йөз белән каршылады, ләкин шундук онытылып, тигез ак тешләрен күрсәтеп, елмаеп җибәрде.

— Сине танырлык түгел! — диде Җәбир, чын күңелдән сокланып. — Мака сар үзенә алып калмаса ярый инде.

Әкълимә куанычтан лалә чәчәгедәй кып-кызыл булды.

— Мака сар Талияне алып калмасын дип телә, — диде Әкълимә, ни дә булса җавап бирергә кирәк булган өчен.

Талия исемен ишетү белән, Җәбирнең йөзе шундук үзгәреп китте. Әйе шул, Әкълимәне мака сар үзенә алып калса, сеңлесе бары бәхетле генә булачак. Ләкин мака сар Талияне алып калса, Җәбир беркайчан бәхетле була алмаячак. Алар беркайчан кавыша алмаячаклар. Нәкъ менә шуннан курка түгелме соң инде Җәбир?!

— Ул синнән чибәррәк түгел, — диде Җәбир, төшенке генә.

Ул моны сеңлесенең күңелен күтәрүдән бигрәк үзенең күңелен күтәрү өчен әйтте бугай. Үз ялганына аның әллә

ни күңеле күтәрелмәде, аның урынына Әкълимәнең йөзе тагын алсуланып китте. Яшь матур күзләрендә куаныч очкыннары балкыды.

— Мака сар мине үзенә алып калса, мин сиңа булышырмын, абый! — диде ул, пышылдап, сер итеп. — Мин сиңа кү-үп итеп алтын җибәрермен. Калымга да булыр, Талиягә өйләнергә дә, әти-әнине карарга да булыр...

— Ак юл сиңа, — диде Җәбир, елмаеп, күңеле булып.

Үзе исә уйлап куйды: «Мака сар сиңа шулкадәр алтынын чыгарып тоттырыр микән соң?» Мака сар алтын бирергә яратмый. Ул бары алырга гына ярата. Шул чакны әнисенең ашыктырып кычкырган тавышы ишетелде.

Җәбир учына йомарлаган нәрсәсен тиз генә сеңлесенең кулына сузды да, шулай ук сер итеп, пышылдап:

— Талиягә бирерсең. Миннән бүләк. Югалтмасын, — диде.

— Бирермен, — диде Әкълимә, абыйсы биргән бүләкне тиз генә учына йомып.

Шул ук вакытта ул күз кырые белән генә аңа карап та алды. Бу бәхет ташы дип йөртелә торган искиткеч күк таш иде. Бәхет ташын каяндыр бик ерактан, көнчыгыштагы җирләрдән алып кайталар иде. Каян алган аны абыйсы Җәбир? Нишләп ул аны моңарчы сиздермәде икән? Әти бирде микәнни? Күрәсең, шулайдыр. Бәхет ташы турында теләсә кемгә сөйләргә ярамый, диләр ич.

— Нәрсә булды соң сиңа, улым? — диде әнисе, тагын Җәбирне күреп, аптырап.

— Берни булмады, — диде Җәбир, бер дә юктан елмайган булып.

Әнисе Әкълимәнең өстен-башын күздән кичерде дә, яратмыйча:

— Нишләп болай төзәндең әле? — диде.

— Үзең әйттең ич, әни, — диде Әкълимә, аклангандай итеп.

— Әйтүен әйттем, ләкин муенсалар, алкалар, йөзекләр тагарга кушмадым, — диде әнисе. — Сал барысын да. Син алырга барасың, бирергә түгел. Боларны күрү белән шундук синнән салдырып алачаклар. Им өенә аяк басу белән, синдәге бөтен нәрсә Изге ананыкы булып исәпләнелә. Күпме тукыдым мин сиңа!

— Ярар, салырмын, — диде Әкълимә. Аның учына йомган күк ташны әнисенә күрсәтәсе килмәде. Шуңа күрә ул, әнисенә яны белән борылып, муенсасын сала башлады. Әнисе башка тукталып тормады, ашыгып чыгып китте. Анда аның тагын нидер эшлисе бар иде бугай.

Ниһаять, тиешенчә җыенып беткәч, алар дүртәүләшеп этиләре бүлмәсенә керделәр, утырыштылар. Әнисе, кулларын югары күтәреп, изге аналарга багышлап сүз әйтте. Аннан соң урында яткан картына карап тантана белән:

— Түкәнәебезне изге Әбетигә садака бирергә алып барабыз. Син каршы түгелме? — диде.

— Каршы түгел, — диде этисе, кызына ягымлы күз карашы ташлап. — Ак юл сиңа, бинтекәм. Изге анабыз алдында бурычыңны үтәү — борынгыдан калган йола. — Шулай дигәч ул икеләнгәндәй бераз тынып ятты. Шуннан соң, карчыгына эндәшеп, әйтеп куйды: — Абыстай белән сөйләшеп кара әле, озаграк тора алмасмы анда безнең кызыбыз. Үзенә бирнәлек өлеш алып кайта алмас микән?

— Сөйләшеп карармын, — диде ана кеше, коры гына. Шуннан соң ул, тагын ике кулын күтәреп, дога сүзләрен укыды да: — Аллага тапшырдык, — дип, урыныннан торды һәм беренче булып ишеккә юнәлде. Аның артыннан Әкълимә кузгалды, Әкълимә артыннан — Җәбир, Җәбир артыннан кара кол кузгалды. Шулай бер-бер артлы тезелеп алар капкадан чыктылар. Суси эчтән капканы бикләп калды.

Капкадан чыккач та алар тигез итеп таш җәелгән киң урамны аркылы чыктылар да уңга борылдылар һәм, беркадәр җир урам кырыеннан баргач, сулдагы Песи тыкрыгы дип аталган тыкрыкка каердылар. Песи тыкрыгы бик тар иде — ике атлы-арбалы очрашса, аерылышып китәрлек түгел иде. Тыкрыкка да тигез итеп таш җәелгән. Таш араларында, койма буйларында саргайган үләннәр тырпаеп утыра. Тыкрыкның як-ягында, биек койма өстеннән шәрә ботакларын сузып, төрле җимеш агачлары калкып утыра. Әле яңа яз башы булса да, көн бик җылы. Түбә өстендәге зәңгәр күк чалт аяз иде. Бөтен тирә-яктан дәртле кошлар тавышы яңгырап тора һәм язгы җир өстеннән искиткеч җиңел исләр аңкый иде.

Тыкрыкта аларга беренче булып ниндидер ак песи очрады. Песи, ят кешеләр килгәнне көтеп, койма буена посып торды да, нәрсәдәндер куркып, юлны аркылы кисеп чыкмакчы булды. Җәбирнең әнисе, песинең юлны кисәргә ниятләвен күреп, адымын кызулый төште, кулын селтәп, тегене куалап җибәрде. Песи, кире борылып, кытыршы ташлардан өелгән койма өстенә менеп китте һәм, «кая барасыз?» дигән кебек, арттан мияулап калды.

Әкълимә түзмәде, пырхылдап көлеп җибәрде. Әнисе, борылып, кызына шелтәле күз карашы ташлап алды. Ләкин ни дә булса әйтергә өлгермәде, борылыштан юеш ишкәген иңбашына салып, яланөс, яланаяк килеш, диңгез ягыннан кайтып килүче Абра килеп чыкты. Ул Җәбирләргә каршы якта гына тора.

— Юлыбыз уңар — ир кешене очраттык, — дип сөйләнде Батима карчык.

Абра, алар белән тигезләшкәч, ялгыш кешегә тия күрмәсен дип, ишкәген җайлабрак тотты, баш иеп күршесе Батима карчык белән исәнләште, төзәнгән-бизәнгән Әкълимәгә, борынын салындырыбрак барган Җәбиргә күз салды. Ул аларның кая баруларын шундук шәйләп алды һәм, якын итеп, теләктәшлек белдереп:

— Юлыгыз уң булсын — баеп кайтсын чибәр күршебез, — диде.

— Амин, шулай булсын, — диде кортка, тукталып тормыйча.

Әкълимә исә бакыр тәнле, озын кара чәчле яшь ирнең «чибәр күршебез» дигән сүзенә эреп, кызарынып китте һәм каш астыннан гына Абрага күз сирпеп алды. Җәбир эндәшмәде. Ул әйтерсең диңгез буеннан кайтып килүче Абраны күрмәде дә. Бар нәрсәдән аның өчен үз уйлары-борчулары артыграк иде. «Бәхет ташын Талия саклый алыр микән?» дип уйлады ул, әнисенең Әкълимәгә әйткән сүзләрен исенә төшереп. Бит абыстай кызларның бар нәрсәсен үзенә алып кала торган булса, ул биргән бәхет ташын гына алмый калыр микән? Бу турыда Әкълимәгә ныгытып әйтергә иде дә, әллә үзе белер микән? Аннан соң, нишләп әнисе бу Песи тыкрыгыннан китте соң әле? Алар бит башта ук җәяүләп барырга сөйләшкәннәр иде. Җәяүләп барганда, Песи тыкрыгыннан түгел, Кыек тыкрыгыннан чыгарга кирәк иде туры урамга. Аның шулай дип уйлавы булды, улының уйларын сизенгән кебек, Батима карчык туктады да, балаларына борылып:

— Абзагыз янына сугылырга булдым әле, — диде. — Нишләп кеше көлдереп җәяүләп йөрергә? Кайчан барып җитәсең, кайчан кайтып җитәсең аннан. Кәмәсенә утыртып алып барсын.

— Ул соң өйдәмени? — диде Җәбир болай гына. — Төнге кизүдә бугай ич ул.

— Кизүен кизүдәдер, — диде әнисе. — Иртүк Суси кереп чыкты. Килен әйткән, кайтмады әле, дигән, сезне көтәрмен, дип әйтте, дигән.

— Көтәр, көтми ни, — дип куйды Җәбир, теләр-теләмәс кенә үзалдына мыгырданып.

— Көтәр, ник көтмәсен, аның да түкәнәе бит! — диде энисе, Җәбиргә ачулангандай итеп.

Мирзый бала вакытында ук көнчел һәм комсыз булды. Бар нәрсәне ул үзенә алырга, үзенеке итәргә һәм һәркайда, һәрнәрсәдә беренче булырга тырышты. Нишләптер ул энесен дә, сеңлесен дә якын итмәде. Өйләнеп, башка чыккач, аның мондый холкы юкка чыкмады, киресенчә көчәйде генә бугай. Иң зур тавыш ата җирен бүлеп аңа йорт салыр алдыннан чыкты. Мирзый җирне тигез итеп икегә бүләргә теләде. «Миңа яртысы, Җәбиргә яртысы», — диде. Мондый оятсызлыкка ата-ананың да, балаларның да бик нык ачуы килде. Әтисе әйтте: «Мине, эниеңне, сеңлеңне кая куясың?» — диде. Мирзый, күп уйлап тормыйча: «Әкълимә кияүгә китәчәк, сез озакламый мәңгелек йортка китәрсез, — диде. — Барлык байлыкка баш булып Җәбир калыр», — диде. «Безне бүгеннән җир куенына илтеп салыр идеңмени?!» — диде әтисе, бик нык ярсып. «Мин илтеп салмам, вакыты җиткәч, алла үзе алыр», — диде Мирзый, сүзен бирәсе килмичә.

Аларның мондый тавышлануын күршеләр дә белделәр. Мирзыйга аңлатырга тырышып караучылар да булды, оялтучылар да булды. Мирзый оялмады да, аңларга да теләмәде. Ләкин карт кәмәче атасы да сүзендә нык торды. Өлкән улына ул җирнең өчтән берен генә бирде. Яшь килен ирен казыйга барырга котыртып карады. Ләкин Мирзыйның шулай да казыйларга барып йөрмәскә башы җитте. Чөнки түрә буенча, башка чыккан улына ата-ана күпме җир бүлеп бирсә, шулай тиеш иде. Казый монда берничек тә Мирзыйны якламаячак иде. Шулай итеп, Мирзый тавышны зурга җибәрмәде, ләкин башка чыккач алар, чит кешеләр кебек, үзара аралашмас булдылар. Батима карчык, күршеләргә ашка-суга баргач, Мирзыйны котырта торган «юха киленен» берике мәртәбә хурлап сөйләде дә шуннан соң тынып калды. Карты әйтте: «Килененнең дә, улыңның да данын сатма, — диде. — Аннан сиңа алтын яумас, — диде, — кеше көлә генә ул», — диде.

Мирзый диңгез тамагында капка сагында тора иде. Аның эше авыр һәм тынгысыз, ләкин шул ук вакытта төшемле урын. Мака сар башкаланың диңгез капкасы сакчыларына яхшы түли. Мирзыйны инде шактый күп байлык туплаган дип, яхшырак урыннан үзенә ике катлы, иркен җирле йорт сатып алырга итә икән дип

сөйлиләр иде. Ләкин монысы инде аның имеш-мимеш кенә бугай — күрше әз генә хәлләнә башладымы, көнчелләр күбәя бит ул. Ни генә булмасын, Җәбирнең күршедәге абзасының баеганын да сизгәне юк, каядыр күченеп китәргә җыенганын да ишеткәне юк.

Шулай да Саркелгә кадәр илтеп куярга кәмә биргәндә яисә үзе илтеп куйганда әйбәт булыр иде. Абзасы аларга яхшы күз белән караса, яшәве дәрәҗәлерәк булыр иде. Көчле абзаңа таяну үзе ни тора! Болай дошманлашып яшәү, билгеле, күңелле түгел. Әлегә бит этисе урын өстендә ятканга гына аны өйдә тоталар. Караучылары юкка күрә генә. Көннәрдән бер көнне... бит аңа да — Җәбиргә дә — кәмәче булып ишкәк ишәргә туры киләчәк. Капкадагы абзаң белән дус булсаң, эшең уңар.

Песи тыкрыгы таш җәелгән киң, якты кәмәчеләр урамына килеп төртелде. Урамның каршы яктагы таш өйләре туры төшкән иртәнге тәбәнәк кояш яктысында аеруча матур, җыйнак һәм ягымлы булып күренде. Каладагы барлык озын урамнар кебек, кәмәчеләр урамы да, башкаланың тышкы бождра сызыгына якынлашып, кәкрәеп сузылган иде. Урам читенә җәяүлеләр йөрү өчен бер-ике адымлык тар гына сукмак калдырылган, сукмак яныннан ук шактый биек таш койма калкып утыра. Берәр, икешәр катлы таш өйләр ишегалды уртасынарак, урам як коймадан эчкәрәк кертеп салынган иде. Шунлыктан урам як койма өстендә ямь-яшел яфраклы җимеш агачлары, бор сабаклары күпереп утыра. Кайбер өйнең чарлакларына, кыек асларына кадәр үрмәләгән бор, йөзем сабаклары, үрмә гөлләр сузылган. Өйләрнең бер төрлесе — тоташ кызгылт ташлардан, бер төрлесе ак, кара ташлардан салынган. Коймалар шулай ук бер үк төсле генә түгел. Ак таштан салынган өйнең коймасы карадан яисә кызгылт таштан, киресенчә, кызгылт таштан салынган йортларның коймалары ак яисә кара таштан өелгән иде. Иртәнге кояш нурында төрле төстәге шома ташлар, ялтйолт килеп, күзнең явын алып тора. Урамга чыга торган капкалар, капка башлары, капка баганалары аеруча тырышып, яхшы итеп, сырлап-бизәп эшләнгән. Кайбер капка башларына ак таштан, йә булмаса җиздән сыннар, сакчы алла сурәтләре утыртылган. Капкалар кызыл, сары, күк төсләргә буялган. Капка кадаклары, тоткалар, бикләр — барысы да җиздән: ялт итеп тора. Койма аша агачлар арасында җыйнак кына каралты-куралар күренә.

Кәмәчеләр урамы Җәбирләр урамына караганда чистарак, пөхтәрәк һәм матуррак булып күренде. Кәмәчеләр

урамы Диңгез капкасына якын гына урнашкан. Урамның каршы яктагы йортларының арткы коймалары барысы да тышкы арыкның яр буена терәлеп тора. Ләкин, беренчедән, яр өстеннән калкып торган койма биек һәм киң, икенчедән, бау баскыч белән теләсә кай төштән суга төшү катгый тыелган иде. Монда чит ил кешеләре аеруча күп була, шуңа күрә урам башлыгы чисталыкны, тәртипне тикшереп, күзәтеп кенә тора, әгәр берәрсенең коймасы пычранса, ташы кителсә яисә өй буендагы сукмагы бозылса, үз кешеләрен ияртеп шундук килеп җитә һәм төзәттерергә куша иде.

Кәмәчеләр урамына килеп чыккач та, Батима карчык, арттан килгән балаларын көтеп, тар сукмакта туктап калды. Тыкрыкның сул ягыннан урам уртасыннан күпергә таба ниндидер атлылар килә иде. Батима карчык, күрәсең, аларның узып киткәнен көтәргә уйлады.

— Кемнәр соң болар? Таң тишегеннән торып кая баралар? — диде ул, үзалдына сөйләнеп, бик үк яратмыйча. Батима карчык «таң тишегеннән» дисә дә, вакыт алай ук иртә дә түгел һәм бу вакытта урамнарда инде атлылар да, җәяүлеләр дә йөри башлый иде. Аның яратмыйча сөйләнүенең сәбәбе башкада — кемнәр соң? дип танымаган булса да, ул аларны еракта ук танып алды. Болар Тишек Комган дип йөртелгән урамда торучы атаклы чүлмәкче Галләм балалары булырга тиешләр сыман. Чүлмәк ясап, чүлмәк сатып баеды Галләм. Күршесенең йортын алып, ике урынны бер итеп курчак кебек иттереп яңа йорт, каралты-кура салдырды. Ишегалдына керсәң, әйләнеп чыккысыз. Байлыгына чыдый алмый. Әнә балаларына атлар, арбалар алып бирде. Рәтләп эштә дә түгел — көне-төне уен, көлкедә, күңел ачуда.

Батима карчык, тегеләргә җәяүле килеш күренмәс өчен, үзе дә сизмәстән тыкрык ягына чигенгәндәй итте. Галләмнекеләрне Җәбир белән Әкълимә дә күреп алдылар. Әкълимә никтер кызарынып китте, күз карашын түбән иде, Җәбир исә күренмәс өчен энисе белән Әкълимә арасына яшеренергә тырышты.

Алар пар ат җигелгән ике арба белән киләләр иде. Ике тәгәрмәчле җиңел тарантасның алдагысына, ал төстәге җиңел күлмәк киеп, матур итеп таралган, үрелгән һәм шомартылган кара чәченә кашкарый кадап, Талия утырган, энисе Хәтимә карчык аның янына кысылган. Икенчесенә Талиянең бертуган энесе Аблай утырган. Талия дә, Аблай да дилбегәне үзләре тотканнар. Алар,

күрәсең, иртән артык тавыш чыгармаска тырышып, атларын тыебрак киләләр. Ләкин җиңелчә атлатканда да ат тояклары, тәгәрмәч тавышлары таш урамда әллә каян ишетелеп, яңгырап тора. Атлы арба килгәнен ишетеп, шундук капкалар ачылды һәм яртылаш кысылган капкаларда кызыксынган йокылы-уяулы йөзләр күренде. Каршыдагы бер йортның чарлагына, чәчәкләр арасына, яшь баласын күтәреп, бер хатын килеп капланды.

Песи тыкрыгы турысына җиткәч, үзләренең танышларын күреп, атлылар тукталгандай иттеләр. Талия, елмаеп, Әкълимәгә нидер кычкырды. Серле күз карашы белән Җәбирне дә өтеп алды. Талиянең әнисе Хәтимә карчык исә сукмактагы кешеләргә борылып исәнлек-саулык сүзләре әйткән булды, ләкин шуннан ары ачылмады, алдына карап, кукраеп, кызына нидер әйтеп алды. Аблай исә, бөтен урамга кычкырып:

— Исәнмесез! — диде.

Берүзе бер тарантаска утырып дилбегә тотып барганга, аның авызы колагына җиткән. Аблай да, Җәбир кебек үк, апасын озата бара иде. Җиз авызлыкларын туктаусыз чәйнәгән, туктаусыз пошкырып һәм туктаусыз ыргылып кына торган тук, симез җирән бияләрен Аблай көчәнеп тыйды да тыкрык авызына ук туктап калды һәм үзе янындагы буш урынга күрсәтеп:

— Әйдә, утыр, Җәбир! — дип кычкырды.

Җәбир аны әйтерсең ишетмәде дә. Аны берьюлы каршылыклы уйлар биләп алды. Күз аллары томалангандай булды. Талия алдында, Аблай алдында ул үзенең бик нык түбәнәюен, никтер оятка калуын бик яхшы аңлады. Ләкин шул ук вакытта ул күз карашын туктаусыз Талия ягына юнәлдерде. Мондый хәлендә ул, билгеле, аңа борылып та карамаска һәм башын югары күтәреп таш сын кебек горур гына басып торырга тиеш иде кебек. Ләкин ул алай булдыра алмады. Талия ягыннан, аның чибәр йөзеннән, аның сөйкемле гәүдәсеннән, килешле киемнәреннән ниндидер яшерен нур бөркелә сыман иде, һәм ул аны туктаусыз үзенә тартып тора иде.

Җәбир эндәшмәгәч, Батима карчык, үз-үзен мәҗбүр итеп:

— Бар әйдә, бар, улым, тоткарланма, — диде Аблайга.

Аблайның шат йөзе сүрелеп калды. Шулай да ул артык күңелен дә төшермәде — алдына борылды да дилбегәсен бушайта төште, утырган урынында калкып куйды һәм, иртәнге таш урамны яңгыратып:

— Әйдә! — дип кычкырып җибәрде.

Атлылар узып киткәнче тыкрыктагы җәяүлеләр, бер тирәгәрәк укмашып, тиз генә исләренә-акылларына килә алмый тордылар да, барысы бергә кузгалып, урам аша чыга башладылар. Шул чакны тагын еракта атлылар якынаеп килгәне күренде.

— Нәрсә булган соң боларга? — диде Батима карчык, үртәлеп.

— Безгә нәрсә булса, аларга да шул булган, — диде кол, сүзгә катышып.

— Безгә булган — аларга юк, аларга булган — безгә юк, — дип куйды Җәбир, күңелсез генә.

— Булыр әле, балакайларым. Күңелегезне төшермәгез, — диде Батима карчык кинәт, ясалма бер күтәренкелек белән. — Тауга карасаң, тау биек. Галләмнең ничек баеганын белмәгән кеше юк. Урлаганын урлый, алдаганын алдый. Бер килеп чәнчелә әле ул андый кеше.

Аңа җавап кайтаручы булмады. Чәнчеләме Галләм, чәнчелмиме — аны әлегә белгән юк. Ләкин анықылар менә дигән биек тарантасларга утырып, бөтен урамны шаулатып, тирә-якка ят исләр таратып китеп бардылар. Алар менә җәяү теркелдиләр. Каты таш өстеннән, яланаяк. Болай да кыен түгел, шулай да үзеңнең атларыңны тотып, үзеңнең йомшак утыргычлы бай арбаңда утырып бару тагын да күңеллерәктер ул.

Арттан икенче атлылар куып җиткәнче алар шактый юл алдылар һәм ашыгып тагын бер тыкрыкка кереп киттеләр. Урам белән барганда алар капка янына тизрәк барып җитәчәкләр иде, билгеле. Ләкин, ураy булса да, моннан тынычрак, аулаграк булды. Чыннан да алар башка беркемне дә очратмадылар. Тыкрыктан арык янына ук барып чыктылар да буш, ташландык урыннан сузылган тар сукмак буенча диңгез ярына якын гына салынган капкага юнәлделәр.

Иртәнге диңгез әле тыныч иде, яр буена шаулап дулкыннар да бәрелми, җил дә исми, акчарлаклар чыр-чуы да ишетелми. Чак-чак кына тирбәлеп, чайкалып яткан зәңгәр диңгез өсте иртәнге кояш нурында көмеш сыман ялт-йолт килә. Диңгезнең ярына якын тирәләре — аксыл-зәңгәр булып, ерактагыраклары исә куе зәңгәр булып күренә иде. Диңгез ярыннан бер йөз карыш чамасы читтәрәк, ике ягы да таш койма белән нығытылган киң һәм тирән арык — Тамак дип йөртелгән арык аша киң һәм биек итеп күпер салынган. Күпер киң һәм тирән арыкның бер ягыннан икенче ягына чыгу өчен генә хезмәт итми. Күпер астында бер як баганадан икенче

як баганага җиз чылбырдан җыелган челтәрле капка куелган. Ләкин бу капка, башка капкалар кебек, күчәнгә утыртылмаган һәм аны каерып ачып та булмый. Аны җыялар яисә тартып сузалар гына. Чылбырларның өске дүңгәләкләре аркылы сузылган озын җиз чыбыкка кидерелгәннәр һәм кирәк чакта капканы чаршау сыман итеп җыярга да, тарттырып-сузып куярга да була.

Җиз капканың ике ягында да көнен-төнен зур кәмәләр белән кораллы сакчылар сакта торалар. Калага килгән-киткән кәмәләрне, каекларны карыйлар, тикшерәләр. Чит илләрдән килгән һәрбер кәмәдән кәмәнең зурлыгына карап кулбау алына. Кулбау бары алтын белән генә түләнә. Алтын тулысынча мака сар казнасына озатыла.

Җәбирләр җыйнаулашып яр буена таш күпер янына килеп җиткәндә, җиз капка әле ачылмаган иде. Капкага якында гына, арык эчендә һәм шулай ук диңгез яр буенда әкрен генә тирбәнеп бик күп кәмәләр тора. Аларның инде күптән җилкәннәре төшкән, ишкәкләре алынган. Кайберләрен яртылаш ярга тартып куйганнар, кайберләрен яр читендәге таштагы боҗраларга арканлап куйганнар. Әле анда, әле монда ят сүзләр ишетелеп куя. Агач читлекләрдә сатарга алып бара торган сарыклар кычкыра, сыерлар мөгри. Зур корсаклы биек бер кәмәгә, араталар ясап, атлар төягәннәр. Икенче берсендә ярым шәрә коллар күренә, өченчесенә таудай итеп капчык тутырганнар. Арык аша салынган киң күпернең теге ягында, күпер эчендә дә, шулай ук бу якта да атлы арбалар, җәяүлеләр күренә. Алар да кала капкалары ачылганын көтәләр. Ләкин аларның капкасы коры җиргә, яр буена салынган. Ике ягына да биек итеп таш койма коелган туры юлның яисә урамның диңгез яр буендагы башына шулай ук капка ясалган. Капка янында шулай ук кораллы сакчылар тора һәм капкага килүче теләсә нинди чит ил сәүдәгәреннән алтын белән тамгалык алына. Коры җирдән, диңгез буеннан башланып киткән таш юл бераздан су боҗрасы аша салынган озын күпергә барып керә. Су боҗрасын үткәч яңадан җир боҗра өстеннән йөгерә һәм тагын су боҗрасы аша салынган ябулы күпердән чыга да туп-туры үзәккә — Изгеләр калкулыгына барып чыга. Диңгездән керү юлы бер генә булса да, коры җирдән керү юллары дүрт яктан дүртәү һәм алар барысы да Саркелгә алып баралар.

Тамакның ике ягына да шомартылган чыңкый ташлардан өелгән бик зур багана утыртып куелган. Баганаың урта бер җиренә төрле тамгалар белән изге сүзләр

язылган. Җәбир кечкенә чагында аз-маз укырга-язарга өйрәнгән иде, баганаларга нәрсә язылганын бик яхшы белә. Бу якка килеп чыктымы, ул һәрвакыт шул сихри баганаларга һәм андагы серле язуларга карап торырга ярата. Хәзер дә ул, энисе белән сеңлесеннән читләшеп, әлеге багана янына барып килмәкче булды. Ләкин энисе аның каядыр китәргә чамалавын күреп кулыннан тотып алды да, коры гына:

— Туктале, йөрмәле теләсә кая, — диде.

Җәбирне ул күпер янындагы тәбәнәк таш йортка таба әйдәде. Күпер төбендәге ул таш йортта гадәттә төнге кизүләр, күпер сакчылары, тамгачылар була. Мирзый да, билгеле, шунда булырга тиеш. Җәбирнең һич тә ул торакка аягы тартмады. Абзасы Мирзыйны күрәсе килмәгәннән түгел, Талияне күрәсе килмәгәннән, дөресрәге, тагын аның тәкәббер энисе күзенә чалынасы килмәгәннән анда барасы итмәде. Песи тыкрыгы яныннан бик шәплән кенә узып китсәләр дә, алар шунда күпер авызында, әлеге сакчылар торагы янында, тукталып калганнар иде.

— Үзең генә бар инде, инәй. Без шушында торып торырбыз, — диде Әкълимә дә, абыйсының уйларын аңлагандай.

— Алардан курыккан күлмәк күптән тузган! — диде Батима карчык, батыраеп һәм никтер үртәлеп.

Шулай да ул балаларын ирексезләп тормады, шәпшәп атлап, таш өстеннән күн аяк чабатасын өстерәп, әлеге торакка таба китеп барды. Ләкин аңа торакка барып җитәргә дә туры килмәде, каршысына өлкән улы Мирзый килеп чыкты.

Мирзый өстенә алыплар киеме кигән, биленә киң каеш буып агач кынылы җиз хәнҗәр таккан. Башында кош каурыйлары тезелгән матур калпагы кукраеп тора. Мирзый үзе унбаш исәпләнелә. Аның карамагындагы кораллы ун сакчы — барысы ялланган чит ил кешеләре.

— Килдегезме, инәй? — диде Мирзый. — Мин сезне көттем. Төнге кизүдән соң әле өйгә дә кайтмадым. Кая соң тегеләр? Ә, анда икән, — диде ул, үзенекеләрне күреп алып.

Ул болай ягымлы, басынкы гына сөйләште. Бер дә инде Җәбир яхшы белгән усал Мирзый дип тормассың.

— Үзең алып барасыңмы, утыртып кына җибәрәсеңме? — диде энисе.

— Түкәнәбезнең шундый изге көнендә илтеп куйганда да ярар иде дә соң, — диде Мирзый, туры гына җавап бирмичә. — Төне буе керфек какмадым. Ни бит әле...

— Ярар, кайтып йокла алай арыгач, — диде Батима карчык, кырт кисеп.

Өлкән улының шулай икеләнеп торуы аңа ошамады. Мондый чакта шулай сөйләшеп торамыни абый булган кеше?!

— Син инде ачуланма, инәй, — диде Мирзый, һаман ык-мык итеп. — Бакчада эш тә күп. Үзең беләсең, минем әлегә колларым юк, барысын да үзем эшлим.

— Килен эшләсен, бала-чагасы юк. Колыны төшеп калмас, — диде Батима карчык, әле күпер ягына, әле үзенекеләр ягына карангалап. — Ярар, бармасаң бармассың! — диде ул, тагын ачу белән. — Хәзер үк утыртып җибәр. Күрәсеңме әнә тегеләрне?!

— Кемнәрне? — диде Мирзый, аңламыйча.

— Кемнәрне булсын, Хәтимә карчыкны, Галләм бичәсен... Йөрәгемә капты. Яныбыздан борылып та карамыйча узып киттеләр. Ике пар ат җикkәннәр! Шартларсың кыланышларыннан!

— Кайгырма, инәй, — диде Мирзый, әнисен юатып. — Баесам әле мин!..

— И йолкыш! — диде әнисе, үртәлеп.

— Тукта, инәй, болай итәбез, — диде кинәт Мирзый, нидер исенә төшеп. — Хәзер сөйләшәм дә мин сезне үзебезнең кәмәгә утыртып озатам. Алардан барыбер алданрак барып керерсез. Күзләре шар булсын.

— Булсын! — диде Батима карчык. — Алар монда капкадан чыкканчы, без тегендә барып җитәрлек булсын.

Мирзый ашыгып сакчылар торагына кереп китте, бераз вакыт анда югалып торды да җилләнеп кире чыкты. Аның кыяфәтенә карап, Батима карчык та, башкалар да эшнең пешкәнен аңлап алдылар һәм аның артыннан китеп бардылар.

Күпер янындагы таш коймадан аска, су өстенә таба, таш баскыч төшә. Таш баскычның аскы басмасы янында кырые белән коймага ышкылып, җиңелчә тәбәнәк зур гына кәмә тора иде. Кәмәнең эче дә, тышы да кызылга буялган. Утыргычларда йокымсырап кояшта янган таза һәм уң як колаклары киселгән ишкәкчеләр — коллар утыралар. Бу көне-төне кизү тора торган һәм тәүлекнең теләсә кайсы вакытында Саркелгә ашыгыч хәбәр алып китә торган яисә шундый берәр ашыгыч йомыш үтәгәндә генә кулланыла торган тиз йөрешле кәмә иде. Бүген төнлә Тамакта бернинди гадәттән тыш хәл булмады, бернинди чит-ят җирләрдән килүче сәүдәгәрләр яисә илчеләр-фәләннәр булмады. Шуңа күрә

Саркелгә ирештерәсе ашыгыч хәбәр дә юк иде. Шуңа күрә кайчагында кызыл кәмәне үз кирәкләренә дә файдаланалар иде. Моның өчен бары кәмә хуҗасы белән сөйләшергә генә кирәк. Мирзый шулай эшләде дә. Үз кеше буларак ул аның белән тиз килеште. Батима карчык белән кызы Әкълимә, улы Җәбир һәм коллары кереп утыргач та, кызыл кәмә җиңел генә яр читеннән кузгалып та китте.

Кызыл кәмә, кузгалып китү белән, киң арыкның уртасына чыкты. Кәмәнең уртасында, иң калку урында басып торган кәмәче югарыдан тирә-якны күзәтеп барды. Кыска-кыска гына итеп койрыкчыга боерыклар бирде. Кәмә кырыена, махсус урыннарга утырган таза ишкәкчеләр бар көчләренә каерып иштеләр. Җиңелчә генә ишкәкләр шыгырдаган, ишкәк очы тиеп су шапылдаган тавышлар ишетелде. Батима карчык иң алга — ачык урынга утырды. Аннан арткарак, аның сул ягына — Әкълимә, уң ягына Җәбир урнашты. Кол иң артка чүгәләде, утырыр өчен аңа урын калмаган иде.

Киңлеге бер ун дилбегә чамасында, озынлыгы бер чакрым булган арыктан озак кына бардылар. Арыкның текә, биек ярлары калын таш белән ныгытылган. Кая карама яр буенда озын сугыш кәмәләре — каркуралар туктап калган. Аларның бер ишесе ярның тышкы ягында, бер ишесе яр астына ясалган зур уемнарга, җир эченә кертеп куелган. Яр өстеннән аска таба төшкән таш баскычларда сакчылар, кәмәчеләр күренә. Иң югарыда биек агачлар, каралты-кура түбәләре күренә. Анда сугышчылар, ишкәкчеләр, кәмәчеләр тора. Алар шунда хатыннары, балалары белән аерым йортларда яшиләр һәм шул ук вакытта көне-төне алмаш-тилмәш кизү торалар. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында алар, каркураларга төялеп, көтелмәгән яуга каршы чыга алалар.

Саркелгә таба юнәлгән кызыл кәмәнең юлына беркем аркылы төшмәде. Алар тиздән беренче су боҗрасына — арыкка аркылы дугаланып сузылып яткан елгага килеп керделәр. Тирә-як яктырып, киңәеп китте. Су боҗрасының ярлары ике яктан да биек таш коймалар белән уратып алынган. Дугаланып, матур булып, серле булып ул бик еракка — үзәккә таба якыная бара. Яр өстеннән калкып, мәһабәт булып ниндидер биек йортлар, манаралар, бакчалар, урманнар күренә. Боҗрада төрле зурлыктагы кәмәләрнең исәбе-хисабы юк: каркуралар, сәүдә кәмәләре, балыкчы каеклары, һәртөрле улаклар...

Җәбиргә болар күптән таныш инде. Шулай да ул мондагы күренешләргә — яр буйларына, таш корылмаларга, оя-оя булып утырган яшелекләргә, борыннарын югары күтәреп йөзгән кәмәләргә караган саен карап туймый. Шул чагында ул үзенең көндәлек кайгыларын, борчуларын оныта. Аның күңелен алла кодрәте белән, кешеләр кулы белән ясалган шундый гүзәл нәрсәләргә соклану һәм горурлану тойгысы биләп ала. Күпме көч, күпме тырышлык салынган шулкадәрле эшләрне башкарырга! Бож̧рага чыгу белән сул яктан, су өстеннән түбәсе ябулы биек күпер сузылган. Нинди биек, нинди озын һәм матур ул! Су эченә кереп, батып торган баганалары ак тигез ташлардан өелгән күпер үзе кызгылт таштан ясалган. Күпердә әлегә хәрәкәт сизелми. Димәк, капканы әлегә ачмаганнар. Талия дә, башкалар да түземсезләнеп шунда көтеп торалардыр. Һу, аларны карап-тикшереп уздырганчы, кимендә ярты сәгать вакыт узачак. Ул вакытта инде аларның кызыл кәмәсе ярты юлны узган булыр. Шулай да Талиянең төрле базарчылар, тупас ирләр арасында көтеп торуы бераз кызганычрак. Ул, билгеле, Әкълимәдән чибәррәк, шәбрәк һәм аның Әкълимә алдында җиңелүе дә кызганычрак. Ул ничектер гел алдан барырга, гел өстен булырга тиеш иде кебек. Әнисе Хәтимә карчык усал икән, борнай икән, Талиянең ни гөнаһысы бар? Талия үзе беренче булып аларга борылып карады, беренче булып елмайды, исәнлек сорашты. Шулай булгач, Талияне берничек тә гаепләп булмый. Тик менә аны мака сар сарайларына гына алмасыннар иде. Бөтен бистәдә беренче чибәр булса да, бистәгә кайтсын иде ул. Кайтыр. Кайтмый мөмкин түгел. Ничек инде кайтмасын, Җәбирнең үзен яратканын ул бит яхшы белә. Бәхет ташын алгач та сөенер әле. Тик менә үзенә була алыр микән ул бәхет ташы? Булыр. Бүләк биргән кешесен чын күңелдән яратса, бүләген дә саклый алыр. Яратмый икән инде... Юк, әлегә ул турыда уйларга кирәкми.

Ул башын күтәребрәк карагандай итте. Алар су бож̧расының икенче як ярына якынлашып киләләр иде. Беренче җир бож̧раның биек таш коймасы кара таштан салынган, кара ташның җекләре тышкы яктан көмешсыман ак кургашын белән каплатылган. Шунлыктан кара белән ак төсләр аралашып, ялт-йолт килеп күренә. Уртанчы җир бож̧рада исә, дүңгәләк сыман ул утрауда, төрле тамашалар, көрәшләр һәм ат чабышлары уздырыла. Шунда ук башкаланы саклый торган күпсанлы чирү тора.

Кояш арттан, көнчыгыш яктан төшсә дә, кара коймага якынайгач, көн ничектер караңгыланып калгандай булды — су өстенә кыя таудай калкып утырган таш койма шундый биек, шундый куркыныч һәм шундый мәһабәт иде. Яр-койма буендагы кәмәләр, койма өстендәге төрле күзәтчеләр, сакчылар өчен салынган түбәле өйчекләр — барысы да монда уенчык сыман гына булып күренә.

Җир боҗраны кисеп үткән арыкның ике ягында да төрле каркуралар, икешәр катлы җир асты уемнары, ишекләр, таш баскычлар, кораллы сакчылар күренеп калды.

Беренче җир боҗраны — утрауны узгач, алар, беркайда тукталып тормыйча, яңадан киң арык-боҗрага килеп чыктылар. Каршыда кызыл ташлардан салынган һәм бакыр белән бизәлгән, урамга таба түгәрәкләнеп барган биек койма күренде. Яңа чыгып килгән кояшның нурлары төшкән бу таш койма уттай балкып тора.

Аларга каршы, әкрен генә кыймылдап, бик зур җилкәнле сәүдә кәмәсе килә иде. Җил булмаганга, аның җилкәннәре күтәрелмәгән. Кәмәгә таудай итеп капчык белән ашлык төягәннәр. Каршыга килүчеләр белән бәрелешмәс өчен, кызыл кәмә тиз генә читкә тайпылды һәм яңадан туры юлга төште дә, су өстеннән җиңел генә шуышып, авыр улакны артта калдырды. Кызыл таш коймалы арыкны узгач, күз алдында, ниһаять, сихри күренеш пәйда булды.

Диңгез ягыннан өченче су боҗрасы артында, уртада, түгәрәк калкулык күренде. Бу Изгеләр үзәнендәге иң әүвәлге калкулык борынгы балыкчы белән аның хатыны һәм соңыннан ятим калган Изге анабыз яшәгән калкулык иде. Бу дөньяда мака сарлар — изге патшалар яши торган биек калкулык Саркел иде.

Саркел дә, башка җир боҗралар кебек, биек таш койма белән әйләндереп алынган. Койма тоташ бакыр белән капланган һәм шунлыктан аннан уттай кызыл балкыш күренде. Аркылысы ярты чакрым чамасы булган бу түгәрәк калкулыкның уртасында, кырыйларында — әле анда, әле монда — күзнең явын алып, алтын манаралар, алтын гөмбәзләр, алтын түбәләр һәм алтын сыннар балкып тора. Биек, мәһабәт таш йортлар арасында куе наратлыклар, яшел әрәмәләр, бик күп басмалы биек-биек баскычлар күтәрелә.

Соңгы су боҗрасы аша чыкканнан соң, бакыр койма янына барып җиттеләр. Шул вакыт Җәбир, артына бо-

рылып, сул яктагы күперләр ягына карады һәм күперләрдә хәрәкәт башланганын шәйләп алды. Атлылар күбесенчә үзәккә таба киләләр иде. Әнисе дә, Әкълимә дә күпердәге атлыларга игътибар иттеләр.

— Барыбер уздык, инәй! — диде Әкълимә, сөенеп, артына борылып.

— Тик кенә утыр, — диде әнисе, кызының янбашына төртеп алып. — Әле барып җитәсең, җиргә аяк басасың бар.

Батима кортка судан бик курка иде һәм кәмәгә утыргач кирәкмәгән теләсә нәрсә сөйләшергә ярамаганлыгын һәрвакыт исендә тота. Әкълимә шундук тынып калды. Чыннан да әле алар җиргә басмаганнар, тиешле урынга барып җитмәгәннәр — нигә алдан кычкырырга?!

Каршыда, бакыр коймада, ярым түгәрәк капка асты сыман булып биек һәм киң уем күренде. Бу диңгез ягыннан килә торган киң арыкның дәвамы иде. Ул, Изге калкулыкны җир астыннан тишеп, икенче якка барып чыга. Җир асты юлында караңгы булганга, билгеле бер ара калдырып, яктылык коелары һәм җир өстенә менеп-төшеп йөрү өчен киң баскычлар ясалган. Калкулык астындагы бу су юлының тагын әллә нинди яшерен тармаклары, тармакларында каркуралары, азыктөлеге һәм башка төрле байлыклары бар, дип сөйлиләр иде. Ярты чакрым чамасы сузылган ул җир асты юлына теләсә кем кертелми. Кәмәләр бары койма артындагы беренче коега кадәр генә керә алалар.

Бакыр койманың дугаланып торган киң уемы янында кызыл кәмәне мака сар сакчылары туктатты. Кызыл кәмәнең хуҗасыннан алар кая барулары, ник барулары турында сораштылар. Сакчылар хуҗага танышлар иде. Ул аларга яшермичә дөресен әйтеп бирде. Сакчылар Җәбирләр кәмәсен ярым караңгы уем эченә үткәреп җибәрделәр. Күп тә үтмәде, кызыл кәмә өстән яктылык төшкән бер таш баскыч янына килеп җитте. Борындагы арканчы таза күкрәкле, таза беләкле яланаяклы эшчегә элмәкле аркан ыргытты. Кәмәне ярга тарттырып бәйләп куйгач, хуҗа Батима карчыкка борылып карады да:

— Килеп җиттек, — диде.

Батима карчык урыныннан торды, куенына, җилән изүе арасына кулын тыгып, аннан күн янчык чыгарды да урта яшьләрдәге кәмәченең юан бармаклы каты учына күпмедер акча салды.

— Бай бул. Алла теләгәнеңне бирсен, — диде.

— Ак юл сезгә. Көтәрмен, — диде кәмәче тыныч кына. — Төштән соңгы күлемдә тагын киләм.

— Өлгерсәк, килербез, — диде Батима карчык һәм беренче булып такта басмага керде.

Саркелдәге Әбетигә багышланган каравыл өе Изгеләр калкулыгының көнчыгыш өлешенә, бер яктан — базарга, икенче яктан мака сар сарайларына якын гына булган әрәмә уртасына урнашкан иде. Кызгылт-саргылт кәүсәле биек наратлар, юан-юан имәннәр һәм башка төрле озын агачлар үскән әрәмә матур ак таш койма белән әйләндереп алынган. Шактый зур урынны биләп утырган бу кирәмәт — изге җир коймасының капка алдына бер якка кулларын югары күтәреп елап торган Әбетинең бик зур ак таш сыны утыртып куелган. Капка аша үткән һәркем аңа баш иеп, белгән догаларын укып керергә һәм күңеленнән бары дөреслек кенә уйларга тиеш.

Кызыл таштан бик биек итеп, алгы ягына юан, озын терәкләр куеп эшләнгән каравыл өе әрәмәнең уртасында — ясалма рәвештә күтәртелгән биеклектә утыра. Монда бары хатын-кызлар гына һәм чит ил ирләре генә кертелә.

Җәбир белән кол-кара койма янына барып тормадылар. Алар каравыл өенең тышкы ягына эшләп куелган бер озынча таш утыргычта утырып калдылар һәм Батима карчыкны шунда көтәргә булдылар.

Батима карчык кызын җитәкләде дә, як-ягына карана-карана, Әбети сыны яныннан киң итеп ачып куелган капкадан кереп китте. Ул монда барыннан да элек Галләм корткасы белән Талия бар микән дип каранды. Юк, алар әле килеп җитмәгәннәр иде. Ишегалды, биек баскыч тирәсендә им өенең эшчеләреннән, кимнәрдән башка шулай ук беркем күренмәде. Димәк, алар чыннан да бик иртә килеп җиткәннәр. Ни генә булмасын, алар ак мәрмәр баскычтан югары менделәр, юан баганалар-терәкләр яныннан, төрле сыннар яныннан үтеп, биек агач ишекнең алтын тоткасына килеп тотындылар. Изге ишектән Батима карчык иң элек үзе керде, аннан соң кулыннан җитәкләп кызын алып керде. Кызның кулына кагылу белән, ул аның чак-чак кына калтырануын, каушавын сизеп алды. Бу изге өйгә кергәндә, кызы түгел, ул үзе дә бераз гына каушагандай булды. Хәер, кызының мондый халәте аңа кайчандыр үзенең дә шушы ук ишектән керүен һәм үзенең дә шулай куркуын-каушавын исенә генә төшерде бугай.

Алар бик иркен бер бүлмәгә килеп керделәр. Идәнгә шоп-шома итеп эшкәртелгән төрле төстәге ташлар җәелгән. Идән кырыена агачтан ясалган артсыз озын утыргычлар тезеп куелган. Утыргычларның түрдәгесендә, башларын югары тотарга тырышып, тып-тын гына берике яшь кыз утыра иде. «Килеп тә җиткәннәр! — дип уйлап куйды Батима карчык, яратмыйча. — Шулай да болары Галләм кызы түгел инде. Күрәсең, якын-тирәдәгеләрдер инде». Батима карчык әлеге кызларга каршы яктагы утыргыч янына килде дә кызына, ярым пышылдап:

— Утыр шушында, — диде.

Яшь чагында ул үзе дә шушында утырган иде һәм һич тә бәхетсез булды дип исәпләми үзен.

Әкълимә, сүз тыңлап, кушкан урынга утырды, никтер көрсенеп куйды һәм, бераз ияләшә төшкәч, каршыдагы кызлар ягына күтәрелеп карады. Кызлар аңа таныш түгел иде. Ул арада Батима карчык түргә узды һәм тар аралыктан бераз җир барды да уңдагы бер ишекне ачып эчкә керде. Шушында төнә-куна яши торган өлкән яшьләрдәге симез карчык — абакай — ул кергәндә йомшак кәнәфигә утырган килеш киемен алыштырып азаплана иде. Бер кулына күлмәк, икенче кулына төзәнү-бизәнү әйберләре тотып, аның янында кара тәнле кол кыз — ким кол кыз басып тора иде. Батима карчык, уңайсызрак вакытта керүен шәйләп, ишек төбендә тукталыбрак калды. Шулай да аның керүен күрделәр. Абыстай борылып карагандай итте, ләкин киенүеннән тукталмады. Батима карчык ишеттереп изге ата-бабаларны искә төшереп сәлам бирде һәм үзенең кемлеген, ни өчен килүен әйтте. Абыстай тиешенчә киенеп бетми торып җавап кайтармады. Киенеп бетеп, ак симез муенына зур ташлы муенсасын таккач, беләкләренә — беләзекләрен, башына бүреген кигәч, бөтен йөзе белән керүчегә таба борылды да, ягымлы күкрәк тавышы белән:

— Түрдән узыгыз, — диде. — Кем дип белик? Каян? Бистәдән?

Батима карчык кабатлап үзенең кемлеген һәм ни өчен килүен әйтте, куенындагы янчыгыннан бер бөтен акча алды да, абыстай янына ук килеп, аның йомшак учына садака салды. Абыстай садаканы алып, шундагы бер кечкенә чүлмәккә ташлады. Түгәрәк алтын кисәге, чүлмәк төбендәге шундый ук акчалар янына төшеп, матур чыңлау тавышы чыгарып, тынып калды. Тавышның нindiлегенә караганда чүлмәк яртылаш тулы булырга тиеш. Шуннан соң абыстай, аяк астындагы сандыгын ачып,

аннан киңлеге бер карыш чамасы булган түгәрәк дисбесен алды. Түгәрәк дисбе чирек илледәй калынлыктагы юка гына балчык кисәгеннән гыйбарәт иде. Аның ике ягына да сырлап серле дога сүзләре язылган. Абыстай дисбесен ике куллап тотты да, аны әкрен генә әйләндерә барып, яндырылган балчык өстендәге серле билгеләр өстеннән бармак битләрен шудырды һәм серле изге сүзләрне укыды.

— Эйемкә, ирәне, ир-атка, абамка, әтекәмә-инәмә... — дип санап китте ул, ярым пышылдап, садаканың кемнәргә багышланганын белдереп. Иң соңыннан «мака сарга» дигән сүзләрне кычкырып әйтте дә дисбесен алдына куйды, ике кулын да югары күтәреп, дога кылды. Батима карчык кайбер сүзләрне аның артыннан кабатлап барды һәм шулай ук «мака сарга» дигән сүзләрне кычкырып әйтте, абыстайга ияреп, кулын югары күтәрде һәм ике як битен сыйпап, дога кылып куйды. Моннан күп еллар элек тә, Батима әле кыз чагында, ул чактагы абыстай да шундый ук дисбесеннән изге сүзләр укыган иде. Ләкин ул чакта ул «мака сарга» дигән сүзен — пышылдап кына, изге аналарга багышланган сүзләрне кычкырып әйткән иде. Бозылды замана. Болай булгач, мака сар изге аналарыбыз Дикәдән дә, Әбетидән дә өстенрәк булып чыга! Болай булгач, мака сар Карун алланың үзе булып чыга! Тфү, тфү! Кем ышансын моңа? Коточкыч бит бу. Ничек аны һаман җир йотмый да, ничек аны яшен сукмый?

Батима карчыкның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ул абыстайның «мака сарга» сүзен кычкырыбрак әйтүенең сәбәбен бик яхшы аңлады — аны, билгеле, мәҗбүр итәләр. Тик шулай да ул ачыктан-ачык аның белән бу хакта сөйләшергә кыймады. Абыстай, изге булса, аның белән ягымлы булса да, чынлыкта ул мака сарның күзе-колагы иде. Бистә кешеләре бу турыда инде күптән беләләр.

Абыстай Батима карчыкның йөзе үзгәрүен күреп утырды һәм, аны тизрәк озатырга ниятләп:

— Бибтикәгә ак юл, — диде.

Ләкин Батима карчык кузгалып китәргә ашыкмады. Аңа ничек тә үз йомышын әйтергә һәм абыстай белән бик әһәмиятле нәрсә турында килешергә кирәк иде. Тиешле садакасын биргәч, берәр айга изге өйдә калырга рөхсәт булмас микән?

Абыстай аның йомышын әйтмичә дә аңлап алган иде инде. Ул, уңайсызланган сыман, буялган күз кабакла-

рын түбән иде, беравык эндәшми утырды, матур күкрәк тавышы белән, ләкин коры, шәфкатьсез итеп:

— Әбетигә багышланган каравыл өе изгеләр җирендә утыра, — диде. — Әбети өендә алынган алтынның бөртегенә кадәр изге казнага тапшырыла. Үзлегемнән мин мака сар боерыгын боза алмыйм. Мака сар боерыгына каршы килү — язык.

Батима карчык авыр итеп көрсенеп куйды, үз-үзен, үзенең балаларын кызганудан аның күзләренә яшь бәреп чыкты.

— Ирем урын өстендә ята, уртанчы улым өйләнмәгән, башкаланган өлкән улымнан бернинди ярдәм юк. Үзенә үзе бирнәлек эшли алмас микән дигән идем шул, абыстай.

— Бирнәлек эшләү өчен тәтиләр йортына барырга кирәк, — диде абыстай, шактый коры итеп.

Яшь чагында Батима карчык шушы ук өйдә кирәгеннән артык бер ай булган иде һәм шул бер ай эчендә шактый күп акча эшли алган иде. Бирнәлеккә дә җитте, туена, башкасына да. Ул чакта мака сар Карун яшь иде, абыстай да кеше хәленә керә торган яхшырак күңелле иде. Туктале, әллә садаканы азрак бирдеме соң ул аңа? Кинәт Батима карчыкның күңеленә шундый уй килде. Инде борылып чыгып китәргә дигәч, ул яңадан куенына тыгылды һәм ялтырап торган бер сумны ашыгып абыстайга бирде. Абыстай акчаны алды, баягыча аны тар авызлы, елан сыман тоткалы һәм күгәрчен сурәте белән бизәлгән чүлмәккә ташлады.

— Бибтикәү бик чибәр булса, сылу тәнле булса... мака сар кешесенә күрсәтермен, — диде ул, йомшаргандай итеп.

Батима карчык, берни барып чыкмаячагын аңлап, ишеккә таба юнәлде. «Башы-аягы астына килсен! Җир йоткыры! Муены сынгыры!» — диде ул, үзалдына карга624нып. Ул шулай күңеле кырылып, ашыгып, бозылган йөз белән Әкълимә янына килде. Килсә, озын утыргычта үз кызы янында нindидер бик чибәр кыз күреп алды. Күзен ачыбрак караган иде — суга төшкән тавык кебек аптырап, бөрешеп Хәтимә карчык басып тормасынмы! Батиманың шундук йөзе ачылып китте:

— И-и, күршеләр дә монда икән! — дигән булды, беренче мәртәбә күргән сыман, ясалма елмаеп. — Нишләп соңга каласы иттегез? Сезне килә дип ишеткән идек.

Хәтимә карчыкның йөзе үзгәреп китте, шулай да ул ачуын эченә йотты да, үз-үзен елмаерга мәҗбүр итеп:

— Ат җигеп килдек анысы, — диде. — Тамак күпе-

рендә озак тоткарладылар. Сакчылары йоклап яткан-мы шунда.

— Булмас, йокламаслар. Безне менә ялт иттереп китереп кенә куйдылар! — диде Батима карчык, масаеп.

— Кайтканда да ялт иттереп кенә кайтарып куйсалар ярый да бит, — диде Хәтимә карчык, кайгырган булып.

Батима телен тешләргә мәҗбүр булды. Хәтимәгә җавап кайтарып тормыйча, ул Әкълимәне кулыннан тотып читкәрәк алып китте дә сер итеп соңгы сүзләрен, киңәшләрен әйтте. Һәм куенындагы янчыктан бер-ике бакыр алып кызының учына салды да:

— Алай-болай кирәк булса, — диде. — Иртәгә иртәнге якта килербез.

— Шулаймыни? — диде Әкълимә, төшенке генә. — Алайса, мин монда калмаячакмынмыни?

— Калмаячаксың, — диде Батима карчык. — Кара аны, борыныңны салындырма, елмаебрак утыр!

Батима карчык кызына шундый акыллы киңәш бирсә дә, үзе ул борынын бик югары да күтәрә алмады, сөенеп елмая да алмады. Ни өчен дигәндә, сөенерлек сәбәбе дә юк. Абыстай белән сөйләшү бер күңелен кырса, Хәтимә карчыкның кыланышы күңелен икенче кырды. Аның тизрәк моннан чыгып китәсе килде һәм ул, артык сүз озайтып тормыйча, ишеккә юнәлде. «Үзенүзе белер әле. Аның янында сакчы булып басып торып булмый инде» дип уйлады ул кызы турында. Ярый ла иртәгә өйгә кайтырлык булса. Тегенең Талиясе чибәррәк шул. Кая инде ул алтын сарайларга аяк басу безнекеләргә!

Ул туры Җәбир белән кол-кара янына килде.

— Булдымы, инәй? — диде Җәбир, әнисен каршылап.

— Нәрсә «булдымы»? — диде ана кеше, икеле-микеле итеп. — Кичкә кадәр утыра әле ул анда, сатучылар килә башлаганчы.

— Талия беләнме? — диде Җәбир һәм Талия исемен әйтү белән үзенең бер дә юктан оялуын, кызаруын тойды.

— Талия белән, — диде әнисе. — Бер эшне эшләдек, иң авыры калды, — диде ул аннары, кол-карага, аннан бигрәк аның кулындагы киндер капчыкка күз ташлап.

Әйе, йомышның иң авыры калды. Батима карчык куеныннан күн янчыгын чыгарды да, янчык эченә кулын тыгып, андагы акчаларны санап карады. Тиз генә исәбенә чыга алмагач, бармакларын бөгеп санарга ке-

реште. Лəкин ничек санаса да, ничə мəртəбə санаса да, бакырлар да, бердəнбер алтын акча да тик ятып балаламаган иде. Лəкин шул ук вакытта югалмаган да. Тик менə базарга кергəч, аласы əйберлəрне алырга җитəр микəн — анысын əлегə əйтеп булмый. Аласы əйберлəр исə җитəрлек. Барыннан да элек бер егерме-утыз кадак чамасы ашлык кирəк... бораймы, бодаймы анда... ярма кирəк. Аннан соң бер биш кадак тоз кирəк, ун кадак ит кирəк. Эчə торган су чүлмəге чатнаган. Алдан алып куймасаң, ватылгач соң булыр. Берəр йөк утын алганда да яхшы булыр иде. Аннан соң, йон алып, йон җегерли башларга да исəбе юк түгел иде. Санап китсəң, əллə нəрсəлəр кирəк. Лəкин аларның барысын берьюлы ничек алып кайтасың? Шулкадəр мал-туар алып кайтырга ишəк ялламый булмас. Бу бетəшкəн кол-кара үзен-үзе дə көчкə күтəреп йөри. Ярар, алып кайтуы бер кайгы, акчаны ничек җиткерергə? Менə ул кайгының зурысы кайда! Былтыр көз мака сар Карун илдəге бөтен ашлыкны, сатып алып, амбарларына тутырды. Очсыз бəягə. Менə хəзер яз җиткəч, чəчəр вакыт җиткəч, ул ашлыкның икелəтə, өчлəтə кыйбатланганын көтə. Әлегə ул телəгəн дəрəҗəдə кыйбат түгел. Ярлылар ачтан кырыла башлагач, бəялəр ул телəгəн дəрəҗəгə җитəчəк. Шулай да базарда ашлыкка якын барырлык түгел, диделəр. Кичə шулай булган. Бүген ничек икəн?

Батима карчыкның күңеленə шундыйрак уйлар килде һəм ул көн янчыгын куенына салып куйды да базар ягына таба кузгалып китте. Җəбир аның нигə шулай кат-кат акча санавын да, ник күңелсез булуын да бик яхшы аңлады. Талия турындагы уйлар онытылды һəм ярлылык, акчасызлык əйтерсең тагын аның бугазыннан буып алды. Их, аңа да тизрəк егермегə җитəсе иде. Егермегə җитсə, аны да йə сакчы итеп алырлар, йə берəр төшемлерəк эшкə кушарлар иде. Әлегə исə ул үсмер санала. Әлегə ул, Әкълимə кебек үк, ата-ана карамагында.

Саркел базары Изге калкулыкның көньягына, кəмəчелəр бистəсе ягыннан килə торган юл ягынарак, ачык бер иркен урынга урнашкан. Дүрт яктан да базар биек таш койма белəн уратып алынган, дүрт якка дүрт капка куелган.

Базар əле яңарак кына ачылган иде бугай. Сатучылар да, алучылар да əлегə йокылары туймаган кебегрəк, үшəнрəк күренəлəр. Әлегə кызып сатулашулар да, кычкырып-кычкырып үз товарыңны мактау да ишетелми.

Батима карчык кеше азрак чагында иң элек ашлык

алмакчы булды. Алар, юлда очраган берән-сәрән кешеләрне әйләнеп үтеп яисә туры кеше арасыннан чыгып, ашыга-ашыга икенче якка атладылар. Капкадан кергәч тә уң якта бакырчы алачыгы торып калды. Кыска муенлы, киң күкрәкле, ярым шәрә бакырчы, үтеп-сүтеп йөргән беркемгә карамыйча, таш чүкеч белән таш сандалга салынган бакыр кисәген чүки иде. Аның яшь колы иренеп кенә күрек бавын тарта.

Бакырчы яныннан узып беркадәр җир киткәч, алар бөтен буш урынны каплап торган арбаларга килеп төртелделәр. Монда арба кирәк-яраклары да сатыла. Арбаларның буялганы да, буялмаганы да, ике урынлы, бер урынлысы да, ике тәгәрмәчлесе дә, дүрт тәгәрмәчлесе дә бар.

Әнисеннән калышмаска тырышып барган Җәбир арбалар янында тоткарлангандай итте. Ике тәгәрмәчле, ике урынлы бер җиңел тарантас аңа аеруча ошады. Ул инде күптән шундый арбага утырып сабантуйда ат ярышында катнашырга уйлый иде. Аннан соң ул арба бүген Талия утырып килгән арбага охшаган. Тәгәрмәчләре биек, нык, тәпиләре, тугымы җиз белән ныгытылган, кызыл күн утыргычы йомшак, арты чәчәкләр белән бизәлгән, тәртәсе кызыл. Аклантита яшьләре хәзер нәкъ шундый арбалар белән мавыгалар.

Арба сатучыларга якын гына утынчылар бүлеге башланды. Арбачылар башлыча кала кешеләре булса, утынчыларның барысы диярлек төньяктан — таулар арасыннан килгән авыл кешеләре. Монда инде яланөс йөрерлек җылы булса да, таулар арасында кайбер җирләрдә әле бик суык дип сөйлиләр. Күрәсең, чыннан да шулайдыр. Утынчыларның күбесе өсләренә, башларына һәм аякларына тупас, җылы киемнәр кигәннәр. Ләкин монда килгәч җылынып, тирләп, кайберсе башындагы бүреген салган, кайберсе җылы тунын салган, яланөс калган.

Тышта, кояшта җылы булса да, утын әле монда да кирәк. Казан аскач та, кайчагында өйне җылыту өчен дә. Авыру этисе еш кына аягым туңа дип зарлана. Утын бүген бик күп булып чыкты. Ишәк җигеп тә килгәннәр, үгез җигеп тә килгәннәр. Кайбер ярлыраклар ике тәгәрмәчле арбаларны үзләре тартып килгән. Кыска итеп киселгән, туралган имәннәр дә, каен, усак та бар, киселмәгән, туралмаган коры-сары да җитәрлек. Батима кортка бер-ике урында утынның бәясен дә сорап карады. Утын аңа артык кыйбат тоелмады. «Таулар арасындагы авылларда ачлык икән, былтыргы ашлыклары

чәчүгә дә җитәрлек түгел икән» дигән сүзләр хәзер еш ишетелә. Биек тау башына урнашкан кайбер авылларның утыннан башка сатарлык әллә нәрсәләре дә юк. Хәер, аларның мал-туарга байлары да җитәрлек. Ит, йон, тире... тере мал.

Батима карчык утынчы белән сатулашып тормады. Иң элек иң кирәген алырга кирәк иде. Ул шулай ук итчеләр, тиречеләр янында да тоткарланмады. Чүлмәкчеләр бөтен базар мәйданының яртысын диярлек алып торалар. Туп-туры җир өстенә төрле зурлыктагы, төрле рәвештәге меңләгән чүлмәкләр, балчык савытлар тезеп куелган. Атлап йөрү өчен тар гына аралыклар калдырылган. Кирәкле чүлмәгеңне сайлап алыйм дисәң, монда көне буе йөрергә кирәк, адашып бетәрсең. Ниндие генә юк монда савыт-сабаның, чүлмәкнең!

Чүлмәк алу турында уйласа да, Батима карчык монда да тоткарланмаска булды. Күз кырые белән генә якягына караштырып ул һаман алга баруында булды. Чүлмәкчеләрне узып киткәч, алар, ниһаять, базарның он-ярма, орлык-ашлык сата торган төшенә якынлаштылар. Якынлашуын якынлаштылар, тик андагы халыкны күреп, шундук эчләренә суык йөгерде. Алар кебек капчык күтәреп килгән кешеләр монда буа буарлык иде. Түбәсенә бер көтү күгәрченнәр утырган, таш баганалары ешылып, керләнеп беткән ябулы каралты эчендә бары тик бер-ике җирдә генә ашлык саталар иде. Базар ачылганчы килеп чират алган, тиешенчә йокламаганга күзләре эчкә баткан, ачулы кешеләр арасыннан үтеп сатучы янына якын барырлык түгел. Дөрес, түбә астында аның өеп куйган капчыклары күп күренә. Ләкин бизмәне бер генә. Булышчысы да бер-ике генә.

Чираттагыларның күбесе — урта яшьләрдәге һәм өлкән яшьтәге хатын-кызлар. Арада шулай ук картрак яшьтәге ирләр дә бар. Каладагы ирләр күбесенчә өйдә эшлиләр яисә мака сарга хезмәт итәләр. Базарга йөрү, ашау-эчүне кайгырту, йорт-җир карау тулысынча хатын-кыз карамагында. Батима карчыкка ияреп килгән яшь, таза Җәбиргә «нишләп йөри бу яшь чибәр егет монда?» дигән сыман сәерсенеп карап алдылар. Әнисенә ияреп базарда йөрү, җитмәсә, капчыклы карт хатын-кыз янына килеп чыгу Җәбирнең үзенә дә оятрак иде, әлбәттә. Аның кебек егетләр мондый вакытта базарда йөрми — йә таулар арасында кирмәндә яши, сугыш уены уйный яисә урта утрауда ат чабышына өйрәнә, йә булмаса кәмәдә йөзә.

Батима кортка якындагы кешеләрнең Җәбиргә шелтәләп, сынап карауларын да, Җәбирнең уңайсызланып торуын да күреп алды һәм, тупас кына:

— Торып тор әле шунда, карап килим, булмаса, — диде.

— Ярар, — диде Җәбир, теләр-теләмәс кенә.

Батима карчык, кешеләрне этә-төртә, алгарак, сатучы янынарак якынлашты. Чират торыр алдыннан бит әле белергә кирәк: нәрсә сата, күпмегә сата. Егерме-утыз кадак ашлыкны, бәлки, аңа чиратсыз да биреп җибәрерләр. Чиратың җиткәнче көтә башласаң, төш җитәр монда.

Батима карчык шулайрак фикер йөртте. Ләкин кешеләр аның сатучыга таба якынаюын күреп алдылар да, шундук төрле яктан ачулы тавышлар ишетелде. «Син кем дә без кем, арттан килгәнсең — артка бас, синең тамак барны безнеке юкмыни?» — китте сүз, китте кычкырыш. Батима карчык, аңа-моңа карамыйча, терсәкләре белән этеп-төртеп алга баруында булды. Кемдер шунда аның беләгенә тотынды, кемдер читкә этте. Батима карчык үзенә карата кычкырган тупас-тупас сүзләрне баштарак колагына да элмәде, ләкин кемнеңдер салкын, каты кулы беләгенә орыну белән: «Ал кулыңны!» — дип кычкырып җибәрде. Җиңелчә гөрелдекне, шау-шуны күмеп яңгырап киткән хатын-кыз тавышына кешеләрнең кинәт йокылары ачылгандай булды. Барысы да тавыш килгән якка борылып карадылар.

— Кая тыкшынасың? — дип кычкырды шундук икенче бер усалрак, көчлерәк тавышлы хатын-кыз, Батиманың юлына аркылы төшеп.

— Сез кая, мин дә шунда! — диде Батима карчык, аннан да усалрак итеп.

Якындагы ирләр көлеп җибәрделәр.

— Без тыкшынмыйбыз, син тыкшынасың, — диде көлүче ирләрнең берсе.

— Мин карарга гына барам — нәрсә сата, күпмегә... — диде Батима карчык, ярсуын тыя төшеп, як-ягына ялтйолт каранып.

— Беләсе килгән икән! Белми тор әле! — дип кычкырды таза тавышлы хатын, үчекләшеп.

Батима карчык аптырабрак калды. Бу кадәр усал һәм ач халыкны тамак ярып кына җиңеп булмаячагын ул шундук аңлап алды һәм, үзе дә сизмәстән кинәт юашланып:

— Нишләп алай... белергә дә ярамыймыни? — диде.

— Ярамый! — дип кычкырды усал хатын, җиңүче

кыяфәт белән. — Беләсең килсә, яхшылап сора. Без менә төн уртасыннан бирле аягөсте торабыз.

— Алай икән, — диде Батима карчык, җиңелүен тәмам танырга мәҗбүр булып.

Шулай да аның тиз генә кире чигенәсе килмәде. Абыстай янындагы кебек ул мескенләнеп борынын тартып куйды һәм, тирә-яктагы кешеләрне кызгандырмакчы булып:

— Кәмәчеләр бистәсеннән мин, ирем урын өстендә ята, туганкайларым, — диде. — Мин дә кирәкмәгәнгә йөрмим. Чыпчык чүпләрлек тә бөртегем юк. Лар эче коп-коры.

— Безнеке тулы, шуңа менә капчык күтәреп килдек! — дип кычкырды усал хатын, әле булса килешергә теләмичә. — Әнә Карун капкасы янына барып күз яшеңне түк. Ул җыеп алды бар ашлыкны, ул интектерә безне.

— Туймас тамак булды шул Карун. Бар дөньяны кабып йотар иде көченнән килсә, муены сынгыры! — диде Батима, җан ачуы белән, үзе дә сизмәстән бар көченә кычкырып.

Аның шулай дип әйтүе булды, әле генә шаулашкан, кычкырышкан халык кинәт шып булды. Барысы да куркып, котлары алынып күзләрен түбән иделәр. Бу нинди хатын булды бу? Мака сарга... Карунга тел тидерде! Бөтен халык алдында үзенең ялгыш сүз ычкындыруын Батима карчык та аңлап алды, аның да кинәт коты алынды, һәм ул ялт-йолт каранды да башын түбән ияргә тырышып читкә тайпылды. Беркем аның юлына төшәргә батырчылык итмәде. Ул үзенең бик зур хата эшләвен яхшы аңлады. Ләкин менә хәзер генә нишләргә — базардан йөгереп чыгып китәргәме, әллә җир тишегенә кереп яшеренергәме? Бит аны хәзер үк мака сарның озын колаклары тотып алырга һәм ике яктан җитәкләп алып та китәргә мөмкиннәр.

Ләкин хәзер әйтерсең нindidер могҗиза булды. Батима карчык иркенрәк җиргә чыгып, койрыкка үзенекеләр янына барырга диебрәк торганда, кемдер арттан:

— Ире урын өстендә яткан ананы чиратсыз кертегез! — дип кычкырды. Тыелып кына аңа башкалар кушылды.

— Юл бирегез! Алсын! — диештеләр әле генә усал чәрелдәгән хатын-кызлар.

Кемдер килеп Батима карчыкның кулыннан тотты, ныгытып, ачуланып түгел, якын итеп, йомшак итеп тотты. Батима карчыкның күңеле йомшап китте һәм ул,

хәлсезләнеп, ихтыярсыздан үзен җитәкләүче яныннан иярде.

Артык озак көтмичә ул сатучыга утыз кадак арпа үлчәтте. Әнисен ерактан күзәтеп торган Җәбир кол-кара белән шундук аның янына килеп җитте. Кулындагы капчыкны кол Батимага бирде. Батима капчык авызын җайлап тотты да бик шома күренгән урта яшьләрдәге мут күзле сатучыга:

— Әйдә, сал, — диде.

Бизмән табагындагы ашлыкны сатучы ике куллап тоткан килеш:

— Башта акчаңны чыгар, — диде. — Синнән ике сум. Алтын белән.

Батима карчыкның кулындагы капчыгы төшеп китә язды. Ике сум! Алтын белән!

— Алтыным бер генә сум. Калганына бакыр бирермен, — диде ул, телен көчкә әйләндереп.

— Мака сар ашлыгын сатам. Мака сар бары алтын гына ала, — диде сатучы, табактагы ашлыкны кире үз урынына сала башлап.

«Ә, шулаймыни әле ул?!» дип уйлап куйды Батима, яңа исенә килеп.

— Ярар, егерме кадак үлчә, — диде ул, янчыгыннан бер алтынын чыгарып.

Сатучы ашлыкның яртысын бушатты да өчаякка куелган бизмән көянтәсенә элде.

— Унбиш кадак. Төп-төгәле белән, — диде ул, үлчәнгән арпаны Батима карчыкның капчыгына бушатып.

Унбиш кадак ашлык Батимага бик җиңел булып тоелды, ләкин аның кайгысы шулкадәр зур иде, ул капчыгын төбендәге ашлыгы белән колга бирергә дә онытып бик кыенлык белән читкә китеп барды. Якындагы кешеләр аның күзеннән тыелгысыз булып яшь акканын күреп калдылар.

Базардан чыккач та алар туры яр буена юнәлделәр. Анда бистәгә кайтучылар да була, бер-ике тиенгә алып кайтучылар да булырга мөмкин. Беркем бернәрсә сөйләшмәде. Һәркем, үз кайгысына бирелеп, таш җәелгән тигез сукмактан теркелдәвендә булды. Иң алдан Батима карчык атлады, аның артыннан, җилкәсенә капчыгын күтәреп, кол Фу-фу, иң арттан Җәбир атлады. Җәбирнең хәзер бер дә әнисе артыннан, кол артыннан теркелдәп бистәгә кайтасы килмәде. Аның күңеле артка, им өенә, Талия ягына тартты. Әнисеннән аерылып койма тышында торып калгач, ул Талияләрне, аларның

ат белән килеп туктауларын күреп торды. Аңа ерак түгел иде. Талия дә аны күрде, ахрысы — күз кырые белән генә аңа карап алды да әнисенә борылды һәм иртәнге тынлыкны бозып, кошлар сайравын күмеп, матур тавыш белән сайраган сыман итеп әнисенә нидер әйтте. Шул чакны әнисенең кискен усал тавышы, энесенең җитлекмәгән яшь тавыш белән көлгәне ишетелде. Монда, им өе янында, капкага якын җирдә берүзе басып тору Җәбиргә оят сыман тоелды. Аңа, билгеле, Талия алдында оят иде, аларның менә шулай яхшы ат-арбага утырып килүләре, үзенең исә җәяү теркелдәп килүе өчен оят иде. Ләкин шул ук вакытта аңа монда Талиягә карап тору күңелле дә сыман иде. Талия әнисе белән капкадан кереп китте. Аблай атларын борып читкәрәк китеп барды. Аблай Җәбирне бөтенләй күрмәде, ахрысы. Күрсә, ул, билгеле, «Әйдә, алып кайтам!» дип кычкырыр иде. Бераз чорсызрак, мактанчыграк, кылтыграк булса да, ул Җәбирне үз итә, якын күрә. Бөтен эшне әнисе Хәтимә карчык боза. Җәбирләрне ул гомумән яратмый, ахрысы. Билгеле, ярлы булган өчен, әтисе аяктан егылып урын өстендә яткан өчен. Кыскасы, файдасы тия торган кешеләр түгел алар сатучы Галләмнәр. Булмаса булмас. Талия үзе каршы булмаса, башкасында аның эше юк.

Ләкин шулай да сөйгән кызыңны... шулай ук яраткан сеңлеңне шушы им өенә калдырып китү... нинди оят, нинди хурлык! Алар анда көне буе үзләре янына берәр сасы ир, чит ил кешесе килгәнен көтеп утырачаклар. Базар әле яңа ачылды гына. Чит ил кешеләре гадәттә базарга киләләр. Шулай ук махсус им өенә, лелег кызларын карарга дип килүчеләр дә күп була. Үзләре белән алар күп итеп алтын алып киләләр. Бары алтын гына. Лелег кызлары белән кунган өчен алтыннарын Әбетигә дип калдырып китәләр. Ләкин ул алтын им өенә дә, Әбетигә дә булмый — мака сар амбарына китә. Моны һәркем белә, ләкин белмәмешкә салыша.

Ул шулай уйланып һаман теркелдәвендә булды. Аның һич тә бистәгә кайтасы килмәде. Аның хәзер үзе генә каласы, уйланып үзе генә йөрисе килде. Ат чабышлары була торган җиргә барып, атта узышучыларны йә булмаса көрәшчеләрне карап торганда да начар булмас иде. Яисә, биек таш күпер янына килеп, аска су өстенә карап торганда да ярар иде. Өстән каранганда су өстендәге кәмәләр, кешеләр бик кечкенә булып күренә. Юк, чынлап та нигә кайтырга әле өйгә? Анда ни көтә, кем көтә аны? Шул ук ярлылык, күңелсезлек, шул ук авыру әтисе.

Җәбирне кечкенәдән һәрвакыт диңгез, диңгездән дә бигрәк шау-шулы, ыгы-зыгылы яр буйлары ымсындырып, җилкендереп торды. Буш вакыты булдымы, иртәдән алып кичкә кадәр яр буйларында, арык буйларында йөрде, биек таш киртә белән әйләндереп алынган, арыклар белән бүлгәләнгән изге тураның әллә нинди җирләренә барып чыкты. Баштарак аның шуклыгына әллә ни игътибар итмәделәр. Шуклыклар күпкә киткәч, әтисе дә, Мирзый абзыйсы да каты гына итеп акылга утыртып карадылар. Җәбир бөтенләй өйгә кайтмаска булды — берәр кәмәчегә ялланып диңгезгә чыгып китәргә уйлады. Төрле зурлыктагы, төрлечә буялган, төрлечә бизәлгән кәмәләр, каеклар туктый торган таш култыкның таш баскычында кояшта янган таза-таза ирләргә кызыгып ул бик озак утырды. Аның да шулар кебек таза, көчле буласы килде, алар кебек бәйсез һәм тупас буласы килде. Аның да, таза аяклары белән сыгылмалы басмаларда нык-нык басып, яр өстенә авыр-авыр чүлмәкләр, капчыклар ташыйсы килде. Аннан да бигрәк аның кулларына озын чыбык тотып, йөк ташучыларны күзәтеп торучы муенсалы, алкалы, усал йөзле бага кебек буласы килде.

Беренче мәртәбә, ахрысы, ул үзен барлык кешеләрдән өлешсезрәк, кыерсытылганрак итеп тойды. Шуннан соң гомер буена шушы тойгы аның җанын кыйды, гомер буена аның башкалар арасында өскә калкып чыгасы, өлешле һәм ирекле буласы килде. Аннан соң аның бай буласы, бик зур байлыкка — алтын-көмешкә, затлы ташларга, биек сарайларга ия буласы килде.

Монысы аның күптән башланды. Изгеләр тавы, таудагы алтын-көмешкә манылган биек сарайлар, манаралар, корылмалар бистәнең теләсә кай төшеннән күренеп тора. Ятса да, торса да, бистәдәге һәркем шул якка күз ташлап ала. Берәүләр, аллага Кояшка табынган кебек, куркып-каушап һәм нәрсәгәдер өмет баглап карый, икенче берәүләр сокланып, исе китеп карый. Анда изгеләр яши, анда мака сар һәм анда аның якыннары, сакчылары яши. Анда аның туганнары, хатуннары һәм балалары яши.

Җиде-сигез яшьлек Җәбирнең иң кызыкканы, иң көнләшкәне менә шунда яшәүче изге балалар булды. Баштарак аның аларны үз күзләре белән күрәсе килде, күргәч исә сөйләшәсе, аралашасы килде. Ул аларны олы бәйрәмнәр, уеннар вакытында читтән генә, ерактан гына күрде. Алар аңа ике куллы, ике аяклы барлык малайлар кебек үк таныш һәм аңлаешлы булып тоелды, ләкин

шул ук вакытта бик үк аңлаешлы да түгел иде бугай. Андый малайларның үз-үзен тотышында, кием-салымында чиксез көч, байлык бөркелеп тора иде. Күзәтүчән малай моны бик тиз чамалап алды. Күңеленнән аның да шундый ук изге буласы килде.

Унөч-ундүрт яшьлек малай теләгән байлык аяк астында аунап та ятмады, күктән дә яумады. Аны каяндыр табарга, алырга йә, булмаса, чәлдерергә кирәк иде. Базарда, яр буенда, чит ил сатучылары янында селкенеп йөргәндә, Җәбир аны-моны чәлдерергә өйрәнеп китте. Бер мәртәбә исә ике кораллы ир, беләгеннән тотып, аны өенә китереп куйды.

— Малаеңны яр буена җибәрмә, — диде кеше, усал итеп. — Икенче тотсам, түрәчегә тапшырам, — диде.

Җәбирнең кирелеге генә көчәйде. «Барыбер качам!» дип уйлады ул, үҗәтләнеп. Бер айдан соң ул чыннан да качты һәм туры таш калкулыкка юнәлде. Очраган беренче кәмәче янына килде дә:

— Ишкәкче итеп алмассыңмы? — диде.

Аксыл чәчле, атныкы кебек зур башлы һәм алыптай таза Акай ире кояшта янган тыгыз тәнле, киң күкрәкле үсмергә сынап бер карады да ничектер ямьсез итеп көлемсерәп куйды.

— Тагын ни эшкә ярыйсың? — диде.

— Ни кушсаң, шуңа ярыйм, — диде Җәбир.

— Ярый, бераз көтеп тор, — диде Акай кәмәчесе.

Акланга алар күн капчыкларга тутырып бакыр ташы алып килгәннәр иде. Йөкләрен ярга бушатып амбардагы санаучылар белән эшләрен бетергәч, аксыл чәчле кәмәче Җәбиргә күз кысты. Җәбир йөгереп диярлек басмадан кәмәгә керде һәм ярдагылар күрмәсен өчен шундук идәнгә ятты. Ләкин аны күргәннәр булып чыкты. Акай кешесенең карага буялган тупас, авыр бораннары, таш култыктан чыгып әзме-күпме юл алгач та, арттан аларны куа чыктылар, тоттылар, кире Аклан турага алып кайттылар, һәм сакчы янә аны, беләгеннән тотып, әтисе янына кайтарып куйды.

— Малаеңны Акайлар урлап китә яздылар, ярый әле күреп калдык, — диде ул, ялганлап.

Шуннан нәрсәләр булыр иде, билгесез... Җәбир уйламаганда-көтмәгәндә гашыйк булды! Талиягә гашыйк булды. Аның бөтен уйлары, бөтен тормышы кисәк кенә үзгәрде дә куйды...

Җәбир адымын әкренәйтә төште һәм әнисенә күренмичә генә берәр багана артына качып калыргамы икән

әллә диебрәк уйлаштыра башлады. Ләкин шул чакны Батима карчык артына борылып карады һәм борыны салынган улын күтәп алгандай итте дә, коры гына:

— Нәрсә әкренәйдең? — диде.

Җәбир эндәшмәде.

— Көнне кыздыра башлаганчы кайтып җитәргә кирәк, — диде әнисе.

— Җитәрсең, җитми ни! — диде Җәбир, ризасызлык белән. — Кайтыгыз үзегез. Сезгә тагылып йөрергә мин теге...

Батима карчык бөтенләй туктап калды һәм улын көтеп торырга кирәк тапты.

— Нәрсә, анаңа тагылып йөрисең килмимени, улым? — диде ул, шелтә белән.

— Озата килдем, шул җитмәгәнмени? Кайтыр юлны беләм, — диде Җәбир, авызын күптереп.

— Зур эш эшләгән икән — озата килгән! — диде Батима, ачу белән. — Телләшмә, оятсыз! Анда атаң урын өстендә ята, бакча казылмаган, арыклар арчылмаган.

Батима карчыкның улыннан бигрәк бөтенләй башка нәрсәгә ачуы килә иде. Нәрсә икәнлеген төгәл генә ул үзе дә белми. Соңгы сүзләрен ул шактый усал итеп, кычкырып әйтте. Җәбир ачудан кызарынып китте, як-ягына каранып алды. Ярый әле якын-тирәдә танышлар күренмәде. Аларның яныннан гына, ямьсез телдә сөйләшеп, ниндидер чит ил кешеләре узып китте. Берсенең кулында чүлмәк, икенчесенекендә капчык — күрәсең, им өенә ашыгалар. Алар, билгеле, Батима карчыкның нәрсә әйткәнен аңламадылар һәм аякларына кигән озын итекләрен шыштырт-шыштырт атлатып китеп бардылар.

Кол-кара Фу-фу арыган иде. Җәбир, бер сүз әйтмичә, аның кулыннан капчыгын алды да алгарак чыкты һәм, башын түбән иеп, әнисе артыннан атлады. Талия аның шулай капчык күтәреп китеп барганын күрсә, билгеле, эченнән мыскыл итеп көләр иде. Шулай ук абыйсы Мирзый күрсә дә көләр, мыскыллар иде. Лелег булган кеше үз ирке белән шулай теләнче кебек урам буйлап капчык күтәреп йөриме?!

Яр буена кадәр алар үзара бик нык ачуланышкан кешеләр кебек сүзсез генә атладылар. Яр буенда кәмәләр дә, кешеләр дә күренде. Кол Фу-фу, арттан килеп, яшүсмернең капчыгына тотынды.

— Бир, үзем, — диде ул, бикә ишетсен өчен дигән сыман ярым пышылдап.

Җәбир җиңел сулап куйды, капчыкны ычкындырды да арткарак калды. «Шулай да яхшы күңелле бу Фу-фу карт» дип уйлады ул күңеленнән. Ярар, кайтып бакча эшләрен, арык эшләрен бетерергә дә кире китәргә... таулар арасына...

Өйләренә алар төш алдыннан кайтып җиттеләр. Баскыч төбендәге кояш сәгате уникенче яртыны күрсәтә иде. Кол хатын учак ягып казан аскан, өйгә аш исе таралган.

Батима карчык, үз өенә аяк басу белән, иң элек карты янына керде. Авыру карт күңелсезләнеп урынында ятып тора иде. Батиманы күргәч, ул башын калкытты һәм, таза чагындагы кебек урыныннан кузгалып:

— Ничек, булдымы? — диде, хатынының авызыннан сүзен тартып алырдай булып.

Батима инде шактый тынычланган, каладагы күңелсезлекләрен оныткан, эченә йоткан иде. Карты урынга егылгач та ул үз-үзен бер нәрсәгә өйрәтә башлады: урыннан кузгалмыйча яткан кешенең хәле болай да шәп түгеллеген белгәнгә күрә, аның янына кергәндә ничек тә күтәренке күңел белән керергә, һәм ничек тә аңа вактөяк күңелсез хәбәрләрне әйтмәскә тырыша торган булып китте. Хәзер дә ул карты белән үз-үзен бәхетле кеше сыман итеп сөйләшергә мәҗбүр итте һәм күргән-белгәннәрен, ишеткәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләргә кереште. Әлбәттә, бары яхшы яктан гына сөйләргә тырышты.

— Барганда Галләмнекеләрне очраттык, — диде ул, җиңелчә мыскыл белән. — Тарантасларга утырып эре генә узып киткәннәр иде, күпер төбендә торып калдылар. Чирттек борыннарына Галләмнекеләрнең.

— Ничек чирттегез? — диде ире, берни аңламыйча.

— Мирзый кизү кәмәсе бирде, күз ачып йомганчы илтеп тә куйдылар. Кызыбыз-түкәнәгебез иң җайлы урынга барып та утырды.

— Кызык булган икән, — дигән булды ата кеше, күңеле күтәрелеп. — Ул Галләм корткасы борынын чөяргә ярата инде. Талиясе ничек соң? Эндәштеме? Сөйләштеме?

— Сөйләшүен артык сөйләшмәде, күзе гел безнекендә булды, — диде Батима карчык.

— Анасы аркылы төшмәдеме? — диде ире.

— Кызы теләсә, анасына карап торып булмый инде. Килешербез әле, Галләм үзе ипле кеше, — диде Батима карчык, ничектер кыеклап, чит итеп.

— Үзләре килешсәләр, анысы Галләм корткасын гына җиңәргә булыр, — диде карты да. — Тик менә икесенең дә туе бергә туры килсә генә кыен бит әле.

— Шулай шул, — дип куйды Батима карчык һәм кисәк кенә тынып калды. Аның картын сөендерерлек башка күңелле хәбәре юк иде.

Карт та беравык тынып торды да, ничектер серле итеп:

— Сез югында мин бер нәрсә уйлап яттым әле, — диде.

— Уйларга дигәндә сине генә куш инде, — дигән булды Батима карчык.

— Арпа алдыңмы соң? — диде карт, күрәсең, серен тиз генә әйтергә теләмичә.

— Алдык. Утыз кадак, көчкә күтәреп кайттык, — диде Батима карчык, ялганлап.

— Мин бер нәрсә уйладым әле! — диде карт, күзләрен очкынландырып. — Мин менә тик ятам... итле бүкән кебек... Кулларым таза! — диде ул, йодрыкларын кысып һәм беләк тычканнарын катырып. — Кулларга эш кирәк, эш!

Бала вакытында Мөхлис бик зәгыйфь булды. Аның ябык, көчсез булуыннан файдаланып, үзеише малайлар еш кына аны кыерсыталар, үртиләр иде. Үсә-үсә ул ныгыды, туктаусыз күнегүләр ясап, авыр эш эшләп, аның көче артты, тәне ныгыды.

— Урында килеш... нәрсә генә эшли алырсың икән син, картым? — диде Батима, иплэп кенә, сакланып кына.

— Алам! — диде карт, дәртләнеп. — Беләсеңме, кул тегермәне белән мин он тарта алам. Көн-төн тегермән ташы әйләндерә алам.

— Беләкләр таза инде синең, — диде Батима карчык, артык сөенеч белдермичә генә.

— Гомер буена ишкәк ишкән беләкләр, — диде карт, бераз гына масаеп. — Беләсеңме... син базардан күп итеп арпа, бодай алып кайтырсың, мин тарттырырмын, син... сатарсың!

Батима аңлап алды, елмаеп җибәрде — баш бар бу картта! Ләкин аның бу елмаюында әллә ни сөенеч күренмәде. Ул бары картының күңелен кырасы килмәгәнгә генә шулай елмайды.

— Кызык, — диде ул. — Анысы шулай: он кыйбатрак. Базарга чыгармасаң, күрше-тирәгә сатырга була.

— Була, — диде карт, күңелле итеп. — Мин инде барысын да уйладым. Көзгә кадәр җитәрлек мая тупларга була. Бер җаен алсам, мин бөтен бистәне бодай, арпа белән туйдырам.

— Шулаен шулай да, — диде Батима карчык, иплэп кенэ. — Ул тегермэнеңне ничек көйлэрбез икэн синең өчен? Ятак янында бөтен өй эче порак он белэн тулыр.

— Тапкансың кайгырыр нэрсэ! — дигэн булды карты. — Мин инде барысын да уйладым. Минем урынны караңгы бүлмэгэ куярбыз, тегермэнне дэ шунда җайларбыз.

— Үзең белэсең тагын, — диде Батима карчык, сикереп төшмичэ генэ. — Оны булса, алучысы табылыр. Бигрэк авыр килде бу яз.

— Базарда хэллэр ничек соң? — диде ире Мөхлис, аеруча кызыксынып.

— Базар хэллэре... ярыйсы инде, — диде Батима. — Кая карама бодай да арпа. Мака сар үзенең ашлыгын саттыра башлаган.

— Он да күпме?

— Он... күрмэдем, — диде Батима карчык.

— Менэ, эйттемме?! — диде Мөхлис, балаларча куанып. — Ничек мака сарның башы җитмэде икэн? Бар ашлыгын онга эйлэндереп сатса, күпме табыш алыр иде ул!

— Бар, шулай дип барып эйт, — диде хатыны, күңелсез көлемсерэп. — Болай да табышны җитэрлек алачак ул. Былтыргы көзге бэясеннэн икелэтэ арттырып саталар.

— Алайса, ун кадагы ун сум бакырмыни? — диде карт.

— Юк шул, ун кадагы бер сум алтын, — диде Батима, ниһаять, эчендэгесен эйтеп.

Икесе дэ тынып калдылар. Батиманың сүзне артыкка сузасы килмэде. Ул, китэргэ җыенып, урыныннан кузгалып куйды. Карты янында озаграк утырса, түзмэс, күңелсез хэбэрлэрне тагын да күбрэк сөйлэп ташлар сыман тоелды.

— Шулай да карап карыйк эле, — диде карт, телгэ килеп. — Болай тик ятуы бик күңелсез.

— Карарбыз, борчылма, — диде хатыны, картын тынычландырып. — Иң элек менэ бакчаны карыйсы бар. Теге баланың да күңеле илэс-милэс.

Батима шыпырт кына, тавышсыз гына чыгып китте. Карт бүтэн эндэшмэде. Ул басылып, йомылып калды. Юкка хыялланды, ахрысы. Бик тиз генэ күп акча эшлэмэкче булды. Эшлэрсең, бар! Бакырга алып булса, эле, бэлки, чыннан да табыш ясарга булыр иде. Кайда да алтын кирэк, алтын! Алтын елга булып мака сарга ага.

Ул туймый алтынга. Барысы да аңлашыла. Мака сар аллага тиң. Ләкин аның мәңге яшисе килгән кебек, бүтәннәрнең дә яшисе килә бит әле! Аягы йөрмәгән килеш булса да яшисе, нидер эшлисе һәм балаларын урнаштырып бетерәсе килә. Аның үзенә әллә ни күп тә кирәкми хәзер. Тиешле корбанын бирә алса, тамагын туйдыра алса, аңа шул җиткән.

Үзләре бистәсенә кайтып җиткәч, Җәбир, ярга чыгып, әнисе артыннан бераз җир барды да ялт кына читкә каерды һәм, яр буендагы агач артына посып, беравык көтеп торды. Әнисе, улының торып калуын сизмичә, алдын-артын карамыйча, әкрен генә теркелдәвендә булды. Әнисе күздән югалганчы, Җәбир юан агачка сөялеп торгандай итте дә ашыкмыйча гына кире яр буена китеп барды. Аның хәзер өйгә кайтасы килмәде. Кайтсаң, әлбәттә, әнисе бакча казырга, арыкны чистартырга кушачак иде. Аның хәзер һич тә кәтмән белән, көрәк белән булашасы килмәде. Аның хәзер гомумән берни эшлисе дә килмәде. Аның хәтта уйланасы да килмәде. Уйлана башлады исә, уй җепләренең үзеннән-үзе бер үк нәрсәгә — Талиягә, ярлылыкка барып төртеләчәген ул инде болай да алдан ук белеп торды.

Аның хәзер үзе генә каласы килде. Ерагая барган әнисе ягына тагын бер күз карашы ташлап алды да, әкрен генә атлап, яр буенча түбән таба — диңгез ягына таба китеп барды.

Яр буенда көндәгечә, һәрвакыттагыча шау-шу, гүелдек ишетелеп торды, көндәгечә, һәрвакыттагыча ниндидер ыгы-зыгы, ашыгу-кабалану сизелде. Кемнәрдер кычкырып сөйләште, кемнәрдер бер-берсенә аваз биреп кычкырды, кемнәрдер күпер аша көтү куалаганда чыбыркы шартлатты. Шундый таныш, күнегелгән тавышларны күмеп, кинәт йә берәр бала нечкә тавыш белән чинапкычкырып җибәрде, яисә, бөтен тирә-якны дер селкетеп, күк күкрәгән авазлар чыгарып, бар куәтенә үгез үкерде.

Күпердән ераклаша барган саен, андагы тавышлар да кими төште, каядыр ашыккан, ары-бире чабышкан кешеләр очрамый башлады. Җәбир яр буенча сузылган таш койма буйлап барды да барды. Су ягыннан җиңелчә дымлы җил исте. Дымлы җил белән бергә балык исе, ят азыклар, тир һәм дегет исе килде. Аста, яр буе коймасына ниндидер кәмәләр, каеклар бәйләп куелган, су уртасыннан зур-зур кәмәләр, каеклар шуыша иде. Алар диңгез ягыннан киләләр. Арык уртасыннан беркемгә

игътибар итмичә кызыл-сары борынлы зур бер кәмә диңгез ягына ашыгып бара. Өске катка, шома өрлекләр янына, шәрә тәнле, бердәй матур тәнле яшь ирләр-сугышчылар, сөңгечеләр тезелеп баскан. Борында, койрыкта шулай ук таза ирләр басып тора. Озын саплы ишкәкләр тигез булып, бердәм булып күтәрелә. Кая ашыгалар алар? Бер-бер ашыгыч хәбәр алып баралармы, әллә берәрсенә каршы яуга киттеләрме? Юк, болай гынадыр, яр буйларын күзәтеп йөрүче сакчы кәмәдер.

Диңгез ягыннан килүчеләр арасында кемнәр генә юк та ниләр генә юк! Менә яр буйлатып, якыннан гына, йөкле хатын сыман авыр гына, әкрен генә йөк кәмәсе кыймылдап килә. Зур корсаклы, текә борынлы. Капчык, чүлмәк төягән. Уртанчы өрлеге урталай сынган, болай да тузып беткән җилкәннәре ертkаланган. Уң яктагы ишкәкләрнең күбесе эшләми — күрәсең, давылга эләккән. Әнә аның артыннан кара-коллар төягән озын, биек кәмә килә. Монысы — кәмитләр. Кара-коллар гел алар ягыннан килә. Арырак, теге як ярга табарак, әнә бер бай кәмә китеп бара. Уртада, калку урында, чатыр. Чатыр өстендә түгәрәк алтын түбә. Өрлекләр алтынга төрелгән, кәмә борынында алтын тәкә барысын да сөзеп, ертып бара. Кырый такталарга матур итеп алтын-көмеш калайлардан бизәкләр беркетелгән, хәтта ишкәк саплары да алтын-көмеш белән бизәлгән. Әллә каян ялт та йолт килеп тора. Кояш нурларын чагылдырып, күзләрне камаштыра. Узучы-баручы кәмәләрдәге һәркемнең күзе шул якта. Кем икән? Изгеләрнең берәрсеме, әллә аларның якыннары, асрауларымы? Нинди бәхетледер ул ирән! Чатыр эчендә, җиләстә йомшак су өстендә тирбәнеп баручы ирән! Бәлки, ул берәр чибәр кыздыр, бикәдер. Бәлки, беркемгә кирәкмәгән берәр карттыр. Чүлмәк-чүлмәк алтыны, байлыклары, коллары, ат-арбалары булган берәр карттыр. Сатучыдыр. Бар соң өлешле кешеләр бу дөньяда!

Җәбирнең күңелендә үзе дә сизмәстән көнчелек тойгысы уянды. Үзенең ярлылыгы, үзенең өлешсезлеге өчен нишләптер нәкъ менә шул бай кәмәдә баручы билгесез бай карт, саран бай яисә мактанчык яшь ирән гаепледер сыман тоелды. Аның да, билгеле, нәкъ шундый ук алтын-көмеш белән бизәлгән матур кәмәдә утырып каядыр баручы бәхетле кеше сыман ук бәхетле, бай, гамьсез буласы килде. Ләкин чатыр эчендә ул үзе түгел, башка кеше булганга күрә, ул аны бөтен җаны-тәне белән дошман күрде.

Алсу чатырлы кәмә, күзнең явын алып, күңелләрне кытыклап, ярсытып, ашыкмыйча, су уртасына барды да барды. Җәбир һич күзен ала алмады. Аңа хәтта аннан хуш исләр һәм моңлы, дәртле җыр авазлары килә сыман тоелды.

Шулай онытылып, алдына карамыйчарак барганда, ул ниндидер кешеләргә килеп бәрелә язды. Ул бары кычкырып көлгән һәм ачуланып кычкырган ниндидер ят тавышлар ишетеп кенә айнып киткәндәй булды. Күзләрен ачыбрак караса, яр буенда, тигез җир өстендә, юнылган, юнылмаган бүрәнәләр, ярым шәрә таза балтачылар күреп аптырабрак китте. Болар, озын саплы җиз балталарын алмаш-тилмәш күтәреп, бик озын бүрәнә юнып яталар иде. Бу турыда яр буе коймасында киң генә ачыклык калдырылган һәм яр өстеннән туп-туры су өстенә киң басмалар салынган иде. Монда эшчеләр кәмә ясыйлар. Сулда, ярдан читтәрәк, теләсә ничек таратып ташланган юеш нарат, имән агачлары сузылып ята. Яңа юнылган агач исе, кайры исе килә.

Җәбир адымнарын әкренәйтә төште, аяк астына караныбрак, балтачылар тавышына колак салыбрак ары узып китмәкче булды. Шул чакны ул үзе дә сизмәстән бар көченә кычкырып җибәрде. Үз эшләренә бирелеп шак-шок бүрәнә каезлаучы ирләр, кинәт эшләреннән туктап, башларын күтәреп карадылар.

— Нәрсә булды? — диде якындагы ирләрнең берсе, яр буеннан узып баручы яшүсмергә карап.

— Җылан! — диде Җәбир, коты алынып. — Койрыгына баса яздым.

Ирләр, эшләрен ташлап, Җәбир янына йөгерешеп килделәр.

— Кая? Нинди? — диештеләр төрле яктан.

— Әнә анда кереп китте, — диде Җәбир, күрсәтеп.

Ирләрнең бер-икесе, балта тотып, ул күрсәткән якка ташландылар.

— Әнә! — диде берсе, балтасы белән кизәнеп.

— Юк, үтермә! Мөгезле җылан! — диде икенче кәмәче, аның юлына аркылы төшеп.

— Мөгезле?! — диде Җәбир, шаккатып. — Чынлапмы?

— Чынлап булмый әллә! — диде өлкәнрәк ирләрнең берсе. — Бүрәнә арасында килә, сал белән.

— Мөгезлене күрсәң, бәхеткә юлыгасың, — диде Җәбир.

— Без аны әледән-әле күрәбез, бәхеткә генә юлыкка-

ныбыз юк, — диде өлкән яшьтәге балтачы, артык исе китмичә.

— Мөгезле җылан күрәсең килсә, безнең янга эшкә кил, — диде яшьрәк балтачы, Җәбиргә эндәшеп.

— Мөгезле җылан күрү үзе бәхет, — диде балтачыларның икенчесе.

— Ямьсез сөйләшәсез, — диде Җәбир, яратмыйча. — Нишләп мөгезле җыланга тел тидерәсез?

— Түрәдә төрмә, улым, — диде шул чакны өлкән балтачы, кырыс кына, киңәш иткән сыман. — Җылан монда күп. Бәхетле булу урынына бәлале булырсың әллә.

Шулай диде дә юна башлаган бүрәнәсе янына китеп барды. Башкалар да тавыш-тынсыз гына аның артыннан иярделәр, һәм яр буенда яңадан тукылдатып агач юнган тавышлар ишетелә башлады.

Җәбирнең ары барырга аягы тартмады. Елан ул барасы сукмакка төшәлгән таш астына кереп китте. Җәбиргә ул аның юлын бүлде сыман тоелды. Нәрсәгә булыр бу? Яхшылыккамы, яманлыккамы? Җәбир үзе генә моны берничек тә хәл итә алмады. Кара еланнан башка еланнарны үтерергә ярамаганлыгын һәм мөгезле еланның изгелеген ул, билгеле, белә иде. Тик менә ул үзе аның мөгезен күрә алмады, бәхеткә юлыгу өчен бит аның мөгезен үз күзең белән күрергә кирәк түгелме соң?

Ул бер урында таптанып торгандай итте дә кире борылды. Билгесезлек, эч пошу, күңелсезлек кул белән алгандай юкка чыкты. Язгы кояшлы көн кинәт кенә караңгыланып калгандай булды. Су өстендәге кәмәләр дә, кәмәдәге кешеләр дә күренмәс булды һәм шулай ук тирә-яктагы өзлексез шау-шу ишетелмәс булды. Елан лелег өчен никадәр изге саналмасын, шулай да ул куркыныч. Мөгезлесе дә, мөгезсезе дә. Җәбир бик озак тынычлана алмады. Болай бер максатсыз йөрү кинәт аңа мәгънәсезлек булып тоелды. Шул ук вакытта аның үтереп ашыйсы килә башлады һәм ул, адымнарын кызулый төшеп, үзләре ягына юнәлде. Үзләре ягына борылу белән, шундук бакча, карт алмагач, чүп-чар, иске яфрак күмеп китә язган арык күз алдына килде. «Миннән башка беркем казымас инде аны», — диде ул үз-үзенә, көрсенеп.

Капканы ачып ишегалдына килеп керү белән, әнисе очрады. Әнисе ике куллап авыр гына кызыл чүлмәк тоткан килеш өйгә кереп бара иде. Җәбирне күргәч, ул туктап калды, артык каты бәрелмичә, шулай да коры гына:

— Кайда йөрисең соң син? — диде.

— Инәй, мин мөгезле җылан күрдем! — диде Җәбир, кирәкмәгән бер ашыгычлык белән.

— Бай бул, — диде әнисе. — Кайда күрдең? Ничек күрдең? Балтачылар янындамыни?

— Шунда, — диде Җәбир, әнисенең белүенә исе китеп. — Юлыма аркылы төште.

— Анда аның оясы бар, диләр, — диде әнисе. — Ата-бабалар корбан өмет итәдер. Шуңа юлыңа аркылы төшкәндер. Билеңнән өч мәртәбә әйләндереп, ата-бабалар рухына садака бирәсе булыр.

— Мин әллә аласы микән дигән идем, бирәсе икән алайса, — диде Җәбир, күрәләтә ризасызлык белән.

— Алай сөйләнмә! — диде әнисе. — Садаканы күпсенмиләр.

— Күпсенгәннән әйтмим, — диде Җәбир.

— Ярар, күп сөйләнмә! — диде әнисе. — Юын да, аша да...

Ул шулай диде дә озын муенлы, киң авызлы кызыл чүлмәген ике куллап күтәргән килеш өйгә кереп китте.

«Юын да, аша да... эшкә чык», — диде Җәбир, әнисенең әйтелеп бетмәгән сүзләрен үзенчә дәвам итеп. Әйе, беркая качып котылып булмаячак. Кол кебек, кулыңа көрәк алып, кәтмән алып, җир казы, чүп-чар актар. Аның кебек яшьләр хәзер ат атланып чабалар, йөгерешәләр, көрәшкә, ярышка әзерләнәләр. Кәмәләрдә йөреп күңел ачалар, кичләрен тамашага, тәтиләргә йөриләр... Ләкин алар — бай балалары!

Өй артында зур гына кызыл таш өстендәге чүлмәк көпшәдән челтерәп су агып ята. Су ерактан, изгеләр калкулыгындагы чишмәдән, шундый ук чүлмәк көпшәләр буенча агып килә һәм, тармакланып, бистәдәге барлык йортларга керә. Мака сар яши торган Изгеләр калкулыгыннан килгән су шифалы исәпләнелә. Җәбир учларын кушлап су астына куйды, кулын юды, аннары кушуч тулы салкын суны битенә тидерде. Ул тынычланып калгандай булды. «Юк, алай түгел ул», — диде ул, күңеленнән әнисе белән бәхәсләшеп. Мөгезле елан теләсә кемгә очрамый ул. Тиккә түгел ул. Тиккә булырга тиеш түгел! Бөтенесе типтереп, менә дигән итеп яшәгәндә, ул гына капчык күтәреп йөрергә, ул гына җир казып, чүп-чарда актарынырга тиешме әллә? Лелег түгелме әллә ул? Лелег ул — Кояш улы, шулай булгач, дөньяда иң бәхетле кеше... булырга тиеш.

Ашап туйгач, Җәбир, әнисенең, әтисенең ни дә булса әйткәнен көтеп тормыйча, шундук тышка чыкты. Кояш,

төшлек турысын узып, кичке якка авышкан иде, ишегалдындагы, бакчадагы күләгәләр озынайган, көн талгына төшкән. Шулай да бөтен тирә-якта җылы, якты һәм күңелле иде. Бакчада агач башларында кошлар чыр-чуы яңгырап тора, арык ягыннан туктаусыз гөрелдек ишетелә. Җәбир ашап-эчеп утырганда дөнья бер генә мизгелгә дә тукталып тормаган һәм бөтен нәрсә әүвәлгечә каядыр барып җитәргә тырышкан кебек туктаусыз кыймылдый, хәрәкәтләнә, ашкына һәм ашыктыра иде.

Тамагы туйгач, Җәбир, күңеле күтәрелеп, үз-үзеннән канәгать булып, койма буендагы таш утыргычта, кояшка йөзен куеп, беравык хозурланып утырды. Ул ашаган арада кара-кол Фу-фу бакчада эшләп булаша иде. Җәбир күз кырые белән генә аның эшләвен карап утырды. Фу-фу инде картайды. Тиешенчә эшли алмый. Шундый җиңел кәтмәнне дә бик авырлык белән күтәрә. Хәрәкәтләре акрын, дәртсез. Аңа инде күптән урын өстендә ятарга иде. Әтисе янында вак-төяк йомышын башкарып торса да җиткән. Әле ул көндезгене ашамагандыр да. Юк, картайган колга салгашып кына баеп булмас бу дөньяда.

Җәбир Фу-фуның кыймылдавын карап утырды-утырды да урыныннан торды. Яшь, көчле аякларының ничек атлавын да тоймастан, ул куаклар арасындагы тар сукмактан бакчаның түрге ягына юнәлде.

— Бар, ашарга кер, — диде ул, колның кулындагы шомарып беткән агач саплы кәтмәнгә тотынып.

Фу-фу аның килгәнен сизеп торган, ахрысы — башын калкытты, билен турайтты да кәтмәнне Җәбиргә бирде һәм, берни әйтмичә, әкрен генә өйгә таба китеп барды. Җәбир Фу-фуның кәтмәне белән бер-ике селтәнеп карады да ачу белән аны читкә атып бәрде — кәтмән аңа тотарга җайсыз да, җиңел дә сыман тоелды. Ул бакчаның иң түрдәге почмагына — эш кораллары куела торган җиргә килде һәм үзенә иң җайлы, нык һәм авыр кәтмәнне алды. Үзе яраткан саплы кәтмәнне тотып шулай кире китеп барганда, күршеләр ягына күз ташлап алды. Койма артында тыелып кына көлешкән тавышлар ишетелгәндәй булды.

Җәбир туктап калды, аяк очларына басып, койма аша теге якка күз ташлады. Ләкин ул басып торган җирдән күршеләрне ныклап күреп булмый иде. Егет әле генә киткән җиренә кире килде дә мыштым гына шундагы ташка басты һәм муенын сузып, колагын үрә торгызып теге якка карады. Шулай яшерен генә, күренмичә генә

күршеләр ягын күзәтү аның өчен иң кызык, иң яшерен нәрсәләрнең берсе иде. Анда ул, билгеле, үзенең абыйсы Мирзыйны күрү өчен карамый. Яшерен генә ул үзенең җиңгәсен, чибәр Галимәне... күзәтергә ярата иде. Әле дә Галимә ишегалдындагы калку таш өстендә җиз табагын куеп кер уып ята. Мирзый, якындагы зәйтүн куагына үрелеп, аңа нидер сөйләпме, аңлатыпмы тора. Үз ишегалдында булганга һәм кер белән, су белән булашканга, Галимә бөтенләй диярлек шәрә килеш калган. Бары күзенә төшмәсен өчен озын, күперенке кара чәчләрен маңгай турысыннан ал тасма белән бәйләп куйган да биленә алъяпкыч сыман, итәк сыман итеп кыска гына киндер кисәге будырып куйган. Җәбиргә ул яны беләнрәк күренә иде. Аны шулай ярым шәрә килеш, тас өстенә иелеп, сылу беләкләре белән, бөтен тәне белән хәрәкәтләнгән килеш, башын калкытып елмая-елмая нидер сөйләнгән килеш күрү белән, яшүсмернең кинәт күз аллары томаланып китте, йөрәге ешрак тибә башлады. Һәм ул, бөтен тәненең уттай януын, сәер хәлсезләнеп калуын тойган хәлдә, тиз генә күзен читкә борды, таш өстеннән төште дә коймадан читкәрәк китеп барды. Ниндидер агач ботагына төртелеп туктап калды, күзләрен ачыбрак карады һәм, үзенең бөтенләй кирәкмәгән якка китеп баруын шәйләп, кәтмәнен кысыбрак тотты да кол Фу-фу казый башлаган җир ягына килде һәм, башын иеп, әкрен генә казый башлады.

Ул бик озак тынычлана алмады. Күз алдында һаман гүзәл күренеш торды, колакка ул яктан сихри, ягымлы авазлар ишетелгәндәй булды. Бераз селкенгәч һәм беренче тәэсир онытылгандай булгач, ул, кәтмәнен куеп, яңадан теге таш янына барды, яңадан койма аша теге якка күз ташлады. Мирзый инде юк иде, Галимә әүвәлгечә тырышып-тырышып кер уа. Җәбир чибәр җиңгәсенә бу юлы озак кына карап торды, ләкин бу юлы инде ул аңа алай ук сихерләнеп карамады.

Шул чакны өй ягында әнисенең тавышын ишетеп сискәнеп китте, тиз генә тигез җиргә басты да кәтмәне янына килде, ашык-пошык казырга тотынды. Тиз-тиз атлап аның янына әнисе килеп җитте.

— Мин фәләннәргә киттем әле, — диде ул, бик әһәмиятле хәбәр әйткән сыман.

Ул, билгеле, үзенең фәләннәргә киткәнен әйтер өчен түгел, улының эшлиме-юкмы икәнлеген карау өчен килгән иде. Җәбир дә моны бик яхшы белде.

— Ярар, бар, — диде ул, башын калкытмыйча гына.

«Нәрсә булган моңа? Кып-кызыл булган?» — дип уйлады Батима карчык улы турында. Ләкин төпченеп тормады, улының бакча казуына күңеле булып, шундук кире китеп тә барды.

«Тикшереп йөри!» — дип уйлады Җәбир, әнисенең шулай килеп китүен ошатмыйча. Аны әкренләп тыелгысыз ачу биләп алды һәм ул кәтмәнен ныграк бәреп казый башлады.

Баш калкытмыйча шактый озак эшләде Җәбир. Авыр кәтмәне бер төште, бер күтәрелде. Кышкы айларда тынып, басылып яткан һәм беркадәр тыгызланган, әлпәләнә төшкән җир өсте җиңел генә таркала, ваклана барды, чүп үләннәре, төбе-тамыры белән киселеп, туфрак астында буталды. Актарылган йомшак туфрактан җир исе, бөре һәм киселгән әчкелтем тамыр исләре килде.

Шулай бирелеп, мавыгып эш белән булашканда, кәтмән ташының үткер очы җир астындагы ниндидер каты нәрсәгә тиеп китте. Элегрәк, ул кечкенә чакта, бакчада таш кисәкләре еш очрый иде. Алар, бакча җирен ничек тә чистартырга, йомшаграк итәргә тырышып, күзгә чалынган бер ташны җыеп баралар иде. Шул гадәт буенча Җәбир кәтмәнгә тиеп киткән каты нәрсәне алып читкә ташламакчы булды. Ул, каты нәрсәне актарып өскә чыгармакчы булып, туфракны тирәнрәк казырга тотынды. Ләкин каты әйбер зур иде, ахрысы. Җәбир никадәр актармасын, ул һич тә кәтмән очына эләгеп чыгарга теләмәде.

— Туктале, нәрсә соң бу? Таш дисәң — таш түгел, агач дисәң — агач түгел. Шакылдаган тавышы да әллә нинди.

Җәбир кәтмәнен читкә ташлады да иелеп кулы белән актарырга тотынды. Туфрак арасында тигез чүлмәк төбенә охшаган каты нәрсә күренде. «Чүлмәк ватыгы икән» дип уйлады Җәбир, туфракка буялган кулларын каккалап. Ул инде яңадан кәтмәненә тотынмакчы да булган иде, ләкин «чүлмәк ватыгы» дигән нәрсәнең ватык булмыйча, бөтен икәнлеген шәйләп, ул баштагы уеннан кире кайтты. Актарылган балчык арасыннан, аңа хәтта чүлмәкнең төбе генә түгел, корсагы да күренеп тора иде. Бик гаҗәп иде, бик кызык иде бу. Нишләп ята бу чүлмәк монда капланып? Ялгыш күмелеп калганмы, әллә... берәрсе юри күмеп куйганмы?

Ул тиз генә көрәк алып килде дә капланып яткан чүлмәк тирәсен сакланып кына казырга тотынды. Учак өстенә утыртып су кайнатырга, ботка-фәлән пешерергә тотардай бу тигез төпле чүлмәк зур гына, киң генә иде.

Аның хәтта юан гына бер тоткасы да бар иде. Җәбир тирә-яктагы балчыкларны читкәрәк алып ташлады да, сабыннан тотып, чүлмәкне күтәреп алды. Чүлмәк көткәнгә караганда бик авыр булып чыкты. Ул шактый калын һәм тупас итеп әвәләнгән иде. Мондый зур авызлы чүлмәкләрне хәзер Аклантитада гына түгел, инде беркайда да ясамыйлардыр, күрәсең. Җиргә капланып яткан бу сәер һәм ят чүлмәкне кулына алып, нәрсәсе бар икән дип, Җәбир аның эчке ягына күз төшерде. Бу борынгы чүлмәкнең эче буп-буш иде. Ләкин кызыксынып һәм гаҗәпләнеп ят чүлмәкне караганда, Җәбир чүлмәк яткан җиргә дә карап алды.

Әлеге калын, авыр һәм тупас чүлмәк җиргә, тирәнгә утыртып куелган икенче бер чүлмәк авызына капкач сыман каплап куелган булып чыкты. Җиргә, тирәнгә утыртып куелган икенче чүлмәккә исә ниндидер ялтыравык сары ташлар тутырылган иде. Ләкин ул ташлар нишләптер елга буендагы шома вак ташларга да охшамаган, кыя таулардан кителеп төшә торган кырлы-очлы ташларга да охшамаган иде. Алар әллә ничек чүкеп ясалган нәрсәләрне хәтерләтә иде.

Җәбир көтелмәгән бу табышка, бу табышмакка исе китеп тораташтай катып тик торды. Ләкин шаккату, ис китү шулай да озакка сузылмады. Аны кинәт зур куанычлы бер сизенү биләп алды. Ул ирексездән елмаеп җибәрде. Бит аның таш дигәне алтын лабаса! Чын алтын! Байлык! Көч-куәт! Иң өстә ялтыравык чылбыр сыман нәрсә күреп алды. Чылбырдан тартып караса, яшел ташлы алтын тамга килеп чыкты. Бу чылбыр тамганың беләзеккә кидерә торган чылбыры булып чыкты. Җәбир тамганы әйбәтләбрәк карады. Озынчарак итеп эшләнгән калку шома ташка коңгыз сурәте ясалган иде. Тамганы балавызга яисә кызыл балчыкка батырсаң, кечкенә коңгыз сурәте калкып калачак иде. Мондый коңгызны кәмитләр кояш билгесе дип беләләр. Димәк, бу таш тамганы да кәмит остасы ясаган булырга тиеш. Бу яшел тамга Җәбирнең күңелендә бер-берсенә капма-каршы уйлар-сораулар өермәсе тудырды.

Аны хәзер бөтенләе белән тамга биләп алды. Нишләтергә аны? Кемгә әйтергә дә кемгә әйтмәскә? Әллә соң, беркемгә дә әйтмичә, киләчәккә калдырырга? Юк, киләчәккә калдыргач, ник кирәк ул?

Чынмы бу, түгелме? Әллә берәр сихер генәме? Туктале, саташамы соң ул әллә?

Юк, саташмый бугай. Нишләп саташсын! Кабак бот-

касы ашап, бераз эремчек ашап чыккач, теләмичә генә җир казыды. Җитмәсә әле, җиңгәсенең сылулыгына күзе төшеп, күпме хыялланып азапланды. Әйе, менә анысы хыял, саташу булды. Монысы — юк.

Монысы чын. Менә янда гына ят чүлмәк ята. Бик борынгы чүлмәк. Менә көрәк, кәтмән...

Ул, алтын тулы чүлмәк алдында чүгәләп, шактый озак телсез-өнсез торды. Ул нишләргә дә белмәде — аның хәзер кәтмәнгә бөтенләй кулы бармады. Ләкин шул ук вакытта бу көтелмәгән хәзинәгә кагылуы да куркыныч иде. Кем белә аны, бәлки, ул чыннан да берәр төрле сихер генә, күз буу гынадыр. Ә бәлки, аны мөгезле елан калдыргандыр.

Ул шулай бер фикергә дә, бер карарга да килә алмыйча утырды-утырды да яшел ташлы тамганы кесәсенә салды һәм авыр чүлмәкне ипләп кенә кире урынына каплап куйды. Аягына басты, чит кеше карап тормый микән дигән сыман, бөтен тирә-якны игътибар белән күзәтеп чыкты. Бакчада да, өй ягында да, беркайда да кеше-кара күренмәде.

Моннан күп, бик күп еллар элек каланың бу җирләрендә өйләр бик сирәк булган чагында бу тирәдә элек тә диңгезчеләр, сәүдәгәрләр яшәгән. Арада диңгез караклары да күп булган. Күрәсең, шуларның берәрсе күмеп калдыргандыр. Бит бу якларда моңарчы да тапкаладылар күмелгән хәзинәләр. Өченче ел, Галләмнәр күмелгән байлык тапканнар, дип бөтен бистә шаулады. Чүлмәкче Сәнәй чүлмәк өчен кызыл балчык казыганда чүлмәк тулы алтын-көмеш тапкан икән дигән сүз ишетелеп калды. Тик андый сүзләр соңыннан ялганга чыгарыла. Беркем дә үзенең хәзинә табуын танырга ашыкмый. Ник дигәндә, бөтен кала гына түгел, хәтта бөтен Аклантита утравы мака сарның үз җире, үз биләмәсе исәпләнелә. Җирдән казып табылган барлык байлык та, шул исәптән хәзинәләр дә, әлбәттә, мака сарныкы санала. Түрә буенча, табылган байлык тулысынча мака сарга бирелергә тиеш. Бирмәсә... ул чагында... Ул турыда хәтта уйлыйсы да килми. Ләкин шул ук вакытта үзе тапкан байлыкны кемнең мака сарга бирәсе килсен? Ул болай да бай, болай да барлык алтын-көмешне, матур ташларны үзенә җыя.

Җәбир тынычсызланып өй ягына барып килде, кире борылды да эш кораллары саклана торган почмакка килеп баягы таш янына барды, таш өстенә басып, койма аша абыйсы ягына күз ташлады.

Галимә өйләре янындагы пальма агачыннан таш койма буендагы казыкка сузылган җепкә керләр элеп тора иде. Күрәсең, көч чыгарып кер юганга ул бераз гына арыган сыман күренә, бераз гына тирләгән дә, чыланган да. Җәбирнең муенын сузып каравын ул күреп алды, ялт кына аның ягына борылды һәм матур итеп елмаеп җибәрде. Ул инде каенесенең үзенә сокланып каравын да, койма аша качып-посып карауларын да, очрашканда күзгә туры карый алмый кызаруларын да күптән күреп, белеп, сизеп тора иде. Баягынак ул аның озак итеп үзенә карап-карап торуын күреп алды, ләкин аны куркытмас өчен үзенең күргәнлеген сиздермәскә тырышты. Хәзер исә, юган кере күп булмаса да һәм булган барын өй янынарак элеп куярга мөмкин булса да, юри койма янынарак килеп элде. Элгәндә әле, җитмәсә, үзе дә болай гына, кызык итеп кенә койма аша күз төшергәләп алды һәм менә шул чагында ул усал, ләкин оялчан каенесенең алмагачка якын җирдә нindидер чүлмәк казып чыгарганын да, чүгәләгән килеш бик озаклап бер ноктага карап утыруын да күреп алды.

— Менә, керләр эләм әле, — диде ул, бик зур сер әйткән сыман.

— Ы-ы... ни... шулай икән, — диде Җәбир, мыгырданып, һәм, үзенең ярамаган эштә тотылуына оялып, кып-кызыл булды.

Аның шулай оялуы, кызаруы җиңги кешегә бик ошады һәм ул ничектер якын итеп көлеп куйды.

— Абыең чыгып китте әле, — диде ул, тагын да сер итеп кенә.

— Кизүгәмени? — диде Җәбир.

— Кизүгә ул төнгә бара, — диде җиңги.

— Алай икән, — диде Җәбир, җиңгәсеннән күзен алмыйча.

Ул үзен ничектер кадаклаган кебек хис итте. Моннан беренче булып кузгалып та китә алмады, аңа шулай ук җиңгәсенә күзен тутырып карап тору да уңайсыз сыман иде.

— Әнкәй күрер, бар инде, — диде җиңги, ниһаять, беренче булып, тәнен каплаштырып. — Кер юганда җиңгигә күз ату килешми ул, каенекәш!

Ул шулай диде, бер кулы белән кочаклап тоткан җиз тастан икенче кулы белән учлап су алды һәм авызын ачып торган Җәбиргә сибеп тә җибәрде. Салкынча су тамчылары Җәбирнең битенә килеп тиде. Яшүсмернең кайнарлыгы шундук сүнде. Көтелмәгән мондый шаян-

лыктан Җәбир дерт итеп китте, кыюсызлык, торгынлык юкка чыкты. Аның ачуы килде. Аның, койма аша сикереп чыгып, җиңгәсенең табагын кулыннан бәреп төшерәсе йә булмаса берәр ничек җавабын кайтарасы килде. Ләкин ул берни дә эшли алмады — уенчак җиңги, көлә-көлә, өйләренә таба китеп барды. Шулай да Җәбир балчык кисәге алып аның артыннан ыргытып калды һәм, элеккедән дә ныграк хурга калып, бакча түренә юнәлде.

Җиңгәсе белән очрашкан арада Җәбир алтын хәзинә турында онытып җибәргән иде.

Ул чүлмәк тирәсендәге җир өстен тигезләгәндәй итте дә көрәген кире урынына илтеп куйды. Шуннан соң, күршеләр ягына карамаска тырышып, әкрен генә китеп барды.

Нишләргә соң шулай да? Иң элек әтисе йә әнисе белән киңәшеп карарга кирәк, ахрысы. Җиңги кешегә әйтсәң, ул Мирзыйга әйтәчәк. Аңа ярамый. Туктале, әтисе урыннан тормый ята, шул тирәгә, аның ятагы астына куйганда ничек булыр икән? Алтын, алтын тамга байлык инде ул! Иң элек Талияне алып кайтырга... аннан соң... атлар алырга... Күп, бик күп әле эшләр.

Ул шулай уйланды да уйланды. Эшләгән булып күренү өчен кәтмәненә тотынды, җир йомшарткандай итте. Ләкин кәтмән аңа хәзер күтәреп булмастай авыр булып тоелды. Ул бер-ике генә селтәнде дә туктап калды һәм, нәрсәнедер онытып та һич хәтеренә төшерә алмый азапланган кеше сыман, кәтмән сабына таянып, хәрәкәтсез катып калды. Ләкин аңа болай катып торырга ярамый, ул нидер эшләргә тиеш иде, шуңа күрә Җәбир, әнисенең күреп ачулана башлавыннан куркып, теләр-теләмәс кенә яңадан селкенә башлады.

Үзе ул, билгеле, агачлар арасында мине беркем күрми дип уйлады. Ләкин мут җиңгәсе койма аша да, ерактан да аның кыланышын күреп, күзәтеп торды. Каенесенең тынычсызлануын ул үзенчә аңлады. Аның әрле-бирле йөренүен, кинәт туктап калып, түбән карап торуын Батима карчык та күреп алды. Ул фәләннәргә бармаган да иде, ахрысы. «Ни булган бу балага?» — диде дә ашыгып бакчага чыгып китте.

Каршысында әнисен күреп, Җәбир сискәнеп китте, гаепле төс белән елмайды да ашыгып казына башлады. Аптыраган әнисе аның ничек эшләвенә карап торды-торды да, ирексездән: «Әллә ычкынган инде бу бала?» — диде үзалдына.

— Нишләдең син, улым? — диде ул, ярым кызгану, ярым аптырау белән.

Җәбир тагын бер сәер итеп елмайды да, ярым пышылдап:

— Әни, мөгезле җылан... безгә байлык китергән, — дип куйды.

Әнисе берни аңламады. Улының җүләрнеке сыман булып үзгәргән йөзеннән күзен алмыйча, шулай да якынрак килде.

— Саташмыйсыңдыр ич, улым? — диде, Җәбирнең кайнар маңгаеннан тотып.

— Юк, әни, — диде Җәбир. — Карале менә монда!

Җәбир шулай диде дә күмелгән чүлмәк өстендәге балчыкны бер читкә сыпырып ташлады. Тигез чүлмәк төбе күреп, Батима карчык тынып калды, аннан соң, калын чүлмәкне алып астагы чүлмәк авызын күрсәткәч, кулларын чабып аһ итте һәм шундук артына ауды.

— Әйттемме?! — диде Җәбир, тантана белән.

Батима карчык эндәшмәде, кысыграк күзләрен зур ачып, аптырап, сөенеп тик утырды. Исенә килгәч, ул җиргә таянып, иләп кенә кузгалып куйды, аягына басты.

— Ас анага корбан бирербез, — диде ул, беренче сүзе итеп. — Каплап куй. Күрүче булмадымы?

— Юк, — диде Җәбир.

— Корбан бирмичә кагыла күрмә, — диде Батима карчык, нык итеп.

Җәбир калын чүлмәкне тиешле урынына каплады да казылган туфракны тигезләп куйды.

— Әтигә үзең әйтерсең, — диде ул, әнисенә киңәш иткән сыман.

— Әйтермен, — диде әнисе.

Әнисе белән сөйләшеп аңлашкач, Җәбир тынычланыбрак калгандай булды. Әнисе, тотынса, барысын да үзе дигәнчә алып чыгачак ул.

Ас ана җиргә корбан бары төнлә генә бирелә һәм корбан малы бары кара төстә генә булырга тиеш иде. Батиманың кара төстәге бер генә кош-корты да, мал-туары да юк иде. Моның өчен йә базарга барырга кирәк булачак, йә күршеләргә ялынырга туры киләчәк. Күршеләргә ялынган очракта да, билгеле, аны сатып алырга туры киләчәк. Сатып алганда исә хуҗа кеше төпченә башлаячак. Нигә кирәкте, ник корбан бирәсең, фәлән-фәсмәтән, диячәк. Аннан соң, сиңа кирәк булган өчен генә кара сарыгын йә кара кәҗәсен сатамы-юкмы әле ул. Шулай булгач, иң яхшысы тагын базарга барырга һәм үзеңә кирәкне сайлап алырга туры килә. Ни генә булмасын, иртәгәгә чаклы көтми булмый. Монда барысын да уй-

лап, җайлап эшләргә кирәк. Ашыгырга ярамый. Моңарчы яткан күпмедер җир астында, тагын бер-ике көн ятар, берни булмас, алла боерса!

Батима карчык шундыйрак карарга килде. Карарга килүен килде, шулай да ул тиз генә тынычлана алмады. Кичкә чаклы вакыт бик акрын узды. Бер-ике мәртәбә ул бер дә юктан бакчага чыгып әйләнде, Җәбир кебек үк, күмелгән чүлмәк турысында туктап уйланып торгандай итте. Шуннан соң ул кереп киндеренә тотынып карады, ләкин эше әз генә дә алга китә алмады — әле бер җебе өзелде, әле кулыннан сосасы төшеп китте. Батиманың тынычсызлыгына Фу-фу белән Суси дә, авыру карты да игътибар итми калмадылар. Фу-фу белән Суси аның тынычсызлыгы турында сорарга батырчылык итмәделәр, ләкин ире, карчыгының үзгәргән йөзен күреп:

— Әллә чирләдеңме, төсең качкан? — диде.

— Чирләдем бугай, — диде Батима карчык, тыелып кына.

Шуннан соң алар арасында башка сүз булмады. Ләкин карт өчен иң сәере шул булды — ишек артында Җәбир белән очрашкач, Батиманың чире шундук онытылды, бер-берсен бик яхшы аңлаган кешеләр кебек алар нәрсәдер үзара пышылдашып кына сөйләшеп алдылар. Карт барысын да тыңлап ятты. Иң гаҗәбе шул булды — караңгы төшәр-төшмәс Җәбир, әнисе белән сөйләшкәч, ястыгын күтәреп тышка чыгып китте. Әһә, төнне тышта кунмакчы була. Кунса ни, аның ни сере бар икән соң? Нигә шулкадәр пыш-пыш килделәр икән?

Карт шулайрак дип уйлады һәм бу турыда инде ул оныткан да булыр иде, ихтимал. Караңгы төшеп, йоклар вакыт җиткәч, Батима карчык гадәтенчә карты янына керде. Ләкин башка вакыттагы кебек чишенеп аның янына ятмады, түшәген идәнгә, авыру картының биек ятагы янына җәйде. Элеккерәк чакларда ул нык ачуланышканда, шулай урынын идәнгә җәеп, берүзе йоклый торган иде.

— Ачуландыңмыни? — дигән булды карты, шаярткандай итеп.

— Ачуланмадым, — диде Батима. — Төнлә кыбырсып синең йокыңны бүләрмен дип куркам.

— Кичтән дә әз кыбырсымадың инде, — диде Мөхлис. — Әллә нәрсә булган сиңа. Җәбир дә әллә нәрсә тыз-быз килә.

Батима эндәшмәде, йокыга киткән кеше сыман тын гына ята бирде.

— Телеңне йоттыңмы әллә? — диде карты, үртәлеп.

— Йоклыйк инде, көне буе йөреп арыганмын, — дигән булды Батима карчык.

— Төн озын, ята-ята кабыргаларың сынар, — диде карты.

Батима карчык тагын озак кына эндәшми ятты. Үзе һаман йокыга китә алмый азапланды: кайгысы бар кеше сыман озын итеп тын алды, урынын җайлый алмыйча, бер яктан икенче якка боргаланды. Аның шулай тынычсызланып ятуын сагаеп тыңлап яткан карты үпкәләгән сыман әйтеп куйды:

— Миннән нәрсәдер яшерәсәң кебек син, — диде.

Батима карчык беравык тынып ятты да кинәт торып утырды, йөзенә таралып төшкән озын чәчләрен артка сыпыргалап, серле бер пышылдау белән:

— Әйтим микәнни соң? Тик менә әйтергә куркам, йөрәгең начар.

— Күңелсез булса, әйтмә, — диде карт, көттереп. Шулай диде дә, ярым караңгыда еш-еш тын алып, чикерткәләр сайравына, ерактагы төнге тавышларга колак салып ятты. Чыннан да, йөрәге ниндидер яман хәбәр буласын сизенгән кебек, кинәт кысылып-йомылып калды. «Кызга бер-бер нәрсә булды микәнни, әллә Мирзыйгамы? Сугышканмы, яралангамы, ни булган?»

— Күңелсез хәбәр түгел, — диде Батима, ятагына утырып.

— Түгел?! Нәрсә соң шулай да? — диде карты кинәт.

Батима аягына басты, картының зур кулларын тотып алды да, колагына иелеп, ярым пышылдап:

— Улыбыз... Җәбир бакчада... чүлмәк тапкан, — диде.

— Тапса ни! — диде карт, исе китмичә, кычкырып, хәтта беркадәр ачу белән. — Чүлмәк күргәнең юкмы әллә?

— Алтын тулы чүлмәк, җүләр, — диде Батима карчык, көлеп, яратып картының кулыннан тотып.

Үзен бер дә юкка рәнҗетелгән, читкә тибәрелгән дип исәпләгән картының барлы-юклы ачуы шундук юкка чыкты. Ул тынсыз калды һәм кинәт ике куллап карчыгының беләкләреннән тотып алды да, курку да, сөенеч тә, таләп итү дә сизелгән бер өн чыгарып:

— Чынмы?! Үзең күрдеңме?! Зурмы?! — диде, кабаланып.

— Үзем күрдем. Зур. Эче тулы алтын! — диде Батима карчык, башка тыелып торуны кирәксез санап.

Карт, үзендә искиткеч җиңеллек, көч-куәт тоеп, үз-үзен белешмәстән, кинәт урыныннан торды, аякларының йөрмәвен онытып, ничектер ятагыннан шуышты да, Батима карчык ни булганын аңлап өлгергәнче, үз аяклары белән такта идәнгә басты һәм сөенеченнән дер-дер калтыранган килеш янындагы чандыр тәнле карчыгын кысып тотты. Аннары акылдан шашкан сыман көлә-көлә еларга тотынды.

— Алтын! Алтын! — диде ул, туктаусыз кабатлап.

Батима кортка нәрсә эшләргә дә белмәде. Картының аягына басуын күреп, аның куанасы да килде, аның сәер кыланышларын күреп, шул ук вакытта ул шикләнә дә калды. «Акылына зыян килдеме әллә?» — дип уйлады ул, коты алынып.

— Карале, утырып карале урыныңа, — диде ул, иплэп кенә, картының каты кулларыннан ычкынмакчы булып.

— Юк, утырмыйбыз әле без! Йөрибез! Йөрибез! — дип кычкырды Мөхлис карт, бөтен өйне яңгыратып. Һәм кулларын Батиманың беләкләреннән ычкындырды да әкрен генә атлап китте. Батима шундук аның беләгеннән тотып алды. Шаккатып, ышанмыйча ярым караңгыда идән буйлап ирен йөртте һәм, бөтен өй эченә кычкырып: «Атабыз Адамга, Ту әниемә», — дип, белгән догаларын укырга тотынды.

Ул арада коллар да уяндылар. Хәер, алар йокламаганнар да иде. Сөенешеп, алар йөгерешеп килеп җиттеләр, учактан пыскытып ут кабыздылар.

— Баебыз йөри! Үз аягы белән йөри! — дип кычкырды Батима Суси белән Фу-фуга, сөенечен кая куярга белмичә.

Коллар картның аягы астына егылдылар, елый-елый аның аякларын кочаклап алдылар. Фу-фу, үзенең яшь чагын исенә төшереп, сөенечтән аяк кулларын бутап биергә тотынды.

— Ирек! Ирек! Биебез йөри! — диде Фу-фу, такмаклап.

— Нинди ирек? — диде Батима, кол авызыннан чыккан мондый тыелган сүз ишетеп.

— Мин сүз бирдем, — диде карт, аңлатып. — Алладан теләгез, аягыма бассам, икегезгә дә ирек бирермен, дидем.

— Шулай диде, без теләдек. Көн-төн теләдек, — диде Фу-фу.

— Ярар, алай булса, — диде Батима, килешеп. — Бүгенгә җитеп торыр, иртәгә сөйләшербез.

— Минем бүген йөрисем килә, тышка чыгасым, җиргә

басасым килә, — диде карт, үзсүзләнеп, тышка чыга торган ишеккә юнәлеп.

Ләкин Батима шундук аның юлына аркылы төште.

— Иртәгә кояшны каршы алырга чыгарсың. Барысы өчен дә зурлап корбан бирербез, — диде ул.

Карт үзендә кинәт ниндидер хәлсезлек тойды, аның куллары калтырый башлады. Аягын әлегә ул ныклап тоймады, ул бары үзенең каты, нык идәнгә баса алуын гына, атлап йөри алуын гына белде.

— Ярар алайса, — диде ул, килешеп.

Мирзый бичәсе Галимә, тәнгә матур-җыйнак булса да, төскә-биткә әллә ни искитәрлек түгел иде. Дөрес, аны алай ямьсез дип тә булмый. Озынча баш, дугаланып торган тигез кара кашлар, кечерәк маңгай, озынча юка борын, кысыграк иреннәр. Вак тешләре дә матур гына. Бит очлары һәрвакыт алсуланып тора. Болай карaганда, килмәгән бер җире дә юк кебек. Тик шулай да анда нәрсәдер килеп тә җитмәгән кебек. Тавышы коры, күз карашы коры. Аннары ул бераз гына йомыкыйрак та, астыртынрак та бугай әле. Менә шуларның барысы да аны ничектер ят итеп, чит һәм сөйкемсез итеп күрсәтә иде бугай.

Җәбирләр өенә килен булып төшкәч, Мирзыйның үзеннән башка аны беркем дә яратмады, ахрысы. Биатасы башта ук аларның нәселен өнәп бетермәде. Батима үзенең кодагые белән килешә алмады. Әкълимә өчен барыбер кебек иде, шулай да ул өйдәгеләргә кушылып җиңгәсенә сырты беләнрәк торды. Җәбирнең шулай ук җиңгәсенә әллә ни исе китмәде. Ни өчен дигәндә, аның Талиясе бар иде. Ул инде аулагөйдә Талия белән берничә мәртәбә очрашкан, күрешкән һәм алар бер-берсен яратышып, аңлашып өлгергәннәр иде. Талия, икәүдән-икәү генә калгач, аның алдында ант итеп кияүгә бары аңа гына — Җәбиргә генә чыгарга уйлавын әйтте. Лелегләр йоласы буенча өйләнешү өчен алай үзара ант бирешү генә җитми, билгеле. Моның өчен әле ата-ананың килешүе дә, калым түләү дә, бирнә бирү дә һәм башка йолаларны башкару да кирәк. Шулай да алар инде өйләнешкән кешеләр кебек — күңелләре, рухлары, омтылышлары белән күптән бер гаилә кебек бергә иделәр.

Талияне им өенә озатып куйгач та Җәбир аннан ничектер көтмәгәндә аерылган сыман итеп тойды. Билгеле, күңелен аның көнчеллек корты да кимерде. Ул үзенең сеңлесе өчен борчылудан бигрәк Талия өчен борчылды.

Чын лелег егете көнләшмәскә һәм им өендә кунарга тиешле якын кызын уйлап кайгырмаска тиешлеген ул бик яхшы аңлады. Ләкин, аңласа да, барыбер үзенең яшерен хисләрен йөгәнли алмады. Күңеленең менә шундый иләс-миләс, борчулы, буталчыклы чагында ул җиңгәсен читтән, ерактан күрде. Хәер, Талиясеннән аерылгач, янган йөрәген басу өчен ул үзе, кәҗә тәкәсе кебек, койма тирәсендә ешынып йөрде. Беренче мәртәбә су керүче хатын-кыз күргән малай кебек, койма аша каранып, күзен тондырып йөрде. Бит чынлыкта ул бурларча койма аша каранып йөрергә дә тиеш түгел. Җиңгәсен күрәсе килсә, ул абыйсы юк чакны гына карап, көтеп торырга да туп-туры капкадан, ишектән барып керергә дә тиеш иде. Йола буенча, бертуган абыйсының бичәсе аның да бичәсе була ала. Әгәр Мирзый башка чыкмаса, ул шулай булыр да иде, һәм монда инде аңа беркем бер сүз әйтә алмас иде. Хәер, аңа хәзер дә беркем бер сүз әйтә алмый. Сүз әйтүен әйтми, шулай да менә нидер тоткарлый.

Җәйге җылы вакытларда Җәбир бакчада кунарга ярата иде. Әле җәй уртасы килеп җитмәсә дә, көн коры һәм җылы иде. Бүген ул тышта кунарга уйлады. Карт алмагач төбенә чыгып яткач, Җәбир бик озак йокыга китә алмый ятты. Аның әллә ни йоклыйсы да килмәде. Төне буена уйланып, хыялланып чыгарга да әзер иде. Түшәген туп-туры чүлмәк өстенә җәйде. Күбрәк ул кесәсендәге яшел ташлы, алтын чылбырлы алтын тамга турында уйлады. Нишләтергә аны? Бик зур байлыкмы бу? Ул үзенең ниләр алачагын, ниләр эшләячәген уйлап хыялланды. Шул чакны аны авыр газаптан коткарырга теләгән сыман, күз алдына кер ууучы җиңги килеп басты. Җиңги турында уйлау алтын тулы чүлмәк турында уйлау кебек үк татлы һәм мавыктыргыч иде. Озакламый җиңги турындагы уйлар да арыта башлады, күз кабаклары авырайды, аяк-куллар онытылды, бөтен тирә-якта, бөтен дөньяда тере, тынгысыз бер уй гына торып калды.

Ул инде онытылып та китә язган иде. Шул чакны кайдадыр якында ташка таш тиеп шакылдаган тавыш ишетелеп китте. Әллә корыган ботак сындымы соң? Югарыдан берәрсе егылып төштеме югыйсә? Җәбир күзләрен ачты һәм бакчага чыгып ятканнан соң беренче мәртәбә күзен ачып күккә карады, тирә-якка колак салып тыңларга тотынды. Төн булса да, күк төбе ничектер аермачык булып, хәтта якты булып күренә иде, исәпсез-хисапсыз алтын комнары җемелдәшә, һава саф һәм сал-

кынча. Якындагы каралты, куаклар, агачлар бөтенесе бертөсле булып, тигез яссылыкка төшерелгән сурәт кебек булып, кара булып күренә иде.

Күршеләр белән ике арадагы таш койма ягында тагын баягыча шакылдаган тавыш ишетелеп китте. Ләкин бу юлы ташка таш түгел, бәлки ташка агач тигән сыман булды. Җәбир, күзләрен зур ачып, башын калкыта төште һәм шул чакны койма өстенә ниндидер карачкы килеп менгәне күренде. Койманың өстенә үк менеп җиткәч, ул аска иелеп нәрсәдер тартып алды һәм тартып алган нәрсәсен иплэп кенә, капшанып кына бу якка төшерде. Ул, билгеле, баскыч иде. Караңгыда, куаклар арасында аермачык күренмәсә дә, Җәбир аны шундук шәйләп алды. Аннары ул шуны да белде: караңгыда койма аша керүче бу карачкы, әлбәттә, җиңги кеше иде.

Йөрәге еш-еш типкән хәлдә, тынып-сагаеп ул көтә башлады. Менә карачкы, бернинди тавыш-тын чыгармыйча, таш сукмактан алмагачка таба килә башлады. Җәбир күзләрен ярым йомык калдырып, йоклаганга сабышып, җиргә береккән кебек ятуында булды. Ул арада карачкы якынрак килде, күз алдын каплап, капкара булып, аның түшәге янына иелде, чүгәләде һәм кулын сузып аның битенә кагылды. Биткә кагылган кул аңа бик салкын булып тоелды. Җәбир үзе дә сизмәстән «а!» дип кычкырып җибәрде.

— Курыкма, бу мин... җиңгәң, — диде карачкы, пышылдап, учы белән аның авызын томалап. Яшүсмернең иреннәре аның учының тиресенә тиде, ләкин ул аның учының чын кешенекеме-түгелме икәнен аңлый алмады — ул шундый салкын иде.

— Син... өрәкме? — диде ул, бөтен тәне белән калтыранып.

— Өрәк түгел, — диде карачкы. — Мин синең җиңгәң... Галимә. Курыкма шулкадәр.

— Өрәк булмагач, ник кулың салкын? — диде Җәбир, теше тешкә тиеп.

Карачкы эндәшмичәрәк торды да:

— Курыксаң, әйдә безгә, — диде. — Абыең кизүдә. Мин дә куркам ялгыз өйдә берүзем.

«Әйе шул, өрәк булса, курыкмас иде» дип уйлады Җәбир. Өйдә аны тикшереп карарга була. Өрәк булса, ул шундук юкка чыгачак.

Шундый фикергә килгәч, ул калтыравыннан туктагандай булды.

— Әйдә, алдан бар, — диде ул карачкыга.

Беренче этәчләр кычкырганда, ул яңадан үзенең алмагач төбендәге урынына чыгып ятты. Күпмедер вакыттан соң ул якында гына ниндидер таныш тавышлар ишетеп уянып китте. Күзләрен ачыбрак караган иде, йомшак кына булып балкып торган иртәнге көн яктысында әнисен һәм әнисе янында сукмакта басып торган этисен күреп шаккатты.

— Әтиең аягына басты, улым, — диде әнисе, елмаеп.

— Менә, үз аягым белән килдем, — диде этисе һәм, үзенең чыннан да таза-сау икәнен күрсәтергә теләгән сыман, җиргә тибеп-тибеп алды.

Җәбир теләсә нинди кешенең үз аягы белән йөрергә тиешлеген бик яхшы белсә дә, шулай да ике-өч айдан артык инде урында яткан этисенең ятакка береккән кебек ятып йә утырып торуына күнегә башлаган иде. Хәзер исә аның чын-чынлап үз аягында басып торуы аңа чиктән тыш гаҗәеп хәл булып тоелды.

Ул сикереп урыныннан торды, этисе янына килде һәм, ышанып җитмәгән сыман, этисенең аякларын карарга тотынды.

— Чын, улым, чын, — диде этисе, көлемсерәп. — Әниең әйткән сөенечтән бастым аягыма. Син чүлмәк тапкансың икән. Каяле, күрсәт әле.

— Хәзер, эти, — диде Җәбир.

Тиз-тиз генә ул урын-җирен җыеп алды. Ястыгын, мендәрен, астагы камыш чыптаны, ябынчыкларын — бөтенесен бер төргәккә төреп, читкәрәк алып куйды һәм йөгереп кенә тимер көрәк алып килде. Кичәгенәк казып йомшартылган җир өсте ятак астында басылган һәм тыгызланган иде. Йомшак җир өстендә хәтта чыпта эзләре дә беленеп калган. Җәбир бер-ике көрәк балчык алып ташлады да алтынлы чүлмәккә капланган тупас чүлмәк төбен ачты, капкач чүлмәкне алды. Әтисе дә, әнисе дә якынрак килделәр. Чүлмәк эчендә кичәгечә алтын-көмешләр балкып-елмаеп ята иде. Әтисенең йөзе шундук яктырып китте. Әнисе инде, бер мәртәбә күргәч, ахрысы, бу юлы әллә ни сөенеч белдермәде.

— Күрдем, күңелем булды. Ябып куй, улым, — диде этисе, күтәренкелек белән. Аннан соң улына ягымлы караш ташлады да мактап әйтеп куйды: — Синең бәхетең бу, улым, — диде. — Син таптың. Болай булгач, баедык без. Моннан соң инде менә дигән иттереп яшәрбез, алла боерса.

Ул шулай диде дә тиз-тиз атлап өйгә таба китеп барды. Аның артыннан Батима карчык атлады. Төреп ку-

елган урын-җирен алып, Җәбир дә алар артыннан ияр-де. Ләкин, чүлмәкнең туфрак белән күмелми калуын исенә төшереп, ул тиз генә алмагач янына килде, көрәк белән чүлмәкне күмде дә тирә-яктагы балчыкны тигезләп куйды.

Җәбир урын-җирен күтәреп өйгә, үзенең ишек төбен-дәге бүлмәсенә керде. Иртүк торып, казанга су салып, казан астына ягып җибәргәннәр иде. Күршедә, юыну бүлмәсендә, идәне, кырыйлары су үткәрми торган шома ташлар белән ныгытылган дүрткел чокыр бар иде. Из-геләр калкулыгыннан балчык көпшәләр буенча агып килә торган су ике төрле: берсе салкын, берсе җылы. Җылы су чишмәдән кайнар килеш чыга, ләкин монда килеп җиткәнче суына һәм җылымса гына булып кала. Шуңа күрә мунчада юынганда өстәмә су кайнатып са-лырга туры килә.

Батима карчык Җәбирнең урын-җир күтәреп керүен күрде дә улын казан янына чакырды.

— Әйдәле, икәүләп күтәреп алыйк, — диде ул, учак өстендәге кайнар сулы җиз казанга күрсәтеп.

Алар, казан кылдавы аша үткәрелгән агачның ике ягыннан тотып, авыр, кайнар казанны учак өстеннән алдылар да юыну бүлмәсенә алып килделәр һәм чокыр-дагы суга каплaдылар.

— Әтиеңнең аркасын ышкырсың, — диде әнисе Җәбиргә.

— Ышкырмын, — диде Җәбир.

Моңарчы ул мондый эшләр белән булашмый иде. Су кайнату, су таманлау, арка ышку, юындыру — барысы да Фу-фу белән Суси эше иде. Ул әтисенә булышуга кар-шы килмәде, шулай да өйдә колларның күренмәве аңа гаҗәбрәк тоелды.

— Тегеләр кая соң, күренмиләр? — диде ул.

— Мин аларга ирек бирдем! — диде кәмәче карт, күтәренкелек белән. — Кичәдән бирле алар — ирекле.

— Чыгып киттеләрмени? — диде Җәбир

— Үзем куалап чыгардым, — диде Батима.

— Өйдә үзебез генә, улым, курыкмыйча сөйләшергә була, — диде әтисе.

Җәбирнең әтисе буйга артык зур түгел, ләкин күк-рәккә киң, беләккә нык иде. Тик менә урын өстендә озак ятканга, ахрысы, тиресе йомшый төшкән, ит уры-нына май җыела башлаган иде. Алар юынып чыгуга әнисе ашарга әзерләгән: табынга борчак боткасы, кай-мак һәм йөзем суы куелган иде. Кәмәче йөзем суы эчәргә

ярата иде. Иң элек ул бор салынган чүлмәккә үрелде һәм көмеш касәләрне тутырып эчемлек салды. Ләкин эчәргә ашыкмады, кулына касәсен алу белән артына борылды да учакка берничә тамчы бор сипте.

— Әбети, сиңа, — диде.

Башкалар да эчәр алдыннан берничә тамчы эчемлекне иң элек Ут анага — Әбетигә бирделәр һәм бары шуннан соң гына касәләрне авызларына якын китерделәр.

— Нинди күңелле сезнең белән бергә табында, җылыда рәхәтләнеп утыру! — диде кәмәче, балаларча куаныч белән.

— Почмагыбыз түгәрәкләнде, — диде Җәбир дә, олылар сымак акыллы булып.

— Түгәрәкләнмәде әле, — диде әнисе. — Кызыбыз юк. Аны барып алып кайтасы бар.

— Әтине күрсә шакката инде ул! — дип куйды Җәбир. Бор суы эчкәч, аның гел сөйләнәсе килә башлады.

— Шаккатарлык нәрсәләр күп булды, улым, — диде этисе. — Мин әле һаман да ушымны җыя алмыйм. Нәрсә булганын аңлап та җитә алмам кебек.

— Ашагач та мин базарга китәм. Сез өйдән чыгып йөрмәгез, — диде әни кеше, боерган сыман итеп.

Түрә буенча, йола буенча, лелег хатыннары гаиләдә ирләр белән бертигез хокукта иде. Ләкин кайбер нәрсәләрдә алар хәтта ирләрдән дә өстенрәкләр. Моңарчы да күп нәрсәне үзе хәл итәргә өйрәнгәнгә, Җәбирләр өендә әнисе гомумән барысыннан да өстенрәк, акыллырак санала һәм аның сүзе һичшиксез үтәлергә тиеш.

— Кая, чыгыйк инде без өйдән, — дип куйды карты, бичәсе белән килешүен белдереп.

— Әллә мин дә синең белән барыйм микән соң, әни? — диде Җәбир. — Үзеңә генә кыен булыр ич.

— Булмас. Өйгә чит кеше-ни кермәсен, капканы бикләп кенә утырыгыз, — диде әнисе.

Шулай сөйләнеп утырганда, бөтенләй көтмәгәндә тышкы ишек шыгырдаганы ишетелде һәм, күп тә үтмәде, ниндидер хатын-кыз тамак кырды һәм, сузып:

— Өйдәләрмесез? Керергә ярыймы? — диде.

Өчесе дә ашауларыннан туктап тынып калдылар һәм ишек ягына борылып карадылар. Карасалар, ишектә ничектер бик сәер елмаеп киленнәре Галимә басып тора. Галимәне күрү белән, барысы да тынсыз-өнсез калдылар. Җәбир, авызын күптереп, йодрыкларын йомарлап, күзен түбән төшерде. Батима карчык, тамагына азык утырган сыман, чәчәп җибәрде, тамагын кыргалый баш-

лады. Бары тик беркатлы диңгезче эти кеше генә чын күңелдән сөенеп елмаеп җибәрде һәм, утырган урыныннан кузгалып:

— Килен кергән ләбаса! Әйдә, түрдән уз, нәрсә сорап торасың? — диде.

— Әйдә, әйдә, түрдән уз, — дигән булды әни кеше дә, тыелып кына.

Галимә керде һәм ашаучылар арасында табын янында чын таза-сау килеш аякларын сузып җибәреп, яшьләрчә шат күңел белән ашап утырган биатасын күреп катты да калды. Нәрсә бу — кинәт аягына басканмы, әллә моңарчы юри авыруга сабышып ятканмы?

— Бәрәч! Биатай да терелгән ләбаса! — диде ул, беренче сүзе итеп.

— Бастым, килен, бастым, — диде кәмәче карт. — Куанычлы сүз ишетеп үзем дә сизми калдым.

Шул чакны Батиманың йөзе үзгәреп китте. Ачу белән ул картына бер усал күз карашы ташлады да:

— Бөтенләй үк йөрерлек түгел, шулай да менә торды әле, — диде. — Ас анага багышлап корбан биргән идек, шул килеште бугай.

— Килеште, килен, килеште, — диде карт, Батиманың ишарәсен аңлап.

— Мирзый сөенер инде, эти дә эти дип бик кайгыра иде, — дигән булды килен.

— Кеше-карага сөйләнмәгез әлегә, — диде Батима карчык, кырыс кына.

— Нишләп сөйләник? Бездән сүз чыкмас, — диде килен. — Сөйләсәң дә ни гаебе бар аның?

— Гаебе юк та, йөри башласын әле ныгытып, әллә күз тияр, — диде биана, аңлатып.

— Күз тияргә сабый бала түгел лә эткәй, — диде килен, көлеп.

Ул шулай түргә дә узмыйча, йомышын да әйтмичә ишек төбендә басып торды да торды. Аның сүзенә һәм тиз генә чыгып китмәвенә карап, аның болай гына, юри генә кергәнлеге сизелде.

Биана түзмәде, беренче булып үзе сорады:

— Йомышың бар идеме әллә? — диде.

— Ни... ы-ы... Кәтмәнегезне биреп тормассыз микән дигән идем, — диде килен, көттереп. — Үзебезнекенең сабы сынган. Мирзыйга ничә әйттем, һич вакыты юк.

— Үзеңә кирәкмиме? — диде әнисе, Җәбиргә эндәшеп.

— Безнең икәү. Берсен алсын, — диде Җәбир.

— Бар, үзең карап бир! — диде әнисе, ачу белән.

Җәбир ашаган җиреннән торып ишеккә юнәлде. Галимә дә аның артыннан кузгалды. Эш кораллары сөялгән җиргә килеп җиткәч, ул кәтмәннең берсен алды да борылып җиңгәсенә бирде. Кәтмәнне биргәндә ул ничек тә аның күзенә карамаска тырышты. Галимә исә бер дә юктан көлеп куйган булды һәм, ачу китергеч итеп үртәп, кызыктырып, матур ян-якларын уйнатып, алдан китеп барды.

Җиңгәсен Җәбир капкага кадәр озатып куйды. Ул аны капкадан кергәндер дип уйлаган иде. Ләкин капка эчтән бикле булып чыкты. Менә сиңа кирәк булса! Тагын койма аша кергән! Аның җиңгәсенә берәр усал сүз әйтәсе килде, ләкин ул берни дә әйтә алмады. Аның караңгы чыраен күреп, Галимә Җәбирнең күзләренә тутырып карады да бик ягымлы итеп елмайды һәм, ярым пышылдап:

— Иртәгә үзең кер, — диде.

Җәбир эндәшмәде. Ул яңадан ашавын дәвам итмәкче булып өйгә керде, табын янына килеп утырды. Әнисенең дә, әтисенең дә йөзләре бик сүрәнләнеп калган иде.

— Капканы бикләп куйган кебек идем, ачык калганмыни? — диде әнисе, Җәбиргә карап.

— Ачык калган, — диде Җәбир, теләр-теләмәс кенә.

— Син төнлә... яткан урыныңнан торып беркая да бармадыңмы? — диде бераздан әнисе, төпченеп.

Ул, күрәсең, нәрсәдер сизенгән иде. Ләкин Җәбир бер ялганлагач, икенче мәртәбә дә ялганламый булдыра алмады.

— Беркая бармадым, — диде ул.

Ләкин аның җавабы әнисен канәгатьләндермәде. Ул инде улының күз карашыннан ук барысын да сизенеп алган иде. Ашап туйгач ул базарга барырга җыена башлады һәм, ирләргә боерып:

— Капканы минем арттан бикләп калыгыз. Сорамыйча беркемне кертмәгез, — диде.

Җәбир әнисен капкага кадәр озатты да артыннан капканы терәтеп куйды һәм йөгереп этисе янына керде. Аңа монда ниндидер эшләнәсе эше бар сыман тоелган иде, ләкин, өйгә кергәч, эшләнәсе эше бакчада булырга тиешлеге аңлашылды. Ул, этисенә берни әйтмичә, бакчага чыгып китмәкче булды.

— Туктале, улым, сөйләшик, — диде этисе.

Җәбир туктап калды. Әтисенең тавышы буенча, кыяфәте буенча ул ике арада бик тә җитди сүз буласын аңлап алды: җитди сүз, әлбәттә, чүлмәк турында булачак иде.

— Улым, әниең югында икәү генә сөйләшик әле бер, — диде ата кеше. — Синең үз кайгың, минем үз кайгым дигәндәй. Безнең ныклап торып сөйләшкәнебез дә юк. Мин менә аякка бастым, мине изгелегеннән ташламаган изге ияләргә көч бирсен алла. Сөенечтән мин сабый бала кебек үзгәрдем. Ләкин сабый бала кебек булганга кадәр мин инде өлкән яшькә җиткән кеше идем. Минем бөтен гомерем диңгездә, кәмәдә, кеше арасында үтте. Кеше арасында булгач, барысын да татырга туры килде. Син юлыккан алтын мине аякка бастырды. Ләкин ул минем башыма авыр кайгы да салды.

— Нинди кайгы, эти? — диде Җәбир, түземсезлек белән.

Ул этисенең алтынга каршы, табылган чүлмәккә каршы алдан ук үзендә кирелек, каршылык калка барганын да тойды.

— Алтынны кем дә ярата, — диде этисе, ашыкмыйча, сүзләрен уйлап кына, җайлап кына. — Алтын сиңа да кирәк, миңа да кирәк. Алтының булса, башың югары була, өең иркен, табының мул була. Алтыны күп кеше җаны теләгәнне эшли ала. Бигрәк тә яшь чакта. Мин менә авырып урында ятканда күп нәрсә турында уйладым. Чынлыкта ник кирәк кешегә алтын? Аны ашап булмый, эчеп булмый, аннан яхшы корал да ясап булмый.

Җәбир этисенең шундыйрак сүзләрен элек тә ишеткәләгән иде. Хәзер ул мыскыл белән көлеп җибәрмичә булдыра алмады.

— Әле генә үзең әйттең ич: алтының булса, башың югары була, өең иркен, табының мул була, дидең, — диде ул, этисенең ялгышын тотып алып.

— Ашыкма, тыңлап тор, — диде этисе. — Мин сиңа ике төрле нәрсә турында сөйлим. Алтынга ике төрле караш турында. Бүген, хәзер безнең Аклантитада шулай: бөтен нәрсәнең тоткасы — алтын! Алтынга теләсә нәрсәне сатып алып була. Теләсә нәрсәне! Тик саулыкны гына, тормышны гына сатып алып булмый. Анысы алла кулында. Менә нәрсәне әйтәм мин сиңа. Җанны безгә — Изге атабыз, тормышны Изге анабыз бирә. Алтынны олуг атабыз Күк биргән. Безнең тормышны ямьләр өчен, матурлар өчен биргән. Үзләрен алла улы дип исәпләүчеләр алтынны күбрәк алып калганнар да, синең кебек, минем кебекләрне үзләренә буйсындырып тоту өчен, аны аллага тиң нәрсәгә әйләндергәннәр. Менә нәрсә турында әйтмәкче булам мин сиңа!

— Беләм мин бу турыда, эти, — диде Җәбир, дәртсез генә, тыңларга теләмичәрәк.

Ата кеше кәефе кырылгандай тынып калды. Ул тиз генә сүзне ничек ялгап алып китәргә белмәгәндәй уңайсызланып торды да:

— Белсәң, бик яхшы, — диде ул аннары, бераз килешүчән тонда.

— Беләм шул! — диде Җәбир, тавышын күтәреп, әтәчләнеп. — Алтынны ашарга да, эчәргә дә ярамый дип, бакчада яткан алтыннан баш тартырга киңәш итәсеңме әллә?

— Менә белмәдең! — диде этисе, ачуланмаска тырышып. — Алтын ул, улым, белеп, саклап тотканда гына байлык. Алтын күреп әз генә акылыңны җуйдыңмы, ул шундук синең башыңа җитә. Менә нәрсә әйтмәкче булам мин сиңа!

— Артыгын түләмәскә, теләсә кемгә бирмәскә дисеңмени, эти? — диде Җәбир, җиңелчә елмаеп.

— Алай түгел, — диде этисе. — Алай түгел. Синең кебек яшь чакта күп байлыкка юлыккач, бик тиз баш әйләнә, борын югары күтәрелә, уяулык югала. Кешедә комсызлык, кансызлык, явызлык баш күтәрә башлый. Менә шулардан сакланырга кирәк, димәкче булам мин сиңа, улым.

— Киңәшеңне истә тотармын, эти, — диде Җәбир, теләр-теләмәс кенә. — Шулай да син мине чүлмәк эчендәге алтын әйберләргә карап сокланып кына утырырга күндермәкче буласың түгел микән?

— Юк, алай түгел, — диде этисе. — Мин сиңа бары кайбер киңәшләр генә бирмәкче булам.

— Аңладым мин сине, эти, — диде Җәбир, түземсезлек белән. — Миннән башка киңәшмичә берни дә эшләмә, димәкче буласың син.

— Шулай дисәң дә ярый, — диде этисе, уйланып. — Күрше-күлән тирәсендә безгә әлегә бай булып күренергә ярамый.

— Анысын гына мин дә беләм! — диде Җәбир.

— «Беләм» дә «беләм»! — диде этисе, үртәлеп. — Тыңлап бетер әйткәнне!

— Нишләргә соң, әйтеп кара, — диде Җәбир, караңгы чырай белән.

Ул нәкъ менә этисенең ниндидер киңәшеннән курка да иде. Бит ул юкка гына шулай читләтеп, уратып ерактан сүз башламагандыр?!

— Үзебезнең бакчада алтын тулы чүлмәк тапканны белсәләр...

— Беләм! — диде Җәбир, үзсүзлеләнеп, этисенең сүзен бүлдереп.

Улының бу кадәр кирелеген күреп, картның йөзе бозылды, мыек чылгыйлары дерелдәп-калтырап куйды, шулай да ул улына кычкырудан үз-үзен тыеп калды. Мәсьәлә үтә җитди, үтә четерекле иде.

— Белсәң беләсеңдер. Шулай да мин үз сүземне әйтеп бетерим инде, калганын үзең карарсың, башсыз малай түгелсең.

Әтисенең соңгы сүзләре Җәбирнең күңеленә хуш килде һәм аның йөзендәге кирелек кул белән алгандай юкка чыкты.

— Мин хәзер аякка бастым. Мин яңадан диңгезгә чыга алам, — диде этисе. — Галләмгә яисә берәрсенә кәмәче булып яллаңам да чит илгә китәм. Кәмиткәме, каралар иленәме. Минем йөрмәгән җирем, күрмәгән илем юк. Көньякка да, төньякка да барырга була. Үзем белән сине дә алам. Менә шул — чит илдән баеп кайтабыз.

— Чит илдән алып кайткан алтында беркемнең эше юк — күршеләрнең дә, мака сарның да! — диде Җәбир, елмаеп, этисенең фикерен дәвам итеп.

— Шулай! — диде этисе. — Башта бурычка бераз товар, акча алып торган буласың. Миңа ышанып товар бирерлек кешеләр булырга тиеш. Бер-ике мәртәбә барып кайтсак, аннары үзебезгә кәмә сатып алырбыз.

— Монысы — киләчәктә. Хәзер нишләргә соң? — диде Җәбир, этисе белән килешүен белдереп.

— Хәзер болай итик, улым, — диде ата кеше. — Син, берни булмаган кебек, бакчаны кәтмәнлә. Безгә аны барыбер казырга, әйбер утыртырга туры килә. Мин менә шушы бүлмәдә, идән ташларын куптарып, баз казып куярмын әниең кайтуга.

— Чүлмәкне шунда күчерербезме? — диде Җәбир.

— Шунда, — диде этисе.

«Түкми-чәчми шунда кертеп куярлар, тагын саклар-лар инде гомер буе болай булгач», — дип уйлады яшь егет, күңелсезләнеп.

— Сез миңа бөтенләй берни дә бирмәссез микәнни, эти? — диде ул, төшенке генә.

— Борчылма, алырсың, — диде этисе, ягымлы итеп.

Җәбир, сөйләшер сүзне беткәнгә санап, бакчага чыкты, кәтмәнен алып килде дә, уйлана-уйлана, арык тирәсен казый башлады.

Яшел ташлы алтын тамганы нишләтергә соң? Кире

чүлмәккә салып куяргамы? Юк, әлегә аны ачарга ярамый. Әтигә кертеп бирсәң, ул әллә кире бирә, әллә юк.

Ул шулай уйлады-уйлады да яшел ташлы тамганы үзендә калдырырга дигән карарга килде. Шулкадәр зур байлыкка тап булып, шул кечкенә таш, алтын кисәген үзендә алып калырга хакы бардыр ич аның?! Юк, аны барыбер әти-әнигә күрсәтмичә йөртеп булмаячак. Аларга әйтергә кирәк.

Иң ахырда ул шундый фикергә килде һәм, эшен ташлап, әтисе янына кереп китте. Ләкин ишек тоткасына тотындым дигәндә генә аның күңеленә икенче бер уй килде: нишләп сорамыйча, каракларча алган дип әйтсә әтисе? Хәзергә калсын үземдә генә, диде ул, ниһаять, нык-лы бер карарга килеп, һәм, тынычланып, яңадан кәтмәнләү эшенә тотынды.

Кичкә таба кара кәҗә җитәкләп базардан әнисе кайтып керде. Әнисе белән сеңлесе дә кайткан иде. Җәбир аларга үзе капка ачты һәм кара кәҗәне җитәкләп үзе абзарга илтеп япты. Сеңлесенең үзен генә туры китереп, аңа беренче соравын бирде:

— Талия дә кайттымы? — диде.

— Талия мака сар сараенда хәзер, — диде сеңлесе, күңелсез елмаеп.

Мондый көтелмәгән яңалык ишетеп, Җәбирнең аяк буыннары хәлсезләнеп калды. Талия... сарайда! Талия юк. Талия аңа язмаган. Менә ул иң зур кайгы дөньяда!

## III

Яз быел да соңгармыйча вакытында килде. Көннәр озая, төннәр кыскара башлады. Кышкы яңгырлар, җилдавыллар тынып калды. Диңгез тынычланды һәм күктә болытлар бөтенләй күренмәс булды. Ягымлы кояш, игелекле, бәрәкәтле кояш, иртәдән башлап кичкә кадәр бәхетле лелегләр илен — мака сар яшәгән Изгеләр утравын — җылы, шифалы нурларына коендырды.

Ел тәүлеге алышынып, көннәр җәйгә авышкач та, җирдә-суда, күктә бөтенесе: җанлы-җансыз хәрәкәткә килде. Былтыр көздән яфракларын коеп куйган агачлар, куаклар, үләннәр яңа бөре җибәрделәр. Яфракларын коймаган мәңге яшел агачлар тагын да яшәреп, матурланып калгандай булдылар. Тау буйларында, үзәннәрдә куаклар чәчәккә күмелде. Бакчаларда, юл буйларында ал, сары, ак, көрән төстәге купшы чәчәкләр күренә башлады. Камышлы күлләрдә, елга буйларында бала

чыгарырга җыенган аккошларның, кыр казларының һәм торналарның, меңләгән, ун меңләгән башка кошларның моңлы чыр-чуы, гүелдеге яңгырап торды. Төннәрен ерак таулар-кыялар ягында, бөтен тирә-якны дер селкетеп, арысланнар үкергән, аюлар кычкырган һәм бүреләр улаган тавышлар ишетелеп торды. Иртәнге якта кеше аягы басмаган куе урманнардан, балаларын ияртеп, бүрәнәдәй юан аяклары белән салмак атлап, кыргый филләр килеп чыкты. Алар, бер-бер артлы тезелеп, тау елгалары ярына су эчәргә килделәр.

Җир уяну белән, агачлар, куаклар, җәнлекләр, бөҗәкләр генә түгел, кешеләр дә яңадан җанланып киткәндәй булдылар. Урамнарда, йорт тирәләрендә балалар, үсмерләр тавышы ешрак ишетелә башлады, капка төпләрендә кояшта җылынып утыручы хәлсез картлар, корткалар күбәйде. Болыннарда, елга буйларында көяз кызлар, егетләр күренде. Игенчеләр кырга чыгарга әзерләнә башладылар.

Ләкин, быелгы яз башка язлардан әллә ни аерылмаса да һәм табигатьтәге бөтен җанлы-җансыз тиешенчә хәрәкәткә килсә дә, игенче язны теләр-теләмәс борчу һәм кайгы белән каршылады. Күпчелек игенче өчен иң зур кайгы шул булды: чәчәргә орлык юк иде. Былтыр көздән мака сар боерыгы белән бөтен биләмәләрдә игенчедән барлык бөртекле ашлыкны җыеп, очсыз бәягә сатып алдылар да, чокырларга, чүлмәкләргә тутырып, авызын томалап, тамгалап куйдылар. Былтыр көз мака сарның ашлыкны ни өчен шулай амбарларга җыйдыруын күп кеше бик үк аңлап та җитмәделәр. Кайберәүләр әйтте: илгә корылык килә икән, җәрингә иген уңмаса, халыкны ачтан саклап калу өчен җыялар икән, диде. Икенче берәүләр әйтте: ачлык бездә булмый ул, ачлык башка илләрдә була. Ашлыкны аларга сатып, зур табыш алу өчен җыялар, диделәр. Өченчеләре исә башкачарак фикер йөртте: мака сар Карун барлык игенчеләрне эшеннән аерып Кәмине яуларга җибәрмәкче икән, шуңа әзерләнә икән, диделәр.

Көнәсә биләмәсенең башы Карман сакага бу хакта кайберәүләр сорау да биреп карадылар. Былтыр көз андый сораулардан бик җиңел котылды: мака сарның боерыгы шундый, мин берни белмим, диде. Ләкин быел, язга чыгып, кыр эшләре якыная башлагач, әле анда, әле монда игенчеләр чәчүлек орлыгы таптыра башладылар. Кырларыбызны чәчми калдырсак, Җир ана (Ас ана) безгә рәнҗер, таза баштан ач калырбыз — без ач булсак, бөтен ил ачыгыр, диделәр. Кайбер авылларда, калаларда яр-

сыган игенчеләр мака сар амбарларын ватарга тырышып та карадылар. Тавыш, ризасызлык көчәйде һәм игенчеләр былтыргы орлыкны йә бурычка бирергә, йә сатып бирергә таләп итә башладылар. Көнәсәдә генә түгел, башка биләмәләрдә дә хәлләр шундыйрак иде. Чәчүгә чыгу вакыты көннән-көн якынлашты, әмма Саркелдән, мака сардан амбарлардагы орлык хакында бернинди яңа боерык килмәде.

Карман сака барлык эшләрен бер читкә куйды да бүген менә җыенып мака сар каласына үзе китте. Нәрсә уйлый икән агасы Карун? Әллә быел игенчегә ашлык чәчмәскә дә ярый микән? Әллә монда яз килгәнен сизмичә-күрмичә калганнармы?

Үз каласыннан Карман сака бүген таң атканда кузгалып китте. Иртәнге якта диңгез тыныч иде, көндез дә тыныч һәм җилсез булачагы сизелеп тора. Шулай да, көн яктыргач, көчсез генә җил чыкты, каршы яктан исеп, җилкән киндерләрен каерды. Су өсте чайкала, дулкынлана башлады. Җилкәннәрне төшерергә туры килде. Яшь, таза ишкәкчеләр бар көчләренә иштеләр. Алар болай шактый тиз килделәр һәм, бернинди хәвеф-хәтәргә юлыкмыйча, төштән соң Аклантита утравына якынлаштылар.

Утрауның очлы таулары караеп су өстеннән калкып чыккач та, кәмәче кәмәне бара торган юлына — уңга, очлы таулар ягына турылады, чөнки алар сулга — көнбатышка таба баралар иде. Очлы таулар бик озак күренеп, маяк булып торды һәм барган саен зурайганнан-зурая, якынайганнан-якыная бардылар. Бер-ике сәгатьтән, ниһаять, утраудагы алтын, җиз, бакыр корылмаларга бәрелеп, утлы очкыннар булып кичке кояш нурлары чагыла башлады. Чын кояш кәмәдәгеләргә сул якта — көнбатышта иде. Чын кояш, зурайганнан-зурая барып, кызарганнан-кызара барып һәм күкне, диңгезне куе кызылсары нурларга күмеп, җир астына төнге йокыга төшеп бара. Шул ук вакытта көнчыгыштагы утрауда әйтерсең аның игезәге булып алтынга күмелгән мака сар Карун Саркеле балкып тора. Искиткеч күренеш иде бу.

Утрауга якынлаша барган саен, бу гаҗәеп күренеш көчәя, байый гына барды. Күренешләр төрләнде, төсләр үзгәрә барды. Өч ягында биек таулар калкып утырган утрауның көньягында, диңгез буенда, киң, иркен тигезлек җәелеп ята. Менә шул тигезлеккә — диңгез ярына — бер ун чакрым чамасы эчкәрәк кертеп мака сар каласы салынган иде.

Аклантитага Карман сака һәрвакыт диярлек менә шушы вакытта — кояш баер алдыннан якынлаша һәм, очлы таулар күренү белән, ул үзенең туган якларыннан күзен ала алмыйча, сокланып, хозурланып бара. Еракта гүзәл корылмалар күренү горурлык тойгысын бермә-бер көчәйтә.

Нинди матур, нинди бай һәм искитмәле аның туган каласы! Дөньяда илләр дә, калалар да, ыгытмалы тораклар да күп. Ләкин беркайда, бер җирдә, бер халыкта мондый утрау да, мондый кала да, мондый коймалар да юк. Аркылысы егерме биш чакрым чамасы булган түгәрәк каланы өч кат таш койма әйләндереп алган. Уртада, үзәктә, аркылысы бер чакрым түгәрәкне — Изге калкулыкны — янә биек койма әйләндереп алган. Анда — үзәктә — мака сар. Изге калкулыкны тирә-яктан су боҗрасы уратып тора, су боҗрасыннан соң — җир боҗра, җир боҗрасыннан — тагын су боҗрасы. Үзәкне, Изге калкулыкны аралашып өч су боҗрасы, өч җир боҗрасы саклый. Таш коймалар тышкы яктан бакыр белән, эчке яктан кургаш белән капланган. Изгеләр калкулыгындагы үзәктәге койма тышкы яктан җиз белән, эчке яктан бакыр белән капланган.

Күпме көч, күпме байлык киткән аларны төзүгә! Күпме мака сарлар, күпме галимнәр баш ватканнар үз калаларын барлык калалардан ыграк, матуррак итеп салу өчен! Һәм алар үз теләкләренә ирешкәннәр дә. Чөнки алар яшәешнең беркем белмәгән серенә төшенгәннәр. Алар һәрвакыт җиргә, суга һәм кояшка турылыклы булып калу турында гына уйлаганнар. Абаларга, Изге атабызга, анабызга багышлап вакытында корбан биргәннәр, йолаларны башкарганнар. Шуңа күрә дә аллалар — мака сарлар яклы, лелегләр яклы булганнар. Менә шуңа күрә дә лелегләрне җирдә дә, суда да беркем җиңә алмый. Алай гына да түгел, аларга каршы беркем корал күтәрергә дә батырчылык итми. Мака сарлар, лелегләр — Кояшның иң сөекле уллары. Алардан изге беркем юк дөньяда.

Әйе, бөтен дөнья шулай дип уйлый. Ләкин мака сарның, сакаларның, лелегләрнең ни дәрәҗәдә изгелеген Карман үзе бик яхшы белә. Белә һәм уйлана. Хәер, бу турыда җаны булган һәркем уйлана. Уйлана һәм борчыла. Кайберәүләр каршы сүз әйтмәкче, баш калкытмакчы да булып карыйлар, ләкин күзгә күренмәгән көч — курку, куркытылу бик күпләрне телләрен тешләргә мәҗбүр итә. Иң яманы шул — балык башыннан чери.

Дин онытыла, изге йолалар юкка чыга, бар нәрсәне байлык, алтын һәм бозыклык алыштыра бара.

Биек, озын коймалар белән әйләндереп алынган, ямьяшел бакчаларга күмелеп утырган, күккә ашкан зур бинаалары булган һәм алтын-көмешләре, байлыгы белән балкып утырган шау-шулы калага якынлашкан саен, Карман саканың күңелен шундыйрак борчулы уйлар биләп алды. Ләкин дулкыннар өстеннән сикереп-сикереп тирбәнеп килгән зур кәмә Тамакка якынлашкач та, яр буендагы шакы-шокы тавышлары, кычкыру, сызгыру, җырлау аермачык ишетелә башлагач та, борчулы уйлар үзеннән-үзе юкка чыкты. Аның күңеле бер дә юктан җилкенә башлады. Аның тизрәк менә шул шау-шулы тормышка кушылып китәсе килде. Бу калада, бу ыгы-зыгыда, бу таш йортлар, күперләр, коймалар, капкалар арасында теләсә кемне алдый торган, җилкендерә торган, үз эченә йота торган ниндидер сихри көч — теләсә нинди изге абалардан да көчлерәк көч куып бара сыман иде.

Көнәсә биләмәсендә Карман саканың Тамакка якынлашып килүен яр буендагылар еректан ук күреп алдылар. Каршыга борыны, кырыйлары сарыга, калган өлеше кызылга буялган ике кәмә якынлашты. Карман сака, мака сар кешеләрен каршылау өчен, үз кәмәсенең борын өлешенә, тар сикегә чыгып басты. Карман сака Аклантитаның тугыз сакасы арасында иң яше, иң чибәре иде. Аңа әле нибары утыз бер яшь. Гәүдәгә ул оста сынчы ясаган бакыр сын кебек таза һәм калку буйлы. Башына ят кош каурыйлары кадап ясалган, затлы ташлар белән бизәлгән, алтын кыршаулы калпак кигән. Муенында гәрәбә муенса. Аның озын кара чәчләре, тугыз үремгә үрелеп, аркасына салынып тора. Биленә алтын аеллы кызыл пута бәйләгән. Билдән түбәнге өлешен каплаган киеме буй-буй сары төшкән күк төстәге кыска итәктән гыйбарәт иде.

Аны каршыларга килгән кәмәләрдәге кәмәчеләр мака сарның туганын котлап кулларын күтәрделәр, чак-чак кына башларын иделәр. Карман сака аларга уң кулын күтәреп җавап бирде. Шуннан соң, аны-моны сорашып тормыйча, каршыга килүчеләр кире борылдылар. Кәмәләрнең берсе Карман сака кәмәсе алдына төште. Андагы койрыкчы сака кәмәсендәгеләргә аркан ташлады. Арканны борындагы ыргакка беркетеп куйдылар. Каршылаучы кәмәчеләрнең икенчесе шулай ук беренчесенең алдына чыкты да, ике арага тагын аркан таш-

ладылар, һәм шул рәвешчә, ике кәмә бер-берсенә тагылып, сака кәмәсен тартып алып киттеләр.

Көне буена туктаусыз ишеп килгән кара ишкәкчеләр бик нык арыганнар иде. Кәмә үзеннән-үзе шуыша башлагач, алар, иркен сулап, сөенечтән җиңелчә кычкырып җибәрделәр, ишкәкләрен тартып алдылар да тирә-якка карап бара башладылар.

Диңгездән кала үзәгенә — Саркелгә таба сузылган каналның киңлеге — йөз адым, озынлыгы ун чакрым иде. Каланы уратып алган иң зур койма диңгез белән канал кушылган төштә Тамакның ике ягында өзелеп кала иде. Ләкин койманың дәвамы рәвешендә Тамак аша өсте ябулы бик зур, бик озын күпер салынган иде. Тамак янында — уңда да, сулда да — кораллы ирләре булган сакчы сугыш кәмәләре туктаган, күпердә һәм күпер янындагы ике яктагы таш манаралар башында шулай ук кораллы ирләр — күзәтчеләр йөреп тора иде.

Карман сака кәмәсен бернинди тоткарлыксыз Тамак авызыннан үткәреп җибәрделәр. Канал уртасындагы кәмәләр, каеклар, бер-берсенә тагылган горур һәм бизәкле кәмәләрне күреп алу белән, шундук читкә тайпылырга, яр буенарак сыенырга тырыштылар. Каршыга килүчеләр шулай ук тиз генә читкә каердылар. Үз кәмәсенең алгы ягына — борын өлешенә чыгып баскан һәм кулларын күкрәк турысында кушырып барган яшь, горур саканы котлап ярның әле уң ягыннан, әле сул ягыннан кычкырган авазлар ишетелде. Кайберәүләр, якын танышларын очраткан кебек, аңа кул болгадылар, ишкәкләрен югары күтәреп сәламләделәр. Изгеләр нәселеннән булган Карман саканы аның үз биләмәсендә генә түгел, мака сар каласы Аклантитада да бик күпләр яраталар һәм якын күрәләр иде. Ни өчен дигәндә, ул монда, калада туган кеше. Аннары ул сакалар арасында иң яше һәм халык арасында сөйләнгән төрле имеш-мимешләргә караганда ул башка барлык сакалар арасында акыллырак һәм шәфкатьлерәк дип исәпләнелә иде.

Каналның ике як яры да тигез итеп киселгән таш койма белән ныгытылган. Койма өстендә, озын ботакларын су өстенә сузып, төз кәүсәле пальмалар, имәннәр утыра. Агачлар арасында берәр, икешәр катлы таш өйләр күренеп калды. Өйләрнең бер төрлесе — тоташ ак таштан, икенче төрлесе кызыл, сары яисә кара ташлардан салынган иде. Капкалар бизәлгән, капка канатларына кояш бизәкләре төшерелгән. Каналның әле уң ягында, әле сул ягында ярга тарттырып бәйләп куелган буш

кәмәләр, шулай ук әле яңа килеп туктаган төрле каеклар күренеп калды. Кәмәләрнең кайберләренә агач, таш, кайберләренә шыплап өеп ашлык, кайберсенә чүлмәктер, савыт-сабадыр төялгән иде. Ара-тирә ат, сыер, сарык ише мал-туар төягән зур, авыр кәмәләр очрады. Яр өстендә балта, чүкеч тавышлары ишетелде, ниндидер кычкырган, балалар елаган тавышлар ишетелеп калды.

Сака кәмәсен тартып баручылар шактый тиз алып бардылар. Кала үзәгенә таба якыная барган саен, яр буйларындагы шакы-шокы килгән, тамак ярып кычкырган төрле тупас тавышлар кими башлагандай булды. Аның урынына яр буенда куе агачлар арасында утырган йортлар ешайды, биегәйде. Каланың бер ягыннан икенче ягына йөрүче ниндидер төрле төстәге, төрле кыяфәттәге каеклар күренде.

Изгеләр калкулыгы астына шулай ук ясалма су юлы керә. Ләкин бу су юлы җиз чылбырлардан теркәлгән челтәр белән бикләп куелган иде. Анда мака сарның үз рөхсәтеннән башка беркем дә керә алмый. Карман саканың кәмәсе, җиз коймага артык якын килмичә, күпер баганаларының берсе янында туктап калды. Мака сарның сөңгечеләре аны күрделәр, таныдылар һәм ашыгыч рәвештә сарайга йомышчы җибәрделәр. Бу вакытта инде кояш баеп килә иде. Су өсләре карайган һәм ничектер тынып калган сыман күренде. Бары тик мәһабәт булып, кыя таудай калкып торган, туп-туры су өстеннән күккә таба үрләгән җиз коймадан гына кызгылт тонык яктылык чагылып күренә иде. Якында гына шундый биектән шулкадәр күп җиздән төшкән кызгылт яктылыкны тою күңелле дә һәм шомлы да иде.

Көне буе кәмәдә килеп Карман сака шактый арыган, йончыган иде. Күпер баганасы янында туктап көтеп торган арада ул ничектер тынычланып калып, тәне белән дә, күңеле белән дә ял иткәндәй булды. Аны хәтта сиздермичә генә йокы да баса башлагандай булды. Монда аңа бөтен нәрсә таныш һәм якын: каршыдагы биек җиз койма да, таш баганалар, таш күпер һәм күпер өстендәге туктаусыз дөбердек тә, су өстеннән арлы-бирле шуып киткән кәмәләр дә, сөңгечеләр дә. Аның бала чагы, үсмер чагы шушында — су өстендә, таш күпер араларында, биек коймалар янында үтте. Аклантитадагы Саркелгә кайтканда ул һәрвакыт бала чакларын, үсмер чакларын исенә төшерде һәм һәрвакыт аңа моңсу да, күңелле дә һәм никтер оят та була.

Шул ук вакытта һәр кайтуында ул үзенең монда инде

күпмедер дәрәҗәдә чит кеше икәнлеген дә, бала чак һәм үсмер чак белән үзе арасында җиз, бакыр коймалардан да биегрәк булып нинди дер башка коймалар ятканын да тоймыйча булдыра алмады. Мондагы су өсте, мондагы һава, йортлар, коймалар, күперләр әйтерсең аның үзенә түгел, бала чакта, үсмер чакта торып калган, ләкин аңа бик тә таныш булган икенче кешегә якын, үз иде. Бүгенге, хәзерге Карман сака исә монда бары кунак кына, һәм бу чыннан да шулай иде. Карман саканың «туган җире» хәзер башка утрауда, башка калада, монда исә тулысынча аның иң өлкән агасы Карун хуҗа, Карун баш.

Биек ак ташка чукып язылган түрә буенча Кар баба нәселеннән булган тугыз саканың мака сар янына тәүлекнең теләсә кайсы вакытында керергә хакы бар. Мака сар үзенең йокы бүлмәсендә ятакта булган чагында гына аның янына беркем кертелми. Элегрәк сакалар Саркелгә кертелгәндә дә күпер астында туктап, сөңгечеләрнең рөхсәт алып килүен көтеп тормаганнар — туп-туры койма авызыннан эчкә үтеп киткәннәр. Менә шулай җиз койма авызындагы җиз чылбырга карап көтеп тору тәртибен Карун булдырды. Ата-бабалар ташка язып калдырган түрәдә Саркелгә ничек керү-кермәү турында бер сүз дә юк иде. Шуннан файдаланып, Карун шулай сакаларның хокукларын чикләүдә хәйлә тапты. Түрәдәге һәр үзгәреш бары тик ага-энеләр тарафыннан расланырга тиеш булса да, Карунның тәкъдименә беркем ныклап торып каршы килә алмады, чөнки ул мондый чикләүнең кирәклеген нигезли алды. Имеш, ага ул аллага тиң кеше, имеш, болай итсәң, башка чит халыклар арасында аганың дәрәҗәсе бермә-бер артачак, аннан куркып, кан калтырап торачаклар. Карун ул, гомумән, шундый кечкенә яңалыклар, яңа гадәтләр, түрәләр уйлап табарга ярата. Ләкин ул уйлап тапкан гадәт-түрә аның үзенең хокукларын арттыруга, башкаларның — сакаларның, лелегләрнең яисә караларның хокукларын кысуга юнәлдерелгән була. Аның бөтен тырышлыгы, бөтен уй-хисе үз-үзен зурлауга, үз-үзен чиксез хуҗага әйләндерүгә хезмәт итә.

Көтеп тору Карман сакага озаккарак сузылгандай булды. Аның инде ашыйсы да килә башлады. Әкренләп ачу, үртәлү тойгысы кузгалды. Шул чакны, ниһаять, койманың гөмбәзле зур, биек авызыннан сөңгечеләр кәмәсе чыгып килгәне күренде. Тоташ кызылга буялган өч-дүрт кешелек кечерәк кәмә туп-туры күпергә, Карман сака янына якынлашты. Мака сар яныннан килгән сөңгече, каркурага менеп тормыйча, астан, су өстеннән генә мака

сарның Саркелгә керергә рөхсәтен әйтте. Аннан соң өстәп куйды:

— Мака сар әйтте: ашыгыч йомышы булмаса, бүгенгә ял итсен, дип әйтеп әйтте, — диде.

Карман сака сөңгече алдында ярсып кычкырып җибәрүдән үзен чак-чак кына тыеп калды. Ни өчен дигәндә, Саркелдә сөңгечеләр мака сарның иң ышанычлы кешеләре иде. Аларның бер өлеше аның белән бер йортта ук торалар, икенче өлеше барлык керү-чыгу юлларын — капкаларны, ишекләрне саклыйлар һәм Саркелдә мака сар турында кем нәрсә әйтә, хәтта кем ничек уйлый — барысын да аңа җиткереп кенә торалар. Шуңа күрә хәтта сака булган кешеләр дә Карун турында алар алдында нинди дә булса сүз әйтүдән тыелып калырга мәҗбүрләр иде. Ә бит мака сарның аңа — Карман сакага — «бүгенгә ял итсен» дип әйтергә бернинди хакы юк. Әле ул йокыга ятмаган, аның ятагында әлегә бернинди хатын-кыз юк. Шулай булгач, ул туп-туры керә алырга тиеш. Ул әнә аны чикли, аның юлына аркылы төшә, аның хокукын кыса. Ул шулай димәсә дә, Карман сака бүген үк аның янына керергә атлыгып тормый иде.

Сака шулай итеп үзен кыерсытылган итеп хис итте. Ләкин ул боларның барысын да эченә йотты һәм Карун боерыгын алып килгән сөңгечегә:

— Юлда бик йончыдым, иртәгә барырмын, шулай дип әйт, — диде.

Сөңгече кәмәсе коймага таба борылды. Сака кәмәсе дә әкрен генә кузгалып китте. Алар койма авызына якынаю белән, койма авызы янында кечерәк кәмә өстендә сакта торган сөңгечеләр югарыдагы, койма өстендәге кешеләргә өзек-өзек кычкырып боерыклар бирделәр. Кайдадыр өстә, биектә чыгырлар шыгырдады һәм җиз койма авызын каплап торган челтәрле чылбырлар пәрдәсе әкрен генә югары күтәрелә башлады. Сака кәмәсе су өстеннән шуышып барган шәпкә ярым караңгы җир авыз эченә барып керде.

Түгәрәк калкулык эченнән чыгып ясалган бу җир асты юлы иң үзәккә кадәр — мака сар сараена кадәр сузыла иде. Мака сар, диңгезгә чыгасы килсә, үз сарае янындагы баскычтан түбән төшә дә, яр буена килә дә, су өстендә үз кәмәсенә утырып, шундук чыгып китә ала. Аның янына килүче сакалар да шушы җир астыннан сузылган су юлы белән генә килә алалар иде.

Ярты чакрымга сузылган бу җир асты су юлы мака сарның һәм шулай ук бөтен Аклантитаның яшерен ам-

бары хезмәтен дә үти иде. Як-яклары, стеналары, астары, гөмбәзле түбәсе төрле ташлардан өелгән бу җир асты юлы шактый киң һәм биек. Бу юлдан өч рәт ишкәкчеләре булган кәмә бик иркен үтә ала, җитмәсә, як-якта әле кечерәк каекларга үтеп китәрлек урын да кала. Мондагы яшерен юлның үзенчәлеге шунда: як-якта туп-туры су өстенә төшә торган таш баскычлары, тигез басмалары һәм җир белән нығытылган зур-зур ишекләре булган өстәмә икешәр катлы амбарлар бар. Амбарларның аскы катында бар җире дә буялган өр-яңа сугыш кәмәләре, өске катында диңгезче өчен кирәк булган төрле нәрсә — агач-таш, бау-шу, буяу, балавыз, кадак, ыргак һәм, әлбәттә, сугыш кораллары — сөңгеләр, калканнар, ук-җәя кебек нәрсәләр саклана. Амбарның бер төрлесендә корал, бау-шу булса, икенче төрлесендә зур-зур чүлмәкләрдә, капчыкларда ашлык, җимеш, май, бор һәм башка төрле азык-төлек саклана. Җир асты юлына төшеп-менеп йөрү өчен йөз адым саен тирән ям казылган. Ямның як-ягы, гөмбәзле түбәсе шулай ук таш белән нығытылган, җизгә төрелгән таш баганалар белән бизәлгән.

Карман сакаың Саркелдә үзенеке исәпләнелгән аерым йорт-җире бар. Йорт-җирдә исә үзенең каралары, кайбер якын туганнары яши. Саркелгә килгән саен ул шунда туктала. Хәзер дә ул үз йортына якынрак урнашкан Карпе янында туктап калды.

Кәмә яр буена килеп туктау белән, борыннан да, койрыктан да ярга аркан ташладылар. Ярдагы кешеләр, тиз-тиз генә кыланып, арканнарны таш баганаларга тарттырып бәйләп куйдылар. Ул арада кәмәдән ярга басма сузылды. Басмадан иң элек саканың ун коралы ире төште. Алардан беркадәр калышып Карман сака ярга үзе чыкты. Аның коралларын, авыр җиз киемнәрен арттан өч яшь кара ир күтәреп барды. Алардан соң чыккан ирләр кулларына зур-зур чүлмәкләр, капчыклар күтәргәннәр иде. Иң ахырда дүрт таза ир аркылы таякларга утыртылган ниндидер бик авыр нәрсә күтәреп чыктылар. Ирләрнең икесе — алдан, икесе арттан барды. Ташкурчакка охшаган авыр нәрсәнең өстенә киндер кисәге капланган. Бу Карман сака әнисенең бер батман авырлыгындагы алтын сыны иде. Сака аны үз каласындагы сынчылардан койдырды, һәм ул аны Карунга бүләк итеп бирергә исәпли иде. Кыйммәтле бүләк алып килсәң, мака сар Карун белән сөйләшүе җиңелрәк була, юкса ул үзен кирәгеннән артык эре һәм һавалы тотачак. Аның мондый гадәтен белгән кешеләр беркайчан Саркелгә буш

кул белән килмиләр, килгәндә һәрвакыт алтыннан ясалган бүләк алып килергә тырышалар.

Киң, тигез баскычлардан югары күтәрелделәр һәм ике ягында да биек агачлар үскән киң сукмак белән турыга бардылар да аннары уңга каердылар һәм бераздан зәңгәр капкасына кашкарый сурәте кадакланган йорт каршына килеп җиттеләр. Капка төбендәге утыргычта калын иренле, көдрә чәчле кара утырып тора иде. Төркемләшеп килүче бик күп кораллы кешеләрне, алар артында җилкәләренә ишкәкләрен күтәргән ишкәкчеләрне һәм бигрәк тә алдан килүче Карман сака765 күрү белән, капка төбендәге кара шундук сикереп торды һәм кабаланып капка артындагыларга нидер кычкырды. Җиз кашкарыйлы зәңгәр капка шундук ачылып китте, ишегалдыннан карт кара сакчы килеп чыкты. Ашыгып ул сака каршысына килде, баш иде, саканың аягын үпте.

— Исән-имин кайтып җитүең белән котлыйм сине, сака, — диде кара, карлыккан тавыш белән ялагайланып. — Йортың-җирең исән-сау. Барысы да үз урынында. Түрдән уз туган җиреңә.

Карман сака, рәхмәт әйткән сыман итеп, карт колның башыннан сыйпады һәм капка аша керешли генә, узып барышлый гына әйтеп куйды:

— Бар, әйт, җылы су таманласыннар, яхшы аш-су әзерләсеннәр. Арыдым, ачыктым, — диде.

Карман саканың дүрт яктан да таш койма белән уратып алынган йорт-җире шактый иркен иде. Монда аерым-аерым утырган берәр, икешәр катлы өйләр дә, терлек-туар тоту өчен абзар-куралар да, җимеш бакчалары, тегесен-монысын чәчү, утырту өчен буш җирләр дә, болай гына, матурлык өчен генә үстерелә торган төрле агачлар да, куаклар да бар иде. Капкадан килеп керү белән, турыга таш җәелгән киң урам сузыла. Урамны бер-ике җирдән таррак урамнар кисеп үтә. Анда-санда кешеләр күренде, үзара уйнап йөргән бала-чага тавышына катышып, сыер мөгрәгән, сарык кычкырган тавышлар ишетелде. Изгеләр калкулыгындагы — Саркелдәге — бу коймаланган җир үзе бер авылны хәтерләтә.

Шушы киң, иркен кешәлекнең уртасында, үзәктә, куе яфраклы матур агачлар артында тигез итеп киселгән, шомартылган ак ташлардан салынган ике катлы биек һәм зур йорт күренде. Бөтен авылда бу иң зур йорт. Заманында бу Карман сака әнисенең, мака сар Минәйнең дүртенче бичәсе Сәлимә йорты булган. Карман шул йортта туган. Сәлимә бикә исән чакта үзенең өлкән кызы

Галиягә кияү алып, аларга шунда яңа йорт салып биргән. Бикәнең икенче, өченче кызлары да үзләренә кияү алып, әниләренең авылында торып калганнар. Сәлимәнең Карманнан башка тагын ике улы булган. Аларның берсе акайлар белән сугышта яуда үтерелгән, икенчесе — төпчеге — үз өе белән аерым торып ята. Үзе яшәгән иң зур, иң бай борынгы йортны Сәлимә бикә өлкән улы Карманга калдырган. Ләкин Карман үлгәч, йорт аның балаларына түгел, ана нәселеннән булган өлкән ир балага калачак.

Хәзер исә бу авылда Карманның апасы Галия иң өлкәне һәм иң башы исәпләнелә. Мондагы бөтен авылга, барлык кешегә ул баш, һәм аның белән килешмичә монда берни эшләнми.

Саканың юлдашлары — алыплар, кәмәчеләр һәм ишкәкчеләр — йөзләп кеше барысы да диярлек ишегалдына кереп тулдылар. Ишкәкчеләр ары китмәделәр: капкага якын җирдә, кергәч тә уң якта, озын гына, тар гына таш йорт бар иде. Алар шунда калдылар. Кәмәчеләр сулга каердылар. Капкадан берничә адым читтә генә алар өчен дә йортлар бар. Утыз алып — Карман саканың иң ышанычлы сакчылары — аның белән бергә киттеләр.

Карман сака иң элек үз өенә түгел, апасы Галия йортына юнәлде. Галиянең йорты Карман йортыннан кала бөтен «авылда» иң зурысы, иң күренеклесе иде. Ул да ике катлы, тик үзәктәге йортка караганда ул бераз гына тәбәнәгрәк һәм бераз гына кечерәк иде, ләкин шуңа да карамастан, аның йорты җанлырак, баерак һәм матуррак сыман иде. Анда көне-төне шау-шулы тормыш, күңелле тормыш кайнаганы ерактан ук күренеп тора. «Шулай булырга тиеш тә» дип уйлады Карман сака, үзенең ничектер боегыбрак утырган таудай ялгыз өе ягына күз төшереп алгач. Бит анда асраулардан, каралардан, хезмәткәрләрдән башка чынлыкта беркем тормый.

Карман сака килүе турында бөтен авыл белеп өлгергән иде. Юл уртасыннан барганда әле уңнан, әле сулдан таныш кешеләр килеп чыкты. Берәүләр килеп сака белән исәнләшергә, олы туганына карата хөрмәтен белдерергә ашыкты, икенче берәүләр, каралар — хурлар, кимнәр — үзләренең бик нык сөенгәнлекләрен белдереп, елмаеп, читтән генә, юл буеннан гына карап калдылар. Әрсезрәк үсмерләр, кыю малай-шалайлар, атаклы абзыйларының алдына ук чыктылар, аның кулын йә булмаса киемен үбәргә тырыштылар. Бер бала хәтта аның юлына аркылы төште һәм үзен күтәреп алуны таләп итә башлады.

Юл читендәге асраулар шундук баланы тотып алмакчы булдылар. Ләкин Карман сака балаларны ярата иде. Ул ярым шәрә ике-өч яшьлек малай апасының улы икәнлеген таныды, күтәреп алды да, аның белән сөйләнә-сөйләнә, шул килеш апасының ишек төбенә килеп туктады.

Шул чакны, тышта күңелле шау-шу ишетеп, өйдән ашыгып апасы Галия килеп чыкты. Ул өстенә кыска җиңле озын күлмәк кигән иде. Энесе Карманны күреп сөенеп кычкырып җибәрде һәм, кулларын җәеп, ак шома мәрмәр баскычтан йөгереп төшкәндәй төште дә, шаулап, кычкырып сөйләнә-сөйләнә һәм шул рәвешчә үзенең бик нык куануын белдерергә тырышкан сыман, энесенең муеныннан кочып алды.

— Иртәдән бирле уң күз кабагым кычыткан иде, сине күрергә булган икән! — диде ул.

Шулай шау-шу килеп сака белән исәнләшкәндә, ул Карманның куенында улын да күреп алды, бик нык гаҗәпләнгән булды, ачуланган булды, хәтта улын абыйсыннан тартып алмакчы да булды. Бала исә аның саен абыйсының таза тәнле, диңгез исе сеңгән нык таза муенына сарыла барды. Галия улының кирелеген күреп шаулатып көлеп җибәрде, малайның йомшак җиренә чәпелдәтеп алган булды.

— Нишләп вакытсыз килдең? — диде Галия энесенә. — Сабантуй җитмәгән, мака сарның туган көненә әле иртә. Менә кунакка барырга дип җыенып ята идек әле.

Галия Карман сакадан ике-өч яшькә генә өлкәнрәк иде. Ул шулай шауларга ярата, килделе-киттеле дә сөйләнеп ташлый, турысын әйтәм дип кайчагында кешенең йөзен ертудан да тартынып тормый иде. Шуңа күрә Карман сака аның сорауларына әллә ни игътибар да итмәде.

Шул чакны ишектән кырык яшьләр чамасындагы басынкы кыяфәтле бер ир кеше килеп чыкты. Бу Галиянең кияве, Карманга җизни кеше иде. Ул, Карманны ерактан ук күреп, исәнләшкән кебек аңа баш иде, туктап калгандай булды, ләкин алай гына килешмәгәнлеген аңлап, аскарак төште, изге сака белән кул биреп исәнләште.

— Галия, кунакка, бәлки, бүген бармабыз олы кунак килгәч? — диде ул, бикәсенә карап.

— Син бармасаң бармассың, мин барам! — диде Галия, каршы әйтергә урын калдырмыйча. — Ничек бармыйсың, сүз бирелгән. Алар көтәләр. Мин барам.

— Барыгыз, бар, — диде Карман, сүзгә катышып. — Мин арыдым. Хәзер ашыйм-эчәм дә йокларга ятам.

— Юк, мин синең үзеңне генә калдыра алмыйм. Килешми, — диде җизни. — Син, алайса, үзең генә бар, — диде ул, бикәсенә карап.

— Теләсәң, син дә бар безнең белән, — диде Галия.

— Арыдым. Иртәгә, — диде Карман сака, сүзне озакка сузасы килмичә.

Карман сака, апасы Галия белән күрешкәннән соң, артык тоткарланып тормыйча үз өенә китте. Өйалдында тигез итеп таш җәелгән һәм як-ягында яшел яфраклы куе куаклар үсеп утырган мәйданчыкта аны өй хезмәткәрләре, асраулар, хезмәтчеләр, эшчеләр каршылады. Алар бил бөгеп, баш иеп, олуг хуҗаның диңгез кичеп исән-имин үз өенә кайтып җитүе белән котладылар. Карман сака, исәнләшкәндәй итеп, аларга кулын күтәреп, баш кагып җавап бирде дә ашыгып биек баскычтан югары менде һәм беренче каттагы коену бүлмәсенә юнәлде.

Тышта инде күз бәйләнә башлаган, өй эчендә исә шактый караңгы иде. Ләкин үз өендә Карман сака күз йомып та үзенә кирәк булган теләсә кайсы бүлмәгә ялгышмыйча бара ала. Шунлыктан ул ян-яктагы биек терәкләр арасыннан, төрле борылышлар аша, бүлмәләр, ишекләр аша, әле уңга, әле сулга борылып, өйнең аргы башындагы бүлмәгә таба баруында булды. Ул араларда хезмәтчеләр пыскыйларга ут яндырдылар һәм бер-берсенә нидер кычкыргалап, сакадан алдарак барып җитәргә тырышкан сыман, бүлмәдән бүлмәгә ары-бире чабыша башладылар. Берсе шунда, чыртлап янган пыскыен югары күтәреп, сака алдына килеп чыкты һәм сака адымнарына яраклашып аның алдыннан бара башлады.

Ниһаять, алар коену бүлмәсенә барып җиттеләр, җиз калайлар кагып бизәлгән авыр ишекне ачып эчкә керделәр. Өйнең ыгы-зыгылы, шау-шулы өлешеннән читкәрәк, аулаграк почмагына урнашкан коену бүлмәсе артык зур булмаса да, иркен иде. Килеп керү белән, саканың борынына бераз гына черек күкәй исен хәтерләткән ис катыш кайнар су исе килеп бәрелде. Бүлмәнең каршыдагы мөгеш өлешенә терәп ясалган зур гына түгәрәк коега җылы су тутырылган, ис һәм бу шуннан күтәрелә. Кое янында — таш урындык, таш урындык янында — ятак. Урындыкта — алтын савыт-саба, сөңге, кием-салым. Өстен сырлап бизәлгән ташлар тезелгән идәнгә камыш чыпта, камыш чыпта өстенә йомшак палас җәелгән.

Өч якта, өч мөгештә, таштан уеп, шомартып ясалган ак таш түмәрләрдә җиз пыскыйлар янып тора. Диварларда — диңгез күренешләре. Бер ягында — зәңгәр су астында суүсемнәр, балыклар. Шунда ук сигезаяклар. Икенче ягында — зәңгәр диңгез өсте. Еракта диңгез зәңгәр күк белән тоташкан. Әз генә җил исә, һәм кызыл җилкәннәрен күтәреп, сары кәмәләр, аккошлар сыман тезелеп, каядыр еракка китеп баралар. Яр буенда, таш коймага сөялеп яисә кулларын болгап, аларны кызлар озатып кала. Ишеккә каршы яктагы диварда, коеның тар ягы терәлеп торган төштә, тау башыннан, ташлар арасыннан ургылып агып яткан чишмә сурәтләнгән. Чишмәнең бер ягында, зур, авыр яфракларын салындырып, пальмалар үсеп утыра, икенче ягында юан купшы имән үсә, алгырак якта ал, ак чәчәкле лаләләр күренә. Пальмалар артында алтын текмә. Кайнар чишмә суы туп-туры бүлмәдәге коега агып төшкән сыман итеп ясалган. Барысы да чынлыктагы кебек. Чишмә янындагы ташлар да, лаләләр дә, куаклар да таудан алып шунда китереп утырткан кебек.

Барысы да таныш, барысы да якын монда. Моннан егерме, егерме биш ел элек ничек булган булса, барысы да шул көе. Күгәрченнәр, тутыйлар ясалган бизәкле түшәм дә, идән дә, диварлар да, мондагы дымлы һава да — барысы да бала чактагы кебек. Шушында җылы суда тыпырчынып ятканда, ул үзен юындыручы кара тәнле кимгә су чәчрәтә-чәчрәтә, еракка китеп баручы диңгезчеләргә, бер-берсен куышып йөзгән балыкларга карап хыяллана торган иде. Еш кына аның да шул балыклар сыман су эчендә чумып йөрисе килә, йә булмаса кәмәнең иң югары басмасына менеп басып, җил-давылга каршы, дошманнарга каршы яуга чыгасы килә иде.

Чишенеп, шәрә килеш калып коега кереп сузылып яткач та Карман саканың шул бала чак хыяллары исенә төште. Әйе, бүлмә дә, кое да, сурәтләр дә — барысы да шул ук. Коедагы су да шундый ук — җылы дисәң җылы түгел, кайнар дисәң кайнар түгел. Таман гына. Рәхәт. Тәнгә вак-вак куыклар килеп куна. Су өсте гел күбекләнеп, куыкланып тора. Барысы да шул ук. Тик менә уйлар, хыяллар гына хәзер башкачарак. Аңа инде күп мәртәбә суүсемнәре арасында, балыклар арасында да йөзәргә туры килде, сигезаякларны да күрде ул һәм, җилкәнле кәмәләргә утырып, иксез-чиксез киңлекләргә дә күп чыкты. Ерак-ерак илләрне дә күп күрде, яуларда да булды. Дошманнарны да җиңде. Шулай да, кайда гына

булмасын, күңелендә шушы өйне, шушы бүлмәне, шушындагы матур әйберләрне юксынды һәм шушы коеда, кайнар-җылымса шушы суда шәрә килеш сузылып яту аның өчен иң зур хыял булып тоелды. Нәрсә кирәк соң бу ата баласына чынлыкта? Кая ашкына ул туктаусыз? Бүген иртән ул ашыгып йокыдан торды. Аның менә тизрәк монда — үз өенә килеп җитәсе килде. Көне буе ул бары шул турыда гына уйлады. Килде. Менә хәзер кич булды. Төн кунасы бар. Иң күңелсезе — төн уздыру. Тизрәк таң аттырасы, тизрәк якты көнне күрәсе һәм ниндидер зур эш эшлисе, һәркемне таң калдырырлык берәр батырлык, изгелек эшлисе килә. Нинди генә батырлык эшли алыр икән ул иртәгә? Ә бит эшлисе иде ул батырлыкны!

Ул шулай уйланып, ләззәтләнеп ятты-ятты да башын калкытты һәм урындыктагы күбәтәгә үрелде. Аның шундый хәрәкәт ясавы булды, ишектән кара хезмәтче кол килеп керде. Биенең нәрсә эшләргә чамалавын ул бик яхшы белде. Күбәтәгә кара сабын салынган иде. Сабын дип аталган тау итәгеннән тирән чокырдан алына торган бу кара ләмне тәнгә үкәсәң, ул тәндәге керне, майлы тапларны юып төшерә, арыганлыкны бетерә һәм тән тиресен йомшарта. Саркел аксөякләре сабын ләме белән бик теләп юыналар. Урта яшьтәге хатын-кызлар аны аеруча күп кулланалар.

Кол керү белән, Карман сака кое читенә чыгып утырды. Нәкъ бала вакыттагы кебек кол аның аркасын, озын чәчләрен сабынлаганда, ул түземсезләнеп хәтта аяклары белән коедагы суны чыпырдатып утырды. Ләкин аңа алай озак чыпырдатырга туры килмәде. Биленә тикле бөтен аркасы сабынлануга, ул коедан чыгып кое читенә басты. Кол иләп кенә аның ботларын, балтырларын сабынлый башлады. Ул аның бары арка ягын гына үкәде. Алгы ягын ул үзе сабынлады һәм шул эшне бетергәч, яңадан коега керде, беләкләрен, күкрәкләрен ышкыпышкып юына башлады. Кол аның аркасын, чәчләрен юды, тарады.

Коедагы су кап-кара булды. Бөкене ачып, суны агызып җибәргәч, кол көмеш комган белән су салып Карман саканы яхшылап коендырды да чәчләрен үрде. Юынгач ул, үзендә җиңелчә арыганлык тоеп, бераз вакыт урында ятып тормакчы булды.

— Җизнигә әйтегез, кунакка китмәгән булса, минем янга килсен, — диде сака.

Ул шулай диде дә аяклары арыслан аягы кебек итеп

фил сөягеннән ясалган йомшак ятакка сузылып ятты, күзләрен йомды.

Карман сака үзенең коену бүлмәсендә юынганда, аның алыплары күршедәге икенче бүлмәдә юындылар. Юынгач, тарангач һәм өр-яңа коры киемнәр киенеп алгач, алар шундагы озын сикеләргә утырып тордылар да, саканың ишектән чыгуын күреп, урыннарыннан кузгалдылар. Икенче катка алар арткы яктан мәрмәр баскычтан менделәр.

Менеп җиткәч, артык зур булмаган бүлмә аша үттеләр дә ике якка ачыла торган зур ишектән киң, иркен һәм биек мәҗлес бүлмәсенә килеп керделәр. Бүлмәнең идәненә сырлы бизәкләр төшерелгән мәрмәр тактачыклар тезелгән, аның өстенә буй-буй бизәкле киң паласлар җәелгән. Ишектән кергәч тә диварларга якынрак төштә, як-якта түшәмдәге кырлы матчаларны тоттырып, парлы терәкләр тезелеп киткән. Юан имәннән юнып ясап эшләнгән ул терәкләр — тоташ кызылга, терәк өстендәге һәм астагы идәндә калку дүңгәләкләр куе сарыга буялган иде. Парлы терәкләр белән диварлар арасындагы тар аралыкларга таш сикеләр, төрле бизәкле һәм төрле кыяфәттәге зур-зур чүлмәкләр, диварлардагы куышларда — алтын-көмеш, җиз-таш сыннар, чүлмәкләрдә — гөлләр. Бүлмәнең урта бер җирендәрәк, парлы терәкләр янында, аяклары арыслан аягы сыман итеп, агачтан кырып ясалган һәм алтын калай белән төрелгән, кырыйлары матур итеп бизәлгән, сырланган зур өстәл. Өстәлдә эреле-ваклы, төрле төстәге, төрле формадагы алтын-көмеш савытлар. Мөгешләрдәге таш багана башларында утлар янып тора. Шунлыктан күзнең явын алып, бөтен җирдә алтын-көмеш, җиз һәм бизәкле чүлмәкләр ялтырый. Диварлар, түшәм бөтенесе матур итеп ал, кызыл, зәңгәр, сары төсләрне аралаштырып буялган. Түшәм астында кашага буйлап кашкарый һәм лалә чәчәкләре төшерелгән.

Карман сака, идәндәге йомшак паласка нык-нык басып, туры өстәлгә таба атлады. Ул арткы ишектән килеп кергәч, күп тә үтмәде, мәҗлес бүлмәсенең түрдәге икенче ишегеннән җизнәсе килеп керде. Уртадагы өстәл янына алар икесе дә бер үк вакытта диярлек килеп җиттеләр. Ләкин бу өйдә төп хуҗа Карман сака булганга, җизни, әдәп саклап, чак кына арткарак калды.

Тәбәнәк өстәл белән парлы терәкләр арасына бай итеп җиһазланган ике артсыз урындык куелган. Берсе Карман саканың үзе өчен куелган, икенчесе җизни өчен иде.

— Түрдән уз, җизни, — диде Карман сака, өстәл янындагы урындыкка күрсәтеп.

Шуннан соң ул үзенең алыпларына борылды һәм күз карашы белән аларга да утырышырга кушты. Җизнәсе белән алар икесе йомшак урынга утырдылар, алыплар өстәл тирәсенә туп-туры идәнгә, калку йомшак урыннарга урнаштылар. Алар утырышып бетү белән, аргы уң яктагы ишектән яңа пешкән кайнар ит күтәреп, нык беләкле, симез, таза ашчы килеп керде. Ике куллап тоткан сырлы-бизәкле алтын табагын ул туп-туры Карман сака алдына китереп куйды. Карман сака, ашыкмаска тырышып һәм беркемгә карамыйча, авызындагы төкерекләрен йота-йота, сөяк саплы җиз пычак белән ит бүләргә тотынды.

— Мака сар җырчы кызларын җибәргән, би, — диде ашчы, сакаaccount колагына иелеп. — Керсеннәрме?

— Җибәргәч, керми нишләсеннәр инде? — диде Карман сака, туравыннан аерылмыйча. — Пешкән ашың җитәме соң?

— Җитмәсә, җиткерербез, — диде ашчы, аптырап тормыйча. — Башта ук билгеле булса, яхшырак буласы иде дә.

Карман сака алтын табактагы изелеп пешкән майлы куй итенең беренче калҗасын кулына алды да, ятак аша үрелеп, таш багана башындагы май янына — Ут анасы Әбетигә корбанга бирде. Беренче кисәкне Әбетигә бирмичә ашый башлау дөрес түгел. Шуннан соң ул икенче кисәкне үзе капты да өченчесен кунагы җизнәсенә сузды. Җизнәсеннән соң тиз-тиз генә берәм-берәм ит кисәкләрен алыпларына бирә торды. Аш-су шулай башланып китте. Моннан соң инде һәркем үзенең алдындагына үзе үрелде. Беренче изге кабымны ашагач, Карман сака, ниһаять, җизнәсенә күтәрелеп карады.

— Ул миңа, беләсеңме, ял итәсе килсә, ял итсен, иртәгә килер, дигән. Хәзер әнә җырчыларын җибәргән, — диде, гаепләгән сыман итеп.

Җизни, билгеле, аның кем турында әйткәнен бик яхшы аңлады. Ләкин, аңласа да, яклау да белдермәде, каршы сүз дә әйтмәде. Ул мондагы кеше. Мака сарга, сарайга якынрак кеше һәм мондагы һәртөрле яңалыкларны да, барлык гайбәтләрне һәм имеш-мимешләрне дә бик яхшы белеп тора. Ул көне-төне шулар арасында кайный һәм мака сарның тормышын биш бармагы кебек белә. Мака сарның бүген кәефе юк. Карман теләсә дә, теләмәсә дә, ул аны кабул итә алмас иде. Ләкин бу

турыда аның сакага әйтәсе килмәде. Аның шулай ук җырчы кызларны Карун исеменнән үзе чакырткан икәнлеген дә әйтеп торасы килмәде.

Күп тә үтмәде, кычкырып сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә, җырчы кызлар керә башлады. Алар барысы да яшьләр, чибәрләр иде. Аларның көдрәләткән, күпертелгән кара чәчләре ике яктан толым-толым булып аркаларына салынып тора. Кыска җиңле, озын итәкле күлмәкләренең муен, күкрәк турысы ачык. Бит очларына, иреннәренә матур итеп кызыл буялган. Кайберсенең чәченә болай гына, әйтерсең ялгыш кына чәчәк кыстырып куелган, күбесе төрле ташлардан, алтыннан, көмештән тезелгән муенса таккан. Ак, сары җирлеккә аралаштырып аркылы буй-буй сызыклар төшерелгән киң күлмәк итәкләре, аяк атлаган саен, салмак кына дулкынланып бара.

Зал уртасына якынлашу белән, өстәл янындагы алыпларны күрү белән, алар көлүдән, сөйләшүдән тыелып калдылар. Шул ук вакытта бер-берсенә карашып йә пырхылдап алдылар, йә тыелып кына нидер гайбәтләшеп алдылар.

Башларын югары тотып, күлмәк итәкләрен җилбердәтеп, салмак, ышанычлы адымнар белән алар шулай алгарак уздылар да ашаучыларга каршы яктагы озын сикеләргә утырыштылар. Үзләре белән алар гөслә, курай, кубыз ише уен кораллары алып килгәннәр иде. Өстәлгә, ашаучыларга каршы якта диварда идәннән бер колач югарылыктан башланып түшәмгә кадәр сузылган киң ачыклык — тәрәзә бар иде. Көндез аннан бүлмәгә яктылык төшә, һава керә, кичен, менә шундый мәҗлесләр вакытында шулай ук саф һава керә һәм өйдә янган пыскый төтеннәре, төрле аш-су исләре чыгып тора. Җырчылар әлеге тәрәзәнең ике ягына утырыштылар һәм кинәт кенә тынып калдылар да көтә башладылар.

Шул чакны кызу-кызу атлап ишектән өлкәнрәк яшьтәге бер хатын-кызның килеп кергәне күренде. Бу җырчы-биюче кызларның абыстасы... Фалия иде. Ул да, кызлары кебек, өстенә озын итәкле нәфис, юка тукымадан тегелгән күлмәк кигән. Тик аның күлмәге кызларныкына караганда бизәкләре белән аерылып тора. Күлмәкнең җиңнәре кыска, түше ачык, хәтта кирәгеннән артык ачыграк сыман иде. Колагына алтын алкалар, муенына кыйммәтле муенса таккан, иреннәренә, бит очларына шулай ук кызыл буяган. Кызларына караганда өлкәнрәк яшьтә булса да, ул әле чибәр һәм дәртле күренә.

Ашаучылар өстәленә якынаю белән матур елмаеп һәм үзен бик иркен тотып, ул сакага баш иде.

— Мака сар мине сиңа җибәрде, Карман сака, — диде. — Ашың тәмле булсын, йокың татлы булсын!

— Йокларга әле иртәрәк, Фалия, — диде Карман сака, көлемсерәп. — Җырлагыз, биегез — йокы качарлык булсын!

— Без җырласак, йокың түгел, алыпларың да качышып бетәр! — диде Фалия, шаяртып.

Карман сака алтын табактан итле генә бер кабырга алды да, өстәл аша үрелеп, атаклы җырчыга сузды.

— Тавышыңны бозмас микән? — дигән булды ул, шулай ук җиңелчә шаяртып.

— Кәефемне бозмаса, миңа шул җиткән, — диде Фалия, итле сөякне алып һәм кычкырып көлде дә, сөяген кимерә-кимерә, үзенең кызлары янына китеп барды.

Карман сакага аның көлүе бераз гына ясалма, тавышы да элекке кебек түгел, карлыккан сымаграк тоелды. Керфекләренә сөрмә тарткан, күз кабаклары тимеркүккә буялган һәм шунлыктан зур, серле күзле булып күренгән, чамасын белеп кенә төзәнә торган, чибәр, дәртле һәм кирәгеннән артык кыю, хәтта әрсезрәк булган бу абыстаны ул бик үк өнәп бетерми иде. Ул үзенең кемлеген һәм ниндилеген яхшы белә һәм бәяне дә алдан үзе әйтә һәм, аксөяк ирләр белән эш иткәндә, ничек тә күбрәк каерырга тырыша иде. Бу турыда Карман сакaның башкалардан да ишеткәне булды һәм шулай ук үзенең дә... кармакка капканы бар иде. Билгеле, яшьрәк чагында. Моннан фәлән еллар элек. Хәер, ул вакытта Фалия дә яшьрәк, чибәррәк иде. Чибәррәк кенә түгел, ут кебек, елан кебек иде!

Мака сар Карун Фалияне үзенә алып калганның беренче айларында чын-чынлап аңа гашыйк иде. Торабара ул аннан туйды.

Фалия исә мака сарның карасыннан бигрәк җизнинең кименә әйләнде. Фалиянең чыннан да чибәр дә, булдыклы да булуын күреп, җизни аны җырчы, биюче кызлар башлыгы ясады. Ул хәзер еш кына мака сар исеменнән аны һәм кызларны үзе теләгән кешегә, үзе теләгән мәҗлескә алып бара. Әле дә ул, мака сарга әйтеп тормыйча, Фалияне Карман сака катына китертте. Мака сарга бүген биюче, җыручы кызлар кирәкми. Аннан соң ул инде гомумән Фалия белән дә, башка биючеләр, җыручылар белән дә артык кызыксынмый иде. Ул элекке чибәр Фалияне онытып та бетергән иде бугай.

Җизнинең исә олуг каенишенә ничек тә бер яхшылык эшлисе килде. Карман сака боларның берсен дә белми. Чөнки аның күптәннән бирле Саркелдә булганы да, сарай гайбәтләрен ишеткәне дә юк.

Ачыккан алып ирләр, күзләрен дә күтәреп карамыйча, комсызланып ашаган-эчкән арада, шаян чибәр кызлар әкрен генә җыр башлап җибәрделәр. Күмәк җыр тиз генә оешып китә алмады. Әле уңнан, әле сулдан берсе сузыбрак, икенчесе сузмыйчарак, берсе ачыграк, икенчесе тоныграк авазлар белән җырлаган тавышлар ишетелде. Шул ук вакытта, берсен-берсе узарга тырышкан сымак, җиз кыллы арфалар, көмеш кыллы гөсләләр чыңлап-гүләп алдылар. Чынлыкта бу әле җырлау-көйләү түгел, бу бары кылларны һәм тавыш җепселләрен сынап карау гына иде бугай.

Ниһаять, Фалия сака биргән итне ашап, артыннан бор суы эчеп куйды да өстәлдә яткан сөлгегә кулын сөртте һәм тиз-тиз атлап кызлары янына килде һәм ягымлы тавыш белән җыр сузып җибәрде. Аның тавышы барлык тавышларны күмеп китте. Башкалар аңа җайлашып, дәртләнебрәк җырларга тотындылар.

Мөгешләрдә, җиз савытларда утлар янган, терәкләр арасындагы, дивардагы ачыклыктан кичке талгын һава агылып торган иркен өй эчендә кызларның күмәк тавышы моңлы булып, сагышлы булып талгын гына агылып торды. Бер җырны бетергәч, алар икенче җыр башлап җибәрделәр. Монысы дәртлерәк, җитезрәк көйле иде һәм алар монысын бирелебрәк башкардылар.

Ашаганда Карман сака җырчыларга бөтенләй диярлек игътибар итмәде. Тамагы туйгандай булгач, ул аратирә аларның тавышларына колак салгалап алды, аратирә шулай ук күз ташлап та алды. Кызларның җыры, уены аңа нишләптер тиз генә көйләнеп китә алмый сыман тоелды. Шул чакны ул, башын калкытып, Фалия ягына ымлады. Аның ымлавын, күз карашын кызлар шундук күреп алдылар, өстәлгә яны беләнрәк торган Фалиягә нидер әйттеләр дә Фалия ялт кына өстәл ягына борылып карады һәм авызын зур ачып җырлавыннан туктамыйча сака янына килде.

— Син чакырдыңмы мине, сөеклем? — дип җырлады Фалия, кызыл читле ап-ак сөлге белән авыз читен сөртеп утырган Карман сакага иелеп.

Бу сүзләрне ул җыр көен бозмыйча, җыр сүзләре кебек итеп әйтте. Карман сакага каршы якта утырган яшь алып ашавыннан туктап, күзләрен зур ачып, сокланып

Фалиягә карап тора иде. Аның шулай җырлап соравы аңа, күрәсең, бик кызык тоелды һәм ул тыела алмыйча көлеп җибәрде. Аның көлүен күреп, Карман сака да елмаеп куйды. Барысы да күңелләнеп, елмаеша-көлешә башладылар. Фалия, кыюланып, күңеле күтәрелеп һәм шулай ук көлә-көлә, нәфис кулы белән яшь алыпның диңгез җиле кискән бакыр муеныннан кочып алды.

— Кызларыңның тавышы чыкмый, — диде Карман сака Фалиягә. — Чакыр монда, тамак ялгап алсыннар.

Фалиягә шундый сүз генә кирәк тә иде. Ул тиз генә кызлары янына китеп барды, кулын күтәреп аларны табын янына чакырды. Кызлар чыр-чу килеп, көлешеп өстәл янына килделәр. Тартынып-нитеп тормыйча, кыю гына кыланып, кысылышып алыплар янына утырыштылар. Алыплар, аларга урын биреп, урыннарыннан кузгалдылар, өстәлдән читләшкәндәй иттеләр.

Кызлар утырышып беткәч, Фалия, гадәтенчә кыю һәм әрсез кыланып, туп-туры Карман сака янына килеп утырмакчы булды. Ләкин Карман сака шул чакны башкалардан аерылыбрак калган, бер читтәрәк басып торган яшь кенә бер кызны күреп алды. Ул аңа чибәр һәм ягымлы тоелды. Мака сарның җыручы кызларын сака яхшы ук белә иде. Ләкин яшь кызны аның беренче күрүе иде.

— Син әнә Шөгәйгә бик ошадың, — диде ул Фалиягә, үзенең каршысындагы яшь алыпка күрсәтеп.

Фалия аңлап алды. Аның йөзе чак-чак кына үзгәреп китте, ләкин шулай да үзенең күңелсезләнүен күрсәтмәскә тырышты һәм, уңайсыз елмаеп, урындыгын Шөгәй янынарак күчерде. Карман сака исә оялган яшь кызны үзе янына чакырды.

Кыз тартынып кына аның янына килде, күрсәтелгән буш урынга утырды һәм, ак нәфис кулларын күлмәк итәге аша йомрыланып калкып торган тезләренә куеп, башын иеп тынып калды. Ул гына түгел, өстәл янындагылар барысы да тынып калдылар.

— Башыңны күтәребрәк утырсаң, син тагын да матурланып китәсең, — диде Карман сака, кызга елмаеп.

Аның шулай дип әйтүе булды, кыз ирексездән башын калкытты, елмаеп сакага карады, кызарынып китте һәм, күрәсең, үзенең уңайсызлануын яшерү өчен, кычкырып көлеп җибәрде. Көлгәндә ак, тигез тешләре матур булып елтырады һәм як-якка тырпаеп торган чәчләре селкенеп куйды. Аннан күрмәкче дигәндәй, башкалар да — кызлар да, алыплар да көләргә тотындылар. Бары Фалия генә үзенең тойгыларын яшерә алмады һәм

бары аның гына кызылга буялган матур иреннәре йомык, нечкә кара кашлары кушылган килеш калды. Хәер, җизнидән башка аның йөзенә игътибар итүче дә булмады.

— Менә әйттемме! — диде Карман сака, мактанган сыман, ләкин чынлыкта кызның чибәрлеген мактап.

Аның бу мактавына кызлар тагын көлешеп алдылар.

— Син минем кызларымны сүз белән генә сыйламакчы буласың, ахрысы? — диде Фалия, көлешү туктагач, Карман сакага карап, кыюланып.

— Шулай икән шул, — дигән булды Карман сака. — Кызлар, җитешегез. Табында булганы — барысы да сезнеке!

— Безгә берни калмыймыни?! — диештеләр алыплар, көлешеп, шаяртып.

— Сезгәме? Сезгә табын да, кызлар да! — диде Карман сака.

Табын янындагылар янә гөр килеп көлешергә тотындылар.

Ул арада Карман сака үз алдындагы сырлап-бизәкләп ясалган озын аяклы алтын касәгә зур көмеш чүлмәктән бор суы агызды. Кызлар үз алларындагы табакларга иелеп ашый башладылар. Алыплар шулай ук ашауларын дәвам иттеләр. Үзенең касәсен тутыргач, сака җизнәсенә салды, аннары берәм-берәм башкаларның касәләренә кан төсендәге сыекланылган бор-шәраб койды. Башкалар ашаган арада шулай касәләрне тутырып чыккач, ул үз янындагы яшь чибәр кызга иелгәндәй итте дә:

— Чибәрлегеңнән күзем томаланып, сорарга да онытканмын — исемең кем синең? — диде.

Кыз, уяу киек баласы кебек, ашавыннан туктап, тиз генә башын калкытты, әле һаман оялган, матур күз карашын сакага текәп:

— Талия, — диде.

— Нинди матур исем! — диде Карман сака, чын күңелдән сокланып. — Кем кызы?

— Кәмәчеләр бистәсеннән чүлмәкче Галләмнеке, — диде Талия.

— Галләм кызы! — диде Карман сака, бераз гына гаҗәпләнү белән. — Атаклы Галләмнең шундый кызы бармыни?!

Ул моны үзалдына сөйләнгән сыман әйтте. Ләкин Талия, беркатлы буларак, аның һәр соравына җавап бирергә кирәк дип уйлап, үзе дә сизмәстән, «бар» диде. Тик шулай да бу мактану булып тоелмады. Карман сака уйланып калгандай булды. Ул хәтта Талиянең җава-

бын ишетмәде дә бугай. Чүлмәкче Галләмне Саркелдә белмәгән кеше юк иде. Чүлмәкче дип аталса да, аны бизәкче дип тә атарга була. Ул иң оста чүлмәкче дә, иң оста сурәтче дә. Аның төрле зурлыктагы, төрле рәвештәге чүлмәкләре бөтен Аклантитада иң яхшы, иң сыйфатлы исәпләнелә. Чит илләрдән килгән сатучылар аның кулы белән әвәләнгән, яндырылган һәм бизәлгән чүлмәкләрне аеруча яратып алалар. Аны шулай ук бик бай дип тә сөйлиләр. Ләкин шулай булса да, ул әнә Саркелнең иң атаклы кешеләре яши торган икенче боҗрада түгел, беренче боҗрада — кәмәчеләр бистәсендә яшәп ята.

— Чүлмәкче Галләм — данлы, атаклы, — диде Карман сака, үзалдына сөйләнгән сыман. — Шулай да нишләп әле булса ул кәмәчеләр бистәсендә яши соң? Мака сардан сораса, ул аны үзенә якынрак та күчерә алган булыр иде.

— Әтигә анда җайлы. Өйрәнгән җир, өйрәнгән урын, — диде Талия.

— Әниеңә ничек? — диде Карман сака.

— Әнинең ничек тә күченәсе килә, — диде Талия. — Мака сар рөхсәт бирсә, ул бернигә карамый күченергә әзер.

— Күченергә... яңа урын, яңа йорт сатып алырга, шулайдыр ич? — диде сака.

— Шулай, — диде Талия, — әти тагын шуннан курка: йорт өчен бер түләргә, мака сарга тагын түләргә кирәк булачак, ди. Каян алырмын мин шулкадәр акчаны, ди.

— Ничек мака сарга түләргә? Йорт өчен түләгәч җитмимени?

— Мин белмим, — диде Талия. — Әти әйтә, мака сарга күп итеп алтын бирергә кирәк булачак, ди.

Карман сака тынып калды. Мака сар Карунның шулай төрле эш, йомыш өчен үз кешеләреннән — лелегләрдән дә алтын белән бирем алуы турында элегрәк тә ишеткәләгәне бар иде. Ләкин ул моңа ничектер ышанып җитми иде. Түрәдә әйтелгән: мака сар да, сакалар да үз кешеләренә яхшылык, изгелек эшләгән өчен бирем алмыйлар, диелгән. Мака сар белән сакалар арасында, мака сар һәм сакалар белән лелегләр арасындагы һәртөрле алыш-биреш ике якның да килешүе буенча акчага эшләнелә, диелгән. Димәк, болай булгач, алтыннан күзе, акылы тонган мака сар үзе, вак-төяк сатучы, карак ялганчы кебек, бирем алучы булып чыга түгелме соң?! Моны болай калдырырга ярамый.

— Әниең өчен мин мака сардан сорасам, син нәрсә әйтерсең, Талия? — диде ул кызга иплап кенә.

— Әни бик сөенәчәк! — диде Талия, җанланып. — Ул мине шуның өчен мака сар сараена бирде дә.

— Җай чыгу белән берәрсенең колагына төшерерсең, дидеме? — диде сака.

— Шулай диде, — диде Талия, беркатлылык белән.

Бор шәрабы салынган зур корсаклы биек чүлмәк янда гына тора иде. Карман сака, аш-су хуҗасы буларак, озын аяклы алтын касәләргә эчемлекне үзе салды. Барысының да касәсен тутыргач, ул иң элек, гадәтенчә, Ут анага өлеш чыгарды, үзе эчте, аннан соң башкалар да күтәрделәр. Ашагач-эчкәч, кызлар да, алыплар да шактый җанланып, кыюланып киттеләр. Баштагы тартыну, уңайсызлану кул белән алгандай юкка чыкты. Өстәл янында әле анда, әле монда тыелып кына көлгән, күршеләргә ишеттереп сөйләшкән өзек-өзек сүзләр ишетелеп китте.

Шулай күңелле генә гәпләшеп утырганда, Фалия кинәт, нидер исенә килеп, урыныннан сикереп торды, үзенең кызларына бер үткен күз карашы ташлап алды.

— Туарылдыгыз, болай булмый. Хәзер үк кузгалыгыз! — диде ул, кызларны алыплардан читкә әйдәп.

Фалиянең холкын яхшы белгән җырчы кызлар эчелеп бетмәгән эчемлекләре белән алтын касәләрен өстәлгә куйдылар, авыз читләрен сөрткәләп, озын күлмәк итәкләрен төзәткәләп, каршылыксыз урыннарыннан тордылар. Уен кораллары булганнар уен коралларын алдылар һәм теләр-теләмәс кенә үз урыннарына таба кузгалдылар.

Кызларның китеп баруын алыплар бик үк килештереп бетермәделәр:

— Утырыгыз әле!

— Шушында гына җырлагыз! — дигән тавышлар ишетелде.

Фалиянең шулай тора салып кузгалып китүен Карман сака да аңлап җитә алмады. Хәер, ул аны аңлады да бугай, аңлаган нәрсәсенә ул ничектер игътибар итеп кенә җиткермәде, ахрысы. Фалиянең, билгеле, ничек тә Талияне сакадан читкәрәк алып китәсе килде. Аныңча, сака янында, һичшиксез, ул утырырга тиеш иде. Ләкин аны читкә кактылар. Ничек итеп ул үзенең күз алдында аларның көлешеп-сөйләшеп утыруына юл куйсын?! Булмаганны! Изге сарайга башы керсә, аягы кермәгән, шулай да хәзердән үк сакалар тирәсенә елыша башлаган Талияне ул хәзер җаны-тәне белән дошман күрде.

— Болай күңеллерәк ич, кузгалмагыз, — диде Карман сака, үзенең алыпларын яклап.

Фалия Карман сака сүзенә колак салмый булдыра

алмады. Бик тә ягымлы елмаеп ул сака янына кире килде, әлерәк кенә Талия утырган урындыкка утырды да, иркәләнеп һәм шул ук вакытта холыксыз бала-чага белән сөйләшкән сыман итеп:

— Син теләсәң, кузгалмабыз, — диде. — Шулай да минем кызларыма күп эчәргә ярамый. Алар яхшы җырларга тиеш. Алыплар янында булганда алар яхшы җырлый алмыйлар.

— Ярар, җырлагыз, — диде сака, Фалиянең ярым серле пышылдавына каршы килә алмыйча.

— Җырларбыз, — диде Фалия һәм кыюланып саканың сул як чигәсеннән үбеп алды, җиңүче төс белән елмаеп, урыныннан сикереп торды һәм, Карман сака аны-моны искәреп өлгергәнче, күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, ислемай исләре таратып, кызлары янына китеп барды.

— Мака сар белән дә... шулай микән бу Фалия? — диде Карман сака җизнәсенә, сул як чигәсен бармак битләре белән капшаштырып. Күрәсең, Фалиянең мондый кыланышларын күптән белгән җизнәсе артык исе китмичә көлемсерәп тик утырды.

— Алай гына түгел, кайчагында аннан да яманрак кылана ул мака сар белән, — диде җизни.

— Ничек кылана? — диде Карман сака, аңламыйча.

— Була инде... — диде җизни, ничектер турысын әйтергә теләмичә.

— Шулай да? — диде Карман сака, төпченеп. — Кеше алдында кыланамы, әллә үзләре генә калгачмы?

— Кеше алдында да, кеше артында да, — диде җизни, эчемлекле касәсенә тотынып.

— Элек яшьрәк чагында алай ук... оятсыз түгел иде бугай ул, — диде Карман сака.

— Элек ул болан кебек иде, хәзер арыслан кебек, — диде җизни һәм көлемсерәп өстәп куйды: — Шома йонлы ана арыслан кебек...

— Мака сар күрәме соң аның шундый икәнлеген? — диде Карман сака, аптырабрак.

— Син каладанерактарак шул. Мондагы тормышны инде онытып бетергәнсең. Беләсең килсә, ул аны уч төбендә биетә! — диде җизни, тавышын әкренәйтә төшеп.

— Кем кемне уч төбендә биетә?!— диде Карман сака, эчүеннән туктап, шаккатып.

— Шома йонлы ана арыслан карт ата арысланны, — диде җизни, мыскыллы көлемсерәп.

Карман сака, ышанмаганлыгын белдереп, коры гына көлеп куйды.

— Сез шуны күреп-белеп торасызмы? — диде ул.

— Күргәндә — күрмисең, белгәндә — белмисең, — диде җизни. — Син килми торган арада монда күп нәрсәләр булды. Син монда һаман элеккечә икән дип уйлый күрмә. Теге яшь кызны үз яныңа утыртып... ялгыштың син, каениш.

— Нәрсә сөйлисең? Булмаганны! — диде Карман сака, чак кына үртәлеп. — Фалиядән куркырга димисеңдер ич?

— Сиңа аннан куркуның кирәге юк. Шулай да Фалия кызыйны харап итәргә мөмкин.

— Бармак белән чиртеп кенә карасын! — диде кинәт Карман сака, үзалдына ярсып, кызарынып.

— Ул аңа, бәлки, бармак белән дә чиртмәс, шулай да син аны үз яныңда утыртма.

— Кемне?

— Талияне, — диде җизни.

Карман сака кычкырып көлеп җибәрде.

— Әллә нинди куркакка әйләнеп беткәнсез сез монда... биек коймалар, алтын сарайлар эчендә ятып, — диде ул, җиңелчә шелтә белән. Шуннан соң ул касәсен кулына алды да, җизнәсен кыстап: — Әйдәле эчик, булмаса, җизни, — диде.

Ачык тәрәзә яныннан кызларның дәртле, җиңел көйгә җырлаулары ишетелә башлады. Барысының да тавышын күмеп Фалиянең көчле, хисле һәм моңлы тавышы ишетелеп торды. Шәп җырлый иде Фалия! Мондый тавышлы хатын-кыз алдында баш имәү, аңа табынмау мөмкин түгел. Әлерәк кенә аны кыерсытуына, аны читкә тибәрүенә һәм аның турында яратмыйча сөйләвенә Карман сака чак-чак кына уңайсызланып китте. Ул үзенең ялгышын аңлагандай булды. Фалиянеке кебек тавыш, моң һәм хис өчен ир булган ир кеше дөньяда эшләп булмастайны да эшли алырга тиеш.

Тәрәзәдән кергән җиләс, талгын һава кебек, Фалиянең тигез агышлы тавышы өй эчен тутырып тирбәнде дә кинәт тынып калды. Карман сака белән җизни генә түгел, өстәл янындагы барлык яшь алыплар Фалиянең җырлавына сихерләнеп тынып калганнар, һәм барысы да җырчылар ягына борылганнар иде. Җыр туктау белән өй эчендә шактый вакыт тынлык сакланды. Кинәт барысы да берьюлы диярлек хәрәкәткә килде, барысы да шатланып эчке хисләрен белдереп шауларга, мактау сүзләре кычкырырга һәм кул чабарга тотындылар.

— Фалия! Яшә, Фалия! — дип кычкырдылар сихерләнгән яшь ирләр-алыплар.

— Менә күрдеңме?!— диде җизни, җиңүче төс белән елмаеп.

— Күрмәдем, ишеттем, — диде Карман сака, караңгы чырай белән.

Моннан өч йөз мең утыз биш ел элек тә хәзергечә, көндәгечә кояш чыкты. Таң атып, караңгы таралгач та, таулар, урманнар, үзәннәр аермачык булып күренә башлагач та, көнчыгыш якта — күк кырыенда — иң элек үзеннән-үзе яктылык барлыкка килде. Таулар, урманнар, ялгыз агачлар һәм таш йортлар әле булса йокыдан арына алмагандай тын гына оеп утырганда, үзәннәр өстендәге аксыл томан әле булса тарала алмый торганда һәм иксез-чиксез диңгез өсте кара-кучкылланып, хәрәкәтсез җәелеп ятканда, бары тик еpактагы тере нурның гына зурайганнан-зурая баруы үзе бер могҗиза иде.

Көмештәй якты нурга озакламый саргылт, кызгылт буяулар кушылды. Бер үк төсле соргылт, караңгы төсләр белән генә бизәлгән иртәнге манзара күз алдында үзгәрә башлады. Менә, ниһаять, диңгез сызыгы өстендә, еpактагы болыт шәүләләре арасыннан, эрегән алтын сыман булып, балкып, сихри нурлар бөркелеп чыкты. Алтын нурлар искиткеч бер җитезлек һәм кодрәт белән киң диңгез аша сузылды да Изгеләр утравындагы Изге калкулыкка иң элек мака сарның таудай биек итеп салынган сарай түбәсенә — андагы алтын гөмбәзгә килеп бәрелде. Алтынга алтын тиеп, тирә-якка тере, якты нур тамчылары чәчрәде. Күп тә үтмәде, Изге калкулыкның изгеләр яшәгән әле бер төшендә, әле икенче төшендә түбәләрдә, тәрәзәләрдә, биек коймаларда шатланып кояш нуры биеде.

Шулай итеп, Изгеләр атавында яңа көн туды. Яңа көн тууын белдереп, биек коймаларның әле бер төшендә, әле икенче төшендә җиз быргылар уйнады, бер-берсен узышып этәчләр кычкырды, әрәмәдә төн кунган изге Бука үкерде һәм агач башларында, өй кыекларында күк күгәрченнәр гөрләште.

Яңа көн туу белән, Саркелдә һәм изгеләр каласының барлык бистәләрендә кешеләр йокылы күзләрен ачтылар, аякларына бастылар һәм иң беренче эшләре итеп бөек Ланы күрергә ашыктылар. Көнчыгыш якта, диңгез астыннан калкып килүче тереклек иясенә күзләре төшү белән, изге Абаны котлап кулларын күтәрделәр, кычкырып, пышылдап йә булмаса ялынып-ялварып, аңа үзләренең теләкләрен юлладылар.

Карман сака соң ятса да, Саркелдәге, каладагы башкалар кебек вакытында торды. Башкалар кебек иң элек көнчыгыш яктагы тәрәзәгә юнәлде. Тәрәзә аша якты кояш нурын күреп, көндәгечә кулларын күтәрде һәм теле ачылу белән өйрәнелгән дога сүзләрен пышылдады. Бүтән вакытта, бигрәк тә үзенә кыен, күңелсез булганда яисә берәр куркыныч янаганда, ул әлеге сүзләрне, асыл мәгънәсенә төшәргә омтылып, ничек тә ихлас күңелдән әйтергә тырыша.

Бүген ул уйламыйча, борчылмыйча гына әйтте. Әйтергә кирәк булган өчен генә, әйтмичә калырга ярамаган өчен генә әйтте. Башка көннәрдәге кебек ул бүген кояшның югарыга күтәрелә баруына да, күктәге, диңгездәге төсләрнең үзгәрә баруына да исе китеп, сокланып карап тормады. Күз карашын шундук тирә-якка, кала өстенә юнәлтте. Алтын түбәләр, алтын коймалар, изге сыннар, биек таш йортлар һәм шул таш йортлар арасындагы купшы куаклар, биек агачлар, серле күләгәләр, бер-берсе белән кисешкән тар урамнар, сукмаклар — барысы да аңа күптән таныш, ләкин шул ук вакытта бераз гына ят һәм тансык иде. Бала вакыты аның шушы өйдә, шушы түбәләр, куаклар, сукмаклар белән бергә үтте. Кайчандыр моннан күп еллар элек тә ул менә шулай, тәрәзә төбенә таянып, еракларга карап торды, иртәнге саф, салкынча һаваны сулады, әтәчләр, тавыклар тавышына, Бука үкерүенә һәм сыерлар мөгрәвенә колак салды. Кайчандыр, моннан күп еллар элек тә, менә шулай тулысынча йокыдан уянып җитмәгән килеш карап, тыңлап, сулап торганда берәрсенең куаклар арасында кыштыр-кыштыр китереп сукмак себергәне йә булмаса берәрсенең иңбашына авыр чүлмәк күтәреп каядыр китеп барганы күренде, еракта манара башларында сузып-сузып җиз быргы кычкырткканы ишетелеп торды. Аста куаклар, агачлар арасында кычкырып кемнәрдер сөйләште, югарыда түбәдә, тәрәзә кашагаларында күгәрченнәр гөрләште.

Барысы да таныш, барысы да якын. Әйтерсең дөнья да үзгәрмәгән, ел артыннан еллар үтеп, вакыт та үзгәрмәгән. Хәер, өстән караганда гына шулай бугай ул, үзгәрешне, яңалыкны күрергә-белергә теләмәгән өчен генә шулай бугай. Кояш чыгуы да, иртәнге тынлык, салкынлык та, алтын түбәләр, юллар-сукмаклар да, билгеле, һаман да әүвәлгечә. Ләкин аның гына — Карман сакаыың — хисләре-тойгылары һәм теләк-омтылышлары инде күптән әүвәлгечә түгел. Элек ул, малай чагын-

да, менә шулай тәрәзәдән карап торганда да, бөек Ладан бигрәк яңадан кире җылы урынга барып яту турында, рәхәтләнеп яңадан бер йоклап алу турында хыяллана иде. Кайчагында аңа бу һич тә тормышка ашмастай хыял булып тоела торган иде. Аннан соң ул әнисе турында, әнисенең җылы куенына кереп, бөгәрләнеп янә дә йоклап алу турында уйлый иде. Үсә төшкәч, кәмәгә утырып, диңгез аша чыгып, һичшиксез, кояшның диңгез астыннан чыгып килгән чагын якыннанрак карау турында хыяллана иде. Ничек чыга ул? Каян чыга? Бит ул шундый җылы, кайнар — диңгез суы нишләп кайнамый икән дә нишләп бу булып күккә күтәрелми икән? Бу турыда аның әнисеннән дә, өлкәннәрдән дә сорап караганы булды, ләкин беркем аңа тиешенчә аңлата алмады. Әллә аңлатырга теләмәделәр микән? Өлкәннәр бит алар күп нәрсәне балаларга әйтмәскә тырышалар. Ләкин аның беләсе килде, барысын да үз күзләре белән күрәсе килде.

Ул инде күрде, бик күп нәрсәне үз күзләре белән күрде. Дөньяның читенә, кояш чыккан төшкә үк барып җитә алмаса да, шулай да җирнең, суның әллә нинди төбәкләренә барып чыкты. Менә ул яңадан монда, туган каласында, дөньяда иң якын, иң изге җирдә. Ул җиңеп кайтты, бик күп байлык, мал, кара алып кайтты. Агасы сөенәчәк, сөенми мөмкин түгел. Бүген дә, моннан соң да бөтен Аклантита илендә ул — иң зур җиңүче. Бүген аның иң бәхетле көне.

## IV

Мәмлине алты яшеннән Типкә би карамагындагы ир балалар әндериенә бирделәр. (Әндери — хәрбиләштерелгән балалар, үсмерләр төркеме.) Бөтен каладан кечкенәләр әндериендә егерме бала җыелды. Биш ел буена алар үзләреннән биш-алты яшькә өлкәнрәк үсмерләрнең йомышчысы, булышчысы булып йөрделәр. Иң элек алар өлкәннәр янына утырып ашарга-эчәргә, өлкәннәрнең вак-төяк йомышларын үтәргә, ашаган табак-савытларын юарга, коралларын карарга-сакларга өйрәнделәр. Тора-бара өлкәннәр өчен дә, үзләре өчен дә аш-су пешерә башладылар, кулларына балта-пычак тотып кисә, юна башладылар — уенчык кораллар эшләделәр йә булмаса камыштан яңа куыш ясауда катнаштылар. Елдан-ел алар башкара торган эшләр, йомышлар, бурычлар катлауланганнан-катлаулана барды. Әкренләп алар ко-

рал тотарга да, төрле сугыш, көрәш алымнарына да өйрәнделәр. Яланаяк, яланбаш көе эсседә, суыкта, яңгырда бер-бер артлы тезелеп, корал тотып ерак аралар үттеләр һәм биек тау башларына, шома кәүсәле агачларга үрмәләделәр. Аларны шулай ук йөзәргә, атта йөрергә һәм үгез өстендә сикереп уйнарга өйрәттеләр. Алар бары олы туй һәм бәйрәмнәрдә генә, өйләренә кайтып, ата-аналарын һәм туганнарын күреп килделәр дә кышкы суыкларда гына биек, иркен өй эчендә, учак янында утырдылар. Мондый чакта алар җырга-биюгә һәм санарга өйрәнделәр, озын җырулар һәм дастаннар ятладылар. Башка чакта ел тәүлегенең теләсә кайсы вакытында алар тышта, кырда-яланда йә булмаса суда-диңгездә булдылар.

Аклантитаның изге патшалары — мака сарлар — Алтын Уртада изге ташка уеп яздырган изге язуда лелег яшьләре бала чактан ук чыныгып, теләсә нинди кыенлыкларны, теләсә нинди дошманны җиңәрлек кыю һәм батыр булып үсәргә тиешләр диелгән иде. Мәмлиләр нәкъ менә шундый чыдам, кыю һәм батыр булып үсәргә тырыштылар да инде. Биш-алты ел йомышчы-булышчы булып йөргәннең соңында, алтынчы елны аларның үзләренә йомышчы малайлар бирделәр. Үзләренең һәртөрле күнегүләрен туктатмыйча, алар хәзер юеш борынлы бүлтерекләрне өйрәтә башладылар.

Аларның барысына да — кечкенәләргә дә, өлкәнрәк үсмерләргә дә — Әмәк атлы пир ата баш булды. Чи утынга ут кабызып яңгыр астында казан асарга да, төрле корал ясарга да, йөзәргә, йөгерергә, сикерергә, ук-сөңге атарга да — барысына чынлыкта аларны бер кеше — пир ата өйрәтте. Пир ата ун ел буена һәркемнең иң якын кешесенә, ата-анасыннан, туганнарыннан да якынрак киңәшчесенә һәм сердәшенә әверелде. Ләкин бу вакыт эчендә һәркемнең пир атадан башка якыннары да барлыкка килде. Ун ел буена бергә торып, бергә ашап, бергә төрле уеннарда катнашып, аларның бик якын дуслары-иптәшләре барлыкка килде. Алай гына да түгел, алар егерме үсмер үзара да бик дус, тату бер әндери төркем булып җитештеләр. Аларның бу дуслыгы хәтта туганлык якынлыгыннан да көчле булды. Бер-берсе өчен алар утка-суга керергә, теләсә нинди дошманның бугазын чәйнәп өзәргә әзер кебекләр иде. Бит аларны мәңгелек йола да, пир ата да нәкъ шуңа — дуслыкка-татулыкка, үзара ярдәмләшүгә өйрәтте. Үсмерләрнең кайберләре үзара мәңгелек ант эчтеләр. Дөрес, бу хакта алар бик

шауламыйлар. Моны алар бары үзләре генә белә. Бу шундый изге нәрсә, моны ант эчүчеләрдән башка беркем күрмәскә, сизмәскә тиеш дип исәпләнелә. Ләкин шуңа да карамастан кемнең кем белән дус булуын, кемнең кем белән ант эчешүен үсмерләр әйтмичә дә бик яхшы беләләр. Андый нәрсә шундук кешенең йөзенә чыга, сүзендә, кыланышында, үз-үзен тотышында сизелә башлый.

Зөлмәт белән Мәмли дә менә шундый яшерен ант эчәр дәрәҗәдәге якын дуслар булдылар. Бу дуслык өлкәнрәк төркемнең өченче елларында көчәеп китте. Еш кына Мәмли дусты Зөлмәт белән ант эчү турында уйлый башлады. Зөлмәтнең дә, икәүдән-икәү генә калгач, пышылдап кына бу турыда сүз ачкалаганы булды. Ләкин башкаларныкы кебек аларның дуслыгы шулай да ант эчүгә, бер-берсенең тәнен җәрәхәтләп, бер-берсенең канын татуга кадәр барып җитмәде. Көтмәгәндә алар арасына салкын җил үтеп керде.

Ир балаларны бала чактан ук батыр, эшчән, булдыклы, кыю кешеләр итеп тәрбияләргә тырышкан лелегләр кыз балаларны да исләреннән чыгармыйлар. Ир балалар тулысынча аталар, ирләр карамагында булган кебек, кыз балалар тулысынча аналар, әбиләр карамагында булды. Билгеле бер яшькә җиткәч, кыз балаларны да махсус төркемнәргә җыйдылар. Алар анда булачак аналарга кирәк булган серләргә, эрләү, туку, тегү-чигү кебек кул эшләренә өйрәнделәр. Күбрәк вакытларын алар калада — түбә астында йә булмаса бакчада, агач күләгәсендә үткәрделәр. Ләкин таурлар илендә лелегләр каласын кыргый кабиләләр чорнап алган иде. Алар белән ике арада бәрелешләр булып тора һәм беркайчан да яу куркынычы юкка чыкмаган, көн тәртибеннән төшеп калмаган иде. Шуңа күрә би дә, каланың өлкәннәре дә ир балаларны гына түгел, кыз балаларны да кыю, нык рухлы, чыдам итеп тәрбияләүгә бик нык игътибар иттеләр. Шул максат белән еш кына кыз балаларны да әледәнәле кырга-яланга алып чыктылар. Алар да атта йөрергә, йөзәргә, йөгерергә, сикерергә өйрәнделәр һәм һәртөрле гимнас уеннарда катнаштылар. Кыскасы, булдыклы хатын һәм ана итеп кенә түгел, үз кызларын лелегләр батыр сугышчы итеп тә тәрбияләргә тырыштылар.

Хатын-кыз буларак, тәрбияче аналар, билгеле, үз кызларының матурлыгы турында да онытмадылар. Син никадәр батыр һәм кыю булма, әгәр син дөньяга кыз кеше булып тугансың икән, яшь ирләрнең күз явын алыр-

лык, башын әйләндерерлек чибәр түгелсең икән, син беркайчан бәхетле булмаячаксың. Яисә, аллам сакласын, гомер буена кысыр, ялгыз калачаксың. Андыйларның урыны ишек төбендә, аяк астында.

Менә шуңа күрә аналар кызларының батырлыгына гына түгел, матурлыгына да бик нык игътибар иттеләр. Бу мәсьәләдә аларның әллә нинди хәйләләре, әллә нинди серләре һәм осталыклары бар иде.

Яшь кызларның сәләтен, булдыклылыгын тикшерү һәм аларның күңелен күтәрү өчен әледән-әле һәртөрле сынаулар-ярышлар үткәрелде. Бу сынаулар-ярышлар башлыча борынгы йолаларга, дингә кагылышлы рәвештә үткәрелә иде.

Ярышларның иң зурысы, иң тантаналысы җәй узгач, яңа арпа өлгергәч була. Арпа урагына төшкән беренче көнне бөтен калада Арпа ана туе уздырыла. Беренче көн урылган яңа арпа аеруча изге санала. Урылган башакларны уып, шул ук көнне беренче он тарталар һәм изге күмәч — әнәчә пешерәләр. Беренче арпадан изге ботка — карга боткасы пешерелә һәм изге әчемлеккә — сырага баш салына. Арпа туе өч көн буена дәвам итә. Өч көн буе бөтен кала ял итә, туй итә. Аксөякләр зурлап аш-су ясыйлар, бер-берсен кунакка чакыралар, колларга, караларга карата ягымлырак, юмартрак булырга тырышалар. Кала уртасында би өенә каршы түгәрәк мәйданда һәм таштан өеп ясалган биек сикедә яшьләрнең җыры-биюе була. Кала янында төрле уеннар, ярышлар үткәрелә.

Кала халкы шулай Арпа туен зурлап, олылап, күңел ачып уздыра да, өч көн үткәч, ныклап торып уракка төшәләр. Урак вакытында арпаны бары ир затындагы коллар, каралар гына ура. Кала аксөякләренә, хатынкызга, бала-чагага да эш җитәрлек була. Коралллы ирләр туктаусыз каланы һәм ашлык басуларын саклый, яшьләр күбрәк үз эшләре белән булалар. Кечкенә балаларны — малайларны кулларына чүлмәк тоттырып, урылган җирдәге башакны җыярга чыгаралар.

Арпа урагына төшкән чакта һәр елны шулай була. Бик күпләр өчен ул быел да шулай булды. Бары тик Мәмли өчен генә быелгы Арпа туе башкачарак булды.

Беренче башак туе һәр елдагыча Аккала урнашкан калкулык астында, Аксу елгасы диңгезгә килеп койган төштә, иркен болында булды. Иң элек кече яшьтәге кыз балалар, малайлар үзләренең төрле һөнәрләрен күрсәттеләр. Җырладылар, биеделәр, йөгерделәр, сикер-

деләр. Кечкенәләрдән соң өлкәнрәкләр чыкты. Иң ахырда, төштән соң, уртага өлкән яшьләр чыга башлады. Кыз балаларны да, ир балаларны да — һәр чыгышны халык шаулатып, кул чабып яисә кычкырып алкышлап утырды. Аеруча тәэсирле чыгышлардан соң бик озаклап кул чаптылар.

Арпа ана туенда булачак ярышларга Мәмлиләр җәй буе әзерләнделәр. Ул көнне туйда, халык алдында нинди ярышлар буласы алдан ук билгеле була. Алар ерактан багана башына эленгән түңгәләккә ук аттылар, иске саламнан ясалган балбал карачкысына сөңге ыргыттылар. Аннан соң йөгерештеләр, бил алыштылар һәм иң ахырда йодрык белән сугыштылар.

Мәмлиләр төркеме мәйданга чыккач, халык уртагарак җыела төште, кысыла төште һәм шау-шу тынып калды. Болар бөтен каланың быелгы буй җиткән яшьләре, озакламый кемнеңдер кияве булачак егетләр иде.

Ук атуда, сөңге ыргытуда һәм йөгерүдә яшьләрнең барысы да катнашты. Бишнең өч төрендә җиңеп чыгучыларны сайлап алып бил алышырга куштылар. Бил алышучылардан башта дүрт кеше сайланып калды, аннан соң иң батырлар икегә калдылар.

Болар Зөлмәт белән Мәмли иде. Алар болай да башкаларга караганда буйга калкурак, тазарак та иделәр. Иң ахырда алар гына торып каласын күпләр алдан ук белеп тордылар. Иң кызыгы, иң әһәмиятлесе Зөлмәт белән Мәмли көрәше булачагы алдан ук билгеле иде. Моны алар үзләре дә бик яхшы белделәр һәм алдан ук бу ярышка ныклап әзерләнделәр.

Башка ярышларда да, күнегүләрдә дә иң ахырга гел алар кала һәм ахырда алар бер-берсен җиңә алмыйча шактый озак азапланалар, көч түгәләр иде. Тик шулай да Зөлмәт көчлерәк, ахрысы. Ул шулай ук холыксызрак, үпкәчел һәм көнчел дә иде бугай. Мәмли, им өендә яралган атасыз бала буларак, бабасы йортында үсте. Зөлмәт үзенең көчлерәк икәнен белә һәм инде ничә көн менә алдан үзенең көндәшен җиңү турында хыяллана. Хәер, алай артык хыялланмады да бугай. Ул моның шулай булачагына чын күңелдән ышанды. Чөнки башкача булырга мөмкин дә түгел. Чөнки Сурияне ул инде күптән яратып йөри. Бил алышта Зөлмәт Мәмлине чыннан да җиңде — кулындагы сөңгесе белән күкрәгенә китереп кысты һәм, җирдән тартып алып, баш аркылы күтәреп орды. Тапталып беткән каты җир дөпелдәп китте, тау битен тутырып утырган халык аһ итте, шаулатып, кыч-

кырып җибәрде һәм пир ата Зөлмәтнең җиңгәнлеген белдереп аның сөңгеле уң кулын югары күтәрде.

Беркадәр хәл алгач, тын алгач, алар йодрык сугышы башладылар. Алар икесе дә яланаяк, ярым шәрә, кара чәчләре өч толымга озын итеп үрелгән, җәй буе шәрә йөргән, кояшта кара янган күкрәкләре, беләкләре таш кебек каты иде. Көрәш башланыр алдыннан ярдәмче малайлар аларга күн бияләйләрен китереп бирделәр. Һәркем бер-берсенә кырын күз белән генә карап, бер-берсен күздән ычкындырмыйча яхшылап күн бияләйләрен киделәр, йодрыкларын йомарладылар. Йомышчы малайлар бияләйләрне беләзек турысыннан махсус бияләй каешы белән кысып бәйләп куйдылар. Пир ата уртага чыгып кул селтәгәч тә, ике яшүсмер шундук йодрыклары белән шап та шоп бер-берсен тукмарга тотындылар.

Бу юлы да аларны тын да алмый меңләгән күзләр күзәтеп утырды, йә булмаса берәрсенә теләктәшлек белдереп, үзләренең хисләрен сиздереп, бөтенесе бердәм аһылдап куйдылар, яисә кинәт кенә кычкырып җибәрделәр. Ирәннәр инде шактый арыганнар иде. Шулай булса да беркемнең дә бирешәсе килмәде һәм алар, әле берсе, әле икенчесе кызып китеп, бер-берсен тукмауларын дәвам иттеләр.

Башлыча Зөлмәт һөҗүм итте. Мәмли исә йодрыклары белән битен каплап, сакланырга гына тырышты.

— Хәл җыя, хәл җыя! — диделәр белгечләр Мәмли турында.

— Тукма ныграк, тукма! — дип кычкырдылар икенче яктан, Зөлмәтне дәртләндереп.

Сәхнәдәгеләр аларны ныклап ишетмәделәр дә. Алар, ялан аяклары белән таптанып, беләк тычканнарын нык кабартып, әледән-әле бер берсенә очынып кунып алдылар. Кинәт Мәмлинең уң як яңагына, күз турысынарак, таш кебек авыр йодрык килеп тиде. Мәмлинең күзеннән очкыннар чәчрәп китте һәм ул, аңын җуеп, каядыр төпсез бушлыкка мәтәлде.

Зөлмәтнең сул кулы да, уң кул кебек, көчле һәм саллы иде. Мәмли, ахрысы, менә шуны онытып җибәрде. Баштүбән бушлыкка мәтәлгәндә, ул бары шул турыда уйларга гына өлгерде. Аннан соң, бик еракта булып, колак төбендә нindидер күк күкрәгән тавыш ишетелде. Шуннан соң бөтен дөнья тынып калды. Күпмедер вакыттан соң сул як күзен ачып караса, ул, үз алдында нindидер ят кешеләр, ят күренешләр күреп, шактый

гаҗәпкә калды. Ниндидер яшь, чибәр егет шатланып нидер кычкыра һәм тау битендәге кемгәдер кул болгый. Үрелгән озын чәч толымы күкрәгенә салынып төшкән, битеннән шыбырдап тир ага, киң күкрәге күрек кебек бер күтәрелә, бер төшә.

Ул аңа озак карый алмады, бик каты авыртуга түзә алмыйча, күзен яңадан йомды һәм яңадан онытылып китте. Ләкин бераздан аның яңадан әлеге егетне күрәсе килде. Бу юлы егет янында ул башаклары белән аска каратылган арпа көлтәсе күреп алды. Баштарак ул берни аңламады. Башаклары аска каратылган көлтә нишләптер кыймылдый, тирбәнә иде, һәм иң гаҗәбе шул, ул көлтәнең кешенеке сыман ике аягы бар иде! «Саташам бугай» дип уйлады ул, артык пошынмыйча гына. Шулай да аның мондый нәрсә белән килешәсе килмәде — Мәмли болай да үзсүзле һәм үҗәт кеше иде. Ул күзләрен ныграк ачып карады һәм шул чакны әлеге башы аска каратылган сәер көлтәнең көлтә булмыйча, көлтә сыман итеп биленә арпа сабаклары бәйләнгән кеше икәнлеген шәйләп алды. Ул кешенең башында да шундый ук арпа көлтәсе тырпаеп тора. Ләкин башындагы көлтәнең башаклары аска таба түгел, югары каратылган иде.

«Арпа ана бит бу!» дип уйлады шунда Мәмли сөенү сыман бер тойгы белән. Арпа ана... булып киенгән кыз... каланың иң чибәр, иң булдыклы кызы иң батыр егетне котларга килгән. Әнә ул матур куллары белән алтын табак тоткан. Табакта — яңа арпа оныннан пешкән әнәчә. Әнәчәне ул быелгы батырга — теге ят егеткә бирде... Димәк, алар быел... өйләнешәчәкләр... каланың иң батыр егете белән иң чибәр кызы...

Җирдә кузгала алмый сузылып яткан, җиңелгән яшь егет күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ул нишләптер үкенмәде дә, әрнемәде дә, хурланмады да. Аның яңадан уң як чигәсе бик каты авыртты. Ул яңадан күзләрен йомды һәм шул чакта ниндидер чит нәрсә булып күңелендә сәер бер тойгы калкып калды. Арпа анасы булып киенгән кыз аңа... Сурия булып тоелды. Сурия батыр егеткә әнәчә бирде. Мондый нәрсәнең булуы мөмкин түгел! Бу, билгеле, төш кенә булырга тиеш.

Аңын җуйган Мәмлине, читкә алып һәм дүрт тәгәрмәчле арбага салып, калага алып кайттылар.

Мәмли әле аңын җуйды, саташты. Кайчакта күзләрен ачкандай итеп, нәрсәнедер исенә төшергәндәй булды. Аның туктаусыз башы авыртты. Бәйләнчек нәрсә булып һаман бер үк күренеш пәйда булды. Мәмли хәзер

аның өнме-төшме икәнен дә аермады — Зөлмәт Мәмлидән кычкырып, эче катып көлә, имеш! Кайчан булды соң әле бу? Бик күптән, бала вакытта ук булды түгелме соң? Нишләп зур Зөлмәт болай көлә икән соң?

Көндәгечә иртән кояш чыкты. Күп тә үтмәде, үзән уртасында оя-оя булып утырган камыш куышлардан йокылы ирәннәр атылып чыга башладылар. Алар яшьләр иде, анадан тума шәрәләр иде. Битләренә төшкән озын чәчләрен артка сыпырыштырып, ачылып җитмәгән күзләрен уыштырып алар ут капкандай читкә йөгерделәр.

Куышлардан бер ярты чакрым чамасы ераклашкач та, шәрә яшьләр Аксу елгасына килеп төртелделәр. Вак ташлар өстеннән шаулап, ашыгып аккан елга артык киң дә, тирән дә түгел иде. Тик аның ярлары гына текә иде. Ирәннәр, бер-берсен узышып, шыбырдашып, яр астына коелдылар. Берәүләр, һау-һаулап, кычкырып, бар көченә аска сикерде һәм исән-имин җиргә баскач, су чәчрәтә-чәчрәтә елга аша чыкты да каршыдагы ярдан өскә үрмәли башлады. Икенче берәүләр, сикереп тормыйча, яр битеннән шуышып кына төштеләр һәм, эре ташлар өстеннән зур-зур атлап, шулай ук икенче якка омтылдылар. Кайберәүләр ялгыш басып аякларын авырттырдылар, кайберләре мәтәлеп китте. Арада бер-берсенә бәрелешеп, җиңелчә генә, тавыш-тынсыз гына йодрыклашып алучылар да булды. Икенче якта тигезлек әкренләп үргә күтәрелде. Ирәннәр, яр өстенә килеп менгәч тә, кызулыкларын киметмәскә тырыштылар. Шулай да үргә каршы йөгерү җиңел булмады. Йөрәкләр ешрак типте, куллар ныграк селтәнде, адымнар әкренәя башлады.

Бернинди куак-фәлән үсмәгән, ачык, шома калкулык башына, яртылаш җиргә күмеп, киң авызлы чүлмәкләр утыртып куелган иде. Чүлмәкләргә исә башаксыз уклар — бер башы кызылга буялган шома таякчыклар тутырылган. Шунда ук чүлмәк янында кырыс йөзле өлкән яшьтәге күзәтчеләр басып тора. Калкулык башына менеп җиткән һәркем чүлмәкне әйләнеп үтә һәм бер ук таягын әләктерә дә алдын-артын карамыйча кирегә йөгерә.

Аксу аръягындагы камыш куышларга җитәргә бер ике йөз-өч йөз адым кала аларны калкулык башындагы кебек үк кырыс йөзле өлкән яшьтәге багалар каршы алалар. Кызарынган, еш-еш тын алган ирәннәрнең һәркайсы багага кулындагы таякчыгын тоттырды, исемен әйтте. Бага аның исемен кулындагы такта кисәгенә билгеләп куйды. Тактага исеме билгеләнгән ирән шун-

дук читкә китеп барды, тиешле урынга килеп чүгәләде дә иркенләп йомышын үтәргә тотынды. Аның бу эшен шулай ук күзәтчеләр карап тордылар.

Мәмли ул иртәдә үзен иң бәхетле кеше итеп сизде. Йокыдан ул иң беренче кеше булып уянды, куышыннан иң беренче булып чыгып йөгерде һәм елга аръягындагы чүлмәкләр янына да иң беренче булып барып җитте. Тигез җирдән йөгереп барганда да, ярдан сикереп төшкәндә, су аша чыкканда да — беркайда да төртелмәде дә, каты нәрсәгә дә басмады. Башаксыз укны ул шулай ук күзәтчегә иң беренче булып китереп тоттырды. Сөенеченнән елмаеп тиз генә як-ягына каранып алды — якында да, еракта да елга ягыннан килүчеләр арасында әле куышлар янындагы күзәтчеләргә якынайган беркем күренмәде. Барлык иптәшләрен ул ким дигәндә кырык-илле адымга артка калдырган иде.

Мәмли үзен җиңүче итеп тойды. Аңа бик тә күңелле булып китте. Әгәр бага кушса, ул хәзер берни уйлап тормыйча яңадан йөгереп китәр һәм, яңадан елга аша чыгып, чүлмәктән тагын бер ук алып килә алган булыр иде. Аңа, билгеле, андый боерык бирүче булмады. Эшен бетергәч ул, тәмам тынычланып, күтәренке күңел белән шулай да елгага таба китте. Хәзер инде яхшылап юынырга кирәк иде. Булачак алып ир теләсә нинди кыенлыкны җиңә ала торган, батыр, таза һәм тәвәккәл генә түгел, ул чиста һәм чибәр дә булырга тиеш.

Ул багалардан ераклашып өлгермәде, ниндидер ямьсез тавыш ишетеп, ялт кына артына борылып карады. Шул чакны ул усал баганың кемнедер камчы белән сыдырганын күреп алды. Бага бар көченә сукты һәм шундый ярсып сукты, Мәмли җидедән үргән камчыны үз тәнендә тойгандай булды. Ул сискәнеп китте, ирексездән кире килде. Бага камчысына эләккән яшь ирән аның күршесе Үти булып чыкты. Үтине шәп кеше дип булмый, билгеле, шулай да аның эчен тотып җирдә бөгәрләнеп ятуын күрү дә күңелле түгел иде. Чүлмәкле калкулыктан кайтканда, ул, егылыпмы, кулындагы угын сындырган икән. Җитмәсә, шәрә тәненә камчы төшкәч, куркудан, авыртудан ул астына да җибәргән иде. Болай булгач, Үтинең эшләре шәптән түгел, болай булгач, аны тагын йөгертәчәкләр. Бер кеше исә бөтен алайны тоткарлаячак иде.

Шул тирәдәге ирәннәр Үтине кызганудан бигрәк аңа ачуланырга тотындылар. Төрле яктан кычкырган тавышлар ишетелде. Мәмли күршесен якламакчы булды.

Жиңүче булгач, ул ничектер онытылып китте һәм бага алдында күршесен якларга кирәк тапты.

— Берлеккә кичерегез аны, бага! — диде ул күзәтчегә.

Күзәтче үзенә акыл өйрәткәннәрен яратмый иде. Жиңүче Мәмлигә ул бары күтәрелеп кенә карады да, йокылы дәртсез тавыш белән:

— Алай бик кызгангач, барыгыз икегез йөгерегез, — диде. — Яныннан булышып барырсың. Карап бар — тагын егыла күрмәсен, суны пычратмасын...

Аның шулай дип әйтүе булды, ирәннәр шаркылдап көләргә тотындылар. Мәмли авызын ачты да калды. Ул телләшеп, карышып торуның мәгънәсез икәнен аңлады. Ул кып-кызыл булды һәм әле булса аягына баса алмаган Үтинең кулыннан тотты да торырга булышты.

— Әйдә! — диде ул аңа, аягына басарга булышып. Алар яңадан йөгерделәр, һәм яңадан ук алып килгәнче шактый вакыт узды. Икенче мәртәбә килгәч, күзәтче Мәмлигә:

— Бүгенге җиңүең саналмый. Икенче кирәкмәгән җиргә кысылмассың, — диде.

Мәмлинең йөзе агарынып китте. «Нишләп саналмый?» — дип әйтәсе килде аның. Ләкин ул телен тешләп тынып калды — өйрәтүчеләр белән телләшүнең нәрсә икәнлеген инде аңлаган иде. Аның ачуы килде. Күзәтчедән бигрәк аның күршесе Үтигә ачуы килде. Хәер, ул аны элек тә яратып җиткерми иде.

Ул көнне барысы да Мәмли белән Үтидән көлделәр. Бигрәк тә Мәмлидән көлделәр. Аның өлгерлеген, җитезлеген һәм һәрвакыт диярлек өстен чыгуын кайберәүләр яратып җиткермиләр иде. Еш кына аннан көнләшәләр һәм җае туры килгәндә аяк чалырга тырышалар иде. Аеруча Зөлмәт куанды. Җиргә тәгәри-тәгәри көлде, эчен уа-уа көлде.

Мәмли эндәшмәде. Үзеннән көлүчеләргә ул ачыктан-ачык ачулана да алмады, шул ук вакытта әлегә ачуын да йота алмады. «Күрсәтермен әле мин сезгә күрмәгәнегезне!» дип уйлады ул, әледән-әле үзеннән көлүчеләргә янап. Бу хәлләр эндеригә алынуның беренче елларында булган иде.

Өч көн буена калада туй иттеләр. Кешеләр яңа арпа оныннан күмәч пешерделәр, яңа арпа ярмасыннан ботка пешерделәр һәм яңа арпадан ачытырга сыра куйдылар. Шуның янына хәлле хәленчә куй суйды, аш-су ясады. Өч көн буена калада, якын тирәдә, диңгез буйларында көнелле шау-шу, уен-көлке, җыр-музыка ишетелеп торды.

Өч көннән соң бөтен кала ныклап торып уракка тотынды. Җиргә, игенгә кагылышлы эшләрнең барысы да изге санала. Арпа уруны да барлык йолаларны саклап, җиренә җиткереп башкарырга тырыштылар. Һәркемнең өендә, чормасында әле борынгылардан калган таш ураклар бар иде. Күптән инде таш ураклар белән урмасалар да, беренче кишәрлекне бары таш урак белән генә урдылар һәм аны иң элек йорт башы, ата кеше, би кеше башкарды. Шуннан соң беренче кишәрлекнең арпасын бик кадерләп җыеп, көлтәләп һәм көлтәләрне, ишәк сыртына салып, калага алып киттеләр. Шуннан калган барлык эшне ир затындагы каралар, коллар башкарды.

Иген игү эше тулысынча ирләр эше санала иде, шунлыктан арпа кырына хатын-кызлар якын да килмәделәр. Ләкин урак вакытында һәркемгә эш җитәрлек булды. Берәүләр урылган ашлыкны калага ташып торды, икенчеләре ындыр табагында эшләде, өченчеләре сугылган ашлыкны җилгәреп, киптереп тирән чокырларга тутырып торды. Бары тик диңгез буенда, елга тамагы буенда кәмә ясаучы балта осталарын гына эшләреннән аермадылар — ул якта иртә таңнан алып кичкә кадәр балта тавышы ишетелеп торды.

Кала саклауны һәм арпа басуындагы уракчыларны саклау эшен кораллы ирләр белән бергә яшьләргә дә йөкләделәр. Мондый чакта кыргый таурлар, искәрмәстән килеп чыгып, йә уракчыларны, йә ашлык ташучыларны кырып ташлыйлар һәм урылган ашлыкны урлап качалар иде.

Яшьрәк үсмерләр алаен тәҗрибәле ирләр җитәкчелегендә коймага һәм манарага куйдылар. Быел соңгы елы булган Зөлмәтләр эндериен урак басуына җибәрергә булдылар. Типкә би, үзенең бер-ике кешесен ияртеп, иртәдән башлап кичкә кадәр ат өстендә килеш, әледәнәле барысын күзәтеп, тикшереп йөрде. Аның үзенең ун пирәйөз арпасы, утыз пирәйөз бодае, борае, тарысы һәм башка ашлыклары, яшелчә-җимешләре бар иде. Ул би һәм кала башлыгы буларак мондый чакта үз җирләренә, үз колларына гына түгел, бөтен ил-көнгә күз-колак булырга, кирәк чакта башкаларга ярдәмләшергә тиеш иде.

Менә шундый кызу урак башлану белән, икенче көнне таң аткач, Мәмли янына пир ата белән иптәшләре килде. Аның җиңелүенә, егылуына инде өч көн тулган. Ул өч көннән артык ятарга тиеш түгел иде. Өч көн эчендә

аягына басып, яңадан элекке хәленә кайта алмаса, бер елга аның яше киметеләчәк һәм ул түбәнге эндеригә күчереләчәк яисә, бөтенләй эндеридән чыгарылып, өенә кайтарылып җибәреләчәк иде.

Мәмлинең бик каты башы авырта, башы әйләнә һәм ул бик хәлсез иде. Шулай да ул иптәшләрен аяк өсте елмаеп каршыларга тырышты. Картая башлаган чандыр пир ата да сөекле оныгын-батырын аягөсте күреп елмайгандай итте һәм аның аркасыннан сөеп куйды.

— Сине алырга килдек, улым, — диде ул, якын итеп.

Башкалар да шаулашып, үз итеп аның кулын кысарга, аның аякка басуы өчен үзләренең сөенечен белдерергә тырыштылар. Иң азактан аның янына Зөлмәт килде. Дустының күзенә туры карамаска тырышып, гаепле сыман, ул аңа кулын сузды. Үзенең җиңүче дустын күргәч, Мәмлинең бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте, йөзенә кан бәрде, шулай да ул, үзенең тойгыларын сиздермәскә тырышып, үз-үзен мәҗбүр итеп, сузылган кулны учына алды һәм теләмичә генә күрешеп йомшак кына кыскандай итте.

— Сиңа үпкәм юк, — диде ул, авыз эчендә мыгырданып, кызарынып.

Шуны гына көтеп торган яшьләр хуплап, шаулашып алдылар һәм шаяртып аларның икесен дә әйләндереп кочтылар, мактадылар. Пир ата да мактау, хуплау сүзләре әйтте. Шуннан соң ул Мәмлигә Типкә би боерыгын җиткерде.

Бу юлы алар, чын сугышчылар кебек киенеп, чын кораллар белән коралланып, атка атланып, кала капкасына һәм кала урнашкан калкулык өстендәге юлдан сулга, көнбатыш яктагы киң үзәнгә — ашлык басулары ягына юнәлделәр.

Иген кырларында һәм яшелчә-җимеш бакчаларында урыласы ашлык урылып, җыеласы яшелчә-җимеш җыеп алынгач, өлкән үсмерләр эндериенә беренче мәртәбә авыр, катлаулы һәм җаваплы йомыш тапшырыла иде. Мондый чакта би кораллы яшьләрне йә булмаса берәр кабиләгә каршы сугышка җибәрә, йә булмаса кәмәгә утыртып, ерак юлга сәфәргә озата иде. Яшьләр беренче мәртәбә пир ата һәм өлкәннәр күзәтүеннән башка үзләренең белемнәрен, осталыкларын тормыш шартларында сынап карарга тиешләр иде. Үз бурычларын җиренә җиткереп тиешенчә үтәгән очракта гына аларның өйрәнчеклеге төкәнгән исәпләнелә һәм шуннан соң алар өйләнә алалар, өйләнгәч исә тулы хокуклы ир кеше

буларак, кала эшләрендә, идарә эшендә катнаша алалар, идарәгә анда-монда сайлана алалар иде.

Берничә ел инде Типкә би олы сынауга дип яшьләрне күршеләргә яуга да җибәрми, кәмәгә утыртып еректагы илләргә сату-алуга ерак юлга да озатмый иде. Аккаладан бер илле чакрым чамасы төньяк-көнчыгышта, таулар-урманнар арасында моннан ун еллар элек, кыргый таурлардан яңа җир яулап, мака сар яңа кала салдырды. Таулар арасындагы үзәннәр иген игү өчен дә, мал асрау өчен дә әллә ни уңайлы түгел иде. Ләкин анда лелегләр якында гына яткан бакыр һәм көмеш катламнары таптылар. Яңа утрауга мака сар үз халкының яртысын күчерде дә кыргый таулар-урманнар арасында читтән китерелгән коллар, каралар көче белән бакыр һәм көмеш чыгаруны җайлап җибәрде. Бакыр кала дип аталган каланың үзенең кораллы көчләре күп түгел иде. Шунлыктан эретелгән, калыпларга салып катырылган бакыр, көмеш бәлешләрен, ике-өч айга бер мәртәбә кораллы алай җибәреп, Аккалага алып кайталар иде. Аннан соң Алтын Уртадан сәүдә кәмәләре килгәч, төзү агачлары, ашлык, затлы таш, чүлмәк, савыт-саба һәм чибәр коллар белән берлектә ул алтынкөмеш, бакырны да башкалага изге патша мака сарга озатып торалар иде.

Быел да көзге эшләр беткәч, Типкә би өлкән үсмерләр алаен Бакыр калага җибәрергә дигән карарга килде. Шул турыда ул иң элек пир атага әйтте.

— Алга кемне куярсың икән? — диде ул аңа.

Пир атаның нәрсә дип җавап бирәчәген ул, билгеле, яхшы белде. Ул моны болай гына, эче пошканнан гына сорады. Күптән инде ул Мәмлине үз кеше итеп күз алдына китерергә күнеккән иде. Мәмли, аның үги улы, аңа бар яктан да ошый иде, тик менә Арпа ана туенда аның җиңелүе генә бөтен нәрсәне чуалтып ташлады.

— Барганда алдан Зөлмәт булыр, кайтканда — Мәмли, — диде пир ата, чак кына уйлангандай итеп.

Пир атаның акыллы сүзенә бинең исе китте. Кара син аны! Ул менә никадәр баш ватып та, нишләптер бу рәвешчә уйлый алмаган иде. Аның җиңгән Зөлмәтнең дә, шулай ук җиңелгән Мәмлинең дә кәефләрен кырасы килмәгән иде.

Хәзер аның бу турыда артык баш ватасы килмәде — Типкә бинең кайгы-борчулары болай да җитәрлек иде. Пир ата белән сөйләшкәч, Типкә би амбарлар ягына китеп барды. Анда башкалага озатыласы ашлыкларны

үз күзең белән күреп, барлап куясы һәм чүлмәкләрне тамгалыйсы бар иде.

Пир ата исә би яныннан чыккач та үзенең ирәннәре янына ашыкты. Ул аларга бинең сүзләрен җиткерде һәм иртәгә иртүк, берәр ат тагып, ерак юлга чыгарга боерды.

— Барганда Зөлмәт алдан барыр, кайтканда — Мәмли, — диде ул, би алдында әйткән сүзләрен кабатлап.

Шулай дигәч тә ул игътибар белән яшьләрнең йөзенә карап алды.

Бүтән вакытта теләсә кая барганда пир ата үзе төркем алдыннан бара, хәтта чынлыкта ул читтән барса да, ул алдан баручы булып исәпләнелә иде. Алдан бару исә ул егерме кешелек алайга баш булуны аңлата иде. Егерме кешенең һәркайсы тиешле шартларда бөтен төркем башы, җитәкче була алса да, унбашы яисә йөзбашы бары бер генә кеше була ала һәм башкалар, һичшиксез, аның боерыкларына буйсынырга тиешләр иде. Зөлмәтләр әндериендәге үсмерләр Мәмлинең еш кына баш булуына ничектер үзеннән-үзе күнеккәннәр һәм аны пир атадан кала икенче кеше дип исәплиләр иде. Зөлмәт бар яктан да Мәмли белән бер чама булса да, аңа бик үк теләмичә генә буйсыналар иде. Аның кыланышларында, үз-үзен тотышында башкаларны читләштерә торган кайбер кимчелекләре бар. Билгеле, ул да батыр һәм көчле, ләкин ул күбрәк кеше исәбенә яшәргә һәм үзеннән көчсезләрне ничектер кысарга, түбәнсетергә тырыша. Аның бу якларын көчсезрәкләр аеруча авыр кичерәләр иде.

Пир атаның боерыгын яшьләр шатланып каршы алдылар. Мәмли дә бернинди ризасызлык белдермәде. Бары тик Зөлмәтнең генә йөзе ачылмады. Ул, күрәсең, моннан соң инде бөтен алайда үзен генә иң көчле, иң батыр кеше дип исәпли башлаган иде. Ләкин пир атага каршы ул шулай да берни әйтмәде. Хәер, пир ата боерыгына каршы килергә аның әле бернинди хокукы да юк.

Икенче көнне алар кояш чыкканчы ук тордылар, ашадылар-эчтеләр дә шундук кузгалып киттеләр. Юл башта калкулык сыртыннан, чәнечкеле гөлҗимеш куаклары арасыннан барды, аннан соң сөзәк тау битеннән төште һәм таулар арасында сузылып яткан киң үзәнгә килеп керде. Калкулык башында шундый салкын һәм көчле булып тоелган иртәнге җил түбәндә бөтенләй юашланып калды. Күп тә үтмәде, диңгез ягындагы таулар артыннан елмаеп кояш чыкты. Дөнья шундук яктырып, ямьләнеп китте.

Үзән уртасыннан, куе камыш һәм тал куаклары арасыннан, сай гына, шулай да җитез генә Аксу агып ята. Кала ягыннан килгән юл, елгага якын килергә курыккандай, бераз җир читтәрәк барды да, уңга борылып, камышлы ярлар ягына каерды. Юл борылу белән, төркем башындагы Зөлмәт атын туктаткандай итте. Башкалар да туктап калдылар, җиргә төштеләр һәм, коралларын салып, елга ягына аркан борылып, иртәнге йомышларын йомышладылар. Шуннан соң яңадан алар каты киемнәрен киделәр, билләрен будылар һәм, коралларын кулларына алып, атларын суга якын алып килделәр. Су иясенә атап иң элек корбан бирделәр дә ташлы яр читенә ятып үзләре дә су эчтеләр, атларын да эчерделәр.

Елга аша чыккач, юл икегә аерылды. Аның берсе яр буйлап төньякка таба китте, икенчесе уңга — көнчыгышка каерды. Атлы, кораллы яшьләр уң якка юнәлделәр. Алар үзәнне аркылы чыктылар да ике тау арасындагы тарлавыкка килеп керделәр. Тарлавыкта җил бөтенләй тынып калды, шул ук вакытта кояш нурлары да юкка чыкты. Монда бераз гына дымлырак, бераз гына караңгырак һәм бераз гына куркынычрак иде. Ике яктан да таш араларыннан, таш өсләреннән каты кәрлә куаклар, нидер теләнгән сыман, кәкре-бөкре ботакларын сузып утыралар иде. Кайбер җирдә таш астыннан тамчылап кына су саркып ята, шунлыктан аяк асты юеш һәм тайгак иде.

Ат өстендәге яшьләр, очлы ботаклардан, күзгә төртелеп торган чыбыклардан сакланып, әле күзләрен каплыйдылар, әле читкә каерылдылар йә булмаса башларын иделәр. Иң алдан баручы Зөлмәт, уңга-сулга селтәнеп, җиз балтасы белән әрсезрәк ботакларны кыеп-кыеп төшерде.

Тарлавыкның боргаланып торган ташлы-түмгәкле сукмагы башта үргә таба менде, аннан соң түбән таба төшә башлады. Үр менүе шактый авыр булды. Әледән-әле атларның аягы тайды, аяк астыннан шома ташлар шуып-тәгәрәп китте. Бара торгач атлар, ниндидер ят исләр сизеп, пошкыра, тынычсызлана башладылар. Яшьләр исә, Селәүсен тарлавыгы турында сөйләнелгән имеш-мимешләрне исләренә төшереп, сөңгеләрен әзер тоткан килеш, туктаусыз як-якларына каранып бардылар. Былтыр шушы тарлавыкта бер аучыга аю ташланган. Аюдан бигрәк монда һәрбер таш артында, һәрбер куак артында таур сагалап торырга мөмкин. Алар, шулай искәрмәстән һөҗүм итеп, бик күп кешенең башына җиттеләр.

Тарлавык әллә ни озын түгел иде, ләкин өркә-курка чыкканга һәм бик әкрен барганга, ул очсыз-кырыйсыз булып тоелды. Менә, ниһаять, чытырман арасына кояш нурлары үтеп керде. Юлчылар тарлавыкның икенче ягына якынлаштылар һәм, сөенеч тойгысына бирелеп, җиңелчә шаулашып алдылар. Озакламый көн яктырды, ботак-сатаклар, таш катламнары, текә ташлар читкәрәк киттеләр. Күз алдында искиткеч киңлек, иркенлек ачылды. Тар сукмактан, тар аралыктан бөгеләсыгыла килгән кораллы яшьләр барысы берьюлы диярлек билләрен турайттылар һәм барысы берьюлы диярлек елмаеп җибәрделәр. Атлар да, башларын чайкап, җиңелчә пошкырып, шәбрәк атларга тотындылар. Югары күтәрелгән сөңге җизләрендә, яшь сугышчыларның каты киемендәге җиз калайларда, җиз калбикларда шатланып кояш нурлары балкыды, яшь күзләр, җентекләп, ниндидер ят, күрмәгән нәрсәләр күрергә өмет итеп, еракка, зәңгәр офыкка текәлде.

Тигезлекнең каршы ягында, шәүлә сыман гына булып, күксел сыртларын кабартып, тоташ таулар тезелеп киткән. Таулар тезмәсенең сул ягында якындарак шулай ук таулар... таулар калкып утыра. Сул яктагы таулар, якынрак булганга һәм иртәнге кояш нурлары белән яктыртылганга, аеруча биек, тамыр-томырлы һәм кыргый булып күренә. Уңда исә диңгез һәм диңгез култыклары булырга тиешле якта әле яшеллеген җуймаган урман белән капланган тәбәнәк калкулыклар сузылып китә. Таулар арасына ташланган бик зур озынча табакны хәтерләткән бу гаҗәеп тигезлекнең уртасында ап-ачык булып, зәп-зәңгәр булып зур гына түгәрәк күл ялтырап ята. Күлнең читендә үләне көйгән болыннар артында аеруча ачык һәм матур булып куе-яшел төстәге камыш куаклары күренә. Күлнең аргы ягында очлы башлы камыш куышлар тырпаеп утыра. Куышлар тирәсендә, кырмыскалар шикелле, кешеләр кыймылдаша. Бер-ике җирдә иренеп кенә күккә аксыл төтен күтәрелә. Күлнең бу ягында исә биш-алты сыердан һәм унлапунбишләп сарыктан торган көтү аптырап тора.

Күлле таба дип аталган әлеге үзәндә тауларның өч авыллы Марис кабиләсе яши иде. Марислар күрше үзәндәге, диңгез буендагы Аккала кешеләре белән ачыктан-ачык дошманлашмыйлар, кайчагында калага барып алыш-биреш итәләр, кайчагында бидән, лелегләрдән теләнеп, ашлык, җимеш-фәлән алып китәләр. Кайчагында исә үтерүдән, чәлдерүдән дә тартынып тормыйлар иде.

Сукмак сыман юл яисә юл сыман киң сукмак, күлне, таурларны унда калдырып, корыган каты үлән арасыннан таулар ягына шуышты. Сукмак буенда агарып, саргаеп беткән эре баш сөякләре, кабырга һәм умыртка сөякләре аунап ята. Болар башлыча төнлә ерткычлар ботарлаган хайван сөякләре иде. Арада кеше сөякләре дә очрады.

Таурлар әз-мәз хайван асрыйлар һәм балык тоталар. Күбрәк вакытларын исә күрше кабиләләр белән сугышта һәм юлбасарлыкта үткәрәләр. Сукмак буенда аунап яткан кеше сөякләре менә шуның нәтиҗәсе булырга тиеш иде. Күрше кабиләләр белән алар бигрәк тә баш сөяген яулап алу өчен сугышалар. Кем күбрәк баш сөяге яулап ала алган булса, андый кеше кабиләдә иң батыр һәм иң хөрмәтле сугышчы исәпләнелә. Лелегләрнең шушы сукмактан йөргәнлекләрен белгәнгә күрә, куркыту өчен әлеге сөякләрне таурлар үзләре китереп ташлаган булырга тиеш.

Үлән арасында аунап яткан сөякләр яныннан коралларындагы, киемнәрендәге җизләрен, көмешләрен елкылдатып каты җир өстеннән җиңелчә юырттырып барганда, яшьләр авыл ягында ниндидер ыгы-зыгы күреп алдылар. Күл ягындагы кешеләрнең бер-берсенә каты итеп, ямьсез итеп кычкырганы ишетелде, һәм, күп тә үтмәде, анда берничә кеше бер төркемгә тупланып алды да ашыгып атлыларга каршы йөгерә башлады.

Яшьләр туктагандай иттеләр, атларын килүчеләргә каршы бордылар да коралларын җайлабрак тоттылар.

— Тукта! Качма! — дип кычкырдылар таурлар, ерактан атлылар төркеменә янап.

— Көтик әле, нәрсә кирәк икән аларга? — диде Зөлмәт, сагаеп.

— Безгә каршы яу киләләр, — диде шунда кемдер, мыскыллы көлемсерәп.

— Җиз татып карыйсы килә боларның, — диде яшьләрнең икенчесе.

— Шаулашмагыз. Үзем сөйләшәм! — диде Зөлмәт, кисеп.

Ашыгып йөгергән таурлар төркеме атлыларга бер ун адым килеп җитмичә туктап калды. Марисларның барысы да анадан тума диярлек шәп-шәрә, бары тик корсак асларында, оят җирләрен каплап, каешланып беткән тар гына күн кисәге асылынып тора иде. Беркайчан тарак йөзе күрмәгән, толымнарга урелмәгән озын чәчләре, ат ялы сыман, таралып, иңбашларына төшеп тора. Кул-

ларына алар тоткасы шомарып беткән чукмар башлы күсәкләр тотканнар иде.

— Якынрак кил, ник кычкырасың? — диде Зөлмәт, таурлар төркеменең башлыгы Мариска.

Марисның Аккалага килгәне бар, шунлыктан аны Зөлмәт тә, башкалар да күреп тә, ишетеп тә беләләр иде. Марис ялындырып тормады, бер-ике адым алгарак чыкты да, башы җиз калай белән тышланган, тоткасы көмеш белән бизәлгән зур күсәгенә таянып, Зөлмәтнең йөзенә төбәп карады.

— Курыкмасаң, үзең кил! — диде ул Зөлмәткә.

Ул бик зур гәүдәле һәм бик таза кеше иде. Аның таш сыман каты шәрә тәнендә бер генә яраланмаган, җәрәхәтсез урыны юк сыман. Бу исә аның күп сугышларда, орышларда катнашып та исән калуы һәм аның чыннан да нык булуы турында сөйли иде. Муенса урынына ул, нечкә көмеш чылбырга тагып, алтынланган кеше башы тагып куйган. Бу аның иң явыз дошманы — төньяктагы күрше әнчекләр кабиләсенең өлкәне Нәреш ту башы иде.

Зөлмәт, атка атланган һәм коралланган булса да, күсәгенә таянып, аякларын аерып басып торган Марис янында шактый көчсез, өтәләнгән бала-чага булып күренде. Кыргый таурның шулай кыю сөйләнүенә, борын чөюенә хурланып ул кызарынып китте һәм, тыелып кына, шулай да кырыс итеп:

— Әйт, ни кирәк? — диде.

— Күмәч бир, ярма бир! — диде Марис.

— Сездә ашлык күп, ашлык бир!

— Ашарга бир! — дип кычкырдылар таурлар, күсәкләре белән янап.

— Монда күмәч тә юк, ярма да юк, — диде Зөлмәт, аңсыз, оятсыз таурларга шулай да нәрсәдер аңлатырга кирәк табып.

— Калага бар, анда сиңа бирерләр кирәгеңне! — диде шул чакны теләсә нәрсәгә кысылырга ярата торган Үти, янап.

Зөлмәт, ярсып, Үтине шундук ачулы күз карашы белән өтеп алды. Зөлмәт, алай башы буларак, башкаларның кысылганын яратмады.

— Ашарга бирмәсәгез, беркая китмисез! — диде Марис, нык итеп, һәм эре, тигез тешләрен күрсәтеп елмайгандай итеп куйды.

— Җибәрмибез!

— Китмисез! — дип кычкырдылар башка ирләр, үзләренең баш кешесен яклап.

Яшьләр күбрәк иде, таурларга караганда алар, билгеле, яхшырак коралланганнар иде. Бик теләгәндә алар — лелегләр — әлеге төркемне генә түгел, бөтен авылларын да күз ачып йомганчы кырып ташлый алган булырлар иде. Кайбер түземсезрәкләр чыннан да шаулаша башладылар. Моңарчы бәхәскә катнашмыйча кырыйдарак торган Мәмли алгарак чыкты һәм корал белән янаучы, шаулашучы юлдашларына карап:

— Туктагыз әле, — диде, — безгә таурлар белән сугышу бурычы йөкләнмәгән. Безгә туп-туры Бакыр тауга барырга кирәк.

— Беләбез, — диде Зөлмәт, коры гына, Мәмлинең монда килеп кысылуын яратмыйча. — Кайтканда син баш булырсың, менә шунда үзеңчә эшләрсең!

— Эшләрмен дә шул! — диде Мәмли, кызарынып.

Теге йодрык сугышыннан соң иптәшләре алдында бу аларның беренче әйтешүләре булды. Моңарчы алар, берберсенең күзенә чалынырга курыккан сыман, ничектер бер-берсеннән читтә булырга тырыштылар.

— Ничек эшләрсең икән, әйтеп карале?! — диде Зөлмәт, мыскыл сизелеп торган бер өстенлек белән.

Мәмли аның мыскылына игътибар итмәскә тырышты һәм, Зөлмәттән бигрәк таурлар туына карап:

— Мин болай эшләрмен. Безнең хәзер, чыннан да, үзебез белән алган күмәчебез дә, ярмабыз да юк. Теләсәк тә без сезгә берни бирә алмыйбыз. Бакыр таудан кайтканда без сезгә ярма да, икмәк тә алып кайтырбыз, хәзергә менә шуны алып тор... — Ул шулай диде дә алтын-көмеш тәңкәләр белән бизәлгән бил каешын ычкындырып Мариска ыргытты. — Миннән сиңа бүләк! — диде ул.

Таур туы уң кулындагы күсәген җиңел генә югары күтәрде һәм бил каешы җиргә төшеп өлгергәнче аны күсәк башына эләктерде дә сул кулы белән бүләкне тотып алды, елмаеп җибәрде. Күрәсең, үзләрен җиңүче санап, башка таурлар да елмаеп җибәрделәр, куанышып шаулашып алдылар.

— Ярар, синеңчә булсын, — диде Зөлмәт Мәмлигә, теш арасыннан гына.

Якындагылар күреп тордылар, Мәмлинең таурларга биргән вәгъдәсе дә, бүләге дә Зөлмәткә ошамады. Күрәләтә аның чырае сытылды. Шулай да ул Мәмлигә каршы да килә алмады. Әле булса алар арасында киеренкелек һәм астыртын дошманлык саклана иде бугай.

— Бар, кит. Мин сине җибәрәм, — диде таур алыбы,

Зөлмәткә кулын селтәп. — Кара аны, кайтканда көтеп торырмын, — диде ул ахырда, кисәтеп.

Яшьләр кузгалып киттеләр һәм юл буе шаулашып әлеге очрашу турында фикер алыштылар. Бары тик Мәмли дә Зөлмәт кенә сүзгә катнашмадылар.

Кояш төшлеккә җитеп килгәндә, алда Бакыр кала күренде. Бакыр кала сирәк-мирәк әрәмәләр белән капланган биек тау башына урнашкан иде. Тау астыннан тау түбәсенә — таш киртә белән уратып алынган калага кадәр урман кисеп туры юл салынган. Урман юлыннан бер-бер артлы тезелеп атлылар килүен манара башындагы сакчылар ерактан ук күреп-күзәтеп тордылар, ахрысы. Кораллы җайдаклар очлы җизләрен ялт-йолт китереп, калбикларындагы кош каурыйларын тирбәндереп, капка янына килеп җитәр-җитмәс, кунак килүен хәбәр итеп, быргылар кычкырды һәм, көттереп-нитеп тормыйча, каерылып капкалар ачылды.

Яшьләрне Кодрәт бага үзе каршылады. Ул имәндәй таза, төз һәм зур гәүдәле урта яшьләрдән өлкәнрәк бер кеше иде. Кодрәт тархан Типкә бинең элекке йөзбашы, Типкә бигә буйсына, ләкин Бакыр каланың үзендә һәм якын тирәдәге тауларда, үзәнлекләрдә — җир өстендә һәм җир астында — барлык лелегләр һәм барлык каралар-коллар, бакыр эзләүчеләр, бакыр эретүчеләр берсүзсез аңа буйсыналар. Аның көче, кырыслыгы йөзенә чыккан иде. Аккаладан, ерак юлдан килгән яшьләрне күрү белән ул исәнлек-саулык сорап бер-ике сүз әйтте дә, алай башлыгы Зөлмәткә бер күз карашы гына ташлап алды да, куна тактасыдай киң аркасын борып, кара чәч толымнарын селкетеп, тузанлы юлдан каядыр каралтыкуралар, таш өйләр ягына китеп барды. Яшьләр башта аның таш йөзен, аннан соң таш аркасын күрү белән кинәт шып булдылар, бөрешеп калдылар һәм, шауламаска тырышып, тархан артыннан иярделәр.

Кодрәт бага аларны тар гына урамнан алып китте. Урамның ике ягында да артык биек булмаган таш өйләр, таштан, агачтан эшләнгән киртәләр сузылды. Өй араларында ботакларын җәеп утырган җимеш агачлары күренеп калды. Тар урам тиз арада кала уртасындагы киң ачыклыкка килеп чыкты. Каршыда тарханның тигез итеп киселгән, шомартылган ак таштан салынган ике катлы йорты балкып утыра, аның янындарак исә тәбәнәгрәк башка йортлар күренә иде. Кодрәт тархан аларны тыштан җиз белән тышлаган зур гына ишеге булган амбар сыман таш каралты янына алып килде.

Ишек янындагы таш өстендә, сабы шомарып беткән кыска сөңгесен таяк сыман таянып, бер сакчы карт утырып тора иде. Кешеләр якынлашу белән, ул ашыгып урыныннан торды, тарханга баш игәндәй бер хәрәкәт ясап, читкәрәк китте. Кодрәт тархан исә, билендәге киң каешка тагылган җиз ачкычның берсен алып, ишекнең йозагын борды да авыр ишекне шыгырдатып ачып җибәрде.

Яшьләр үзләре белән озынча күн капчыклар алып килгәннәр иде. Буш капчыкларны алар ишек төбенә өеп куйдылар. Бага капчыкларны санап тикшереп торды. Шуннан соң ул яшьләрне берәм-берәм ишектән кертә башлады. Бераз гына дымлы сыман тоелган ярым караңгы амбар уртасына идәнгә күн капчыклар өеп куелган. Капчыкларга икешәр кисәк бакыр бәлеше салынган, капчык авызы ныгытып бәйләнелгән һәм балавыз кисәге белән тамгаланган иде. Һәр бәлеш егермешәр гөрәнкә, ике бәлеш кырык гөрәнкә иде. Яшьләр берәр капчык алып чыктылар да, озынча капчыкны урталай бөкләп, эчмәк сыман итеп атларының буш сыртына салдылар. Капчык эчендәге бакырларның берсе — ат сыртының бер ягында, икенчесе икенче ягында калды. Шуннан соң капчыкка беркетелгән озын каеш бауларны атның корсак астыннан үткәреп, авыр капчыкны яхшылап бәйләп куйдылар.

Ишектән кергән-чыккан һәркемне бага санап-билгеләп торды. Ишектән чыккан һәркемнең исемен сорады һәм, капчыкны ат сыртына салганчы, капчык авызын ныклап бәйләнгәнме-түгелме, тамгалы балавызның төзекме-түгелме икәнлеген тикшерергә кушты. Егерме егетнең егермесе дә үзләренә тиешле капчыкны алып чыккач, ул ишекне яртылаш япты да җирдәге буш капчыкларны берәм-берәм күздән кичереп чыкты. Шуннан соң ул башын калкытты, билен язды.

— Булды. Барысы да бар. Алдым-бирдем, — дип куйды. Аннан әле һаман җыенып бетә алмаган яшьләргә күтәрелеп карады: — Кайсыгыз баш соң әле сезнең? — диде.

— Мин, — диде Зөлмәт.

— Юк, мин, — диде Мәмли аңа каршы.

Бага берни аңламыйча аптырагандай итеп әле Зөлмәткә, әле Мәмлигә карап алды.

— Баш бер генә була, — диде ул.

— Килгәндә Зөлмәт баш булды, кайтканда — Мәмли! — диде Кодрәт багага якынрак торган Үти, аңлатып.

Кодрәт бага, тамак кыргандагы сыман бер гырылдык тавыш чыгарып, көлгәндәй итеп куйды.

— Өйрәткән сезне пир ата акылга! — диде ул. — Ярар, капкадан чыкканчы — Зөлмәт, капкадан чыккач Мәмли баш булыр. Зөлмәт! Мәмлигә әйт, бигә әйтсен, бакыр ташы чыгарырга кеше җитми. Биш кеше үлде, өчесе качкан. Кеше җибәрсен, бер ун батман яңа арпа кирәк. Сыра кайнатырга.

— Әйтермен, — диде Зөлмәт, теләр-теләмәс кенә.

Зөлмәт Кодрәт баганың шаяртып сөйлиме, чынлап сөйлиме икәнлеген аңлап җитмәде. Ни генә булмасын, аның мондый хәлгә тарыганы юк иде. Шунлыктан аның тизрәк моннан чыгып китәсе һәм бар җаваплылыкны үз өстеннән төшерәсе килде.

— Олуг бага, — диде шул чакны Зөлмәт, арпа дигәннән таурларны исенә төшереп. — Син безгә бераз икмәк бирә алмассыңмы?

Баганың йөзе үзгәреп китте һәм ул Зөлмәткә сынап карап тора башлады.

— Арпаны мин каладан алам, — диде ул, коры гына. — Ачыксагыз, кайткач ашарсыз.

— Ни... безгә үзебезгә түгел... — диде Зөлмәт, буталып. — Марис алып сораган иде. Аның өчен.

— Марис шулай теләнергә ярата инде ул, — диде Кодрәт, коры гына.

Зөлмәт нидер әйтмәкче булды, ләкин Кодрәт бага аларны куарга ук тотынды.

— Барыгыз, бар. Әнә көн дә бозылырга тора. Яңгыр яумагае бүген, — диде.

Зөлмәт теләр-теләмәс кенә кузгалып китте. Башкалар аның артыннан тагыла тордылар. Кодрәт бага икеләнгәндәй итеп ары-бире каранып торды да кинәт кискен генә кулын күтәрде.

— Туктагыз әле! — диде ул, кычкырып. — Дүрт кешегә... бер бөтен ипи алырсыз, мич өенә, икмәк өенә борылыгыз әле.

— Безнең үзебезгә кирәкми, Марисларга кирәк, — диде шунда якында гына Зөлмәт янында торган Үти, аңлатырга кирәк табып.

Зөлмәт Үтигә ачулы күз карашы ташлап алды.

— Сиңа сүз бирелмәгән! — диде ул, усал гына итеп. — Дүрт бөтен икән дүрт бөтен, — диде. — Безгә артыгы кирәкми дә.

— Ярар, камыр өенә бара торыгыз, хәзер куып җитәрмен, — диде Кодрәт бага, бикләнмәгән ишегенә кире барып.

Кодрәт баганың сүзен барысы да ишетеп тордылар һәм, күңелле шаулашып, камыр өе ягына борылдылар. Кодрәт баганың камыр өе ике катлы ак өйдән читкәрәк, соргылт ташлары чыгып торган тау янына урнашкан иде. Ул яктан бертөзлексез ниндидер тавыш-гөрелдек ишетелеп тора. Бу гөрелдеккә кеше тавышлары да, якында гына чылтырап таулардан агып төшкән чишмә тавышы да, бала-чага чыр-чуы да кушылган. Камыр өе дип тә, тегермән өе дип тә аталган бу иркен, биек өйнең бер ягында коллар, калку такта — сике өстенә утырып, аягөсте басып, кул тегермәннәрендә бертөзлексез ашлык тартып он чыгаралар, икенче бүлмәдә зур мичтә бага өчен, баганың йөзләгән коллары, каралары өчен икмәк пешерәләр. Якындагы чишмәдән таза ирләр зур-зур чүлмәкләр белән су ташып торалар, икенчеләре, әледән-әле утын кертеп, мичкә ягып тора. Шунда ук җиз казаннарда эшчеләр-коллар, каралар өчен ботка пешә һәм сыра кайный. Ул яктан үзенә бертөрле тавыш, гөрелдек һәм шакы-шокы тавышлары ишетелгән кебек, ул яктан, шулай борыннарны кытыклап, яңа пешкән ипи исе, төтен исе килеп тора.

Атлы яшьләр төркеме тегермән өенә берничә адым җитмичә туктап калдылар, аларны арттан куып җиткән Кодрәт ачык ишектән эчкә кереп китте һәм бераздан камыш тубылга яңа пешкән түгәрәк ипи тотырып ярым шәрә яшь, таза кол килеп чыкты. Ул дүрт кешегә бер бөтен исәбеннән, кемгә туры килә, шуңа ипи таратып чыкты да, таратып бетергәч, тубыл авызын аска каратып, читкә китеп Кодрәт баганы көтеп торды. Камыр өеннән Кодрәт бага бер бөтен ипи алып чыкты да төркемнең иң артында торган Зөлмәткә тоттырды.

— Монысы Марисларга булыр, — диде ул.

— Ярар, — диде Зөлмәт, алтынчы бөтенне алып.

Шуннан соң алар юлга чыктылар.

Капкадан чыккач, атлылар тезмәсе яңача тезелде. Койрыктагылар башка таба уздылар, Мәмли алга чыкты, Зөлмәт иң артта калды. Атларын тыя-тыя, алар тау юлыннан аска төштеләр. Бакыр калада тау өстеннән чыккан таштан ташка сикереп, үзенчә шаулап аккан татлы чишмә каяндыр агачлар арасыннан түбәнгә төшеп җиткән һәм куе үлән эченнән елкылдап, шуышып агып ята иде. Бер җайлы, иркен урында яшьләр туктап калдылар, җиргә төштеләр һәм атларын тибенгә җибәрделәр дә үзләре яшел чирәмгә утырып икмәкләрен бүлештеләр. Яңа пешкән һәм әле җылысы да бетеп җитмәгән бодай

икмәген алар бик тәмләп, кадерләп һәм әз-әзләп кенә ашадылар. Ашагач, ярга ятып татлы чишмәдән су эчтеләр. Су эчкәч, бу кадәр рәхәтлеккә, бу кадәр изгелеккә исләре киткән сыман, күңел хушлыгын һәм тамак тую ләззәтен бозарга теләмәгәндәй, яшь тәннәрендә рәхәт талгынлык тоеп, беравык тынып, чишмә агышын карап утырдылар. Пир ата Әмәк аларны гел өйрәтә килде: ашау — изге эш, диде, ашаганда сөйләшергә, ашыгырга кирәкми, ашагач бераз тынып утырсаң, аякларга, беләкләргә көч күбрәк килә, диде.

Алар шулай бер ярты сәгать чамасы тукланып, онытылып утырдылар. Ул арада атлар да аяк астында бераз ялманып алдылар.

— Алтынчы бөтен синдәме? — диде Мәмли, кузгалырга вакыт җиткән сыман булгач, Зөлмәткә карап.

— Миндә, — диде Зөлмәт.

Мәмли беренче булып аягына басты, җиргә салып куелган коралларын алды. Башкалар да бер-бер артлы аякларына бастылар һәм, атларына атланып, яңадан кузгалып киттеләр.

Урман юлыннан алар шактый озак бардылар. Урман эчендә көн бераз гына караңгырак иде, аннан соң һава да дымлырак, авыррак сыман иде. Баш өстен ике яктан килеп кушылган куе агач ботаклары каплап алганга, яшьләр баштарак күк йөзен бөтенләй диярлек күрмәделәр. Ләкин урман бетеп, юл ачык урынга килеп чыккан иде, һәркайсы Кодрәт баганың Бакыр калада әйткән сүзләрен исенә төшерде. Чыннан да көн бозылган, чалт аяз күк йөзендә кара-кучкыл болытлар барлыкка килгән иде.

— Яңгыр килә!

— Ашыгырга кирәк! — диештеләр кайберәүләр, күккә каранып.

Мәмли эндәшмәде дә, артына да борылып карамады. Хәзер ул ничек әйтсә, башкалар шуны эшләячәкләр иде: ул ашыгырга дисә, ашыгачаклар, ул әкрен барырга дисә, әкрен барачаклар иде. Алай башын икеләнү биләп алды. Яңгыр ява башлаганчы тарлавыктан чыгып калганда яхшы булыр иде дә, ләкин, башкаларның үзе турында куркак дип уйлауларыннан куркып, ул бу хакта берни әйтә алмады. Аннан соң, алар — булачак ирләр, сугышчылар — яңгырдан йә булмаса шомлы тарлавыктан куркырга тиешләр микән? Юк, әлбәттә! Аларның тиешле кораллары бар, алар теләсә нинди куркынычны чигенергә мәҗбүр итә торган серле догалар беләләр. Шулай булгач, коткыга бирелү килешмәс.

Юлдашлары тынычсызлана башлагач, ул шулай да туктарга кирәк тапты. Куркыныч килгәндә алай башы үзенең якыннары белән киңәшергә тиеш, ди әледән-әле пир ата. Койрыкта килсә дә, Мәмлинең иң якыны шулай да Зөлмәт иде.

— Син ни дисең? — диде ул, Зөлмәткә эндәшеп.

Зөлмәтнең күңелендә бу вакытта бөтенләй башка төрле уйлар иде. Бу вакытта аны пир ата сүзләре дә, яңгыр яисә тарлавык куркынычы да борчымый иде. Аның ничек тә алтынчы бөтеннән берәр сынык сындырып аласы килә иде. Чишмә буенда ашаган чирек бөтен икмәктән ул әз генә дә туймады. Шундый уңган, кетердәп пешкән өсле бодай икмәген ашагач, аның тагын да ныграк ашыйсы гына килә башлады. Ук садагы сыман каеш бауга асылынган күн янчыктагы түгәрәк бөтен икмәкнең рәхәт авырлыгын тоеп, татлы исен иснәп килде ул. Инде берничә мәртәбә арткарак калып, сындырып алырга укталып та карады, ләкин үзеннән алда барган Үтинең әледән-әле артка борылып каравы гына аны тыелып калырга мәҗбүр итте.

— Тоз түгел, эремәбез, — диде Зөлмәт Мәмлинең соравына каршы.

Ул шулай дигәч, башкалар шундук шып булдылар. Чыннан да, лелег яңгыр күрмәгәнме әллә? Зөлмәт исә үзенчә уйлады. Күлле табага җиткәнче яңгыр яуса, бигрәк тә шәп булачак: яңгырда кыргыйлар өйләрендә качып ятарлар.

Күлле таба үзәненә якынлашканда, чыннан да, беренче тамчылар төшә башлады. Зөлмәт сөенеченнән нишләргә белмәде һәм тыела алмыйча, күн янчыкка кулын тыгып, түгәрәк икмәктән зур гына кисәк сындырып алды да комсызланып кабып та җибәрде. Нәкъ шул чакта оятсызланып, әрсезләнеп Үти артына борылып карады, Зөлмәтнең авыз тутырып ипи ашавын күреп алды һәм шелтә дә, ялыну да, өмет тә белдергән бер тавыш белән мөңгерәп куйды. Ул, хәтта атын тыя төшеп, Зөлмәтне көтеп алды. Зөлмәт тиз генә аңа да бер-ике кабарлык ипи сындырып бирде.

— Башка сорама! — диде ул, аны кисәтеп.

Озакламый яңгыр шәбәя башлады. Бу инде чыннан да көн бозылды һәм көчле яңгыр явачак дигән сүз иде. Мондый чакта нишләп Марис коры, җылы куышыннан чыксын?! Зөлмәт бу юлы икмәкне шактый зур итеп сындырды һәм, башкаларның юеш аркаларын күздән ычкындырмыйча, рәхәтләнеп ашавында булды. Ләкин шул

чакны Үтинең ялагай йөзе күренде. Ул кулы белән битен яңгырдан каплаган булып ялт кына борылып карады да Зөлмәтнең кулындагы икмәкне күреп алды, авызын ерып елмаеп җибәрде һәм сынык өмет итеп тагын арткарак калды. Нишлисең, тагын өлеш чыгарырга туры килде.

Марислар үзәненә аяк басканда, яңгыр беравык туктап торды да яңадан сибәли башлады. Мәмли дә, башкалар да иң элек күл ягына, куышлар ягына борылып карадылар. Иртәнге кебек анда кешеләр дә, төтен дә күренми иде. Бары көтүләре генә, бер тирәгәрәк тупланып, күл буенда һаман баягыча аптырап тынып торалар иде. Мәмлинең дә, башкаларның да эченә җылы йөгерде. Беркемнең дә бу яңгырда күсәк белән янаган кыргый таурлар белән очрашып торасы килмәде. Зөлмәт исә тәмам тынычлангандай булды. Ул Марислар әле аларның кайчан кайтырын да белмиләр. Бәлки әле, иртәгә кайтырлар дип көтәләрдер. Бәлки, эчеп куышларында яталардыр. Бүләккә билбау алды — аларга шул җиткән. Зөлмәт шулайрак дип уйлады һәм янчыктан ипинең соңгы өлешен алды да яртысын үзе яныннан теләнеп, өметләнеп барган Үтигә сузды.

— Икебез ашадык — җавабын да икебез бирербез, — диде ул аңа, кисәтеп.

— Шуның өчен асып куймаслар әле, — диде Үти, көлеп. — Корсак ачты да — ашадык, бетте-китте.

— Юк, алай түгел. Урманда юлбасарлар чыкты, аларга бирдек, — диде Зөлмәт.

Үти, канәгать булып, шаркылдап көләргә тотынды. Шаулап яуган яңгыр тавышында аларның үзара сөйләшкәннәрен дә, көлешкәннәрен дә беркем ишетмәде. Һәркем башын иебрәк, бөрешебрәк, бары бер-берсенең аркасына караган килеш үзән аша юырттыруын белде.

Чыннан да Марис алып камыш куышында йоклап калды, ахрысы. Күл ягыннан күсәк күтәреп йөгереп килүчеләр күренмәде. Тарлавыкка җитәрәк Мәмли соңгы мәртәбә артына борылып карады да, җиңел сулап, тарлавык иясенә:

— Селәүсен иясе! Без кайтып барабыз. Юлыбызга аркылы төшмә, — дип кычкырды.

Шулай кычкырып ул кыю рәвештә ташлы сукмакка керде. Ат аягы астыннан каршыга таба яңгыр суы агып ята. Бу бер дә күңелле нәрсә түгел. Алай-болай яңгыр көчәйсә, су да көчәячәк һәм сукмактан, кыялар арасыннан баруы кыенлашачак иде. Мәмли үзе артын-

нан тезелеп килгән атлыларга борылып карап алды да, атын кызулап, тар аралыкка кереп китте. Ул, гадәтенчә, як-ягына да каранырга онытмады, тик шулай да уңнан сибәләп яуган яңгыр чак-чак кына аның уяулыгын томалагандай итте. Әгәр яңгыр яумаса һәм ул уяурак булса, ихтимал, тарлавык читендә, таш артында качып торган таурларны күрми калмас иде.

Марис алып ирләре, егетләр уйлаганча, яңгырдан качып, куышларында ятмадылар. Алар инде күптән атлыларны тарлавыкта көтеп торалар иде. Таурлар егетләрнең һәркайсын күреп, исемнәре белән беләләр. Аннан соң аларның лелегләргә әллә ни ачулары да юк һәм лелегләр белән бозылышуның бик үк яхшы түгеллеген дә аңлыйлар иде алар. Аларның бары бигә үзләре турында искә төшерәселәре, үзләренең дә лелегләр җыеп алган ашлыкта өлешләре барлыгын белдерәселәре генә килә иде. Бит алар — лелегләр Марислар җирен яулап алдылар, алар җирендә кала салып, иген игеп, мал асрап яталар! Аннан соң башка елларны би аларга калан итеп онын, ярмасын, сырасын җибәрә торган иде. Быел әле нишләптер ашыкмый. Иртән дә алар чынлыкта лелегләргә менә шул турыда исләренә төшермәкче генә булдылар. Хәзер дә чынында аларның күңелендә яшьләргә карата ул кадәр дошманлык хисе дә юк. Бит яшьләрнең яхшы коралланган булуын һәм яхшы сугышчылар булуын алар бик яхшы беләләр.

Марис алып егетләрне берәм-берәм күздән кичерә торды. Иң алдан барган Мәмлине күреп ул бераз гына гаҗәпләнгәндәй булды. Аныңча, иң алдан иртәнгечә Зөлмәт барырга тиеш иде һәм ул — Марис — тарлавык авызына кергәндә, иң элек аны туктатып, аннан вәгъдә ителгән икмәк, тагын ашлык сорарга тиеш иде. Мәмлине ул берсүзсез үткәреп җибәрде, Мәмлидән соңгы яшьләрне дә тоткарламаска булды.

Зөлмәт нишләптер иң артта калган булып чыкты. Җайдаклар бер-бер артлы үтә тордылар. Марис бары Зөлмәтне генә тоткарларга булды. Аныңча, иң арттан барса да, төркем башы әле дә Зөлмәт булырга тиеш иде. Зөлмәт алдындагы Үти узып китү белән, таур алыбы, күсәген күтәреп, аның алдына төшмәкче булды. Ләкин алдан никадәр барысын да уйлап-исәпләп куймасын, тарлавык авызындагы бу очрашу Марис теләгәнчә барып чыкмады. Зөлмәт таурларны коры куышта яңгырдан куркып яталардыр дип үз-үзен тынычландырырга тырышса да, ул барыбер үзен тулысынча тыныч сизә ал-

мады. Таур алыбы алдында да, иптәшләре һәм Кодрәт бага алдында да ул үзен гаепле сизде. Шунлыктан аңа туктаусыз әле кемдер арттан ияреп, сагалап килә кебек, әле тарлавык авызында аны кемдер көтеп тора кебек тоелды. Чыннан да, башкалардан беркем күрми үткән таурларны ул ерактан ук күреп алды. Алар сукмакка якын гына бик зур таш артына посканнар иде. Яңгыр сибәләгән якка каршы торганга, аларны атлар да сизмәделәр, егетләр дә күрми үтеп киттеләр. Зөлмәт күрде һәм шундук кыска сөңгесен җайлап тотты. Таш артында качып торган таурлар аның алдан ук сугышка әзерләнүен, билгеле, күрми калдылар. Башкалар тыныч кына узып китkәч, Зөлмәт тә, күрәсең, берни күрмәс дип уйладылар, ахрысы. Зөлмәт кыядан аерылып торган зур таш белән тигезләшкәч, Марис алып чүгәләгән җиреннән кинәт калкып чыкты да, күсәген югары күтәреп, сукмакка, ат алдына сикереп чыкты. Башкалар да, бик каты кычкырып, аның артыннан ташландылар.

Ләкин шул чакны, күз алдында булган хәлдән исләрен-акылларын җуеп, артка чигенергә мәҗбүр булдылар. Зөлмәт җиз башаклы сөңгесен Марисның яңгыр астында чыланып, күп яуларда яраланып беткән киң, таза күкрәгенә тондырды. Сөңге аның уң як кулбашына якын җирдән, үпкәсе турысыннан тишеп чыкты. Марис, әйтәсе сүзен әйтә алмыйча, телсез калып, бер урында катып торды да, үз артыннан сөңгене ияртеп, ташлы сукмакка бөгелеп төште. Аның юлдашлары курkышып качыша башладылар.

Зөлмәт шундук атыннан сикереп төште, ике куллап сабыннан тотып, сөңгесен тартып чыгарды. Ике-өч адым алданрак барган Үти, атыннан төшеп, Зөлмәт янына килде.

— Күсәге белән кизәнеп... юлга чыкты... ярый әле! — диде Зөлмәт, үз-үзен акларга теләгәндәй, аңлатып.

Монда инде аңлатып торуның кирәге юк иде. Монда барысы да үзеннән-үзе аңлашылып тора. Марис юлга аркылы төшкән, кулында — күсәге. Юлдашлары качып китте. Үти аларны үз күзләре белән күрде. Тик менә яңгыр яуганда кан коелуы гына яхшы булмаган.

— Нишләтергә моны? — диде шулай да Зөлмәт, аптырабрак.

— Әйдә, читкә чыгарып куйыйк, — диде Үти.

Алар таур алыбын икәүләшеп читкәрәк өстерәп чыгардылар да, атларына атланып, яңадан кузгалып киттеләр. Юлбасар Марисны үтереп, көтелмәгән батырлык,

уяулык күрсәтсә дә, нишләптер Зөлмәт үзендә әллә ни куаныч тойгысы сизмәде. Таур юлбасарының үзенә карата бернинди яманлык эшләргә теләмәгәнлеген ул яхшы аңлады. Бит Марис аннан үзенә тиешле бер бөтен икмәкне генә сорамакчы булган иде!

Яңгыр туктаусыз койды да койды. Атларның аяк астыннан, шаулап, ташларны кузгатып, болганчык су ага башлады. Тирә-як караңгыланып калды, һәм алда да, уңда да, сулда да рәтләп берни күренмәде. Төркем башындагы Мәмли тарлавык уртасын узганда, яңгыр әле ул кадәр шәп яумый иде кебек, шулай ук аяк астындагы су да алай ук күп түгел иде кебек. Ләкин ул түбән төшә башлаганда инде яңгыр көчәйде. Бер-ике мәртәбә Мәмли, туктап, артына борылып, иптәшләренә кычкырып карады, ләкин арттан килүче өч-дүрт кешедән башка аны беркем ишетмәде. Арттагы өч-дүрт кеше туктаусыз киләләр иде. Алай башлыгы бүтәннәрне дә шулай туктаусыз киләләрдер дип уйлады һәм тарлавыкны чыкканчы башка артына әйләнеп карамады. Тарлавыкны чыккач исә аның күңелен бөтенләй башка кайгы биләп алды. Аларның бит әле Аксуны да кичәсе бар. Яңгыр вакытында таулардан үзәнгә агып төшкән сулар туптуры Аксуга ыргыла. Андый чакта Аксу танымаслык булып үзгәрә: ярлары тула һәм тыныч чакта ягымлы гөрелдәп агып яткан инеш көтмәгәндә аждаһага әверелә. Менә хәзер ничек тә Аксуны чыгып калырга кирәк... әгәр инде соң булмаса...

Мәмли артына борылды һәм, яңгыр аша караеп күренгән карачкыларны ашыктырып:

— Тизрәк! Тизрәк! — дип кычкырды.

Алар аны ишеттеләрме-юкмы, ул моны белә алмады. Аның үзен исә кемдер эчтән ашыктыра, куалый башлады. Ул ачык җирдән атын, бик каты куып, үзән уртасына чаптырды. Башкалар да, билгеле, аннан калышмаска тырыштылар. Ләкин Марисның үле гәүдәсе белән булашып вакыт уздырган Зөлмәт белән Үти ярыйсы ук артта калдылар. Тарлавыктан ачык җиргә килеп чыкканда алар үзләре алдында беркемне күрмәделәр. Туктаусыз яуган яңгыр чаршавы аша шулай да алда, бик еракта, нindидер карачкыларны шәйләргә була иде. Зөлмәт тарлавыктан чыккач, юлда инде бүтән куркыныч юк диебрәк уйлады. Аннан соң әле булса аны үтерелгән Марис борчып торды. Аңа хәзер мәетне ул юл буена дөрес ташлап калдырмады сымак булып, яңгыр вакытында аның өстенә нидер капларга кирәк иде сы-

ман булып тоелды. Аннан соң аның җаны да чыгып бетмәгән сыман тоелды. Иртәгә барып карарга, торып китмәсә... яисә ырудашлары алып китмәсәләр, яндырырга кирәк дип уйлады ул, ниһаять, билгеле бер карарга килеп. Шуннан соң аның күңеле бер урынга утыргандай булды. Ул як-ягына күзен ачыбрак карады. Ләкин соң иде инде.

— Кара! — диде шул чакны янәшәдән барган Үти, үзән уртасына күрсәтеп. Анда Аксу ярлары эченнән шаулап, күпереп-күбекләнеп, нииндидер әкәмәт зур җанлы нәрсә булып ур Су ургылып килә иде. Алдагы карачкылар инде елга аша чыгып өлгергәннәр бугай — аларның төрле якка сибелеп, калкулык өстенә менеп барулары күренде. Артта калган Зөлмәт белән Үти дә, атларын бар көчләренә куып, үзән уртасына таба ыргылдылар.

Зөлмәт Үтидән чак-чак кына алданрак ташланды. Мондый ташкын күрмәгән аты, башын югары күтәреп, пошкырып, йөзәргә тырышып карады, ләкин су атны йомычка урынына әләктереп алды да, бөтерелдереп, түбән таба алып китте. Ат йөзә алмавын шәйләп, куркып, чинап-кычкырып җибәрде. Зөлмәт шундук мәтәлеп төште һәм, инде су төбенә китәм дигәндә, себерке сыман, чыбык сыман нииндидер нәрсәгә тотынып калды. «Тал бугай» дип уйлады ул соңгы мәртәбә. Шуннан соң ул берни уйлый алмады. Аның авыр киемнәре, кораллары аны каядыр аска тартты.

Шулай да күпмедер вакыттан соң ул исенә килде. Ул үзенең аты койрыгына тотынган булып чыкты. Котырынган елга аларны Аккала турысындагы болынга, төзелеп ята торган кәмә янына, күпер баганалары янына китереп чыгарган иде. Күпер баганаларына эләгеп, алар шунда яңгыр тукталганчы, су басылганчы тордылар.

Бакыр тауга киткән яшьләрне Аккалада көне буе борчылып, дүрт күз белән көтеп тордылар. Бит алар беренче мәртәбә шундый ерак юлга, куркыныч юлга чыгып киттеләр. Өлкәннәрдән башка, үзләре генә. Исән-имин барып җитәрләрме, исән-имин әйләнеп кайта алырлармы? Юлда ул-бу булмасмы — үзара сугышып китмәсләрме яисә кыргый таурлар тозагына эләкмәсләрме? Ата-ана, туган-тумача шулайрак фикер йөртте. Ата-ана балам дип кайгырды, туган-тумача якыны булганы өчен кайгырды. Пир ата үзенең шәкертләре булган өчен кайгырды. Бинең кайгысы башкачарак — киңрәк, тирәнрәк иде.

Төштән соң, көн бозылгач, аеруча коеп яңгыр ява башлагач, борчылу чынлыкта ут йотуга әверелде. Яңгыр

коеп торганда Селәүсен тарлавыгы аша үтүе дә, Аксу аша кичүе дә уен эш түгел иде. Гомумән, Бакыр тау юлында әледән-әле хәвеф-хәтәр булып тора — тарлавыкта юлчыларга әле таурлар һөҗүм итә, әле качкын коллар һөҗүм итә. Шулай булса да, яшьләргә булышка кораллы алай җибәрү турында беркемнең күңеленә килеп карамады. Яшьләр сынау үтәләр иде һәм алар ул сынауда йә җиңәргә, йә җиңелергә тиешләр иде.

Коеп яңгыр яуганда манма су булып кайтып кергән яшьләрне калада, билгеле, сөенеп, шау-шу килеп каршы алдылар. Шундук аларның атларын түбәнрәк төркем әндери малайлары тотып алдылар, түбә астына алып кerделәр. Җайдакларның үзләрен исә коры һәм җылы өйдә кайнар аш көтеп тора иде. Капкадан кергәндә, аларны санап керттеләр. Зөлмәт белән Үтинең юклыгы беленде. Ләкин аларны эзләргә кеше җибәрелмәде.

Яңгыр тынып, су бераз кими төшкәч, Зөлмәт караңгыда көч-хәл белән калкурак җиргә чыкты һәм, бигәнгән атын җитәкләп, кала капкасына килде. Капка сакчылары аны берсүзсез калага керттеләр. Үти төнлә дә, таң аткач та кайтмады. Аны өч көнгә кадәр көттеләр. Үти күренмәде. Шуннан соң аны үлгәнгә исәпләделәр. «Күрәсең, Су иясе алгандыр», — диделәр калада, пошынып.

Бу, билгеле, күңелле хәбәр түгел иде. Ләкин шул ук вакытта монда инде берни эшләп булмый. Су иясе дә, Су бабасы да һәр елны үзенә кирәген алмый калмый. Тиешенчә корбан бирелмәгәндер яисә берәр җирдә кирәкмәгәнгә кан коелгандыр. Шуның белән күңеле булса ярый да бит... Аты-ние белән юкка чыккан Үти турында һәркем шулайрак уйлады. Үтинең югалуына бары Зөлмәт кенә сөенгәндәй булды. Алай-болай бер бөтен ипи турында йә булмаса үтерелгән Марис турында сүз чыгып төпченә башласалар, кем хәзер Зөлмәткә төртеп күрсәтә алыр икән? Андый кеше бер генә иде. Ул әнә юкка чыкты. Шул кирәк андый ялагайга, куркакка!

Марисның ничек үтерелүен, билгеле, Үтидән башка беркем күрмәде. Кодрәт бага биргән алтынчы бөтен икмәк турында Мәмли дә, башкалар да нишләптер онытып җибәрделәр — яңгыр вакытында һәркемнең үз кайгысы булды. Яңгырдан соң исә башка зуррак борчулар калкып чыкты.

Иң нык кайгыручылар пир ата белән би булды, ахрысы. Яшьләр яңгырга эләккән төнне алар озак кына киңәшеп, борчылып утырдылар.

Башка елларны бу вакытта әле көннәр аяз була торган иде. Бу вакытта әле шулай коеп яңгыр да яумый, Аксу да шул дәрәҗәдә кабарып чыкмый иде. Мондый хәл гомумән сирәк була. Бу юлы көн бөтенләй көтмәгәндә бозылып китте. Төньяктан кинәт кара булып болыт калкып чыкты. Чалт аяз күктә шомлы болыт барлыкка килүен һәм аның тиз арада көнбатыш яктагы таулар өстеннән шуышып үтүен, бөтен түбә өстен каплап алуын каладагы һәркем күреп-күзәтеп торды. Яңгыр явар алдыннан кинәт кара болытны урталай ярып, бик озын нечкә тамыр сыман булып көпә-көндез нәҗагай ялтырап алды. Нәҗагай яктысында якындагы тау битләре, үзәннәр, каладагы манаралар яктырып китте. Күк күкрәгән-ниткән тавыш ишетелмәде. Ничектер тавыш-тынсыз һәм бик шомлы булып килде бу яңгыр. Юк, бу гади яңгыр гына булмады. Бу ниндидер куркыныч, хәвефле җил һәм яңгыр булды.

Нәрсәгә ишарә булды икән бу көтелмәгән җил-яңгыр һәм кара болыт? Җирдә, Аккалада шулкадәр күп языклы эшләр бармы, әллә киләчәктә моннан да яманрак нәрсәләр булуын белдерүче бер-бер зилзиләме бу? Ярый ла бер кеше белән бер атны алып, шуның белән генә тынычланса. Бит диңгездә бу вакытта кемнәрдер дулкыннар белән, җил белән көрәшеп Аккалага таба юл ярадыр.

Би өчен дә, пир ата өчен дә иң әһәмиятлесе хәзер менә шул иде. Югалган бер кеше һәм бер аттан бигрәк алар кайдадыр диңгездә булырга һәм төньяк ярларга йөзәргә тиешле кәмәдәге кешеләр турында кайгырдылар. Анда, ул кәмәдә, танышлар да, таныш түгелләр дә булырга мөмкин иде. Ләкин кем генә булмасыннар, алар бигә дә, пир атага да, каладагы башкаларга да бик кирәкле кешеләр иде. Мондагы бик күпләрнең киләчәк язмышы күзгә күренмәгән менә шул кәмәдәге кешеләргә бәйле иде.

Ул төнне калада бик аз кеше тынычлап йоклады. Һәркем йокы аралаш тышка колак салды. Тышта инде җил тынган иде бугай. Тынып ук җитмәсә дә, көндезге сыман ук тоелмады. Әллә соң йокы аралаш кына шулай тоелды микән?

Типкә би дә әледән-әле тышка колак салды. Тышта әле шыбырдап, бәргәләп яңгыр яуды, яңгыр тынган арада, агач ботакларын бөгеп һәм өй ташына ышкып, җил исте. Җил шулай ук морҗа башында ниндидер ачык калган тәрәзә уемнарында улады. Җил-яңгыр тынган араларда аста, яр буенда, тирә-якны дер селкетеп, кыя

ташларына дулкыннар бәрелгәне ишетелде. Бу көннәрдә Типкә бинең йокысы качты. Әледән-әле торып ул караңгы өй буенча йөрде, диңгез ягындагы тар тәрәзә каршысына килеп, яр буен күзәтте. Ләкин анда ара-тирә елкылдап киткән дулкын сыртларыннан, таныш яр шәүләләреннән башка берни күренмәде.

«Унике ел! Унике ел!» — диде ул үзалдына, күптән инде тынгы бирми торган уйларын дәвам итеп. Бер атнаун көннән аның монда килеп аяк басуына унике ел булачак. Унике ел. Кайберәүләр өчен бу ярты гомер. Искән җилдәй үтте дә китте бу унике ел гомер. Искән җилдәй микән? Юк, алай ук түгелдер. Искән җилнең дә төрлесе була. Бер төрлесе аның җиңел генә, шома гына үтеп китә — биттән, агач яфракларыннан, чәчәкләрдән сыйпап үтә дә китә. Бер төрлесе бөтен нәрсәнең астын өскә әйләндереп, кырып, җимереп китә. Синең гомер җилең ничек үтте соң, Типкә би? Кырып-җимерепме, әллә сылап-сыйпапмы? Юк, алай да түгел, болай да түгел, ахрысы. Көн-төн эш белән, тырышлык һәм йокысыз төннәр белән үтте синең унике ел гомерең, Типкә би. Яртысы аның сагыш белән, әрнү һәм газап белән, яртысы... өмет һәм ышаныч белән үтте. Өмет һәм ышаныч, чиксез ярату һәм омтылыш яшәтте сине монда... кыргый яр буенда, кыргый таулар, урманнар, кыргый кабиләләр арасында. Бары диңгез генә, бары кыялар һәм яр буендагы шома ташлар гына таныш һәм якын иде сиңа монда. Аннары — күк йөзе, кояш... мәңге яктылык, тереклек чыганагы — Изге атабыз бөек Кояш кына якын һәм ягымлы иде сиңа монда. Бу ташлар, таулар һәм кыргыйлар арасында.

Баштарак ул монда ничек яшәрен, ничек итеп исән калырын күз алдына да китермәгән иде. Кайчакларда аның суга ташланасы, дулкыннар кочагына кереп юкка чыгасы килгән чаклары да булды. Кайчагында исә элеккеләрне беркайчан да, беркайчан да искә төшермичә, искә төшермәслек, күз алдына китермәслек ят һәм кыргый җиргә, моннан да ераграк җир читенә, Акуан буйларына китеп юкка чыгасы килгән чаклары да булды. Ләкин хәтер булмаган җирнең, төбәкнең беркайда да юклыгын ул бик яхшы аңлады. Пир ата да шулай диде. Кеше булып тугансың икән, теләсә кайда, теләсә нинди шартларда яшәргә кирәк, исән калырга кирәк, диде. Диңгез дулкынына ташлану, Акуан ярларына, Ахирәт якларына бару беркайчан да соң түгел, анда һәркем бара, ләкин аннан кире кайтып булмый, диде.

Язмыш аны менә монда китереп ташлады. Моннан ул кире кайтырга тиеш. Моннан унике ел элек аңа шулай диелде. Күктә — Кояш, җирдә — мака сар. Аклантита сары изге, аның юсыгы изге һәм гадел. Бу хакта Алтын Уртада изге ташка уеп язылган. Ташка уеп язылган Изге атам сүзен беркем боза алмый. Бозса... Юк, беркем боза алмый! Бозсалар, туфан калкачак, дөнья бетәчәк. Тәңренең теләгенә, тәңре юсыгына беркем каршы килә алмый. Хәтта мака сар да.

Унике ел. Газап һәм сагыш, өмет һәм ышаныч. Мака сарлар нәселеннән булган кеше сөргендә унике елдан да артыкка җибәрелми. Изге Бука канын эчеп алар шулай юрадылар. Берничә көннән башкаладан, Алтын Уртадан алтын кәмә киләчәк. Алтын кәмә белән бергә мака сарның боерыгы киләчәк.

Тик менә көннең кисәк бозылып китүе генә яхшы түгел бит әле. Юк, яхшы түгел. Дөнья булгач, җил дә исә, яңгыр да ява, диңгез дә, дулкыннар да котырына. Ләкин хәзер түгел, бу көннәрдә түгел. Бит әле чын-чынлап көннәр бозылырга, дулкыннар кузгалырга иң күбе — бер ай, иң азы ярты ай вакыт бар. Башка елларда шулай булды. Ник быел гына кирәгеннән алда уянды соң әле бу төн җилләре?

Типкә бинең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Бер урыныннан торып, аягына баскач инде ул тиз генә йоклап китә алмаячагын аңлады. Аның кире урынына барып ятасы килмәде. Аннан соң аңа өйнең җылысын җил алып бетергән сыман тоелды. Ул, өйдәгеләрне уятмас өчен, таш баскычтан сакланып кына атлап, аска, түбәндәге катка төште һәм идән уртасындагы учак янына килде, учакка утын өстәмәкче булды. Ләкин ул учакка якынаю белән, караңгыда шәүлә сыман булып, озын күлмәк итәкләрен өстерәп, Бәчкә карчык килеп җитте. Өйне җылы тоту, учакка ягу аның эше иде. Ул үзен бу эшнең остасы дип, ир кеше учакка утын якса, Ут анасы Әбетинең хәтере кала дип исәпли иде. Аның ятагы да шушында гына — учак янында гына иде.

— Үзем, би! — диде ул, йокылы тавыш белән, би кулындагы утын агачларына үрелеп.

Типкә би каршы килмәде, сүзсез генә утын агачын кулыннан ычкындырды да учак янындагы йомшак утыргычка утырды.

Бәчкә карчык тиз-тиз кыланып түгәрәк учакка утын өйде һәм мыштым гына килгән кебек, шәүлә сыман китеп тә барды һәм икенче бүлмәдәге урынына барып ятты.

— Таңга кадәр җитәр, керткән коры утын юк, — дип сөйләнде ул, китәр алдыннан.

Типкә би ничек утырган булса, шул көе кымшанмыйча урынында утырып калды.

## V

Иң беренче мәртәбә ул Фалиянең үзен күреп түгел, аның тавышын ишетеп шаккатты. Аныкы кебек саф тавышны, күкрәк түреннән чыккан сихри тавышны аның беркайчан, беркемдә ишеткәне булмады. Аның яшь, дәртле һәм гүзәл тавышы ул белгән, ул ишеткән бер генә хатын-кыз тавышына да охшамаган иде. Бу тавышта ир кешене сихерле торган, аны үз иркенә тартып ала торган, аны сабыйларча еларга йә булмаса күкләргә ашарга мәҗбүр итә торган ниндидер илаһи бер көч бар иде. Андый тавышлы кыз бар яктан да чибәр, күркәм һәм дәртле булырга тиеш иде.

Таулар янсын, ташлар яусын —
Ташлар ярым түгелсең, —

дип җырлады ул кичтә яр буена якын гына бакчада, ак һәм кызыл ташлардан салынган өйнең ишегалдында, өзгәләнеп, сылу кыз.

Ялгыш кына ишетелеп киткән менә шушы сүзләр һәм сүздән бигрәк шул сүзләрнең сихри моң тавыш дулкыны яшь Типкәнең мәңге хәтеренә сеңеп калды. Аның үзенең җырга-көйгә эллә ни җәптәшлеге булмады һәм ул беркайчан беренче ишетүдән үк яңа көйләрне отып ала алмады. Ләкин сүзләрен ул онытмады. Сүзләрен ул соңыннан да әледән-әле кабатлый торган булды һәм кабатлаган саен ул сүзләрдә аңа беркем төшенә алмаган тирән мәгънә бар сыман тоелды. Чыннан да аның өчен Фалия мәңге ташлап булмый торган ярга әйләнде. Ләкин ул вакытта кыз, билгеле, аны — мака сарның бертуган энесе Типкә бине уйлап түгел, бөтенләй башка «яр»ны күз алдында тотып җырлаган булган. Монысы аның соңыннан, бик соңыннан гына билгеле булды.

Ул көнне Типкә би төньяктан, Балкан ярлары буеннан акайларны җиңеп кайткан иде. Ул кызылга буялган очлы борынлы кәмәнең башында, аягөсте басып, кулларын күкрәк турысында кушырып, киң арыкта Алтын Уртага таба кайтып бара иде. Ул — җиңүче. Күңелдә куаныч, йөздә горурлык, эрелек. Арыкның ике ягыннан сузылган яр буйларында — халык. Яше-карты,

ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар. Барысы да аны каршыларга, аны күрергә, аны котларга чыкканнар. Әле анда, әле монда җиңүчеләрне мактап кычкырган авазлар, тантаналы җырлар яңгырый. Аларга ярдан чәчәк бәйләмнәре ыргыталар. Җиңүчеләр утырган кызыл борынлы кәмәләрне киң арыкта йөзләгән башка кәмәләр, каеклар озата бара.

Ул көнне Типкә би Аклантита башкаласына шулай кайтып керде. Ул көнне аннан да бәхетле, аннан да өлешле, аннан да горур беркем юк иде дөньяда. Менә бермәлне киң арык артта калды, алар уңга борылдылар һәм тигез итеп таш өелгән текә яр буйлап бара башладылар. Мондагы йортларның җимеш бакчалары туп-туры олы боҗра суына килеп терәлә иде. Урамнар монда ярдан читтәрәк, әчке яктарак иде. Кайчандыр диңгез караклары бистәсе булган һәм шуңа күрә телдә Караклар бистәсе дип аталган бу якта хәзер башкаланың хәлле кешеләре — сәүдәгәрләр, базарчылар һәм һөнәр осталары яши иде.

Кызыл борынлы, авыр, җиз белән тышланган кәмә ярга бик нык якынайгач, талгын искән җил аңа беренче мәртәбә Фалиянең моңлы тавышын алып килде.

Менә шушы тавышны ишетү белән, бәхетле, горур җиңүче үзен никтер бәхетсез итеп, мескен һәм көчсез итеп тойды. Дөньяда, башкалада, Изгеләр утравы Аклантитада моннан да, хәтта мака сардан да көчлерәк, бәхетлерәк кемдер икенче берәү бар иде. Дөресрәге, аның бәхетен, аның җиңүен һәм горурлыгын шик астына алырлык бөтенләй башка чыганак, башка кеше бар иде. Аның моңа эче пошты, күңеле тырналды. Мондый тавышлы кешегә, үз бакчасында җырлап торган мондый иягә ачуланып та булмый иде. Ләкин аңа бирелергә дә ярамый иде. Ул — җиңүче! Аны бүген Аклантита алкышлый. Ул бүген мака сар янына барачак. Ул өйләнмәгән, һәм аннан «булачак ишеңне яратасыңмы?» дип сорамаячаклар иде. Аны югарыдан кушып, барысын да алдан уйлап, исәпләп өйләндерәчәкләр... Шул чакны ул үзеннән чакчак кына арттарак, читтәрәк басып барган һәм үзе кебек үк шәрә, таза беләкләрен күкрәк турысында кушырып, үрелмәгән чәчләрен җилфердәтеп горур кыяфәттә алга карап барган меңбашына борылып карагандай итте.

— Кемнең өе икән ул... анда... яр буенда, — диде ул аңа һәм шулай дигәндә никтер үзалдына кызарынып уңайсызланып китте.

— Кайсы өйне әйтәсең, би, — диде меңбашы, аңлап җитмичә күзен читкә борып.

— Әле генә берәү җырлап калды, ишетмәдеңмени?! — диде ул, шактый исе китеп.

— Ул — минем өй, — диде меңбашы Әмәк, никтер авыр сулап.

— Җырлаган кыз кемнеке, — дип кычкырды би, чукрак кеше белән сөйләшкән сымак.

— Кыз да минеке, би, — диде меңбашы Әмәк, тыйнак кына.

Фалия меңбашы Әмәкнең тәрбиягә алган кызы булып чыкты. Дөресрәге, аны Әмәк түгел, ише Залия алган тәрбиягә. Залия үзе Изге Урта аксөякләренең чыбык очы икән. Фалия Залиянең бертуган сеңлесенең кызы булган. Фалиянең этисе кәмәләр белән диңгез сугышында үтерелгәч, аның хатыны Сәлинә икенче мәртәбә кияүгә чыккан. Ләкин бер елдан ул да үлеп киткән. Шулай итеп, биш яшьлек Фалия ятим калган. Менә шул чагында алганнар да инде аны Әмәкләр.

Фалия Залиянең үз балалары белән бергә үскән. Беркем аңа кырын күз белән карамаган, беркем аны читкә тибәрмәгән. Ләкин тора-бара кыз бала үзенең ятимлеген сизә башлаган. Шунлыктан ул шикчел, астыртын булып үскән. Шуның өстенә ул бик моңлы булган, еш кына ялгыз калып җырларга яраткан һәм Залиянең генә түгел, барлык тирә-як кызларын уздырып чибәр, сылу булып үскән. Ерактан аның моңлы тавышын ишеткән кешеләр, уфтанып: «Бәхетсез булыр бу бала», — дигәннәр. Күреп аның гүзәллегенә сокланган кешеләр: «Моннан бәхетле беркем булмас дөньяда», — дигәннәр.

Көннәрдән бер көнне унбиш яше тулар-тулмас чагында Фалия үги атасы, үги анасы белән талаш чыгарган. Әмәкнең төп өе башта тышкы койма янында, арткы урамнарның берсендә, чытыр бистә дигән җирдә, күренексез җирдә булган. Фалияне урам җыенында, халык алдында тәрбиягә алгач, бу хакта тамга сугылган такта булгач, Әмәк үзенең чытыр бистәсендәге өен сатып, Фалия исемендәге өйгә күченгән. Иркен бакчасы текә ташлы ярга, су буена чыга торган ике катлы зур, матур йорт Залия белән Сәлинәнең аталарыныкы булган. Шулай булгач, бу таза, зур йорт Фалиянеке генә түгел, үги әнисе Залиянеке дә булып исәпләнергә хакы булган. Көн-төн төрле кәмәләр йөреп торган, шау-шулы, күңелле су буендагы төп йортка күченгәндә Әмәк тә, ише Залия дә шулайрак дип уйлаганнар. Кызыбыз Фалиягә дә күңелле булыр, дигәннәр. Аннан соң бу вакытта йортның беренче һәм бердәнбер хуҗасы Фалиянең

картәтәсе үлеп киткән булган. Ни генә булмасын, урам җыены да, бистә түрәләре дә, беркем дә Әмәкләрнең күчепеп килүенә каршы сүз әйтмәгән. Барысы да Акланти-таның изге юсыгына ярашлы итеп эшләнгән.

Ун елга якын болар монда бик тыныч, бик күңелле яшәгәннәр. Беренче мәртәбә бозылышу менә шул өй аркасында чыккан. «Бу минем өй. Сез минем туган әтәм дә, инәм дә түгел!» — дигән унбиш яшьлек Фалия, шартлатып, үзенең үги атасы белән үги анасына. Нишләсеннәр, ата белән ана шаккатып авызларын ачканнар да калганнар. Шулай да иплә кенә аңлатырга да тырышканнар, без сине карап үстердек, син безнең кызыбыз, дигәннәр. Фалия елаган, холыксызланган. Тора-бара мондый ызгышлар ешая башлаган һәм бу боларны өйдән үк куарга тотынган. Әмәкнең дә, Залиянең дә тавышны, ямьсезләнүләрен өйдән чыгарасы, күршеләргә белдерәсе килмәгән, ләкин боларның өендә, ишегалдында, бакчада Фалиянең моңлы, дәртле җыр тавышы белән аралашып, холыксыз, чәрелдек тавышлар да ишетелгәли башлаган. Күршеләр, билгеле, сизенми калмаганнар. Хәзер инде бакчада аның тавышы ишетелгәндә, кайберәүләр: «Әнә юха ысылдый», — дигәннәр, кайберәүләр исә, сөенеп: «Шул кирәк аларга! Карамасыннар иде үксезне!» — ди торган булганнар.

Әмәкнең беркайчан бигә үзенең тормышы, өй хәлләре турында сөйләгәне юк иде. Би кешесе һәм бинең иң якыны булса да, алар арасында моңарчы үтеп булмаслык каршылык, тау ята сыман иде. Аннан соң би дә үзе турында сөйләргә, үзенең күңеле турында чишелергә бик үк яратмый иде. Акайларны җиңеп кайтканда кызыл борынлы биек зур кәмәнең алдында янәшә барганда булган кыска гына сөйләшүдән соң алар бер-берсенә ничектер якынаеп киткәндәй булдылар. Дөресрәге, Әмәк меңбашы бигә үз атасы кебек якын булып, туганнарча якын булып тоелды. Ә колак төбендә, ятса да, торса да, яшь кызның өзгәләнеп җырлаган дәртле тавышы ишетелеп торды һәм авыз эченнән генә әледән-әле ул аның җыр сүзләрен кабатлады:

Таулар янсын, ташлар яусын —
Ташлар ярым түгелсең, —

диде.

Икенче бервакытны, Әмәк меңбашы белән икәүдән-икәү генә калгач, ул аннан тагын Фалия турында сораштыра башлады. Серле ятимә кыз турында аның барысын да беләсе килде. Әмәк сөйләде, теләр-теләмәс кенә

сөйләде. Баштарак ул, аны-моны искәрмичә, тәрбиягә алынган кызын ничек булса, шулай тасвирларга тырышты — мондый чакта мактаудан бигрәк яманларга туры килде. Чөнки буй җиткән кыз аның да, ише Залиянең дә каннарына әледән-әле тоз салып кына тора иде. Ләкин тәҗрибәле кеше буларак, ул бинең Фалия белән тиккә генә кызыксынмавын аңлап алды. Шуннан соң инде ул, Фалия турында сүз чыкканда, аны гел яхшы яктан сурәтләргә тырышты.

Тагын да беркадәр вакыттан соң яшь би үзенең өлкән яшьтәге меңбашына:

— Минем аны күрәсем килә! — диде һәм теге вакыттагы кебек тагын кып-кызыл булды.

Әмәк аны үзләренә кунакка чакырды. Мака сар нәселеннән булган бинең меңбашы өенә кунакка баруы ул меңбашы өчен зур дәрәҗә иде. Типкә би берсүзсез риза булды. Әмәк берәр атна алдан әзерләнергә теләвен белдерде.

— Минем хәзер үк барасым килә! — диде түземсез яшь би.

Меңбашы авыр сулап куйды. Шулай да бигә сиздермичә генә үзенең кешесен тиз генә өенә җибәрде. Би килгәнче, өйнең астын өскә актарып, анысын-монысын җыештырганнар, казан асканнар һәм яхшы итеп сый әзерләгәннәр. Аннан да бигрәк Фалияне кунак кызы кебек итеп баштанаяк яңага киендергәннәр һәм аңа алдан ук бик зур кунак киләсен әйтеп куйганнар. Бу хакта соңыннан Фалия үзе сөйләде.

Ләкин ул чакта би аның аяк очына төшеп торган киң итәкле, кыска җиңле яңа күлмәгенә дә, муенындагы яңа гәрәбәләренә дә, матур итеп үрелгән кара чәч толымнарына да, беләгендәге беләзекләренә дә — бернигә дә игътибар итмәде, ахрысы. Аның чибәрлеге, табигый чибәрлеге андый ясалма бизәкләрне күмеп китәрлек иде. Буйга ул калку гына, тулы гәүдәле, озынча ак битле, кара кашлы. Күзнең явын алырлык иде. Аның тышкы кыяфәте дә тавышы кебек үк искиткеч иде. Мондый чибәр, күркәм кызны бинең беркайчан күргәне, очратканы булмады.

Кунакта ул төн урталарына кадәр булды. Алар хуҗа белән ашадылар, эчтеләр. Тегесен-монысын сөйләштеләр. Үги атасы сорагач, Фалия оялган, кызарынган би өчен үзенең яраткан җырын җырлады.

Өйдә, аш-су янында ул-бу турында бернинди сүз булмады. Кирәкле сүз төнлә кайтып киткәндә әйтелде:

— Мин аңа өйләнәм, — диде би, билгеле бер карарга килеп.

— Мин сиңа әйтмәдем, би, — диде Әмәк, көттереп. — Ул инде им өендә булды.

— Булсын! Бик яхшы! — диде би.

— Аның өч яшьлек улы бар, — диде үги ата.

— Булсын, улы белән алам! — диде би, чигенергә теләмичә.

— Бездән каршылык юк, би, — диде Әмәк.

Бер атна узгач, би кәмәче бистәсенә яучы җибәрде. Әмәк кәмәче яучыга да шул ук сүзләрне кабатлады: «Бездән каршылык юк», — диде. Шуннан соң ике арада тыз-быз арадашчылар йөри башлады. Типкә би эшне тиз тотмакчы булды. Ләкин эшләр ул теләгәнчә үк тиз бармады. Әмәк ягыныкылар булачак никахка кирәгеннән артык сөенеч белдерсәләр дә, би ягыннан әллә ни сикереп төшмәделәр. Аның үз әнисе, үги әниләре, күпсанлы ага-энеләре мака сар нәселеннән булган Типкә бинең ниндидер кәмәче кызына өйләнергә ниятләвен өнәп бетермәделәр. Аны, билгеле, яклаучылар да табылды. Ләкин каршылык күрсәтүчеләр күбрәк булып чыкты. Иң ахырда бу хакта мака сар Карунга җиткерделәр. Бәхәсне бары ул гына хәл итә ала иде.

Күк төстәге озын чапан кигән, кулына бөркет сынлы алтын таягын тоткан мака сар аны фил сөягеннән ясалган тәхетендә утырып торган килеш каршылады. Аның чал кергән озын кара чәчләре унике үремгә үрелгән һәм җилкәсенә салынып төшкән иде. Сакал-мыегы матур итеп кырылган, озынча бите, майланган кебек, шоп-шома булып ялтырап тора. Ул инде урта яшьтән узган һәм бераз гына симерә башлаган. Бит тиресе һәм тән тиресе картаймасын, җыерчыкланмасын өчен, картлык тиз генә килмәсен өчен, көн дә иртә-кич ике мәртәбә Кайнар һәм Салкын чишмәдән килгән коеда су коена, һәм шуннан соң аның битен, тәнен төрле хуш исле үлән майлары, зәйтүн мае катыштырып ясалган махсус майны тәненә үкиләр. Шунлыктан аның бите шулай яшь булып, шома булып ялтырап тора. Аны еш күргән кешеләр шулай дип сөйлиләр.

— Сине кәмәче кызына гашыйк булган дип сөйлиләр, — диде мака сар Карун, көлемсерәгәндәй итеп.

— Алар белеп сөйлиләр, агам, — диде Типкә би, түбәнчелек белән, чак-чак кына башын калкыткандай итеп. Би тәхет алдындагы, мака сарның аягы астындагы зур камыш чыптага тезләнгән килеш сөйләште.

— Ул кыз шулай бик матурмыни? — диде мака сар.

— Миңа матур, — диде мака сарның энесе Типкә.

— Кем кызы соң ул? — диде мака сар, төпченеп.

— Кәмәче бистәсеннән меңбашы Әмәк кызы Фалия, агам, — диде Типкә би, бөтен батырлыгын җыеп.

— Фалия? — диде мака сар, гаҗәпләнгән булып, тагын да ныграк көлемсерәп. — Мака сарның энесенә килешер микән тома ятимә кызга өйләнү?

— Әмәк аны тәрбиягә алган, агам. Фалия ятим кыз түгел, — диде би һәм шул чакны ул үзенең тынычсызланудан тирли башлавын сизде.

— Миңа алай дип әйтмәделәр, — диде мака сар бераздан, җитди итеп.

— Фалиянең туган әтисе кәмиләр белән диңгез сугышында шәһит киткән, агам. Ул изгеләр нәселеннән.

— Алай икән, — диде мака сар көттереп һәм үзенең аяк астында, камыш чыптада тезләнеп торган энесенә төбәп карады, боерган сыман әйтеп куйды: — Минем ул кызны күрәсем килә, — диде.

Ул көнне мака сар белән шундыйрак сөйләшү булды. Яшь би бөек агасы яныннан каршылыклы уй-хисләр белән чыгып китте. Мака сарның изге сараена чит кешеләрдән беркем кертелми иде. Алтын Уртадагы — Изге калкулыктагы алтын сарайларны, изге өйләрне тыгыз боҗра булып көн-төн мең кешелек ир сакчылар саклый иде. Чит кешеләр түгел, хәтта аның иң якын ир туганнары да монда бик сирәк кертелә һәм кертелгәндә дә, бик нык тикшерелеп, сакчылар белән бергә кертелә иде. Шунлыктан урта эне Типкә бинең монда әле беркайчан булганы юк иде. Сарайдан, изге бүлмәдән чыкканда аның күзләрен бәйләделәр һәм ике ягыннан ике кеше кулларыннан җитәкләп каядыр алып киттеләр. Көн яктысына чыкканчы ул ниндидер бүлмәләр аша үтте, ниндидер баскычлардан менде, төште, борылды, чигенде. Аның борынына ниндидер ят исләр, хуш исләр килеп бәрелде, колагына әле балалар тавышы, әле яшь хатыннарның көлгән тавышы ишетелеп калды.

Ниһаять, аны якты булып, ап-ачык булып кояш яктысы төшкән биек бүлмәгә китереп куйдылар, күзләрен чиштеләр дә кайсы юлдан китәргә кирәклеген аңлатып китеп бардылар. Монда Типкә бине хәрби ярдәмчеләре көтеп торалар иде.

Икенче баруында ул агасы мака сар катына күренмешкә меңбашы Әмәк һәм аның кызы Фалия белән барды. Мака сар бу юлы энесенә түгел, Әмәк белән кызга

бер-ике сорау бирде дә, шуның белән күренеш төкәнде. Әмәк белән Фалияне күзләрен бәйләп сакчылар шундук алып чыгып киттеләр. Типкә би агасы белән икәүдән-икәү генә калды.

— Өйләнерсең, — диде мака сар, кыска гына итеп.

Типкә би эне сөенеченнән нишләргә белмичә башын идәнгә орды һәм агасының чапан итәген үбеп алды.

— Агам! Тәңрем! — диде ул, үзалдына мыгырданып, кызарынып.

— Ошады миңа кызың, — диде мака сар.

Шулай дигәндә аның тавышы калтыраныбрак чыкты һәм никтер тынгысыз күзләре ялт-йолт йөренде, күз карашы энесеннән читкә юнәлде.

Типкә би андагы бу сәер үзгәрешләрне кырын күзе белән генә күреп алды, ләкин ул чакта аңа ничектер игътибар итеп җиткермәде. Барысы да соңыннан гына билгеле булды.

Бер ел чамасы Типкә би, йолага туры китереп, киявләп йөрде. Аннан соң шаулатып туй ясадылар. Туй башта бистәдә булды. Иң элек алар Фалия белән икәүләп, төзәнеп-бизәнеп, кияү егетләре һәм кызлар озатуында бистәдәге Изге ана өенә барып садака бирделәр. Анда аларны бөтен бистә халкы алкышлады. Әмәк кәмәче өенә кунаклар — туган-тумача, таныш-белеш — бүләкләр, күчтәнәчләр ташыды. Аларның өеннән туктаусыз күңелле шау-шу, чыр-чу ишетелеп торды, бөтен тирә-якка тәмле аш-су исе таралды. Ул көннәрдә йөзләгән, меңләгән кунакларны сыйлау өчен куй артыннан куй суйдылар, базлардагы чагыр тулы зур-зур чапчакларны бушаттылар. Анда җыр, монда җыр һәм күңелле көйләр ишетелеп торды.

Шулкадәр күп халыкны сыйларга Әмәкнең мөмкинлеге койты иде, Типкә би туйга берни кызганып тормады, үзенең ерактагы көтүлегеннән сугымга сыерлар кайтартты, амбарларыннан тамгаланган һәм бишәр-унар еллык бузаларын китертте. Әмәк кәмәче капкаларында, өендә, бакчасында ул көннәрдә төрле төстәге байраклар, сөлгеләр җилфердәде. Якындагы болында туй вакытларында гына үткәрелә торган уеннар, ярышлар булды.

Кәмәче бистәсендәге туй өч көн дәвам итте. Шуннан соң ул Алтын Уртага — бинең туган йортына күчте. Мондагы туй тагын да баерак, тагын да шау-шулырак һәм күркәмрәк булды. Ләкин нишләптер бистәдәге туй — беренче мәртәбә кияү егете булып кыз өенә аяк басу, Изге ана өенә бару, андагы ыгы-зыгы һәм андагы шат-

лык, бәхет тойгысы яшь бинең хәтерендә ныграк сакланып калды. Соңыннан ул нишләптер Алтын Уртада булган күренешләрне түгел, бәлки бистәдә — ярлырак, гадирәк кешеләр белән булган күренешләрне исенә төшереп сагынды. Анда чакта ул бәхетлерәк иде, үзенең сөеклесен күрү, тою, аның белән бергә булу тойгысы, куаныч тойгысы тулырак һәм ваемсызрак иде. Күрәсең, шуңа күрә дә ул әледән-әле менә шул беренче тойгыларын сагынды да.

Фалияне Алтын Уртага ул су юлы белән алып кайтты. Кызны алып килү өчен агасы аңа үзенең ун кәмәсен, кораллы йөз ирен бирде. Кәмәләрне аллы-гөлле итеп бизәделәр. Иң зурысына уртага кыз белән кияү өчен алтынлап затлы тукымалардан чатыр корылган иде. Йола саклап, Фалияне кияү егетләре төнлә урлап киттеләр. Кияү егетләрен кораллы кызлар куа чыктылар. Ике арада сугыш булды. Бу билгеле тамаша өчен генә — ике як ярдан, күперләрдән, бакчалардан, агач башларыннан карап торган халык өчен оештырылган сугыш иде. Ләкин ул көнне тамаша өчен оештырылган сугышта да чынлап үлүчеләр булды. Туйның иң кызыгы шунда — анда кемнәрдер үләргә, кемнәрдер җиңеп чыгарга тиеш иде. Җиңүче, әлбәттә, би яклылар, кияү егетләре булды. Тышкы ягына җиз, эчке ягына кургаш коелган биек таш койма белән әйләндереп алынган Алтын Уртада — Аклантитаның бөек патшасы — мака сары яши торган Изге калкулыкта Фалия белән Типкәнең туе ай буена барды. Монда алтынланган биек, якты сарайларда чагыр елга булып акты, тау-тау итләр пеште, олау-олау исәпсез-хисапсыз икмәкләр пешерелде. Көтү-көтү мал-туар суелды. Табын янында меңләгән кунаклар сыйланды. Алтын Уртада — дөньяда иң бәхетле, иң изге аксөякләр янында үскән һәм бала вакытыннан төрле туйларны, аш-суларны, шау-шулы мәҗлесләрне күп күргән Типкә би өчен мондагы туй әллә ни тәэсир итмәде. Аңа үзенең туе элек ул күргәннәрнең бер дәвамы гына булып тоелды. Ләкин анда да кайбер нәрсәләр аның күңел күгендә онытылмаслык булып уелып калды.

Аларның бу туенда агасы мака сар Карун да катнашты. Беренче көнне туй башлыгы булып ул иң түрдә утырды. Аның уң ягында — яшь кияү, сул ягында чәченә аллы-гөлле чәчкәләр кадаган, акка кызыл буй төшкән күлмәк кигән Фалия утырды. Шулай туй кызган чагында мака сар Карун аягүрә басты да, Фалия ягына карап, елмаеп:

— Безнең киленне бик матур җырлый диләр. Безгә берәр җыр җырламас микән ул, — диде.

Фалия бу кадәр олылауга нишләргә белмичә уңайсызланып күзләрен түбән төшерде.

Типкә би, тынын кысып, аңа ярдәмгә әзер булып, агасы аша аңа карап алды.

— Син теге... мин беренче ишеткән җырны җырла, — диде ул, Фалияне дәртләндереп.

Якында гына бер читтәрәк, фил сөягеннән кырып, алтынлап ясалган арфа янында утырган кыз, җырчы әйтү белән тиешле көйне башлап җибәрергә әзер булып, нәфис бармакларын көмеш кылларга тидереп алды. Фалия тартынып кына урыныннан торды һәм, калку урыннан төшеп, арфа янына килде. Кара матур чәчләрен көдрәләтеп маңгаена төшереп куйган, ирененә кызыл сөрткән чибәр кыз сөрмәле күзләрен тутырып аңа карады. Фалия арфачыга җырланачак җырның көен әйтү белән, көмеш кыллар җиңелчә чыңлап алды. Фалия мака сарга карап җырлый башлады. Башта аның тавышы калтыранып чыкты, ләкин бераздан ул үзен шактый иркен тотып, җырын дәвам итте:

Таулар янсын, ташлар яусын —
Ташлар ярым түгелсең, —

диде ул, Типкә бигә тәэсир иткән җырның сүзләрен кабатлап.

Кунаклар аның җырын тын да алмый тыңлап утырдылар. Озын мәрмәр аяклы алтын савытларда утлар янды, чагыр эчүдән һәм җыр тәэсиреннән яшь ирләрнең, яшь хатыннарның — кунакларның күзләре янды. Җыр тынгач, барысы да шаулатып кул чаптылар, түземсезрәкләр аяк тибәргә, өстәлләрдәге буш чүлмәкләрне кагарга тотындылар. Майланган, хуш исләр аңкытып торган изге йөзе белән елмаеп, мака сар аягына басты һәм Фалиянең беләгенә җәүһәр ташлар тезеп ясалган алтын беләзек кидерде. Мака сарның бүләген барысы да янә алкышлап шауладылар.

Шуннан... шуннан алар бергә тора башладылар. Алтын Уртада, Түгәрәк утрауда үз сараенда Типкә би белән Фалия бәхетле гомер кичерә башладылар. Им өендә йөргәннән соң туган Мәмлине Фалия йола буенча әтисе-әнисе өендә — Әмәкләрдә калдырды. Ике-өч ай буена алар яшь кияү белән кәләш булып балда-майда йөзделәр. Аларның түбә өстендә көн дә якты кояш балкып торды.

Аклантита патшаларын бигрәк тә көнчеллек һәм комсызлык җене котырткан. Бик күпләргә Кәми чүлендәге Куфу сар төрбәсе тынгылык бирмәгән. Күккә таба очлаеп менгән, зур-зур шома ташлардан өелгән һәм пирамита дип аталган ул серле төрбә турында кәмиләр үзләре дә, башкалар да әллә нинди имеш-мимешләр сөйлиләр. Берәүләр әйтә, Куфу, имеш, шундый биек төрбә салдырып, үз заманындагы һәм үзенә кадәр заманнардагы барлык сарларның данын томаламакчы булган, диләр. Икенче берәүләр: үзенә буйсынган барлык кабилә кешеләрен бергә туплау, аларны бер халык итү өчен аларны юри шулай таш кисәргә, таш ташып, таудай таш өяргә мәҗбүр иткән, диләр. Өченче берәүләр исә башкачарак сөйлиләр.

Айның-Кояшның, йолдызларның хәрәкәтен һәм шул нигездә күктәге аллаларның уйларын-теләкләрен тикшереп-күзәтеп торучы гыйлем ияләре Кәми сары Куфуга киләчәк ике мең ел эчендә туфан калкып, бөтен җирне су басачагы, барлык кешеләрнең, барлык тереклекнең юкка чыгачагы турында әйткәннәр. Кеше гомере белән исәпләгәндә ике мең ел вакыт Ай-Кояш һәм йолдызлар гомере белән исәпләгәндә ике көнлек вакыт икән. Туфан шул ике меңеллык вакытның йә башында, йә уртасында, йә ахырында калкырга мөмкин икән. Җирдәге тереклекне исән калдыру өчен хәзердән үк чарасын күрә башларга кирәк, дигәннәр гыйлем ияләре. Кәми сары Куфу болай да бик динле булган һәм барлык эшен аллалар теләгән яхшы аңлаучы галимнәр белән киңәшеп эшли торган булган. Хәзер дә ул алар сүзенә колак салган һәм үзе исән чакта аларның теләген тормышка ашырырга булган. Чүл уртасында, калку җирдә, Хапи суының сул ягында, бик тирән чокыр казытып, шул чокырга ул эре-эре ташлардан бик зур сарай салдырган. Хапи ярына кадәр сарайга җир астыннан арык үткәргән. Арыкның ике башында да төрле тирәнлектәге коелар булган. Кирәк чакта ишек-капкаларны ачып, коеларга елгадан су агызганнар, коелардагы су арыкка агып төшкән һәм җир астындагы сарайга кадәр килеп җиткән. Җир астындагы арык шулкадәр киң һәм тирән икән, аның буенча төрле зурлыктагы кәмәләр йөзә ала һәм, кирәк булса, чүл уртасындагы, җир астындагы сарайдан Хапи елгасына барып чыга ала икән.

Җир асты сарае өч катлы, ди, имеш. Анда бүлмәләрнең, һәртөрле куыш, амбарларның исәбе-хисабы юк, ди. Ул куышларга, амбарларга Куфу сар йөз мең кешегә ун елга җитәрлек азык-төлек ташыткан, ди. Аннан соң ул

үзенең барлык алтын-көмешләрен, коралларын шунда ташытып куйган, ди. Алтын-көмеш, җәүһәр, мәрҗән амбарларда тау-тау өелеп тора, ди.

Бүгенге көндә башы күккә ашкан әлеге таудай төрбә менә шул җир асты сарае өстенә салынган икән. Куфу сар заманында туфан калыккан. Аннан соң менә мең ел вакыт үткән. Узган мең ел эчендә вак-төяк җир тетрәүләр булган булуын, ләкин бөтен җирне су басарлык булып туфан калыкмаган. Куфудан соңгы сарлар аның төрбәсен баштарак бик нык саклап торганнар һәм ул тирәгә бернинди чит кеше якын китерелмәгән. Әмма вакытлар үтү белән, сарлар алышына барган, Кәминең элекке халкы да алышынган. Әле анда, әле монда яңа төрбәләр барлыкка килгән. Яңа сарлар, үч итеп, ачу итеп, бер-берсенең төрбәләрен вата-җимерә башлаганнар, һәм, әлбәттә, Куфу төрбәсен ватарга, андагы байлыкларны алырга тырышып караучылар да күп булган. Ләкин күпме генә тырышмасыннар, беркемнең дә әлегә Куфу пирамитасының серенә дә төшенгәне юк, аның эченә, андагы сарайларга да үтеп керә алганы юк.

Аның серен бары тик Кәми галимнәре генә белгән. Ул серне алар буыннан буынга тапшыра килгәннәр. Алар аны үзләре кебек галим булмаган һәм махсус ант эчмәгән беркемгә чишмиләр икән. Илгә бик зур бәла-каза килсә генә яисә төрбә төзелүгә ике мең ел тулгач кына алар Кәми сарына яисә аның ышанычлы кешеләренә әлеге төрбәнең серен һәм җир асты сарайларына керү юлын өйрәтә алалар икән.

Кәминең үзендәге һәртөрле ярлы-ябагай, һәртөрле бур-карак һәм юлбасар гына түгел, Аклантита сарлары да күптән инде менә шул төрбә астындагы исәпсез-хисапсыз байлыкларны кулга төшерү турында хыялланганнар һәм төрлечә чарасын да күреп караганнар. Шуның аркасында кәмиләр белән лелегләр арасында әледән-әле яулар-сугышлар булган. Бер мәртәбә моннан ике йөз ел чамасы элек Аклантита сары Кәмине басып алган, Куфу төрбәсен төбенә кадәр сүтеп ташламакчы булган. Алар бары өстән бер ташны гына куптарып төшерә алганнар. Аяз көнне кинәт күк күкрәгән, яшен яшьнәгән һәм төрбә башына менгән лелегләрнең барысын берьюлы яшен суккан. Янып кара күмергә калган лелегләр төрбә башыннан коелып кына төшкәннәр. Шуннан соң Аклантита сары, калган кешеләре белән кәмәләргә утырып, тизрәк үз иленә кайтып китү җаен караган.

Ике мең ел эчендә бик көчле булып туфан калкачак дигән сүзне Аклантита галимнәре дә әйткәннәр. Алар да Айны-Кояшны һәм йолдызларны көн-төн тикшерепкүзәтеп торалар. Алар бигрәк тә тауларны, тау араларыннан чыккан суларны тикшерәләр. Куфу турындагы имеш-мимешләргә ышанып, бәлки, үз галимнәренең сүзләренә колак салып, алар да җир астында куышлар, сарайлар, җир асты юллары салдырганнар. Төрле җирдән, төрле илдән килгән байлыкның яртысы җир өсте сарайларын, коймаларын бизәүгә китсә, калган өлеше җир астындагы ныклы амбарларга, андагы куышларга, чүлмәкләргә тутырыла бара. Аклантита мака сарлары да барлык башкала халкына ун елга түгел, өч елга җитәрлек азык-төлек җыеп куйганнар. Андагы азык-төлек ел саен яңасына алыштырыла тора, ләкин алтын-көмеш, затлы ташлар, энҗе-мәрҗән һәм кыйммәтле кием-салым кире алынмый, бары элеккесенә яңасы гына өстәлә.

Мака сар Карун бу эштә барлык Аклантита сарларын уздырып җибәрде. Көннәрдән бер көнне табылган байлыкның яртысын түгел, дүрттән өч өлешен амбарларга салдыра башлады. Сатудагы, кулланудагы байлык, товар күзгә күренеп кимеде. Бигрәк тә алтын-көмеш, җиз-бакыр һәм җәүһәр әзәйде. Барысын да Карун үзенең җир астындагы һәм җир өстендәге кырыкмаса-кырык сараена, амбарларына, чүлмәкләренә тутыра башлады. Элеккечә бар байлыкның яртысын җыеп салып барганда да бик җиткән иде югыйсә. Ләкин Карунның комсызлыгы башыннан ашты. Моны һәркем белде. Карун исә галимнәр сүзенә дә, киңәшчеләр һәм сакалар сүзенә дә колак салмады. Комсызлык чиргә әйләнде.

Фалиягә өйләнеп бергә тора башлавына ике-өч ай чамасы булганда, көзге матур көннәрнең берсендә, иртәнге якта ашап утырганда кемдер капка шакыды. Капка янында кеше-кара юк иде, ахрысы, шакучыга тиз генә ачмадылар. Бераз тынып торгач, шаку тавышы тагын кабатланды. Бинең күңеле, нидер сизенеп, тынычсызланып алды. Аягөсте басып, ул тәрәзәдән капка ягына карап алды. Күп тә үтмәде, каралардан берсе мака сардан кеше килүен кереп әйтте. Бераздан ике коралды ирән ияртеп, мака сар йомышчысы Йули килеп керде һәм, тартынып, кыюсызланып тормастан, туп-туры бусага аша үтте дә ашаучылар ягына якынлашты.

— Сине мака сар чакыра, — диде ул сораулы караш белән үзенә текәлгән Типкә бигә.

Мака сар аны бик сирәк чакыра иде. Телсез кеше кебек ул аптырап Йулигә карап тик торды.

— Ишеттеңме, Типкә би? — диде тәкәббер Йули, балачага белән сөйләшкән сыман.

— Ишеттем. Барырмын, — диде, ниһаять, Типкә би, исен җыеп.

— Барырмын түгел, барабыз, — диде Йули. — Минем белән барасың.

— Ярар алайса, — диде Типкә би, бик авырлык белән генә.

Ашавыннан туктап калган Фалия барысын да күрепишетеп торды. Ул әле бу сөйләшүнең эчтәлеген тиешенчә аңлап-төшенеп тә җитмәде бугай, шулай да иренең үзгәргән тавышы, бозылган йөзе аны шундук куркуга салды. Урыныннан сикереп торып, ул аны чытырдатып кочып, кочаклап алды.

— Җибәрмим! Беркая да бармыйсың! — диде ул кинәт, күз яше сизелеп торган бер ныклык белән, кабаланып.

Типкә би үз-үзен мәҗбүр итеп елмайган булды.

— Ник? Нәрсә булды? — диде ул, гаҗәпләнгән булып.

— Җибәрмим! — диде Фалия, кайнарланып. — Мин күрдем... нидер булган...

— Мака сар боерыгы үтәлергә тиеш, бикә, — диде би, йомшаграк итеп.

— Беләм! — диде Фалия. — Алайса, ник курыктың?

Бу сүзләрен ул иренә карап әйтте, ләкин би җавап биреп тормады, ул инде тынычланган иде.

— Би кешегә курку килешми. Синең яннан китәсем килми, шуңадыр, — диде ул.

Фалия, ышанып җитмәсә дә, беркадәр тынычланды бугай. Шулай да ишектән чыкканда ул аның муенына сарылды.

— Тиз кайт! — диде ул, үпкәләгән бала сыман еламсырап.

— Кайтырмын, — диде Типкә би һәм ипләп кенә яшь хатынның кайнар беләкләреннән арынды да, нык-нык басып, капкага юнәлде.

Шул китүдән китте һәм бүтән әйләнеп кайта алмады. «Кайтырмын» дигән сүзен үти алмады би. Дөрес, кайтудан өметен дә өзмәде, шулай да менә инде унөченче ел сөекле ише Фалияне күрә алганы юк.

Ак сарайда аны бернинди тоткарлыксыз мака сар янына алып бардылар. Ул бизәкле зур капкалар аша, тезелеп киткән алтын сыннар яныннан тигез таш җәелгән матур сукмаклардан туп-туры Ак сарайга юнәлде.

Иң алдан, юл күрсәткән сыман, Йули барды, җинаятьче сыман аның артыннан Типкә би, аның артыннан кораллы ирләр барды.

Ак сарайга кергәч, матур итеп бизәлгән, ташларына канатлы балыклар, суүсемнәре, икенче ягында алтын балыклар йөзеп йөргән зәңгәр диңгез сыман итеп ясалган, бизәлгән, идәнгә йомшак палас җәелгән бүлмәдә көтеп торырга куштылар. Бу вакытта мака сар кайнар су белән коенырга ярата иде. Ул аны белде һәм тыныч кына көтеп утыруында булды. Күңеленнән фараз кылды: тагын акайларга каршы яуга җибәрергә уйлый микән, әллә соң ерак илләргә барасы сәүдәгәрләрне озатып куярга кушар микән, диде.

Бер ярты сәгатьтән аны агасы янына чакырдылар. Гадәтенчә Карунның йөзе тыныч, ягымлы һәм ялтыравык иде. Гадәтенчә аннан хуш исләр килеп тора иде. Аның катына килеп керү белән би шанлы тәңрегә котлау сүзләре әйтте һәм үзенең буйсынуын белдереп идәнгә егылды.

— Сиңа йомышым төште, энем, — дип сүз башлады мака сар, тыныч кына ягымлы тавыш белән.

— Тыңлыйм, агам, — диде би.

Ләкин мака сар йомышын әйтеп өлгермәде, сул якка борылып, ачык ишек аша кемгәдер баш какты. Ул яктан чандыр гәүдәле корышып беткән бер карт килеп керде. Өстенә ул ап-ак киндер күлмәк кигән, кулына ниндидер юан, сырлы таяк тоткан, башы тап-такыр, аягында исә камыш чабата иде. Би шундук танып алды — бу Кәми keләүчесе булырга тиеш иде. Бөтен гомерләре буена келәүлектә яшәүче изге Кәми келәүчеләре — галимнәр менә шундый була иде.

Таяклы кәми гәүдәсен төз тотып бүлмәгә керде, мака сарга җиңелчә баш какты, аннан соң каш астыннан гына бигә карап алды да аякларын бөкләп туп-туры идәнгә, каты җиргә утырды.

— Таныш бул: келәүче баба Мати, — диде мака сар, энесе бигә карап. — Кырык ел буена кәмиләрнең келәүлегендә яшәгән. Лелег дип белмәгәннәр. Ул аларның серләрен алган. Аңлыйсыңмы, төрбәнең серен алган!

Соңгы сүзләрен ул куаныч һәм тантана белән әйтте. Гадәттә салынып торган калын кашлары астыннан күренми торган кысылып беткән комсыз күзләре зур булып ачылды. Анда куаныч һәм шашкын бер комсызлык иде.

— Аңлыйм, — диде Типкә би, берни аңламаса да.

— Аңласаң менә шул: җил уңай, бүген җыенасың, иртәгә кузгаласың. Кәмигә! — диде мака сар. — Җиңеп, төрбәләрен... барлык байлыкларын төяп кайтасың. Җиңә алмасаң...

— Аңладым, агам, — диде Типкә би, караңгы чырай белән. — Җиңә алмасам нәрсә булыры болай да билгеле.

— Билгеле микән? — диде мака сар, энесенә сынаулы күз карашы ташлап усал гына. — Мин ышанам, син җиңәрсең, — диде ул, аннары шактый нык итеп, боерып. — Киләүче баба синең юл күрсәтүчең булыр. Аннан соң, син бит яшь бичәңне яратасың... Фалияне!

— Яратам, агам, — диде би, сөенеч тойгысы белән, һәм үзе дә сизмәстән елмаеп җибәрде.

Мака сар Карун күптән инде Кәмигә каршы олы яуга әзерләнә иде. Тугыз биләмәдән һәм Аклантита утравының урман-таулары арасына таралып утырган авыллардан, калалардан көн саен башкалага кызылга, карага буялган сугыш кәмәләре, кораллы сугышчылар, корал, азык-төлек килә тора иде. Алар су бозраларга кереп тулганнар, яр буйларында туктап калганнар һәм кузгалырга боерык булганны гына көтеп торалар иде. Бу турыда бөтен башкала халкы белде. Кәмиләргә каршы яу чыгу-чыкмау хакында төрле сүзләр йөрде. Күпчелек мака сарның ниятен хупламады. Ни өчен дигәндә, Кәми белән Аклантита күптән инде дуслашып-туганлашып беткән иде. Ике арада туктаусыз алыш-биреш бара, туктаусыз сәүдә кәмәләре йөреп тора иде. Арада, билгеле, теләсә нинди яуга атлыгып торучылар да күп булды.

Типкә би дә мака сарның яуга әзерләнүен белмәде түгел, белде. Тик шулай да ул, сугышчы һәм сугыш остасы булса да, бу арада яулар-сугышлар турында исеннән чыгарып тора иде. Ни генә булмасын, әле яңа гына өйләнгән кеше буларак, ул үзенең Фалиясе янында, үз өендә, тынычта яшәргә тиеш иде кебек. Ул сугышка бармаска тиеш иде сыман. Мондый зур яуларга элек мака сарлар үзләре йөргәннәр. Мака сар Карун барлык борынгы йолаларны, барлык изге юсык-юрыкны аяк астына салып таптады. Ул инде күптән, моннан дүртбиш ел элек, тәхетен үзеннән кечерәк энесенә тапшырырга тиеш иде. Төрлечә хәйлә табып, ялган белән ул яңадан биш елга мака сар булып кала алды. Үзе югында алай-болай баш күтәрүләреннән куркып, ул хәзер менә, урынына береккәндәй, башкаладан, хәтта Алтын Уртадан беркая чыкмыйча яшәп ята.

Әйе, барысы да аңлашыла. Кәмигә каршы яуны ул инде күптән юри уйлап тапкан. Аны башкаладан читкә җибәрү өчен ул моны юри уйлап тапкан. Бернинди байлык та, яшерен сарайлар да юк ул төрбә астында. Аннан соң нишләп кәмитләр тора салып, җиңел генә шундый атаклы төрбәләрен мака сардан талатырлар икән? Кәмитләр көчле, аларның җирләре, байлыклары күп. Димәк, мака сар Карун аны ун меңләгән кеше белән күрәләтә үлемгә озата!

Мака сар белән булган сөйләшүдән соң Типкә бинең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ул әйтерсең ике ут арасында калды. Мака сарның кансызлыгын, ялганын белеп торса да, ул аның боерыгына каршы килә алмады. Каршылык белдерсә, аның шундук башын чабачаклар йә булмаса иң яхшысы, тирән базга ябачаклар иде. Берсүзсез боерыкка буйсынып, Кәмигә каршы яуга барганда да аны ни көтә икән соң киләчәктә? Ул моны белмәде. Моны беркем белмәде. Билгеле, һәркемнең җиңеп, кәмәләргә бик күп байлык, коллар төяп кайтасы килде.

Алар таң алдыннан кузгалып киттеләр. Алтын уртадан туп-туры ачык диңгезгә чыга торган киң арык тамагындагы сакчы кәмәләр аларга юл биреп як-якка киттеләр. Тышкы койманың су аша бер ягыннан икенче ягына тарттырып, ташка беркетелгән ыргакларга каптырып куелган авыр җиз чылбырлар чыңлап су астына төште. Яр буена, койма, күпер өсләренә җыйналган меңләгән халык, кул болгап, елашып һәм соңгы сәлам сүзләрен кычкырып, аларны ерак юлга озатып калды.

Биек койма өстеннән сузылган күпер астыннан чыкканда, күперне чыккач та, би әледән-әле халык ягына борылып карады. Аның ничек тә Фалияне күрәсе килде. Ләкин анда кемне дә булса тану-аеру мөмкин түгел иде. Кул болгаган, кычкырган йә булмаса елаган һәрбер яшь хатын аңа Фалия булып тоелды. Бер-ике мәртәбә ул, Фалия дип алданып, хәтта борылып кемнәргәдер кул да болгады.

Ләкин ишкәкчеләр бик тырышып иштеләр, авыр ишкәкләрнең шап та шоп су өстенә төшкәне генә ишетелеп торды. Кәмә җиңелчә генә дулкыннар өстеннән тирбәнеп алга, билгесезлеккә таба ыргылуында булды. Бик озак, төшкә, хәтта кичкә кадәр арттан ялт-йолт килеп аларны башкаланың алтын манаралары, җиз, көмеш коймалары, биек йортлары озатып калды. Караңгы төшкәндә исә, еракта, төньякта шәүлә генә булып, караеп таныш таулар карап тордылар.

Бардылар алар Кәмигә. Басып керделәр кәмиләрнең комлы-тузанлы җиренә. Сугыштылар, Куфу төрбәсенә дә барып җиттеләр, ләкин ул вакытта инде киләүче баба Мати диңгездә давыл вакытында аяк сузган иде. Үзенең серен ул беркемгә, хәтта бигә дә әйтергә теләмәде. Шулай итеп, бу юлы да лелегләрнең төрбә астындагы сарайларның ишеген ачарга, байлык таларга дигән теләкләре тормышка ашмады.

Коры кул белән мака сар катына кайтып күренү хәтәр нәрсә иде. Сугыш осталары, алып су башлары белән киңәшкәч, Типкә би Хана буйлап көньякка — Нубия кыргыйларына каршы яу чабарга булды. Анда алтын күп диләр. Колларны богаулаган чылбырлар да, балта-пычак ише кораллар да анда, имеш, алтыннан икән дигән сүзләр йөри иде. Чыннан да ике ай дигәндә алар Нубия тауларына да барып җиттеләр, андагы кабиләләрне җиңеп, пыр туздырып, алтыннарын ишәкләргә, елга кәмәләренә төяделәр дә үзләре диңгез буенда көтеп торган чиру янына юнәлделәр.

Башкаладан алып чыккан кешеләрнең, кәмәләрнең яртысы чамасын югалтып, шулай да бик күп алтын һәм җәүһәр-мәрҗән ташлар алып бер елдан соң ул башкаланың диңгез ягындагы капкасына кайтып төште.

Мака сар боерыгын җиренә җиткереп үти алмаса да, ул аңа ике батман чамасы саф алтын бәлешләре алып кайтты. Мондый байлык белән мака сар йөзенә күренү ул кадәр оят булмаска тиеш сыман иде.

Алтын, таш, байлык төялгән кәмәләрне капкадан үткәреп җибәрделәр, ләкин аның үзенә һәм аның юлдашларына башкалага аяк басмаска, мака сардан яңа боерык килгәнче көтеп торырга куштылар. Мака сар боерыгы озак көттермәде. Төрбәнең серенә төшенә алмаган өчен аңа юлдашлары белән бергәләп төньяк диңгезгә таба юл тотарга һәм анда, таурлар илен яулап алып, яр буенда яңа кала корырга боерылган иде. Анда, имеш, таурларда алтын тапканнар.

Менә шулай булды ул. Аларны монда сөргенгә озаттылар. Унике елга. Икенче елны артыгыздан хатыннарыгызны, балаларыгызны җибәрерләр диелгән иде мака сар боерыгында. Бер елдан соң чыннан да сөрелгән кешеләрнең хатыннары, балалары, карт ата-аналары килде. Фалиянең әтисе-әнисе дә, им өеннән алып кайткан улы Мәмли дә килде. Тик... алар арасында Фалия генә юк иде. Мака сар Карун Фалияне генә җибәрмәгән иде.

## VI

Көн бозылу белән калада тормыш та тукталып калгандай булды. Тукталып ук калмаса да, ничектер үзеннән-үзе чыгырдан чыккандай булды. Кисәк килеп яуган яңгыр берәүләрнең эшләнәсе эшен туктатты, икенче берәүләрнең шулай итәрмен, болай итәрмен дигән теләгенә каршы килде.

Яңгыр төне буе яуды. Таң алдыннан җил-давыл басыла төште, ләкин яңгыр туктамады. Ул көнне кешеләр озаграк йокладылар, ишекләр соңрак ачылды, сыерлар соңрак савылды, ашарга да соңлабрак пешерделәр.

Типкә би, төнне бөтенләй диярлек йокысыз уздырса да, барысыннан иртәрәк торды. Өстенә кыска тире тунын киде, аның өстеннән башлыклы ябынчасын бөркәнде, билен буып, көмеш саплы озын кылычын такты да тышка чыкты һәм ташлы сукмактан якындагы койма буена таба атлады. Киң басмадан таш койма өстенә менгәч, ул диңгезгә карап тукталып калды. Диңгез шаулый һәм дулкынлана иде. Мондый вакытта диңгезгә чыкмаганың яхшы. Мондый вакытта диңгез яр буеннан карап тору өчен генә күңелле: әнә таудай дулкыннар ыргылып, бер-берсен узышып киләләр дә текә ярларга, таш өемнәренә китереп бәрәләр. Көн дә шулай. Бертуктаусыз шулай. Кайда да шулай. Ник бәрә, ник шаулый һәм ник шулкадәр дулкынлана ул — һич аңларлык түгел. Бары да Мин алла эше. Күренә дә кебек ул, күренми дә кебек күзгә. Усал да кебек, юаш та, ягымлы да кебек.

Бүтән көннәрне Типкә би иртән шушы төштән кояш чыкканын карап торырга ярата иде. Күңеле сыкрап, әрнеп, туктаусыз башкалага, алтын-көмеш коймалар, алтын-көмеш манаралар, сарайлар ягына тартса да, аңа хәзер монда да инде күп нәрсә якын һәм кадерле. Иртән, салкынча һавада, ерактагы каралҗым таулар артыннан кызарып кояш чыгып килүен, көн тууын күрү үзе генә дә бер хозур. Монда да шул ук кояш, шул ук диңгез, шул ук күк йөзе. Әйе, кайбер нәрсәләрне исәпләмәгәндә...

Бүген монда кояш чыкканын карап торып булмаячак. Бүген кояш әллә чыга, әллә юк. Үз-үзе белән сөйләшкән сыман ул күңеленнән шулайрак дип фикер йөртте һәм, каршы сибәләгән яңгырга әле ян-ягын, әле битен куеп, койма өстеннән капкага таба китте. Аста йокылы сакчыларның үзара сөйләнгәне ишетелеп калды. «Би торган да!» — диде берсе, ризасызлык белән.

«Йокысы качкан», — диде икенчесе. Капка янында да төнге сакчылар шундыйрак сүзләр әйттеләр. «Бу яңгырда рәхәтләнеп йокласа ни булгандыр», — диде берсе, мыгырданып. Би аларны ишетмәмешкә салышты. Иртәнге йокы аеруча тәмле. Иртәнге йокыдан бүлгәнне беркем яратмый. Хәтта уяу булырга тиешле капка сакчысы да!

Авыр капка бик нык шыгырдап ачылды. «Майларга кирәк. Бигрәк ямьсез шыгырдый», дип уйлады би капка турында. Үзе белән ул бер сакчыны алды һәм ташлы такыр сукмактан турыга — Аксай үзәненә таба юнәлде. Бу көннәрдә аны әле булса тиешенчә өлгереп, төзелеп бетмәгән кәмә борчыды. Башкаладан боерык килеп төшсә, аның кайчагында монда бер көн тормый юлга чыгасы килде. Менә шул ерак юлга чыгу өчен ул инде икенче ел менә буе йөз аршынлы бик зур кәмә эшләтә. Башкалага ул өтәләнгән булып түгел, чын диңгезче, чын кеше булып, менә дигән булып кермәкче була. Унике ел буена сөргендә кыргыйлар арасында ятып өтәләнеп беткән, хәерчегә калган димәсеннәр, баеп, ныгып кайткан дисеннәр. Ул инде мака сарга бүләк итеп бирергә бик күп алтын-көмеш һәм затлы ташлар җыйды. Билгеле, аның аларга исе китмәс. Шулай да мондагы ят җимешләрне, дала ягыннан, бик ерактан китерелгән кайбер ят җәнлекләрнең тиресен күрсә, ихтимал, исе дә китәр. Ул кеш, ас, төлке, ак аю тиреләре, болан, поши мөгезләре үзе генә дә ни тора! Бу яктагы ташка әйләнгән суны, кыш көнендә күктән мамык булып ява торган, утка төшкәч эри торган яңгыр тамчыларын алып кайтып күрсәтәсе иде аларга! Яисә каядыр төньякта, урманнар арасында агып ята торган зур елгадагы акула сыман бик зур балыкны алып кайтып күрсәтергә иде аларга! Ите нинди дә, уылдыгы нинди! Билгеле, аның базларында Аклантита аксөякләрен шаккатырырлык бүләкләр дә, күчтәнәчләр дә җитәрлек. Ап-ак тәнле коллар, кыргыйларны үз кулы белән тапшырачак. Карун өчен, билгеле, аның базларында алтын-көмеш, җәүһәр ташлары да җитәрлек. Әле булса туктаусыз алтын җыя микән? Шулкадәр бүләк, күчтәнәч, коллар, ят әйберләр биргәч, аның да күңеле бер эреми калмас лабаса! Хәтта йөрәге таш булса да! Һәм шуннан соң ул, әлбәттә, үзенең Фалиясе белән кавышачак. Ул яңадан аның моңлы, серле тавышын ишетәчәк!

Туган җиргә, туган калага кайту көне якынайган саен, бинең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Билгеле, мон-

дый уйларның бик үк җитди булмавын да ул танымый булдыра алмады. Күпме генә уйланса, хыялланса да, ул инде барыбер моннан ун-унбиш еллар элекке хыялый үсмер егет түгел иде. Күрәсең, Фалия дә үзгәргәндер, ул да инде, бәлки, моңлы итеп, матур итеп җырлый да алмыйдыр. Бит дөньяда үзгәрми торган берни дә, беркем дә юк.

ШулаеН шулай да. Хыялланмый да мөмкин түгел. Моңарчы аны хыял һәм өмет яшәтте. Хыял һәм өмет аны исән-имин шушы көнгә кадәр саклап килде. Шулай булгач, ник оялырга аңа яшьлек хыялларыннан?!

Юл буе би үз-үзе белән бәхәсләште, юл буе үз күңелендә казынды. Хәер, бүген генә түгел. Соңгы көннәрдә ул әледән-әле элеккеләрне исенә төшерде һәм, телиметеләмиме, шәп кеше булып башкалага кайту турында уйлады. Бәргәләнеп уйлады. Капкадан бер ярты чакрым чамасы җир киткәч, тау астында, Аксай буенда коры җиргә кагылган баганалар өстендә аның сөеклесе — кәмә күренде.

— Фалия исән! — диде ул кычкырып, куанып.

Аның яныннан сүзсез генә теркелдәп барган сакчы, би авызыннан «Фалия»сүзен ишетеп, колагын үрә торгызды. Яңа төзелгән кәмәне бинең «Фалия»дип атавын ул әле белми иде.

Кичәгенәк бөтен үзәнне тутырып аккан Аксай бүген ярларына кайткан һәм, туктаусыз яңгыр сибәләп торуына да карамастан, шактый юашланып калган сыман күренде. Әмма кичә монда эшләр шәптән булмаган: эшләр монда кыл өстендә генә калган. Коры җиргә, яр кырыена ук тезеп утыртылган баганалар өстенә җәелгән күпернең кайбер төшенә су кергән. Багана башларына, аркылы салынган өрлек башларына төрле чүп-чар, камыш, чыбык-чабык эләгеп калган. Ничек бөтен күперне күтәреп, агызып алып китмәгән ул?! Күперне алып китсә, «Фалия»не дә күпер белән бергә алыр иде дә китәр иде. Сал өстендә барган кебек агып барыр иде, диңгез дулкынына эләгеп челпәрәмә килер иде. Юк, дулкын аны кире ярга чыгарып ташлар йә булмаса кыяларга китереп бәрер иде! Менә күтәреп тә алмаган, агызып та китмәгән! Атабыз Куранның изгелегеме бу, әллә атабыз Миннең шәфкатеме бу? Кемнеке генә булмасын, бу юлы алар аңа артык зыян китермәгәннәр. Бер кеше белән бер атның югалуы ул «Фалия» белән чагыштырганда берни түгел. Бу бары корбан гына.

Ә бәлки, бу берәр төрле кисәтүдер. «Фалия» артык зур, артык чибәр булды. Мин кешеләрнең үзе белән

көрәшкәнен, үзенә каршы килгәнен яратып җиткерми. Ул бары үзенең җаеннан торганнарга гына яхшылык эшли. Әллә бер-бер корбан сорый микән?

Җир өстенә җыелып калган суларга басмаска тырышып, би коры җирдән коры җиргә, калку җирдән калку җиргә сикереп атлый-атлый күпергә якынлашты. Ләкин күпер янына килеп җиткәч кенә ул менеп-төшеп йөри торган басманың юклыгын абайлап алды.

Аның якынаеп килүен күпердәгеләр күрделәр, ләкин нишләптер аны каршы алырга ашыкмадылар.

— Хәзер була, хәзер! — диде Ярыш балтачы, күпер кырыена килеп, аска карап.

Типкә би бары шунда гына күпердәгеләрнең ашыгып, шак-шок килеп, нидер эмәлләп азаплануларын аңлап алды. Бераздан җиргә бер ягына баскыч сыман итеп киртләп ясалган юан бүрәнә төшерделәр. Берсе шунда бүрәнә башына аркан ташлады. Бүрәнә уйнаклап тормасын өчен, бүрәнә башына ике яктан тимер атлама суктылар. Шуннан соң би икенче очы нәрсәгәдер бәйләнгән арканны үзенә таба тартып сакланып кына текә бүрәнә буйлап күпер өстенә менде. Аның артыннан яшь сакчы менде.

Балтачыларның барысы да диярлек аяк өстендә иде. Алар барысы да тазалар һәм барысы да диярлек яланөс иде. Бары берничә картрак балтачы гына җиңсез кыска тун кигән йә булмаса башлыклы бөркәнчә ябынган иде. Яшьрәк, тазарак ирләр, үзләренең нык, тыгыз тәннәре белән мактанырга теләгәндәй, юри яңгыр астына чыгып басканнар иде сыман. Көне буе кояшта, ачыкта эшләгәнгә, аларның тәне кара-кучкылланып, бакырдай янып чыккан, хәзер исә яңгырда чыланып, ышкып чистартылган җиз шикелле елкылдап тора иде.

— Исәннәрмесез? — диде би, күпер өстенә килеп менгәч, беренче сүзе итеп.

Балтачыларның өлкәне Ярыш, күпер читенә үк килеп, бине көтеп торды. Алыптай зур гәүдәсе белән иелеп, ул бигә кулын сузды һәм аңа күпер өстенә басарга булышлык итте.

— Исәннәр, — диде Ярыш бинең соравына каршы, калын, көр тавыш белән.

Уртачадан чак кына калкурак, какчарак би янында артык зур булып күренмәс өчен Ярыш шундый оста итеп иңбашларын салындырды, җилкәсен җыера төште һәм аяк атлаганда ничектер сыгылып, бөгелеп атлады. Бүтән вакытта балтачыларның колак төбендә күк күкрәгән

сыман яңгырый торган калын тавышы да аның би янында йомшак, көчсезләнеп калгандай булды. Тик шулай да алла тарафыннан бирелгән артыклыкларын ул хәтта би алдында да тулысынча яшерә, киметә алмады. Шуңа күрә аның көчәнүе шундук төртелеп чыкты. Балтачылар Ярышның кыланышын читтән генә мыскыллы күз карашы белән күзәтеп һәм тыңлап тордылар. Типкә би исә күрмәмешкә салынды.

Би якынлашкач, башка балтачыларның да теле ачылды.

— Исән, — диде берсе, теләр-теләмәс кенә.

— Кыл өстендә калдык, би, — диде икенчесе.

— Котыбыз ботыбызга җитте, — диде йончылган кыяфәтле өченчесе.

— Күперне алып китсә, туп-туры Мин авызына барып керәдериек, — диде шунда бер сүзчәнрәге.

Би беркемгә дә җавап кайтармады. Күпер өстендә буяу, агач, сагыз исләре аңкыткан, биек булып, матур булып утырган кәмәне бер кат әйләнеп чыкты да югарыга менде. Кәмәнең өсте ябулы иде, монда баш өстеннән кояш нуры да, яңгыр да үтә торган түгел иде. Кәмәнең ишкәкчеләр өчен эшләнгән ике яктагы сикеләре арасыннан би борын ягына таба атлады. Анда борын башында ике балтачы идән түшәп яталар иде. Шунда берсе, Әгъли дигәне, кулындагы шома саплы җиз балтасын яткырып куйды да билен язды.

— Төне буе йокы йокы булмады, — диде ул, беркемгә дә атап әйтмичә. — Инде менә ашамаган көе эшкә куша. Ашамагач, хәл юк.

Соңгы сүзен ул Ярышка карап әйтте, аннары бигә карап алды.

— Син йокламаганда мин йоклап яттыммы әллә? — диде Ярыш, балтачы Әгълинең шулай би алдында тел озынайтуын ошатмыйча.

Ярышның яртысы кадәр генә, йомры гына Әгъли иң оста балтачылардан санала иде. Үзенең кемлеген яхшы белгәнгә, ул би алдында да, Ярыш алдында да куркып-ялагайланып тормады, өлкән балтачының йөзенә бәреп:

— Мин сиңа кол түгел ашамыйча эшләргә! — диде.

Һәртөрле ярышларда, көч сынашуларда өстен чыгарга күнеккән һәм шуңа күрә Ярыш кушаматы алган өлкән балтачы үзенә буйсынган ирләрнең сүз көрәштерүен өнәп бетерми иде. Ләкин би янында булгач ул чынлап торып Әгълигә үз көчен күрсәтә алмады. Ачудан аның йөзе генә үзгәрде дә күзләрен кан басты. Ике арада би бул-

маса, ул, күрәсең, үзенә каршы эндәшүченең җилкә тамырына кундырып алырга да күп сорамас иде.

Типкә би аларның ызгышып китү мөмкинлеген шундук чамалап алды һәм, сүзне икенчегә бормакчы булып:

— Бил сызламыймы, Әгъли? — диде.

Көн бозылыр алдыннан Әгълинең биле сызлавын балтачылар да, би дә яхшы беләләр иде. Кайберәүләр аның шул бил сызлавын исенә төшереп шаяртырга ярата, кайберәүләр, чын күңелдән ышанып, аның бил сызлау турындагы сүзләренә колак салалар иде. Әгъли бинең шаяртканын-шаяртмаганын аңлап җитмәде.

— Сызлый, — диде ул, шактый коры гына.

— Бүген дә кичәге кебек китереп коймас микән? — диде Типкә би, чын күңелдән борчылып.

— Өч көн алдан сызлый башлады, би! — диде Әгъли, кинәт ачылып. — Ярышка әйттем. Кеше сүзенә колак сала торган бәндә түгел, көлде генә.

— Әйе, мин сиңа бәндә түгел, — диде Ярыш, ачусыз гына гөрелдәп.

— Өч көн алдан чарасын күргән булсак, болай да булмыйдырыек, — диде Әгъли. — Кәмәне алданрак беркетеп куйган булсак, коеп яуган яңгырда төне буе азапланмасыек. Төне буе аркан белән булаштык: бәйләдек, тарттырып беркеттек... Эт кебек арыдык.

— Тагын бил сызлыймы? — диде би.

— Сызлый. Бил генә түгел, йөрәк сызлый, — диде Әгъли, тавышын әкренәйтеп, бик зур серен чишкәндәй. — Төне буе йоклый алмадым. Малай исән микән... Алар кичә Бакыр тауга киткәннәрие бит.

— Беләм, — диде би күңелсез генә. — Исәннәр микән, әлегә берни белмим.

Чынында ул кайбер нәрсәләрне белә иде. Үти кайтмаган. Бу турыда аңа кичә кичтән үк әйттеләр. Аңа шулай ук Зөлмәтнең дә кайтып җитмәвен әйткәннәр иде. Ләкин бераздан Зөлмәт кайтты. Ник соңлаган, ничек кайткан, бу хакта ул кичәгенәк төпченеп тормады. Бүген исә, балтачылар белән сөйләшкәч, аның аты белән агып китүе, күпер баганасына эләгеп калуы һәм шул рәвешчә котылуы билгеле булды.

Балтачылар яныннан кайткач та Типкә би яшьләр өенә китте. Яшьләр өе Уртаның уң ягында, калкулык өстендә, би сараеннан бер чирек чакрым чамасы җирдә генә урнашкан иде. Монда үсмерләр, малайлар өчен аерым-аерым өйләр салынган. Шулар дүртесе дүрт яктан бер-берсенә китереп текәлгән. Уртада дүрткел ачык

җир — ишегалды бар. Үсмерләрнең күпчелек вакыты шунда үтә. Алар монда уртадагы зур учакта, зур казанда үзләренә-үзләре ашарга пешерәләр. Аш пешкәч, шунда ук җир өстенә җәелгән чыпталарына утырып ашыйлар, ашагач, табак-савытларында калган азыкларын утта тотып, Ут анага садака бирәләр дә чистарып калган савытларын өй эченә, шүрлекләргә тезеп куялар. Кар, яңгыр яуганда, алар өй эчендә, таш җәелгән как идәнгә тезелеп йоклыйлар. Баш астында коры үлән тутырылган күн мендәр — күнчек була, асларында таяк итеп төрелә торган, теләсә кая үзләре белән йөри торган камыш чыпта була. Йокыдан, ашау-эчүдән буш вакытларында алар туктаусыз чабып, сикереп, уйнап, үзара көч сынашып үткәрәләр. Кайчагында күмәкләшеп, төркемләшеп кырга, урманга баралар, диңгез тыныч чакта диңгез буена төшәләр йә булмаса өлкәннәргә кыр-басу эшендә булышалар.

Йола-түрә буенча им өенә ир затыннан булган беркем якын килергә тиеш булмаган кебек, ир өенә дә хатын-кыз затыннан булган беркем якын килергә тиеш түгел. Ләкин еш кына монда әле бер аулакта, әле икенче бер аулакта качып-посып кечкенә малаен сөеп торган, күз яшен сөртеп торган берәр ананы йә булмаса берәр карчыкны күрергә була. Әле яңа гына ир өендә тора башлаган һәм андагы тәртипләргә күнегеп китә алмаган җиде-сигез яшьлек сытык малайларның шулай анасы итәге янында балавыз сыгып торуын күрсәләр, өлкәннәр шундук ыгы-зыгы, шау-шу куптаралар, малайны төрлечә оялтырга, аннан көләргә тотыналар. Берәр өлгеррәге хәтта пир атага әләкләргә йөгерә. Ләкин пир ата гадәттә андый тәртип бозучыларга бармак аша карый һәм, гадәттә, әләкченең үзен шелтәләп җибәрә.

Типкә би ир өе янында шундый ана белән малайны күрсә, гомумән күрмәмешкә салынып үтә. Бүген дә ул шулай ир өенә бара торган тигез юл буендагы гөлҗимеш куагы яныннан күрмәмешкә салынып, тиз-тиз генә узып китмәкче булган иде, куак артында качып-посыбрак торган бер карчык аның юлына аркылы төште.

— Би! — диде ул, калтыранып чыккан бер кайгылы тавыш белән, бинең беләгеннән тотып. — Үтием... балам!.. Чынмы? Кайтмадымы?

Типкә би каушабрак калды, туктады, арткарак чигенде. Аның, билгеле, бу ябышкак карчыкны селтәп ташлыйсы килде, ләкин аның йөзенә күтәрелеп карагач, аның чандыр йөзендәге, эчкә баткан нурсыз күзләрендәге коточкыч кайгы, әрнү күреп, тетрәнеп китте.

— Мин... әлегә... белмим, — диде ул, ык-мык итеп. — Күрим, белим...

— Беләсе юк, кайтмаган, би, кайтмаган!.. — диде Мәлия карчык, үксеп, борынын тартып.

— Эзләргә кеше җибәрербез, — диде би, мөмкин кадәр йомшак булырга тырышып. — Бар, кайт — йөрмә бу тирәдә. Үзебез әйтербез.

— Үти! Балам! — диде карчык, аны тыңламыйча күз яшьләре белән, һәм бинең беләген ычкындырды да читкәрәк тайпылды. — Суларга акты микән, таурлар кулына эләкте микән?! — диде карчык, такмаклый-такмаклый ерагая барып.

Типкә би капка сыман биек, киң итеп ясалган аралыктан үтте дә иркен ишегалдына барып керде. Ишегалдының дүрт ягында да ике катлы биек таш өйләр калкып утыра иде. Таш өйләрнең барлык тәрәзәләре һәм дүрт яктагы дүрт ишеге — барысы да ишегалды ягына карыйлар иде. Ишегалды уртасында, түбә астында берике казанда нидер пешә, казаннар тирәсендә кизү малайлар, үсмерләр мәш киләләр, кечерәкләр ике яктан тотып, зур чүлмәкләр белән су китерәләр, утын ташыйлар, казан асты янында булашалар. Зуррак ике үсмер аларның эшен карап-күзәтеп торалар иде. Бала-чага булган һәр җирдәгечә, анда казан тирәсендә, түбә астында чыр-чу, ыгы-зыгы яңгырап тора.

Бинең килүен күреп, казан янындагылар да, ишегалдында бер дә юктан йөгерешеп, куышып, үзара болагайланып йөрүчеләр дә тынып калдылар. Кайберләре ялт кына ишекләргә кереп югалды.

Ир өенең аскы катында дүрт якта да пир аталар тора иде. Монда һәрьяктагы һәр бүлмә ирләрнең төрле төркеменә бүленгән. Югары каттагы бүлмәләрнең берничәсендә кораллы ирләр, койма, капка сакчылары яши, читтән килгән кунаклар төн кунып чыгалар. Бүлмәләрнең берничәсе кала аксөякләренеке исәпләнә. Калада аларның үз сарайлары бар, хатыннары, балалары, каралары бар, ләкин төрле йола, туй, бәйрәм вакытларында йә булмаса ирләр җыены булган чакларда алар шушында үз бүлмәләренә киләләр, үзара гәпләшеп, сөйләшеп-киңәшеп вакыт уздыралар. Ир өен карау, бүлмәләрне җыештыру, себерү һәм аксөякләргә, ирләргә ашарга пешерү, ашаганнан соң табак-савытларын җыештыру тулысынча берничә төркемнән торган малайлар һәм үсмерләр өстенә йөкләнгән. Малайларга һәм үсмерләргә пир ата Әмәк баш иде.

Типкә би үз юлында очраган һәм аның күзенә күренеп иң олы аксөяк белән исәнләшергә тырышкан малай-шалайга, чәрелдек үсмерләргә баш кагып кына җавап биргәләде дә үз бүлмәсенә барып керде.

Бүлмә зур һәм иркен иде. Бүлмәнең диварлары, түшәме матур итеп бизәлгән, идәненә тигез итеп киселгән шомартылган таш, таш өстенә камыш чыпта җәелгән иде. Каршыдагы пыяласыз киң биек тәрәзәдән саф һава һәм яктылык кереп тора.

Би, үзенең бүлмәсенә килеп керү белән, өстендәге авыр ябынчасын салды. Күләгәдәй алып артыннан ияреп кергән кизү үсмерләрнең берсе тавыш-тынсыз гына ике куллап башлыклы ябынгычны алды да каядыр алып китте. Би билендәге авыр кылычын чишеп, кулын читкә сузу белән, кизүләрнең икенчесе кылычны алып китте. Шуннан соң би өстендәге кыска җиңле тунын-күртәнәсен салды. Аны да шулай ук өлгер кизүләр эләктереп алдылар. Аннан соң ике малай аның аяк киемен салдырдылар. Би кыска күн ыштаннан һәм озын җиңле киндер күлмәктән генә калды, яланаяк, яланбаш көе бүлмәнең уң ягындагы тәбәнәк ишектән ян бүлмәгә кереп китте. Монда коену бүлмәсе урнашкан иде.

Аккаланы сала башлаганда Типкә би булдыра алган кадәр бар нәрсәне башкаладагы сыман итеп төзергә тырышты. Иң кирәге урын һәм салкын сулы чишмә булды. Кала өчен урын сайлаганда иң элек ул аның диңгез буенда һәм шул ук вакытта бар яктан да тигез җир белән әйләндереп алынган калкулыкта булуын шарт итеп куйды. Ләкин, күпме генә эзләмәсен, таурлар илендә, диңгез буенда төп-төгәл андый җир табылмады. Аккала каплап куелган казан сыман кечерәк бер калкулыкка урнашты. Тик аның бары көнчыгыш ягы гына тигезлеккә килеп ялгана да, көньягы исә, текә яр булып, диңгезгә терәлә, көнбатыш һәм төньягында, беркадәр читтәрәк, биегрәк таулар башлана иде. Көнбатышта, калкулык итәгенә ялганып, тирән упкын ята, төньякта исә дөя өркәчедәй дулкынланып тар гына сырт сузыла иде.

Башкалада барлык өйләргә, сарайларга килә торган җылы һәм салкын су турыдан-туры калкулыкның үзеннән чыкса, монда эчү, юыну, коену өчен яраклы андый чишмәләр табылмады. Салкын суны күршедәге, төньяктагы таурларның берсеннән борып китерергә туры килде. Өйләргә керә торган җылы суны махсус йортта, туктаусыз ягыла торган чүлмәк казаннарда кайнатты-

лар. Боларның барысын да тәҗрибәле, булдыклы өлкәннәр карамагында шул ук ирәннәр башкарды.

Коену бүлмәсендә юынып-коенып чыгу белән, иркен бүлмәгә шул ук җитез үсмерләр түгәрәк өстәл китереп куйдылар. Күп тә үтмәде, икенче бер үсмерләр йөгереп кенә кайнар сөт, ботка, җимеш салынган алтын, көмеш табаклар күтәреп керделәр һәм шуларның барысын да тәбәнәк өстәл өстенә куйдылар да ялт кына чыгып та китмәкче булдылар.

— Тагын бер табын кертегез, — диде би үзенең яраннарына. — Пир атага әйтегез, монда керсен, — диде ул аннары.

— Ярар, би, — диде үсмерләрнең өлкәнрәге.

Иртәнге ашны би пир ата Әмәк белән бергә ашады. Ашаганда алар бөтенләй диярлек сөйләшмәделәр һәм бөтенләй диярлек ашыгу галәмәте сиздермәделәр. Бары тик ашап туйгач һәм алтын касәләргә салып бераз чагыр эчеп алгач кына, алар сакланып кына сүз башладылар.

Үтинең кайтмый калуы пир атаны да борчуга салды. Ныклап торып кайгырырга әле иртәрәк булса да, кичәдән бирле ул бары шул турыда — Үти турында гына уйлады. Аны әле кояш чыкканчы көтәргә була иде. Исән булса, атлы, кораллы кеше үзе кайтырга тиеш. Исән түгел икән инде, анда эш башка. Мондый хәл сирәк була. Мондый хәл һәрвакыт бөтен каланы аякка бастыра, бөтен нәрсәнең астын өскә китерә һәм халык арасында бик озак төрле сүзләр сөйләргә сәбәпче була. Кешенең югалуына йә булмаса берәр ничек үлеменә күп вакытта андый кеше үзе гаепле булса да, ата-ана, туган-тумача фаҗига өчен бүтәннәрне гаепләргә тырыша. Шундый көтелмәгән хәлләр аркасында кайчагында кешеләр арасында бик озакка сузыла торган дошманлык, үчләшү барлыкка килә. Берәүләрнең дошманлашуы, үзара үчләшүе еш кына бөтен каланы борчуга салып, кешеләрнең тормышын агулап тора.

Бу юлы шундый хәл килеп чыкмасмы? Үтинең юкка чыгуында турыдан-туры берәрсе гаепле түгелме. Мәсәлән, Зөлмәт, Мәмли. Бит Бакыр тауга җибәрелгән төркемгә алар баш итеп куелды. Таякның юан башы кемгә төшәчәк — Үтинең янында барган иптәшләренәме, әллә Зөлмәт белән Мәмлигәме?

Типкә бигә дә, пир атага да менә шундый сорау тынгы бирмәде. Аларның, билгеле, Мәмлине бар яктан да гаепсез итеп күрсәтәселәре килде. Ләкин чынлыкта шулай микән — әлегә алар берни белмәделәр һәм төпченә башларга да ничектер йөрәкләре җитмичәрәк торды.

Тикшерә башларга, һичшиксез, кирәк иде һәм тикшерә башлауны да нәкъ менә Мәмлидән һәм Зөлмәттән башларга кирәк иде.

— Алып кил барысын да, — диде би, көрсенеп, пир атага карап.

Пир ата башын иеп ишеккә юнәлде. Ишектә ул көтмәгәндә Әгъли белән очрашты һәм, бу көтелмәгән очрашудан каушап калгандай булып, чак-чак кына сискәнеп китте, читкә тайпылды. Балтачының йөзе шактый кырыс һәм борчулы иде.

— Артыңнан килдем, би, ачуланма, — диде ул, бүлмәгә узып.

Шул килеш ул би янына ук барып җитмәкче булды, ахрысы, ләкин каяндыр як-яктан ике яран килеп чыкты. Алар шундук балтачы Әгълинең юлына аркылы төштеләр һәм боерык көтеп би ягына текәлделәр.

— Ашаттылармы әле сезне? — диде би Әгълигә, кәмәдәге сөйләшүне искә төшереп.

— Ашау кайгысы китте әле, — диде Әгъли.

Нурсыз күзләренә, ачулы йөзенә караганда аның әле булса тамагын туйдырмаганлыгын аңларга була иде.

— Бар юын, тынычлан, аннары ашарсың, — диде би Әгълигә, киңәш итеп.

Яраннар аны коену бүлмәсенә озатып куйдылар һәм ул анда шапыр-шопыр юынган, коенган арада ике табын янына өченче табын, аның өстенә алтын табаклар белән кайнар аш кертеп куйдылар. Әгъли юынып, сөртенеп би янына чыкканда, түр ишектән, шаулашып, таш баскычка дөпе-дөпе басып, бер төркем үсмерләр килеп кергәне ишетелде. Болар пир ата алырга киткән Мәмлиләр төркеме иде.

— Бераз көтеп торсыннар, — диде би яраннарның берсенә.

Ишектән килеп керүче пир ата аның сүзләрен ишетеп калды һәм үз артыннан этешә-төртешә килгән үсмерләргә таба борылып, аларга кире борылырга һәм керергә дип әйткәнче көтеп торырга кушты.

Би белән пир ата балтачы Әгълинең ашаганы-эчкәнен сүзсез генә көтеп тордылар. Би янында, би табыныннан ашау балтачы Әгъли өчен зур мәртәбә иде, әлбәттә. Ләкин мондый мәртәбәгә ялгыш кына тап булуын Әгъли яхшы аңлады. Шуңа күрә ул, кыстатыпнитеп тормыйча, табакта нәрсә бар — ялт итеп куйды. Ашап бетергәч ул үзендә авыр бер хәлсезлек тойды һәм күзләрен челт-мелт йомгалый башлады.

— Булды. Бай бул, би, — диде Әгъли, телен көчкә әйләндереп.

Типкә би пир атага күтәрелеп карады. Пир ата сүзсез генә урыныннан купты да ишеккә юнәлде. Бераздан бүлмәгә тиктормас, шау-шулы үсмерләр кереп тулды. Керү белән алар шундук тынып калдылар, түргәрәк уздылар һәм идәнгә, чыпта өстенә түгәрәкләнеп утырдылар да көтә башладылар. Сүзне пир ата башлады.

— Кояш чыгар вакыт җитте дә, узып та китте, — диде ул. — Үти кайтмады. Бинең, балтачы Әгълинең, минем беләсебез килә: соңгы кат Үтине кем, кайда күрде?

Бүлмәдә тынлык урнашты. Үсмерләр тынычсызланып борыннарын тарттылар, бер дә кирәкмәгәнгә тәннәрен кашып алдылар, урыннарыннан кузгалып-кузгалып куйдылар. Үтинең кайтмавында турыдан-туры үзләренең бернинди гаепләре булмаса да, алар, күрәсең, шулай да үзләрен гаепле саныйлар иде. Шунлыктан барысының да йөзе борчулы, кайгылы, хәтта куркынган сыман иде.

Иң элек Зөлмәт сөйләде. Зөлмәт кичәгенәк ничек итеп каладан чыгып китүләрен, ничек итеп таурлар үзәне аша үтүләрен, таурларның күсәк күтәреп каршыга чыгуларын, янауларын, ашарга сорауларын — барысын да сөйләде. Шуннан соң Мәмлине сөйләттеләр. Ул үзләренең Бакыр тау каласында булуларын, кайтырга чыгуларын, кайтканда чишмә буена утырып ипи ашауларын, таурлар күл үзәне аша үткәндә яңгыр башлануын, Селәүсен тарлавыгын чыккач бик каты җилъяңгыр башлануын, шуннан соң ашыгып кичүгә таба чаптыруларын сөйләде. Зөлмәт белән Мәмлидән соң берәм-берәм башкаларны да сөйләттеләр. Әйе, барганда таурлар каршы чыкты, кайтканда алар күренмәделәр. Тарлавыкка җитәрәк көчле яңгыр башланды. Яңгырда алар бер-берсеннән аерылдылар. Су килеп басканчы, тизрәк кичүдән чыгарга дип ашыктылар. Яңгыр яуганда көнне караңгылатып җибәрде. Тирәякта берни күренмәс булды...

Сөйләүчеләрнең барысы да Зөлмәтнең дә, Мәмлинең дә сүзләрен раслрадылар. Ләкин бару турында да, кайту турында да һәркем үзенчә сөйләде һәм башкалар сөйләгәнгә һәркем берәр кечерәк кенә булса да яңалык өстәде. Күпчелек Үтине соңгы мәртәбә чишмә буенда ипи ашап утырганда күргән. Кайберәүләр аны Селәүсен тарлавыгына керер алдыннан да күргәннәр. Соңгы мәртәбә аның тавышын да шунда ишеткән булганнар.

Тарлавыкны чыккач яисә кичүгә якынлашканда аны күрүче дә, ишетүче дә булмаган.

Өлкәннәр беркемне дә бүлдермичә, тын гына тыңлап утырдылар. Балтачы Әгъли үзенең улы турында әйтелгән һәр сүзне аеруча йотлыгып тыңлады. Әле ул борынын тартып алды, әле аһылдап-көрсенеп куйды.

Үсмерләрнең барысы да бер кат сөйләп чыккач, өлкәннәр сорау бирә башладылар. Типкә бигә Зөлмәт сөйләгәннәрдән кайбер нәрсәләр аңлашылып җитмәде. Сорауны ул иң элек Зөлмәткә бирде.

— Барганда алайга син баш булгансың, кайтканда син артны саклап кайткансың,— диде ул аңа. — Үти синең алдан гына кайткан. Син әйтмәдең — соңгы тапкыр кайда күрдең аны? Ничек күрдең? Ул нишләде, нәрсә әйтте?

Зөлмәт башын иеп, кызарынып, озак кына эндәшмичә торды.

— Мин аны... мин аны... — диде ул, ниһаять, нидер әйтергә тырышып. Ләкин шуннан башка берни әйтә алмады.

— Тарлавыктан бергә чыктыгызмы? — диде би.

— Чыктык, — диде Зөлмәт.

— Кичүгә дә бергә килдегезме? — диде би.

— Тарлавыктан чыккач мин аны күрмәдем, — диде Зөлмәт.

— Кая булды соң ул? — диде пир ата, сүзгә катышып.

— Ул чабып китте, мин арттарак калдым, — диде Зөлмәт.

— Ник?

— Ботакка эләгеп янчыгымның каешы өзелде. Шуны алырга дип җиргә төштем. Шуңа арткарак калдым. Яңгыр аша алда кемнәр икәнен аерырлык түгелие, — диде Зөлмәт.

Башкаларга да аерым-аерым сораулар бирделәр, кайбер шиклерәк тоелган нәрсәләрне ачыкларга тырыштылар. Ләкин өлкәннәр күпме генә төпченмәсеннәр, үсмерләр башта сөйләгәннәренә бернинди яңалык өсти алмадылар. Тарлавыкны чykканнан соң Үтинең кая булуы, ничек юкка чыгуын барыбер ачыклап булмады. Би үсмерләргә чыгып китәргә боерды. Яраннар, дәррәү кузгалып, ишеккә ташландылар. Зөлмәт арткарак калды. Бигә дә, пир ата белән Әгълигә дә Зөлмәт башкаларга караганда тынычсызрак тоелды. Хәзер дә ул аякларын бик авырлык белән атлады.

— Зөлмәт! — диде шул чакны пир ата, туктарга боерып. Зөлмәт туктады һәм ирексездән артына борылып карады. Ул шактый каушаган иде.

— Ни... пир ата? — диде ул, күз карашын яшереп.

— Оныткан мын, җиргә төшкәч янчыгыңны алдыңмы? — диде пир ата.

— Алдым, — диде Зөлмәт.

— Анда нәрсәң бар иде? — диде пир ата.

— Анда Кодрәт тархан биргән бер бөтен ипи бар иде, — диде Зөлмәт, тагын да ныграк кызарынып.

— Ул янчык исәнме? — диде пир ата.

— Бата башлагач мин аны ташладым, — диде Зөлмәт.

Яшьләр чыгып киткәч, өлкәннәр үзара киңәшеп, сөйләшеп алдылар. Зөлмәтнең каушавы, кызарынуы өлкәннәргә сәеррәк тоелды. Ләкин аның кыланышы сәеррәк тоелган өчен генә аны әле беркем гаепләргә җыенмады.

— Тарлавыктан чыккач ул, күрәсең, Үтине узып киткәндер дә, Үти арткарак калгандыр, шуңа хәзер әйтәсе килми, уңайсызлана, — диде пир ата.

— Зөлмәт үзе дә кичүгә соңга калган! — Алар икесе дә соңлап килгәннәр кичүгә. Зөлмәт Үтинең батканын күргән. Әйтми генә, — диде Әгъли, күз яшьләрен агызып.

— Юк, — диде би. Барганда аларга таурлар чыккан, кайтканда күренмәгәннәр. Таурлар андый түгел. Алар кайдадыр сагалап торган булырга тиешләр. Читкә тайпылган яисә артка калган Үти алар кулына эләккән.

— А-а, мин аларны! — диде кайгыдан нишләргә белмәгән ата кеше, шундук би сүзенә ышанып. Зөлмәт нәрсәнедер яшерә! — диде пир ата.

— Ул бернәрсә дә яшерми, — диде би. — Арттан баручы баш буларак Зөлмәт Үти өчен дә җавап бирергә тиеш. Ул аны саклый алмаган. Ул аны коткара алмаган, шуның өчен уңайсызлана. Каушый.

Пир атага да, Әгълигә дә бинең бу фикере ышандыргыч тоелды. Ләкин бераздан күңелдә яңадан шик калкып чыкты. Алар шулай күпмедер вакыт сөйләнеп, фикер алышып бәхәсләшеп утырдылар да, яңгыр туктаганны көтмәстән тарлавыктан алып кичүгә кадәр булган бөтен араны җентекләп тикшерергә дигән карарга килделәр. Үлеме-тереме, Үтине йә булмаса аның атын, киемнәрен табарга кирәк иде. Хәтта аны су иясе алган булса да барыбер аның берәр нәрсәсен ярга чыгарып ташларга тиеш иде... Энә түгел, югалмас кешесе дә, аты да. Чыннан да таурлар кулына эләкмәсә...

Әгъли улы Үтинең юкка чыгуы бөтен кала халкын аякка бастырды. Һәркайда сүз бары шул турыда гына булды. Ул арада төрле имеш-мимеш таралып өлгерде. Имеш-мимешне чынлыкта Әгъли үзе таратты. Би яныннан чыккач, ул очраган бер кешегә Үтинең ничек югалуы турында сөйләргә тотынды. Берсенә сөйләгәндә, ул аны кичүдән чыкканда суга агып киткән, диде, икенчесенә сөйләгәндә, ике тау арасыннан чыкканда яңгырда таурлар кулына эләккән, диде, өченче кешегә сөйләгәндә инде аның сөекле улы Үтине үсмерләрнең кайсыдыр, үчекләшеп, кадап, чәнчеп үтергән булып аңлашылды.

Ир өеннән Әгъли иң элек үз өенә кайтып китте. Анда аны дүрт күз белән көтеп торалар иде. Үз өендәгеләргә дә ул Үти турында төрлечә сөйләде. Хатын-кызлар, балалар елашырга тотынды. Шулай өй эчендәгеләрнең тынычлыгын алгач, Әгъли балтачылар янына китте — Ярыш аңа төшкә кадәр килеп җитәргә кушкан иде. Балтачылар да сораштыра башладылар һәм тагын Әгъли берсенә бер төрле, икенчесенә икенче төрле җавап бирде. Аның бераз гына башы буталган һәм бераз гына зиһене таралган иде. Ул үзе Үтинең үлеменә ышанмый, аныңча, Үтинең кичүдә суга агуы да, таурлар кулына эләгүе икесе дә берьюлы чын да булырга һәм шул ук вакытта ялган да булырга мөмкин иде. Ләкин аның берберсенә ялганмаган өзек-өзек сүзләрен тыңлаучылар шулай да үзләренчә фикер йөрттеләр: Үтинең кайчан һәм ничек юкка чыгуы билгеле түгел иде. Шулай булгач аны эзли чыгарга кирәк иде.

Яңгыр бүген иртән генә сибәләде дә, төшкә туктады һәм күк йөзендә көндәгечә балкып кояш чыкты. Көн яктыру белән би янына төркем-төркем булып та, аерым-аерым да ирләр килә башлады. Алар Үтине эзли чыгарга теләк белдерделәр.

Ун кешелек алайны, атка атландырып, би Күлле таба үзәненә, җәяүле ун кешене диңгез буена җибәрде. Тагын ун кеше, шулай ук атка атланып, коралланып, төньяк таулар ягына китеп барды.

Балтачыларның эше көне буена бик сүлпән барды. Төнлә ыгы-зыгы килеп арыган кешеләрнең болай да эшлиселәре килеп тормый иде. Үтинең юкка чыгуы, Әгълинең кайгысын уртаклашу ял итү өчен үзе бер сәбәп булды.

Үтине эзләргә киткән кешеләр кичкә бер-бер артлы кайта башладылар. Иң элек төньяк таулар ягына китүчеләр кайтып төште. Алар берни тапмаганнар, беркем-

не күрмәгәннәр. Диңгез буена китүчеләр дә берни тапмыйча кайттылар. Күлле таба үзәненә китүчеләр дә буш кул белән кайттылар. Шуның өстенә алар бик нык пошаманга төшкәннәр иде. Күл буенда алар таурлардан беркемне очратмаганнар. Моңарчы гел шунда яшәп яткан һәм кала кешеләре белән еш кына алыш-биреш иткән, дус-тату яшәгән таурлар, бөтен авыллары белән, барлык мал-туарлары белән каядыр китеп барганнар иде. Кая булсын? Күрәсең, таулар арасынадыр. Ник? Бу хакта сорашырга-белешергә беркем очрамаса да, монда инде әллә ни сер юк. Күрәсең, алар чыннан да Үтине аты-ние белән тотып алганнар да үзләре белән алып киткәннәр һәм атын да, үзен дә... ашап бетергәннәр. Лелегләрнең үченнән куркып, каядыр качып киткәннәр.

Һәркем шулай дип уйлады. Би дә, пир ата Әмәк тә шулайрак дип уйладылар. Тик менә шунысы аңлашылып җитмәде — ник Үтигә каршы чыктылар икән таурлар. Бит алар кала белән, би белән күптән инде дустату яшиләр. Инде күптән. Бик күптән алар тарафыннан берниндии явызлык, берниндии юлбасарлык эшләнгәне юк. Бит алар Типкә бинең кемлеген беләләр — алар аннан куркалар да, шул ук вакытта алар аны изгеләштерәләр дә. Типкә би Аллага тиң мака сарның бертуган энесе! Типкә би таурларга монда Алла улы тарафыннан җибәрелгән. Ничек итеп аның кешесенә, аның малына кул күтәрмәк кирәк?! Таурлар башлыгы Марис ахмак аңгыра түгел. Тора салып аның Типкә би белән бозылышасы килмәс. Аннан соң, таулар арасына китеп ул кая барсын? Анда да шул ук таурлар, тик алар Марисның үзенә дошманнар. Алар җиренә аяк басу белән, аларның үзләрен тотып ашаячаклар, хатыннарын, балаларын коллыкка алачаклар. Типкә би каласына якын яшәгән өчен генә тынычта, иркендә яши бит ул Күлле таба ыруы.

Әгәр чыннан да Үтине Күлле таба таурлары табып алганнар һәм үзләре белән алып киткәннәр икән, моның өчен нинди дә булса көтелмәгән сәбәп булган булырга тиеш. Йә аларга таурлар арасындагы башка кабиләләр яу белән килгәннәр дә, барысын да кырып бетергәннәр һәм берьюлы Үтинең юлына аркылы төшкәннәр яисә... Туктале, иртәнге якта Күлле таба үзәнендә Марислар булган лабаса. Иртән алар исән булганнар. Бакыр таудан кайтканда беркем каршы чыкмаган. Димәк, чыннан да...

Би белән пир ата шактый озак уйлаштылар һәм, яшьләрне җыеп, тагын бер мәртәбә төпченеп сорау алды-

лар. Бинең дә, пир атаның да шуны беләселәре килде: кайтканда яраннар күл буенда камыш куышлар, куыш тирәсендә кешеләр, мал-туарлар күрделәр микән? Берәүләр әйтте, күрдек, диде, икенче берәүләр әйтте, күрмәдек, диде. Мондый җавап би белән пир атаны янә аптырашта калдырды. Күлле таба авылына яу килгән булса, күрәсең, аларның куышларын җимергән булырлар яисә хәтта ут төртеп яндырган булырлар иде. Бер кабилә икенчесенә каршы сугышканда иң элек куышларын җимерәләр, яндыралар — анысы аның күптән билгеле. Ләкин күл турысыннан узганда яңгыр ява башлаган, шуңа күрә яшьләрнең күл буендагы тауларда кайгылары булмаган булырга мөмкин. Аларның үз хәлләре хәл булган, күрәсең. Шуңа да аларның җаваплары да төрлечә.

Шулай да нәрсә булды икән? Би, никадәр баш ватмасын һәм никадәр төрле сораулар биреп карамасын, берни ачыклый алмады.

Үтине эзләргә икенче көнне дә, өченче көнне дә каладан кешеләр чыгып китте. Әүвәлгечә берәүләр таулар, урманнар арасын тикшерделәр, икенче берәүләр диңгез буенда йөрделәр. Үти барыбер табылмады. Шулай итеп, Үти юкка чыкты. Югалуына өч тәүлек булганда, Әгъли һәм аның якыннары Үтине үлгән дип белделәр. Бу вакытта инде Үтинең агач сыны һәм мәет кәмәсе әзер иде. Дүртенче көнне, таң ату белән, балтачы Әгълинең төньяк тим буендагы Бакыр комган тыкрыгындагы өе янында, бөтен калага шом салып, кычкырып-кычкырып елаган-сыкраган тавышлар ишетелә башлады. Башта ирләр тавышы ишетелеп торды, аннан соң чәрелдек хатын-кызлар тавышы ишетелде. Алар туктауга, такмаклап-такмаклап, тагын калын тавышлы ирләр тотынды. Балтачы Әгълинең ике катлы таш йорты алдында башта күрше-күлән, аннан соңерактагырак урамнардан, тыкрыклардан моңсу йөзле ирләр, хатын-кызлар җыела башлады. Барысы да, елау-сыкрау тавышларына, авыр, моңсу мөнәҗәт сүзләренә колак салып тын гына көтеп тордылар. Ишегалдында исә, биек капка артында, күмүчеләр, келәүчеләр ашыкмыйча-кабаланмыйча, шулай да тизрәк булырга тырышып, соңгы эшләрне башкардылар. Юан тупыл агачыннан эче чукып, кырыйлары юнып ясалган мәет кәмәсенә Үтинең үзе зурлыгындагы сынын, тиешенчә кәфенгә төреп, сузып салдылар. Тере кешеләр балтачы Әгъли улын соңгы кат күреп калсыннар өчен, сынның йөзен ачык калдыры-

лар. Каладагы оста сынчы Үтине тач үзе кебек итеп ясаган иде. Тик ул тере кеше кебек итеп түгел, бәлки үлгән итеп — күз кабакларын йомган, битен шиңгән итеп эшләгән иде.

Соңгы юлга озатканда, озак юлда кирәк булыр дип, сын янына кәмә төбенә чүлмәк белән су, күбәтә белән бер сынык көлчә куйдылар. Иң кыены шул булды: Үти өйләнмәгән егет иде. Ләкин аның инде ярәшелгән кызы бар һәм шушы көннәрдә алар өйләнешергә тиешләр иде. Йола буенча, өйләнмәгән егет сыны янына кыз кеше сыны да салынырга тиеш. Яшь егетнең үле хәбәре ул өйләнергә тиешле кызга да, аның ата-анасына да, туганнарына да Үтинең үз ата-анасыннан ким тәэсир итмәде. Шундук алар Әгълиләр өенә килеп җиттеләр һәм көнетөне диярлек вакытларын шунда үткәрделәр. Үлек кәмәсен соңгы юлга әзерләгәндә алар, чын мәгънәсендә кәмәне, киләүчеләрне, сынчыларны уратып алдылар һәм аларның бер генә хәрәкәтен дә күздән ычкындырмаска тырыштылар. Киләүче изге Ана алдында Әгъли үзенең сөекле улына ниндидер таур кызын ярәшкән булулары турында кычкырып әйтсә дә, аларның, берәр ничек үчекләшеп, егет сыны янына чыннан да ярәшелгән кызның сынын салулары ихтимал иде. Калым, бирнә, туй мәсьәләсендә ата-ана арасында элегрәк берәр төрле каршылык, килешмәүчәнлек булган булса, кайчагында шундый хәлләр дә булгалый иде. Мәет сыны янына тере кеше сыны куеп калдыру ул тере кешене терeләй күмү белән бер санала иде. Шуңа да мондый чакта бәхетсез ата-аналар шулай аеруча уяу һәм сак булырга тырышалар иде.

Әгъли кызның ата-аналары белән бозылышмады. Үти сыны янына эштер-өштер генә эшләнгән таур кызының ямьсез генә курчагын салдылар. Таур кызы курчагына киләүче ана «Әнә бара юлың!» дип исем кушты да, зур авызлы ямьсез йөзенә бер төкерде дә, Үти сынының сул ягына, ак кәфен эченә кыстырып куйды. Шуннан соң ирләр кәмә кырыеннан калкып яткан мәет сынын аркылы-торкылы китереп бау белән бәйләделәр. Бәйләгәндә бауны кәмә астыннан чыгардылар, бауның очларын исә, беркем таба алмаслык итеп, аска калдырдылар. Шуннан соң өч аршын озынлыгындагы кәмәне ике типан өстенә куйдылар, типан башы белән кәмә башын бергә китереп бәйләделәр дә артып калган бау очын җиргә сузып салдылар. Җиргә сузып салынган бауны ике яктан икешәр шәрә кол тотып алды.

Елау-сыкрау тавышлары тынып калды. Киләүче ана соңгы юлга озатканда әйтелә торган соңгы сүзләрен әйтте. Хатын-кызлар кычкырып мөнәҗәт әйттеләр. Шуннан соң әкрен генә капка ачылды һәм коллар, башларын иеп, ташлы сукмактан мәет кәмәсен тартып алып киттеләр. Тыкрыкта көтеп торган кешеләр юл биреп сүзсез генә ике якка тайпылдылар. Мәет кәмәсе төньяк капкага таба юнәлде. Кешеләр, койрык булып, арттан ияределәр. Үз сарае турысында күмүчеләргә Типкә би дә кушылды.

Мәетне Бакыр-тау калага бара торган юлдан алып киттеләр. Капкадан чыккач, бераз җир калкулык өстеннән бардылар да, түбән төштеләр һәм Аксай кичүенә җитеп туктап калдылар. Көн аяз түгел иде, әледән-әле кояшны каплап, баш өстендә оешып җитмәгән таркау болытлар йөзә иде. Төнлә яңгыр яуган һәм таулар арасыннан агып төшкән яңгыр суларын агызып бетерә алмыйча, Аксай әле булса тулып, кара-кучкылланып ага иде.

Мәет кәмәсен кичүдән бер ярты чакрым чамасы үргә тартып бардылар. Кара тиргә баткан колларга туктарга кушылды. Алар туктап калдылар, иркенләп бер тын алдылар да үзләре артыннан ияреп килүчеләргә күтәрелеп карадылар.

Киләүче ана яр буенда соңгы догасын укыды. Сыктаучылар соңгы кат сыктадылар, еладылар. Изге атабызга теләкләрен юлладылар. Тартып килгән арканны җыйнап «мәет»сыны янына куйдылар. Изге ата чакма чагып ут чыгарды да кәмәдәге коры камыш, чыбык-чабыкка ут төртте. Камыш чытырдап яна башлау белән, коллар тиз-тиз генә кәмәне арттан этеп елгага төшерделәр. Җыелган халык тып-тын калып күзәтеп торды.

Агымсу шундук кәмәне эләктереп алды һәм диңгезгә таба шундук эләктереп алып та китте. Кәмәдәге ут әкренләп зурайды, көчәйде, күккә кара төтен күтәрелде һәм бер заман бөтен кәмәне ялкын чорнап алды. Махсус майлар белән майланган сын да, кәмә дә диңгезгә барып җиткәнче үк янып бетәргә тиеш дип исәпләнелгән иде. Әгәр кәмә янып бетмичә диңгезгә барып керсә, бу, һичшиксез, яманга юралачак иде. Диңгезгә, Мингә мәетнең көле һәм кайбер калдык-постыклары гына барып җитәргә, җаны, рухы исә кара төтен булып күккә ашарга тиеш иде.

Ут чолгап алган кәмә артыннан, яр буеннан ирләр шактый озак җир йөгереп бардылар. Кәмә ярга якыная башласа, озын колгалар белән аны уртагарак этеп җи-

бәрделәр. Түбәндә, Аксай тамагына якын җирдә, балтачылар «Фалия» кәмәсен эшләгән җирдә, күпер янында озын колгалар белән яр буенча тезелеп тордылар. Алай-болай кәмә күпергә якынаеп, алай-болай очкын, ут чыкмасын дип, алар сакта тордылар. Ләкин күпер янына җиткәнче мәет кәмәсе янып бетте һәм бәйләп таш тутырылган кәмә калдыгы шундук чыжлап, пыскып су төбенә китте.

Озата килүчеләр җиңел сулап куйдылар.

— Атабыз катына китте! — диде пир ата.

Бөтен калада Туктар иң оста аучы санала иде. Тауда-кырда аның белмәгән-күрмәгән киеге юк, йөрмәгән-күрмәгән сукмагы юк. Күбрәк вакытын ул, бурзай эт ияртеп таулар-урманнар арасында йөреп үткәрә иде. Башкалар кырга җир сөрергә яисә уракка киткәндә, ул, этен ияртеп, аркылы-торкылы авыр садакларын тагып, таң тишегеннән таулар ягына күптән куйган капкынын карарга китеп бара, башкалар таш куптарып таштан йорт салганда, шулай ук атына атланып әкрен генә шул ук таулар ягына китеп бара. Кырда-басуда иң чүпле җир кемнеке дисәң, аныкы була. Башагы коела башлаган арыш басуы, бодай, арпа күбәсе кемнеке дисәң, шулай ук аныкы була. Язгы сөрүгә бер көнгә, ярты көнгә булса да ул һәркемнән соңлабрак чыгар, уракка шулай ук соңлап чыгар. Басуда кемнең калган ашлыгын кошлар чүпли дисәң, Туктар басуы икән — урылмый ята. Йортына, ишегалдына барып керсәң, тагын шул ук хәл — анда җимерек, монда җимерек. Кайчан барма, капкасы яртылаш ачык, өй ишеге яртылаш ачык, тәбәнәк таш өйнең биек баскычы баскан саен ишелеп төшәргә әзер булып, селкенеп, шыгырдап тора. Мал абзары иске-москыдан, калдык-постык агачлардан гына әмәлләнгән сыман. Шул ук вакытта Туктарның унлап эте бар. Барысы да көр, таза ау этләре — бурзай, барак, торзайлар. Берсе-берсе бозау чаклы. Алар өрә башласа, бөтен тирә-як яңгырап, гүләп тора. Аларның тавышы ерактагы тау башларына кадәр барып ишетелә, яңгырап кире кайта. Аның бар карап торганы шул аты да, этләре.

Очраган бер кеше белән үз итеп, кычкырып сөйләшә торган, һәрвакыт көләч йөзле, көр тавышлы аучы Туктарны белмәгән кеше юк. Кем белән генә сөйләшеп китмәсен, ул һәркем белән уртак тел таба. Үзе кебек ирләр арасында ул төрле кызык сөйләп җиңел генә көлдерә белә, хатын-кыз янында, яшенә карап, таулар, урманнар арасында ауда башыннан кичкәннәрне сөйләп, тың-

лаучыларны шаккатыра ала. Үзеннән яшьрәкләр, үсмерләр, балалар белән сөйләшергә туры килсә, аның шулай ук авызына каратып тотар өчен сөйләр сүзе табыла. Картлар, авырулар янында исә ул үзен бөтенләй башкача тота. Күбрәк ул аларның күңелен күтәрергә, юатырга, берәр акыллы киңәш әйтергә тырыша. Аучы Туктар белән аралашу, сөйләшү, аның башыннан кичкәннәрне тыңлау кайчагында үзе бер бәйрәмгә әверелә. Кем генә булмасын, кайда гына булмасын, һәркем аның янына тартыла.

Ләкин, никадәр аны яратмасыннар, шулай да аучы Туктарга карата ныклы, төпле хөрмәт юк. Ул бары очрашып сөйләшкәндә яисә көлдергәндә генә яхшы. Башка вакытта ул күпчелеккә бераз гына ялкаурак, бераз гына пошмасрак һәм бераз гына мактанчыграк булып тоела. Аннан соң ул күп ашарга ярата. Ир өендә ирләрнең аны сынап караганнары бар. Таулар арасында дүрт көн ач йөреп кайтканнан соң ул бер утыруда бер куйны ашап бетергән дип сөйлиләр. Бер утырганда бер чиләк сөт эчеп бетерү яисә бер чүлмәк каймак эчеп кую аңа берни тормый.

Аучы Туктарның тагын бер һөнәре бар — ул да булса җыр. Ирләр арасында бөтен калада җырда аучы Туктарның тиңдәше юк. Зур туйларда, бәйрәмнәрдә, аш-суда Туктарның урыны түрдә. Кем чакыра, ул шунда бара, беркемгә дә каршы килми. Аеруча ул Типкә би сараена барырга ярата. Би дә, күрәсең, үзенең Фалиясен оныта алмыйча, иң элек Туктарны чакыра һәм сәгатьләр буена аның җырлавын тыңлый ала. Би белән алар болай да якын мөнәсәбәттә. Аудан алып кайткан иң яхшы тиреләрен, болан мөгезләрен, тоякларын аучы Туктар иң элек бигә илтеп бирә. Кайчагында бүләк итеп, кайчагында салым өчен дип, кайчагында исә ашлыкка алыштырып кайта. Үз басуында әллә ни иген уңмаса да, илдә барында Туктарның да чокыры буш булмый.

Шулай үз иркенә уйнап-көлеп, җырлап һәм ау аулап кына яшәп ятканда һәм киләчәк тормыш тагын да күңеллерәк, иркенрәк булыр сыман тоелганда, көтмәгәндә китереп койган җил-яңгыр һәм Үтинең юкка чыгуы, аучы Туктарга да кире яктан китереп суктырды. Зөлмәт аның улы иде. Этләре, атлары һәм кечкенә хатыны Хәлимә кебек үк яраткан һәм якыны иде. Ул, билгеле, Зөлмәтнең дә үзе кебек батыр аучы, җырчы һәм көрәшче булуын теләде. Үзе кебек үк бөтен калага данлы, сөекле булуын теләде. Ул шулай ук аның бөтен калада быелгы

иң чибәр кызга өйләнүен, Зөлмәт турында, димәк, аның үзе турында бөтен кала халкының мактап сөйләвен, данлавын теләде.

Тазалыгы, батырлыгы ягыннан Зөлмәт атасына охшады. Кирәк чакта ягымлы итеп сөйләшүе дә, көр тавышы да тач атасыныкы иде. Арпа ана туенда Мәмлине җиңеп Сурияга өйләнергә хокук яулап алгач, чынлап та кала халкы ду килде. «Атасыннан да уздыра бу!» диделәр Зөлмәт турында. Ләкин Үтинең югалуында күпмедер дәрәҗәдә Зөлмәтнең дә языгы барлыгы беленгәч һәм, бигрәк тә беренче авыр сынауда ук Зөлмәтнең эндереннән аерылып калуы, җитмәсә, аты-ние белән агып китүе ата кешенең дә, Зөлмәткә зур өметләр багышлаган башкаларның да күңеленә кара кайгы булып ятты. Шундук аның бар яктан да атасына охшамавын искә төшерделәр. Тавышы көр һәм ягымлы булса да, Зөлмәт атасы кебек хисле итеп, дәртле итеп җырлый белми иде. Аннан соң ул кирәгеннән артык мактанчык, кирәгеннән артык пошмас — гамьсез иде. Шул ук вакытта ул бик тиз кызып китә һәм бик тиз үпкәли иде. Аннан соң ул бераз гына мәкерле дә иде бугай әле. Монысы инде аучы Туктарда бөтенләй юк иде! Аучы Туктар ул чын мәгънәсендә алып Туктар иде. Кәмиләргә каршы яуда ул берүзе йөз кеше өчен сугышты, ике-өч мәртәбә Типкә бине, башкаларны җиз калканы белән күрәләтә үлемнән саклап калды. Диңгездә, давыл вакытында бик күп йомшак буынлылар кәмә идәнендә егылып аңсыз ятканда, ул көнетөне аяк өсте кыю рәвештә кәмәнең көсмәнен тотты. Мәкердә, икейөзлелектә, куркаклыкта аны беркем гаепли алмас! Зөлмәт урынында булган булса, аучы Туктар, яңгырга сылтап, борын төбендәге иптәшен югалтып тормасые, башкалардан соңга калып, кичүгә дә соңламас иде.

Алып Туктарның йөзен соңгы көннәрдә кара болыт басты һәм аның күңелен менә шундый нәрсәләр борчыды. Йөрәгенә кан сауды. Иң күңелсезе шул булды: озын колак аңа булачак кодасы Ярышның сүзләрен китереп җиткерде. Суриянең этисе балтачы Ярыш ир өендә ирләр белән яшьләр турында гәпләшеп утырганда «Суриянең туе бозылды болай булгач»дигән сүз ычкындырган, имеш.

Туйның бозылырга мөмкинлеген Туктар алып үзе дә бик яхшы сизенде. Калым һәм бирнә турында күптән инде сүз башларга кирәк булса да, балтачы Ярыш әлегә бернинди әзерлек сиздермәде. Быел көз туганлашырга, кода-кодагый булып туйларда йөрергә тиешле кешеләр

күптән инде үзара яучылар, димчеләр йөртә башладылар, кайберәүләр инде килешеп куйдылар. Аларның эшләре майлаган арба кебек бара. Тик менә каладагы өч кешенең генә туй хәстәрлеге әле һаман бер урыннан кузгалмыйчарак тора. Моның сәбәпләре, билгеле, бер Туктарда гына яисә аның улы Зөлмәттә генә түгел иде. Монда әле Мәмли ягыныкылар да бар иде. Туктар бик яхшы аңлады — Типкә би белән пир ата Әмәкнең дә җиңел генә бирешәселәре килми, аларның да Сурияне һичшиксез үзләренең Мәмлиенә аласылары килә. Балтачы Ярыш исә би белән пир атага да, Туктарга да каршы сүз әйтәсе килмичә, беркемне дә өметләндермичә суза бирә. Билгеле, аның хәле дә әллә ни кызыгырлык түгел. Бит аның да, башкаларның да бинең мәңгелек ягысы, дошманы буласы килми. Ләкин шул ук вакытта ике атаклы кешенең Сурияне үзенең килене итәргә тырышуы ул чынлыкта аның кызының данын гына арттыра. Мондый хәлләр ел саен диярлек була һәм моның бернинди йөз каралыгы юк.

Кызның атасы көрәштә беренче мәртәбә җиңгән егеткә кызын бирергә теләми икән, йола буенча ул яшьләрне икенче, хәтта өченче мәртәбә көрәштерә ала. Күрәсең, Ярыш шулай эшләргә җыенадыр да. Ләкин бит әле моның икенче ягы да бар — бер үк җиңелгән кеше икенче, өченче мәртәбә дә җиңелеп хур булырга теләр микән? Туктар алып Мәмли турында шулайрак дип тә уйлаган иде һәм бу аның чак-чак кына күңелен тынычландырып тора иде шикелле. Ни генә булмасын, ул Зөлмәтенә чын күңелдән ышанды һәм Ярыш яңадан көрәш оештыра-нитә калса, һичшиксез тагын улы җиңеп чыгар дип өметләнгән иде.

Үтинең үле сынын күмү йоласын башкаргач, халык шактый озак таралмый торды. Күмү йоласыннан соң үлек ашы ашыйсы бар иде. Балтачы Әгъли кимендә йөз кешегә җитәрлек итеп сый әзерләде. Абзарындагы бишалты сарыгын, бердәнбер сыерын суеп казан асса да, җитәрлек түгел иде. Үлек ашына дип балтачы Ярыш Әгълигә бер башмак тана, Типкә би исә бер кысыр сыер белән бер үгез башмак бүләк итеп бирде. Шуның өстәвенә Ярыш та, Типкә би белән пир ата Әмәк тә Әгълигә бирәр мичкә яңа сыра, чагыр һәм буза бирделәр.

Бу турыда Туктар күмү йоласы төкәнеп, кәмәчеләр күпере янында, тау буенда, ачык языда үлек туе башлангач кына белде һәм шундук барысын да аңлап алды: Әгъли бүген үзенең мәрхүм Үтиенә багышлап яшьләрнең ярышын уздырачак. Йөзләгән кешене сыйларга

кирәк булган кебек, ярышта җиңүчеләргә бүләк тә бирергә кирәк булачак. Ул бүләкләрне кала тоткасы би белән Ярыш, пир ата бирмәсә, балтачы Әгъли каян алсын?!

Чыннан да нәкъ шулай булып чыкты. Туктар алып сизенгәнчә булып чыкты. Йоласына, шартына туры китереп, артык шаулашмыйча, киресенчә, тын гына, басынкы гына, кайгылы гына аш-су уздыргач, аякчылар сыра, чагыр таратып чыктылар да, Әгъли барысына ишетелерлек итеп, ил-көнгә үзенең теләген әйтте.

— Туганнар! Ил-көн! Батыр улым Үтигә багышлап мин яшьләрнең ярышын уздырырга булдым, — диде Әгъли. — Үти улым исән чагында мин аның күңелен күрә алмадым. Инде соңгы юлга озатканда мин аңа яхшылык эшләргә булдым. Мәет җаны миңа үпкәләмәсен дидем. Олуг атабыз янына баргач, атам-анам мине санламадылар дип, башкалар арасында борлыкмасын дидем. Без сине яраттык, улым... без сине...

Соңгы сүзләрен ул әйтеп бетерә алмады, тыела алмыйча елап җибәрде. Аның янына шундук күршеләре килде, юатып, ике ягыннан култыклап читкә алып киттеләр. Уртага Ярыш чыкты. Әгъли әйтәсе сүзләрне ул әйтеп бетерде.

— Туганнар! — диде ул, балта чапкандагы сыман никтер кулын селтәп. — Әгъли — минем күрше. Әгъли минем кул астында — балтачы. Аның кайгысы — минем кайгы. Җиңүчеләргә бүләкләрне Мин дә, Әгъли үзе дә, аның якыннары, күрше-күлән дә куйды.

Шулай дигәч ул аяк астындагы өемнең өстенә япкан киндер япмасын ачып җибәрде. Япма астыннан түгәрәк өстәлгә куелган зур корсаклы ярты батман керешле кызыл чүлмәк калкып чыкты, аның янында ике тоткалы, нечкә аяклы көмеш савыт балкып китте. Шунда ук җиз калайлар тегеп ясалган сугышчы киеме салынып тора, ук тулы садак ята иде. Ярыш бүләкләрнең кайсын кем бирүе турында әйтте. Ярты батман ашлык керешле, зур авызлы, зур корсаклы чүлмәкне Әгълинең абзасы, атаклы чүлмәкче Кәмзә биргән булып чыкты. Көмеш савыт Типкә бинеке иде. Балык тәңкәсе кебек итеп җиз калайлар тегеп ясалган сугышчы киеме көбә Әгълинең үзенеке, ук тулы садак исә Әгъли белән бергә кәмә ясаучы балтачы Халикныкы иде.

Җиңүчеләргә барлыгы биш бүләк булырга тиеш, ләкин монда бары дүрт кенә бүләк иде. Күпчелек моның серен бик яхшы белде. Шулай да, белмәмешкә салынып, якындагылар беравыздан диярлек:

— Бишенчегә ни? — дип кычкырдылар.

Ярыш, билгеле, андый сорауны көткән иде. Ул бары шундый сорауны гына көтеп ләззәтләнә иде. Ул ишетмәмешкә салышты. Өстәлдәге бүләкләрне, утын яргандагы кебек кулын селтәп, яңадан санап чыккан булды да, бүләкләрнең дүрт кенә икәнлегенә ышангач, көттереп, кайгылы итеп:

— Бишенчегә, туганнар, мин кызым Сурияне бирәм, — диде.

Ярышка бары Үтинең яшьтәшләре һәм алардан яшьрәкләр генә катнаша ала иде. Ярыш Үти истәлегенә багышланса да, чынлыкта монда Суриянең һәм шул ук вакытта быелгы каладагы ике яшь егетнең язмышы хәл ителергә тиеш иде. Моны һәркем шулай дип аңлады.

Иң элек ун яшьлек малайларны йөгерештерделәр. Аннан соң унбер яшьлекләр, унике яшьлекләр йөгеrеште. Беренче, икенче, өченче килгәннәргә бүләкләр бирделәр. Аннан соң өлкәнрәк малайларны, атка атландырып, таулар ягына җибәрделәр. Аларны иң яхшы җайдаклар алып барды. Бер биш чакрым чамасы җир киткәч, тигезлек буйлап алар ярыш булган якка омтылдылар. Атлар ярышка киткән арада, иң яхшы укчылар еракта багана башындагы карачкы әтәчкә ук ата башладылар. Укчылар эшләрен бетергәндә, болынга атчылар кайтып керде. Еракта томырылып килгән таныш атлар, таныш җайдаклар күренү белән, халык җанлана төште, урыннарыннан купты һәм түгәрәк читендәгеләр атларга каршы кузгалып куйдылар, малайшалайлар атлыларга каршы йөгерделәр. Ат чабышын кешеләр яраталар иде һәм ат чабышы нинди уңай белән генә уздырылмасын, тамаша зур кызыксыну тудыра иде. Тик шулай да бүген малайларның йөгерүе дә, карачкыга ерактан ук ату да, хәтта ат чабышы да элеккечә кызыксыну уятмады. Барысы да иң соңга калдырылган көрәшне һәм йодрык сугышын түземсезләнеп көтте.

Быелгы язгы сабан туенда да Зөлмәт белән Мәмли арасында көрәш һәм йодрык сугышы булды. Анда әле ачыктан ачык Сурия турында сүз булмады, ләкин һәркем ул вакытта да бары Сурияне генә күз алдында тотып көрәште. Чөнки быел калада кияүгә биреләсе иң гүзәл, иң беренче кыз Сурия булачагын инде алдан ук юрап торалар иде. Сабан туенда көрәштә Зөлмәт җиңде. Бу, билгеле, көчләр тигез дигән сүз иде. Шуңа күрә дә җәй буена төркемгә алар — Зөлмәт белән Мәмли — алмаш-

тилмәш баш булдылар да. Сүриягә кияү була алырлык батыр алып калу өчен кимендә ике төр ярышта җиңеп чыгарга кирәк иде. Җәй буена Мәмли соңгы көрәшкә, менә бүгенге икенче көрәшкә, ярышка әзерләнде.

Ул Зөлмәтнең кире якларын болай да яхшы белә иде. Язгы сабан туендагы ярышта аның Мәмли белмәгән тагын бер кире ягы ачылды. Бу турыда ул әлегә беркемгә әйтмәде. Үзенең дусты турында яман сүз сөйләүне килештермәде. Бу турыда ул хәтта бигә дә, пир атага да әйтмәде. Пир ата Әмәк, Мәмлинең карт этәсе исә җәй буена, әз генә буш вакыты булдымы, батыр уланны күнегергә, чыныгырга өндәде. Мәҗбүр итте. Хәер, аны алай мәҗбүр итеп торасы да юк иде. Мәмли үзенә максат куйды: ул барыбер Сүрияне алырга тиеш иде. Ул аны яулап, көрәшеп, батыр калып алырга һәм бөтен кала халкының исен китәрергә тиеш иде. Башкача була алмый иде. Ул барыбер җиңәргә һәм һичшиксез җиңәргә тиеш иде. Җәй көне ул күзгә күренеп үзгәрде. Моңарчы бераз гына холыксызрак, үзсүзлерәк һәм юкка-барга үпкәләргә әзер торган оланның күз алдында үзгәрүен күреп торган пир ата күңеленнән сөенеп бетә алмады. Берүзенә ике атасы, бер анасы булган, ләкин чынлыкта тома ятим Мәмли кечкенәдән үк үзенең кимчелекле булуын аңлап үсте. Би дә, пир ата да моны яхшы аңладылар һәм ничек тә аның күңелен кырмаска тырыштылар. Ләкин аларның менә шул адым саен күңел кырмаска тырышулары нечкә күңелле ятим малайны үзүзен никтер кыерсытылган итеп тоярга мәҗбүр итте. Әндеригә алынуның беренче елларында еш кына ул киреләнеп берәр нәрсәдән баш тартты йә булмаса тиктомалга үзенең берәр яшьтәше белән сугышып китте. Хәер, читтән караганда гына ул «тиктомалга»булып тоелгандыр. Җайлап сораштыра торгач, пир ата соңыннан белде: аны кемдер кыерсыткан, аңа ниндидер ярамаган сүз әйткән икән. Менә шундый үпкәчел һәм тиз кызып китә торган олан пир атага шактый күп борчу салды. Кеше күңелен никадәр яхшы белмәсен, шулай да пир ата Мәмли белән чын-чынлап уртак тел таба алмады, ахрысы. Сабан туенда җиңелгәннән соң Мәмлигә ул киләчәктә нишләргә кирәклеге турында төрлечә киңәш биреп карады. Ләкин егет Мәмли андый киңәшләргә артык колак салмады.

Андагы борылыш бөтенләй көтмәгәндә булды. Бер язгы кичтә алар берничә яшь-җилкенчәк төркемләшеп кала читенә, кызларның киндер тукыган җиренә бар-

дылар. Егетләр килгәч, кызларның киндере шундук оныгылды. Күңелле сөйләшү, такмак әйтешү башланды. Тора-бара түгәрәк әйләнеп җырлау, бию һәм һәртөрле уеннар башланып китте. Кызлар янында әниләре, карчыклар да бар иде. Алар шунда, кич мал ашатырга чыккан көтүче кебек, яшь кызларга күз-колак булып утыралар иде. Шулай булса да ул кичне алар тау башында төн урталарына кадәр күңел ачтылар. Тау башында, калку җирдә, бик озак аларның чыр-чуы, көлешкәне ишетелеп торды. Якында гына аяк астында буталып бала-чага чабышып йөрде.

Шул кичтә ул беренче мәртәбә Сурия белән ачыктан-ачык сөйләште. Түгәрәк әйләнеп җырлаганда алар янәшә туры килделәр. Ул аның кайнар кулыннан тотып алды. Сурияне озын күлмәк итәге җилләнеп, әледән-әле аның тезенә, аягына тиеп китте. Селкенгәндә үзенең дә чәче бер-ике мәртәбә Сурияне битенә тиде. Яшьләр бер-берсенә карашып-көлешеп алдылар. Бер мәртәбә парлашып уйнаганда алар арасына Зөлмәт килеп кысылды һәм көчләп диярлек, шаярып сөйләнәсөйләнә Сурияне култыклап алды. Икенчесендә түгәрәк уртасында биегәндә, Зөлмәт тагын Сурия турысына килеп тыпырдап биеде дә үзе янына чакырды. Мәмлинең моңа эче пошты. Ләкин ачыктан-ачык Зөлмәткә каршы килергә аның хакы юк иде. Яшьләр кемнең кемнеке икәнен үзара белсәләр дә һәм күпләр инде танышыпкилешеп куйган булсалар да, Сурия әле беркемнеке дә түгел иде.

Менә шул кичтә шаярышып куышканда алар ничектер бергә туры килделәр. Сурияне Мәмли кочып алды һәм шунда кыз аңа беренче кат үзенең күңелендәгесен сиздерде. Юк, ул яратам да димәде, мин синеке булырмын да димәде, башка шундый сүзләр дә әйтмәде. Ул бары Зөлмәтне генә шелтәләде, бөтенләй сорамаганга, көтмәгәндә, бераз гына иркәләнеп, бераз гына назланып һәм үпкәләп: «Бигрәк былагай шул Зөлмәт», — диде.

— Мин дәме? — диде Мәмли, үзе дә сизмәстән.

— Юк! Син — юк! — диде Сурия, көлеп һәм аның күкрәгенә салынып төшкән озын чәч толымнарын тартты да, кул арасыннан балык кебек шуып чыкты һәм кызыл, сары буй-буй аралаштырып сугылган күлмәк итәген бик каты җилфердәтеп йөгереп китте.

Барысы да аңлашылды. Мәмли аңлап алды. Ул үзен искиткеч бәхетле итеп тойды. Дөнья кинәт киңәеп, ямьләнеп, яктырып киткәндәй булды. Ул төнне Мәмли йок-

лый алмады. Ул төнне генә түгел, башка төннәрдә, көннәрдә дә ул бары Суриянең ягымлы йөзен, сүзен уйлап, куанып исерек сыман йөрде. Бер атна чамасы шулай хыялланып йөргәч, ул айнып киткәндәй булды. Әйе, ул үзен бәхетле итеп тойды, ләкин ул бәхетне әле яулап аласы бар иде. Әгәр «былагай» Зөлмәтне көз көне җиңмәсә, берничек тә Сурия аныкы була алмаячак иде. Шуннан соң ул зур көрәшкә, соңгы ярышка әзерләнә башлады. Пир ата киңәшен тотып, ул көн дә иртүк күңел биреп таулар ягыннан йөгереп кайтты, үз эшләре белән әледән-әле көрәш башлап җибәрде. Ләкин ул хәзер Зөлмәткә якын да килмәде. Үзенең күңелендәгесен, эчендәгесен сиздерергә теләмәгәндәй, ул аннан читтә, ул булмаган җирдә генә йөрергә күнекте. Аннан соң ул ныклап торып йодрык сугышына өйрәнә башлады. Моның өчен караңгы бер почмакта, әтисенең сараенда, яшерен бер җирдә, өрлек башына күн капчык асты, капчык эченә исә бүкән салды һәм буш вакыты булган саен шул бүкәнне тукмый торган булып китте. Аннан соң ул хәзер пир ата сүзләренә игътибар беләнрәк колак сала башлады.

Мәмлинең еш кына югалып торуын, йөгерүен, күнегүләр ясавын Зөлмәт тә, башкалар да күрмәделәр түгел, күрделәр. Ләкин моңа беркемнең дә исе китмәде. Зөлмәт үзен Мәмлидән көчлерәк дип исәпли иде. Үзенең җиңәсенә ул әз генә дә шикләнмәде. Мәмлинең тырышып-тырышып ярышка әзерләнүеннән ул көлеп кенә куйды, җае чыккан саен дуслары алдында аны түбәнсетергә, аннан көләргә тырышты. Ләкин Бакыр таудан кайтканда булган хәл, Үтинең юкка чыгуы һәм үзенең чак-чак кына Мин авызына китеп бармавы Зөлмәтне шактый куркуга салды. Тиздән ярыш булачак. Ничек көрәшер ул Мәмли белән? Җиңә алырмы? Үз көченә артык ышанмый микән ул? Күңеленә аның шундыйрак уйлар килде. Ләкин ныклап торып ярышка әзерләнә башларга аңа нидер комачаулагандай кебек булды. Әллә ялкаулык, әллә шүрләү. Бүгенге ярыш аның өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Ул каушап калды һәм көне буе караңгы чырайлы булды һәм көрәш башлану белән алар озак сынашмадылар да — Мәмли аны әләктереп тә алды, баш аркылы атып та бәрде.

Зөлмәт, ахрысы, бик каты төште — кузгала алмыйча бик озак ятты ул. Шундук ашыгып бер яктан атасы Туктар килеп җитте, икенче яктан Ярыш килде. Аны ике яктан күтәреп торгыздылар да култыклап читкәрәк

алып киттеләр, алтын касә белән сыек аракы — чагыр бирделәр.

— Тагын кем чыга? — диде Әгъли төркемдәге яшьләргә карап.

Түгәрәк тирәли басып торган яшьләр, оятлы йөзләрен түбән иделәр. Мәмлигә каршы чыгучы булмады.

— Меңгә чаклы саныйм. Шуннан соң да Зөлмәт аягына басмаса, Мәмли җиңүче булып кала, — диде Әгъли бераздан, халыкка белдереп һәм кычкырып ашыкмыйча гына саный башлады.

Ул арада исенә китерү өчен Зөлмәткә төрле яктан сөлге җилпеделәр. Кемдер чүлмәк белән салкын су алып килде, кемдер алтын касәгә салып чагыр китерде. Туктар сөлгене юешләп башта улының битен, күкрәген, аркасын, шәрә аякларын-кулларын ышкыды, колак төбендә генә аңа дәртләндерү сүзләре әйтте. Зөлмәт, ниһаять, күзләрен ачты, аптыраган сыман як-ягына карап алды да йомшак урыныннан тормакчы булып ухталып карады. Аңа чагыр эчерделәр. Шуннан соң аның агарынган битенә кызыллык йөгерде. Ул тиз генә аягына басты һәм ярсып түгәрәк уртасына ташланмакчы булды. Ләкин аны тотып калдылар.

Меңгә якынлашып килгән Әгъли Зөлмәтнең аякка басуын күреп алды.

— Йодрык сугышына чыгасыңмы? — диде ул аңа.

— Чыгам, — диде Зөлмәт, батыр күренергә тырышып, чамадан артыграк кычкырып.

— Ярар, чыгасың икән, чыгасың. Әзерләнегез, — диде Әгъли.

— Мин әзер! Мин аны бер сугуда җиргә сеңдерәм! — диде Зөлмәт, кәпрәеп.

Тирә-якта көлешеп алдылар. Мәмли эндәшмәде. Туктар белән Ярыш та, Типкә би белән пир ата да эндәшми калуны яхшырак күрделәр. Сугышчылар эчләрен саклау өчен билләренә үгез күненнән ясалган ике кул яссылыгы киңлегендәге каеш будылар. Каешның очлары арткы якка чыгарып яшереп куелды. Бит, муен, күкрәк, беләк тулысынча ачык калды. Аннан соң, күптән килә торган гадәт буенча, бармакларын имгәтмәс өчен һәр сугышчы йодрыкларына күн тасма урый ала иде. Язгы сабан туенда да Мәмли белән Зөлмәт нәкъ хәзергесе кебек билләренә киң каеш тактылар, йодрыкларына күн тасма урадылар. Ул вакытта Зөлмәт Мәмлинең башына бер-ике генә тондырды — Мәмли исен җуеп түнеп китте, авып китте һәм Зөлмәт тагын берничә мәртәбә өстәгәч,

чалкан барып төште. Ул вакытта шулай булды. Мәмли аны бик яхшы хәтерли. Онытырлык булмады ул чактагы сугыш. Зөлмәттән ул мондый көч көтмәгән иде. Зөлмәт белән аның элегрәк тә көрәшкәннәре бар иде. Кайчагында әле берсе, әле икенчесе чыккаласа да, аларның көче бер чама иде. Быел яз әнә Зөлмәт өстен чыкты. Бу турыда Мәмли бик озак уйланды һәм уйлана торгач Зөлмәтнең батырлыгының серенә төшенде. Бу турыда ул җәй буена беркемгә әйтмәде — күңелендә генә саклады. Менә хәзер ул сернең чыннан да дөресме, түгелме икәнлеген сынап карар чак җитте.

Әгъли әзерләнергә кушкач та, кулына күн тасмалар тотып, бер яктан Зөлмәтнең малае, икенче яктан Мәмлинең малае йөгереп килде. Тасмаларны көрәшчеләр кулына гадәттә өлкән ирләр бәйли иде. Туктар малай кулыннан тасмаларны алды да, улының югары күтәрелгән кулын бәйләмәкче булды. Мәмли кулын бәйләтергә ашыкмады.

— Минем сүзем бар, — диде ул, сугышны оештыручы Әгълигә карап.

— Әйт сүзеңне, Мәмли, — диде Әгъли.

— Минем кулга Зөлмәтнең тасмаларын урагыз, Зөлмәт кулына — минекеләрне, — диде Мәмли.

— Юк, юк, — диде Зөлмәт, үз тасмасын алмакчы булып.

Ләкин балтачы Әгъли аннан өлгеррәк булып чыкты, җиргә төшкән тасманың берсен эләктереп тә алды, читкәрәк китте. Яз көне дә Зөлмәт кулларына шул ук тасмалар уралган иде. Ул тасма уртасына тар гына, юка гына уемга хәйләкәр Зөлмәт кургаш калай кисәкләре яшереп калдырган иде. Яз көне Мәмли аның менә шул кургаш калайларын татыды да инде. Ерактан караганда һәм тиз-тиз генә кулга ураганда, тасма эчендәге кургашны күрерлек түгел иде. Әгъли мондый хәйлә турында белми иде, әлбәттә. Тасманы ул игътибар беләнрәк карады да уртадан аның ямаулы икәнлеген күреп алды. Пычак очы белән ямауны кискәч, аннан ялтырап кечкенә калай кисәкләре килеп чыкты.

Халык тып-тын калды. Зөлмәт ык-мык итте, кызарынды, ярдәм эзләгән сыман этисенә карап алды.

— Оятлы иттең башымны! — диде Туктар ачу белән һәм бер кызудан сулагайлап улының яңагына салып җибәрде.

Зөлмәт чайкалып китте, ләкин егылмады. Җыелган кешеләрнең кайсы көлде, кайсы, кызык буласын сизеп,

алгарак омтылды. Төрле яктан кычкырган, сызгырган тавышлар ишетелде.

— Ныграк бир — сабак булыр!

— Салып тапта! — дип кычкырдылар, ата кешене котыртып.

Ләкин Туктар алай коткыга бирелмәде — эткәләп-төрткәләп улын уртадан чыгарып җибәрде.

— Сугышсыннар!

— Болай гына сугышсыннар! — дип кычкырдылар аңа каршы яшьрәк әтәчләр.

Әгъли, киңәш сораган сыман, Типкә бигә карап алды. Ләкин Типкә би, берни эндәшмичә, караңгы чырай белән тын гына утыруында булды. Хәзер аның бу эшкә бөтенләй катнашасы килмәде. Монда инде Мәмли тулысынча үзе җиңеп чыгарга тиеш иде. Ул би, аның сүзе монда юш, ләкин ялгыш алай-болай Мәмлине яклау белдерсә, соңыннан аның күзен дә ачтырмаячаклар. Аның исә бернәрсәдә дә илгә каршы киләсе килмәде.

Типкә би эндәшмәгәч, Әгъли киңәш сорап Ярышка күтәрелеп карады.

— Нишләтәбез? — диде ул аңа.

— Халык ничек тели, шулай булсын, — диде Ярыш та, икеле-микеле итеп.

— Халыктан түгел, иң элек үзләреннән сорарга кирәк! — дип кычкырды Туктар, кызып, кемгәдер ачуланасы килеп. — Сорагыз әнә Мәмлидән — аның якта көч!

— Мин җәй буе көрәшкә, сугышка әзерләндем, Зөлмәт кебек хәйләләп җиңәргә уйламадым, — диде Мәмли.

— Сугышасыңмы, юкмы — шуны әйт! — дип, ачулы Туктар кызарынып Мәмлигә җикеренде.

— Мин сугыштан курыкмыйм! — диде Мәмли дә, усалланып. — Зөлмәт үзен җиңелгәнгә санаса, мин аны кичерәм.

— Миңа синең кичерүең кирәкми! — диде шул чакны Зөлмәт, әтәчләнеп һәм шәрә йодрыкларын йомарлап, тузынып, ашыгып түгәрәк уртасына килеп чыкты.

Йодрык сугышы шулай итеп үзеннән-үзе башланып китте. Мәмли әле кулларын күн тасма белән бәйләтеп өлгермәгән иде. Халык тынып калды, түгәрәк кысыла төште, һәм ике яшь егет усалланып бер-берсенә шап та шоп йодрык белән тондыра башладылар. Зөлмәт, йодрык сугышында үзен һичшиксез батыррак санаса да, шулай да ул үзенең серле тасмаларына ныграк исәп тоткан иде, ахрысы. Мәмли Зөлмәтне тиз арада кысрыклый башлады. Алар беравык түгәрәк буйлап куышып

йөрделәр. Мәмли җай туры китереп Зөлмәтнең калын иренле симез түгәрәк битенә күз төбенәрәк нык кына итеп сул кулы белән китереп бәргән иде — Зөлмәт чайкалып китте. Тау-таш җимергәндәге сыман кинәт көчле тавыш чыгарып халык шаулашырга тотынды. Зөлмәт, әйләнчек булган сарык кебек, бер урында әйләнгәләде дә күбеп чыккан йөзе белән тузанлы җиргә капланды.

— Җиңүче — Мәмли! — дип кычкырды тамак ярып Әгъли, Мәмли янына йөгереп килеп.

Тамаша кызуыннан кирәгеннән артык очынган, кайнарланган кешеләрне сүрелдерергә теләгәндәй, искәрмәстән сибәләп яңгыр ява башлады. Урыннарыннан кузгалып шаулашып кычкырына башлаган кешеләр чыннан да басылып калдылар. Кайберәүләр тизрәк бөркәнчекләрен, ябынчаларын башларына капларга ашыктылар, кайберәүләре калага таба йөгерде, кайберәүләр исә кызып-кызып көрәшчеләр турында, кемнең ничек көрәшүе — хаклык-хаксызлык турында бәхәсләштеләр. Ни генә булмасын, тамаша бозылды, кешеләр үзләренең мәет ашында, мәет тамашасында булуын исләренә төшерделәр, күккә карап-карап алдылар, белгән догаларын укыдылар. Күк йөзе инде ачылырлык түгел иде. Халык күпләп тарала башлады.

Барысы да таш капкага таба юнәлделәр. Иңеләй ачык капка авызыннан таш койма эченә кереп югалдылар да тар урамнардан, тыкрыклардан үз өйләренә таралдылар. Сүз өйләрдә дәвам итте. Туктарларда бүген тынлык хөкем сөрде. Күз төбе күгәргән, болай да калын ирене күбеп чыккан Зөлмәт бүген атасы йортына кайтты һәм үзенең яраткан урынына — абзар түбәсе астындагы печәнлеккә менеп ятты. Өйдә мәет чыккандагы кебек, беркем берни сөйләшмәде.

Әгълиләр өендә дә сүз әллә ни куермады. Ярышларда исә искиткеч күтәренкелек хөкем сөрде. Анда һәркем бер-берсен уздырырга тырышып сөйләште, көлде. Анда яңгыр яуганын да, кич булганын да бөтенләй диярлек сизмәделәр. Хәтта каралар шатлыктан кичке савымга чыгарга онытa язганнар. Ярый әле Ярышның хатыны исләренә төшерде.

Аларда бүген учакта ут дөрләбрәк, ялкынланыбрак янды һәм казандагы ботка да дәртләнебрәк быкырдады.

Ярышның үзенең, хатынының алдан ук әйтеп куйган нәзерләре бар иде. Кичке аш вакытында иң элек шуны искә төшерделәр. Балтачы Ярыш кызым Мәмлигә

чыкса, каравыл өенә изге Анага багышлап бер батман керешле бизәкле чүлмәк, аңа өстәп ятимнәргә бер батман арпа, ярты батман тары бирермен дигән иде. Хатыны Салия исә үз артыннан килгән карасына ирек бирермен дигән иде. Хәзер алар яңадан шуларны исләренә төшерделәр һәм кайчан, ничек туй итү турында сөйләшә башладылар. Монысы турында да алданрак инде сүз күп булган иде. Ләкин бу турыда күпме сөйләшсәң дә сүз бетмәс сыман иде һәм күпме сөйләшсәң дә күңелле генә иде. Киләчәк турында хыяллану һәрвакыт күңелле. Балтачы Ярыш белән аның чибәр хатыны Салиянең дә бу турыда сөйләшеп сүзләре бетмәде. Ярышның да, Салиянең дә туган җирләренә кайтып изге Аклантитаны күрәселәре килә иде. Бу аларның күптәнге хыялы иде. Алар Типкә би белән пир атаның да, Әмәк тарханның да шул турыда хыяллануын бик яхшы beләләр иде. Аларның сөргененә быел соңгы ел. Соңгы көннәр. Башкаладан боерык килсә, боерык белән өстәмә кешеләр дә килсә, алар теләгәндә туган җирләренә кире кайтып китә алалар. Алар инде монда да күнектеләр, үз иттеләр. Авырлык белән салган өйләре, каралтылары бар, җирләре, бакчалары, мал-туарлары бар. Аларны да ташлап китәсе килми, шулай да үлгәнче бер туган җирләрне күреп, туганнар белән аралашып килгәндә яхшы булыр иде. Алар шулай. Аларга кайда да ярый. Ярышка кайда да эш табылыр. Типкә би менә нишләр. Бөтен нәрсә шуңа терәлеп кала. Типкә би бөтенләйгә башкалага кайтып китсә, монда ул үз урынына улы Мәмлине калдырачак. Ул чагында инде Ярыш белән Салиягә туган җирне күрәсем килә дип кычытынып йөрүнең кирәге дә булмаячак. Киявең би булса, ничек тә аның янында булырга, аның таянычы булырга кирәк булачак. Яшь бигә беренче көннәрдә дә, соңыннан да Ярыш кебек балтачылар да, Ярыш кебек алып ирләр дә бик кирәк булачак.

Типкә би белән пир ата Әмәк тә шулайрак фикер йөрттеләр. Боерык килсә, билгеле, алар бер көн тормый юлга чыгачаклар. Би булып монда Мәмли калачак. Ярыш та, Әгъли дә яшь бинең иң ышанычлы кешеләре булыр дип ышандырырга кирәк. Тик менә Туктарның гына бөтен эшне бозып куюы бар. Мәмли белән Зөлмәтнең көрәше-сугышы — барысы да ил алдында, бернинди ялгансыз, хәйләсез булды. Туктарның күрәләтә каршы чыгуы мөмкин түгел. Шулай да һәркемнең бармагы үзенә таба кәкре. Шулай да Туктар аучы ышанычсыз кебек. Күн эчендәге кургашны белмәмешкә са-

лышып, улының кулына урамакчы булды. Хәйләсе ачылгач, нинди тузынды. Кем белә. Бәлки әле үзе үк котырткандыр Зөлмәтне!

Туктар шулай бераз гына эчләрен пошырып торса да, шулай да Типкә бигә дә, пир атага да ул алай ук куркыныч булып тоелмады. Туктарны яклардай кеше күп түгел. Шулай булгач аның көче аз. Тора салып башсызлык эшләмәс.

Типкә би, учак каршысына утырып, пир ата белән әкрен генә шулай сөйләшеп утырдылар, фикер алыштылар. Бүген алар үзләрендә беркайчан булмаганча тынычлык, канәгатьлек тойдылар һәм кичке ашны ашагач та йокыга киттеләр.

Төнне би тыныч йоклады. Бүген ул башка вакыттагы кебек, төнлә уянып та ятмады, йокысызлыктан интегеп, койма өстенә, капка якларына чыгып, капка каравылчыларын тикшереп тә йөрмәде. Шулай да йокы аралаш төнлә бик каты җил чыгуын, диңгез шаулавын ишетеп ятты. Ләкин бу юлы да ул нишләптер моңа әз генә дә пошынмады. Исмәгән җил түгел, шауламаган диңгез түгел дип уйлады. Икенче көнне ул тирә-яктагы ниндидер шомлы, гадәттән тыш шау-шу ишетеп уянып китте һәм тыныч кына тыңлап ятты.

## VII

Төш җитәр алдыннан койма башындагы капка сакчылары үзән ягыннан калага таба менеп килүче ниндидер җайдаклар төркеме күреп алдылар. Алар шактый күп иде һәм алар бик җилләнеп, кызулап киләләр иде. Тирә-якта калага лелегләргә каршы яу белән килерлек көч юк иде, шуңа күрә сакчылар кала капкаларын бик үк уяу сакламыйлар иде. Көтмәгәндә үзән ягыннан кораллы җайдаклар килеп чыгуы капка сакчыларында ыгы-зыгы тудырды. Ләкин җайдаклар якынрак килгәч, аларның Бакыр-тау каладан килүче Кодрәт тархан ирләре булуы беленде. Әле генә тыз-быз килгән сакчылар, үзләренең куркуларыннан көлә-көлә, тархан кешеләрен алдан ук капка ачып каршы алдылар.

— Кала яуларга килдегезме? — диделәр алар, шаяртмакчы булып, тарханга һәм аның кораллы кешеләренә.

Кодрәт тархан да, аның ирләре дә мондый шаяртуны аңлап җиткермәделәр. Алар бары мондый чакта әйтелә торган котлау сүзләре генә әйттеләр дә исәнләшүне аңлаткан кебек баш кына кактылар. Алар чын яуга

чыккан кебек, баштанаяк каты киемнәр кигәннәр, укҗәя, калга, сөңге-кылыч белән коралланганнар иде. Ерак юл килгәнгәме, капка сакчыларына алар кырыс һәм борчулы, хәтта ачулы тоелдылар. Аннан соң тархан беркайчан шулай күп көч белән йөрми иде. Бу сәер тоелды.

Атлы җайдакларның барысы да калага кермәде. Кодрәт тархан белән килгән илле ирнең күпчелеге диярлек капка алдындагы ачык урында туктап калдылар. Унлап кешесе белән тархан калага керде һәм туры би йортына юнәлде. Үзе белән тархан бер батман чамасы бакыр һәм затлы ташлар алып килгән иде. Тарханның бакырдан да, затлы ташлардан да кыйммәтлерәк, әһәмиятлерәк икенче бер нәрсәсе дә бар иде бугай. Калага ул бөтенләй яңа хәбәрләр алып килгән иде.

Би янына керер алдыннан тархан барлык коралын, авыр киемнәрен салып ишек төбендәге сикегә куйды. Аның инде яздан бирле калада булганы юк иде. Зур, авыр гәүдәле булгангамы, Бакыр таудагы эше авыр, мәшәкатьле булгангамы, Кодрәт тархан күбрәк вакытын үзенең тау башындагы каласында уздыра иде. Би янына ул бик сирәк килә — анда да кичектергесез эше-йомышы төшкәндә генә. Ләкин ничек кенә, кайчан гына килмәсен, беркайчан да ул баштанаяк коралланган кырык-илле кеше ияртеп йөрми иде. Әгәр ул шундый зур көч белән, кораллы ирләр белән килгән икән, димәк, тиккә түгел.

Типкә би, калага тархан килүен һәм аның кораллы ирләр белән килүен белгәч тә, шулайрак дип уйлады. Кодрәт тарханның нинди дә булса күңелсез хәбәр әйтүе мөмкинлеген сизеп, аның кинәт эче пошып куйды. Тарханны ул туры үзенең диңгез ягындагы иркен бүлмәсенә чакырды. Алар балтачы Ярыш сырлап, бизәп ясаган зур түгәрәк агач өстәл янына утырдылар. Ашчылар ашарга-эчәргә китерде. Тарханның сүзне туп-туры күңелсез хәбәрдән башлыйсы килмәде. Башта ул Бакыр-тау каладагы хәлләр турында сөйләде. Бакыр базында бакыр балчык казучылардан җәй көне биш кеше үлгән икән. Ашарларына да булган. Җир астыннан яңа чишмә чыккан да, шуның суын эчкәннәр. Күрәсең, агуланган булгандыр. Өч таур колы узган айда көчле яңгыр вакытында качып киткәннәр. Безнең сакчылар абайламый калганнар. Яңгырда түбә астында калганнар. Яшьләр. Чыбык белән суктырырга туры килгән. Аннан соң кемдер ашлык абзарының йозагын ватып кергән, бер чүлмәк сары майны, бер батман онны алып чыгып киткәннәр. Күрәсең, шул ук таурлардыр. Азындылар алар...

— Азындылар? — диде Типкә би, аңлап җитмичә. — Бакыр-тау калада кемнәр хуҗа соң — таурлармы, лелегләрме?

— Азындылар, би, — диде тархан, көрсенеп. — Кирәк булса дип, мин сиңа илле ир алып килдем.

— Әлегә кирәген күрмим, — диде би, тарханның тел төбен төшенмичә, — таурлар азынгач, үзеңә кирәгрәк түгелме соң кораллы ирләр?

Кодрәт тархан берни әйтмәде, бары шаулатып көрсенеп кенә куйды.

— Сез монда берни белми ятасыз икән, би, — диде ул, ниһаять, чишелә башлап.

— Сөйләп кара, — диде би, караңгы чырай белән, ләкин сөйләгәнне көтмәде, тынычсызланып урыныннан торып китте. Йөренеп килде дә яңадан урынына килеп утырды.

— Беләсеңме, бөтен эшне теге малайлар бозган, — диде Кодрәт тархан, авыр йодрыгын кая куярга белмичә.

— Нинди малайлар?! — диде би һәм «Мәмли»сүзен ишетүдән куркып аеруча сагаеп калды.

— Моннан бер ай элек син бакырга җибәргән малайлар, — диде тархан. Беләсеңме, теге... Туктар малае Зөлмәт... Марисны сөңге белән кадап үтергән.

— Кем күргән? — диде би, җиңел сулап.

— Алар өч-дүрт кеше булганнар... таурлар, — диде тархан. Зөлмәттән икмәк сорамакчы булганнар.

— Икмәк? — диде би, аңлап җитмичә. — Туктале, ул бит нидер сөйләгән иде. Икмәгем төшеп китте дә, шуны эзләргә төштем, дигән иде.

— Юк, эзләп тормаган ул, —диде Кодрәт тархан, сүзнең нәрсә турында барганын яхшы чамалаган сыман. — Тегеләр кисәктән килеп чykканнардыр. Алар бит шулай... таурлар. Бу курыккан инде. Сөңге белән кадаган. Таурлар башта каушап калганнар. Аннан соң...

— Аннан соң... Зөлмәтне эләктерәбез дип, Үтине эләктергәннәр. Шулаймы? — диде Типкә би.

— Зөлмәт качып котылган, — диде тархан. —Үти атланган атның аягын күсәк белән бәреп имгәткәннәр. Аты сөрлегеп киткән, үзе егылган.

— Шуннан?!

— Билгеле инде ничек булыры: тотып алганнар да җыйнаулашып... ашаганнар... — диде тархан, бөтенләй ят тавыш белән.

— Уф аллам! — диде Типкә би, авыр көрсенеп. Сүз таба алмыйча ул беравык тынып утырды. — Ашаган-

нар... — диде ул аннан соң, ышанасы килмичә, шикләнгән сыман. — Син шундый итеп сөйлисең — үзең карап торган кебек... Әгълигә әйтә күрмә, болай да кайгыдан кара коелып чыкты.

— Үтине күмгәнсез ич инде, барыбер түгелмени? — диде тархан, гамьсез генә.

— Барыберен барыбер дә... — диде би. — Минем дә улым бар бит. Күз алдыма китерсәм, чәчләрем үрә тора! Ничек итеп шул гадәтләрен ташлатырга аларның?! Ике аяклы, ике куллы кешеләр алар. Ә үзләре ерткыч кебек. Ташлатырга кирәк аларның бу гадәтләрен.

— Ничек итеп, — диде тархан сүлпән генә, бинең теләген уртаклашып.

— Ничек итепме? Иген иксеннәр, мал асрасыннар. Ашарларына булса, ташларлар. Мин бит ул Марисларга болай да өлеш чыгарам. Ашлык бирәм.

— Әйе, алар шуңа алданып юанып торалар иде дә, — диде тархан. —Ләкин иген иктеләрме соң алар? Юк. Мал асрадылармы? Юк. Аларның берсен калдырмый кырып бетерергә кирәк. Бүрене, аюны кырган кебек.

— Урмандагы киекне кырып бетерсә, кеше ничек яшәр соң җирдә? — диде би. — Аучы нәрсә аулар? Затлы тиреләр, йон, мамык, киезне каян алыр?

— Белмим, — диде тархан, караңгы чырай белән. — Мин бары шуны гына беләм: аларны кулга ияләштереп тә, акылга утыртып та булмый. Мин инде аларны күп күрдем. Алар кеше телен аңламыйлар, алар бары күсәк, кылыч, сөңге телен генә аңлыйлар.

— Шулай микән? — диде би, уйчан гына. — Безнең кешечә сөйләшкәнебез бар микән соң алар белән? Син, тархан, аларны күп күргәнсең, шулай да алар белән шул күсәк, йодрык телендә генә сөйләшкәнсең, ахрысы.

— Башкача булмый, — диде тархан, бинең күзенә туры карамаска тырышып. Аның бинең акыл сатарга чамалавына ачуы килә башлады. Бу турыда сүзне бетерәсе килде, ләкин шул ук вакытта сүзне җиңел генә туктатып булмаячагын да аңлады. Таурлар, кыргыйлар мәсьәләсе би белән аның арасында күптән инде бәхәсле нәрсә иде. Таурлар, тирә -яктагы кыргый кабиләләр турында сүз чыктымы, алар бер-берсен аңламыйча һәм аңларга теләмичә, хәтта тыңламыйча сәгатьләр буе бәхәсләшергә һәм бер-берсенә каты-каты сүзләр әйтергә мөмкиннәр иде. Кодрәт тархан таурлар, төрле кыргыйлар белән ныграк аралаша. Ул аларны яхшырак белә. Аңа җир казып, бакыр ташы чыгарып, бакыр эретергә

кирәк. Башкала шуны сорый. Җитмәсә, аңа һәртөрле кыргыйларны, юлбасарларны туйдырырга һәм саклап тотарга кирәк. Алар әнә йә чебен кебек кырылалар, йә качып китәләр. Тау-ташны кем актарыр да бакырны кем чыгарыр. Бигә рәхәт. Ул монда лелегләргә баш. Ул диңгез буен саклый, иген иктерә, мал асрата. Аның карамагында таурлар аз. Менә хәзер аңа кара, авыр эшкә кимендә унбиш таза ир кеше кирәк. Каян алырга аларны? Унбиш таза ир кеше, билгеле, бинең үзенә дә кирәк — аңа тизрәк кәмәсен эшләтеп бетерергә дә, башкалага сыпырырга кирәк. Менә шуңа каршы килә дә ул Типкә би аның таурлар турындагы фикеренә.

Кодрәт тархан күңеленнән шулай дип уйлады. Үпкәләгән сыман ул беравык тынып утырды. Типкә би аның нәрсә уйлавын бик яхшы аңлады. Ул да тынып калды. Хәзер аның да тархан белән сүз көрәштереп торасы килмәде. Элегрәк менә шулай таурлар турында бәхәс чыкканда, ул күршедәге таурларны, Марисны мисалга китерергә ярата торган иде. Әнә бит алар юлбасарлыкларын ташладылар — балык тоталар, мал асрыйлар, кабилә башлыклары үзен кешечә тота, дип әйтергә ярата торган иде. Болай булгач, чыннан да аныңча — Типкә бичә булып чыкмады түгелме соң? Кем аркасында? Туктар малае Зөлмәт аркасында, билгеле! Юк, моны болай гына калдырырга ярамый.

— Нишләтерсең? — диде тархан, Зөлмәт турында сүз чыккач.

— Яңадан тикшерергә дә, кирәк булса, багана башына асып куярбыз! — диде би.

— Шул Марис өченме?! — диде тархан, җирәнү белдереп, авызын кыйшайтып.

— Марисны үтергән өчен, — диде би, шактый җитди итеп. Миңа буйсынган, минем... минем кешене үтергән өчен.

Кодрәт тархан җавап кайтармады. «Әйтим микән, әйтмим микән» дип уйлады ул үзалдына, икеләнеп. «Әйтми торыйм әле» диде бераздан, билгеле бер карарга килеп. Үз-үзенә ышанган һәм һичшиксез яхшылык эшләргә тырышкан Типкә би аңа хәзер никтер кызганыч булып тоелды.

Алар төштән соң килеп чыктылар. Төньяк капка бикле түгел иде, капка сакчылары, дөньяларын онытып, түбәндә, капка тышындагы күләгәдә ашык уйнап утыралар иде. Бакыр-тау калага бара торган юл буендагы

гөлҗимеш, кыргый алмагач һәм груша куаклары арасыннан көтмәгәндә ниндидер ярым шәрә ят ирләр килеп чыкты. Алар туп-туры капкага таба килә башладылар. Кулларына шома саплы күсәкләр тотканнар, иң алдан килгән тазарак, калкурак буйлы берсенең биленә каеш буылган, каешка кынылы хәнҗәр тагылган иде.

Ашык уйнаучыларның берсе көтмәгәндә аларны күреп алды һәм сагасын кул очында тоткан килеш тынып калды. Аның кыяфәтен күреп, башкалар да ул караган якка борылып карадылар һәм үзләренә якынлашып килүче таурлар төркемен күреп тиз генә аякларына бастылар, капка эченә керделәр дә кайсы-кая ташландылар йә булмаса капка баганасына сөяп куелган коралларына тотындылар. Берсе шунда тиз арада капканы япты, шапылдатып аркылы бикне таш баганадагы ояларына кертеп куйды.

Капка сакчыларының кереп китүләрен күреп, таурлар төркеме кызулый төште. Алар йөгерә үк башладылар һәм капка биге үз урынына урнашып та өлгермәде, тышкы яктан капканың җизле тактасына күсәк белән китереп тә тондырдылар. Капка артында ыгы-зыгы килгән, ярсып кычкырган тавышлар ишетелде.

— Ач капка! Ач, би!

— Ачмасаң яндырабыз! — диделәр ярсулы таурлар, авыр күсәкләре белән капка калаен дөпелдәтеп.

Каушап, аптырап калган сакчылар агач баскычтан йөгерешеп югары менделәр, чыгып торган таш, бүрәнә кырыйларына ышыкланып, ярыклардан түбән карадылар. Болар чыннан да таурлар иде. Арада таныш йөзләр дә күренде. Танышларның берсе, башкалардан калкурагы, тазарагы Марисның бертуган энесе Нарис булырга тиеш иде.

— Кем кирәк? Нәрсә кирәк? — дип кычкырдылар капка түбәсендәге сакчылар.

Сакчыларның югарыдан килгән тавышларын ишетеп, ярсыган таурлар капка башына күтәрелеп карадылар. Кемдер таш бәрде. Таш күзәтү ярыгына килеп тиде дә ике агач арасында кысылып калды. Капка сакчысы, коты алынып, шундук читкә тайпылды — чак-чак кына артына барып төшмәде, ярый әле басма өстендәге аратага тотынып калды.

— Би кирәк! Типкә би! — дип кычкырдылар таурлар, капка сакчыларына җавап итеп.

Ул арада юл буендагы куаклар арасыннан бер-бер артлы ярым шәрә ирләр чыга тордылар, кача-поса, ялт-

йолт каранып, капкага таба якынлаша тордылар. Тышкы якта капка алдында шаулашкан, баш өстендә күсәкләрен болгаган ярсулы кыргыйлар төркеме арткannан арта барды. Ни булды боларга? Нәрсә кирәк боларга? Моны капка каравылчысы гына хәл итәрлек түгел иде. Сакчыларның берсе, яшьрәге, тиз генә би сараена йөгерде, икенчесе, яу килгәнен белдереп, чаң сугарга тотынды.

Тиз арада чаң тавышын ишетеп һәм шулай ук таурлар килүен күреп, капка янына кала кешеләре җыела башлады. Койма өстеннән башка капкалардагы, күзәтү манараларындагы кораллы сакчылар килә башлады. Әле аннан, әле моннан таурлар ягына берән-сәрән уклар очты. Кыргыйлар ягында бер-ике кеше, шәрә тәненә килеп кадалган угын тотып, җиргә егылды. Ямьсез итеп кычкырып чинаган тавышлар ишетелеп китте.

Шул ук вакытта сарай ягыннан капкага таба ашыгып килүче би, Тархан һәм пир ата күренде. Җыелган төркемне икегә аерып, алар туп-туры капкага якынайдылар. Типкә би өстенә алтын калайлар тезеп тегелгән көбәсен, башына җиңел мамыктай җиңел кош каурыйлары кадалган алтын алпагын кигән иде. Аның йөзе кырыс, тыныч һәм куркусыз иде. Ул баскычтан ашыкмыйча өскә менде, бөтен гәүдәсен күрсәтеп, койма читендәге калку урынга чыгып басты. Астан, ерактан очып килгән теләсә нинди ташны, күсәкне кире кагарга әзер булып, кулларына түгәрәк җиз калкан тотып, аның ике ягында ике таза яшь ир тынып калды. Алтынлы киемнәрен кояшта балкытып, күктән төшкән сихри зат кебек, бура читенә чыгып баскан бине күргәч, таурлар төркеме дә тынып калды.

Типкә би, шәрә беләкләрен күкрәк турысында кушырган килеш, башын югары тотып, каш астыннан гына түбәнгә карады, буйсынырга теләмәгән таур ирен күздән кичерде. Ул аңа таныш иде. Бу теге кабилә башлыгы Марисның бертуган энесе Нарис иде. Ул әле яшь, аның ачулы йөзендә, беләкләрендә төрле җәрәхәтләр, күгәргән урыннар белән тапланып беткән күкрәгендә көч-куәт һәм яшьлек ярсуы ташып тора иде.

— Улым, тезлән, — диде Типкә би, боерып, тыныч кына.

— Тезләнмим, — диде Нарис, ярсу, үч һәм нәфрәт белән үзсүзләнеп. Кулына агасы Марисның җиз белән калайланган чукмар башлы, шома саплы күсәген тоткан, муенына нечкә чылбырга тагып кеше баш сөяге асып куйган иде. Бу исә аның варис урынына кабилә

башы булуы турында әйтеп тора иде. Ул шулай «тезләнмим»сүзен әйтеп бетерүе булды, таяк сыман җиңелчә генә күсәген җирдән күтәрүе булды, шундук өстән җиз башаклы, каурый койрыклы кызыл ук килеп төште. Көч белән атылып җибәрелгән ук чыңлап үҗәт таурның каршысына, каты җиргә бәреп керде, каурыйлы койрыгы калтырап, селкенеп торды да тынып калды. Кыю, ярсу таурның йөзендә шундук курку чагылып китте, ирексездән ул чак-чак кына артына чигенде, борылып карады, каядыр качып китмәкче булды, ләкин үзе янындагы барлык ирләрнең башларын җиргә сузып, йөзтүбән тезләнеп торуларын күреп, ыңгырашуга охшаш бер өн чыгарды да шулай ук җиргә егылды.

Типкә би сүзсез генә барысын да югарыдан күзәтеп торды. Тирә-як тып-тын булып калды.

— Тор, сөйлә, улым, ни булды, ни кирәк? — диде ул, ниһаять, илаһи бер мәрхәмәтлек белән.

Нарис тузанлы җирдән аягына басты, яңадан күсәгенә тотынды, бер-ике адым алгарак атлады. Башкалар да аякларына бастылар.

— Зөлмәт кирәк! — дип кычкырды Нарис, яңадан баягыча ярсып һәм оятсызланып.

— Арпа, сыра кирәкме әллә дип уйлаган идем мин, — диде Типкә би Зөлмәт сүзен ишетүгә әз генә дә гаҗәпләнмичә.

— Арпа да, сыра да кирәк, — диделәр Нарис артындагылар, шаулашып.

— Минем кешеләр сезгә арпа да, сыра да алып бардылар. Баргач сезне тапмый кайттылар. Кая киттегез? — диде Типкә би, шелтә белән.

Таурлар, гаепле сыман, күзләрен читкә бордылар.

— Зөлмәт минем агам Марисны үтерде. Син безгә башта Зөлмәтне бир! — диде Нарис, яңадан ярсый башлап.

— Кем күрде Зөлмәтнең Марисны үтергәнен? — диде би, бик нык гаҗәпләнгән сыман.

— Мин күрдем! — диде беренче булып Нарис.

— Мин дә күрдем!

— Мин дә! — диделәр тагын бер-ике таур ире.

— Алайса, минем улым Үтине сез ашадыгызмыни?! — диде Типкә би, әкрен генә дәһшәтле итеп.

Яңадан кыза, ярсый башлаган таурлар кинәт шып булдылар. Әле генә кукраеп, күкрәк киереп, мин дип торган яшь ирләр, куркышып, бер-берсенә карашып алдылар. Таурлар арасында ыгы-зыгы башланды. Читтәрәк, кырыйдарак торганнар тизрәк табан ялтырату

ягын карадылар. Капка сакчылары качучыларны мыскыллап көләргә, кычкырырга, сызгырырга тотындылар. Арада хәтта таурлар артыннан уклар очты. Элек тә мондый гына бәрелешләр булганы бар иде. Типкә би качучыларга ук-сөңге атмаска боерган иде. Берни белән сакланмаган шәрә аркага арттан ук атып калуда әллә ни батырлык юк дип уйлый иде ул. Аннан соң Күлле таба Марис-Нарис таурларын кырып бетерүдән аңа бернинди файда юк иде. Элек тә шулай өркетеп җибәргәч, алар икенче көнне үк калага киләләр һәм бөтенләй юашланып, буйсыну белдереп киләләр иде. Типкә би шундук ук атучылар ягына борылып карады һәм ачу белән бар көченә:

— Атмаска! — дип кычкырып җибәрде.

Ләкин атылган укларны кире кайтарып, аннан да бигрәк, ук тиеп, җирдә егылып калган ирләрне яңадан тергезеп булмый иде. Качып баручы таурлар артыннан ук атучылар исә Кодрәт тархан ирләре булып чыкты.

— Кем чакырды сезне монда? — диде Типкә би, ачу белән. — Ник аттыгыз?

— Аларга шул гына кирәк тә! — диде тархан ирләренең берсе, авызын ерып, бинең сүзләрен колагына да элмичә.

Таурлар качыша башлау белән, кинәт аста капка ачылып китте. Капкадан кораллы сакчылар һәм тархан ирләре бәреп чыкты. Аларның күбесе җәяүле иде, ләкин арада берничәсе атка атланырга өлгергән иде. Яхшы коралланган кала ирләре һай-һаулап, кычкырып таурларны куа киттеләр. Таурлар исә артларына борылып та карамыйча, бар көчләренә куаклар ягына элдерделәр. Алданрак йөгергәннәрнең кайберләре куаклар арасына кереп тиз арада юкка чыктылар, кайберләре, читкә тайпылып, текә яр астына ташландылар. Унлап кешене исә тархан ирләре бүлеп алдылар. Бүленгән ирләр, күсәкләре белән селтәнеп, үзләренең өстенә килгән ат башларын ярдылар, кала ирләренең кулларындагы калканнарын, сөңгеләрен бәреп төшерделәр. Күсәксез, коралсыз калган кайбер башсызраклары, тартып алмакчы булып, үзләренә таба төбәлгән сөңгеләргә таба сикерделәр. Тархан ирләре таурларны ничек тә тере килеш алырга тырыштылар, шуңа күрә сөңге-кылычларын бик үк эшкә җикмәделәр. Элмәкле арканнары булганнар исә шундук табышлы булдылар. Төрле яктан чолгап алгач һәм боҗраны кысканнан кыса баргач, кыргыйлар каршылык күрсәтүдән туктап калдылар һәм аларны әтә-төртә,

кыйный-кыйный, шау-шу китереп, кала капкага таба куып киттеләр.

Бу ничектер бик тиз арада булды. Типкә би барысын да бура өстендә карап, күзәтеп торды. Беренче мизгелдә ул каушап-аптырап калды. Таурларның шулай ябырылып килүенә дә, мондый көтелмәгән сугышка да ул бөтенләй әзер түгел иде.

Башбаштаклык, капканың сораусыз-нисез ачылып китүе, тархан ирләренең сораусыз-нисез таурларга каршы ташлануы аны кинәт ярсытып җибәрде, аны кинәт йокысыннан уяткандай булды. Шулай да ачуын тыярга тырышып ул басмадан аскарак төште, Кодрәт тарханны күрмәкче булып як-ягына каранып алды. Ул аны тиз генә күрә алмады. Баксаң, ул якында гына торган икән. Кемнедер эзләвен күреп, Кодрәт тархан үзе аның янына килде.

— Менә җир казучылар да, качкыннар да кире кайтты. Качкыннарны тоттык! — диде Кодрәт тархан, үзүзеннән канәгать булып, таурлар төркеменә күрсәтеп.

— Капканы кем ачты? — диде Типкә би, Кодрәтнең канәгать йөзен утлы күз карашы белән өтеп. Аңа никтер капканы Кодрәт тархан үзе килеп ачкандыр сыман тоелган иде.

Бинең бозылган ачулы күз карашын күреп, Кодрәтнең дә кыяфәте үзгәреп китте.

— Мин түгел, би, — диде ул, мыскыл сизелеп торган бер корылык белән.

Типкә би ярсып капка сакчылары ягына борылды.

— Капканы кем ачты? — дип кычкырды ул бар көченә.

Капка сакчылары да, башкалар да тынып калдылар.

— Кем кизү торды? — дип кычкырды би.

Арадан кысылып, башларын түбән иеп ике ир килеп чыкты. Аларның икесе дә яшьләр, икесе дә, күрәсең, әле генә таурлар артыннан чабып йөреп тирләп төшкәннәр, кызарынганнар, шуңа күрә еш-еш тын алалар иде. Болар капкага аркылы салына торган авыр бик өчен җаваплы сакчылар иде. Алар ашыгып килделәр дә би алдына тезләнделәр.

— Кем ачты капканы? — диде би, бер үк сорауны кабатлап, тыела алмыйча.

— Мин, — диде, ниһаять, ирләрнең берсе, чак-чак кына башын калкытып.

Озын буйлы, киң җилкәле егерме яшьләр чамасында бик чибәр егет иде бу. Аның матур булып мыегы чыгып

килә, үрелгән кара чәчләре салынып тора. Бу әле чын яуда да булмаган — үлемнең күзенә дә карамаган иде. Аның, күрәсең, үлемнең нинди булганлыгын күрәсе килгәндер.

— Тор! — диде би, әкрен генә.

Егет бик авырлык белән аягына басты һәм үзенең гаебен аңламаган кебек, үпкәләгән сыман, бинең күзләренә сынаулы караш ташлады.

— Коралларыңны сал, — диде би, боерып.

— Ник? — диде егет, аңламыйча.

— Сал! — дип кычкырды кинәт ярсып Типкә би.

Шуннан соң ул тиз генә тархан ягына борылып карады.

— Тархан! — диде ул. — Яуга капка ачып без бик зур хата ясадык. Капка ачылганда, мин бура өстендә, син читтә калдың. Сакчы үз белдеге белән капканы ачып...

— Үз белдегем белән түгел, — диде гаепле егет, акланмакчы булып.

— Алайса, кем кушты сиңа? — диде би, егеткә борылып.

— Бакыр таунысылар! — диде егет. — Безгә эшче кирәк, диделәр. Качканнар урынына яшь таурлар кирәк, диделәр.

— Аңлашылды, — диде би. Шуннан соң ул тарханга борылып карады һәм барысына да ишетелерлек итеп: — Тархан! Ирләр! — диде би. Әле генә без зур хата ясадык. Безгә үзләренең гозерләрен әйтергә, безнең белән аңлашырга-сөйләшергә килгән таурларга каршы корал күтәрдек. Таурлар безнең күршеләребез. Таллы таба күл үзәне таурлары безнең белешләр, дуслар. Без алар белән моңарчы дус-тату яшәдек, моннан соң да тату булыйк. Әлеге хатамны төзәтү юлыннан мин тотып алынган таурларның барысын да кире чыгарып җибәрергә боерам.

Шулай дигәч ул җыелган төркемгә күтәрелеп карады. Ирләр беравык тынып тордылар да әкрен генә, ризасызлык белдереп, гүелдәргә, шаулашырга тотындылар. Тархан Кодрәтнең йөзе караңгыланып китте. Ил алдында бигә каршы сөйләргә ярамаганлыгын белсә дә, беренче булып ул сүз башлады.

— Эләккән балыкны кире диңгезгә җибәрмиләр, — диде ул.

— Юк, тархан, кайчагында җибәрәләр, — диде би, нык итеп, каршы эндәшергә урын калдырмыйча.

— Миңа эшчеләр кирәк, би, — диде Кодрәт тархан, беркемгә дә карамыйча.

— Әнә сиңа ике эшче, — диде би, коралларын салып, башларын иеп торган капка сакчыларына күрсәтеп.

Шулай да Кодрәт тархан би белән бәхәсләшеп тормады һәм үзенең ирләренә тотылган таурларны кире чыгарып җибәрергә боерды. Тархан ирләре теләр-теләмәс кенә тоткыннарның бауларын чишә башладылар. Капканы яңадан ачтылар һәм котылуларына ышанып җитмәгән, куркынган яралы таурлар, як-якларына карана-карана, ачык капкадан чыга башладылар. Каланыкылар алар артыннан көлеп, кычкырып-сызгырып калдылар.

Иң арттан Нарис чыкты — тоткыннар арасында ул да бар иде. Ул барысын да күреп-ишетеп торды. Үзләрен би коткарганын ул яхшы аңлады. Шулай да аның яныннан узганда аңа борылып карамаска тырышты.

Би аны туктатты да, шелтәләп:

— Менә, күрдеңме, улым, синең белексезлегең аркасында... — дип сүз башлаган иде, яшь Нарис аңа ачулы итеп карап алды.

— Юк, минем аркада түгел, би! — диде ул. — Сезнең Зөлмәт аркасында!

«Дөрес әйтә бит ул!» дип уйлады би, үзалдына. Ләкин бу турыда кычкырып әйтә алмады. Башын югары тотарга тырышып, яшь кабилә башлыгы капкадан чыгып китте һәм үзен көтеп торган яшь ирләр төркеменә барып кушылды. «Йөгерерләр микән» дип уйлады би, ачык капка аша таурларны күзәтеп. Алдан чыккан таурларның күбесе инде күптән йөгереп китеп барган иде. Ләкин болары — арткарак калганнары, ничек тә үзләрен дәрәҗәле тотарга тырыштылар һәм адымнарын әз генә дә кызуламадылар, артларына да борылып карамадылар.

«Иртәгә ашлык илтеп бирергә кирәк» дип уйлады би, алар артыннан карап калып.

Төн уртасы узып, беренче әтәчләр кычкыргач, калада ниндидер ыгы-зыгы купты. Өзек-өзек тавышлар ишетелде, шыгырдап ишекләр ачылды, шак-шок басып кемнәрдер каядыр йөгереп уздылар. Бераздан капка ягында, манараларда шомлы итеп чаң суга башладылар. Озын колга башында утлар чайкалды. Типкә би шау-шу ишетеп уянган һәм ашык-пошык өс киемнәрен киеп ята иде. Шул чакны тыны бетеп аның янына төнге кизү килеп керде.

— Күпер яна, кәмә яна! — дип кычкырды ул, коты алынып.

Би аңа каршы берни эндәшмәде, сөяп куйган җиреннән җиз хәнҗәрен, сөңгесен алды да бара-барышлый

бил каешын рәтләп ишеккә юнәлде. Яшь ирләр ике ягыннан аның юлын яктыртып бардылар. Тиз арада бигә атланырга ат китереп бирделәр. Атка атланган берничә кораллы атлы аңа сарай алдында зәйтүн куагы янында көтеп торалар иде. Алар ашыгып олы капкага таба юнәлделәр. Капка сакчылары шул ук сүзне әйттеләр: күпер ягында ут күренә, кычкырган тавышлар ишетелә, диделәр.

Кәмә күпере махсус сакчылар белән сакланылмый иде. Балтачылар, кизүгә бүленеп, алмаш-тилмәш шунда төн куналар — бөтен сак менә шул иде. Балта-пычкыдан һәм башка эш коралларыннан башка аларның тагын сугыш кораллары да бар иде. Ләкин алар, көне буе арып эшләгәнгә, кичкелекне ашагач та, караңгы төшү белән урынга авалар. Төне буе уяу булырга тиешле кизү дә, гадәттә, сөңгесен кочаклап, берәр почмакта йокы симертә иде.

Кичәгенәк таурлар белән булган бәрелештән соң Типкә би капка ябылыр алдыннан балтачылар янына барып кайтты. Таурларны озаткач, бик озак аның эче пошты. Ул үзендә ниндидер бер икеләнү һәм ризасызлык тойды. Ул тумыштан сугышчы иде. Үзенә каршы корал күтәреп яисә корал күтәрергә мөмкин булган теләсә кемгә каршы ничек, нәрсә белән җавап бирергә, кайчан ничек сугышырга — ул инде боларын үзләштергән иде. Тик менә кичәге таурлар сыман аңсыз, кыргый һәм бөтенләй диярлек чын коралы булмаган сабый сыман ирләргә каршы нишләргә кирәген аның әлегәчә үзләштереп җиткергәне юк. Аныңча җиз корал белән коралланган чын ир күсәк белән коралланган иргә каршы сугышырга тиеш түгел иде. Көчләр монда күрәләтә тигез түгел. Өстендә иләнмәгән иң яхшы болан тиресе йә булмаса ярым шәрә һәм кулында бер күсәге булган батырның корсагын төртеп тишүдән әллә ни ләззәт, канәгатьләнү алып булмый, әлбәттә.

Балтачылар янында ул озак тормады — ансын-монсын карады да калага кайтып китте. Таурлар белән булган бәрелешне балтачылар белә иде. Ләкин әйтерсең алар да, би кебек үк, әлеге сугышка артык игътибар итмәделәр һәм беркемнең дә ул турыда сүз куертасы килмәде. Күрәсең, таурларга карата булган шундый карашка бирелеп, би дә төнге кизүләрне кисәтергә, уяу һәм сак булырга кирәклек турында әйтергә онытты.

Алар, бинең кисәткәнен көтеп тормастан, болай да уяу һәм сак булырга тиешләр иде. Ләкин алдырыр көн яздырыр дигәндәй, алар көндәгечә йокы симерткәннәр.

Таурлар ничектер сиздермичә килеп, күпернең берничә җиренә ут салганнар. Борыннарына төтен исе килеп, күпердәгеләр, кәмәдәгеләр уянып киткәндә, күпернең әле бер төшендә, әле икенче төшендә ут күренә. Ирләр шундук сикерешеп урыннарыннан торалар, кайсы-кая чабыша башлый. Берәүләр ут үзлегеннән чыккан дип уйлый һәм су белән, ком белән ут сүндерергә тотына. Икенчеләр якын-тирәдә шаулашкан таурларны күреп алалар, коралларына тотыналар. Читтән балтачыларга таш, күсәк, таяк ыргыталар. Күпердә ыгы-зыгы, шау-шу куба, җиз калайга сугып бөтен тирә-якка чаң кага башлыйлар.

Күпердәгеләр белән таурлар арасында сугыш-бәрелеш кызган чакта кала ягыннан ашыгып коралды ирләр килеп җитте. Аларның беркадәре атлы, күпчелеге җәяүле иде. Таурлар каладан килүчеләрне күреп алдылар, качыша башладылар һәм елга яр астына төшеп юкка да чыктылар. Атлылар качакларны эзәрлекләп китте, җәяүле ирләр ут сүндерергә тотындылар. Ыгы-зыгы таңга кадәр барды.

Күпергә, бигрәк тә кәмәгә әллә ни зыян килмәгән иде. Шулай да монда әле эш көне буена җитәрлек иде. Каланыкылардан үлүче-нитүче булмады, бары тик берике кешенең кулы-аягы гына имгәнгән иде. Аның урынына җирдә төнлә кемдер хәнҗәр ыргытып үтерелгән ике таур гәүдәсе табылды. Аларны би куркыту өчен таурлар килә торган якка асып куярга боерды.

Төшкә кадәр балтачылар күпернең янган, ауган баганалары урынына терәүләр куйдылар, астан янып тишелгән, ишелгән басмаларны, баскычларны алыштырдылар. Төш вакытларында төньяк таулар ягыннан, ачык калкулык итәгеннән йөгереп, ашыгып, бик күп җәяүле кешеләр килгәне күренде. Болар шул ук таурлар иде.

Балтачылар шундук чаң суга башладылар, төтен чыгарып каладагыларга хәбәр бирү өчен җир өстендәге чүп-чар, йомычка өеменә ут төрттеләр. Ирләр тиз арада катырак киемнәрен киделәр, сугыш коралларын алдылар. Таурларны, күрәсең, каладагылар да күреп алды — күп тә үтмәде, ул яктан ашыгып килүче атлы чиру күренде. Атлылар ашыгып таурлар төркеменә каршы китте.

Атлы сугышчыларны күрү белән элегрәк таурлар куркып шундук качыша, табан ялтырату ягын карыйлар иде. Бу юлы алай булмады. Атлыларны алар бик кыю каршыладылар. Үзләре белән билләренә аскан нин-

дидер капларга, капчыкларга тутырып төрле зурлыктагы ташлар, очлы агач тамырлары алып килгәннәр иде. Атлы, кораллы, җиз киемле ирләргә алар таш ыргыттылар, күсәкләр, ботак-сатаклы агач тамырлары ыргыттылар. Кызып, ярсып килгән атлылар төркемендә әле берсе, әле икенчесе кычкырып җибәрде — таш тиеп берсенең кулы өнсез калды, икенче берсе күзенә тотынды. Кайберәүләрнең атлары яраланды һәм алар кызганыч тавыш белән чинап-кешнәп арт аякларына бастылар, тыпырчына башладылар. Би ирләрен ярсу биләп алды. Таурлар ягына шундук сөңгеләр очты, выжылдап уклар очты. Кыюланып үтә якын килгән, хәтта башсызланып ат өстендәге ирләргә килеп тотынган таурларны хәнҗәр белән турадылар.

Ярсыган, кычкырышкан ярым шәрә һәм таркау кыргыйлар калкулык буенда бик күп үлекләр калдырып, ниһаять, чигенергә мәҗбүр булдылар. Ләкин чигенгәндә дә алар шактый нык каршылык күрсәттеләр һәм туктаусыз лелегләр ягына таш, күсәк, таяк ыргыттылар.

Типкә би турыдан-туры сугышта катнашмады, ул арттарак күзәтеп кенә торды. Шул чакны ул кыргыйлар ягында үзенә атап кычкырган тавышлар ишетеп алды.

— Би, Зөлмәтне бир! — дип кычкырды яшь Нарис, баш өстендә озын күсәген селтәп.

Зөлмәтнең атасы Туктар сугышның иң үзәгендә сугыша иде. Күрәсең, ул да Нарисның сүзләрен ишетеп алды.

— Бирермен әле мин сиңа Зөлмәтне! — диде ул Нариска янап һәм юан саплы сөңгесе белән уңга-сулга селтәнеп, як-ягындагы таурларны ырып-ерып туп-туры Нариска таба ташланды. Ләкин төрле яктан таурлар аның юлына аркылы төштеләр, берсе кизәнеп Туктарның атына тондырды. Чукмарлы күсәк атның күкрәгенә килеп тиде. Икенчесе күсәкне Туктарның үзенә төбәп җибәргән иде. Туктар янга авышып калды. Ачулы Туктар оста аучы Нарисны ерактан сөңге белән алмакчы булды, сөңгене ул орды, ләкин очып барган сөңгене таурларның берсе күсәге белән сугып читкә җибәрде. Яшь таурның мондый өлгерлегенә исләре киткән кыргыйлар барысы берьюлы кычкырып җибәрделәр. Нарис шаркылдап көләргә тотынды.

Сөңгесез калган Туктар кабаланып сул ягына тотынды — аның да кыргыйларныкы сыман чукмар башлы зур күсәге бар иде һәм ул аны еш кына ауга да, сугышка да алып бара иде. Ләкин сугыш ыгы-зыгысында кем-

дер сиздермичә генә аның каешын кисеп кистәнен алып киткән иде. Аның борылып эзләнүен күреп, Нарис тагын тантана белән шаркылдарга тотынды.

— Менә ул, менә! — диде яшь батыр бәхетле таур кулындагы Туктар кистәнен күрсәтеп.

Аучы Туктар «ах» итеп җибәрде һәм ярсып туп-туры Нариска таба томырылды. Бу юлы аның юлына аркылы төшүчеләр булмады. Коралдан түгел, аның усал йөзеннән, кан баскан күзләреннән куркып, тирә-якка сибелеп беттеләр. Таурлар урман-таулар ягына кире чигенделәр.

Типкә би ирләре таурларны төньяктагы Куш-тау дигән җиргә кадәр куалап бардылар. Түбәләрендә шәрә ташлар тырпаеп утырган, итәкләре исә куе яшел урман белән капланган, бер ук биеклегендәге ике калкулыкны шулай Куш-тау дип атыйлар иде. Куш-тауга кадәрге җирләр — таулар, үзәннәр, болыннар — каланыкы, Куш-таудан соң таурларныкы исәпләнелә. Куш-тауга кадәр тирә-як ачык иде. Тәбәнәк калкулыкларда һәм шулай ук калкулыклар арасындагы тигез җирләрдә яшеренеп калырлык, качып торырлык бернинди урман да, куаклыклар да юк иде. Монда кая карама кала кешеләренең иген басулары, яшелчә, җимеш бакчалары җәелеп ята иде. Качаклар әле тар юллардан, әле ызан буйлатып, әле басу өстеннән элдерделәр генә. Куучылар бик күп таурларны кырып, чәнчеп, чабып үтерделәр. Шулай да таурларның кайберләре берәр ызан артына яисә берәр таш артына качып калдылар, кайберәүләр йөгереп, атлы куучылар өчен уңайсызрак булган чакыр-чокырлы, куаклы җирләргә борылып йөгереп китеп бардылар.

Үз коралын дошман кулында күрү Туктарның җен ачуларын чыгарды. Ул куучыларның барысыннан алгарак ыргылып чыкты. Аның ничек тә Нарисны тере килеш кулга төшерәсе килде. Кайчагында ул шулай берәр киекне бик озак куып алҗыта да, киекне куып җитә дә, бар көченә киек өстенә сикерә һәм аны шәрә куллары белән буып үтерә торган иде. Хәзер дә аның Нарисны шулай алҗытасы, куып җитәсе һәм өстенә сикереп бар көченә кочагына аласы килде. Җиңү шатлыгы бары шунда гына тулы булачак сыман иде.

Ләкин Нарис та алай җиңел генә тоттырырга ашыкмады. Ул Туктарның үзен куа килүен һәм, һичшиксез, тере килеш алырга чамалавын бик яхшы аңлады. Ул әледән-әле артына борылып карады, кинәт кенә читкә,

кырыйга борылды һәм бөтенләй икенче яктан йөгерә башлады. Аннан да бигрәк, аның яныннан өч-дүрт таур ире йөгерде. Нарис кебек үк алар да яшьләр, озын буйлылар һәм тазалар иде. Аларны, әйтерсең ат түгел, эт тә куып җитәрлек түгел иде. Урылган яисә сөрелгән иген кырлары беткәч Куш-тауга таба бер чакрым чамасы буш җир сузыла. Корыган каты үлән белән капланган буш, тигез җир сөзәк кенә булып тауга таба күтәрелә бара иде. Үргә йөгергәндә таурлар әкренәячәкләр һәм менә шунда аларны куып җитәргә булачак. Туктар күңеленнән менә шулайрак дип уйлады, алай-болай кирәк булса дип ул кынысыннан хәнҗәрен суырып чыгарды, хәнҗәрнең сабын тешенә кысып капты да, йодрыкларын йомарлап, атның тезгенен бушайтып җибәрде. Бик тиз арада ул таурларны куып җитә башлады. Таурлар янә артларына борылып карадылар. Хәзер аларның эшләре шәптән түгел иде. Моны алар үзләре дә бик яхшы аңладылар, ахрысы, һәм алар, үзара киңәшләшкән кебек, бер-берсенә елыша төштеләр. Менә шул чагында куып җитеп, барысын берьюлы басып алырга иде дә бит, юк, булмады, бөтен гомерләрен таулар арасында үткәргән һәм балачактан ук туктаусыз йөгерергә күнеккән яшь таурлар әз генә дә адымнарын әкренәйтмәделәр. Шулай да, никадәр генә йөгерешче булмасыннар, алар белән ара торган саен кысыла барды. Шул чакны бер төркем булып оешкан таур ирләре кинәт як-якка сибелделәр. Юнәлешләрен үзгәртмичә шулай җыйнаулашып йөгерүләре дә, бергә тупланулары да, аларның бары бер хәйлә генә булуын Туктар бик соңлап аңлады. Аңлавын аңлады, ләкин бу вакытта инде ул төрле якка таралган качакларның кайсы артыннан куарга да белмичә аптырабрак калды. Нарисны күзләп уңга-сулга караган арада кинәт аның сул ягыннан чукмар башлы, җиз калай белән ныгытылган шома саплы күсәк очып килгәне чагылып калды. Күсәк туп-туры атның башына килеп тиде. Ат кисәк чинап кычкырып җибәрде, яралы башын бик каты чайкап сөрлегеп китте һәм бөтенесен алдан исәпләп, киеренкелектә барган аучы бар көченә мәтәлеп җиргә кадалды.

Ул бик озак исенә-акылына килә алмый ятты. Күзләрен ачып караганда аның сөекле аты, дүрт аягын сузып, әледән-әле хәлсез генә тыпырчынып, җирдә чалкан ята. Аның янында ирләр, атлар туктап калган, барысы да борчылып аңа карап торалар иде.

— Тоттыгызмы? — диде ул, беренче сүзе итеп.

— Юк, — диде Типкә би, теләр-теләмәс кенә

—Эх!.. дип куйды аучы Туктар, көрсенеп. — Шундый шәп киекне кулдан ычкындырдым.

— Исән калгансың — шунсына сөен, — диде би, Туктарны юатып.

— Үзләрен дә әз кырмадык, акыл булыр — моннан соң килмәсләр, — дип куйды шунда кемдер.

Башкалар җавап бирмәде.

Ләкин алар барыбер килделәр. Икенче көнне үк түгел, берничә көннән соң, инде бетте, тынычландылар дип уйлаганда, бөтенләй көтмәгәндә, бик күп булып, ябырылып килделәр.

Икенче көнне исә диңгездә давыл купты.

## VIII

Чибәр апа Лүчнәнең ир бала табуы турындагы хәбәр тиз арада турага, турадан үзәнгә таралды. Тини бәкнең асабалы булуына тура халкы чын күңелдән куаныч белдерде. Куанмыйча! Ир бала туса, илгә бәрәкәт килә, кыз бала туса, яу чыга. Борынгылар белми әйтмәгән. Ир бала илнең терәге! Ул көнне көллесенең телендә чибәр апа Лүчнә дә Тини бәк булды. Дөньяга яңа туган яшьне, булачак алып ирне әлегә телгә алмадылар. Ни өчен дигәндә, әлегә аның исеме юк иде.

Ул көнне күрше-күлән күчтәнәч итеп чибәр апа Лүчнәгә җылы аш китерделәр, тәмле-тәмле җимешләр китерделәр. Ләкин әле беркемне дә авырдан котылган ана янына кертмәделәр. Күрше-күлән, китергән күчтәнәчләрен ишек төбендәге тәбәнәк өстәлгә куйдылар да, тиз генә чыгып китүне уңайсыз санап, чибәр апа Лүчнәнең хәлен сораштырдылар, тегесен-монысын киңәш иттеләр, кайбер телчәнрәкләр, өлкәнрәкләр исә, чишелеп китеп, үзләренең дә яшьрәк чакларын искә төшерергә тотындылар. Аларның тавышы ябык ишек аша да ишетелә башлагач, Лүчнә янында утырган кендек әбисе Хасия апа ипләп кенә урыныннан торды, ишек янына килеп, хатыннарга теге якка кул селтәде. Телчән хатынннар тынып калдылар һәм, аяк очларына гына басып, тизрәк чыгу ягына ашыктылар.

Күрер күзгә малай таза һәм арыслан баласыдай усал күренә иде, ләкин кендек әби чамалаганча, чибәр апа Лүчнәнең хәле ничектер икеле-микеле иде. Әлегә ул ашамады да, эчмәде дә. Әлегә ул берни белән кызыксынмаган сыман, күзен йомып, йокылы-уяулы килеш ята бир-

де. Кайчагында күзен ачып түшәмгә йә тәрәзәгә карап алды, хәлсез кулы белән янындагы тере төенчеген капшап, онытылып китте. Кайчагында кендек әбисенә борылып карады, авызын ачып, иреннәрен кыймылдатты, нидер әйтмәкче булды, әйтә алмады.

Лүчнә яшь иде, таза, көчле иде. Аннан соң яңа ай башланганга әле ике-өч кенә көн узган иде. Шунлыктан баланы ул авыр тапмады. Болай караганда аның хәлен начар дип әйтеп тә булмый иде. Кендек әбисе моны яхшы белде. Ләкин монда ул белмәгән тагын нидер бар иде бугай. Ни генә булмасын, кендек әбисе күңелен төшермәде.

Тини бәк өйдә юк иде. Өченче көн ул таулар ягына ауга китте. Китәр алдыннан бикә янына керде. Чибәр апа Лүчнә берни булмагандай каба төбендә җеп җегерләп утыра иде. Ире аның чамадан тыш авырайган тәненә, ябык, җитез бармакларына һәм бик нык суырылып калган сөйкемле йөзенә сынабрак карап торгандай итте дә, китәргә рөхсәт сораган кебек:

— Җир асты юлын ике буй казып төшкәч, бер-ике көнгә ауга барып кайтырмын дигән сүзем барые,— диде.— Син каршы килмәсәң...

Ул шулай дигәндә, бикәнең чандыр йөзенә нишләптер кызыллык йөгерде һәм тигез хәрәкәтләнә торган бармаклары ялгышып, тоткарланып алгандай булды.

— Бар, бар, миңа карама! — диде чибәр апа Лүчнә, ашыгып. Алай әйткән сүзең дә булгач... Без әле ашыкмабыз, без сине көтеп торырбыз...

Алар янында бу вакытта кендек әбисе Хасия апа да бар иде. «Без»дигәндә чибәр апа Лүчнә кендек әбисен түгел, бәлки үзен һәм булачак икенче берәүне күз алдында тотып әйтте.

Тини бәк моны шулай дип аңлады һәм, елмаеп, уенынчынын бергә кушып:

— Мин улыма яшь болан алып кайтырмын! — диде.

— Шулай да озаклама, улым, — диде кендек әбисе, Тини бәк ишеккә борылгач. — Янында ире булса, ана баладан җиңелрәк котыла.

— Озакламам, Хасия апа, — диде Тини бәк.

Чибәр апа Лүчнәдән күзен алмыйча, аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп, һәрбер тын алуына колак салып утырган кендек әбисе Хасия апа әлеге шул сөйләшүне исенә төшерде. «Ирен көтә, исән-сау кайтып кына җитсен инде», — дип уйлады ул, билгеле бер нәтиҗәгә килеп.

Бала таң алдыннан туды. Ата кешегә куанычлы хәбәр

әйтергә дип шундук Куш-тау ягына өч кеше җибәрелде. Икенче көнне кичкә таба ашыгып Тини бәк турага кайтып төште. Киткәндә вәгъдә иткәнчә ул болан түгел, арыслан атып кайткан иде. Ул көнне Яңа турада куанычның чиге-чамасы булмады. Таулар ягыннан зур байлык белән кайтып килүче батыр аучыны, бәхетле атаны каршыларга бөтен тура халкы чыкты. Барысы да Тини бәккә мактау, котлау сүзләре әйттеләр, киләчәктә озын гомер, бәхет-куаныч теләделәр. Тау астында, капка артындагы болында, төн урталарына кадәр яшьләрнең күңелле уен-көлкесе, җыры ишетелеп торды. Урамнарда чыртлап янган утлар күтәреп кешеләр йөргәне күренде. Бәхетле ата, күңеле нечкәреп, караларга өч көнлек ял бирде, үз өендәге бер колга ирек бирде.

Ире кайткач, чибәр апа Лүчнә җанланып китте — күзен дә ачты, елмайгандай итте һәм әкренләп ашыйэчә башлады. Тик шулай да бу әле чын-чынлап җанлану түгел иде. Көннән-көн хәле яхшыга таба барса да, әле булса ул үзен чын-чынлап бәхетле итеп авыр йөктән, котылгысыз бурычтан арынган һәм җиңеләеп калган итеп сизми иде сыман. Әле булса аның күңелен нидер борчый, нидер кимерә иде, ахрысы. Ләкин нәрсә? Кендек әбисе никадәр сизгер, никадәр кызыксынучан булмасын, берни белә алмады.

Урыныннан торып, элеккечә ашый-эчә, йөри башлагач, савыгып һәм тән җиңеллеге, күңел җиңеллеге тоя башлагач, чибәр апа Лүчнә Хасия апа янына үзе барды. Хасия апа бөтен турада иң йомшак куллы, йомшак күңелле кендек әбисе булуы өстенә, иң оста имче дә иде. Турада, үзәндә бер генә бала да Хасия апа булышлыгыннан башка дөньяга килә алмаган кебек, бер генә хатын-кыз да үзенең яшерен серен, яшерен авыруын Хасия апага әйтмичә, белгертмичә кала алмый иде.

Хасия апа Тини бәкнең таш сараеннан якында гына, калку, ачык урынга урнашкан куышта ялгыз башы яшәп ята иде. Аның кәмәче ире моннан биш-алты ел элек бу дөньядан теге дөньяга күчкән. Туган бер балалары үлеп торганлыктан, балалары булмаган. Шуңа күрә картаймыш көнендә Хасия апа менә шулай ялгыз башы торып калган. Талдан, камыштан үреп, кызыл балчык белән сылаган куышында кунарга туры килгәндә гадәтенчә ул өй эшләре белән шөгыльләнә, чүлмәк белән чишмәгә суга барып килә һәм әз генә буш вакыты булдымы, кул тегермәне белән он тарта. Оның булса, суың булса, аннан соң учагыңда өзлексез ут янып торса, бу дөньяда

бер кайгың булмый. Аның кәмәче Гайнулы давылда диңгезгә батып үлде. Куыштан, ачык тау башыннан аяз көнне, тыныч көнне зәңгәрләнеп диңгез күренә. Ахырга барып тоташкан һәм чиксезлеккә кереп югалган диңгезне күрдеме, Хасия апа үзенең Гайнулын күргәндәй була һәм шул чагында алар сүзсез генә аның белән сөйләшә-аңлаша башлыйлар сыман.

Бер кулына ак биләүгә уралган Тити улын, икенче кулына зур гына төенчек күтәреп, чибәр апа Лүчнә тар сукмактан тау башындагы ялгыз куыш янына килеп җиткәндә, Хасия апа ишек төбендә тез өстендәге кул тегермәнендә он тарта иде. Чибәр апа Лүчнәне күрү белән, ул эшеннән туктап калды, аягына басты да итәгендәге бөртекләрен сыпырып төшерде. Якында гына чүпләнеп йөргән тавыклар, бөртек коелуын күреп, әрсезләнеп чабышып килделәр һәм канәгатьлек белән кыты-кыты килеп чүпләргә тотындлар. Хасия апа аларны күрмәде дә.

— Минем Тити улым килә! — диде ул, килүчеләрне каршылап, ягымлы итеп.

Иң элек ул чибәр апа Лүчнәнең тынычлана башлаган йөзенә күз төшереп алды, аннан соң әннәсе күкрәгенә сыенып йоклаган баланың йөзендәге ак киндерне күтәргәндәй итте, аның да йөзенә карап алды.

— Тфү-тфү! Күз тимәсен! — диде.

— Менә синең хәлеңне белергә килдек әле, — диде чибәр апа Лүчнә.

— Минем хәлемнән бигрәк синең үзеңнең хәлеңне беләсе иде дә бит, — диде Хасия апа. — Ярар, үзең килгәнсең. Барырмын дип торадырыем.

— Моннан соң, он кирәксә, үземә кил, Хасия астай, — диде чибәр апа Лүчнә, җәймә өстендә эшсез моңаеп яткан кул тегермәненә караштырып. — Тегермән белән булашырга... син теге, яшь кешемени?

Хасия апаның йөзе үпкәләгән сыман кинәт төссезләнеп, сүрелеп калды. Сүз табалмаган сыман ул беравык эндәшми утырды да, авырлы авыру хатын белән сөйләшү гадәтен үзгәртмичә, тынычландыргыч бер йомшаклык белән, шулай да беркадәр борчылу сиздереп:

— Рәхмәт, иркәм. Кирәксә, сезгә бармый кемгә барыйм? Әйтсәм әйтим инде, бу тегермәннең сере бар аның...

— Сере? — диде чибәр апа Лүчнә, ашыгып, каушагандай итеп.

— Сер дә түгел инде ул, — диде Хасия апа бераздан, үз-үзенә каршы килгәндәй. — Гайнулым истәлеге бу тегермән. Өйләнешкәч, иң каты ташны сайлап үз кулы

белән эшләде. Мин югында тоткасыннан тотып шуны әйләндерсәң, минем белән күрешкән, сүләшкән кебек булырсың, диде. Бик тырышып, күңел биреп эшләде. Әнә уртасына сигез чатлы кашкарый чукыды. Әйткәне әле дә исемдә: миннән соң да кашкарый кебек күп яшә, диде, тегермәннәр туктаусыз әйләнеп торсын, туктаусыз бөртек тартып торсыннар, туктаусыз күктә кояш көлеп торсын, диде. Сүзгә оста, телгә тәмле булды. Он юктан да түгел... эчем пошса, чыгам да, диңгез ягына карый-карый, Гайнулым белән сүләшә-сүләшә, тегермән әйләндерәм. Күңелем тынычлана. Шул аның сере, иркәм.

— Минем дә шундыйрак серем бар, Хасия астай, — диде бераздан матур апа Лүчнә, сүзгә башлап. — Менә шул эчемне тырный. Ятсам да, торсам да... Исемә төште исә якты көннең яме китә, тәмле ашның тәме китә. Мин инде күптән аны сиңа сөйләргә дип йөрим — йөрәгем җитми.

— Алай икән, — диде Хасия апа, уйлап-нитеп тормастан.

— Шулай, — диде Лүчнә, дәртсез, хәлсез генә дәвам итеп. — Кыз чагымда нәзер әйттем, Хасия астай. Ир бала тапсам, Җир анага гәрәбә муенсамны садака итеп бирермен дидем.

— Җир анагамыни, иркәм? — диде астай, тынычсызлану галәмәте сиздереп.

— Җир анага, — диде Лүчнә — Балага узу белән, бар кайгым шул булды: кем булыр, ир баламы, кыз баламы? Котым алынып шуны көттем. Беренчесе кыз булды. Монысы менә...

Нидер сизенеп, ана кеше сүзеннән туктап калды һәм таралып йоклап яткан улының йөзен ачып карады. Баланың күзе ачык иде. Күзләре белән күреп, карап, тыңлап ята сыман иде. Чибәр апа Лүчнә куркып кинәт кычкырып җибәрде:

— Астай! Ул мине тыңлап ята! — диде.

Шул чакны аның күз аллары караңгыланып китте, башы әйләнде. Ул үз-үзен тота алмыйча артына авып китте. Алар, аякларын сузып җибәреп, ала-кола төстәге барс тиресе өстендә утырып торалар иде. Хасия астай чайкалып киткән хатынны тотып алды, иплән кенә кочып алды да йомшак кулы белән аның тирләп чыккан маңгаеннан, битеннән сыйпады. Ул арада бала кычкырып елый башлады. Баланың елау тавышын ишетеп, Лүчнә дә исенә-акылына килде. Хасия астай өенә кереп көмеш чүмеч белән су алып чыкты.

— Эчеп җибәр, иркәм, тынычланырсың, — диде.

Чибәр апа Лүчнә эчте, авыр йөктән котылган кебек, җиңеләеп китеп, тирән итеп бер тын алды да, көйсезләнгән баласын тирбәтә-тирбәтә, иелә төшеп имәргә бирде. Шул ук вакытта аның күзләреннән яшь акты, әйтерсең әле генә эчкән суы, күз яшенә әйләнеп, кире чыга иде.

Бала имеп бетергәнче алар сөйләшмәделәр. Икесе дә, кояш нуры балкыган аяз күккә, күк читенә түкәлгән зәңгәрле-яшелле диңгезгә карый-карый, тын гына утырып тордылар.

— Әйткән нәрсәне бирергә кирәк, иркәм, — диде бераздан Хасия астай.

— Шулай шул. Муенсам да исән, — диде чибәр апа Лүчнә. — Монда гына, турада гына бирсәм, дөрес булырмы? — шуны белмим, астай. Шул бәгыремне телә.

— Син аның монысын да беләсең, иркәм, — диде астай. Изге Җир ана өе Аклан илендә бер генә урында. Ул тегендә калды.

— Ничек кайтыйм соң Акланыма? Кош булып очыйммы, балык булып йөзимме? — диде Лүчнә, пышылдап. — Кая карама — диңгез, кая карама — таурлар. Юллар ябык, капкалар йозаклы. Ничек кайтыйм, ничек итеп нәзеремне бирим Матута анага?!

— Ireңә әйттеңме? — диде Хасия астай.

— Юк, куркам, — диде чибәр апа Лүчнә.

— Курыкма, әйт, — диде астай. — Ирдән куркырга кирәкми, ирне аңларга кирәк. Ул да сине аңласын. Шул чагында берни куркыныч түгел. Озакламый ун ел була. Юллар ачылыр, йозаклар ватылыр. Ун ел тулганчы кәмәләр ясатсын. Кайтырсың, нәзереңне үтәрсең, күңелең тынычланыр.

Икенче көнне иренең аеруча ягымлы, якын чагын туры китереп, чибәр апа Лүчнә сүз башлады. Акланымны сагынам, диде. Ятсам — төшемдә, торсам — күз алдымда. Алтын-көмешкә манылган түбәләрне, таш киртәләрне, бер ярдан икенче ярга сузылып яткан көянтәдәй таш күперләрне, Изге таудагы сарайларны сагынам диде. Үзебезнең су буендагы ике катлы өебезне, бакчаны, агач араларыннан челтерәп аккан чишмәне сагынам, диде. Тезде генә — берсен дә калдырмады. Иң ахырда әйтте: Кайнар чишмә суында бер коенып чыксам ... яңадан тугандай тазарып китәр идем, диде.

Ире, Тини, бүлдермичә, тыныч-киеренке бер хәлдә тыңлап кына утырды. Лүчнә барысын да берьюлы әйтеп бетерим дигән кебек ашыгып-кабаланып сөйләде. Мон-

дый чакта аның бик нык борчулы булуын, шуңа күрә аңа каршы килергә ярамаганлыгын Тини яхшы белә иде. Диңгез аръягында калган Акланын, билгеле, ул да сагына иде. Аның да ятса да, торса да күз алдына сарайлар, күперләр, юллар, шау-шулы урамнар килә, таныш йөзләр күренә, колагына таныш тавышлар ишетелә иде. Ләкин Аклан турында, сагыну турында алар инде күптән сөйләшмиләр. Бу болай да аңлашыла. Ул турыда сөйләшү үз-үзеңне телгәләү, газаплау белән бер иде. Баладан соң Лүчнә әле булса мантый алмый. Күрәсең, шуңа шулай тора салып Акланны искә төшерә торгандыр да инде ул.

— Изге тауны, сарайларны, өйләрне... минем дә исемнән чыгарганым юк, — диде Тини бәк, йомшак кына итеп. — Ләкин Аклан безнең өчен матур төш кенә. Матур төшне уйламасаң яхшырак. Безнең илебез-җиребез хәзер монда. Язмыш безнең шундый. Монда да диңгезләр, таулар бар, челтерәп аккан чишмәләр бар ... Коенырга, юынырга кайнар сулы мунчаларыбыз бар... Онытыйк без төштә күргәннәрне, Лүчнәм!

Чибәр апа Лүчнәнең кинәт йөзе үзгәрде, күзенә яшь килде.

— Минем Акланга кайтасым килә, — диде ул, ачынып.

Мондый сүзгә каршы Тини эндәшми калуны яхшырак күрде. Ул бары күңелсез итеп көлемсерәп кенә куйды.

— Минем менә диңгез төбенә төшеп ...су иясе тартып алган кәмәләремне, кешеләремне, терлек-туарымны кире кайтарасым килә дә бит, — диде ул береаздан, әкрен генә, Лүчнәнең акылга сыймый торган сүз сөйләвенә ишәрәләп.

— Аклан су төбендә түгел! — диде Лүчнә, иренең аңламавына яисә аңламаган булып кылануына ачуы килә башлап.

Чибәр апа Лүчнә исәпләгәнчә ире Тини барысын да белә, барысын да сизенә, тик менә юри аны үртәр өчен генә белмәгән-сизмәгән булып кылана иде.

— Безнең Аклан монда. Аңлыйсыңмы, монда! — диде Тини бәк, киресенчә Лүчнәнең берни белмәгән булып «кылануына» исе китеп.

— Озакламый ун ел тула. Ун елдан соң да кайтып күренергә ярамас дип уйлыйсыңмыни син? — диде Лүчнә, үзенең тел төбенә төер булып утырган соравын башкачарак әйтеп.

— Ун елдан соңмы? — диде Тини бәк, уйланып. — Әйе, ун елдан соң безнең сөргенлек бетә. Түрәдә язып-

ганча, без Акланга кире кайта алабыз. Ләкин, минем белүемчә, әле беркемнең дә ун ел сөргеннән соң кире Акланга кайтып, үзенчә яши алганы юк. Сөргеннән кайтучыларны тоту, тоткарлау, кире борып җибәрү өчен мака сар ялчылары кырык төрле сәбәп табалар. Ярлыкау турында боерык килмичә торып, безнең моннан кузгалырга хакыбыз юк. Белмисеңмени шуны?

— Беләм, — диде Лүчнә, пышылдап. — Белүен беләм... — диде ул аннары, нидер әйтмәкче булып, ләкин әйтә алмады. Әйтмәде. Ире төпченеп тормады.

Бу сөйләшү шуның белән төкәнде. Икенче мәртәбә сөйләшкәндә, Лүчнә үзен тынычрак тотты һәм бернинди каушаусыз барысын да сөйләп бирде: минем нәзерем бар, диде, Хасия астай хәзердән үк олы кәмәләр ясый башларга кирәк дип әйтте, диде, мине яратсаң, кәмә ясата башла, диде. Мондый сүзләр ишетеп Тини бәк уйга калды. Әйткән нәзерне кемгә тиешле шуңа илтеп бирү ул Лүчнәнең үзе өчен генә кирәкми иде. Улы Титинең сау, таза булып үсүе турыдан-туры ананың тазалыгына, аның күңел тынычлыгына бәйле иде. Тити исә булачак ил тоткасы, илнең алтын баганасы иде. Шулай булгач, ничек итеп ул, Тини бәк, үзенең, иленең, халкының киләчәге турында кайгыртмасын.

— Киңәшергә безнең Хасия астаебыз гына түгел, пир атабыз бар, санатыбыз-аксакалларыбыз бар. Киңәшик, уйлашыйк, — диде ул, хатынына вәгъдә итеп.

Менә бүген таң атып, күзен ачып, көндәгечә күнегелгән шөгыленә тотынгач, Тини бәк күптәнге шул сөйләшүне исенә төшерде. Иртәгә ниләр эшләргә кирәклеген ул инде кичтән үк уйлап, күңеленә беркетеп куйган иде, бу хакта Лүчнә белән дә киңәшеп алган иде. Аларның кичәгенәк килешеп-сөйләшеп куйган эшләре шул булды: басуда арпа өлгергән, уракка төшәргә кирәк, диләр. Чыннан да шулаймы, түгелме икәнлеген белү өчен, алар бүген басуга барырга, бөтенесен үз күзләре белән күрергә һәм шунда берочтан пир ата янына да сугылып чыгарга тиешләр иде. Бу арада пир ата тазалыкка туймый, ахрысы, инде озакламый бер ай була бугай — хәл белергә дип үзе дә килеп чыкмый, кеше дә җибәрми. Аның килүен көтеп ятмыйча, вакыт табып тиз генә янына барып кайтканда да яхшы булыр иде дә, әлеге дә баягы — вакыт юк.

— Соңгы мәртәбә кайчан күрдек әле без аны? — диде Тини бәк, үзалдына сөйләнгән сыман, ләкин чынлыкта Лүчнәгә эндәшеп.

Бикә, никадәр чибәр һәм сөйкемле хатын булмасын, шулай да ул иртән дә, кичен дә, ире юынганда, ясанганда аның янында асрау хатын-кызлардан беркемне кертми, мондый чакта кирәкле чәч тарау, үрү, тәненә хуш исле майлар сөртү кебек эшләрнең барысын да үзе башкара иде. Хәзер дә ул, иренең чәчен үреп бетереп, муенына алтын чылбырлы муенса тагу белән мәшгуль иде. Тини бәкнең кем турында сөйләвен ул шундук аңлап алды, шулай да аңлап җитмәгән сыман:

— Әтине әйтәсеңме? — диде.

— Әтине, — диде Тини бәк.

— Нишләп иртүк аны исеңә төшердең әле? — диде бикә.

— Бу көннәрдә нишләптер гел уйлыйм мин аны, — диде Тини. Бүген дә йокы аралаш уйланып яттым. Менә тагын исемә төште. Бер ай бардыр инде — күргән дә юк. Үпкәләмәде микән?

— Ул андый түгел, — диде чибәр апа Лүчнә, әтисе өчен беркадәр горурлык белән.

Алар шулай иренеп кенә, ашыкмыйча гына үзара гәпләшеп торганда, ишек артында тамак кырган тавыш ишетелде һәм беркадәр серле кыяфәттә кол хатын кереп:

— Пир атадан кеше килгән! — диде.

Мондый сүз ишетеп, Тини бәк кинәт сискәнеп китте.

— Ә?! — диде ул ашыгып, кол хатынга борылып .

— Әтидән? Ни булган? — диде бикә дә, каушагандай итеп.

— Белмим, — диде кол хатын.

— Булуын булмагандыр, — диде Тини бәк. — Шулай да бу арада төшкә керүе тикмәгә түгел. Ни дә булса бар монда.

— Мин берни белмим, — диде кол хатын.

— Кешесе кайда? — диде Лүчнә кол хатынга.

— Тышкы ишек төбендә көтеп тора, — диде тол хатын.

Чибәр апа Лүчнә иренең муенсасын җайлап каптырып куйды да, яратып, сокланып, аның таза аркасыннан йомшак кулы белән сыйпап алды һәм, үзенең җыелмаган, таралмаган озын кара чәчләрен артка ташлап, киң, озын күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, тышкы ишек ягына ашыкты. Аның артыннан яңа сөртелгән май исләре таратып, салмак кына атлап, Тини бәк тә тышкы ишеккә таба юнәлде.

— Ни булды? — диде Лүчнә, пир атаның кешесен күрү белән, беренче сүзе итеп.

— Пир ата... исәнме-саумы? — диде Тини бәк тә.

Пир атаның кешесе, җавап урынына ниндидер ыңгырашу-мыгырдану сыман бер аваз чыгарды да, шундый

ике олы кеше алдында аягөсте басып торуны ялгыш санап, шундук идәнгә тезләнде.

Чибәр апа Лүчнә аны күтәреп торгызгандай торгызды.

— Пир ата... исән. Урын өстендә ята, — диде кеше, аягына басып, бикәгә туры карарга кыймыйча.

— Тагын ни әйтте? — диде Лүчнә, кешенең ахмакларча кылануын күрмәскә тырышып.

— Пир ата килергә кушты, — диде кеше.

Пир атаның кешесе яшь кенә бер егет иде. Әле яңарак кына йокыдан торып, рәтләп юынмаган, төзәнмәгән, муены, күкрәкләре, беләкләре ачык бикә күзнең явын алырлык дәрәҗәдә чибәр иде. Аның хәтта куркынган йөзеннән, серле, тирән карашлы күзләреннән җылы, сихри нур бөркелә сыман иде.

Яшь егетнең каушап калуын бикә үзе дә, Тини бәк тә күреп-сизеп тордылар. Бикәнең моңа, билгеле, күңеле булды, ләкин шул ук вакытта бу аның ачуын да китерде.

— Үзең сөйләш әле рәтләп! — диде ул, иренә карап һәм бер дә юктан үртәлеп, дөресрәге, үртәлгән сыман кыланып, китеп барды. Яшь егетнең үзеннән уңайсызлануына әйтерсең үзе түгел, ире гаепле иде.

Тини бәк көлемсерәп кенә куйды һәм пир ата кешесе белән артык сүз озайтып торуны урынсыз санап, шулай ук эчкәре бүлмәгә кереп китте. Үзе исә уйлап куйды: «Сүзен ул миңа гына әйтергә тиеш иде бугай. Пир ата минем үземне генә чакырган бугай», — дип. Шулай да аның яңадан төпченеп, сорашып торасы килмәде.

Өйдә ниндидер ят кеше барлыгын, әтисе белән әнисенең ничектер үзара серле пышылдашып сөйләшүләрен ишетеп, Рәвия дә, башкалар да уянды. Ул арада бөтен өй эче аякка басты һәм барысы да колактан колакка пир атадан кеше килүе, пир атаның чирләп китүе, шунлыктан кызы белән киявен үз янына чакыруы турында чыш-пыш китте. Пир атаның урын өстендә ятуын һәркем үзенчә юрады һәм юраганда да күбрәк күңелсез якка юрады. Ләкин беркемнең дә бу хакта кычкырып әйтергә теле бармады. Барысы да бүген өй эчендә аяк очларына гына басып йөрделәр, барысы да тавышларын әкренәйтеп сөйләштеләр һәм ничек тә бәк белән бикә күзенә чалынмаска тырыштылар.

Шулай тавыш-тынсыз гына ашагач-эчкәч, Тини бәк юлга әзерләнә башлады — юл киемнәрен киде, билен буып коралларын такты. Шунан соң аңа йөгәнле ат китереп тоттырдылар. Бикә өчен ике зур тәгәрмәчле кәрендәс арба җигелде. Әтисе белән әнисенең пир ата янына барырга җыенуын күреп, Рәвия дә юлга чыгарга

теләк белдерде. Аңа каршы килмәделәр — кәрендәстә өч кешелек урын бар иде. Ләкин Титине уятып тормаска булдылар.

Тини бәк әкрен генә атын атлатып Котилле капкасына юнәлгәч, пар ат җигелгән җиңел кәрендәс кузгалып киткәч, таш сарайның таш баганасыннан мүкәләп, кычкырып елый-елый Титинең төшеп килгәне күренде. Аның артыннан, ашыгып, бала караучы хатын йөгереп килә иде. Бала тавышын ишетеп, ата кеше дә, ана кеше дә атларын туктатырга кирәк таптылар һәм артларына борылып, елак улларын көтеп тора башладылар. Рәвия исә, тиз арада кәрендәстән төшеп, анадан тума шәрә энесен күтәреп алды һәм аны энисе янына йомшак тире җәелгән утыргычка утыртты.

— Кем елаткан минем улымны? Кемнәр генә елаткан икән минем Титиемне? — дип сөйләнде матур апа Лүчнә, улының әле аркасыннан сөеп, әле битендәге күз яшьләрен сөртеп.

— Ләвия елатты! — диде малай яшь аралаш.

«Ләвия»нең мондый оятсызлыкка исе китте.

— Ялганчы. Нишләп мин елатыйм сине?! — диде ул чын күңелдән ачуланып.

— Кем ялганчы, улым, Ләвияме, әллә Титиме? — диде энисе, улын тотмакчы булып.

— Ләвия! — диде Тити, тоттырасы килмичә.

Иртәнге кояш кебек ул елмаеп җибәрде һәм көлемсерәп карап торган әтисен күреп алды да, урыныннан торып, кулларын сузып, әтисе янына күчәргә сорый башлады. Ата кеше улын бик ярата иде. Атын кире борып, ул кәрендәс янына килде, кулын сузып Титине күтәреп алды. Тити, куанычыннан нишләргә белмичә, әтисе кулындагы тезгенгә тотынды һәм, бар көченә кычкырып, атны тарткалый башлады. Иренең кире борылуы Лүчнәгә генә ошап җитмәде.

— Юкка борылдың. Юлыбыз уң булса ярар иде, — диде ул, пошынып.

— Борчылма, капкадан чыкмадык әле, — диде Тини бәк, бикәне тынычландырып.

Алар яңадан кузгалып киттеләр. Тигез итеп таш җәелгән юлда ат тояклары, җиз кыршаулы тәгәрмәч тавышлары ишетелеп торды. Юл сөзәк кенә булып өстән түбәнгә таба шуышты. Юлның текәрәк дип исәпләнгән төшен узып киткәч, алар тар гына тыкрыкка килеп керделәр. Тыкрыкның ике ягында да тоташтан диярлек таш киртәләр сузылды. Киртә артында, ишегалды ягында берән-сәрән кеше тавышлары, эт өргән һәм мал-туар кыч-

кырган тавышлар ишетелеп китте. Яртылаш яисә иңеләй ачылган җилкапкалардан матурлап бизәлгән болдырлар, шомартылган таш баскычлар, ишегалдындагы каралты-куралар, өй алдында тәрәзә турысында үсеп утырган алсу гөл түтәлләре күренеп калды. Кайберәүләр, тыкрыктан узып баручыларның күз карашлары белән очрашып, ерактан ук кычкырып сәлам бирделәр, иртә таңнан каядыр китеп баручы бәк белән бикәгә ак юл теләделәр. Таш киртәнең тәбәнәгрәк урыннарыннан тыкрык ягына җимеш агачлары озын-озын ботакларын сузып калды. Алар да Тини бәк белән бикәгә, аларның сөйкемле кызына, алардан да бигрәк, иртәнге сайрар коштай куанып теләсә ни сөйләнеп, кычкырып барган Титигә ак юл теләгән сыман булдылар.

Турадагы ике капканың берсе диңгез яры буена алып бара торган тарлавык ягына, икенчесе болын ягына чыга. Болын ягы капкасын Котилле капкасы дип, тарлавык ягына чыга торган капканы Диңгез капкасы дип йөртәләр. Диңгез капкасы көненә бер-ике генә ачылса, Котилле капкасы көне буена диярлек ачык тора иде. Аны бары караңгы төшү белән генә ябалар һәм таң аткач яңадан каерып ачып куялар иде. Турадагы барлык эш шушы капка аша башкарыла, монда беркайчан кеше өзелеп тормый иде.

Менә бүген дә, капка ачылу белән, коллар, каралар турада төн кунган мал-туарны болын якка алып чыгып яталар. Беркадәр вакыт үткәч, капка юлында бөтен бер төркем булып, җиңелчә юрттырып килгән ат көтүе күренде. Тиз арада көтү капкага килеп тә җитте. Алдагылар бернинди тоткарлыксыз теге якка чыгып китә алдылар. Ләкин арттагылар бер-берсенә төртелеп, кысылып, капка авызында тоткарланып калдылар.

Атларның, сыерларның менә шулай капка алдында тоткарланып торуы Мөнип сакчының иң яратмаган нәрсәсе иде. Ни өчен дигәндә, бу аңсыз хайваннар шушында әз генә тоткарлангандай иттеләрме, ни хикмәттер, тизрәк бушанырга, үз йомышларын йомышларга тотыналар. Капкадан чыккач, иркендә, болында, тау астында бушансалар ни булгандыр аларга?! Көтү узып киткәч, капка төбендә бер генә тизәк төшеп калса да, Мөнипнең күңеленә шундыйрак уйлар килә. Ул, билгеле, шундук себерергә, чистартырга тотына, ләкин мондый эшне үз дәрәҗәсен төшерә торган кирәксез нәрсәгә санап, якын тирәдәге кеше ишетелерлек итеп сукранырга да онытмый. Атаклы диңгезче, батыр сугышчы шушы хәлгә төшсен әле? Сукранмасаң да сукранырсың! Заманында Мөнип — Олы

диңгезне аркылыга-буйга йөргән кеше. Күпме сугышта батыр калган, исән калган, әллә нинди балык авызыннан исән чыккан... дөньяның астын-өстен актарып йөргән... юлбасар Мөнип... сынык хәлендә менә монда ачы-төче тизәк исе иснәп гомерен уздырсын икән!

Кайчагында аның, билгеле, бик нык ачуы килә. Андый чакта ул капка авызына килеп тыгылган мал-туарны сөңге сабы белән этеп-төртеп, куалап тора, көтүчеләр күрмәгәндә исә берәр аңгырасының сырт буена сылап алудан да тартынып тормый.

Менә бүген дә ат көтүе чыкканда шулай булды. Зур корсаклы бер кара бия, тар капка авызында туктап, бөтен көтүнең юлын бикләп, арт аякларын аерып баскан килеш, үз эшенә тотынмасынмы! Аны-моны уйламыйча, Мөнип карт кулындагы сөңгесен күтәрде дә авыр сөңге сабы белән тегенең арт санына берне тондырып алды. Шундый иттереп тондырды — сөңге сабы яңгыраудан куллары авыртып китте. Кара бия шундук читкә ыргылды, башкаларны кысрыклады. Атлар усалланып, пошкырып, бер-берсен тешләп алдылар. Шул ук вакытта көтү артында көтүчеләрнең ачуланып кычкырган тавышлары ишетелде.

Үзенең кирәгеннән артык кызып китүен шәйләп, Мөнип сакчы тиз генә читкә тайпылды һәм, усал көтүчеләрнең йөзен күрмәс өчен, үзенең капка төбендәге оясына кереп посты. Ачык ишектән күз кырые белән көтүгә, көтүчеләр ягына караган иде, көтү артыннан беркадәр калышып Тини бәкнең килүен күреп алды. «Бетте! Харап булдым!» дип уйлады ул, коты алынып. Атлар чыгып беткәнче, Мөнип сакчы, тын алырга да куркып, якынаеп килүче куркынычны көтте.

Көткән кеше килеп җитте, тигезләште. Мөнип сакчы урыныннан кузгалды, бер-ике адым атлады да бозылган, кызганыч йөз белән баш иде һәм, ил агасын котлап:

— Атабыз-анабыз хакына... туар көн хакына, — дип мыгырдана башлады.

Тини бәк капка сакчысын әллә күрде, әллә күрмәде — ничек килгән булса, шулай берни эндәшмичә, як-ягына каранмыйча, үз уйларына бирелеп узып та китте. Мөнип сакчы сөенеп иркен итеп тын алды һәм ерагая барган бәккә:

— Юлың уң булсын, бәк! — дип кычкырды.

Шул чакны Тини бәк атын туктата төште һәм сакчының ни әйткәнен ишетеп җитмәгән кебек, артына борылып карады. Мөнип сакчы ашыгып бәк янына килеп җитте.

— Юлың уң булсын, бәгем! — диде ул кабатлап.

— Амин, шулай булсын, — диде Тини бәк һәм атыннан иелә төшеп, кулындагы улын Мөнипкә сузды.

— Мәле, Мөнип ата, шуны печ иттер, — диде.

Мөнип сакчы мондый сүз ишетеп каушабрак калгандай булды. Ашыгып атлы кешегә якынрак килде, кулындагы сөңгесен читкә ташлады да Титине ике куллап тотып алды. Ат өстендә, әтисе алдында тирбәнеп килгән малайның инде күзләре йомыла башлаган иде, шулай да ул Мөнип сакчы кулына күчкәч тыпырчына башлады. Мөнип сакчы аның тәпиен тотмакчы булды.

— Үзем! — дип кычкырды малай, чарага куймыйча.

— Үзең икән үзең, — диде Мөнип сакчы, ил агасының улына каршы килергә кыюлыгы җитмичә.

Малай, киерелә төшеп, бик зур эш башкарган кебек, бар көченә сиптерергә тотынды. Аның бу эшенә әтисе дә, Мөнип сакчы да рәхәт көлемсерәп карап тордылар. Алардан күрмәкче, Тини бәкнең зур, биек һәм көчле аты да, гәрәбәдәй зур ялтыр күзләрен боргалап, исе китеп карап торды.

«Кая китте икән соң бу ил агасы улын күтәреп. Уракка микәнни? Басуны күргән дә юк» дип уйлады Мөнип сакчы, батыр малайны атасына тоттыргач.

Ул арада җигүле кәрендәс тә килеп җитте һәм колак төбендә генә:

— Иминлекме, Мөнип ага? — дигән сүзләр ишетелеп китте.

Капка сакчысы шундук тавыш килгән якка борылып карады һәм чибәр апа Лүчнә белән аннан да чибәррәк яшь кызны күреп, чын күңелдән елмаеп җибәрде.

— Изге инәбез Рабига ана хакына, атабыз-анабыз хаха... кына юлыгыз уң булсын, бикә! Шулай да иртәләгәнсез. Кая юл тоттыгыз болай? — диде ул, бер-бер артлы тезеп.

— Кояш чыккач, ниндәен иртә инде ул, Мөнип ага, — диде чибәр апа Лүчнә.

Соклануын яшерә алмыйча, авызын ачып карап торган Мөнип сакчының борынына кәрендәс ягыннан дәртләндергеч хуш исләр килеп бәрелгәндәй булды. Йөрәге җилкенеп куйды. Күз алдына иксез-чиксез диңгез килде, томанлы күк артында сихри таулар, биек йортлар, манаралар күренгәндәй булды. «Эх! Шулай да монда күңеллерәк. Басуың бер читтә торсын» дип уйлады капкачы карт, бу мизгелдә үзен искиткеч бәхетле санап.

Беренче мәртәбә шушы җиргә аяк баскач та, беренче мәртәбә яр буйларына, күккә, тирә-якка күз ташлап ал-

гач та, мондагы бөтен нәрсә Тини бәкнең күңеленә хуш килде. Төньягында — таулар, көньягында — зәңгәр диңгез. Таулардан болайрак — диңгез буенда — тигезлек. Таулар ягыннан ниндидер саф сулы елга агып төшә. Елга үзәнендә — тал, камыш куаклары, ләм утырган уңдырышлы җирләр, вак күлләр, ермаклар, тәбәнәк калкулыклар күренә. Бөтен нәрсә тегендә, еракта калган туган илдәге кебек дип әйтер идең, монда, үзәндә, агарып, ерактан ук матур булып таш өйләр, таш сарайлар да күренми, тигез юллар да, юл буйларында эшкәртелгән басулар, җимеш куаклары да, мал-туарлар да күренми. Алай гына да түгел, монда хәтта кешеләр дә юк! Хәер, монда аның иң яхшысы шул кешесезлек иде бугай. Ләкин шул ук вакытта мондый хәл шомлылыкны һәм билгесезлекне көчәйтә генә төшә иде.

Шулай да нинди җир бу? Кемнәр җире?

Монда алар кичкырын килеп җиттеләр. Кәмәләрнең бер өлеше елга тамагыннан үргә күтәрелде, бер өлеше диңгез буенда калды. Беренче төнне алар кәмәләрдән җиргә төшмәделәр. Картлар, балалар һәм хатын-кызлар гына йокладылар. Ирләр алмаш-тилмәш кизү торып таңга кадәр сакта тордылар. Төне буена тирә-якта ниндидер ят тавышлар ишетелде, әле бүреләр улады, әле еракта юлбарыслар үкерде һәм өзелеп-өзелеп төн кошлары сыкранды. Кемнәрдер сугышты, кемнәрдер, тантана итеп, ырылдап, дошманының бугазын чәйнәде, кемнәрдер җан ачысы белән күккә, җиргә, суга үзенең соңгы сулышын, соңгы үпкә-әрнүен юллады.

Ай буе дулкыннар белән, җил-давыллар белән тарткалашып арыган-алҗыган, йончыган һәм дөньяда яшәүдән өметен өзә башлаган кешеләргә төнге ерткыч улаулары, үкерү һәм елау-сыкраулары иркәләп эндәшкән изге тавышлар булып тоелды.

Икенче көнне таң ату белән, кешеләр барысы да ярга чыктылар, селкенми, тирбәнми торган каты җирне тоеп, сөенешеп туган көнне, изге аталарны, аналарны олыларга, бер-берсен котларга тотындылар. Яр буенда учаклар ягылды, учак өстенә казаннар асылды. Кораллы ирләрнең бер өлеше, унар кешелек берничә төркемгә бүленеп, тирә-якны карарга киттеләр. Аяк астыннан, куе үлән арасыннан эре-эре кәлтәләр, шома еланнар шуышып китте. Каяндыр якыннан гына кузгалып зур канатлы кара кошлар, бөркетләр очып китте, тау сыртларында, еракта, артына борылып ниндидер ят кешеләргә карап торучы ала-кола җирән тиреле ерткычлар күренеп калды. Аяк астында адым саен диярлек

эре-эре ташлар, ташлар белән аралашып, җилдә, яңгырда агарып-шомарып беткән ниндидер баш сөякләре, кабырга һәм умыртка сөякләре очрады. Баш сөякләре арасында атныкы, сыерныкына охшаш болан, поши башлары белән бергә, күз тишекләре акаеп, тигез тешләре ыржаеп торган кеше башлары да күренеп-күренеп калды. Бер-ике җирдә түгәрәк учак урыннары, учак тирәсендә өем-өем бакыргыч калдыклары очрады. Юк, бу җирдә, күрәсең, ерткычлар гына түгел, кешеләр дә булырга тиеш иде.

Бу җиргә беренче мәртәбә аяк баскан иртәдә дә нәкъ бүгенге кебегрәк иде. Менә шулай диңгез артындагы каралҗым шәүләләр артыннан тере булып утлы кояш чыккан. Иртәнге нурлар иркәләп арканы җылыта. Алда, төньякта исә, өндәп, мавыктырып, күңелләрне җилкендереп, күксел-яшькелт тау тезмәләре калкып ята. Тик шулай да ул беренче иртәдә көн бүгенгедән салкынрак, шыксызрак иде бугай. Һәрбер куак, һәрбер таш артыннан аларны кемнәрдер көтеп, сагалап торадыр сыман иде.

Иң элек илле-иллегә җир бүлделәр. Барсилләргә диңгез буе эләкте. Тураны шунда диңгез буендагы аерымланыбрак утырган тау башына салырга булдылар. Карлар, сабалар арырак, таулар ягынарак урнаштылар. Беренче елны кура-куыш әмәлләделәр дә беркадәр җир ачтылар. Икенче елны язга чыгу белән бераз арпа, тары чәчтеләр, җимеш, яшелчә утырттылар. Шул ук вакытта таш кистеләр, таштан сарай һәм каравыл өе сала башладылар.

Яңа җирдә яңа тормыш шулай башланды. Үзәннең тура-тауга якын өлеше иген игү өчен уңайлырак булып чыкты. Елга ярының уң ягы биегрәк иде, аннан соң үзән уртасыннан челтерәп чишмә агып ята иде. Чишмәне буып, суын басуларга, җимеш, яшелчә араларына җибәрделәр. Елдан-ел шаулап игеннәр үсте, җимеш, яшелчә үсте. Беренче еллардагы кыенлыклар инде онытылып бара.

Күңелле, караган саен карыйсы килә бу җиргә — үз кулың белән яулап алынган, үз көчең белән эшкәртелгән, матурланган ят җирләргә! Тик менә пир атаның... урын өстенә ятуы гына күңелгә кара тап булып төште. Алай-болай нитә калса, тфү-тфү, әйттем исә кайттым! Шулай да беркем дә бу дөньяга мәңгегә килмәгән. Кайчан да булса барыбыз да... шунда китәчәкбез. Әйе, алай-болай була-нитә калса, бөтен нәрсә аның өстенә, Тини бәк өстенә өелеп калачак түгелме соң? Әлегә пир ата бөтенесенә үзе җигелеп, үзе өстерәп бара. Аннан башка мондагы тормышны күз алдына китерүе дә кыен. Алай-болай булса,

ул чагында инде тегендә, еракта калган изге утрауга кайту турында уйлап булыр микән? Ни өчен дигәндә... Шулай да ни булды икән соң аңа, тынгысыз пир атага?

Моннан ике-өч ел элек Акланга кайту өчен зур кәмәләр ясый башларга дигән карарга килгәч, бу эшне пир атага тапшырдылар. Моның өчен аннан да кулайрак кеше дә юк иде. Пир ата үзе моңа бик теләп алынды. Якындагы тауларның, үзәннәрнең күп өлеше карурман белән капланган. Карурманда исә кәмә ясау өчен яраклы менә дигән имән, нарат, чыршылар да җитәрлек иде. Менә шунда, карурман белән үзән читендә, диңгез ягыннан күренеп торган тәбәнәк бер калкулык өстендә, пир атага ак таштан биек манаралы бер өй салып куйдылар. Дөресрәге, ул аның урынын да үзе сайлады, манаралы өен дә үзе салдырды. Манаралы өйдән беркадәр эчтәрәк, урман-таулар арасында исә кәмә ясау эшен башлап җибәрде.

Тини бәк, капкадан чыгып тау астына төшкәч тә, үзән уртасыннан сузылган төп юлдан шул Ак манаралы йортка карап барды. Турадан биш-алты чакрым ераклыкта урнашкан һәм иртәнге кояш нурында балкып утырган манаралы өй дә, өй тирәсендәге каралты-куралар да, эшкәртелгән басулар, төрле җирдә төрлечәрәк өлгергән һәм шуңа күрә төрлесе төрле төстәрәк булып күренгән арпа кәшәрлекләре бу мәлдә гаҗәеп бер могҗиза булып күренде. Хәер, әллә ни могҗиза да түгел. Мондый манаралы өйләрне, мондый басуларны, түбәсе күккә ашкан, алтынкөмешкә манылган сарайларны ул күп күрде. Күрүен күрде, тик алар тегендә, еракта калды. Андагылар белән чагыштырганда, мондагылар...

Атын үз көенә атлатып һәм берни белми йоклап барган Тити улының тән җылысын тоеп, Тини бәк уйланды да уйланды. Ара-тирә юл читендә йокымсырап утырган җәйге камыш алачыклар торып калды. Тар сукмакларда, кәшәрлекләрдә бил бөгеп, җир тырнап, йә булмаса чүп утап яткан каралар күренде. Алар шулай ук төп юлда да күренгәләделәр. Ләкин тура ягыннан атка атланган ил агасының һәм кәрендәскә утырган бикәнең килүен күреп, шундук читкә тайпылу ягын карадылар — мыштым гына берәр сукмакка кереп киттеләр һәм, чүгәләп йә булмаса юлга ятып, олы кешеләрнең узып киткәнен көтеп тордылар. Кулларына чыбык тоткан бер-ике бага, йөгереп килеп, Тини бәк алдында бил бөктеләр, төнлә басуда, каралар арасында ни булганын аңлатырга кирәк таптылар. Андый сүзләргә Тини бәк әллә ни колак салып тормады.

Төньякта чикләвек куаклары ягыннан арпа басуына төнлә ниндидер хайваннар кергән икән дә арпаны бераз таптаганнар, ашаганнар икән. «Тояклары зур, пошидыр» диделәр багалар. «Пошилар кермәсен өчен киртә корып булмый инде» дип уйлады үзалдына Тини бәк. Аннан соң елга ярына якын төштә кичке якта кыргыйлар, таурлар күренгән. Алар да арпа җирен таптап бетергәннәр, башак өзгәннәр. Күреп алгач, кыргыйларны куып җибәргәннәр икән, елга аша икенче якка чыгып киткәннәр. «Болары белән эш кыенрак булачак» дип уйлады Тини бәк, артык хафаланмыйча гына. Быелтыр да шулай теңкәгә тиделәр. Иген өлгергәнне көтеп кенә торалар. Сакчылар күздән югалганны ерактан карап, күзәтеп кенә торалар. Аларга әллә ни күп тә кирәкми, бер-ике уч арпа уып алсалар, беркадәр тамаклары туйса, шул җиткән. Ләкин көннәрдән бер көнне күпләп, көтүләре белән килсәләр, шундый тырышып, карап үстергән игенеңнең бөртеген дә калдырмаска мөмкиннәр. Әлегә алай күпләп килмиләр, әлегә кыюраклары, башсызраклары гына килә. Арпа, җимеш өчен генә түгел, кызык эзләп, этлек эзләп киләләр. Нидер эшләргә кирәк булачак.

Тини бәкне һәм аның юлдашларын Ак манарада ерактан ук күреп, күзәтеп торганнар иде, ахрысы. Тигез җирдән калкулыкка күтәрелә башлау белән, таш манара тирәсендәге алачыклардан кешеләр чыкты. Пир атаның өлкән багасы елмаеп ил агасының атын тотып алды, тагын бер-ике ир кеше кәрендәскә җигелгән атларны җитәкләделәр һәм, шул рәвешчә, аларны капкага чаклы җитәкләп килделәр. Имән такталардан ясалган биек капка үзеннән-үзе диярлек ачылып китте. Ишегалдына килеп керү белән, беренче булып кәрендәстән чибәр апа Лүчнә сикереп төште һәм, ире янына килеп, йоклаган Титине кулына алды. Улын ышанычлы кулга тапшыргач, Тини бәк тә аттан төште һәм алар өчәүләшеп-дүртәүләшеп каршыдагы биек болдырга таба атладылар.

Нәкъ шул чакта өй ишеге ачылып китте һәм тигез, шома ташлардан тезелгән ак баскычтан ашыга-ашыга төшеп килүче… пир ата үзе күренде. Көл сыман төстәге сирәк һәм кыска чәчләре ике толымга үрелгән, шактый тыгыз тәнле, җиңел сөякле өлкән яшьтәге кешенең, урын өстендә ятарга тиешле кешенең шулай ашыгып һәм елмаеп төшеп килүен күргәч, Тини бәк катты да калды. Кая, ничек? Кем әйтте, ник әйтте аны урын өстендә ята дип? Теге җүнсез егет ялгышканмы, әллә алар… үзләре тиешенчә аңлап җитмәгәннәрме? Йөзе, күз карашы әллә ничек ахмакларча иде шул аның. Чирле, имеш, хәле

шәптән түгел, имеш! Юл буе кияү балакай әллә нәрсәләр уйлап бетерде.

— Минем яшьтәш килгән! — диде пир ата, беренче сүзе итеп, һәм кызының кулындагы Титине күтәреп алды да, яратып, тәмләп-тәмләп, йокылы малайның кояшта янган шәрә тәнен каян туры килә шуннан үбәргә тотынды.

Шуннан соң ул, өлкәннәрнең берсенә дә күтәрелеп карамыйча, икенче кеше итеп Рәвия белән исәнләште, шаяртып аның нечкә генә толымыннан тартып алды. Рәвия белән исәнләшкәч, кызы Лүчнәне күреп алды. «Иртән йөрү бик килешә икән сиңа — мәк чәчкәседәй булгансың, Лүчнәм!» — диде. Иң азактан ул киявен килеп кочаклады.

— Әти, сине урын өстендә ята дигәннәрие, — диде Лүчнә.

— Урын өстендә? — диде пир ата. — Ятса ни? Кеше урын өстендә ятмыйча, кайда ята соң... йоклаганда?

— Котыбыз алынды. Әллә нәрсәләр уйлап бетердек, — диде Лүчнә.

— Сезнең килерегезне белдем дә, сикердем дә тордым менә! — диде пир ата.

Аларга каршы биек ишектән әкрен генә атлап Лүчнәнең әнисе килеп чыкты.

Бу салкын якка килеп урнашканнан бирле аның буыннары сызлый иде, шунлыктан ул иртәнге якта тышка чыкмаска тырыша иде. Әле дә ул өстенә искереп беткән тире тун, аягына шулай ук тире оек кигән. Ул, ахрысы, карты белән кызының соңгы сүзләрен ишетеп калган иде.

— Бер атна урын өстендә ятты, — диде ул, пир атаның серен чишеп. — Көн дә сезне көтте. Килмәгәч менә кеше җибәрдек. Үзем әйттем, урын өстендә ята, дип әйт диеп.

Тини бәк сүзгә катышмаска тырышты. Беренче күрүдән үк бабасы аңа чамадан тыш күтәренке һәм шат күңелле тоелды. «Шулай да нидер булган моңа», — дип уйлады ул үзалдына.

Кияве белән кызы килми торган арада, Ак манара авылында чыннан да кайбер нәрсәләр булып алды. Өйгә кереп бераз юынгач, тегесен-монысын белешкәч, сөйләшкәч, пир ата Гай ат китерергә кушты. Атка атланып, алар кияве белән икәүләп төньякка — таулар ягына, балтачылар янына китеп бардылар. Тини бәкнең күптән инде кәмә ясаучыларны күрәсе, олы кәмә ясау эшенең күпме дәрәҗәдә алга киткәнен, ничегрәк барганын беләсе килә иде. Пир атаның исә киявенә сөйләргә бик күп сүзе җыелган иде.

Симет елганың уң ягыннан диңгезгә тәбәнәк калку-

лык сузыла. Озын сырт дип йөртелгән бу калкулыкның елга яры ягында таллар, вак куаклар үсә. Ак манара үзәне янында һәм сырт өстендә анда-санда юан-юан имәннәр, юкәләр үсеп утыра. Пир ата авылына якын җирдән соң имән, юкә, чыршылар ешая, куера башлый һәм тоташ карурманга әйләнеп китә иде.

Беренче мәртәбә монда аяк басканда, күченүчеләрнең барлык кәмәләре, елга буенча үргә күтәрелеп, хәзер Ак манара торган төшкә чаклы килеп җиттеләр һәм, җайлырак урын эзләп, ярның уң ягында да, сул ягында да туктап калдылар. Тини бәк тә, пир ата һәм башкалар да иң элек озын сырт ягына түгел, иксез-чиксез сыман күренгән үзән ягына игътибар иттеләр. Озын сыртка каршы яктагы үзәндә тәбәнәк, түгәрәк калкулыклар да, ләм утырган тигезлекләр, камышлыклар, таллыклар да җитәрлек. Анда хәтта күлләр, ниндидер ермалаклар да бар. Иген игү, җимеш, яшелчә үстерү өчен мондый җирне эзләсәң дә таба алмассың!

Ләкин ныклап торып карана торгач, әлеге киң, иркен үзәннең уңайсыз яклары да ачыклана төште. Беренчедән, ул диңгез ягыннан шыр ачык иде. Су күтәрелгәндә, язгы ташу вакытларында да, үзәнне, күрәсең, су күмеп китә иде. Аннан соң, диңгездә йөргән теләсә нинди ят кеше аларны ерактан ук күреп алачак һәм, бик теләсә, алар кебек үк кәмәләре белән үргә менә алачак. Яу килә-нитә калса, якын тирәдә бер генә качып котылыр урын да юк — таулар ерак, озын сырт һәм урманнар елга артында калачак.

Болары аның күренеп, күзгә төртелеп торган уңайсызлыклар иде. Иң зур уңайсызлык исә шул булды: үзәндә инде кемнәрдер бар. Кәмәдән төшеп, әлеге үзән ягына таралган кешеләр комда, ләмдә торып калган кеше эзләре, анда-санда аунап яткан сөякләр, учак урыннары һәм таш, буш бакыргыч өемнәре күреп, тиз арада кире килделәр. Кайберәүләр хәтта тал-камыш куаклары артында ниндидер ярым шәрә кыргыйлар белән күзгә-күз очрашулары, кыргыйларның куркып, чыркылдап качып китүләре турында сөйләделәр.

Үзән хуҗалары таурлар белән чын очрашу икенче көнне булды. Иртәнге якта диңгез өстеннән кояш әле яңа күтәрелеп килгәндә, тал-камыш әрәмәләре артында, калкулыклар артында кәмәләргә таба якынаеп килгән ямьсез шау-шу, гүелдәү ишетелде. Ерактан килүчеләр җир өстенә учак ягып, казан асып ашарга пешерү белән мәшгульләр иде. Шаулаучылар, ниндидер ят тавышлар белән кычкыручылар озакламый үзләре дә күренделәр.

Алар якындагы тигез җиргә таралып, бик күп булып киләләр иде. Алар барысы да анадан тума диярлек шәрәләр. Аларның билдән түбәнрәк җирендә тире кисәкләре салынып тора да, кайберләренең аркаларында шулай ук тире кисәкләре күренә иде. Алар ябыклар һәм тәбәнәк буйлылар. Арада калкурак буйлылар, тазараклар да күренде. Аларының тавышы көчлерәк, янаулырак булып ишетелде. Мондыйларның баш кеше икәнлеге әллә кайдан күренеп тора. Муеннарында тишеп шома таш яисә ниндидер сөякләр тагылган муенсалар. Булган бар коралары күсәк тә башы утта яндырып очлайтылган кыска сөңгеләр. Баш кеше дип уйланылган берсе озын саплы балта тоткан. Балта дигәне шул: үткен йөзле озынча ташка сап бәйләгәннәр. Андый балталарны Тини бәккә элегрәк тә тегендә, Акланда да күрергә туры килгән иде. Агач сапны таш балтага сеңер белән кысып бәйлиләр дә, шуны ниндидер тау җилеме белән катырып куялар — берничек сүтеп, чишеп алырлык түгел.

Кыргыйлар якынлашу белән, хатын-кызлар, бала-чагалар куркышып шундук кәмәләргә кереп постылар, кайберәүләр елгага ташланды. Ирләр күкрәкләрен, аркаларын каплый торган каты киемнәрен, каты башлыкларын киеп, коралларын, калканнарын алып бер тирәгә туплandылар һәм тавыш-тынсыз гына көтә башладылар.

Таурлар, кәмәләргә якынаю белән, таш ата башладылар. Ташны ату өчен аларның бернинди җайланмалары юк иде. Ташны алгарак чыккан тазарак, озынрак буйлылары атты. Арттарак торган икенче ирләр, тире капчык сыман савыттан таш алып, атучыга биреп торды. Таш күтәреп килүчеләр арасында хатын-кызлар да күренде. Кайберәүләр кәмә тирәсендәге кешеләргә төзәп сөңге ыргыттылар. Кайберәүләр, кыюраклар, озын колга башында чыртлап янган утларын югары күтәреп, башкалардан узып, кәмәләргә якын ук килергә азапландылар.

Лелег ирләре калканнары белән сакланып һәм боерык булганны көтеп, тынычсыз бер кыяфәттә басып торуларында булдылар. Боерыкны Тини бәк бирергә тиеш иде. Тини бәк исә һич тә боерык бирергә ашыкмый сыман тоелды. Кыргыйларның ташлары, сөңгеләре лелеглэрнең аяк астына килеп төшә башлады, бер-ике таш шакылдап җиз калканнарга килеп тиде һәм шул чакны чыңлап җиз тавышы ишетелеп китте.

Ике арадагы киеренкелек соңгы чиккә җитте сыман тоелгач, пир ата, каушап һәм ашыгып:

— Әллә яхшылап сөйләшеп-аңлашып карагамы соң? — диде.

— Кем белән? — диде Тини бәк.

— Кыргыйлар булсалар да, алар да тәңребез Кояш уллары! — диде пир ата, нидер аңлата башлап.

Тини бәк эндәшмәде. Пир атаның кирәкмәгән җиргә килеп кысылуы, бер дә юктан чәпчергә тотынуы аңа бөтенләй ошамады. Шулай да ул каты бәрелмәскә тырышты. Ул туктаусыз кыргыйлар ягын күзәтте. Аларның баштанаяк коралланган лелег ире өчен куркыныч булырдай бернинди коралы юк. Ләкин алар күп һәм ярсулы иде. Аларны җиңәргә, кырып салырга түгел, куркытырга гына кирәк иде.

Ләкин пир ата үзенчәрәк уйлады, ахрысы. Лелегләрнең кузгалмыйча урыннарында нык торуын һәм ниндидер ят кораллар белән кораллануын күреп, ахрысы, таурлар беразга тыныбрак калгандай булдылар. Шул чакны пир ата Гай, кулын күтәреп, озын чәчләрен җилфердәтеп, алгарак чыкты һәм:

— Туктагыз! Сөйләшик, аңлашыйк! — дип кычкырды.

Аның ни әйткәнен, билгеле, тегеләр аңламадылар. Шулай да озын саплы балта тоткан калку ир, алгарак чыгып, нидер кычкырып җибәрде. Ул, ахрысы, үзләренекенә шауламаска кушты — тавышлар тынды, югары күтәрелгән куллар түбән төште. Пир ата, тынлыктан файдаланып, янә үзенең сүзен кабатлады. Аңа җавап сыман итеп, балталы ир тиз-тиз нидер сөйләргә тотынды. Аның тавышында элеккечә янау, куркыту сизелде. Лелегләр берни аңламадылар.

Шул чакны пир атаның аяк янына гына кемдер ыргыткан агач сөңге килеп төште. Ул сискәнеп китте, ләкин куркуын үзенекеләргә дә, кыргыйларга да күрсәтмәскә тырышып сөңгене кулына алды да аның башын караштыра башлады. Сөңге башына юка гына очлы таш беркетелгән иде. «Уйлаган идем мин аны» диде ул, агач сөңгенең серенә төшенеп. Шул ук мизгелдә дип әйтерлек, кәмәләргә якынайган таурлар төркеме артында, еракта тагын да күбрәк булып икенче бер төркем якынаеп килгәне күренде. Болары кебек алар да ерактан ук кычкырып, шау-шу ясап килделәр.

Түземлекләре соңгы чиккә җиткән ирләр, Тини бәк ягына карап, кайсы ярсып, кайсы ачуланып, кайсы ялварып шаулаша, кычкыра башлады. Тини бәк кулын күтәрде.

— Балталыга атыгыз, балталыга! — дип кычкырды ул.

Ирләр инде үзләре дә күптән шуны уйлап торалар иде бугай — балталыга берьюлы өч-дүрт ук очты. Бал-

талы соңгы мәртәбә кычкырып, авызын зур ачып ава башлады. Ләкин ауганда да ул балтасын кулыннан ычкындырмаска тырышты. Ярым шәрә тәннәргә шап-шоп уклар барып тия торды, кыргыйлар ямьсез тавышлар белән кычкырып, куркып, котлары алынып кире чабыша башладылар. Ук тигәннәр укларын ботларыннан, корсакларыннан тартып алмакчы булдылар. Кайберәүләр ите-ние белән тартып алды, ләкин хәле бетеп шундук җиргә ауды. Кайберләре кадалган угы-ние белән качарга тырышты, ләкин ерак китә алмады — барыбер җиргә капланды яисә авыртуга чыдый алмыйча бөгәрләнеп сызланырга, тәгәрәргә тотынды.

Таурлар аркалары белән борылгач та, Тини бәк атуны туктатырга кушты. Ирләр җәяләренә яңадан ук тутырып көтә башладылар. Тини бәк тә көтте. Ул качучылар белән якынаеп килүчеләрнең ничек итеп очрашуларын көтте. Алар очраштылар һәм нәкъ Тини бәк күз алдына китергәнчә диярлек, таурларның ике төркеме арасында ыгы-зыгы, буталыш китте. Качып баручылар үзләренә ярдәмгә килүче кан кардәшләренә нидер аңлатырга тырыштылар. Тегеләр аңларга теләмәде. Бик каты шаулашып, куркытып, янап качучыларны кире бордылар һәм алар элеккедән дә күбрәк, дәһшәтлерәк булып яңадан кәмәләргә якыная башладылар. Алар якынайдылар, бик нык якынайдылар. Аларга каршы тагын атарга туры килде. Бу юлы бик күп атарга туры килде. Үтерелгән бик күп кешеләрен һәм тагын бер балталы юлбашчыларын калдырып кыргыйлар качып киттеләр.

Шул китүдән киттеләр һәм бүтән килмәделәр. Алар каядыр үзәннең көнчыгыш ягынарак күченделәр, ахрысы, кайчагында анда, еракта төтеннәр күренде. Ни генә булмасын, өч ел буена якын тирәдә бер генә таур да очрамады. Бары өч елдан соң гына, язгы ташу узгач, аргы яктагы тал-камыш араларында, күл буйларында, калкулык буйларында нидер эзләнеп, җыеп йөргән, нидер тотып йөргән кыргыйлар күзгә чалына башлады.

Аларның күбесе хатын-кызлар, балалар, картлар иде бугай. Болар теге елны Кояш уллары белән бәрелештә кырылып бетә язган кабилә калдыгы иде микән, әллә соң башка кабилә иде микән, ерактан күзәткәндә моны белерлек түгел иде. Ни генә булмасын, алар үзәнгә яңадан килделәр. Хәзер инде аеруча сак һәм уяу булырга кирәк иде. Тик шулай да таурлар хәзер елгага йә булмаса турага, Ак манара үзәненә якын килергә батырчылык итмәделәр. Елга үзеннән-үзе ике арадагы чик сызыгына әверелде.

Кыргыйлар җылы айларда гына вак-төяк җәнлек, кошкорт аулап, анда-монда эзләнеп көн үткәрделәр дә, суыта башлау белән, яңадан таулар ягына китеп бардылар. Анда аларның авыллары-фәләннәре бар иде микән — беркем бернәрсә белмәде. Менә быел да алар бер-ике айдан үз якларына кайтып китәргә тиешләр һәм шул чагында бөтен тирә-як тынычланып, иркенәеп калырга тиеш иде.

Шулайрак дип уйлаштырып йөргән бер вакытта көтелмәгән бер хәл булды. Беркөнне кичкә таба атка атланып, балтачылар яныннан кайтып килгәндә, пир ата Озын сырт өстендә, сукмакка якын бер җирдә, ярым шәрә бер таурны күреп телсез-өнсез калды. «Ничек? Нишләп алай?» дип уйлады ул, шундук гаҗәпләнеп. Бит аларның күптән инде бу якка аяк басканнары юк! Кем бу? Нишләп йөри бу? Ялгышып чыкканмы, әллә... бүтән кабилә кешесеме ул? Пир ата балтачылар янында чагында... үзәнне әллә ят кабиләләр басып алганмы, тәңрем-аллам?!

Куркып-каушап, пир ата билендәге хәнҗәрен барлады һәм җир өстеннән нидер эзләгән кыргыйдан күзен алмыйча, атын кызулый төште. Тояк тавышы ишетеп кыргый кинәт билен турайтты, пир атага борылып карады һәм, коты алынып, бар көченә кычкырып җибәрде. Пир ата бик кыска вакыт эчендә аның куркынган йөзен, зур ачылган күзләрен, тырпайган кара чәчләрен һәм бөтен килеш-килбәтен күреп алды. Ул аңа яшь һәм таза күренде. Озын сырт өстенә килеп менгән бу кыргыйга күп булса унтугыз-егерме яшь булырга тиеш иде. Моңарчы ул хәтерендә калдырган таурлардан аермалы буларак бу таур төз һәм озын гәүдәле иде. Аның оятлы җирен каплаган тире кисәге кыскарак һәм җыйнаграк иде. Беренче очрашуда ук боларның барысы да пир атага ничектер шикле тоелды. Ләкин бу хакта ул озак уйланып тора алмады. Коты алынган кыргый үзенә якынаеп килгән атка һәм ат өстендәге кешегә сихерләнгән кебек карап торгандай итте дә куркынган ямьсез тавышлар чыгарып йөгерә башлады. Ләкин ерак китә алмады, нәрсәгәдер абынып егылды, ыңгырашып җиргә ауды.

Пир ата боларның барысын да күреп-күзәтеп калды. Аны хәзер тыелгысыз бер кызыксыну биләп алды. Атыннан төшеп, атын наратка бәйләп, ул вак куаклар арасыннан түбән төште, җирдә ыңгырашып, бөгәрләнеп яткан кыргыйга беравык карап торгандай итте дә, иелеп, аны икенче якка әйләндерде. Ялгыш басып таур аягын имгәткән иде бугай. Сул як тезе аның ташкамы, агачкамы бәрелеп күгәреп чыккан, яраланган, ярасыннан кан

сыркып тора. Яра эзләре кыргыйның кулында, аркасында да бар иде.

Пир ата аны аягына бастырырга итеп карады. Пир атаның кулы тәненә тию белән кыргый авыртынган сыман кычкырып җибәрде, ыңгырышты һәм аксый-аксый качып китәргә азапланды. Ләкин бер-ике адым атлагач та, кычкырып җиргә егылды.

Пир ата як-ягына каранып алды, елга аръягына каранды. Якын-тирәдә беркем күренмәде. Аны монда калдырып китсәң, яңадан аягына баса алырмы ул, юкмы? Әллә төнлә ерткычларга азык булырмы? Нишләтергә соң моны? Ташлап китсәң, бу кансызлык булачак, алып кайтсаң? Ничек итеп? Пир атаның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Уйлана торгач, ул тиз-тиз генә аты янына килде дә, ашыгып, Ак манарага өенә кайтып китте. Бераздан ул үзе белән ике-өч таза ир алып килде. Җир өстендә ыңгырашып яткан кыргыйны алар күтәреп үзләренә алып кайттылар.

Ак манаралы таш өенә алып кайткач, пир ата яралы кыргыйны башта җылы су белән юындырды, коендырды, аннан соң имгәнгән аягына дару мае катыш чыршы пешеге сыланган әрекмән яфрагы каплады, бәйләп куйды, яраларына ачу ташы кырып салды, шулай ук бәйләп куйды да яралы өчен тышкы ишек янындагы бер бүлмәне тазарттырып, иске-москыдан арындырып, шунда урын-җир әзерләргә кушты. Яралыны карап-күзәтеп торырга үзенең бер кешесен билгеләде.

— Бигрәк зурдан кубып йөрисең, — диде карчыгы, аның бу эшен бик үк ошатмыйча. — Әллә шуны өеңдә асрамакчы буласыңмы?

— Аягына басканчы торып торсын, — диде пир ата.

— Күзе уттай янып тора! — диде корткасы яратмыйча. — Бер дә ошамый ул миңа.

Пир атаның корткасы белән сүз көрәштереп торасы килмәде. Шулай да ул аның бу сүзләрен күңеленә салып куйды һәм яралы таур янына кергәндә аның йөзенә, үз-үзен тотышына игътибар белән рәк карый торган булды. Баштарак кыргый таур бар нәрсәгә куркып, шикләнеп карады, янына кем килсә дә, таяк күргән эт кебек шыңшып почмакка посарга тырышты. Аңа, билгеле, беркем дә сукмады. Киресенчә, аңа ашарга-эчәргә бирделәр һәм ничек тә аны дәваларга, аякка бастырырга тырыштылар. Күрәсең, ул үзе дә моны аңлап алды һәм ике-өч көннән мондагы ят кешеләргә, ят нәрсәләргә, ят тәртипләргә ияләнә төште.

Ул үзен Нарис дип атады. Бар нәрсәгә ул исе китеп

карады. Пир атаның өстендәге киндер киемен, билбавын, савыт-сабаларны, җиз-көмеш әйберләрне тотыптотып карады. Аның алай тотып каравына артык каршылык күрсәтмәделәр, шулай да пычак, хәнҗәр ише очлы, үткер нәрсәләрне яшерергә тырыштылар. Ике аягында басып, таяк белән йөри башлагач, беркөнне пир ата аны бакчага алып чыкты. Бакчадагы куакларга, аллы-гөлле чәчкәләргә Нарисның әллә ни исе китмәде. Ул бары шалкан, торма, кишер кебек яшелчәләрнең тигез түтәлләрдә күп булып, эре булып үсүенә генә гаҗәпләнде. Басуга алып баргач һәм шулай ук күп булып, тигез булып үсеп утырган арпа, тары кишәрлекләрен күрсәткәч, аның гаҗәпләнүе тагын да көчлерәк булды. Кыргый урманнарда, болыннарда, су буйларында аның кишер, торма кебек яшелчәләрне дә, куе үлән арасында үсеп утырган бөртекле ашлыкларны да күргәне бар иде, ахрысы. Ләкин аның әле җир өстенең, ташлар, агач тамырлары, сөяк-санаклар белән чүпләнгән каты җирнең тигез итеп йомшартылуын, эшкәртелүен күргәне булмаган, ахрысы. Басуга, басудагы авыр башаклы күп, бик күп арпаларга, тарыларга ул бик озаклап карап торды. Пир ата аңа кишер, шалкан алып бирде, арпа уып күрсәтте. Ашап карагач, Нарис шатлыгыннан көлеп җибәрде.

Пир ата Нарисны көн дә бакчага, басуга алып чыга башлады. Ике арада дуслык сыман бер якынлык урнашкач, ул аннан теге-бу нәрсәнең таурча исемнәрен сорады. Шул ук вакытта ул андый әйберләрнең лелегчә исемнәрен әйтергә дә онытмады. Сүзләр, исем-атамалар турында сөйләшү Нариска тагын да кызыграк тоелды. Иң гаҗәбе шул булды: Нарис бераз лелегчә аңлый булып чыкты. Шулай бер-берсеннән сораштыра торгач, пир ата да, Нарис та үзләре өчен күп кенә яңалык белделәр.

Нарисның өзек-өзек сүзләреннән, ишарәләреннән пир ата Гай кайбер нәрсәләр аңлады. Таурлар күп, бик күп икән. Алар кайдадыр тегендә — төньякта — таулар, урманнар арасында яшиләр икән. Аларның да анда пир атаныкы кебек тора торган «тау»лары бар икән. Ләкин ул «тау» пир атаныкы кебек таштан түгел, агачтан өелгән икән. Агачтан өелгән ул «тау»да аларның аллалары тора икән. Агачтан өелгән «тау»ның эче куыш, куыш уртасында өзлексез ут яна икән. Аларның алласы... пир атага охшаган икән, тик ул аннан яшьрәк, көчлерәк һәм кансызрак икән. Утны ул теләсә кемгә бирми, ут сорарга килгән таурлардан болан, поши сорый, кызлар сорый икән. Ак «мамык» яисә «чүп» ява башлагач, алла үзенең

тавы эчендә, ут-учак янында ашап-эчеп, күңел ачып кына утыра икән. Кирәк булса, янына кызлар чакыра, кызлар исә аны яратып, иркәләп кенә торалар, шул ук вакытта учактагы утны да сүндермичә, әледән-әле аңа «ашарга» биреп торалар икән. Югарыдан ак «чүп» коелып, көннәр суыта башлагач, таурлар үзләре дә тау куышына кереп качалар икән. Аларның анда алланыкыннан да зуррак, иркенрәк куышлары бар икән.

Кайдадыр шушы якта, урман-таулар арасында тере «алла»булуы, җитмәсә, аның үзенә охшаш булуы турында белгәч, пир ата шактый уйга калды. Ул Наристан кат-кат сорады, төрлечә аңлатып сорады. Нарисның «алла»дигәне чын булырга охшый иде. «Алла»дигәч тә ул күккә, югарыга төртеп күрсәтте һәм аны үз телендә «Ни»дип атады. Читтәге, ерактагы җирләрдә кайбер кыргыйларның Аклан иле кешеләрен «алла» дип белүләре, олылаулары, алар алдында куркып, кан калтырап торулары турында пир атаның элек тә ишеткәне бар иде. Кояш уллары — лелегләрнең һәр эше, һәр кыланышы, кораллары, киемнәре — һәрнәрсәсе кыргыйларда соклану, гаҗәпләнү һәм курку тудырганга һәм төсләре-битләре белән, тән төзелешләре белән үзләреннән камилрәк булганга лелегләрне алар чыннан да алла улы, Нун улы дип исәплиләр иде булса кирәк.

Нарис сөйләгән таурлар алласы чыннан да тач үзенә охшаган иде микән, әллә соң барлык лелегләр кебек үк башка бер кеше иде микән — пир ата аңлый алмады. Сорап-сорап караса да, Нарис аның соравын төшенеп җитми иде. Пир ата да артык төпченмәде. Кемгә генә охшаган булмасын, ул «алла» лелег яисә лелег сыман булырга тиеш. Ул кыргый түгел! Менә нәрсә борчуга салды пир атаны.

Каян килгән, ничек барып эләккән ул анда таурлар арасына? Таулар, үзәннәр арасында таурлар күп булгач һәм ул «алла» аларны шулай үзенә буйсындырып, куркытып тора алгач, көннәрдән бер көнне ул монда, диңгез буена, үзе кебекләргә яу белән килмәсме? Дөрес, таурлар әле күп нәрсәне белмиләр, әлегә алар сабый бала кебек. Ләкин көтмәгәндә, искәрмәгәндә килеп бассалар яисә басуларга, алачыкларга ут төртеп китсәләр? Яисә, көтүчеләрне үтереп, барлы-юклы көтүләрне, атларны куып китсәләр? «Алла»лары акыллы булгач, акылсыз кыргыйлар да талап, кырып сала алачаклар.

Дөрес, моңарчы ул серле «алла» лелегләргә бернинди кырап-талау салмады, хәтта үзенең барлыгын-юклыгын да сиздермәде. Диңгез буена ят кешеләр килеп ур-

нашуын белмәгәндер дип әйтеп булмый. Бәлки, аңа теге елны беренче көнне үк хәбәр иткәннәрдер, бәлки әле кыргыйлар өерен ул җибәргәндер монда кәмәлеләргә каршы сугышырга... Ни генә булмасын, мондагы яңа хуҗаларны ул белергә тиеш. Димәк, ул үзе курка алардан... читтән килүчеләрдән. Бәлки әле, ул Нарис әйткәнчә үк усал да, кансыз да түгелдер. Нишләтергә аны — тотып алып, оясын туздырыргамы, «алла» мин дип, кыргыйларны алдап ятканы өчен таш белән бәргәләп үтерергәме?

Шулай. Сораулар күп. Тик әлегә җавап кына юк. Бер җавап та юк. Уйланасың килмәсә дә уйланырсың монда! Нарис нәрсәнедер яшерә иде кебек. Ул үзенең монда ничек килеп чыгуын, нишләп бөтен тәне яралы булуын да аңлата алмады...

Нарис белән ныклап торып аңлаша, аралаша торгач, пир ата чын-чынлап йокыдан калды. Элеккечә ул иртүк торып чишмә буена да төшеп китмәде, бакчага да чыкмады, хәтта балтачылар янына да бармады. Йомыш белән килгән кешеләргә ул үзе турында «авырып тора» дип әйтергә кушты. Әлегә ул беркем белән дә киңәшә алмады. Кем белән дә булса киңәшү өчен иң элек аның үз фикере булырга тиеш иде кебек. Менә шулай ачык кына бер уйга килә алмый йөргән бер вакытта тагын бер көтелмәгән хәл булды.

Бу көннәрдә күбрәк теге «алла» һәм күсәк күтәреп шаулашкан кыргыйлар өере турында уйлап тынычсызланса да, пир ата үзенең яңа танышын да исеннән чыгармады. Көн дә аңа Нарисның яңадан-яңа шуклыклары турында кереп әйттеләр. Беркем дә күрмәгәндә, ул таш бәреп бер тавыкны үтергән икән дә шундук йолкып ашарга да азаплана башлаган икән. Икенче мәртәбәсендә бакчадагы тормаларны, кишерләрне йолкып, үз оясына алып кергән икән дә, юып-нитеп тормыйча, төне буе кишер кимереп чыккан икән.

Мондый гына нәрсәләр өчен пир ата Нарис белән бозылышмаска булды. Шул ук вакытта Нарисның киләчәк язмышы аны борчый башлады. Аягы ныклап торып төзәлгәч нишләтергә аны — монда калдырыргамы, әллә каян килдең, шунда кайт дип чыгарып җибәрергәме? Аның иң дөресе, билгеле, шул булыр иде. Бит ул аны сатып та алмады, яулап та алмады. Ул аны хәтта тапмады да. Ул аны бары имләү өчен генә алып кайтты. Ләкин үз кешеләре янына кайтып китсә, ул монда күргәннәрен сөйләмәс дип кем әйтә ала? Сөйләсә дә ул иң элек «алла»ларына сөйләячәк. «Алла»нәрсә уйлый, ничек хәл

итә бит әле! Аның нинди кеше икәнлеген белми торып, ничек итеп аңа мондагы серләрне чишәсең? Якында гына зур кәмә төзелеп ята, инде икесе суга төшәргә әзер тора. Авыллар киртәләп алынмаган, кирәкле җирләргә тиешле сакчылар куелмаган, куелганнары уяу түгел. Басу тулы өлгергән иген.

Эх, ялгышты, ахрысы, пир ата Гай йомшаклык күрсәтеп. Берни күрмәгәндәй узып китәсе иде теге көнне Озын сырт өстеннән барганда. Имгәнгән икән имгәнгән. Үзе егылган еламас. Каян килсә шунда китеп барыр иде әле. Хәер, әле дә соң түгел бугай. Аягын-кулын бәйләргә дә, муенына таш асарга да ташларга Симет елгага! Кем эзләп торсын аны?!

Пир атаның күңеленә әледән-әле шундыйрак уйлар килде. Ләкин, бу турыда ныклап уйлана башладымы, ул үзенең мондый эшне эшли алмаячагын аңлады. Тора салып, бер гаепсез кешене үтерү ул язык иде, моның өчен аллалар, билгеле, аның башыннан сыйпамаслар, бу дөньяда ук тиешле казасын бирәчәкләр иде. Ни генә булмасын, бу турыда ул ил агасы белән киңәшергә тиеш иде кебек.

Төн урталарында йоклый алмыйча боргаланып ятканда, бу аның иң соңгы уе, карары булды. Иртән таң атар-атмас борын аны төнге кизүләр килеп уяттылар. Төне буе манара башында кораллы кизүләр тора иде. Кизүләрнең өчесе йоклаганда, берсе уяу булырга һәм тирә-якка колак салырга, җиргә төшеп ишек капкаларны карап йөрергә тиеш иде. Ләкин, пир атаның йомшаклыгыннан файдаланып, кизүләр төн уртасына кадәр генә уяу булалар да төн уртасыннан соң дүртәүләшеп йокы симертәләр иде.

Таң алдыннан уяу булырга тиешле кизү шулай да уянып киткән һәм соңлап булса да җиргә төшкән, тышкы якка чыгып әйләнеп килмәкче булган. Шул чакны ул олы капканың ачыклыгын күреп алган. Күреп алган да коты алынып пир ата янына йөгергән.

Кемнең капканы ачык калдырып чыгып китүен тикшереп торуның кирәге дә юк иде. Бу бары Нарис эше генә булырга мөмкин иде. Күзен ертып аягына басу белән, пир ата иң элек баскыч янындагы бүлмәгә күз салды. Наристан җилләр искән иде.

— Киткән. Үзе киткән! — диде пир ата, җиңел сулап.

Ул инде тынычлап, яңадан җылы бүлмәсенә кереп ятмакчы да булган иде. Шул чакны күңеленә бер уй килде. Бара торган җиреннән кире борылып, ул тар гына аралыктан берничә адым атлады да икенче бер бүлмәнең

ишегенә барып тотынды. Җиз тотканы кулына алу белән, авыр тәбәнәк ишек, таныш шыгырдау тавышы чыгарып, җиңел генә ачылып китте. Бүлмәдә пир атаның эш кораллары, өф итеп кенә тора торган төрле кирәк-яраклары саклана иде. Бүлмә ишеген ул һәрвакыт бикле тота иде. Ишек ачык. Димәк, ул аны онытып бикләми калдырган яисә аны... ачып кергәннәр!

Мондый коточкыч уйдан пир атаның шундук йокысы качты. Кем ачарга мөмкин аны? Өйдә сорамыйча аның ишеген ачардай кеше юк. Кыргый таур... кыргый Нарис теләсә дә ача алмаячак. Ишек бигенең йозагы катлаулы. Аңа ачкыч яратып булмый, шулай ук аны каерып та ачып булмый. Булмаска тиеш. Ләкин әнә ул ачык. Йозагы да ватылмаган, күгәнен дә каермаганнар. Ничек ачканнар аны?!

«Күрәсең, бикләргә онытканмындыр» дип уйлады пир ата, үз-үзен тынычландырып, һәм ярым караңгы бүлмәгә таба атлады да, кораллары саклана торган шүрлеккә күз ташлады. Беренче караудан ук ул ике яклы җиз балтаның юклыгына игътибар итте. Кыяктай үткер йөзле, кояштай ялт итеп торган җиз балтасын ул шүрлеккә кагылган җиз кадакка сабыннан элеп куйган иде. Ул анда эңгер-меңгердә дә балкып, ялтырап күренеп торырга тиеш иде.

Балтасының юклыгын күреп, пир атаның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Билгесез бур коралларның берсенә дә кагылмаган, шул балтаны гына алган, күз карасыдай саклап, чәч пәкеседәй гел үткерләп кенә торган кадерле балтаны гына алган. Аның, билгеле, балтасы бер генә түгел, ләкин ике яклысы, изге артыш агачыннан ясалган, өстенә сырлап, матурлап көмеш калай беркетелгән балтасы бер генә иде. Андый балтаны тиз генә ясап та булмый, ясасаң да, ул инде анысына, беренчесенә охшамаячак. Ул балта белән ул тегендә бик күп эшләр башкарды, ул балта аның яшьлек истәлеге дә иде.

Пир ата яңадан урынына кереп ятты һәм шул ятудан тора алмады. Корткасы төпченә башлагач исә әйтте:

— Син дөрес әйткәнсең, — диде. — Теге кыргый... бер балтамны алып качып киткән, — диде.

«Ике яклы җиз балтамны» дип әйтергә аның теле бармады.

— Бер балта күп түгел, — диде корткасы, үзенчә нәтиҗә ясап. — Ярый әле котылганбыз. Ярый әле бөтенебезне суеп чыкмаган. Беренче күрүдән үк шикле тоелганые аны...

— Шулай шул, — диде пир ата, күндәм генә.

Корал бүлмәсенең серле рәвештә ачылуы турында да, ике яклы җиз балтасының югалуы турында да пир ата Гай беркемгә дә әйтмәскә булды. Корткасына исә әйтеп куйды:

— Синең авызыңда сүз тормый. Бу хакта ләм-мим! — диде һәм ышандыргычрак булсын өчен өстәп куйды: — Беләсеңме, аллалар эше булырга тиеш бу, — диде. — Кыргый дигәнебез дә кыргый түгелдер әле, изгеләр илчеседер. Әйттең бит, күзе уттай янып тора, дидең.

Аллалар, изгеләр турында сүз чыккач, кортка шым булды. Аллаларга да, изгеләргә дә ул берсүзсез ышана иде һәм, аягы ныграк сызлый башлаган саен, изге ияләргә багышлап корбан йә садака бирү ягын карый иде. Пир ата, аллаларга, изгеләргә тел тидермәсә дә, бу мәсьәләдә үзенчәрәк фикер йөртә иде. Аныңча, дөньяда кеше үзе алла. Кыргыйларны алдап, куркытып, үзен алла дип күрсәтүче ниндидер оятсыз, ялганчы «алла» түгел, бәлки башкачарак алла иде. Кешенең кулыннан килмәгән эш юк. Ләкин кеше аллаларның, изгеләрнең серен әлегә белеп бетерми. Аллалар серен белеп бетерү мөмкин дә түгелдер, бәлки. Ләкин туктаусыз аны белергә, өйрәнергә кирәк, аллалар сере, нигездә, җирдә кешенең тормышын җиңеләйтергә, ачлыкны, хәерчелекне бетерергә, чир-чорларны, авыруларны юкка чыгарырга кирәк. Аллалар, изгеләр башкара алган эшләрне башкару теләсә кем кулыннан килми, билгеле. Ләкин аллалар һәм изгеләр санаулы гына булган кебек, аларның серенә төшенүчеләр дә күп түгел. Бик үк кычкырып әйтмәсә дә, күңеленнән пир ата үзен шундый серләрне төшенә башлаучыларның берсе дип исәпли иде. Моның өчен аның кайбер нигезе дә бар иде.

Менә шул рәвешчә төрле фәлсәфи уйларга бирелеп, шулай да бөтен тәнендә, кул-аякларында авырлык һәм хәлсезлек тойган хәлдә, ул өч көн буена чын-чынлап урын өстендә ятты. Пир ата Гайның болай сырхаулавы бик сирәк була торган иде. Бер-ике мәртәбә корткасы, пошынып:

— Әллә турага кеше җибәрикме? — диде.

— Җибәрмик әле, үзем торырмын, — диде пир ата.

Чыннан да дүртенче көнне ул аягына басты һәм теге вакыттагы кебек таң атар-атмас корал бүлмәсенең ишеген барып карамакчы булды. Моннан өч көн элек ишекнең ачыклыгын һәм ике яклы җиз балтасының юклыгын белеп, йөрәгенә тотынып, урынга барып яткан мәлдә, ул куелган җиреннән ишек ачкычын барып тикшереп карарга да, ишекне яңадан бикләп куярга да оныткан

иде. Соңгы көндә ишек шул көе ачык торырга тиеш иде. Ләкин иртәнге эңгер-меңгердә алпан-тилпән атлап, таныш ишекнең таныш тоткасын тартып карагач, пир ата аның бикле икәнлеген белде. Аптыраудан пир ата катты да калды. Искәрмәстән маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Егылып китүдән куркып ул аркасы белән ишекнең салкынча таш яңагына сөялде.

«Димәк, мин кузгалмый урында яткан чакта монда тагын кемдер булган!» дип уйлады ул. Хәзер инде ачкычның барлыгын-юклыгын гына ачыклыйсы калды. Теге вакытта ул ачкычын тикшереп карарга оныткан иде. «Каяле, барып карыйм», — дип уйлады пир ата һәм тар караңгы аралыктан кире борылып китмәкче булды. Шул чакны аның аягына ниндидер каты, салкын нәрсә тиеп киткәндәй булды. Пир ата бу көтелмәгән шатлыктан кычкырып җибәрде: аяк астында корал бүлмәсенең ачкычы аунап ята иде!

Ул аны алды, йозакны ачты һәм авыр, тәбәнәк ишекне шыгырдатып корал бүлмәсенә атлады. Биек түшәмле бүлмәгә яктылык югарыдагы тар гына тәрәзәдән төшә иде. Иртәнге эңгер-меңгердә бүлмә эче әле шактый караңгы иде. Ләкин каршыда гына, киң шүрлек кырыена кагылган җиз кадакта асылынып торган ике яклы җиз балтасын күреп, пир ата Гай тораташтай катты да калды. Шулай да ул, күптәнге танышын, якын дустын күргәч, сөенеченнән елмаеп җибәрде. Балтаны үрелеп кулына алды. Таныш сапны тою анда шатлык һәм күңел тынычлыгы тудырды. Ләкин нишләптер аңа балта элеккегә караганда авыррак сыман тоелды. «Нәрсә соң бу, су эчкәнме әллә?» дип уйлады ул үзалдына, шаяртмакчы булып. Ул малай чакта алар кем күбрәк күтәрә ала дип, чирек батманлы шома таш күтәрергә ярталар иде. Шунда һәркемнән көчсезрәк Мөхлис бервакыт ташны кузгаткандай итеп карый да, күтәрүдән баш тартып: «Таш бүген авырайган — су эчкән», — дип куя. Ташны беркем суга да салып куймаган, авырайсын өчен аңа су да китереп сипмәгән. Ул шунда киртә буенда тузанда аунап ята.

Шуннан соң гомергә Мөхлисне малайлар «су эчкән» дип йөрттеләр. Мөхлис моңа, билгеле, кимсенде, аның эче пошты. Аның бик көчле буласы килде һәм ул туктаусыз күнегә торгач, үсә-үсә көч буенча иптәшләреннән көчлерәк тә булды.

Әле дә менә нишләптер пир атаның күңеленә шул «су эчкән» Мөхлис килеп төште. Шулай да аның ике яклы җиз балтасы су эчмәгән иде бугай. Тегәрҗептәй нечкә генә сеңергә бәйләп, балтага ниндидер авыр гына

нәрсә тагып куелган иде. Бу авыр гына нәрсә такта сыман юка, дүрткел һәм озынчарак иде. Аннан соң ул бераз гына йомарлана төшкән, бер ягы шома, икенче ягы кытыршы иде. «Юкә кабыгы түгелме соң?» дип уйлап алды пир ата, серле әйберне төрлечә капшап карагач. Әйе, бу чыннан да калын гына юкә кабыгы иде, ләкин нишләп аны монда балтага элеп куйдылар икән соң? Берберхикмәте булырга тиеш моның!

Пир ата балтаны урынына элеп куйды да, юкә кабыгын алып бүлмәдән чыкты һәм, ишекне бикләп, үзенең йокы бүлмәсенә ашыкты. Ул инде нидер сизенде, нидер төшенә башлады, ләкин әле аның бу турыда үз-үзенә танырга да батырчылыгы җитмәде. Юкә кабыгының шома ягына нидер язылган булырга тиеш иде — бармак бите белән сыйпап карагач, пир ата анда ниндидер тамгалар барлыгын белде. Бүлмәсенә кергәч, ул фил сөягеннән кырып ясалган кабыкчыгыннан зурайткыч пыяласын эзләп тапты һәм калтыранган куллары белән зурайткыч пыяланы да, юкә кабыгын да күзенә якынрак китерде. Кабыкның эчке ягына бары Аклан илендә генә кулланыла торган һәм бары аллага якын изге кешеләр генә белә торган тамгалар төшерелгән иде. Тамгалар кибеп җитмәгән чи кабыкка ниндидер очлы нәрсә белән сызылган. Әллә шуңа күрә, әллә сызучы бик үк оста булмаганга, тамгалары тигезле-тигезсез чыккан, кайберсенең сызыклары кәкре-бөкре булып читкә киткән. Малай вакытында өйрәнгән дә, шуннан соң беркайчан кулына язу каләмен алып карамаган бу кеше... «алла» булырга тиеш дип уйлады пир ата, билгеле бер нәтиҗәгә килеп.

Әйе, бу кабыкны аңа теге Нарис әйткән... «алла» җибәргән. Моның хәзер бернинди сере юк. Язуы да изгеләр — Кояш уллары лелегләр телендә язылган. *«Сине кунакка чакырам. Җәбир»* диелгән язуда. Пир ата Гай язуны катькат укыды. Уңнан да, сулдан да, өстән дә, астан да укып карады. Дөрес, аңлаешлы сүз бары уңнан укыганда гына барлыкка килде. Ничек кенә укып карамасын, юкә кабыгына төшерелгән тамгалар үзгәрмәде дә, юкка да чыкмады. Монда бернинди сихер, күз буу юк иде. «Алла» кулы белән язылса да, моны, әлбәттә, ике аяклы, ике куллы кеше — Җәбир дигән кеше язган иде. Монысы аның бик яхшы аңлашыла иде. Ләкин бөтен хикмәт шунда: «иң аңлашылган» нәрсә әлегә аңлашылып җитми иде.

Пир ата яңадан урынга ятты һәм бик ныклап уйлана башлады. Акланда ул белгән Җәбирләр берничә кеше иде. Аларның берсе яшь, берсе карт дигәндәй, берсе

үсмер, берсе бала гына. Ул белгән Җәбирнең берсе «су эчкән» Мөхлиснең төпчек улы. «Җәбир»дигәндә нишләптер иң элек ул Мөхлиснең шул улын исенә төшерде. Төшермичә, кайчандыр Мөхлис үзе Гайның кодасы, Җәбир исә кияве иде ләбаса! Акланда беренче чибәр Лүчнәнең ире иде. Лүчнә өчен яшьләр ул чакта үзара кыйнашып-канашып беттеләр. Уллары аркасында күп кенә ата-ана үзара бозылышуга, ил-көн алдында бер-берсен хурлауга кадәр барып җиттеләр. Мака сар Карунның тууына илле беренче ел киткәндә, көзге туклыкта Акланның изге аналары Лүчнәне иң чибәр, иң булдыклы кыз дип, Борай ана рәвешендә киендереп тамашага чыгаргач, өч меңлек халык алдында яшьләр ярышы булды. Ук аттылар, атта чаптылар, сөңге ыргыттылар, иң азактан йодрык сугышы булды. Менә шунда «су эчкән» Мөхлиснең улы Җәбир барысын да җиңеп чыкты.

Бала вакытында Мөхлис «су эчкән» кушаматыннан хурланып, кимсенеп яшәгән. Өйләнеп беренче улы Мирзый тугач, аны батыр көрәшче, сугыш чукмары итеп тәрбияләгән. Кече улы Җәбирне тәрбияләргә дә кирәкмәгән, ахрысы. Бала вакытыннан ук ул барысын да күреп, ишетеп, белеп үскән, шуңа күрә теләсә нинди көрәштә, ярышта беркемгә дә алдынгылыкны бирми торган батыр булып җитешкән. Тәнгә таза, беләккә, күкрәккә нык булса да, яшьтәшләре аны хәрәмләшә дип сөйлиләр иде. Кайберәүләр аны күз бууга да маһир икән диделәр. Ярышта җиңүче турында соңыннан шулай имеш-мимеш сөйләргә яраталар инде ул. Ул чакта Мөхлис улы Җәбир турында да имеш-мимеш күп булды. Имеш-мимешнең кайсы ялган, кайсы чын, аны инде хәзер беркем белә алмый. Хәзергә чыны шул: иң соңгы көндәше Коркулны Җәбир бер-ике селтәнүдә үк ушсыз калдырды. Коркул яңагын тотып шундук җиргә ауды. Шуннан соң бер ай буена урында ятты. Бер айдан соң торды, ләкин торганда инде элекке Коркул түгел иде, мескен. Акылга җиңеләеп калды. Диңгезгә дә чыгып карады. Бер карасаң, алышынган кебек, икенче карасаң, тап-таза кеше. Сонышнан бөтенләй юкка чыкты — диңгезгә чыгып киткән җиреннән бүтән кайтмады.

Коркул урын өстендә яткан чагында Лүчнә белән Җәбирнең туе булды. Шәп узды аларның туйлары! Мөхлис бер-ике мәртәбә чит җирләргә йөреп кайтып бик нык баеп киткән иде. Эх! Бар иде күңелле чаклар. Алар бары ярты ел чамасы гына торып калдылар. Пир атаның кияве Җәбирне таш эше дә, балта эше дә тартмады. Аны туктаусыз диңгез котыртып торды. Юк, алай да

түгел, аны байлык, мал, алтын-көмеш, җиз-бакыр тартты! Соңыннан Лүчнә кызы бер ычкындырды: аның кияве Җәбир мака сар кебек иксез-чиксез байлыкка ия булу турында хыялланган икән. Син дөньяда иң чибәр хатын, мин сине алтын белән ябылган биек сарайда яшәтергә тиешмен, синең меңләгән колларың, караларың булырга тиеш, дигән. Күрәсең ул аны чыннан да яраткандыр. Дөрес, үсмер чагында ук ул Талия исемле бер кызны яратып йөргән, ләкин язмыш аларны аерган — им өенә баргач, аны мака сар үзенә алып калган. Әйе, яраткандыр ул Лүчнәне. Яратканда ир кешенең теле ни сөйләмәс?! Аннары яшь кеше, бәхетле кеше. Җәбир алыптай батыр булса да, мактанчык, коры куык һәм бик тиз кызып китә торган тотрыксыз кеше иде.

Кияве Җәбир пир атага баштарак менә шундый җиңел акыллырак, ышанычсызрак булып тоелган иде. Шулай булып чыкты да. Үз көченә ышанып ул үз ишләреннән көтү оештырган, бер-ике кәмә юнәткәннәр дә давыллы бер кичтә диңгезгә чыгып киткәннәр. Киткәндә сер итеп Лүчнәгә әйткән: көтеп тор, мин кәмә тутырып алтын-көмеш алып кайтырмын, дигән. Акылсыз! Тутырып куйганнар ди сиңа диңгез төбендә алтын-көмешне. Шул китүдән китте һәм кайтмады аның башсыз кияве Җәбир. Алар, ахрысы, Акай ягында очраган бер кәмәләрне талап, юлбасар булып йөргәннәр. Акайлар беләнме, кәмиләр беләнме сугышта кырылып беткәннәр, ахрысы. Әллә соң каты давылга эләктеләр микән? Төрлечә сөйләделәр соңыннан. Бер-ике кешеләре кире кайтты. Алар бер төрле сөйләде, Акланга килгән чит ил диңгезчеләре икенче төрле сөйләде. Ни булса булды, Җәбир юкка чыкты. Тол булып утырган чибәр апа Лүчнәгә Тини өйләнде. Өйләнеп күп тә тормадылар, мака сар аларны илләре-көннәре белән читкә сөрде. Ах, гомер! Барысы да күз алдында, йөрәк түрендә.

Шулай да кем ул, нинди ул таурлар арасында яшәп ята торган Җәбир «алла»?

Күпме генә уйланмасын, пир ата Гай әлегә моның серенә төшенә алмады, киләчәктә нишләргә тиешлеген дә ачык кына күз алдына китерә алмады. Киңәшмичә торып монда берни хәл итеп булмый иде, әлбәттә. Ләкин пир ата киңәшергә дә ашыкмады. «Алла» кеше беренче кияве булып чыкканда, икенче кияү нәрсә әйтер дә, аның яраткан хатыны нәрсә әйтер? Алар гына түгел, пир ата үзе дә ни әйтергә, ни кылырга тиеш? Бөтенесе ачыклананитә калса, шундый авырлык белән җайланган яңа тормыш көтмәгәндә баш-аяк килеп чәлпәрәмә килмәсме?

Пир ата Гай бер-ике көн уйланып, икеләнеп йөрде. Ул арада ашыктырган сыман әле анда, әле монда таурлар күренә башлады. Аларны хәзер елганың теге ягында да, бу ягында да, Озын сырт өстендә дә, иген басуында да күрә башладылар. Каралар пошаманга төште, пир ата Гай исә эчтән сызды. Ил агасын үз янына чакырырга аның бернинди хакы юк иде, әлбәттә. Ул авыруга сабышты. Кияве Тининең авыру бабасы янына килми калганы юк иде әле.

Атларын янәшә атлатып, Озын сырт өстеннән таулар ягына барганда, пир ата ил агасына соңгы көннәрдә булган хәлләрне сөйләде. Ул күбрәк Нарисны очратуы, өенә алып кайтуы, Нарисның искәрмәстән юкка чыгуы турында сөйләде. Монда да ул әлегә кайбер нәрсәләрне әйтмәскә кирәк тапты. Тини ага озак кына эндәшми барды. Аның өчен хәзер бабасының чирле түгеллеге тагын да ныграк ачыкланды. Тора баштан шулай ил агасын чакырып ятуы, әлбәттә, аның кытыгына тиде һәм әле булса шул кире тойгы ике арада җылылык, якынлык тууына киртә булып тора иде бугай.

— Шул кыргыйлар белән булашуың бер дә ошамый миңа, пир ата! — диде ул бераздан, шактый коры итеп.

— Ошамыйдыр инде, — диде пир ата, килешкән сыман итеп. — Шулай да син онытасың: синең белән без кыргыйлар җирендә яшәп ятабыз түгелме соң?

— Кыргыйлар җирен без яулап алдык. Хәзер бу безнең җир, — диде Тини ага, үзсүзле пир атаның билгеле нәрсәне искә төшерүенә эче пошып.

— Шулайдыр, улым, — диде пир ата, тагын да күндәм генә. — Кыргый да кеше. Кыргый булган өчен генә, очраган бер таурны чәнчеп китеп булмый.

— Кешесен кеше, ләкин кыргыйны кыргый алла яраткан! — диде Тини ага, мыскыллы көлемсерәп.

— Яратуын яраткандыр, — диде пир ата, янә дә килешкәндәй итеп. — Таурларның чын «алла»лары... кыргый түгел икән шул!

Тини ага берни аңламады, шулай да тынып, сагаеп калырга мәҗбүр булды. Андагы бу үзгәрешне пир ата Гай шундук сизеп алды һәм серле, тантаналы бер өстенлек белән:

— Аларның «алла»ларымы, агаларымы... безнең кеше икән! — диде.

Тини ага болай да тыелып кына барган атын тагын да тыя төште һәм аптырашлы, сораулы күз карашы белән бабасының йөзенә текәлде. Бу көтелмәгән яңалык аңа чын-чынлап аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Пир ата да атын әкренәйтте.

Ил агасы Тини киявенә соңгы көннәрдә булган яңалыкларны түкми-чәчми сөйләп бирде. Ул бары аңа таурлар «алла»сының Җәбир исемле булуын әйтмәде дә, аның нинди Җәбир булуы ихтималы турындагы үзенең шикләнүләрен генә әйтмәде.

Көтелмәгән хәбәрләр ишетеп, чит һәм кырыс кыяфәтле ил агасының йөзе шундук уйчанланып, җитдиләнеп калды.

Алар хәзер сөйләшмәделәр һәм атларын әкрен генә атлатып юлларын дәвам иттерделәр. Озын сырт өстендә як-якта төз кәүсәле биек наратлар, чыршылар утырып калды. Озын сырт өстеннән салынган сукмак бераздан уңга каерды һәм түбән төшә башлады. Күп тә үтмәде, аста, яшел урман арасында, көмештәй ап-ак булып, елтырап агып яткан елга, елга буенда тар гына тигезлек һәм тигезлекне тутырып яткан агач-таш, озын-озын бүрәнәләр янында кайнашкан кешеләр күренде. Урмандагы, тирә-яктагы өзлексез кошлар чыр-чуын, кортлар безелдәвен күмеп, балта тавышлары, өзек-өзек кеше тавышлары күмеп китте.

## IX

Талияне мака сар алып калганнан соң, Җәбиргә дөньяда яшәүнең бөтен кызыгы бетте. Аның бернәрсәгә күңеле ятмады, нишләптер беркая китәсе дә килмәде. Менә шулай икеле-микеле йөргәндә, энисенең, җиңгәсенең үзара сүзеннән ул үзе өчен бик тә кызык бер сүз ишетеп калды.

Күршедәге Чүлмәкчеләр бистәсендә Лүчнә дигән чибәр бер кыз бар икән. Буе җиткән, кияүгә бирер вакыт җиткән, ләкин атаклы чүлмәкче Гай чибәр кызын кемгә бирергә дә белми икән. Ни өчен дигәндә, бистәнең яшьләре үзара сугышып-бозылышып беткәннәр икән, хәзер шуңа өлкәннәр дә кушылып киткәннәр икән. Болай булса, көрәш уздырмый хәлем юк дип әйтә икән атаклы чүлмәкче Гай.

Бу турыда Җәбир агасыннан да ишетте.

— Әнә, күршеләрдә Лүчнә дигән кыз үсеп җиткән, ди. Тырай тибеп, теләсә кайда селкенеп йөргәнче, шул кызны алып кешечә яши башлар идең, — диде агасы Мирзый, уенын-чынын бергә кушып.

Мондый сүз ишетеп, Җәбирнең йөрәге сулкылдап тибәргә тотынды, күзләре уттай янды һәм битенә, колак очларына кызыллык чыкты.

— Аны бик чибәр диләр шул, — диде ул, күтәрелеп карарга кыймыйча.

— Чибәрдән куркасыңмыни? — диде абзасы, көлеп, беркадәр мыскыл белән. — Курыкма! Курыксаң, җиңгәңә әйт, ул сине өйрәтер, — диде агасы, авызын ерып.

— Мин беркемнән курыкмыйм! — диде Җәбир, усалланып.

— Лүчнәдән түгел, үзең ишеләрдән курыксаң да ярый, — дигән булды абзый кеше.

— Алардан да курыкмыйм! — диде Җәбир. — Мин дуңгыз кебек көне-төне балчыкта аунамыйм. Бер суксам, мин аларның чүлмәкләрен чәлпәрәмә китерәм!

— Менә-менә, шулай кирәк, улым! — диде читтән генә тыңлап торган этисе, кече улын мактап. — Күптән мин синең авыздан шундый сүз чыкканын көттем. Болай булгач бөтен Акланга даның таралыр, алла боерса.

— Чүлмәкче Гайның Лүчнәсен дә алып кайтырсың! — дип кыстырды абыйсы, энесен үсендереп.

Ул вакытта алар арасында шундыйрак сүз булды. Икенче көзне чүлмәкчеләр бистәсенең тау буенда, яшел болында көрәштә Җәбир чүлмәкчеләрнең иң батыр егете Коркулны җиңеп батыр калды һәм ике бистәдә генә түгел, бөтен турада иң чибәр Лүчнәне үзләренә алып кайтты. Ул вакытта бөтен Аклан гөж килеп торды. Барысы да Җәбирне мактадылар, Лүчнәне мактадылар.

Әтисе аңа үз торагы янында тәбәнәк кенә, кысан гына таш куыш әмәлләп бирде, кирәкле савыт-саба, азык-төлек, тегесен-монысын бирде. Менә шунда алар яшь чибәр хатыны белән ярты ел чамасы тордылар. Җәбир, көн дә этисе белән балтасын күтәреп ерактан килгән салларны сүтәргә, йә булмаса бүрәнә юнарга, такта ярырга эшкә китте. Кич арып-талып үз өенә кайтты, сөекле хатынын кочты, яратты, бөтен аруы, талуы юкка чыкты.

Ләкин озакламый мондый тормышның да кызыгы юк сыман тоела башлады. Зәңгәр диңгез, яр буенда чайкалган кәмәләр, ят илләр һәм кайдадыр күк белән җир арасында кояш сыман асылып торган сихри сарайлар, манаралар ымсындыра башлады аны. Чиксез байлыкка, алтын-көмешкә һәм затлы ташларга ия булу турындагы хыялы яңадан баш калкытты. Әтисенең базына күмеп куелган чүлмәк тулы алтыны инде чүлмәк тулы түгел иде — туйга күп тотылды. Шулай да әле алтын бетмәгән дә иде. Шулхәтле байлыгың була торып, йөре инде таң тишегеннән кичкә кадәр көч түгеп! Үзе тапкан байлыкның тулысы белән үзенә булмавы аның ачуын китерде. Әтисе исә һаман нәрсәдәндер курыкты, кирә-

геннән артык сак кыланды. Икенче яктан җиңгәсе Галимә әледән-әле Җәбирне котыртты:

— Хатының дөньяда бер чибәр, ләкин ярлы килеш ул чибәрлекнең бер файдасы да юк, — дигән кебегрәк сүзләр әйтеп аның канына тоз салды.

Бервакыт таш култыкның таш амбар янындагы эчкечеләр алачыгына барып кергәч, ул көтмәгәндә сәер сүзләр ишетеп сагаеп калды. Калку корсаклы, рәхәтлектән күзләрен кысып, авызын ерып торган Бор ата — эчкечеләр алласы сурәте ясалган зур чүлмәк тирәсенә җыелып утырган таза диңгезчеләре, үзара ниндидер яшерен нәрсәләр турында гәпләшәләр иде. Үз сүзләренә алар шул дәрәҗәдә бирелгәннәр, сүз белән шулкадәр мавыкканнар иде, якында гына туктап калган Җәбирне алар күрмәделәр дә, ахрысы. Исерек диңгезчеләр сүзеннән ул шуны аңлады. Кәмиләр былтыр кырык ел тәхеттә утырган сарларын соңгы юлга озатканнар икән. Кәмиләр сары кырык ел буена мәңгелек йорты — таш төрбә төзеткән, төрбәгә куеп калдыру өчен, кырык ел буена байлык җыйган. Сарның табутын төшергәннәр, ишекләрне, тишекләрне япканнар, барлык эзләрне юкка чыгарганнар, шунда эшләгән колларны-караларны юк иткәннәр икән, тик арада берсе, имеш, качып котылган. Шул, имеш, юлбасарларга серен ачкан, ишек-тишекне, юлларны күрсәткән. Юлбасарлар серне алганнар да колны үтергәннәр.

— Их! — диде шул чакны тыңлап торучыларның берсе, үкенү белдереп.

— Юлбасарлар акылсыз булган, — диде Кәми сарының җир астына яшерелгән кырык еллык байлыгы турында сөйләүче. — Акыллы юлбасар юл күрсәтүчене үтерми. Атасын-анасын, туганнарын үтерә — юл күрсәтүчене үтерми!

— Алайса юк сүздер ул! — диде «их» дигән диңгезче, шик белдереп.

— Юк сүз түгел, — диде сөйләүче. — Кәмидә үз колакларым белән ишеттем: сарларының җаны күккә ашкан, гәүдәсе таш төрбәдә. Байлыгы да шунда. Ышансаң ышан, ышанмасаң — синең эш.

— Их! — диде теге диңгезче тагын да.

— Кәминең үзендә дә «их»диючеләр җитәрлек, — диде эчкечеләрнең икенче берсе.

— Барыбер эзенә төшәчәкләр аның, юлын табачаклар! — диде сөйләүче, ашыкмыйча гына. — Таланмаган бер генә төрбә дә юк Кәмидә.

— Бар! — диде шунда яшьрәге. — Шафа төрбәсе.

— Ул сихерләнгән. Аны ияләр саклый, — диде сөйләүче, белдекле булып.

— Менә миңа шунсы аңлашылмый: безнең мака сарга да алтын-көмеш, байлык кирәк, нишләп ул Кәмигә чиру җибәрми икән? — диде Җәбиргә якынрак утырган берсе.

— Алай булмый, — диде акыллы сөйләүче, тыныч кына. — Кәми көчле. Аны чиру белән җиңеп булмый. Җиңсәң дә, төрбә астындагы байлыкны кулга төшереп булмый.

— Ник?! — диде шул чакны тагын түземсез «Их».

— Кәмидә сихерчеләр көчле. Алар теләсә нинди яуны илләренә аяк бастырмаячаклар.

— Шулай да аяк бассалар?

— Юк итәчәкләр, — диде сөйләүче, кулындагы тулы касәсен авызына китереп.

— Менә монысына ышанмыйм! — диде «Их», бөтен алачыкка кычкырып. — Безнең Акланнан көчлерәк ил юк. Сихерчеләр дә көчлерәк, мака сар да.

— Көчсез дип әйтүче булдымы сиңа? — диде «Их» янындагы Алкалы, усал көлемсерәп.

— Их, — диде тагын да «их». — Алтын-көмеш кирәк миңа! Бик күп кирәк! Затлы ташлар, гәүһәрләр кирәк.

— Чибәр кызлар да кирәкмиме? — диде Алкалы, мыскыллы көлемсерәп.

— Ха-ха! — диделәр исерек таза ирләр, күңелләре күтәрелеп.

— Төрбә янына яу белән барып булмый: яу килсә, төрбәсен-ниен, байлыгын — барысын җир йота, — диде «Акыллы», яңадан сүзгә башлап. — Сихерчеләр шулай эшләгән.

— Алайса... туктале, юлбасарлар ничек барганнар да, ничек җир астына төшеп капчык тутырып байлык ташыганнар? — диде «Их», шик белдереп.

— Аның сере бар, — диде «Акыллы», мондый гына шикләргә исе китмичә.

— Ниндирәк сер? Безгә дә әйтмәссеңме? — диде «Алка», «Акыллы»га усал күз карашы ташлап.

— Бер сере шул: төрбәләр янына яу булып түгел, төркем-төркем булып барырга кирәк. Иң күбе ун кеше. Икенче сер шул: таш ишекләр үзеннән-үзе ачылсын өчен яшерен сүзне белергә кирәк. Өч сүз.

— Анысын да беләсеңме?! — диде түземсез «Их», Акыллының таза беләгеннән эләктереп алып.

— Юк, белмим, — диде «Акыллы», көттеребрәк. — Аны сихерчеләр генә белә. Аннан соң... Тотмас дигән юлбасар белә, диләр. Ләкин ул... тәхеттә утыра, диләр.

— Тотмас түгел, Тоттырмас булды бу болай булгач, — диде шунда берсе.

Барысы да шаркылдап көләргә тотындылар. Шул чакны эчкечеләрнең берсе якында гына колагын сузып тыңлап торган Җәбирне күреп алды, күзен акайтып яратмыйча бер карап куйды да ачу белән теш арасыннан аның ягына төкереп җибәрде. Исерекнең теш арасынан чыккан төкерәге туп-туры Җәбирнең битенә килеп тиде. Хурланудан Җәбир баскан урынында сикереп куйды, йодрыкларын йомарлап исереккә укталды. Эчкечеләр күреп тордылар, көлешергә тотындылар. Бары төкерүче исерек кенә көлмәде.

— Бар, бар, йөрмә мондый җирдә иснәнеп, аңдышып, — диде Җәбиргә ул, кул селтәп.

Башын иеп, оятыннан уттай янып, Җәбир чыгып китте. Ләкин ул анда тагын барды, тагын колак салып тыңлап торды. Монысында диңгезчеләр дә башка, сүзләре дә башка, тик уртадагы борлы чүлмәк кенә, тәбәнәк, түгәрәк өстәлләр һәм касәләр генә шул ук иде. Шулай да, тыңлый торгач, боларның да сүзе бер үк төслерәк булып чыкты. Байлык һәм чибәр кызлар. Кәмидән дә көньяктарак Кәмине исән-имин яшәтеп торучы Нил суының чыккан җиренә якынрак Нуби илендә алтынкөмеш, асылташлар аяк астында аунап ята икән. Андагы кыргыйлар алтын-көмешне чүпкә дә санамыйлар икән. Кәминең үзендә алтын да, көмеш тә чыкмый, асылташлар да юк — барысын да алар шуннан, Нубидән ташыталар икән! Кәми сарларының төрбәләрен талап йөргәнче, иң яхшысы, шуннан гына барып аласы икән. Тик менә анда юл йөрүе генә кыенрак икән — кәмәдән төшкәч бик озак кайнар комнан барасы икән. Анда, имеш, эчә торган су табуы кыен икән, акыллы кешеләр үзләре белән күп итеп су алып чыгалар икән дә бушаган курҗыпларының яртысына алтын-көмеш, энҗемәрҗән кебек ташлар тутырып кайталар икән.

Таныш алачыкка Җәбир бер генә мәртәбә кермәде. Кергән саен җыйнаулашып, шаулашып бор аракысын эчеп утырган ниндидер ирләргә, диңгезчеләргә, чит ил сатучыларына тап булды. Кергән саен аларның сүзләренә колак салды, уйланды, хыялланды һәм көннәрдән бер көнне катгый бер карарга килде. Карарын иң элек ул үзенең бистәдәге яшьтәшләренә тиште, берсүзсез буйсынырга риза булган яшьләрдән көтү туплый башлады. Өлкәннәр сизмәсен өчен бу эш, билгеле, бик яшерен эшләнде. Сүзләреннән кире кайтмасыннар, сөйләнеп йөрмәсеннәр өчен яшьтәшләре белән алар иң элек ант

эчтеләр һәм ерак юлга әзерләнә дә башладылар — ышанычлы берәүнең алачыгына төннәрен азык-төлек, корал ташыдылар, зур-зур курҗыплар белән су ташыдылар.

Балтачылар бистәсендә Җәбир кирәк кадәр яшьләр таба алмады. Шуңа күрә Таш комган бистәсенә барырга, андагы дус-таныш яшьләр белән сөйләшергә туры килде. Көтү башы монда иң көчле егет Коркул исәпләнә иде. Диңгезгә чыгу, ерак илләрне күрү, бетмәс-төкәнмәс байлыкка ия булу Коркулның да күптәнге хыялы иде. Күңелендә Җәбиргә карата үпкәсе, ачуы булса да, ул да икеләнеп тормады. Тик көтүнең яртысы Таш комган бистәсеннән булыр диде. Җәбир риза булды. Бөтенесе бергә җыелгач, Таш комган бистәсеннән бер кеше ким икәнлеге беленде. Җәбир моңа да каршы килмәде.

Караңгы һәм җилле бер төндә алар атасы Мөхлиснең Бормалы арык буендагы Сал-күперенә җыелдылар. Монда Мөхлиснең күптән түгел эшләнеп беткән, суга төшерелгән өр-яңа яу кәмәсе тора. Сал-күпердә ялланган сакчы-мазар тотмыйлар. Шулай да яңа кәмә әзер булып, суга төшерелгәч, Мөхлис үзе һәм уллары алмаш-тилмәш яр буендагы куышта төн куналар иде. Әтисе дә, агасы да куышта төн үткәрүне авыр санап, бу эшне күбрәк Җәбиргә тапшырырга тырышалар. Ул караңгы һәм җилле төндә дә судагы кәмә янында Җәбир кизү санала иде. Яшьләрнең барысы да яр буена җыелгач, алар Мин аллага багышлап тәкә чалдылар, тәкәнең канын тамчысын да калдырмый агыздылар да, тәкә башын озын колгага бәйләп, колганы яр буена беркетеп куйдылар да, келәүләрен әйтеп, кәмәгә керделәр. Тәкәнең тиресен тунап тормыйча кәмәгә алып керделәр. Шулай ук яшерелгән азык-төлекләрен, коралларын, кирәк-яракларын да тиз-тиз генә кәмәгә тутырдылар. Барысы да әзер булгач, Җәбир арканнарны ычкындырып җибәрде. Яшьләр, ишкәкләрен ярга терәп, барысы берьюлы көчәнгәндәй иттеләр дә, кара су өстендә әкрен генә тирбәнеп торган авыр кәмә күз алдында ярдан аерылып китте һәм түбән таба шуыша башлады. Шатлыгыннан Җәбир кычкырып җибәрә язды. Алар кузгалдылар! Чын-чынлап кузгалдылар! Башкалар да бу мизгелдә шундый ук күтәренкелек, шатлык-куаныч кичерделәр, җиңелчә генә гөрелдәп-гүләп алдылар, ләкин бар тавышка кычкырырга беркемнең йөрәге җитмәде.

Бормалы арыктан алар туры юл арыгына барып чыктылар һәм туп-туры диңгезгә таба юнәлделәр.

Диңгездән туры Изге тауга сузылган су юлы бер генә иде. Туры юл дип аталган киң һәм тирән арыкның диң-

гезгә тоташкан төшендә, арык тамагында ике ягында ике таш баганасы булган бик зур капка ясалган. Таш баганалар өстенә бер ярдан икенче ярга киң итеп, дуга сыман итеп калку күпер сузып салынган. Күпер өстендә, таш куышта көне-төне кораллы күзәтчеләр утыра. Көн яктысында күпер аша арык буйлап әрле-бирле төрле зурлыктагы кәмәләр, каеклар, бораннар йөреп тора. Берәүләр чит илләрдән, чит утраулардан Акланга мал-туар, ашлык, җимеш, агач-таш һәм коллар алып килә, алып кайта, икенче берәүләр Акланнан шулай ук үзенә кирәкле нәрсәсен алып китә. Арада күңел ачып, җырлап, уйнап-көлеп баручы шат күңелле кешеләр белән тулы матур-матур кораблар да очрый. Көндез капкада беркемне тоткарламыйлар. Әмма караңгы төшү белән, хәрәкәт кими төшә. Таш баганалар турысына, арыкның ике ягына сакчы кәмәләр килеп туктый. Уртада калган тар аралык аша кәмәдән кәмәгә җиз чылбыр сузыла. Керүче-чыгучыларны карап-тикшереп җибәрәләр яисә шикле тоелса, җибәрмичә, эләктереп камап алалар да таң атканчы дип читкәрәк илтеп куялар.

Туры юл арыгыннан диңгезгә таба барганда, аларга беркем дә игътибар итмәде, ахрысы. Игътибар итсә дә, күрәсең, исе китмәгәндер. Иң кыены, билгеле, капка аша чыгу булачак иде. Юлдашларына Җәбир алдан берни белдермәде. Ул бары коралланырга һәм сак-уяу булырга гына кушты. Кизүдәге күпер сакчылары һәр якта утызар-утызар кеше. Алай-болай сугышырга туры килсә, күпердән беркадәр читтәрәк тагын өч йөз кешелек кораллы сакчылар тора. Моны һәркем белә. Ләкин өч йөз алтмыш кешегә түгел, утыз алты кешегә каршы баруның да уен эш түгеллеген дә һәркем белә. Сал-күпердән кузгалып киткәндә, күңелләре күтәрелгән яшьләрнең таш күпергә якынаю белән йөрәкләре кысыла төште, күңелләргә курку һәм шом үтеп керде. Шулай да тавыш чыгаручы булмады.

Караңгы су өстеннән шыпырт кына, мыштым гына баручы өр-яңа яу кәмәсен күпер янындагылар тиз арада күреп алдылар. Күреп алдылар да, юлларына аркылы да төштеләр. Сакчы кәмәдән шикле кәмәгә басма ташладылар һәм, коралларын шакылдатмаска тырышып, басмадан бер-бер артлы таза-таза ирләр керә башлады. Караклар шып булдылар. Кайберәүләр батыраеп җиз кылычларын югары күтәрде. Җәбир үзенекеләргә борылып кына карады да «тик торыгыз» дигәнне аңлатып, кул селтәде. Аның каршысында күпер сакчыларының башы — кәмәдәге караклар кебек үк яшь-яшь,

кыска буйлы, таза һәм баштанаяк коралланган кеше басып тора иде.

— Кемнәр сез? Кая юл тотасыз болай? — диде ул, ничектер серле-мәкерле итеп, күптәнге танышлары белән сөйләшкән сыман.

— Төн матур чакта диңгездә йөреп кайтыйк дигән идек бер, — диде Җәбир, аның үзе кебек серле һәм ягымлы итеп.

— Диңгездә көндез йөрү күңеллерәк түгелме соң? — диде сакчы, белмәгән сыман кыланып.

— Бүтәнгә көндез күңелле, безгә — төнлә, — диде Җәбир.

Алар бер-берсенең йөзен күреп, бер-берсенә якын гына басып торалар иде. Шулай аңлашкан сыман булгач, баш сакчы үз кешеләренә борылырга, кәмәдән чыгарга кушты. Кораллы ирләр борылу белән, башлык киресенчә, кәмәнең эченә табарак атлады.

— Каяле, шулай да кая барасың икән? — диде ул, үзалдына сөйләнгән сыман.

Шул чакны Җәбир бил каешындагы авыр гына күн капчыгын ычкындырып алды да тавыш-тынсыз сакчы башлыгына сузды. Башлык шулай ук, тавыш-тынсыз, янчыкны кулына алды һәм билен кысып торган эчке каешына кыстырып куйды. Аларның бу сүзсез генә алыш-бирешен беркем дә күрмәде-сизмәде, ахрысы. Җәбиргә шулай тоелды. Кәмәнең борыныннан койрыгына үтеп, сүз битлеге өчен болай гына карап чыккач, сакчылар башлыгы басмага юнәлде, үз кәмәсенә чыкты. Бераздан чылтырап, чупылдап, җиз чылбыр суга төште. Юл ачылды. Караклар кәмәсе ачык диңгез ягына юл алды.

Чыгу белән, алар җилкәннәрен күтәрделәр. Еракта инде таң беленеп килә иде, диңгез белән күк арасы аермачык шәйләнә башлаган иде. Куркыныч капкадан бер ярты чакрым чамасы ерагаю белән, яшьләр, сөенечләреннән нишләргә белмичә, барысы беравыздан кычкырып җибәрделәр, көләргә, сызгырырга, чинарга тотындылар. Бер-икесе җырлап җибәрде.

Җәбир дә сөенде. Тик шулай да ул башкалар кебек кычкырмады, чинамады да, җырлый да алмады. Ул үзенең тәбәнәк, кысан алачыкта берни белми йоклап калган чибәр Лүчнәсен уйлады. Сакчылар башлыгына биргән янчыктагы алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән — барысы да Лүчнә милеге иде. Бу янчыкта шулай ук яшел ташлы алтын тамга да бар иде.

Җиттеләр алар Кәмигә. Еракта, бик еракта таудай

биек таш төрбәләрне күрделәр, Акландагы сыман биек сарайларны, манара һәм таш киртәләрне күрделәр, тулып-җәелеп аккан изге су — Нил суын күрделәр, ләкин таудай төрбә асларына күмеп калдырылган бетмәс-төкәнмәс байлыкны күрергә насыйп булмады. Яр буе сакчыларына Аклан ягыннан килгән кыю яшьләр беренче күрүдә үк шикле тоелды — тикшереп тә тормыйча аларны кире бордылар, каян килгәнсез, шунда китегез, диделәр. Аларның килгән якларына кире кайтып китәселәре килмәде — анда хәзер юл ябык иде. Алар шауларга, кычкырырга, ялынырга тотындылар, эчәргә суыбыз бетте, ашарга азыгыбыз бетте, һичьюгы, ярга чыгарга рөхсәт итегез, диделәр. Юк, рөхсәт итмәделәр. Сездәйләргә сарның боерыгы шундый. Тыңламасагыз, тотып алып коллыкка сатабыз, диделәр.

Ирекле баштан беркемнең дә кол буласы килмәде. Бик нык арысалар, йончысалар да, алар ярдан читкә, диңгез ягына борылдылар. Шунда Җәбирнең күңеленә акыллы бер фикер килде:

— Караңгы төшкәнче читкәрәк китеп, яр буендагы камышлар арасында качып торабыз да, караңгы төшү белән елгага керәбез, — диде юлбашчы. — Берара үргә менеп, ярга чыккач, анда безне кем таный, — диде.

Юлбашчы ничек әйтсә, шулай булды. Яр буе сакчылары яныннан читкәрәк киттеләр дә, караңгы төшә башлаганны көтеп тордылар, аннары Нил тамагындагы камышлы күлләр, ермаклар ягына борылдылар. Монда аларның юлына беркем аркылы төшмәде. Бары тик әледән-әле көтүе-көтүе, оясы-оясы белән су кошлары очрады да, камыштан камышка җиңел генә сикереп йөргән, күңелсез нечкә тавыш белән чинаган, мияулаган сәер җанварлар — кәмиләрнең изге мачылары очрады. Аннан соң бер-ике мәртәбә караңгыда күзгә күренмәгән ниндидер су хайваны көчле койрыгы белән кәмә кырыена сугып алды. Шундый авыр кәмә йомычка кебек янтаеп китте. Кәмәдәгеләр котлары алынып кычкырып җибәрделәр, бер-берсенә тотындылар, өрлекләргә тотындылар. Шул чакны якыннан гына кечкенә башын су өстеннән чыгарып, бик зур, озын һәм шактый юан су еланының боргаланып җиңел генә шуыша-шуыша диңгез ягына китеп барганы күренде.

Бары шул чакны гына Аклан яшьләре беркем йөрми торган, киресенчә, ничек тә читләтеп үтәргә тырыша торган куркыныч чоңгылга килеп керүләрен шәйләп алдылар. Нил тамагының көнчыгыш ягында, ярга якын җирдә, камышлар, сазлыклар арасында өч дилбегә буе

озынлыктагы изге елан — Су иясе яшәве турында, ачуланган чакларында аның койрыгы белән селтәп зур-зур кәмәләрне аударуы, кешеләрне йотуы турында Җәбирнең дә, башкаларның да ишеткәне бар иде, әлбәттә. Аклан илендә олысы-кечесе сөйли торган иң куркыныч нәрсәләрнең берсе шул изге Су иясе иде. Изге Су иясе Кәми илен, төрбәләрдәге Кәми сарларының табутларын, байлыкларын саклый икән, Нил тамагыннан төрбәләргә кадәр җир астыннан су юлы бар икән, дип сөйлиләр иде.

— Беләсезме, ул бездән корбан сорый! — диде шул чакны Коркул.

— Корбан бирсәк, ул безне үткәреп җибәрәчәк, — диде икенче бер чүлмәкче, Коркулның сүзен куәтләп.

Мондый сүздән барысының да котлары алынды. Барысы берьюлы телдән язгандай өнсез калдылар. Мондый чакта, үзе теләп корбан буласы кеше табылмаса, шобага тотарга туры килә иде. Шобагадан беркем дә качып котыла алмый. Барысы да киңәш сораган сыман юлбашчы Җәбиргә текәлде.

— Кәми җиренә аяк басыйк, уйлашырбыз. Кире кайтасы да бар бит әле, — диде ул, икеле-микеле итеп.

Күңеленнән исә ул изге ияне алдамакчы булды. Кире кайтканда бөтенләй башка яктан китәргә булмыймыни?! Үз чоңгылында кемнедер саклап тик ятсын кәмиләрнең изге иясе. Аклан кешесе өчен Аклан ияләре, аллалары гына изге түгелмени? Алар инде үзләренең Мин аллаларына корбан бирделәр — шул җиткән.

Җәбир шулайрак дип уйлады. Исән-имин камышлыктан үтеп, исән-имин ярга аяк басса, нишләргә кирәген белер иде әле ул!

Төнне алар су өстендә, камышлар арасында уздырдылар һәм таң атар-атмас борын яңадан кузгалып киттеләр. Бик озак төрле ермакларда, камыш әрәмәләре арасында буталып йөрделәр. Кояш төшлеккә якынлашканда гына киң, иркен су өстенә килеп чыктылар һәм сул як яр өстендә, калкурак җирдә, кечерәк кенә бер тура күреп шунда борылдылар. Яр буенда, басма кырыенда унлап эреле-ваклы кәмәләр туктап калган. Шундук зур гына боран тора, яр өстендә исә базар, базарда ыгы-зыгы, сату-алу бара иде.

Кәмәләрен басма кырыена туктатып, алар шундук ярга чыктылар, җир өстенә өеп куелган азык-төлек, җимеш арасыннан йөреп, үзләренә кирәк нәрсәләрне караштыра башладылар.

Кәми җиренә аяк бассак, шундук үз кеше булып ки-

тәрбез, кәмиләрнең, бигрәк тә багаларның, сакчыларның күзенә чалынмыйча, җиңел генә үргә — төрбәләр ягына китәрбез дип уйлаган иде Җәбир. Ләкин беренче мәртәбә кәмиләр җиренә аяк басу белән ул үзенең бик нык ялгышканлыгын аңлап алды. Акланнан килгән кораллы яшьләргә кәмиләр беренче күрүдә үк шикләнеп-сагаеп карадылар. Акланнар яисә лелегләр монда әллә каян аерылып торалар иде. Аларның кораллары, бил каешларындагы аеллары, каты киемнәрендәге тәңкәләре, калканнары — барысы да җиздән иде, ерактан ук ялт-йолт килеп, «менә, без ул! «дип кычкырып тора иде. Аннан соң аларның җиз калканнары кояштай түгәрәк, кәмиләрнең озынча һәм үгез тиресеннән катырылган иде. Кәми ирләренең кара чәчләре кыска һәм үрелмәгән, лелегләрнең исә озын итеп өч толымга үрелгән һәм аркага сузып салынган иде.

Дөрес, мондагы нәрсәләрне Җәбир элек тә белә иде, ләкин монда ул үзләренең кәмиләрдән аерылып торуларын тагын да ныграк күрде, тойды. Бу, билгеле, яхшы да һәм шул ук вакытта начар да иде. Аларга шундук игътибар иттеләр, аларның һәрбер сүзенә колак салып тыңлап тордылар һәм һәр хәрәкәтен күзәткәндәй булдылар. Базарда алар кирәк кадәр азык-төлек сатып алдылар, яр буенда ит кыздырып ашадылар, татлы җимешләр ашадылар, бераз вакыт ял итеп алдылар да, эссе басыла төшкәч, кичкә таба кузгалып киттеләр.

Алар үргә, ерактагы төрбәләргә карап бардылар. Җил бөтенләй диярлек исми иде. Үргә таба ишүе шактый авыр булды. Биш-алты чакрымлык ара киткәч тә алар яңадан ярга чыктылар һәм төнне шунда уздырмакчы булдылар. Ләкин чатлы ыргак «песи»не су төбенә ташлап, яр буена басма ташлагач та, якындагы таш куыштан йөгерешеп кораллы ирләр килеп чыкты. Алар шаулашып кунакларны уратып алдылар, сораштыра да башладылар: кая барасыз, нишләп йөрисез, диделәр.

Аларның, билгеле, җаваплары әзер иде.

— Өченче каты төп илендә, куян илендә төзәлми торган яраны төзәтә торган ачу ташы саталар икән дип ишеттек. Изге атабыз түшәк өстендә ята. Шул ташны алырга барабыз, — диде Җәбир, әз генә дә тоткарланып тормыйча.

Шулай диебрәк җавап бирергә кирәклеге турында ул теге Ташкултыкта тәҗрибәле диңгезчеләр авызыннан ишетеп калган иде.

— Сез ялгыш юлдан киткәнсез, — диде сорау алучы кәмиләр башлыгы. — Куян иле Өченче каты янында

түгел, түбәндә, теге якта. Син әйткән ачу ташын да шунда саталар.

Җәбир ык-мык итте. Куян иленең кайдалыгын ул белми иде. Үзләрен чолгап алган кораллы сугышчыларга каршы корал күтәрергә аның йөрәге җитмәде. Аларга борылырга кушылды. «Юл күрсәтеп» аларны ике яктан ике кәмә озата барды. Кәми сары да, якын-тирәдәге башка ил сарлары да Акланнан куркалар һәм шуңа күрә лелегләр белән усал кыланмыйлар иде. Аларны Нил тамагындагы сакчылар турасына кадәр илтеп куйдылар. Шулай итеп, изге сарлар, таудай төрбәләр иленнән куалап, хур итеп, сөреп чыгардылар.

— Су иясенә корбан бирмәдек, шуның өчен бу! — диде тагын Коркул, беренче булып.

Чүлмәкчеләрнең юлбашчысы тыштан дус-күндәм, сүз тыңлаучан булып күренсә дә, Лүчнә өчен көрәштә җиңелүен әле булса онытып бетерә алмый иде. Җае чыккан саен ул берәр каршы сүз әйтеп куярга, берәр төрле ризасызлык, канәгатьсезлек белдерергә тырыша иде. Җәбир моны юлга чыккан көнне үк сизеп алды. Ул алай турыдан-туры Җәбиргә каршы да килми, балтачыларга да тел тидерми, шулай да кирәк чакта телен дә тыймый — әле аның ишкәк сабына ачуы килә, кытыршы, янәсе, әле аяк астында аунап яткан берәр нәрсәгә ачуы килә. Су иясе аның күңеленә кереп утырды — хәзер ул аны өзмәс тә, куймас та, җанны игәп, күңелгә шом салып әледән-әле кабатлавын беләчәк.

Корбан. Бу чыннан да шомлы һәм куркыныч нәрсә иде. Ияләрнең күңелен күрмичә дә булмый иде, шул ук вакытта көчең ташып торган яшь чагыңда якты дөньядан да аерыласы килми шул. Аннан соң үз араңнан кемне дә булса корбан итү ул көчеңне киметү булачак. Балтачылардан берәрсен корбан итсәң, башкалар сиңа шундук теш кайрый башлаячаклар, чүлмәкчеләр дә дошманлашачак.

— Син нәрсә киңәш итәсең, Коркул? Шобага тотыйкмыни? — диде Җәбир чүлмәкчеләргә, ачулы караш белән.

— Мин белмим... Син бит юлбашчы, — диде Коркул, туры гына җавап бирмичә.

— Белмәгәч, нигә гел шул Су иясен искә төшерәсең? — диде Җәбир.

— Син әйт, син бит юлбашчы. Син алып чыктың безне хәтәр юлга, — диде Коркул, үртәлеп, зәһәрләнеп.

— Ә-ә, шулаймыни әле?! — диде Җәбир, йодрыкларын йомарлап Коркулга таба омтылып.

Алар бу вакытта елга тамагыннан еракта комлы яр буенда туктап торалар иде. Җәбирнең көдрәеп үзләренең юлбашчысына таба килүен күреп, чүлмәкчеләр шундук аякларына бастылар, шаулаша башладылар һәм Коркулны саклап уратып алдылар. Ул арада балтачылар да аякка басты, Җәбир тирәсенә туплана төштеләр.

— Юлга чыгар алдыннан сез миңа ант эчтегез, — диде Җәбир, йодрыкларын язып.

— Безнең антыбыздан баш тартканыбыз юк, — диде Коркул.

Бу юлы аның тавышы килешүчән һәм күндәм булып ишетелде. Җәбир үзенең юкка кызуын аңлап, ачуын эченә йотты. Шулай да күңеленнән уйлап куйды, «күрсәтермен әле мин сиңа күрмәгәнеңне!» диде.

— Син әйт! Син юлбашчы! — диделәр Җәбиргә башкалар да.

Җәбир үзенең юлбашчы икәнлеген онытмаган иде, әлбәттә. Тик менә ул нишләргә кирәклеген үзе дә белми иде. Яшьлеге, көче, кыюлыгы ташып торса да, аңа белем һәм тәҗрибә җитеп бетми иде. Менә монда ул шуны аңлады.

— Алайса, башта сез әйтегез — нишләргә? — диде ул юлдашларына.

— Тагын бер мәртәбә тырышып карарга кирәк!

— Юк, юк, Акланга кайтабыз.

— Үлсәм дә кайтмыйм Акланга! — диештеләр яшьләр, бер-берсен бүлеп.

Җәбир, ялгыш сүз ычкындырудан куркып, озак кына эндәшмәде. Акланга аның күңеле тартмады. Капчык тутырып алтын-көмеш, асылташлар алып кайтса гына Акланда аның йөзе ак булачак иде, бары шул чагында гына аны әтисе дә, агасы да, Лүчнәсе дә кичерер, ярлыкар, гафу итәр сыман иде. Болай тора салып коры кул белән кайтып килсә, беркем аңа якты йөз белән карамас сыман булып тоелды.

— Акланга буш кул белән кайтмыйбыз! — диде ул, нык итеп. — Акланга бары баеп кына кайтырга була. Аклан ярлыларны яратмый. Мака сарга күп, бик күп алтын-көмеш кирәк. Сезнең аталарыгызга, туганнарыгызга, бичәләрегезгә бетмәс-төкәнмәс алтын-көмеш, энҗемәрҗән кирәк. Бездә көч, яшьлек, корал бар. Эзләгәнебезне теләсә каян, теләсә ничек табарбыз! Сез шуңа ризамы?

— Риза! — диделәр көче ташып торган яшьләр беравыздан.

— Җир астына яшерелгән байлыкны эзләп тормыйча, су өстендәге байлыкны сөзәргә кирәк безгә, — диде Җәбир.

Нәрсә турында сүз барганын һәркем бик яхшы аңлады. Эшсезлектән интеккән һәм каядыр барырга, нидер ватарга-җимерергә, нидер таларга-йолкырга атлыгып торган яшьләр яңадан диңгезгә чыгып китмәкче булдылар. Аларның инде азыклары, сулары да кими бара, аннан соң искәрмәстән кәмиләрнең яр буен саклаучы кораллы ирләре килеп чыгарга мөмкин иде. Комлы яр буенда шулай ике-өч көн ял иткәч, кәмәләрнең кайбер какшаган җирләрен төзәткәч, ныгыткач, алар диңгезгә чыгарга әзерләнә башладылар. Бу юлы алар көнбатыш якка карап китмәкче булдылар. Нубидә генә түгел, Либи дигән илдә дә алтын-көмеш аяк астында аунап ята икән дип ишеткән иде Җәбир. Ул якта да биек-биек таулар бар икән, анда да җиз, кургаш, фил сөяге чыга торган урыннар күп икән дип белә иде ул.

Яңадан кузгалып китәргә дигәч кенә нишләптер ярдан да, ярга да җил исми башлады. Хәер, аның монда рәтләп искәне дә булмады бугай. Ләкин иң кирәк чакта җилнең булмавы аеруча нык сизелде. Иртәннән башлап кичкә кадәр кояш кыздырды, күктә каз мамыгы кадәр дә болыт күренмәде, диңгез исә, терекөмеш тутырган кебек тип-тигез булып, тыгыз һәм куркыныч булып, әз генә дә тирбәнмичә, чайкалмыйча тик ятты. Мондый эсседә, мондый тынлыкта ишкәкләргә генә ышанып диңгезгә чыгу шактый куркыныч иде. Шуның өстенә эчә торган су көннән-көн кими башлады. Җәбирнең ишеткәне бар — мондый тынлык, җилсезлек, имеш, айлар буена сузыла икән.

Яшьләр җил чыгуын бер атна көттеләр, ике атна көттеләр. Без туктаган җир ияледер йә булмаса кан коелган урындыр дип, бүтән төшкә күченеп тә карадылар. Ләкин җил һаман исмәде. Менә шул чагында ачу китергеч Коркулның янә «акыллы» сүзе ишетелде:

— Елга иясеннән котылдык, җил иясенә тотылдык. Корбан бирмәсәк, какланган балык кебек кибеп бетәчәкбез бу эсседә, — диде ул, үҗәтләнеп.

Башка чүлмәкчеләр дә теләр-теләмәс кенә үз башлыкларының фикерен куәтләделәр:

— Әйе, әйе, җил иясенең күңелен күрмәсәк, эсселектән, сусызлыктан, ачлыктан юкка чыгарбыз, диделәр.

Бу юлы Җәбир киңәшчеләрнең сүзен тыңларга булды.

— Алайса болай итәбез: яртыбыз монда кала, яртыбыз якын-тирәгәауга чыга, — диде ул.

— Ауга кем бара — чүлмәкчеләрме, балтачылармы? — диде шундук Коркул.

— Шобага тотабыз, — диделәр яшьләр.

— Шобага тотмыйбыз, — диде Җәбир, каршы килеп. — Шобага корбан сайлаганда гына тоталар. — Ауга чүлмәкчеләр бара.

Коркул да, башка чүлмәкчеләр дә шып булдылар. Тиз генә каршы әйтер сүз дә тапмадылар.

— Ник без? — диде шулай да Коркул, хәтере калган сыман.

— Бу минем боерык, — диде Җәбир, аңлатып.

Чүлмәкчеләр карышып тормадылар. Караңгы төшә башлаганны гына көттеләр дә, тире капчыкларын алып, ярдан читкә комлы калкулыклар ягына китеп бардылар. Көндез ул якта ниндидер авыллар булуы шәйләнә, ул яктан өзек-өзек булып ниндидер тавышлар ишетелеп китә иде.

Кәмәдә калган яшьләр тынычсызланып төне буе ауга киткән иптәшләрен көттеләр.

Таңга таба зарыгып көткән шифалы җил исеп куйды. Күңелләр күтәрелеп китте. Яшьләр, сөенешеп, Су иясенә келәү әйттеләр, рәхмәтләрен белдерделәр. Тиз арада ишкәкләрен тартып алдылар. Җилкәннәр күтәрелде. Шул мәлне тыны бетеп, җан-фәрманга чабып килүче бер иптәшләре күренде. Килеп тә җитте, бернәрсә аңлатып тормыйча:

— Тизрәк, тизрәк, ычкыныйк моннан, бетәбез! — дип кычкырды.

Аның сүзләреннән бигрәк, кыяфәте кәмәдәгеләргә ныграк тәэсир итте бугай. Болай да шомланган, төне буе йокламаган яшьләр куркуга төштеләр һәм тиз генә кәмәләрен ярдан аерып диңгезгә алып чыгу ягын карадылар. Кәмә җил уңаена, унлап таза яшьләрнең ишкәге һәм җил ярдәмендә су өстеннән «чабарга» тотынды.

Бераз тын алгач, тынычлана төшкәч, әлеге чабып килгән егет сөйләде: алар авылга таба чыгу белән яр буенда ташлар арасында качып-посып торган ике үсмерне күреп алалар да, аларны тотып алу максаты белән шунда ыргылалар. Балалар, куркышып, чәрелдәшеп кача башлыйлар. Шулай да берсен эләктереп алып, башына таш белән сугып күн капчыкка салалар, икенчесе каядыр посып качып кала — аны никадәр генә эзләсәләр дә таба алмыйлар, чөнки инде нык кына караңгы төшкән була. Теге малайны эзләп йөреп, болар караңгыда адашып, бөтенләй икенче якка китәләр. Шул вакыт, этләр белән, атларга атланган бик күп ирләр килеп чыгып боларны урап та алалар, кулларын каерып бәйләп, типкәләп каядыр алып та китәләр. Сөйләүче егет, күргәннәрен яңадан күңеленнән кичереп, түзә алмыйча елап җибәрде.

Җил көчәйгәннән-көчәйде. Әле кайчан гына чалт аяз булган күк йөзе караңгыланып калды, диңгез шауларга, дулкынланырга тотынды. Бөтен тирә-якта ниндидер ят тавышлар, гүләүләр, үкерүләр ишетелде, кәмә кырыена әледән-әле дулкыннар китереп бәрде. Югарыда, баш очында гына, чинап, куркып кошлар очты. Алар, күрәсең, давыл чыгасын белмичә, ярдан ераграк киткәннәр дә, хәзер ничек тә яр буена кайтып калырга ашыгалар иде. Бер-ике кош караңгыда күрмичә өрлеккә килеп бәрелде һәм җансыз калып, кәмә эченә килеп төште. Авыр кәмә таудан тауга йөгереп йөргән кыр кәҗәсе кебек җиңел генә дулкыннан дулкынга сикереп каядыр алга ыргылды.

Бөтен тормышлары суга бәйле булганга, Аклан кешеләре олысы-кечесеннән алып тумыштан ук диңгезне беләләр. Җәбирнең юлдашлары да, балтачы, чүлмәкче булсалар да, чынында алар да күптәнге диңгезчеләр иде. Мондый гына җил-давылны аларга инде бик күп мәртәбәләр күрергә туры килгән. Шунлыктан давыл чыгу белән яшьләр куркып калмадылар — һәркем җаен, тәртибен белеп үз урынына басты. Җәбир биек борындагы тар сикедә калды. Берәүләр күн чиләкләр белән су түктеләр, икенче берәүләр җилкәннәрне күзәтте, өченчеләре исә ычкынып китмәсен, ватылмасын-кырылмасын дип, ишкәкләргә, су-азык тулы капчыкларга, савыт-сабаларга күз-колак булды. Ләкин кәмәне тиешенчә бер юнәлештә алып барыр өчен аларның кешеләре бик азайган иде.

Ләкин кая баралар соң алар? Бу хакта беркем берни белмәде. Күктә исә бер генә йолдыз да күренмәде. Акланнан кузгалып киткәндә, алар ниндидер бай җирләргә барып чыгу, төрле мал төягән ниндидер ят кәмәләргә юлыгу, яулау, талау, баю турында хыялландылар.

Асты өскә килеп шаулаган, дулкынланган диңгез өстеннән чабып барганда, алар якында гына ниндидер карамҗыл кыялар күреп алдылар, якында гына шулай ук үзләре кебек үк җил-давыл белән тартышып, андамонда бәргәләнеп барган ниндидер кәмә күреп калдылар. Кәмәгә таудай итеп зур-зур чүлмәкләр төялгән иде.

Караңгыда су өстеннән калкып торган очлы кыяны иң элек Җәбир күреп алды. Коты алынып ул кәмәне читкәрәк борырга боерды. Ләкин аны ишетүче булмады. Ярый әле кыяны исән-имин узып киттеләр.

Күк йөзе караңгыланганнан-караңгылана барды. Ачулы мөңгердәп, үкереп күк күкрәде, ялт-йолт килеп, чатнап-чытырдап яшен яшьнәде. Җил көчәя төште, кәмәнең тизлеге артты. Ике җилкәннең берсен төшерергә, икенчесен кыса төшәргә туры килде. Ләкин кәмә тизле-

ге барыбер кимемәде. Ул һаман туктаусыз «чабуында» булды. Икенче җилкәнне дә төшерделәр. Ләкин ул да ярдәм итмәде — кәмә, йөгәннән ычкынган яшь тай кебек, алып-биреп, койрык чәнчеп «чабуында» булды. Әле тирән чоңгылга төшеп китте, әле җиңел генә су кыясына йөгереп менде дә, борыны белән дулкын сыртларын ерып, тагын аны-моны карамыйча, упкынга ташланды.

Аны хәзер берничек тә тыярлык, тоткарларлык яисә тиешле юнәлештә алып барырлык түгел иде. Аны хәзер аллалар алып бара иде бугай. Туктаусыз киеренкелектән арый, хәлсезләнә башладылар. Аларның кулларыннан чиләкләр төшеп китте, арканнар ычкынды. Шул чакны караңгы күкне һәм актарылган су өстен көчле яктылык белән балкытып, көчле булып яшен яшьнәде. Шуннан соң ук дөбердәп күк күкрәде. Кәмәдәге кемдер чыркылдап кычкырып җибәрде — яшен уты кәмә уртасыннан тырпаеп торган озын өрлек башына килеп тигән иде. Борындагы, сикедәге Җәбир чыркылдау тавышын сыңар колагы белән генә ишетеп калды, шулай ук өрлек башына тиеп ярылган яшен утын да сыңар күзе белән генә күрә алды. Кәмә алдында, таудай ике дулкын арасындагы чоңгылда бөтенләй көтелмәгән нәрсә күреп, ул тораташтай катып калды. Дулкын таулары арасындагы упкыннан боргаланып-сыргаланып, бик озын булып, кәмәгә аркылы төшеп, Су иясе шуышып бара иде. Бу теге елга тамагындагы, камышлыклар арасында күргән Су иясеннән ике-өч мәртәбә озынрак, ике-өч мәртәбә юанрак иде. Яшен яктысында ялт-йолт килгән тәңкәле шома гәүдәсе яртылаш суга күмелгән, нечкә озын муены бөгелеп су өстеннән чыгып бара. Гәүдәсенә караганда бәләкәйрәк тоелган башы еланныкына охшаган. Түбә өстендә ачык сары төстә зур гына табы бар.

Әллә чытырдап күк күкрәвеннән, әллә диңгез шавыннан, Җәбирнең берьюлы колагы тонып калгандай булды. Ләкин суга төшкән яшькелт яшен яктысын да, Су иясен дә ул аермачык күрде, барлык вак-төякләре белән, елкылдау, боргалanулары белән күрде һәм мәңге хәтеренә алып калды.

Менә шул чагында аларның йомычкадай акылсыз кәмәсе, тау сыртыннан ычкынып, туп-туры түбәнгә, чоңгылга ыргылды һәм туп-туры Су иясенең сыртына барып төште. Су иясе кәмәнең авырлыгын сизде микән, сизмәде микән, Җәбир моны белә алмады, бу турыда уйлана да алмады. Кинәт кәмәгә нидер китереп сукты. Шундый иттереп сукты, таза агачлардан җыйналган, сүс арканнар белән беркетелгән, эче тулы кеше, савыт-саба,

азык-төлек булган «айа» күсәк белән тондыргач коелып төшкән чүлмәк кебек чәлпәрәмә килде. Кемдер җан ачысы белән кычкырып җибәрде, кемдер ярдәмгә чакырды, шытырдап өрлекләр сынды, шартлап арканнар өзелде һәм кыю, батыр, яшь ирләр, кулларын бутап, чүлмәк савыт-сабалар белән бергә, мәңгегә су төбенә киттеләр. Җәбирнең күзенә күренгән иң соңгы нәрсә шул булды: бик зур балык койрыгы кебек ниндидер тәңкәле, лайлалы һәм кара-кучкыл төстәге иләмсез зур койрык урталай сынган кәмә койрыгыннан җиңелчә генә шуышып су эчендә юк булды. Шул ук мәлдә дип әйтерлек аны тотынып торган сикесе-ние белән каядыр читкә атып җибәрде.

Бик озак тоелган күпмедер вакыттан соң давыл тынды, диңгез тынычлана төште. Берничә мәртәбә көн белән төн алышынды. Кәмә сикесенә эләгеп калган ярым үлек Җәбирне дулкын көннәрдән бер көнне комлы ярга чыгарып ташлады. Каты җирне тою белән, Җәбир үзенең исән калганлыгын аңлады. Көч-хәл белән як-ягына каранды. Комлы яр буе тигез, әледән-әле ярга дулкыннар йөгереп килә. Киләләр дә хәлләре бетеп кире чигенәләр. Берсе чигенә, аның артыннан куып яңа дулкын килеп җитә. Шулай туктаусыз бер килеп, бер китеп, комлы җирнең битен юалар. Төпсез күк йөзе зәп-зәңгәр, яп-якты. Баш өстендә мәңге тере, мәңге утлы кояш балкый.

Тигез яр буе да, дулкыннар да, күктәге кояш та аңа күптән таныш иде. Аңа шулай ук мондагы яр буе да, ерактагы ялгыз кыя да, эсседән әлсерәгән пальмалар — барысы да таныш сыман иде. Шулай да нинди җир икән соң бу? Шул ук кәмиләр җиреме, либиләр җиреме? Ул үзе генәме, әллә тагын берәрсе исән калды микән? Берьюлы аның күңеленә шундыйрак сораулар килде. Ләкин ул әлегә берни дә белә алмады.

Беркадәр хәл җыеп, уйлангандай итеп яткач, ул үзен коткарган сике агачлары арасыннан чыкты, тәненә уралган су үләннәрен сыпырып төшерде һәм, кәмә борынының сынык-санык агачларына таянып, яңадан үзенең кайдалыгын чамаларга тырышты.

Аягына баскач тирә-як та яхшырак күренде. Шул чакны ул еракта эт өргән тавыш ишетеп алды. Ныклабрак караса, ярдан артык ерак булмаган калкулык ягыннан эт ияртеп, дөресрәге, эткә ияреп, бер-ике кеше килеп ята иде.

Менә алар яр буена якын ук килделәр һәм дулкын юып өстәл өстедәй тигезләгән юеш комга килеп кер-

деләр. Җәбир, баскан урыныннан кузгалырга да куркып, килүчеләргә карап тик торды. Кешеләрдән бигрәк аңа аларның озын торыклы йөнтәс сары этләре куркыныч тоелды. Эт нишләптер аны яратмады. Ул, ахрысы, ерактан ук аның исен сизеп алган һәм шуңа күрә кешеләрдән алга чыгып, шулай ярсып-ярсып өрә иде. Җәбир, эт ыргыла-нитә калса сакланырга дип, тиз арада як-ягына каранып алды. Ләкин якында гына, кул астында гына этне куркытырдай берни юк иде. Хәлсез куллары белән ул билендәге хәнҗәрен капшап карады. Хәнҗәр үз урынында иде.

Килүчеләрнең берсе кулына ботаклы-сатаклы һәм шомарып беткән юан гына таяк тоткан, ләкин ул нишләптер үзенең этен куалап җибәрергә ашыкмады. Килүчеләрнең таяклысы өлкән яшьтәге ир кеше, икенчесе, яшьрәге, кыз кеше иде. Ир кешенең билдән түбән оятлы җирен каплаган күн кисәгеннән башка берние юк. Кыз исә ак киндер кисәгеннән эмалләнгән һәм капчык сыман кыска, туры итәкле күлмәк кигән. Икесенең дә кыска итеп киселгән, таралган чем-кара чәчләре төшеп тора иде.

Беренче күрүдән үк Җәбир аңлап алды — болар кәмиләр булырга тиеш. Чыннан да, ир кеше этенә селтәнеп алды, эте өрүдән туктагач, беренче булып Җәбиргә үз телендә сүз кушты.

— Исәнме, юлчы, кайлардан килдең, кая юлдашларың? — диде.

Кәмиләр теле лелегләр теленә төп-төгәл охшамаган булса да, сөйләшкәндә алар бер-берсен аңлый алалар иде. Җәбир аңлады, ләкин җавап кайтарырга ашыкмады — сөйләшергә хәле дә юк, аннан соң ят кешенең уен белмичә торып, сөйләшү дә куркынычрак иде. Таяклы кеше исә аның җавабын ишетергә теләмәде дә, ахрысы. Иң элек баштанаяк ул Җәбирнең үзен күздән кичерде, аннан соң таяк очы белән төрткәләп, кәмә калдыкларын караштырды. Шулчакны ул кайчандыр кәмә борыны булып, алга чыгып торган һәм елан башы сымак итеп юнылган агач кисәгендә җиз калай түгәрәк күреп алды. Калай кисәгенә чүкеп бөгәрләнгән елан сурәте төшерелгән иде.

— Ә-ә, алай икән! — диде ир кеше, калай кисәген караштырып.

Шуннан соң ул сорап-нитеп тормыйча, хәтта тупас кыланып, Җәбирнең сул кулын тотып алды, имән бармагындагы яшел ташлы алтын йөзеген күзенә якынрак китерде дә йөзек кашындагы тамгага карап торгандай итте. Йөзек кашына су төбеннән күренгәндәй итеп, кеч-

кенә түгәрәк, түгәрәк уртасына сигез чатлы йолдыз төшерелгән иде.

— Алай икән, — диде тагын да ир кеше, хәлсез кулны ычкындырып. — Аңлашылды. Аклан. Лелег.

— Аңлашылмыйча, маңгаена язылган бит! — диде яшь кыз.

Ир кеше үзенең кулындагы йөзеген караштырганда Җәбир ирексездән кызны күзәтте. Кыз аңа чибәр генә булып күренде. Шул чакны күңелен әрнетеп, бәгырен телгәләп, Акланда калган сылу Лүчнәсе, әйтмичә аның энҗе-мәрҗәнен алып китүе исенә төште. «Мин сиңа йөзе белән, меңе белән кайтарырмын, Лүчнәм!» дип уйлаган иде ул, тәбәнәк куыштан чыгып киткәндә.

— Маңгаена язылган дисеңме? — диде ир кеше һәм диңгез китереп ташлаган бу кешенең маңгаенда ни бар икән дигән сыман, Җәбирнең битенә янә бер җентекләп күз төшереп алды.

— Маңгаенда берни юк, кызым, — диде ул, үзалдына сөйләнеп.

— Лелегләрнең маңгаенда кояш балкый дип үзең әйттең түгелме соң, әти, — диде кызый, төнбоектай апак тешләрен күрсәтеп.

— Шулайдыр, балкыйдыр, — диде ата кеше, күрәсең, кызының сүзгә катышуын бик үк яратмыйча.

Шул чакны ул Җәбирнең билендәге көмеш кынылы хәнҗәрен күреп алды, Җәбир аны-моны уйлап өлгергәнче, бил каешындагы каптырманы ычкындырды да, сөяк сапны кысып тоткан килеш җиз хәнҗәрне тартып чыгарды. Хәнҗәр йөзеннән кан сыман булып диңгез суы тамды. Кеше кынидагы суны түкте дә үткер җизне кире кыныга тыгып куйды.

— Син кем? — диде Җәбир, телгә килеп.

Аның күңелендә бу кешегә карата ачу тойгысы уяна башлады.

— Мин — Нәхи, — диде ир кеше. — Бу минем кызым — Сара. Монысы безнең этебез — Тоткап. Моннан бер чакрым ераклыкта безнең утар. Сыерым, утыз сарыгым бар. Бу — минем җир. Диңгез ни китереп ташлый — барысы да минеке. Бу агачың да, хәнҗәрең дә... үзең дә!

Көтүче Нәхи, юеш ком өстендә аяк эзләре калдырып, читкә китеп барды. Аның артыннан кызы Сара, эте Тоткап иярде. Аларның да ком өстендә аермачык булып аяк эзләре калды. Юеш ком бетеп, коры ком башланган төшкә җиткәч, Сара артына борылды, елмайгандай итте. Тоткап та артына борылды, өрә-өрә кире килде. Ләкин

Җәбир янына ук килеп җитмәде — Сараның «әйдә!»сен ишетеп, өрүеннән туктап, хуҗалар артыннан ашыкты.

Бераздан тәбәнәк чанага ике үгез җигеп, алар яңадан килделәр. Җәбирне чанадагы камыш чыптага сузып салдылар да кайту ягына борылдылар. Кузгалып киткәнче Нәхи яңадан су буена барып, кәмә калдыгын кузгатып карады, кузгата алмады.

— Ярар, соңыннан килеп алырбыз, — диде ул.

Чанага салынган Җәбирне ярдан читтәге, калкулык өстендәге бер кечкенә авылга алып кайттылар, мал абзары янындагы бер кечкенә куышка кертеп салдылар.

— Ашат-эчерт. Аякка басканчы күз-колак бул, — диде ата кеше кызына.

Боларның барысын да Җәбир төштәге кебек кенә ишетеп ятты. Ул инде күптән ярым йокылы хәлдә иде.

Хәлләнгәч, аягына баскач аны бакчада эшләргә куйдылар. Таш кәтмән белән ул бакчадагы кантарларны вaклады, җирне йомшартты һәм, канау ерып, якындагы күлдән су кертте. Кәмиләрнең изге суы, Нилнең бер тармагы, дөресрәге, шул тармакның бер чыбык очы Либи иленә якын урнашкан шушы авылга килеп җитә. Ташу вакытында су тар елганы күмеп китә, ярларыннан чыга, юллар, басулар, бакчалар су эчендә кала. Калкурак җирләргә урнашкан өйләр, каралты-куралар гына коры җирдә торып кала. Бу вакытта кешеләр күршеләренә кәмәләргә, камыш салларга утырып йөриләр. Ташу монда озак тормый. Ташу кайткач та җир эшләре башлана: бүлеп алынган басуларга ашлык чәчәләр, җимеш-яшелчә утырталар. Эссе кояшта җирнең өсте кибә, корый һәм ката башлый. Шуңа күрә аны туктаусыз йомшартып торырга, чүп үләннәрен утарга туры килә. Һәркемнең үз җире, үз җирендә үз күле бар. Күлдә балык үрчи, күл буенда урман булып камыш үсә. Камышлыкта су кошлары бала чыгара. Ташу вакытында күлләргә су тулып кала. Корылык башлану белән суны күлдән алалар, бакчага, басуларга җибәрәләр. Бөтен нәрсә шаулап-гөрләп, котырып үсә. Арпа, бодай басулары, бакчалар кешегә мул итеп уңыш бирә. Кулыңнан көрәгең, кәтмәнең төшмичә туктаусыз казынсаң, туктаусыз карап, күз-колак булып торсаң, әлбәттә.

Моңарчы Нәхи җырлап-көлеп кенә яшәгән. Ни өчен дигәндә, кайгысы булмаган. Тәүлегенә дүрт-биш сәгать кенә йоклап, көне-төне басуда, бакчада бил бөксә дә, бернинди авырлык сизмәгән — үз җирендә үзе өчен эшләгән. Янында хатыны булган, балалары булган. Хатыны белән кызы күбрәк өйдә аш-су белән булашсалар,

малайлары көтү көткәннәр, көтүдән бушаган чакларында аталары янында булганнар. Аның беркайчан колы-карасы булмаган, хуҗалыктагы барлык эшне алар шулай үз көчләре белән башкарып барганнар. Аның урынына авыз тутырып икмәк ашаганнар, ит, балык ашаганнар, аллаларга тиешенчә корбан биргәннәр, салым, ясак түләргә дә, биләргә бирем бирергә — барысына да җиткән.

Тик менә былтыр көз, каудан аеның унөченче көнендә Нәхи башына зур кайгы килгән — көтмәгәндә аның хатыны үлеп киткән.

Беренче көннәрдә Җәбир тырышып, күңел биреп эшләде. Юеш, пычрак җирдә казынырга яратмаса да, бу эш аңа таныш иде. Акланда аларның да шундый ук җирләре, иген басулары, җимеш, яшелчә бакчалары бар. Анда да туктаусыз казынырга туры килә. Туфрак та мондагы сыман түгел, башкачарак, суы да кибеп тормый — ага да ага. Җитмәсә, бер көпшәдән җылы су, икенче көпшәдән салкын су килә. Эчсәң эч, юынсаң юын, коенсаң коен. Сулы көпшәләр хәтта өй эченә керә һәм челтер-челтер агып яңадан тышка чыгып китә. Андагы сулар Изгеләр тавыннан килә. Шуңа күрә аның шифасы да күбрәк.

Монда эшләр бөтенләй башкача. Монда эш авыррак та, күңелсезрәк тә. Монда суны бүлеп, җыеп тотарга, йә булмаса әз-әзләп кенә тиешле җиргә агызып торырга кирәк. Барысы да кул көче белән.

Күңел биреп эшләде дигәч тә, ул моңа әллә ни күңел бирә алмады. Нәхинең карасы-колы буларак ул күңел бирергә, һичьюгы, күңел биргән булып күренергә тиеш иде. Аннан соң ул әле үзенең кайдалыгын да рәтләп белми. Теләсә дә ул моннан беркая да качып китә алмаячак иде. Аннан соң, аның инде качып китәсе дә килми иде бугай. Гел бергә, бер тирәдә булгангамы, икесе дә яшь булгангамы, озакламый Сара белән алар уртак тел таптылар, яратыша башладылар. Үзалдына сөйләнергә ярата торган һәм беркайчан йөзе ачылмый торган Нәхи дә аларның яратышуларына каршы бер сүз дә әйтмәде кебек. Шулай да киявенең бу ялкау лелег түгел, үз кешесе булуын Нәхи артыграк күрә иде бугай. Мал абзары янындагы куышта Җәбир дүрт-биш ай гына ялгыз йоклады бугай. Тора-бара монда Сара да күченгәч, тар куыш балкып, дөнья иркенәеп киткәндәй булды. Сараның Җәбир янына күченүенең икенче көнендә Нәхи тавыш чыгарды.

— Кызны бездә сорап, яулап алалар. Син сорамыйча гына алырга күнеккәнсең икән! — диде ул Җәбиргә, төкерекләрен чәчеп.

— Әти, мин үзем, — диде Сара, ике арага кереп.

— Һе, үзең булмый ни! — диде Нәхи, мыгырданып.

Шулай да артык тузынмады. Бер-ике көн карасына коелып йөрде дә, яңадан элеккечә үзалдына сөйләнә башлады. Җәбир белән Сара шунда кечкенә ялгыз куышта торып калдылар — аларны иркенрәк өйгә чакыручы булмады. Икәүдән икәү генә торып ятканда, көннәрдән бер көнне Сара моннан ерак булмаган Хәсән авылында яшәп ятучы туганнары турында сөйләде. Былтыр көздән аларның малайларын ниндидер юлбасарлар үтереп капчыкка салып алып китә язганнар, имеш. Икенче бер бала качып калган. Хәзер шул бала куркудан этенеп сөйләшә икән дә, акылга да җиңеләйгән икән, имеш.

Сара Җәбирдән баштарак аның кем булуы, каян килеп чыгуы турында сораштырып караган иде, ләкин Җәбир аңа ачылырга бик ашыкмады. Сара да артыгын төпченеп тормады. Аны ярата, аның янында көчле, дәртле ире бар — аңа тагын ни кирәк тә, аның үткәне нигә кирәк?! Билгеле, Җәбир аңа үз исемен, чын максатын әйтмичә генә икеле-микеле итеп кайбер нәрсәләр сөйләгән иде. Җәбир, үткәне турында сөйләшкәндә, ул ни өчендер үртәлде, тотлыкты, тупасланды һәм гомумән үзен бик сәер тотты. Хәсән авылындагы тотлыга торган малай турында сүз чыккач, Җәбир сагаеп калды, төсе үзгәрде. Сара, билгеле, андагы үзгәрешне шундук сизеп алды.

Бераздан Сараның этисе Нәхи юкка чыкты.

— Әтиең күренми... кая китте ул? — диде Җәбир.

— Мин белмим... — диде Сара, ничектер ышанычсыз гына, нәрсәнедер Җәбирдән яшергән сыман.

Икенче көнне үзе генә бакчада казынып ятканда ишегалдына кулларына озын таяк тоткан, калку гәүдәле, усал кыяфәтле таза гына ике-өч ир кеше килеп керде. Килеп керделәр дә, туп-туры Җәбир янына килеп җиттеләр һәм аны-моны аңлап өлгергәнче, икесе ике яктан тотып та алдылар, кулларын артка каерып бәйләп тә куйдылар. Җәбир бар көченә кычкырырга тотынды. Ләкин Нәхи куышыннан да, абзар янындагы куыштан да ярдәмгә беркем чыкмады, хәтта Тоткап та күренмәде. Әллә ишетмәделәр, әллә каядыр китеп барганнар иде.

Ирләрнең берсе Җәбиргә муенчак кидерде, бар көченә сыртына таяк белән берне кундырды да, сугымга алып барган мал кебек аны каядыр алып киттеләр. Куркудан, коты алынудан Җәбирнең йөрәге туктап калгандай булды. Бөтен гәүдәсендә ул беркайчан булмаган авырлык тойды. Аяклары карышты, башы үзеннән-үзе аска

иелде. Күз кырые белән генә ул камыш сыман куышлар янында, тәбәнәк җилкапкалар алдында басып торган картларны, хатын-кызлар, бала-чагаларны күреп калды. Алар аңа төртеп-төртеп күрсәттеләр, кычкырдылар, аның турында шомлы итеп нидер сөйләп калдылар.

Бер-ике мәртәбә ул абынып китте, чак-чак кына егылмый калды. Абыну белән шундук муенны авырттырып торган муенчак тартылды һәм арттан сакчылар бер-бер артлы таяк белән тондырып алдылар. Җәбир кычкырып җибәрде. Шул ук вакытта үз-үзен кызганып, искәрмәстән күз яшьләре агып чыкты.

Алар шактый озак бардылар — Җәбиргә шулай тоелды. Аны авыл агасына алып бардылар. Авыл агасының өе бүтәннәрнекенә караганда зуррак, биегрәк күренде. Өй янында халык җыелган, үзара шаулашып, гәпләшеп, аның килеп җиткәнен көтеп торалар иде. Алар якынаю белән, шау-шу тынып калды, барысы да юл биреп читкәрәк тайпылдылар. Алар яныннан узып киткәндә, Җәбир ачу, нәфрәт бөркелеп торган уттай күз карашлары күрде, ачулы пышылдаган, ысылдаган тавышлар ишетелде.

Авыл агасының өе эчке яктан да зур гына иде. Камыш чыпта җәелгән җир идәндә аякларын бөкләп берничә аксакал, түрдә, калку урында, яңак сөякләре калкыбрак торган, озынча битле, зур башлы һәм зур гәүдәле авыл агасы утыра иде. Алгы ягын каплый торган кыска гына алъяпкычтан башка аның өстендә бүтән берни юк. Ике як күкрәкләре салыныбрак торган тәне шәрә, кара-кучкылланып кояшта янган. Аяклары ялангач.

Авыл агасының аяк астында гына диярлек, ике якта ике битекче. Алар, аксакаллар кебек, аякларын бөкләп утырганнар да, тезләренә куелган киң тактадагы ак кәгазьләргә карап, камыш каләмнәрен әзер тотып, тынып калганнар. Җәбирне өйгә алып кергәч тә, алдан муенчак тотып килгән ир, муенчак очын кулыннан ычкындырмыйча читкәрәк китте, таяклы сакчылар ишек төбенә бастылар. Җәбир, хәлсез калып, ярлыкау өмет итеп, ага алдына тезләнде.

Авыл агасы кулындагы таягы белән җир идәнгә төртеп алды да сорау ала башлады. Кем син, каян, диңгезгә ник чыктың, юлдашларың кая, кемнәр? — берсе дә калмады. Барысын да сорады. Җәбир, каушап, тотлыгып, һәр сорауга җавап бирде. Нәхигә, аның кызына нәрсә әйткән булса, шуларны сөйләде: «Былтыр, өченче айда Акланның мака сары Кадирга җибәрде, — диде, — анда савыт-саба, ашлык алып бардык. Диңгездә карак-

лар, юлбасарлар очрый-нитә калса дип, мака сар безне сакчы итеп җибәрде, — диде. — Тирән диңгездә көчле җил-давыл чыкты, безне дулкын бөтереп алды, берзаман кәмәбәзне кара кыяга китереп бәрде. Юлдашларым исәнме-юкмы, белмим — мин менә исән калганмын»,— диде.

Авыл агасы бүлдермичә тыңлап торды. Ике яктагы ике битекче, каләмнәрен карага манып, тиз-тиз генә язып бардылар. Җәбир сөйләп бетергәч, авыл агасы янә таягы белән идәнгә төртеп алды. Өйгә Нәхи белән аның кызы Сараны керттеләр. Нәхи дә, Сара да шундук ага алдында тезләнделәр. Беренче булып Нәхи сөйләде. Күргәч тә күңелем сизенде — агамның улларын бу явыз гына урлаган булырга тиеш, диде. Аның яңадан безнең җиргә килеп туктавы — аллалар эше ул, диде. Сөйләгәндә ул әледән-әле Җәбир ягына бармагы белән төртеп алды, очып кунардай булып кымшанып, укталып алды. Шуннан соң Сара сөйләде. Ул да белгәнен әйтте. Бер гөнаһсыз энеләренең урлануы турында сөйләгәндә, бу кол бик үртәлде, тынычсызланды, диде.

Шуннан соң авыл агасы, күзләрен акайтып, ашардай булып, Җәбиргә карады да:

— Моннан бер ел элек, җил иясенә корбан итеп бирү өчен, балаларны син урларга куштыңмы, Җәбир, әйт! — диде кычкырып. Җәбир үз исемен ишетеп сискәнеп китте, коелып төште. Шулай да ул үзен кулга алды.

— Юк, мин урламадым да, кушмадым да һәм мин... Җәбир исемле түгел, — диде ул, нык итеп. Эченнән исә уйлап куйды: димәк, чүлмәкчеләр «сатканнар» моны.

Авыл агасы тыныбрак торды.

— Алайса, Сарага сөйләгәндә ник үртәлдең, каушадың? — диде ул.

— Сара сөйләгәнчә, аның энеләрен лелегләр, акланнар урлап киткән. Мин дә аклан. Ничек каушамыйсың?! Ул бит күрәләтә, алдан ук «Син урладың!» дип әйтмәкче булып сөйли. Кәмигә Акланнан да, башка илләрдән дә төрле кешеләр килә. Аклан кешесе булган өчен генә мине балалар урлауда гаепләү дөрес булмас иде, изге ага.

Барлык батырлыгын җыеп, барлык осталыгын, хәйләсен бергә туплап, Җәбир шулай диде. Авыл агасы беравык тынып утырды, аксакаллар тавыш-тынсыз гына бер-берсенә карашып алдылар. Җәбирнең сүзләре аларга ышандыргыч тоелды, ахрысы. Авыл агасы Нәхигә төбәп карады.

— Шушы Аклан кешесенең, синең колыңның малай урлап китүен үз күзе белән күргән кеше бармы? — диде ага.

Нәхи мондый сорау көтмәгән иде бугай. Ул каушабрак калды, тиешле сүз таба алмыйча ык-мык итте.

— Юк, изге ага, — диде. — Андый кеше юк.

— Шулай булгач, ник тавыш куптардың? — диде ага, ачу белән.

Нәхи эшнең болайга китүен күреп, кычкырып еларга тотынды. Аңа кызы Сара кушылды.

— Ялган эш кузгаткан өчен Нәхигә ун таяк, кызы Сарага биш таяк! — диде авыл агасы, соңгы сүзен әйтеп.

Нәхи дә, Сара да шып булдылар, бөрешә төштеләр. Аларны шундук өйдән алып чыгып киттеләр. Авыл агасы Җәбиргә борылып карады.

— Син, Аклан диңгезчесе Җәбир, Нәхинең туганының улын урламавыңны әйтеп, изге аллалар исеме белән ант ит, — диде ул, күтәренке тавыш белән.

Җәбирнең күз аллары яктырып китте. «Нинди алла исемен әйтерсең, шуны әйтәм» дип уйлады ул шундук һәм кычкырып авыл агасы, аксакаллар алдында ант сүзләрен әйтте дә үзен хәзер котылганга, хәтта җиңүчегә исәпләп:

— Изге ата, Нәхи минем көмеш саплы җиз хәнҗәремне алды, диңгез чыгарып ташлаган кәмә калдыгын алып кайтты. Бер елга якын мин аңа кол урынына эшләдем. Ул миңа җиз хәнҗәремне кайтарып бирсен, кәмә калдыгы өчен — мака сарга, эшләгән өчен миңа түләсен, — диде.

Мондый сүзгә ага аптырабрак калды. Киңәш сорагандай, ул аксакаллар ягына карап алды. Шунда аксакалларның берсе, тупас, карлыккан тавыш белән:

Бездәге тәртип шундый: диңгез буе да, диңгез китереп ташлаган нәрсә дә авылныкы исәпләнә. Сине диңгез Нәхи турысына китереп чыгарган. Үзең дә, әйберләрең дә Нәхинеке, — диде.

— Мин — Изге Аклан кешесе! — диде Җәбир, тавышын күтәрә төшеп. — Мака сардан илче килсә, мин аңа барысын да сөйләрмен. Бу эшне ул болай гына калдырмас!

Шуннан соң алар җиңелчә шаулашып, сүз көрәштереп алдылар. Авыл агасы таягы белән төртеп алды да:

— Кәмә калдыгын да, хәнҗәреңне дә, үзеңне дә Нәхи үзендә калдыра ала иде, — диде. — Ләкин безнең тынычлыкны бозып, урынсыз эш кузгатты. Шуның өчен синең көмеш саплы җиз хәнҗәреңне Нәхи миңа бирер, кәмә калдыгын мака сар килеп алып киткәнче үзендә саклап торыр. Биш аксакалның һәркайсына берәр көн бушка эшләр. Сине, Аклан улы Җәбир, түрәчегә юллыйм.

Хәсән авылы Кәминең Сай иленә карый иде. Түрәче Сай иленең башкаласы Мичәндә тора иде. Котылдым дип уйлаган Җәбирне, кулын бәйләп, тәпи-тәпи атлатып, илле чакрым ераклыктагы Мичәнгә алып киттеләр, түрәчегә тапшырдылар. Авыл агасы чишә алмаган буталчык эшне түрәче бик җиңел чиште. Әле яңа тәхеткә утырган унике яшьлек сарның булачак төрбәсе өчен таш чыгаруда таза кул көчләре җитми иде. Шуңа күрә түрәче беркемгә дә үлем җәзасы чыгармый — барысын да Кызыл диңгез буендагы акташ кыяларына таш чыгарырга озата иде. Тыңлап, тикшереп тә тормыйча, Җәбирне дә ул шунда озатты.

Таш кисүдә тоткыннар биш кешелек, ун кешелек көтүләргә бүленеп эшләделәр. Биш кешелек көтүдә бер көтүче, ун кешелек көтүдә бер көтүче, ике ярдәмче булды. Кемнең ничек эшләгәнен, кемнең кая атлаганын көтүчеләр карап, күзәтеп кенә тордылар. Карышкан, телләшкән, ялкауланган тоткыннарны таяклы сакчылар таяк белән сыйладылар. Эшләгән эшне тикшерүчеләр үлчәп, тикшереп тордылар. Бер-ике сәгать эшләгәннең соңында берара ял бирделәр — үз йомышыңны йомышларга, эш коралларыңны җайларга, үткерләргә рөхсәт иттеләр.

Эш көне бер караңгыдан икенче караңгыга сузылды. Арып хәлдән тайганчы, ашыйсы килүдән, эчәсе килүдән башлар әйләнгәнче, кулдан кораллар төшеп киткәнче эшләттеләр. Арыганны, сусаганны, ачлыкны онытып тору өчен тоткыннар күмәкләшеп, көйләп күләү әйттеләр. Иртән йокыдан уянганда, көнең көнчыгыш ягына карап, Изге атабыз Атум бүген анасы карыныннан соңгарак калып тусын иде, диделәр. Көндез түбә өстен рәхимсез кояш кыздырганда, югарыга карап, атабыз Ра безгә дә шәфкатьлерәк булсын иде, без дә аның балалары, дип ялвардылар. Кичен эштән туктар вакыт җиткәндә, атабыз Атум тизрәк анасы куенына кереп югалсын иде, дип зекер әйттеләр.

Җәбирне таш кисеп күзе чыккан, куллары сөяккә әйләнеп беткән өлкәннәр көтүенә куйдылар. Аны өлкәннәр этеп-төртеп кенә йөрттеләр, барлык вак-төяк эшләрен аннан эшләтергә, барлык йомышларын аннан башкартырга тырыштылар. Көтүче Хамис аеруча оятсыз кыланды. Элекке юлбасар Хамис Кәми кешесе иде. Ул болай да Кәми булмаган кешеләрне өнәп бетерми иде. Көтүдә исә кәмиләрдән тыш, Аклан, Әблә кешеләре дә, Нуби каралары да, килмәтләр дә бар иде. Бөтен тәне, бите, аяклары яраланып, кутырланып беткән, башкалар-

дан калкурак гәүдәле калын һәм карлыккан тавышлы Хамис Җәбирне искәрмәстән сугып та җибәрде, тибеп тә җибәрде. Яңа кешене беркем якламады. Бары шаркылдап көлделәр генә һәм көтүчегә ачуланмаска, үпкәләмәскә киңәш кенә бирделәр. Яшь һәм җиңел булганга, Җәбирне Хамис таш эшенең иң авыр, иң хәтәр урыннарына куйды. Кулына таш чүкеч һәм җиз кискеч тотып, ул кош кунмас кыя башларына да менеп китте, биленә аркан бәйләп, упкын өстендә асылынып та эшләде, кичләрен, утын беткәч, күршеләрдән утын урлап та кайтты.

Шул рәвешчә, бер ел үтеп китте. Җәбир хәзер үзенең көтүдәшләренә өйрәнә, күнегә төште, аларның гадәтләрен, кыланышларын күзәтте һәм әле кайчан гына үзеннән шаркылдап көлгән кайбер тоткыннар белән уртак тел таба алды. Болар акланнар иде. Ул аларга үзенең серләрен чишге. Бары тик Хәсән авылы Нәхинең абыйсының улын корбанга бирү нияте белән үтертүе турында гына эндәшми калды. Тегеләр дә кайбер серләрен әйттеләр. Берсе, Камус дигәне, диңгездә йөзгән, төрле илләр күргән. Давылга эләгеп, кәмәләре су төбенә киткәч, Җәбир кебек үк, агач кисәгенә тотынып исән калган. Ярга чыккач, юлбасарлар кулына эләккән. Әлеге юлбасарлар... борынгы сарларының төрбәләрен талаучылар булып чыккан. Боларны тотканнар да менә монда таш кисәргә җибәргәннәр.

— Моннан чыгу юлы юк, — диде Камус, корык-корык йөткереп. Анда үпкә чире иде, ахрысы. — Сарга түгел, үзебезгә төрбә кисәбез. Безне шунда чүп-чар, ташком арасына ташлап калдырачаклар.

Икенче Аклан кешесе Сәмит яшьрәк иде. Ул әле котылуга, Акланга кайтып яшәячәгенә өметен өзмәгән иде.

Шулай бер ел үтте, бер елдан соң сигез ай үтте. Көннәрдән бер көнне көтүче Хамис, элекке гадәтенчә, нигәдер ачуы килеп, Җәбиргә сугып җибәрде. Җәбир чайкалып китте. Башкалар шаркылдап көләргә тотынды. Хамис шулай ук көлә башлады. Алар көлешкән арада, Җәбир исен-акылын җыеп аягына ныклап басты да көтүченең яңагына берне чәпәп алды. Көлешү тынып калды. Хамис аптырап калды, башкалар тынып калдылар. Хамис тешләрен кысып яңадан Җәбир өстенә килә башлады. Ләкин шул чакны көтелмәгән хәл булды — арттан килеп кемдер Хамиснең колак төбенә кундырды. Шундый иттереп кундырды, үз кулының авыртуына түзә алмыйча, кире чайкалып китте. Әллә үз кыюлыгыннан үзе куркып, әллә хәлсезлектән, ул хәтта артына чүкте, берни эндәшмичә котырып килүчегә карап тора

башлады һәм буылып-буылып ютәлләргә тотынды... һәм кан түкерә башлады.

Хамис инде аның ягына борылган да иде, кулын да күтәргән иде — көтмәгәндә арттан тагын берне сыладылар. Бу юлы Хамис чайкалып китте, авызын ачып нидер әйтмәкче булды, әйтә алмады — бары шаулатып тын гына алды. Тоткыннар арттан килә тордылар, йодрыкларын йомарлап тегеңә сылый тордылар. Хамис үзенең хәлен аңлап, качып китмәкче булды. Аңа аяк чалдылар. Ул егылды, һәм тиз арада аның эшен дә бетерделәр.

Элекке юлбасарны монда беркем яратмый иде. Аннан бары куркалар гына иде. Ректә чагында да, тоткында да ул күп кешенең канына тоз салды, җанын кыйды. Элегрәк ул йөз кешелек көтүнең көтүчесе булган, соңыннан картая башлагач аны үзе кебегрәк өлкәннәргә баш итеп куйганнар. Ул мондагы бик күп кешене танып белә, бик күп кешенең серен, кыек эшләрен белә, өстәге сакчыларга, күзәтчеләргә барысын да җиткереп тора иде.

Хамис белән бәрелешү кичкырын авылга кайткач, ашарга утырыр алдыннан булды. Үзара бәрелешләр, кычкырышлар, тәпәләшүләр еш булганлыктан, алардагы ыгы-зыгыга беркем игътибар итмәде. Караңгы төшкәч, куыштагы тоткыннар Хамиснең үле гәүдәсен пычрак чыптага салып төрделәр дә ач бүреләр улаган якка — иксез-чиксез сахра ягына алып киттеләр. Көндезге кызу сүрелеп җитмәгән комда сай гына чокыр казыштырдылар да, мәетне шунда ташладылар, өстенә ком сипкәләделәр һәм кире куышларына кайтып киттеләр. Алар китеп тә өлгермәделәр, артта, мәет күмеп калдырылган турыда, ялт-йолт булып яшькелт утлар янды һәм үзара ырылдашкан, чинашкан тавышлар ишетелде.

— Әнә, алла уллары килеп тә җитте. Юкка анда калдырдык. Яндырып көлен очырасы калган, — диде шул чакны Нуби карасы, үкенү белдереп.

— Уттан изге берни юк. Андый мәетне утта яндырырга ярамый, — диде Кәми кешесе, нәфрәтләнеп.

— Упкынга ташлыйсы калган — ятсын иде шунда, беркем күрмәгән җирдә, — диде Акай кешесе.

Әледән-әле артларына карап, андагы тавышларга колак салып, алар үзләренең авылларына кайттылар. Төнге чүлдә калу куркыныч булган кебек, аларга үзләренең авылына кайтып керү дә куркыныч иде. Авылны кораллы сакчылар саклый. Ләкин сахра ягы болай да үлеләр ягы исәпләнгәнгә, ул якка беркем дә качып китми, качса йә аны төнге шакаллар ботарлап ташлый, йә адашып ул үзе шунда юкка чыга. Алар исән-имин авылга кереп, үз

куышларына җиттеләр, чыпта ишекләрен күтәреп эчкә керделәр һәм шундук башларын төртеп йокыга китмәкче булдылар. Ләкин тиз генә йокыга китеп булмады. Курку әле бетеп җитмәгән иде. Сахрадан, бүреләрдән, сакчылардан курку түгел, башка төрлерәк курку иде бу.

Шулай да йокы куркудан да көчлерәк булып чыкты. Озакламый әле анда, әле монда гырлап йоклаган, борын тарткан һәм саташып сөйләнгән тавышлар ишетелә башлады. Бер ярты сәгать вакыттан соң бөтен тирә-як тынып калды. Бары тик тышкы якта гына, бик ерактa ниндидер чинаган, үкергән тавышлар ишетелеп-ишетелеп китте. Ләкин куыштагылар өчен андый тавышларның бернинди куркынычы да, катнашы да юк иде.

Менә йоклап китәм, менә йоклап китәм дип үз-үзе белән тарткалашып ятканда, көтмәгәндә Җәбир янына кемдер шуышып килде һәм аның битенә сакланып кына кулын тидерде. Җәбир сискәнеп китте һәм чиктән тыш сагаю белән тагын ни буласын көтә башлады. Тиз генә башын калкытырга йә булмаса битендәге кулны алып ташларга ихтыяр көче җитмәде — аның инде бөтен тәне оеп бара иде.

— Җәбир, йоклыйсыңмы? — диде караңгыда ят кеше, пышылдап.

Ят кешенең тавышы шулай да таныш сыман тоелды. Бу теге Хамискә өченче булып арттан тондырган Аклан кешесе Сәмит булырга тиеш иде.

— Йокламыйм, — диде Җәбир, көттеребрәк.

— Әйдәле, тышка чыгыйк — сөйләшәсе сүз бар, — диде Сәмит, шулай ук пышылдап.

— Ярар, — диде Җәбир янә көттереп һәм үзе дә сизмәстән йоклап китте.

Күп тә үтмәде, кемдер авырттырып аның кабыргасына төртте һәм, колак төбендә генә пышылдап:

— Әйдәле, тышка чыгыйк — сөйләшәсе сүз бар, — диде.

«Бер мәртәбә әйткән иде бит инде» дип уйлады Җәбир йокы аралаш, ризасызлык белән. Аның, билгеле, һич тә йокысын бүләсе килмәде. Аның йоклыйсы, онытыласы, көндезге, кичке күренешләрне онытасы килде. Сәмит шул чакны аның башын калкытты, чәчен тарткалады һәм шактый усал итеп:

— Җәбир улым, тор! Куа киләләр! — диде.

«Куа киләләр?! Кемнәр?» дип уйлады Җәбир, йокы исереклегеннән айнып. Аягына басты да, каядыр китмәкче булды. Сәмит аны култыклап, тышка алып чыкты.

Тышта дөм караңгы иде. Күктә, бик еракта, җемелдәп йолдызлар балкый. Һава тын һәм салкынча. Тән карасыннан чак-чак кына аерылып торган зур таш янына килделәр. Ташны кайчандыр бик күптән төрбә өчен дип кискәннәр, тигезләгәннәр, чанага салганнар дә төрбә төзеләсе урынга алып киткәннәр. Ләкин юлның бер ягы авышрак булган. Көтмәгәндә таш янтайган, ауган һәм мәңге шунда торып калган. Таш ауганда өч-дүрт кеше шунда басылып калган.

Таш янында тагын ике-өч карачкы бар иде. Болар якташлар, акланнар иде. Барысы бергә җыелгач, Сәмит һәркем ишетерлек итеп, шулай да күбрәк Җәбиргә эндәшкән сыман, сүз башлады:

— Монда сезне мин җыйдым, — диде ул. — Хамисне тәмугка олактырдык та котылдык дип уйладыгызмы? Котылмый тор! Иртәгә иртән барысы билгеле булачак. Кичкә безнең үзебезне Хамис янына чүл бүреләренә азыкка илтеп ташлаячаклар. Беренче булып Хамискә кем сукты? Җәбир! Икенче булып кем сукты? Камус! Өченче булып кем сукты? Мин!

— Иң элек ул үзе башлады. Барыгыз да күреп тордыгыз! — диде Җәбир, тавыш биреп.

— Күреп тордык, — диде Сәмит, Җәбирнең сүзен җөпләп. — Без аны барыбыз бергәләп юк иттек. Шуңа күрә иң элек безнең өчебезне таяк белән кыйнап үтерәчәкләр яисә Нуби иленә алтын чыгарырга җибәрәчәкләр.

— Алтын чыгарырга?! — диде Җәбир, үзе дә сизмәстән.

— Алтын, — диде Сәмит мыскыл белән. — Җир астына төшерәләр дә, үлгәнче шунда алтын чыгарасың.

— Анда алтын җирдә аунап ята, диләр! — диде Җәбир.

Кара таш янындагы карачкылар җиңелчә гөрелдәп алдылар.

— Җирдә түгел, җир астында! — диде Сәмит.

— Анда киткән кеше кире кайтмый! — диде Камус һәм корк-корк йөткерергә тотынды.

Аның йөткерүе басылганны көтебрәк тордылар да Сәмит карачкыларны үзенә якынрак тартып китерде һәм, ярым пышылдап:

— Без барыбыз да акланнар, — диде. — Таң атканчы безгә моннан таярга кирәк. Сез шуңа әзерме?

— Таярга? — диде Җәбир, аңлап җитмичә.

— Мин юлын беләм, — диде Сәмит. — Көн яктырганчы безгә ничек тә елга ярына барып җитәргә кирәк. Анда, яр буенда, кәмәләр!

— Бик үк аңлашылмады, — диде Җәбир. — Таң атканчы елга ярына ничек барып җитәсең? Тау-таш арасында адашып без барыбер сакчылар кулына эләгәчәкбез.

— Мин исән булсам, эләкмәссез! — диде Сәмит. — Син килгәнче без инде күп йөрдек монда. Хәзер без турыга китәбез, пычак кыядан туп-туры яр буена төшәбез.

— Ничек итеп? — диде Җәбир, тагын да ныграк түземсезләнеп.

Башкалар сүзсез генә тыңлап тордылар.

— Безнең анда... ышанычлы җирдә җеп яшерелгән, — диде Сәмит, серен чишеп.

— Кыядан төшәргә... минем хәл җитмәс, — диде Камус һәм яңадан авызын томалап тыелып кына йөткерә башлады.

— Каласыңмыни? — диде Сәмит усал итеп.

— Калам. Чәнчеп китегез шушында, — диде Камус, өметсезлек белән.

— Юу-к! — диде Сәмит, сузып. — Без сине монда калдыра алмыйбыз. Син безнең белән китәчәксең. Теләсәң, кыя башында калдырып китәрбез... козгыннарга... тилгәннәргә...

— Китәрмен, — диде Камус, теләр-теләмәс кенә.

— Син, Җәбир, — диде Сәмит, очлы хәнҗәрен яшь егетнең ияк астына терәп.

— Мин сезнең белән, — диде Җәбир. — Үлсәм дә, калсам да, сезнең белән.

— Антмы?

— Ант! — диде Җәбир.

— Сез? — диде Сәмит, карачкыларга борылып.

— Энә кая — җеп шунда! Син безнең көтүче, — диделәр тегеләр дә, ризалыкларын белдереп.

Шуннан соң алар бер-бер артлы тезелеп Сәмит артыннан каядыр китеп бардылар. Бер-ике сәгатьтән пычак кыяга барып җиттеләр. Сәмит яшерелгән җирдән яхшылап җыелган, төйнәлгән аркан чыгарды. Арканның бер очыннан икенче очына кадәр ике яктан тартып ныклыгын тикшереп карадылар. Шуннан соң шобага тоттылар. Иң өскә чыккан кеше иң ахырдан төшәргә тиеш иде. Җәбир өскә чыкты. Беренче булып Камус төшәргә тиеш булып чыкты. Ул тагын киреләнә башлады. «Мин куркам, шушында гына калдырып китегез», — диде. Сәмит юлдашларына борылып карады.

— Төшсен! — диделәр башкалар.

Камус калтыранган куллары белән арканга тотынды, кычкырып, белгән догаларын укыды да әкрен генә төшә башлады. Барысы да, тыннарын кысып, аның түбән

төшә баруын карап тордылар. Күпмедер вакыттан соң аркан бушап калды һәм икенче булып түбәнгә Сәмит төшә башлады. Өстәгеләр арканның җиз шешкә бәйләнгән һәм кыя ярыгына кыстырып куелган очын тотып карап-күзәтеп тордылар.

Күктә инде йолдызлар сүнә башлады. Көнчыгыш якта илаһи яктылык туып килгәне шәйләнде. Аста, бик еракта һәм шул ук вакытта бик якында тере булып, җанлы булып, караңгыда исә иксез-чиксез булып, бөек елга агып ята.

Шобагада чыкканча, алар шулай бер-бер артлы төшә тордылар. Иң ахырда кыя башында Җәбир үзе генә торып калды. Аңа куркыныч, бик куркыныч булып китте. Ул хәзер моннан беркайчан төшә алмас, юлдашларына кушыла алмас шикелле тоела башлады. Төшкәндә йә арканы өзелеп китәр яисә кыя ярыгына кыстырган җиз шеш ычкынып китәр төсле тоелды. Ләкин аның, билгеле, монда торып каласы да килмәде. Монда калу ул үлем белән бер иде. Кыядан төшү никадәр куркыныч булмасын, шулай да аңа яшәү вәгъдә итә иде.

Аркан нык тартылмый башлагач, соңгы мәртәбә ул кыя ярыгындагы җиз чөйне тикшереп карады да ике куллап арканга тотынды, корсагы белән таш өстенә ятып, түбән таба шуыша башлады.

Юлдашлары тавыш-тын чыгармыйча аны аста көтеп тордылар. Төшеп җитәрәк, кулларын сузып, күтәреп алдылар һәм котылуларына сөенеп, ташлы тар үзәннән елга ярына элдерделәр.

Елга аларны диңгез буена алып чыкты. Ике тәүлектән соң, камыш урманнары арасыннан бара торгач, иртәнге якта ниндидер дөпелдәгән тавышлар ишеттеләр. Күп тә үтмәде, алда, елга тамагындагы зур гына утрау янында туктап калган йөк кәмәсе күренде. Кәмәдән яр өстенә сузып салынган таскаклар өстеннән бүрәнә тәгәрәтәләр иде. Кояшта янган таза ирләр ыргаклы арканнар, тырнаклы колгалар белән бүрәнәне кәмә кырыена тартып китерәләр дә «һәйли-һоп!» дип, бер-берсенә көч биреп таскак ягына тартып чыгаралар. Кызгылт кабыклары чыелган юан наратлар, авыш таскаклар ягына чыгу белән, дөпелдәп түбән тәгәри. Шуннан бөтен тирә якта дөпелдәгән, тонык кына шакылдаган тавыш ишетелеп куя.

Йөк кәмәсе Акланныкы иде, кәмәдән бүрәнә бушатучы ирләр дә акланнар иде. Җәбир моны ерактан ук шәйләп алды. Туган ил кәмәсен, туган ил кешеләрен, бүрәнәләрен күреп аның кинәт күңеле нечкәрде, күзләренә яшь килде, йөрәге сулкылдап тибәргә тотынды.

Аның тизрәк кәмәдәгеләр янына барып җитәсе, кешеләрне генә түгел, елан башлы, горур борынын югары күтәреп, талгын гына чайкалып торган кара кәмәне, җир өстендә аунап яткан бүрәнәләрне берәм-берәм кочасы, иркәлисе килде. Шул ук вакытта, төнге яшен яктысы кебек булып, аның күз алдында балкып торган бистәсе, этисе, әнисе, туганнары һәм, әлбәттә, сөекле Лүчнәсе күренеп киткәндәй булды.

Аның белән бергә килгән юлдашлары да шундыйрак хисләр кичерделәр, ахрысы. Аклан кәмәсе күренү белән, барысы берьюлы диярлек кычкырып җибәрделәр. Утрау ярына килеп туктадылар да, ашыгып-кабаланып ярга чыктылар һәм котылулары өчен изге бөек аллаларга рәхмәт юллап җиргә егылдылар, түшләре белән шуышып кәмәгә таба бара башладылар.

Бүрәнә бушатканны күзәтеп, яр читендә ниндидер олы кеше басып тора иде. Ул өстенә җирән төскә манылган киндер чапан бөркәнгән, башына исә яңгырдан саклану өчен киелә торган башлык киеп куйган. Беркайчан диярлек яңгыр яумый торган Кәми җирендә, билгеле, яңгырдан саклануның кирәге юк иде. Чапанын да, башлыгын да ул чебен-черкидән саклану өчен кигән булырга тиеш иде. Моның шулай икәнлеген аңлаткан кебек, олы кешенең ике ягында ике шәрә кеше кулларына тоткан озын саплы зур яфрак — җилпәзә белән чебен-черкиләрне куып торалар иде.

Үз артында ниндидер шау-шу ишетеп, олы кеше артына борылып карады һәм күз яшьләрен агызып, түшләре белән шуышучы кешеләрнең үз янына килеп җитүләрен көтеп тора башлады. Камышлы ермак ягыннан килүче кешеләрне бүрәнә бушатучылар да күреп алдылар һәм кызыксынып, гаҗәпләнеп, исләре китеп карап тора башладылар. Комлы җирдән түшләре белән шуышып килүчеләр кояшта какланган балык кебек чандырлар һәм ябыклар иде. Аларның кемлеген ачыклау өчен әллә ни баш ватып торасы да юк. Алар тоткыннар йә булмаса коллар гына булырга тиеш. Ләкин күз яшен агызып елаучы ирләр һич тә үзләрен тоткын яисә кол дип атамадылар. Алар үзләрен диңгездә давылга юлыккан, дулкын тарафыннан яр буена чыгарып ташланган бәхетсез мескеннәр дип атадылар. Аларның бердәнбер үтенече шул булды: Акланга алып кайт безне диделәр.

Олы кеше тиз генә эндәшмәде. Иң элек ул, аягы белән төртеп, якындагы Сәмитнең җиргә кадәр түбән иелгән башын күтәргәндәй итте, аның йөзенә карады, таныды

һәм усал көлемсерәп, теш арасыннан «Алай икән!» дип куйды.

Шуннан соң олы кеше Сәмит янындагы икенче бер кешенең дә башын аягы белән генә күтәргәндәй итте дә аның да йөзенә карады, аны да таныды, аяк очы белән төртеп җибәрде.

Тупас һәм кырыс йөзле, зур, авыр гәүдәле олы кеше карлыккан тавыш белән нидер әйтте дә иелгән, тезләнгән кешеләрне берәм-берәм карап чыкты. Арада тагын бер кешене таныды ул. Иң ахырдан арттарак, башкаларга посыбрак торган Җәбир янына килде. Олы кеше үзен таныганчы, Җәбир инде аны бер караудан ук танып алган иде. Бу теге Акланда, Таш култык кабагында аны төртеп җибәргән, кабактан куалаган диңгезче «Их»иде. Мондый көтелмәгән очрашудан Җәбирнең эче жу итеп китте. Җәбиргә ул аның барлык этлекләрен — Акланнан кәмә урлап китүен дә, җил алласына багышлап корбан бирү өчен малай урлавын да — барысын да беләдер шикелле тоелды. Менә ул мондагы тоткыннан, коллыктан котылды. Ләкин Сәмит уйлаганча, алар Акланга кире кайтсалар, аны анда хөкем көтә. Олы кешене күргәч, таныгач, аның күңеленә шундый уй килде һәм аның өчен монда хәзер беркемнең, бернинең кызыгы калмады. Шуңа күрә ул бөрешеп, җиргә берегеп, олы кешенең килеп җитүен көтә башлады.

Олы кеше килде, аягы белән төрткәләп, Җәбирнең дә башын калкыткандай итте. Җәбир ничек тә йөзен күрсәтмәскә тырышты.

— Сине дә кайдадыр күргән кебек булам, — диде олы кеше.

Шулай диде дә, Җәбирнең киреләнеп торуына ачуы килеп, күрәсең, арт яктан каты итеп тибеп җибәрде. Җәбир борыны белән комлы җиргә төртелде. Ачудан аның шундук сикереп торасы, Хамискә салып җибәргән кебек бар көченә салып җибәрәсе килде. Ләкин ике көн инде рәтләп ашамаганга, аның хәле юк иде. Аннан соң ул үзенең генә түгел, бөтенесенең дә тулысынча олы кеше кулында булуын да аңламый булдыра алмады. Җәбир хурлыктан һәм көчсезлектән елап җибәрде. Олы кеше аңа бүтән игътибар итеп тормады. Сәмит каршысына барды да уйлангандай итеп аңа карап тора башлады:

— Нишләтергә икән сезне? — диде ул, үзалдына сөйләнгән сыман.

— Коткар! Акланга алып кайт, атабыз! — диде Сәмит, җанланып, кулларын сузып.

— Акланга? — диде олы кеше. — Акланда сезне беренче күрүдә үк тотып асачаклар.

— Ассыннар, туган илемне күрсәм, ишемне, балаларымны күрсәм, үлсәм дә үкенмим, — диде Сәмит.

— Алай икән, — диде олы кеше, усал көлемсерәп. — Мин сиңа, Сәмит, әйттем: алтын безнең үзебездә чыга, алтын безнең үзебезнең аяк астында аунап ята, дидем. Тыңламадың. Кәмиләрнең төрбәгә күмелгән алтыннарына кызыктың. Кая алтының? Мин сезне бушлай ашатырга, бушлай алып кайтырга тиешме?

— Бушлай түгел, бушлай түгел. Эшләрбез. Ни кушсаң, шуны эшләрбез. Менә кулыбыз: беләктә көч, йөрәктә дәрт бар, — диде Сәмит, олы кешенең аягын кочаклап. — Ни кушсаң, шуны эшләрбез. Кулыбыз эш белә, күзебез күрә, аякларыбыз йөри.

— Болар да синең кебек аяк астында аунап яткан алтынны эзләп килгәннәрме? — диде олы кеше, Сәмитнең ялваруына игътибар итмичә.

— Барыбыз да алла бәндәләре, — диде Сәмит, башкалар өчен җавап биреп.

— Алла бәндәләре булсагыз, алладан сорагыз, — диде олы кеше, ямьсез көлеп, һәм башка сөйләшәсе килмәгәнен белдереп каядыр читкә китеп барды. Җилпәзәләрен селкетеп, сүзсез генә аның ике ягыннан ике колы атлады.

Шул чакны олы кешегә каршы атлаучы тагын да олырак икенче кеше килгәне күренде. Ул мондагы утрау хуҗасы булырга тиеш. Куе кара чәчләре арттан турыга кыска итеп киселгән һәм таралмасын өчен челтәр белән тоттырып куелган, тезенә кадәр җитеп торган ак киндер итәгеннән башка өстендә бернинди кием-фәлән булмаган Кәми сар «кулы» карап торуга олы кешедән яшьрәк, калкурак һәм аннан эрерәк, дәрәҗәлерәк кыяфәтле иде. Аның ике ягыннан шулай ук җилпәзәле ике кол килә, алардан читтәрәк язу каләмнәрен, язу такталарын әзер тотып, битекчеләр атлый иде. Ул монда тамгалыкка килеп туктаган кәмәләрне карап-тикшереп тора һәм Кәми сар өчен төрле мал кабул итеп тора иде, ахрысы. Кәми сар кешесе белән олы кеше очрашкач, икесе дә туктап калдылар, нидер сөйләшеп алдылар, нидер аңлаштылар. Шул ук вакытта битекчеләрнең икесе дә язу такталарына нидер билгеләп куйдылар.

Аңлашкач, сөйләшкәч, икесе дә кузгалып, үз юллары белән китеп бардылар. Олы кеше артыннан барырга кыюлыклары җитмичә, туктаган урыннарында торып калган

алла бәндәләре барысын да күреп тордылар: Кәми сар кулы туп-туры аларга таба килә иде. Елан авызына керәсе бәрән сыман котлары алынган алла бәндәләре үзләре дә сизмәстән «аһ» итеп кычкырып җибәрделәр һәм, буйсыну белдереп, шундук йөзтүбән җиргә капландылар.

— Сез кемнәр? — диде Кәми сар кулы, җирдәге кешеләр янына туктап.

— Без — акланнар, — диде Сәмит, башын чак-чак кына калкыткандай итеп. — Кәмәбез давылга юлыкты, үзебезне дулкын ярга чыгарып ташлады. Илебезгә кайтасыбыз килә, олуг Кул! Кәмәгә утырып китәргә рөхсәт ит безгә.

Кәми сар кулы уйлангандай итеп тыңлап торды да, матур муенын әкрен генә борып, артына әйләнеп карагандай итте. Ары китеп барган олы кеше нидер сизенгән сыман яңадан бу якка килеп ята иде. Кәми сар кулы эре генә, әкрен генә кыланып килүчегә таба борылды һәм көтеп тора башлады. Олы кеше килеп җиткәч, алар арасында яңадан сүз булып алды.

— Туганым, күреп торам, болар — таш эшеннән качучы коллар, — диде Кәми сар кулы. — Ләкин алар давылга юлыктык, диләр, дулкын ярга чыгарып ташлады, диләр. Илләренә кайтмакчы булалар. Алып кайтасыңмы?

— Минем кешем җитәрлек. Эшчеләрем бар, ишкәкчеләрем бар. Миңа артык коллар кирәкми, — диде олы кеше, теләмичә генә.

— Ярар, бер башка бер «корсаклы» чүлмәк. Чүлмәкнең берсе бал тулы булыр.

— Колларны мин үзем алып киләм түгелме соң сиңа?! — диде олы кеше, килешәсе килмичә. Коллар Кәми сарга күбрәк кирәк.

— Мака сарга кол кирәкми башлаганмыни? — диде Кәми сар кулы, исе китеп.

— Ярар, биш башка, өч «корсаклы», берсе бал тулы, — диде кинәт олы кеше, йомшарып.

Кәми сар кулы, килешүен белдереп, кәмә хуҗасына кулын сузды. Алар кул кысыштылар. Кәми сар кулының битекчеләре язу такталарына шундук нидер теркәп куйдылар. Кибеп, чатнап беткән комлы җир өстендә тын алырга да куркып яткан Җәбир ике олы кеше арасында нинди сүз, нинди сатулашу барганын бөтенләй аңламады. Моны бары Сәмит тә, аннан соң аның юлдашы Камус кына тиешенчә аңлый алдылар, ахрысы. Алар да башкалар кебек йә үләм, йә калам дип көтеп тыңлап яттылар һәм ике олы кеше килешеп, бер-берсенең кулын кы-

сышкач, җиңел сулап елмаеп җибәрделәр. Сәмит исә, чамадан тыш куаныч белдереп, түше белән шуышып, башта Кәми сар кулының аягын кочты, үпте, аннан соң олы кешенең аягын кочты, үпте дә, күз яшьләрен түгеп:

— Коткаручыбыз! Мең яшә! — диде.

Олы кеше күңеле йомшап Сәмиткә күз ташлап алды, аяк очы белән төртеп, торырга кушты. Бу юлы аның аяк очы белән төртүе дә баягыча чит һәм хурлыклы булып тоелмады.

— Тор! — диде ул Сәмиткә.

Сәмит торды, башкалар да аякларына бастылар.

— Сез әле бүген ашамагансыздыр да? — диде олы кеше, алла бәндәләренең хәленә кереп.

— Ашамадык.

— Бер көн түгел, инде өченче көн берни ашамадык! — диештеләр бәхетле бәндәләр, шаулашып.

Олы кеше аларны туйганчы ашатырга кушты, шуннан соң йөк бушатырга булышырсыз, диде. Аларга арпа боткасы белән пешкән балык бирделәр, кош савытка салып, берәр чокыр сыра бирделәр.

Шуннан соң алар, күңелләре күтәрелеп, йөк бушату эшенә кушылып киттеләр.

Диңгездә озакламый җил кузгалырга тиеш сыман иде. Җил кузгалу белән китеп бару өчен, кәмәләрдәге йөкләрне тизрәк бушатып бетерергә, бушаган кәмәләргә яңа мал төяргә кирәк. Шуңа күрә олы кешегә өстәмә эшче куллар бу арада бик тә кирәк иде. Биш башны өч чүлмәккә сатып алуына ул күңеленнән сөенеп бетә алмады. Яхшырак эшләсеннәр өчен «алла бәндәләре»нә ашауны да кызганып тормады — туйганчы ашатты, эчертте.

Алдан ул үзенең бернинди шартын әйтмәде. Ул бары аларны Кәми сары кулыннан сатып кына алды. Теләсә, ул аларны Акланга алып кайта ала, теләсә, берәр җирдә ташлап та калдыра ала иде. Качаклар да бернинди шарт куя алмадылар. Аларга бары Кәми җиреннән китеп бару кирәк. Кәмидән исән-имин китеп бара алсалар, алар инде котылган булачаклар иде сыман. Һичьюгы, үзләренә шулай тоелды. Олы кеше — Аклан кешесе. Ничек тә ташламас, ничек тә коткарыр сыман тоелды. Аларга хәзер шуннан башкасы кирәкми дә иде кебек. Дөрес, тамаклары туеп, башкалар кебек эшкә тотынгач, алар әледән-әле еракка, камышлар арасыннан агып яткан су ягына, диңгез ягына караштырдылар. Алай-болай куып килүче күренмиме? Аннан соң киләчәк язмыш та әкренләп эчне тырный башлады.

Башкалар Җәбиргә берни уйламыйдыр сыман тоел-

ды. Ләкин Җәбир үзе туктаусыз уйланды һәм Акланга кире кайту аны бик үк куандырмый иде. «Әллә моннан да качып китәргәме?» дип уйлаштырды ул авыр эш арасында. Ләкин ул бер карарга да килә алмады. Ул арада бер иртәдә җил чыкты һәм йөзеп китәргә әзер кәмәләр җилкәннәрен күтәрделәр һәм дулкында чайкалып, очлы борыннарын горур чөеп, җиз калай белән капланган күкрәкләре белән тыгыз суны ерып, төньякка таба йөзеп киттеләр. Камышлы күлләр, кызыл комнар уртасында күкрәп утырган бакчалар, биек таш сарайлар һәм ерактан ук таудай булып зәңгәрләнеп, томанланып күренгән олы төрбәләр әкренләп артта кала барды.

Алла бәндәләре арасында чынында бары Сәмит кенә олы кешене якыннан белә иде. Ул кайчандыр аның белән бергә йөзгән, бергә ишкәк ишкән һәм төрле илләрдә, төрле җирләргә аяк баскан кеше иде. Җәбир кебек аны да төрбә астына күмелгән исәпсез-хисапсыз байлык һәм Нуби илендә аяк астында аунап яткан алтын кызыктырды. Бер елны шулай Акланнан агач-таш һәм төрле корал, савыт-саба төяп килгәч, ул үзе кебек берничә кеше белән кәмә хуҗасыннан качып китте. Киткәндә, олы кешене дә котыртып карады. Олы кеше риза булмады. Ул беркайчан андый имеш-мимешләргә ышанмады, байлыкны ул бары көч түгеп, эшләп табарга кирәклеген бик яхшы аңлады. Аннан соң озакламый өлкән агасы үлә-нитә калса, аның урынына баш булып калачак. Акланда, икенче ерыкта, су-боҗрада, аларның зур гына таш йортлары, бакча-җирләре бар. Һәм ул чит илләр белән сату-алу алып бара. Озакламый шундый байлык кулыңа керергә торганда, нишләп әле ул һавадагы торна артыннан куып йөрсен?!

Моннан биш-алты ел элек Сәмит белән аерылышкач, ул аның белән мәңге аерылыштым дип уйлаган иде. Алай булып чыкмаган икән. Язмыш менә аларны яңадан очраштырды. Сәмит — кол хәлендә. Ярга чыгарып ташлаган балык хәлендә. Аның белән чагыштырганда, олы кешенең хәле — җир белән күк арасы! Бүгенге көндә бөтен Акланда олы кешедән бай кеше юк дип әйтер идең, бик үк дөрес булмас. Бай кешеләр бар. Алар — мака сар һәм аның якыннары. Ләкин алар кеше түгел. Алар — аллалар нәселеннән. Олы кешеләр нәселе — карадан акка үрләгән кешеләр. Аның байлыгы — ай-һай-һай! Ул аны үзе генә белә дә, тагын берничә җан иясе белә.

Аларның нәселе эшне авырдан башлаганнар. Алар гомер-гомергә кәмә йөрткәннәр, сату-алу иткәннәр. Алар-

ның затындагы сатучылар ниндидер боз белән капланган төньяк җирләргә, көне-төне кояш кыздыра торган чүлләргә, агач башында яши торган җирләргә, тагын әллә кайларга барып чыкканнар. Ләкин олы кеше барысыннан да уздырып җибәрде. Моңарчы ул Акланнан рәтле агач үсмәгән Кәмигә яхшы агач ташыды. Ләкин агачны Акланда да сатып алырга кирәк иде. Еракка, тауларга барып кисәргә, елгадан агызырга аның үзенең көче юк иде. Уйлана торгач, ул агачны бушлай, бөтенләй диярлек бушлай алу җаен тапты. Агачны ул Акланның үзеннән түгел, читтән, ерактан әзерләргә кирәк дигән уйга килде. Читтә, еракта, беркемгә буйсынмаган кыргыйлар илендә менә дигән нарат, чыршы, карагай урманнары бар икән дип аның элек тә ишеткәне бар иде. Менә шул ишеткән буенча ул кораллы кешеләр белән төньяк җирләргә китеп карады һәм таур дигән илдә нәкъ менә шундый байлыкка тап булды.

Бу юлы да ул агачны әлеге шул таурдан алып килде. Агачы өчен Кәми сарыннан алтын алды. Алдан килешү нигезендә һәм ташка язылган канун буенча сәүдәгәр табышының уннан берен мака сарга бирергә тиеш һәм биргәндә дә бары алтын белән бирергә тиеш. Мака сар алтын ярата. Ярата гына түгел, алтын өчен үлеп китә. Алтын — изге алтын ул, күктән төшкән. Кояшның үзәге алтын, диләр. Шуңа да ул шундый яктырта. Тик менә шунысы аңлашылмый, үзәге алтын булгач, ничек итеп кояш җылыта икән? Бит алтын салкын, җылытмый. Әйе, кулны җылытмый, ләкин күңелне, йөрәкне җылыта. Җылыта гына түгел, туктаусыз кыздырып, котыртып тора. Аның шундый үзенчәлеге бар. Аллалар нәселеннән булган мака сар аны, күрәсең, ныграк белгән.

Диңгезгә чыгып, Кәми ярыннан ераклашкач, алла бәндәләре белән Хуҗа арасында ачыктан-ачык сөйләшү булды. Хуҗа аларның барысын бер тирәгә җыйды да, сынап, һәркемне күздән кичерде. Барыннан да элек ул аларның йөзенә, тәненә, беләкләренә игътибар итте. Әледән-әле йөткергән Камуска ул карап та тормады — аннан бернинди рәт чыгарлык түгеллеге әллә каян күренеп тора иде. Сәмит тә элекке Сәмит түгел. Картайган, бирешкән, күкрәге дә элеккечә күректәй киерелеп тормый, беләк тычканнары да еландай уйнаклап тормый. Башкаларның да әллә ни искитәрлек җире юк. Арыганнар, йончыганнар, яшьлек уңган, утлары сүнгән йә сүнә башлаган. Арада бары Җәбир генә яшь иде. Ачлыктан эче эчкә тартылган булса да, күкрәк сөякләре, кабырга

сөякләре беленеп торса да, ул әле яшь. Күзендә очкын, тәнендә көч һәм дәрт ташып тора.

— Мин сине таныдым, — диде ул, иң элек Җәбиргә эндәшеп һәм зур йодрыгы белән аның аяк астына төртеп. — Миңа алай каш астыннан карама. Күземә туры кара. Менә шулай! Мин яшермичә сөйләшергә яратам. Мин сезне кызганып коллыктан коткардым. Күз алдыгызда булды: ике корсаклы чүлмәгемне, бер чүлмәк балымны Кәми сар кулына бирдем сезнең өчен. Менә хәзер уйлыйм инде — минем ул изгелегемне нәрсәгез белән кайтарырсыз икән, димен. Сезнең, билгеле, Акланга, ата-аналарыгыз, хатыннарыгыз, балаларыгыз янына кайтасыгыз киләдер.

— Килә, олы кеше, килә! — диде Сәмит. — Минем ничек тә Фәниямне кочагыма аласым килә.

— Алай икән, — диде олы кеше. — Син инде, Сәмит, уйлыйсыңдыр, Фәниям минем өчен түләр дип.

— Түләр! — диде Сәмит. — Ул түләмәсә, эти-әни түләр. Исәннәрдер әле. Алар түләмәсә, үзем түләрмен — без бит бер бистәдән, бергә уйнап үскән кешеләр.

— Ала-ай, — диде олы кеше, ничектер серле итеп. — Без, билгеле, бер бистәдән, бергә аунап үскән кешеләр, ләкин бит күптән безнең юллар аерылды. Син өеңнән чыгып киткәнгә дә хәзер ун ел! Атаң-анаң күптән җир куенында, сөекле хатының Фәния...

— Ә, Фәния?! — диде Сәмит, искәрмәстән.

— Сөекле хатының Фәния башка ирләр куенында, — диде олы кеше, тыныч кына.

— Юк, булмас! — диде Сәмит, кайнарланып. — Мин аңа баеп, алтын-көмеш төяп кайтырга сүз бирдем.

— Алтын-көмешләрең кая соң? — диде олы кеше, мыскыл белән көлемсерәп.

— Ул көтеп торырга тиеш иде. Ул миңа ант итте! — диде Сәмит, тыңламыйча.

— Аның инде яңа ирдән өч-дүрт баласы бар, — диде олы кеше, үтергеч бер кансызлык белән. — Өч елдан синең антың үзеннән-үзе юкка чыга. Оныттыңмыни?!

— Ah! — диде Сәмит, хәлсезләнеп һәм ушы китеп утырды да тавышсыз гына еларга тотынды.

Менә шушы сөйләшү вакытында Җәбир бер кызарды, бер агарды һәм ничек тә олы кешедән, башкалардан күзен яшерергә тырышты. Коты алынып ул аның үзе турында да шундый ук хәбәрләр ишеттерүен көтте. «Мин дә Лүчнәгә шундый ук байлык төяп кайтырга сүз бирдем» дип уйлады ул үзалдына. Ләкин Олы кеше аңа икенче яктан суктырды.

— Син дә Акланга, балтачы бистәсенә кайтып, чибәр Лүчнәң куенына керү турында уйлыйсыңдыр, Җәбир, — диде ул, аңа беренче мәртәбә исеме белән эндәшеп. — Акланда сине белмәгән кеше юк. Качып киткәч бөтенесенең телендә син булдың. Атаң кәмәсен урлап, капка сакчысын алдап чыгып китүең турында бөтен Аклан белә. Ташка язылганча, урлашкан өчен сиңа йөз таяк, атаңны, туганнарыңны алдаган өчен — йөз таяк, арык каравылын алдаган өчен йөз таяк бирәчәкләр. Адәм баласының өч йөз таяк түгел, ун таякка да чыдаганы юк.

— Мин Акланга кайтам димәдем әле, — диде Җәбир.

— Алаймы? Алайса, бер ел миндә ишкәк ишәрсең, шуның белән бирәчәгең түләнер. Шуннан соң дүрт ягың кыйбла!

— Антмы? — диде Җәбир, кыюланып.

— Мин кол белән ант бирешмим, — диде олы кеше коры гына. — Минем сүзем антка тиң.

— Суда — ирләр, күктә тәңребез Кояш ишетеп торды. Сүзеңнән таңма, олы кеше! — диде Җәбир, күккә һәм юлдашларына карап.

Олы кешенең йөзе караңгыланып китте. Үз кәмәсендә үз колларының үзе белән болай кыю һәм бәйсез сөйләшүләренә ул күнекмәгән иде. Ул аларга бары боерырга, аларны бары куркытырга һәм эшләтергә генә күнеккән иде. Әле дә ул чынын сөйлим дисә дә, кайбер нәрсәне яшереп калдырды, кайберсен күпертеп сөйләде. Сәмитнең Фәниясе кияүгә чыкмаган — ул һаман үзенең ирен көтә иде. Олы кеше бу турыда бик яхшы белде. Шул ук вакытта Җәбирнең эше дә ул сөйләгәнчә үк түгел иде. Аңа да әле, теләсә, Акланга кайтырга, мака сардан ярлыкау үтенергә булачак иде — бит аның әле базга яшерелгән алтын-көмеше дә җитәрлек! Яртысын мака сарга биргәндә дә... Ләкин шул ук вакытта аңа инде Акланга кайтып йөрүнең бөтенләй кирәге юк иде. «Бик тыпырчынсаң, мин сине дә бик тиз кулга алырмын әле» дип уйлады олы кеше Җәбир турында. Шулай күпмедер аңлашкач-сөйләшкәч, ул аларга чын күңелдән изгелек теләп, үзенең карарын белдерде.

— Сез хәзер туры төньякка юл тотарсыз. Мин югында минем улым Нәмәгә буйсынасыз... Мин Акланга кереп, мака сарга тиешле кулбауны түләп чыгарга тиешмен. Шунда ук Кәмидән алган малны бушатырбыз. Ишетелсә, сезнең өчен яңа хәбәрләр алып килермен. Берәр ай мине кыя тау утравында көтеп торырсыз. Шуннан без таурга юл тотабыз. Таурда — урман. Анда минем агач кисүчеләрем бар. Агач төярбез дә яңадан Кәмигә

юнәлербез. Син дә, Сәмит, бер ел ишкәк ишәрсең, агач төярсең, бушатырсың. Бер елдан шулай ук дүрт ягың кыйбла!

— Антмы? — диде Сәмит, нәкъ Җәбир кебек җанланып, күңеле күтәрелеп.

— Мин инде әйттем сезгә... — диде олы кеше, яратмыйча. — Аңлашыладыр, шәт?

— Борчылма, колың булырбыз, төп таянычың булырбыз, — диде Сәмит, яңадан мескенләнеп.

— Менә монысы ошый! — диде олы кеше. — Диңгездә башкача сөйләшү була алмый.

## X

Кәбир бүген ныклы бер карарга килде. Ул моннан китәргә булды. Ул инде моннан бер ел элек китәргә дигән карарга килгән иде, тик менә әлегәчә һаман аны монда кемдер, нидер тотып тора сыман иде. Бүген барысы да ачыкланды. Аны беркем тотмый да, тота да алмый. Чыннан да аны монда беркем көчләп тотмый. Ләкин дөньяда көчләүдән башка тагын ярату, якынлык һәм инану дигән нәрсәләр дә бар бит әле! Бер ел буена аны монда менә шул ярату, якынлык һәм инану тотып торды да инде. Ләкин бүген соңгы көн. Ул моннан барыбер китәчәк. Дөрес, моннан китәргә карар кылу белән әле ул үзенең ратуыннан да, инануыннан да баш тартырга җыенмый. Изге анага, ияләргә һәм аларның теләкләренә ул беркайчан каршы килмәячәк. Тик шулай да аңа моннан китәргә кирәк. Монда кемдер, нидер тотып торган сыман булган кебек, тегендәге, башка дөньядагы кемдер аны хәзер үзенә чакырып тора сыман. Ни әйтергә тели аңа тегендәге кемдер? Ул аны көтә, ул аны сагынып, зарыгып көтә. Кем ул, нәрсә ул? Бит аны ничек тә, кайчан да күрергә кирәк ич! Өметен акларга һәм аңа да ярдәм кулы сузарга кирәк ич!

Билгеле бер карарга килгәч, ул беркемгә берни әйтмичә, таң ату белән юлга да чыга алган булыр иде. Ләкин ул алай итә алмады. Үзенең карарын иң элек ул пир ата Мәҗиткә әйтергә һәм аның фатихасын алырга тиеш. Шунсыз аның юлы уңмаячак. Ул моны аңлый, ул моны бөтен күңеле белән сизенә. Моңарчы ул аңа берни әйтмәде. Бүген... хәзер әйтергә, барыбер әйтергә кирәк булачак.

Пир ата Мәҗит, гадәтенчә, Кәбирдән иртәрәк тора, тышка чыгып тиешле йомышларын йомышлый да, якында гына челтерәп аккан чишмәдә юына, чистары-

на һәм, шәрә тәнгә иске чапанын бөркәнеп, ашыкмыйча гына таш баскычтан менеп китә. Кәбир аннан беркадәр калышып уяна, су чәчрәтеп, пошкырынып чишмәдә юына һәм пир ата илленче басма тирәсендә булганда, зур-зур атлап аны җиңел генә куып та җитә. Шуннан соң алар таш баскычтан икәүләшеп менәләр.

Бүген дә ул пир ата куыштан чыгып китү белән күзен ачты, ләкин башка көннәрдәгечә аның артыннан ияр-мәде. Ул инде күптән уянган иде һәм үземнең карарымны пир атага кайчан һәм кайда әйтсәм яхшырак булыр икән диебрәк уйланып ята иде. Чынында ул бүген рәтләп йокламады да, ахрысы, бары таң алдыннан гына беркадәр онытылып алды бугай.

Пир атаның чишмәдә юынуы ишетелә башлагач та, ул аягына басты һәм эре ташлардан өелгән түгәрәк куышның камыш чыпта ишеген ачып тышка чыкты. Куыштан беркадәр читкә китеп билгеле бер урында йомышын йомышлады да чишмә буена килде. Бу вакытта пир ата эшен бетереп, салмак кына атлап, таш баскычка таба китеп бара иде. Алар бер-берсенә күз төшереп алдылар, ләкин берни эндәшмәделәр. Кәбир чишмә янында озак булашмады — тиз-тиз генә битен-күзен юыштырды да, пир ата артыннан китте. «Баскычта сөйләшергә кирәк» дип уйлады ул баштарак. Ләкин шулай дип уйлавы булды — көтмәгәндә аяклары карыша башлады. Шул ук вакытта күкрәгендә хәлсезлекме, каушаукуркумы барлыкка килде. Бүген аңа пир ата нишләптер җитезрәк атлый сыман тоелды. Тик шулай да ул аны илленче басма тирәсендә түгел, кырыгынчы басма тирәсендә куып җитте.

Көндәгечә пир ата бер басма алданрак барды, беркадәр калышып, аның сул ягыннан Кәбир атлады. «Баскычта сөйләшергә ярамый. Менеп җиткәч әйтермен» диде Кәбир үз-үзенә, баштагы уеннан кире кайтып. Алар шулай әкрен генә, сүзсез генә югары үрмәләделәр.

Таулар арасындагы тигезлектән башланган таш баскыч алтмышынчы басмага кадәр туп-туры сузылды. Шуннан соң зур кыя өстендәге кечерәк кыя төбенә менеп җиткәч, аркылысы-буе ике өч адымлык тигезлек дүрткел мәйданчык идән барлыкка килде. Пир ата Мәҗит, таш идәндә туктап, артына карап алгандай итте. Бүтән көнне дә ул шулай, «киләме-юкмы?»дигәндәй, күз карашы белән Кәбирне барлый. Кәбир ике-өч басма арткарак калган булса, көтеп тора, калмаса, яңадан кузгалып китә. Кәбир аның янында гына иде. Алар мәйданчыкта тоткарланып тормадылар.

Алтмышынчы басмадан соң таш баскыч, кече кыяга җайлашып, боҗра сыман күтәрелә башлады. Баскыч, ике кеше атлап барырлык итеп эшләнсә дә, шактый тар һәм куркыныч иде. Аяк асты тайгак булганда, көчле җил искәндә яисә караңгыда алай-болай ялгыш бастыңмы, түбәнгә, упкынга ычкынуыңны көт тә тор. Ярый әле баскыч кыя ташын уеп-кисеп ясалган — баш өстендә, җил-яңгырдан саклап түбә асылып тора, түбә белән баскыч арасындагы уентыкта тотынып өчен очлаеп торган таш кисәкләре калдырылган. Кыядагы ярыкларга ара тирә җиз тоткалар кагып куйганнар.

Беренче мәртәбә шушы баскычтан менгәндә, Кәбир тоткаларга, очлы ташларга тотына-тотына менде, ничек тә аска карамаска тырышты. Пир ата шулай кушты. Беренче мәртәбә менгәндә, ул шабыр тиргә батты һәм, менеп җиткәч, бик озак тынычлана алмыйча торды. Хәзер ул монда күз йомып, йөгереп менә ала. Ләкин күз йомып менәргә дә, йөгереп менәргә дә ярамый. Алдан пир ата атлый. Аңа хәзер моннан менүе авыр, бик авыр. Ул, билгеле, сиздермәскә тырыша. Ләкин күзең булгач, колагың, тойгыларың булгач, ничек итеп сизмисең дә ничек итеп күрмисең, ишетмисең? Боҗра сыман күтәрелә торган баскычның алтмышынчы басмасыннан соң кыяга уеп, утырып тору өчен тар гына урын эшләнгән иде. Шунда җитү белән пир ата утырды, Кәбир исә кыяга сөялеп басып торды. Бераздан алар тагын кузгалып киттеләр, алтмыш баскыч менгәч, яңадан туктап тордылар. Ике йөз кырык басма менгәч, кечерәк кыя өстендә өченче кыя башланды. Икенче кыя белән өченче кыя арасында тар гына ара бар иде. Тар арага салынган таш күпердән алар өченче кыя ягына чыктылар һәм кара ташлы кыяны кырып ясалган тар баскычтан һаман югары күтәрелә бардылар. Алтмыш басмадан соң пир ата Мәҗит янә туктады, еш-еш тын алды һәм күрмәс күзләре белән як-ягына карангалады.

Кәбиргә пир ата беренче мәртәбә диярлек бик кызганыч булып тоелды. Кичәгенәк тә, өченче, дүртенче көннәрдә дә ул болай ук туктамый иде. «Нидер булган аңа, — дип уйлады Кәбир. — Минем кебек рәтләп йоклый алмаганмы, әллә бер-бер хәл булганмы?»Никадәр изге булмасын, никадәр үзен-үзе сакламасын, ул да адәм баласы. Ничә яшьтә ул? Моны беркем белми. Ул һаман яшьләрчә. Дөрес, аңа инде күптән егерме дүрт түгел. Ләкин аңа җитмеш дүрт тә түгел. Туктале, кем белә аны — бәлки, җитмеш дүрт тә бардыр?! Үзенең яше турында, кайчан, кайда тууы турында да ул бит берни

әйтми. Аның белмәгәне, сизмәгәне, тоймаганы юк. Аның булдыра алмаган берние юк.

Өч йөз басмадан соң алар, ниһаять, өченче кыя өстенә менеп җиттеләр. Ләкин бу әле иң югарыга менеп җитү дигән сүз түгел иде. Өченче кыяның очлы башы тигезләнгән, шунлыктан кыя башында тип-тигез урын барлыкка килгән иде. Шул тигез урынның тач уртасына, шакмаклап киселгән кызыл, ак һәм кара ташларны аралаштырып, биек һәм иркен итеп түгәрәк өй салып куйганнар. Өйнең аскы ягында, өченче кыя башында, икеөч кеше янәшә атлап барырлык киңлектә, буш урын калдырылган. Кыя кырыена матур итеп, тигез итеп ярты гәүдә биеклегендә таш баганалар тезеп куелган — баш әйләнүдән, җил очыртып төшерүдән курыкмыйча өй тирәли әйләнеп йөрергә, тирә-якны күзәтергә була. Түгәрәк өйнең ишеге дә, тәрәзәсе дә юк. Өйгә керү өчен иң элек аның түбәсенә менәргә кирәк. Түбәгә менү өчен исә тагын боҗра сыман баскычтан тәпи-тәпи атларга туры килә. Хәер, монысы инде соңгы алтмыш басма. Өй түбәсенә менеп җитү белән, барлыгы өч йөз алтмыш басма була. Таш өйнең таш түбәсе беркадәр кабарынкы итеп эшләнгән. Түгәрәк түбәнең уртасында чүлмәк морҗа башы тырпаеп тора. Түбә кырыена астагы кебек таш баганалар тезеп чыкканнар. Кайсы якка гына борылып карама — иксез-чиксез киңлек, иркенлек. Кояш чыгыштан алып кояш батышка кадәр — бөтен төньякта, бик еракта диңгез җәелеп ята. Икенче якта — көн ягында — шулай ук кояш чыгышыннан кояш батышына кадәр таулар, үзәннәр томанланып күренә. Ара-тирә ул якта зәңгәр кыяларны, каралҗым урманнарны, елгаларны һәм елга буена тезелеп утырган авыл, тураларны, җиз түбәле сарайларны һәм алтынланган, ялт- йолт килгән биек манараларны шәйләргә була. Шунда ук, Актау үзәненнән беркадәр читтәрәк, калкулыклар, яшел үзәннәр арасыннан еракка таба туры, тигез таш юл сузыла. Юл каядыр зур турага, биек сарайлар, манаралар ягына алып бара.

Монда менгән саен Кәбир күбрәк менә шул таш юл ягына карарга ярата. Җентекләбрәк карасаң, анда кыймылдаучы ат-арбалар, җәяүлеләр күренә. Алар каядыр баралар, каяндыр кайтып киләләр. Озаграк итеп карап торган саен, Кәбиргә андагы кешеләр дөньяда иң бәхетле, иң өлешле кешеләр сыман булып тоела башлыйлар. Алар Кәбир белмәгән ниндидер нәрсәләрне беләдер, Кәбир күрмәгән, ишетмәгән нәрсәләрне күрәдер сыман тоела. Аннан да бигрәк, алар үзләре теләгән теләсә кая

бара алалар, үзләре теләгән теләсә кем белән очраша алалардыр сыман тоела.

Дөрес, ул андагы кешеләрнең, андагы тормышның ничек икәнлеген төгәл генә күз алдына китерә алмый. Берәүләр аны мактый, берәүләр хурлый. Ләкин хурлаучыларның да, мактаучыларның да сүзләре нигезендә генә фикер йөрткәндә дә, андагы тормыш, андагы кешеләр, андагы мөнәсәбәтләр мондагыча Актау дип аталган һәм таулар арасында кысылып калган тар үзәндәге тормышка охшамаган булырга тиеш. Менә шул охшамаган булганга, икенче төрле, башка төрле булганга күрә дә Кәбирне менә бер елдан артык тәкатьсезлек газаплый. Шуңа күрә дә аның күрәсе, беләсе, тоясы, татыйсы килә.

Түгәрәк өй түбәсенә аяк басып, беркадәр тын алгандай иткәч, Кәбир өлкән юлдашы ягына карап алды һәм тагын аңа Изге атаның йөзе кызганыч булып тоелды. «Монда да сөйләшеп булмас, ахрысы» дип уйлады ул.

— Алып менимме? —диде ул, күндәм бер кыяфәттә.

— Бар, — диде пир ата.

Кәбир таш түбәнең кырыендагы түгәрәк җиз капкачны ачты да, җиңелчә шакылдатып, таш баганага терәтеп куйды. Түбәдә түбәнгә төшү өчен түгәрәк ачыклык һәм баскыч бар иде. Кәбир таныш басмалардан тиз-тиз атлап түбән төшеп китте, ярым караңгыда кулын сузып, капшанып ул үзенә кирәкле май тулы чүлмәкне эзләп тапты һәм, өй эчендә артык тоткарланып тормыйча, таныш баскычтан өскә менде.

Пир ата, кояш чыгышы ягындагы таш баганага тотынып, еракка, диңгез артына карап тора иде. Кояш әле чыгып җитмәгән, ул әле судан яртылаш кына калкып күренә, шунлыктан әле ул кып-кызыл, нурлары да әле тоныграк һәм кыскарак иде.

Түбә өстендә, түгәрәк баздан читтәрәк, икесе ике якта, һәркайсы өч аяклы ике таш савыт калкып утыра. Казан сыман түгәрәкләп, шактый тирән итеп, чит-читләрен, аякларын бизәп-сырлап ясалган таш савытларның берсендә төне буе балкып ут яна, икенчесендә көне буе шулай ук ут яна һәм төтен чыга иде. Таш савытларның икесен дә өчаяк дип йөртәләр. Ләкин төнге өчаяк белән көндезге өчаякны бер-берсе белән буташтырмау өчен кайчагында көндезгесен — алтир, төнгесен нәфит дип тә атыйлар иде.

Җир астыннан, су астыннан кояш чыгып көн туу белән, нәфиттәге утны сүндереп куялар, алтирга исә хуш исле май сибеп, черек агач һәм кипкән арыслан, каплан яисә бүре тизәге өеменә ут төртәләр. Шуннан соң көне

буена алтирдан күккә төтен күтәрелә. Кич, караңгы төшеп, кояш баер алдыннан, алтирдагы утны сүндереп, нәфиткә ут кабызалар.

Актаудагы изге ирләр көненә ике мәртәбә өчаяклардагы утны шулай алыштырып торалар. Көне-төне Актаудагы изге өй башында әле балкып, әле төтәп өзлексез ут яна. Ерактагы, биектәге утка карап, төннәрен адашкан, юлдан язган кешеләр аз гына вакытка булса да Әтәбезне, Инәбезне, изгеләрне исләренә төшереп тәүбәгә киләләр һәм җир йөзендә эшләнәсе бозыклыклар эшләнмичә кала.

Туып килүче кояш су өстеннән өч чирек чамасы күтәрелгәч, пир ата җитез бер хәрәкәт белән Кәбир ягына борылды, бер сүз әйтмичә, аның кулындагы чүлмәкне алды да алтир янындагы күтәрмәгә менде. Таш савытларның икесе дә кеше гәүдәсеннән биегрәк иде. Ул арада Кәбир шаулап, чыртлап һәм куе кара төтен чыгарып янган нәфит утыннан коры камыш очына ут алды, утлы камышны пир атага бирде. Шул ук вакытта ул, нәфит савытына сөяп куелган озын саплы чүмечне алып, төнге утка чүмеч каплады. Нәфит уты исә барлык утлар кебек ачык җирдә, иркендә янмый, өчаяк уртасыннан тырпаеп торган чүлмәк көпшә башында яна иде. Кәбир чүмечне менә шул чүлмәк көпшә авызына гына каплады. Төне буе, бәйдәге эт кебек, уңга-сулга ыргылып, ярсып янган ут шулай итеп тынды да калды. Кәбир өчен генә түгел, Актаудагы, Акландагы күпләр өчен бу — сер. Ничек яна, нәрсә яна анда. Пир атадан сорасаң, ул, нәфит яна, ди, ләкин нәфитнең нәрсә икәнлеген дә, аның шулай нигә янганлыгын да, кайдан алынганлыгын да әйтми. Әллә белми, әллә әйтәсе килми. Нәрсә генә янмасын — утынмы, корыган үләнме — аны күрергә була, аны тотып карарга була. Янгач, аларның көле, корымы, күмере кала. Моның бернәрсәсе калмый. Моны хәтта күреп тә булмый. Чүлмәк көпшә авызыннан бөркелеп ут та кара төтен генә чыга. Шул беләк буе көпшә эчендә туктаусыз янарлык нәрсә булырга мөмкин — һич аңларлык түгел. Әллә көпшә эченә яки таш савыт эченә борынгылар мәңге яна, ләкин янып бетми торган берәр нәрсә куеп калдырганнармы?

Еш кына Кәбир шулайрак дип уйлады. Ләкин үз башы белән генә моның берничек тә очына чыга алмады. Ул инде бер-ике мәртәбә, таш савытка менеп, көпшә эчен карамакчы да булган иде, ләкин пир ата мондый чакта аңа бары төбәп карап кына алды. Ачуланмады да, хәтта сүз дә әйтмәде. Кәбир моның шундук тыелган нәрсә

икәнлеген аңлады, һәм серле утка сокланудан, куркып һәм ялварып караудан башка чара калмады.

Алтир савыты янына менеп баскан пир ата сул кулы белән чүлмәктән таш савыттагы черек агачлар, коры тизәкләр өстенә хуш исле май агызды да уң кулындагы камыштан алтирга ут кабызды.

Шуннан соң ул чүлмәкне дә, камышны да Кәбиргә бирде, күтәрмәдән аска төште һәм чыгып килгән иртәнге кояшка йөзен борып, ике кулын югары күтәреп, кычкырып зекер әйтте:

— Әтекәмә, Инәмә! Илемнең иминлеге өчен, йортымның тынычлыгы өчен, мака сар өчен садака. Амин! — диде.

Кулындагы әйберләрен читкә куеп өлгергән Кәбир дә, пир ата кебек кулын югары күтәреп, авыз эченнән изге теләк сүзләрен кабатлады. Соңгы аминне ул беркадәр калышып, кычкырып әйтте.

Шуннан соң алар тынып калдылар. Баскан урынnarыннан кымшанмыйча, сокланып, исләре китеп, озак кына диңгез өстендәге алтын кызыл шар — кояш ягына карап тордылар.

— Туды! Бүген дә туды! — диде пир ата, канәгатьләнү тойгысы белән.

Яртылаш бушаган чүлмәкне урынына куймакчы булып, Кәбир түгәрәк базга төшеп китте. Чүлмәген куйгач ул яңадан өскә менмәкче булган иде, таш баскычтан төшеп килгән пир атаны күреп, гаҗәпләнә калды. Ни булган аңа? Ник төшә ул монда? Аның шулай дип уйлап бетерүе булды, аның уйларына җавап биргән кебек, пир ата:

— Нишләптер башым әйләнә, балам, турыдан төшәрбез, — диде.

Түгәрәк өй астыннан түбәнгә таба авыш кое сыман итеп казылган туры юл сузыла иде. Бу юлдан пир ата бик сирәк очракта гына — тышта җил-яңгыр булганда гына яисә ашыгыч рәвештә изге өйгә, изге ут янына менеп төшәргә кирәк чагында гына йөри иде. Моңарчы әле аның баш әйләнү, күз күрмәү, йөрәк кагу, хәлсезлек турында беркайчан авыз ачып бер сүз әйткәне юк иде. Ул әнә башым әйләнә ди. Тавышы да ничектер хәлсез, дәртсез чыга. Йөзе дә башка көннәр белән чагыштырганда сулыгыбрак, чырайсызланыбрак калган сыман. Ни булган аңа? Пир атага да чир ияләшә башлаганмы әллә? Юк, булмас! Пир ата Мәҗит андый ир түгел, ул алай тиз генә бирешә торган кеше түгел.

Кәбир, берни әйтмичә, тын гына, күндәм генә, пир атаның төшеп җиткәнен көтеп торды. «Болай булгач, монда да ачыктан-ачык сөйләшеп булмас, ахрысы. Ярар,

җиргә төшкәч сөйләшербез» дип уйлады ул, һаман үз кайгысын кайгыртып. Пир ата төште, ләкин Кәбир көткәнчә яшерен баскыч авызына таба түгел, капма каршы якка борылды. Анда, төрле чүлмәкләр, ватык-китек савыт-саба, кыскыч, балта ише кораллар һәм агач череге, коры-сары, чыбык-чабык куелган җиргә якын гына салам түшәк тә бар иде. Ул түшәктә түгәрәк өйгә май, утын, камыш ише нәрсәләр, су ташып торучы Әппә кайчагында башын төртеп йоклап ала, кайчагында пир ата үзе дә шунда ятып тора иде.

Пир ата түшәккә килеп утырды һәм шунда аяк астында аунап яткан арыслан тиресен өчкә-дүрткә бөкләп, мендәр кебек итеп аркасы турысына кыстырып куйды.

— Күз алларым караңгылана, әллә ни булды, балам, — диде ул, ыңгырашуга якын бер өн чыгарып.

— Ни сөйлисең, пир ата?! — диде Кәбир, каушап, аптырап һәм ашыгып түшәк янына килеп җитте.

— Соңгы сәгатьләрем якынлашкандыр, балам, — диде пир ата, хәлсез пышылдап.

— Теге суны биримме? Биримме?! — диде Кәбир, кинәт урыныннан кубып, кабаланып һәм такта шүрлеккә тезеп куелган эреле-ваклы савыт-саба арасыннан үзенә кирәклесен эзләргә тотынды.

— Бирмә, — диде пир ата. — Вакыт җитсә, ул гына коткармаячак. Утыр әле яныма... әйтәсе сүзләрем бар.

Кәбир, күндәм генә итеп, тезләнеп, пир атаның аяк очына килеп утырды. «Гаҗәп, нәрсә әйтмәкче була икән... соңгы сәгате алдыннан?» дип уйлады Кәбир. Бәлки, ул үзенең кайбер серләрен дә әйтер? Иң элек нәрсә турында сорарга? Көпшәдәге ут ничек яна, нәфит нәрсә ул, каян килә ул? Шуны сораргамы?

— Әйт, мин сине тыңлыйм, пир ата, — диде ул, колакларын торгызып.

— Якынрак кил, балам, — диде пир ата.

Кәбир, урыныннан күчеп, шәрә ир кешенең алдынарак күчеп утырды. Ул үзе дә анадан тума шәрә иде. Күчеп утыру белән, аның тәне пир атаның сөякчел балтырына тиеп китте. Теге дөньяга күчә башлаган кешенең аягы-кулы, бөтен тәне салкын булырга тиеш иде кебек. Ләкин Изге атаның тәнендә Кәбир бернинди үзгәреш тоймады, киресенчә, сөякчел балтыр яңа йокыдан торган чактагы кебек җылы, хәтта артык җылы сыман тоелды.

Ул арада пир ата тураеп утырды, якынрак килде һәм аяк очындагы яшь җегетне арттан кочып алды. Аның кулы, тәне җылы гына түгел, хәтта кайнар иде. Ул аны

яратып, иркәләп кочты, аның шома иңбашын, беләкләрен, күкрәкләрен сыйпады һәм, исерткеч татлы май исе катыш тир исе чыгарып, яшь тәнгә елышканнан елыша барды. Пир атаның хәлсезлеге, башы әйләнүе «соңгы сәгате» — барысы да аңлашылды. Бөтен күңеле белән яшь егет аның ялганын, икейөзлелеген аңлады һәм беренче мәртәбә диярлек анда татлы май исенә, тир исенә карата кире тойгы барлыкка килде.

— Тау иясе көтеп торадыр, пир ата. Соңга калмабызмы? — диде ул, телгә килеп.

— Калмабыз, — диде пир ата, аннары өстәп куйды: — Кирәге булса, көтеп тә торыр.

Изге атадан Кәбир һич тә мондый сүз көтмәгән иде. Тау иясе турында... ничек итеп алай сөйләшә ала ул? Бит Тау иясе барысын да белеп, ишетеп тора! Туктале, нишләгән бу пир ата? Әйттем исә кайттым, ычкынмагандыр ич?

— Тау иясен көттерергә ярамаганлыгын исеңә төшергәнгә ачуланмыйсыңмы миңа, пир ата? — диде Кәбир, сүзне тагын Тау иясенә күчереп.

— Синәмы? Сиңа ачуланыргамы?! — диде Изге ата, Кәбирне кочагына ныграк кыса барып. — Беркайчан мин сиңа ачуланмадым. Ачуланасым килсә дә ачулана алмадым. Нишләптер синең сөягең сөйкемле, күзеңнән, йөзеңнән нур бөркелә. Сөйләгән сүзләрең колагымны иркәли. Тәнеңә кагылсам, күңелемә ялкын дөрли. Әз генә янымда булмасаң да, шундук чиргә сабышам, сине чит ирләр янында күрдемме, үртәлә башлыйм, көнләшә башлыйм.

— Мин дә сине генә яратам, пир ата, — диде Кәбир, мактау, иркәләү тәэсиренә бирелеп.

— Кабатла! Тагын кабатла! — диде шашкын карт, сылу тәнле яшь егетнең әле бер төшеннән, әле икенче төшеннән үбәргә тотынып.

— Бары сине генә! — диде Кәбир, кабаланып.

Мәҗит беразга тынып калгандай булды. Ике арадагы киеренкелек бушана төште һәм бөтенләй көтмәгәндә Изге атаның тын алуында, еш-еш борын тартуында күз яше сизелде. Ярым караңгыда Кәбир чыннан да аның күз төпләренең кызаруын, юешләнүен шәйләп алды. Кәбирнең әле беркайчан мондый нәрсәгә тап булганы юк иде. Ул белгән пир ата беркайчан күңел йомшаклыгына бирелми торган, беркайчан юкка-барга борчылмый торган, кирәк кадәр генә якын-ягымлы, кирәк кадәр генә коры һәм кырыс бер кеше иде. Кайчагында аның яратуын яисә яратмавын да, кайгыруын-кайгырмавын да аңлап

булмый иде. Барлык хис-тойгылары аның тирәнгә яшеренгән һәм шунлыктан ул башка беркем белми торган бик зур серләр белүче, бөек акыл иясе булып тоела иде.

Кәбир, пир атаның яшьләрен күрмәс өчен, аннан да бигрәк, аны уңайсыз хәлдә калдырмас өчен, күз карашын читкә борды. Түгәрәк баз авызыннан өй эченә бөркелеп яктылык төште, анда югарыда җил искәне һәм ишетелер-ишетелмәс черт-мерт килеп майлы түмәрләр янганы ишетелде. Әллә төтен күреп, әллә болай гына каяндыр ниндидер кош очып килде һәм канатларын сызгыртып ачыклык турысыннан очып та китте. Шул чакны Кәбирнең күңеленә бер кыю уй килде.

— Син мине... генә яратам диден, — диде ул, әкрен генә сүзгә башлап. — Яраткан кешеңә яхшылык эшлиләр. Син үзең гел шулай дисең...

— Шулай димен, балам, — диде пир ата, ягымлы итеп. Ләкин аның тавышында хәзер гашыйктан акыл иясенә әйләнә бару сизелде.

— Мин менә яраткач гел синең белән — энәгә сапланган җеп кебек, — диде Кәбир, кызарынып, сүзен дәвам итеп. — Син кайда — мин шунда. Мин синең күзеңә генә карап торам, бер теләгеңә дә каршы килмим.

— Син шулай булырга тиеш тә — син минем яраным, — диде пир ата, әле һаман йомшак, ягымлы булырга тырышып.

— Ансы шулай, мин синең яраның, — диде Кәбир. — Ләкин син дә мине яратасың!

— Ярату язык түгел, балам, — диде пир ата.

Ул, ахрысы, Кәбирнең үзеннән нидер сорарга җыенуын сизеп алды. Ул инде аның нәрсә сорарга җыенуын да белә иде бугай, шуңа күрә, ахрысы, күңелсез сөйләшүне ничек тә артка чигерергә тырышты.

— Беләм, язык түгел, — диде Кәбир, үз уеннан кайтасы килмичә. — Яраткач... син миңа... кайбер серләрне дә әйтергә тиеш түгел микән?

Әле генә яшь егетне үпкән-кочкан, ярату сүзләре сөйләгән Изге ата кинәт шып булды.

— Тиеш түгел, — диде ул бераздан, коры гына. — Мин белгән сер — аллалар сере. Аллалар серен бары алла улы гына белә ала. Монда Актауда гына түгел, бөтен Аклан илендә андый кеше мин генә, балам.

— Кичер мине, Изге ата! — диде Кәбир. — Шулай да сиңа бер сорау бирсәм...

— Бир, — диде Изге ата.

— Учакта ут янса, сер түгел, өчаякта нәфит янса, сер. Нишләп алай?

— Син аны әйтәсең икән! — диде Изге ата, җиңел сулап. — Өчаяктагы нәфит — бик зур сер, балам. Мин аны үзем дә белмим. Каян килә, ничек яна... Нәфит ул май кебек. Борынгылар аны күптән беләләр. Теләсә нинди май кебек, нәфит тә яна. Тик менә безнең өчаякта каян барлыкка килгәндер ул, нишләп һаман бетмидер ул — әйтә алмыйм. Кара кыя башындагы шушы өйне дә, баскычларны, җир асты юлларын да дөнья яралганда ук атабыз Мин үзе төзегән, диләр. Син аны беләсең.

— Беләм, — диде Кәбир.

— Башкача әйтүчеләр дә бар, — диде пир ата. — Мондагы бөтен нәрсәне мака сарлар төзеткән дип тә сөйлиләр. Ул заманнардан бернинди язу калмаган. Кешеләр, кыргыйлар кебек, тау куышларында яшәгәннәр...

— Анысын да беләм, Изге ата, — диде Кәбир, тыйнак кына. — Үзебез дә алар яшәгән тау куышында яшәп ятабыз түгелме соң?

— Без — изгеләр, — диде пир ата.

— Алар да изге булмаганмыни? Синең үзеңнең дә әйткәнең бар... — диде Кәбир, пир атаның ялганын тотмакчы булган сыман.

— Әйткәнем бар, — диде пир ата, килешеп, — Ләкин ул заманнардагы изгеләр белән бүгенге изгеләр арасында җир белән күк аермасы.

— Мин әллә ни аерма күрмим, пир ата, — диде Кәбир. — Алар да чишмәдән ятып су эчкәннәр, без дә. Алар да шәрә йөргән, без дә...

— Аерма бар. Аерма зур, — диде пир ата, бирешәсе килмичә. — Без монда үзебез теләп яшибез. Без — аңлылар. Без анабыз Дикәне олылап шәрә йөрибез. Без бары аңа гына турылыклы. Шуңа күрә дә без хатын-кыз затындагы кешеләр белән аралашмыйбыз, алар белән якынлык кылуны иң зур язык саныйбыз. Безгә кадәр яшәгән кыргыйлар, киекләр кебек, мал-туар кебек, ираты бергә буталып яшәгән. Менә ул кайда аерма! Тегендә, алтын сарайларда, авыл-тураларда яшәүче кешеләр әле бүген дә кыргыйлар кебек барысы бергә буталып яши бирә. Монысы инде бозыклык!

— Бозыклык?! — диде Кәбир, искәрмәстән. — Нишләп бозыклык була соң ул? Ирне, хатын-кызны Атабыз, Анабыз яратмаганмыни? Алар безне үзләре кебек үк итеп яратканнар, үзләре кебек үк кавышырга, сөешергә, балалар тудырырга яратканнар! Син үзең дә шулай дидең ич, пир ата!

— Дидем. Барысы да дөрес, — диде пир ата Мәҗит. — Җирдәге ир-ат бер-берсен яратканда иң элек үзен түгел,

Атабыз-Анабызны исендә тотарга тиеш. Атабыз Минне, Анабыз Дикәне. Алар менә шуны оныттылар. Шуңа күрә аларның кылган бар эше — бозыклык. Алар бүген байлык, ләззәт колына әйләнделәр. Бозыклык менә шул, балам.

Пир ата Мәҗит белән аллалар, изгеләр турында сүз көрәштерүнең җиңел түгеллеген Кәбир бик яхшы белә. Менә бүген дә ул аның белән бөтенләй икенче нәрсә турында, турыдан-туры үзенә кагылышлы нәрсә турында сөйләшергә тиеш иде. Ләкин андый сөйләшү булмады, була алмады. Кәбир бөтен күңеле белән сизеп-тоеп утырды: пир ата, аның нәрсә әйтергә теләгәнлеген алдан ук белгән кебек, сүзне үзенә кирәкле юнәлешкә борды да җибәрде. Бу иртәдә, бу аулак өйдә Кәбирнең бер дә пир ата белән яратышып утырасы да, аның күптән инде билгеле нәрсәләр турындагы сүзләрен дә тыңлыйсы килми иде. Пир атаның кинәт йомшаруыннан, яратышырга омтылуыннан файдаланып, аның чыннан да кайбер серләрне дә аласы килә иде. Нәфит утының серен белә алсаң, ул чагында бит дөньяның, яшәешнең, киләчәкнең язмышы синең кулда булачак дигән сүз! Ул чагында... ул чагындамы?!

Ул чагында нәрсә булырын Кәбир әле үзе дә анык кына күз алдына китерә алмый, ләкин, ни генә булмасын, ул монда бикләнеп ятмаячак! Ул чагында ул тирәягын текә таулар, кызыл-кара кыялар әйләндереп алган бу Актау үзәнен мәңгегә ташлап китәчәк. Барыбер китәчәк!

Ике арадагы беркадәр тынлыктан соң пир ата аягына басты.

— Кузгалыйк. Безне анда көтеп торалар, балам, — диде ул.

«Мин дә әлерәк кенә шул турыда әйткән идем түгелме соң, Изге ата?!» дип әйтәсе килде Кәбирнең, ләкин әйтмәде. Ул бары тагын бер мәртәбә Мәҗит атаның һәрвакытта дөрес сүз сөйләмәвенә, кайчагында күрәләтә ялганларга, икейөзлеләнергә мәҗбүр булуына гына игътибар итте. Әйткәнне көтмәстән, ул җитез генә өскә менеп китте. Як-ягына каранып та тормастан, коры камышка өчаяктан ут алды да, җиз капкачны үз артыннан ябып куеп, түбән төште. Баскыч янындагы чүлмәк пыскыйның майлы чүпрәгенә ут тергезде дә озын саплы пыскыйны кулына алды. Пыскыйга ут кабызгач, түгәрәк өй эче яктырып китте һәм шул чакны түбәдән төшә торган баскычка каршы якта, салам ятактан читтәрәк, караңгы һәм зур гына баз авызы күренде.

Турыдан, җир астыннан төшә торган яшерен баскыч шуннан башлана иде. Төшкәндә Кәбир алдан китте, пир ата Мәҗит, бер адым чамасы калышып, аның артыннан атлады. Турыга юл кыскарак булганга, мондагы баскычның басмалары тәбәнәгрәк иде. Монда да барлыгы өч йөз алтмыш басма бар иде. Монда да басмалы юл ике кеше янәшә атлап барырлык киңлектә ясалган иде. Җир асты юлы баш тимәслек дәрәҗәдә биек итеп эшләнгән, ике ягына да тигез итеп киселгән кара, кызыл ташлар тезелгән, түбә өстенә исә гөмбәзләп шулай ук киселгән ак ташлар тезелгән. Ак түшәмдә, беленер-беленмәс кенә булып, пыскыйларда янган хуш исле май корымы сыланып калган. Түшәмдәге, кырыйдагы ташлардан бик борынгы кешеләр кара тиргә батып кискән, шомарткан тигезләгән ташлардан ниндидер ят исләр бөркелә сыман. Кулыңда утлы пыскый булса да, яныңда Изге ата булса да, монда һәрвакыт никтер куркыта, никтер шомландыра. Пыскый утының яктылыгы барып җитмәгән караңгылыктан — алдан, арттан, алтмыш басма саен ясалган сикеле уемнардан кемнәрдер сине сагалап, күзәтеп тора сыман. Монда тып-тын. Шулай да чак кына туктап, тирә-якка колак салдыңмы, кайдадыр челтерәп чишмә дә ага, кайдадыр кемнәрдер пышын-пышын килеп үзара сөйләшә дә кебек, кайчагында хәтта ташка таш, ташка җиз тигән тавышлар ишетелеп киткән кебек. Кайчагында исә чигәләрдәге тамырлардан шаулап кан акканы, яктыга ыргылып, ашыгып йөрәк типкәне ишетелеп китә.

Пир ата бераз гына соңга калганны чамаламый булдырмады, күрәсең, Тау иясе турында баягынак кирәкмәгән сүз ычкындыруын да онытып җиткермәгәндер — төшкәндә сикеләргә дә утырып тормады, «йөрәгем!», «башым әйләнә!» дигән сүз дә әйтмәде. Хәтта Кәбирне ашыктыра төште.

Җир асты юлы бераздан тар һәм тәбәнәк ишеккә килеп төртелде. Ишеккә җиту белән, Кәбир утын сүндереп пыскыйлы савытны аяк астына, ишек төбенә куйды. Ишек бикле түгел иде. Җиңелчә этү белән, ул, чак-чак кына шыгырдаган тавыш чыгарып, тышкы якка ачылып китте һәм шул чакны хуш исләр белән, рәхәт талгынлык белән җанланган яктылык бәрелде. Җир асты караңгылыгыннан кояшлы иркен дөньяга килеп чыгу күңелдә ниндидер авыр, күңелсез нәрсәдән котылу куанычы тудырды.

Яшерен ишектән соң бер-берсе өстенә өелешеп утырган зур-зур таш кантарлары арасыннан түбән таба бор-

галанып тар сукмак сузылды. Сукмакны, таш араларын куе, чәнечкеле куаклар каплап алган иде. Энә сыман озын чәнечкеләргә төртелмичә исән-имин үтеп китү өчен, юлчыларга әле иелергә, бөгелергә, әле тар җирләрдән яннары белән үтәргә туры килде. Башка вакытта, алдан ук яшерен юлдан барырга кирәк чагында, алар, гадәттә, өсләренә башлыклы тире чапан каплыйлар иде. Бүген менә пир ата да, Кәбир дә, җир асты юлына аяк баскан-да, тар сукмак буендагы чәнечкеле куакларны онытып җибәрделәр.

Тигез, ачык җиргә килеп чыккач, пир ата уңга каерды һәм тапталган үлән арасыннан каршыдагы калкулыклар ягына атлады. Сукмаклар кисешкән төштән бер ун адым чамасы арырак, сукмак эчендә дүрткел таш багана калкып утыра иде. Таш багана янында алар туктап калдылар. Кәбир, аны-моны әйтмичә, таш баганаың таш капкачын ачып, аны җиргә куйды. Яртылаш куыш таш багана эченә ике яктан ике тоткасы булган тирән генә агач табак куелган, табакка бал катыштырып яңа сауган сөт салынган иде. Пир ата белән Кәбир килүгә көн дә иртән аны монда шулай көтүчеләр куеп китә. Кәбир, иелеп, сөтле табакны кулына алды. Ул арада пир ата таш сандык төбендә яткан җиз быргыга үрелде, суга сикерергә җыенган кеше сыман, сөткә карап, беравык тынып торды, тирән итеп бер тын алды. Шуннан соң ул, калкулыклар ягына борылып, сузып-сузып быргы уйнатырга тотынды. Бертын уйнаткач, чак кына туктап торгандай итте, шуннан соң тагын уйнатты һәм тагын тынып торды. Өч мәртәбә өзеп-өзеп быргы уйнатканнан соң, ул, табакны кулына алып, калкулыклар ягына таба кузгалып китте. Кәбир таш багана янында торып калды.

Пир ата сөт тулы агач табакны ике куллап тоткан килеш, ашыкмыйча гына калкулыклар ягына атлады. Ара-тирә адымын әкренәйтеп, сузып-сузып аваз салып алды. Ике калкулык бергә килеп кушылган төштә, куе агачлар белән капланган чытырманлык арасында, тар гына тау куышы бар. Анда — Тау иясе. Җиз быргы тавышын ишетеп, ул көн дә куышыннан чыга, куыш алдындагы яшел болын уртасындагы имәнгә урала да көтеп тора. Алдына куйган табактагы сөтне эчә дә кире куышына кереп китә.

Бүтән көннәрне, җиз быргы тавышын ишетү белән, Тау иясе ашыгып чыга һәм пир ата килеп җиткәнче имәнгә уралып ята торган иде. Бүтән көннәрдә пир ата аның куаклар арасыннан шуышып чыгуын да, имәнгә

килеп урала башлавын да ерактан ук күреп тора иде. Бүген ул нишләптер аны беркайда күрмәде — шуышып килүен дә, имәнгә урала баруын да. Ул үзенең тегендә югарыда Тау иясе турында ялгыш сүз ычкындыруын әле булса оныта алмады, һәм аның күңелен әле булса шомлану тойгысы изеп торды. Аны курку биләп алды. Ләкин аңа, әлбәттә, куркырга ярамый иде, хәтта курыккан очракта да, Тау иясенә берни сиздерергә ярамый иде.

Пир ата түгәрәк болынга аяк басканда, ниһаять, куаклар арасыннан чыгып килүче Тау иясе күренде. Пир ата, аны күрү белән, буйсыну белдереп, башын түбән иде һәм, ярым көйләп, ярым кычкырып:

— Изге ия, изге Ата! — диде. — Сиңа көнлек азык килде. Син яраткан баллы сөт. Без сине олылыйбыз, алкышлыйбыз. Үзебезне, малыбызны, җиребезне кырып салма. Мәңге безнең яклаучыбыз бул. Көч-куәт иясе, олуг Ата!

Аклы-каралы таплары, түбә өстендә саргылт тамгасы, кыска гына ике мөгезе булган, таза ир кеше ботыдай юан гәүдәле һәм дилбегәдәй озын елан кыяфәтле Тау иясе, исәнләшкән сыман башын калкытып, җиңелчә ысылдап алды һәм киң ботаклы юан имәнгә уралды да көтә башлады. Пир ата, бик нык иелеп һәм ничек тә иянең дәһшәтле йөзенә карамаска тырышып, һаман имәнгә якынлашты. Бер-ике адым каларак ул тезләнде һәм шулай тезләнгән килеш, вак-вак адымнар белән атлагандай итеп, мөгезле елан авызына якынлашканнан якынлаша барды. Шул ук вакытта ул Тау иясенә алкышлау сүзләре көйләвеннән туктамады. Ике арада ярты терсәк буедай гына ара калгач, ул табакны җиргә куйды һәм иплән кенә артына чигенгәндәй итте. Тау иясе сөтне дә, балны да бик ярата, шуңа күрә ашыгып, кабаланып эчкәндә, кайчагында аның авызыннан сөт чәчрәргә, битеңә-күзеңә тияргә мөмкин. Ул чагында инде бетте дигән сүз. Күзең сукыр кала, битең шешеп, янып чыга. Үзең бер-ике көннән аяк сузасың. Бөтенесен тапшырганда изге пир аталар шулай кайбер серләрне әйтеп калдырганнар. Менә хәзер ул серләрне аңа да — Мәҗиткә дә кемгәдер әйтеп калдырырга туры килер микәнни? Түгәрәк өйгә менгәндә дә, төшкәндә дә, ул туктаусыз шул турыда уйлады. Тау иясе авызына якын гына торганда да, ул әлеге уйларын оныта алмады. Аның, билгеле, әлегә беркемгә үзенең серләрен чишәсе килмәде.

Сөтне эчеп бетергәч, Тау иясе башын табактан күтәреп, читкә борылды һәм әкрен генә имәннән сүтелә башлады. Хәзер ул кире үз куышына кереп китәчәк һәм көне

буе, төне буе тын гына йоклап ятачак. Ул кузгалып, сүтелеп куаклар арасындагы куышына юнәлгәнче, пир ата Мәҗит тын да алмый көтеп торды һәм бары тик аның кереп китүенә ышангач кына, арты белән кайту ягына кыймылдый башлады.

Таш багана-сандык янында шулай ук тын да алмый аны Кәбир көтеп торды.

Кәбир янына килеп җиткәндә, пир атаның тын алуы җайлана, йөзендәге куркуы кими төште. Яранына күтәрелеп карамыйча гына ул аңа буш табакны тоттырды да ары китеп барды. Кәбир буш табакны кире урынына куйды, таш капкачны япты һәм ашыгып Изге ата артыннан китте.

Бу вакытта инде бөтен үзән аякка баскан иде. Берәүләр күптән инде торып, казан асып, ут-учак тирәсендә булаша, икенче берәүләр, картраклар, иртәнге кояшта җылынып, хозурланып утыра, өченче берәүләр исә әле яңа куышларыннан чыгып килә. Болары — яшьрәкләр, йокларга яратучылар. Мондагы кешеләрне беркем таяк белән кыйнап эшкә кумый, беркем аларны бернигә мәҗбүр итми. Алар үз ирекләрендә. Алар бары Актау илендә буыннан буынга килгән тәртипләргә, кагыйдәләргә генә буйсыналар. Барыннан да бигрәк алар атабыз Адамны олылыйлар, аңа гына хезмәт итәләр. Аннан соң алар, билгеле, атабыз Адамның сөекле улы пир ата Мәҗиткә буйсыналар. Буш вакытларында һәркем үзе теләгән, үзе яраткан эшен эшли. Берәүләр мал-туар янында булырга ярата — андыйлар көтү көтәләр. Актау изгеләренең йөзәр баштан да ким булмаган ике сыер көтүе, меңгә якын куйдан торган ике сарык көтүе бар. Кайберәүләр иген эшен, бакча эшен ярата — алар башлыча иген, җимеш, яшелчә үстерәләр. Яшьрәкләр, тазараклар якындагы таулар-урманнар ягына ауга йөри. Монда һәркем изге, изгеләрдән дә изгерәкләр имче һәм галим санала.

Үзән кырыендагы текә кыяларны казып кереп яки анда таш, кыя араларындагы ярык, куышларны җайлап, борынгы кешеләр үзләренә оя корганнар. Ул вакытларда үзәндә кыргый хайваннар да күбрәк булган, дошман кабиләләр дә әз булмаган. Хайваннардан, күршеләрдән саклану өчен, борынгылар куыш авызын җир өстеннән ничек тә өстәрәк, югарыдан ясарга тырышканнар. Куышка кереп-чыгып йөрү өчен биек баскычлар куелган. Баскычларны төнгә алып куйганнар. Тора-бара үзәндә генә түгел, бөтен тирә-якта ерткыч хайваннар да кимегән, кораллы күршеләр һөҗүме дә

тукталган. Кайбер биегрәк, тору өчен җайсызрак куышларга мәет күмеп, куышларның авызын таш белән томалап куйганнар. Җайлырак, иркенрәк куышларда яшәү дәвам иткән.

Соңгы елларда Актауда, түгәрәк үзәндә кеше арта башлагач, изгеләр борынгы куышлардан баш тартып, үзән уртасына — берәр калкурак, матуррак җиргә, йә чишмә буена үзләренә таштан, камыштан куышлар ясый башладылар. Кайберәүләр хәтта берләшеп таштан чын өйләр салырга тотынды. Кәбирнең әле андый чын өйләрне күргәне юк. Күрмәсә дә, ул инде күптән чын өйне күз алдына китереп, хыялланып алды. Дөрес, хыялы аның бала вакытында хәтерендә сакланып калган күренешләрдән ары узмады. Җаен туры китереп, ул Мәҗиткә дә әйтеп карады: «Пир ата, син монда иң олы, иң хөрмәтле кеше, ник үзеңә дә биек итеп, мака сарныкы кебек итеп алтынлап-көмешләп өй салдырмыйсың?» — диде. Мондый сүзгә пир ата көлемсерәп кенә куйды, аннан соң әйтте: «Беркайчан алтын-көмешкә күмелгән биек өйләргә, биек манараларга, күзнең явын ала торган байлыкка кызыкма, балам, — диде. — Мака сар бөек, изге. Мака сар — көч-куәт иясе. Аклан сараена бүген дөньяның яртысы буйсына, — диде. — Ләкин нинди генә бай, көчле-куәтле булмасын, ул да берзаман өрәк иленә күченеп китәчәк. Без барыбыз да — атабыз Адам балалары... Тәңребез Мин дә, анабыз Дикә дә иң элек алтын сарайларда түгел, тәбәнәк кенә камыш куышларда яшәгәннәр...» — диде.

— Безнең кебек куыштамы? — диде Кәбир.

— Безнеке кебек куышта, — диде пир ата Мәҗит.

Һәр көнне иртән башкарыласы эшләрен башкарып, күпмедер дәрәҗәдә җиңеләеп һәм ашыйсы килеп, үзләренең чишмә янындагы куышлары янына килгәч, нишләптер Кәбир шушы сөйләшүне исенә төшерде. Аннан соң аның нишләптер Карлы елгасының теге ягына чыгасы, ул яктагы болыннарда, агач араларында йөрисе, тирәякны Карлы елгасының бер ягыннан икенче ягына салынган асылмалы күпер уртасыннан түбән карап торасы килде. Шуннан соң бернинди бәйләнешсез рәвештә ул үзенең бала чагындагы биек йортлар, тар урамнар, коймалар арасына әйләнеп кайтты, туктаусыз чайпала, чайкала торган диңгез буенда кәмәләргә карап торды, таш юлдан ары-бире агылган кешеләргә, җигүле арбаларга карады. Кара кыя башына менеп, еракларга күз ташлап төшкәннең соңында һәрвакыт аның күз алдына шундый күренешләр килә һәм элеңдән-әле искә төшеп, борчып интектерә башлый.

Үзләренең куышлары янында алар тоткарланып тормадылар, таш күбәтәләрен алдылар да ары китеп бардылар. Читтәрәк, үзән уртасына табарак, иртәнге тын һәм талгын һавага ачы төтен, тәмле аш исләре чыгарып, корымланып беткән җиз казанда ботка пешә иде. Шунда ук казан тирәсендә ашчылар кайнаша һәм шунда ук, төкерекләрен йотып, түгәрәкләнеп, тыйнак кына изгеләр көтеп утыра иде.

Казан янына якынлашу белән, пир ата баш кагып иң элек ашчылар белән, аннан соң көтеп утыручылар белән исәнләште. Изгеләр, күңелле гөрелдәп һәм шулай ук баш кагып, икесе бергә кушылган кулларын югары күтәреп, пир ата Мәҗиткә алкышлау белдерделәр. Яшьрәкләр аягүрә бастылар. Арада биш-алты, җиде-сигез яшьлек малайлар да бар иде. Беркайчан тыныч кына утыра, тыныч кына басып тора белми торган, һәрвакыт нидер сөйләнә, көлә-шаяра торган малай-шалайлар сөенеп кычкырырга, шаулашырга ук тотындылар. Мәҗит ата үзенең тире җәеп куелган калкурак урынына килеп утыргач, кыюрак малайларның кайберләре Актаудагы иң өлкән, иң изге ата янына елыша башладылар — кайсы аның уң ягына, кайсы сул ягына килеп утырды, бер аягына аксый торган, башкаларга караганда кечкенә буйлы, дүрт-биш яшьлек Сабит исә өлкән ир кешенең тезенә үк менеп утырды. Пир ата балаларның башыннан, аркасыннан сыйпады, елмаеп, йомшак кына итеп берәр сүз әйтеп куйды. Пир атага якынрак утырган олыраклар әрсез балаларны читкәрәк куалап җибәрмәкче булдылар — кайберләре сиздермичә генә төртеп алды, кайберсе ачуланып ысылдап алды. Пир ата, балаларны яклап, киресенчә, аларны кочагына якынайта төште.

Әрсез малай-шалай кайчагында Кәбирнең дә ачуын китерде, ләкин ул башкалар кебек аларга кычкырмаска, каты бәрелмәскә тырышты. Бигрәк тә менә бу Сабит кебек бәләкәчләргә ул беркайчан каты сүз дә әйтмәде, тупаслык та эшли алмады. Кайчандыр аны да монда нәкъ менә шундый Сабит кебек чагында калдырып киткәннәр. Күп нәрсәне инде ул хәтерләми, ләкин кайбер нәрсәне әле бик яхшы хәтерли. Аны монда әтисе алып килде. Алар монда әле җәяүләп, әле арбага утырып килделәр. Арбада утырып килгәндә дә, җәяүләп килгәндә дә күбрәк йоклап килде бугай. Арбага утыру белән туктаусыз тирбәнеп-чайкалып барудан шундук аның күзләре йомылды. Җәяүләп барганда нишләптер бик тиз арыды һәм әтисе кулына алып күтәрдеме, аруалҗудан һәм сөенечтән шундук аның күзе йомылды.

Иң кыены этисе белән аерылышу булды, ахрысы. Әтисе олы, карт кешеләр белән нидер сөйләште дә, кинәште дә: «Сау бул, исән бул, улым!» — диде дә китте дә барды. Ул елап аның артыннан йөгерергә тотынды, ләкин эти кеше артына борылып та карамады. Кәбир берни аңламады. Аның бик нык хәтере калды. Мондый читләшүгә, мондый кансызлыкка аның бик нык итеп үпкәлисе килде. Аннан соң аны курку, берни белән аңлатып булмастай курку биләп алды. Нишләргә, нәрсә уйларга белми баскан җирендә катып торганда, искәрмәстән аның янына этисеннән дә олырак гәүдәле, зуррак куллы бер кеше килде дә, яратып, аркасыннан сөйде, башыннан сыйпады һәм бик тә якын итеп:

— Исемең ничек әле синең, балам? — диде.

Куркудан, аптыраудан, хәтере калудан Кәбир хәтта исемен дә оныткан иде.

— Белмим, — диде ул һәм яңадан еларга кереште.

— Миңа сине Кәбир исемле дигәннәр иде, — диде олы кеше. — Кәбирме син, түгелме син?

— Кәбир, — диде ул, яшь аралаш.

— Кәбир ул беләсеңме кем? — диде олы кеше. — Кәбир ул «зур малай» дигән сүз. Зур малайлар, батыр малайлар бер дә еламыйлар. Батыр малайлар бездә көләләр, уйныйлар, сикерәләр. Аннан соң көн дә атабыз Мингә рәхмәт әйтәләр, зекер кылалар.

— Минем эти киләме соң? — диде Кәбир.

— Килмичә! — диде олы Кеше, җиңел генә. — Менә күрерсең, иртәгә килеп тә җитәр. Иртәгә килмәсә, иртәгә соңга килер. Иртәгә соңга да килеп җитә алмаса, җәрингә килер.

Ул вакытта Кәбир «җәрингә»не дә, «иртәгә соңга»ны да бик үк аңлап җитмәде. Ул бары этисенең яңадан килерен генә белде, аннан да бигрәк, этисенең килүен һәм үзенең яңадан әле арбага утырып, әле этисенең күкрәгенә сыенып, киң, озын һәм тигез юлдан каядыр барырга, туктамыйча барырга да барырга гына теләвен белде. Әтисеннән дә зуррак гәүдәле, ягымлырак йөзле ят ир кеше аны күтәреп алды, сөйде, иркәләде һәм каядыр алып китте.

Ул вакытта да алар нәкъ менә шушында, шушы корымланган зур казан янына килделәр. Олы кеше, ягымлы кеше шушы ук калку урынына утырды, биш яшьлек Кәбирне исә алдына — йомшак, җылы тәненә сыендырды. Ул вакытта көн, бәлки, салкынрак булгандыр — ул хәтта өстендәге киндер чапан итәген аның аркасына ябып куйды. Тагын шунысы истә калган: бер савыт тутырып

аңа яңа сауган җылы сөт бирделәр. Сөткә бал катыштырганнар иде. Ул әле дә шул монда беренче мәртәбә эчкән баллы сөт тәмен авызында тоя сыман. Әле дә дөньяда иң тәмле, иң татлы ашамлык-эчемлек аңа шул баллы сөт булып тоела.

Сөт эчкәч тә ул тамагы туеп, җылынып һәм бар кайгысын онытып оеп китте.

— Йокла, балам, йокла, — диде пир ата, ул чагында сөеп, иркәләп.

Менә монда ул унтугыз ел йоклады. Әле йоклады, әле күзен ачты һәм уянып киткән саен өйләрен, әтисен, андагы туганнарын, танышларын хәтерләде. Әтисе «иртәгә соңга»да, «җәрингә»дә килмәде. Кәбир аны унтугыз ел буена көтте. Көн туып таң аткан саен күзе юлда булды. Юк, килмәгәч килмәде әти кеше. Аңа хәзер егерме дүрт тулды... Кайчан туладыр ул — төгәлен генә белерлек түгел. Көзгә таба булырга тиеш. Көн кызуы сүрелә төшкәч, игеннәрне урып алгач, яфраклар, үләннәр саргая башлагач егерме дүрт яше тулган беркемне дә монда тотып тормыйлар. Мондагы кеше егерме дүрт яше тулгач, йә иркен дөньяга чыгып китә, яисә мәңгегә шушында торып кала. Ул менә чыгып китәргә булды.

Ул инде монда күп нәрсәгә өйрәнде, күп нәрсәнең серенә төшенде. Чыккач, теләсә, динче булачак, теләсә, имче булачак. Теләсә, ул ташчы да, балтачы да, көтүче дә була ала. Теләсә, ул балаларны язарга-сызарга, җыргакөйгә өйрәтә алачак. Бер җирдә дә эш тапмаса, саилче булып, өйдән өйгә, авылдан авылга теләнеп йөриячәк. Тик монда гына калырга язмасын, Изге атам! Ләкин пир ата белән ачыктан-ачык сөйләшеп булмады бит әле. Ашагач-эчкәч инде...

Пир атаның тез өстенә менеп утырган Сабитны күрү белән, Кәбирнең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ул иплән кенә, шау-шусыз гына олы кешенең артынарак барып утырды һәм көндәгечә көтә башлады.

Ашчыларның берсе — биленә кыска гына күн алъяпкыч бәйләп куйган, гел аш-су тирәсендә булашкангамы симерә башлаган Шәүкат — бер кулына авыр такта чиләк, икенче кулына озын саплы җиз чүмеч тотып һәркемгә сөт бүлеп бирә башлады. Казан янына һәркем күбәтәсен үзе белән алып килгән иде. Сөт бүлүне ул пир атадан башлады. Пир атадан соң аның тезендә утырган Сабит күбәтәсенә салды. Сабиттан соң шул тирәдәге башка малайларга салды. Пир атадан арттарак утырган Кәбирне ул, билгеле, күрмәде түгел, күрде, ләкин күрмәмешкә салынып читләтеп үтте. Ул гел шулай. Кәбир-

дән ул бер-ике яшькә яшьрәк. Икәүдән-икәү генә калганда, ул ягымлы, күндәм, хәтта ялагай. Икәүдән-икәү генә булганда, ул үзенең синнән кечерәк тә, түбәнрәк тә булуын танырга мәҗбүр. Ләкин башкалар белән бергә булганда, Шәүкат үзгәрә дә куя. Шунда ул сине санга сукмавын сиздерә башлый — йөзеңә карап синең кимчелегеңне әйтә, әллә кайчангы нәрсәләрне исенә төшереп, синнән көләргә тотына һәм үзенең барлык сүзе, кыланышы белән синнән шәбрәк тә, өлгеррәк тә, чибәррәк тә икәнлеген күрсәтмәкче була.

Аның бу гадәтен һәркем белә, аңа инде яхшылап әйтеп тә карадылар, тупасланып та карадылар, ләкин аның әлегә үзгәрергә исәбе юк. Шундый кыланышлары өчен, икейөзлелеге һәм аумакайлыгы өчен Кәбир аны беркайчан чынлап торып якын күрмәде. Аумакай, икейөзле булу өстенә, Шәүкат көнчел дә иде бугай әле. Кәбирдән ул ачыктан-ачык көнләште. Үзеннән өлкәнрәк булган өчен генә түгел, пир атаның, Изге атаның беренче яраны, сөеклесе булганы өчен дә көнләште. Кем белә, бәлки, аның да аш-су белән булашмыйча, көн дә Изге атага ияреп кара кыя башына менәсе, нәфит утын яндыруны-сүндерүне үз күзләре белән күрәсе киләдер. Аннан соң аның мондагы кайбер серләрне дә беләсе килә. Башкалар кебек ул да, пир ата белән бер куышта торгач, Кәбир инде бик күп серләрне беләдер, галимлеге баштан ашкандыр дип фикер йөртә. Кайчагында ул аңа карата чынчынлап хөрмәт күрсәтә һәм беркатлы бер кызыксыну белән: миңа гына әйт әле, ничек яна соң ул? дигән сораулар биргәләп куя. Андый чакта Кәбир, билгеле, үзенең дә берни белмәвен сиздермәскә тырыша һәм бик тә мәгънәле итеп: «Аны бары алла гына белә», — дип куя.

Менә тагын Шәүкат Кәбирне юри читләтеп узып китте. Кәбир, тешен кысып, үз-үзен тыеп калды. Изгеләр алдында, аш янында тупаслану түгел, юк-бар сөйләнү дә әдәпсезлек санала иде. Яратмыйча күзәтеп утырганда, Кәбир шуңа да игътибар итте: пир ата тирәсендә Шәүкат юри озаграк тоткарланды, бер дә кирәкмәгәнгә елмайган булды, пир атаның күз алдында гына бөгелгән-сыгылган булды. Тикмәгә түгел, билгеле. «Менә мин киткәч, тулысынча синңа калыр Изге ата» дип уйлады карасына коелып утырган Кәбир. Аш пешерүеңне ташларсың, пир ата белән бер куышта тора башларсың, көн дә кара кыяга менеп төшәрсең. Пир атаның сөеклесе булырсың. Яратса, билгеле. Ләкин синең кебекләрне ярата алыр микән ул?

Кәбир үзалдына шулай юк-бар уйланып утырганда, Шәүкат түгәрәкләнебрәк утырган кешеләргә уртадан сөт

таратып чыкты да, казан янындагы икенче чиләкне алып, түгәрәкнең тышкы ягына чыкты һәм Кәбир кебек арырак утырган калганнарга таратырга тотынды. Сөт алган һәркем, эчәр алдыннан берничә тамчы сөтне иң элек Ту атага садака итеп бирде. Чишмә ярына якынрак утырганнар садаканы борылып, үрелеп кенә бирделәр, арырак утырганнар, урыннарыннан торып, агымсу янына барып үзләренең изге бурычларын бурычлап килделәр. Кәбир кузгалып та тормады, кулын сузып учындагы сөтне суда юып кына алды.

Бал катыштырылган сөтне эчкәч, ул шундук тынычланып, хәтта авыраеп калды. Сөттән соң Шәүкат арпа боткасы өләшә башлады. Бу юлы да ул иң элек пир атадан башлады. Аннан соң кечкенә малайларга салды. Бу юлы да Кәбир аның һәрбер хәрәкәтен, һәрбер кыланышын күзәтеп утырды, ләкин баягыча аның юкка-барга ачуы да килмәде, ашчы турында төрле ямьсез уйлар да килмәде. Шәүкат аңа, киресенчә, хәтта бик җитез һәм өлгер булып тоелды. Шул чакны ул Бәләкәчнең пир ата тезендә йоклап китүенә игътибар итте. «Мин дә иртән ашагач йоклап китә торган идем» дип уйлады ул. Шәүкат чиләктән җиз чүмече белән кайнар ботка сосып алды да йоклаган малайның җиз күбәтәсен җиңелчә генә шакылдатып алды. «Мине дә шулай уята торганнарые», — дип уйлады Кәбир. Бәләкәч уянмады. Пир ата, Бәләкәчнең бәләкәч кенә күбәтәсен җайлап тотты. Ботка салынгач, ул аны читкә, җир өстенә алып куйды.

— Уянгач ашар, — диде ул, Бәләкәчнең башыннан сыйпап.

— Туйган инде ул! — диде шунда Бәләкәчтән берике яшькә өлкәнрәк икенче бала.

— Ашамаса, кошларга бирер, — диде пир ата, малайга җавап итеп.

Боткадан соң Шәүкат әле генә өзгән җимеш өләшеп чыкты. Иң тәмлесе җимеш булды. Барысы да ашап туйгач, бу рәхәтлектән аерыласы килмәгәндәй, беравык тынып утырдылар. Яшьләр, балалар үзләренә тигән өлешне иртәрәк ашап бетерделәр, ләкин өлкәннәрдән узып торып китәргә беркемнең дә күңеленә килмәде. Ашау пир атадан башланган кебек, урыннан торып китү дә бары аннан гына башлана иде. Пир ата исә бүген Кәбиргә озаграк утыра сыман тоелды. Ашап туеп эше беткәч, ул яңадан үзенең күптәнге уен исенә төшерде. Хәер, аның онытылып торганы да булмады. «Ашагач нишләр пир ата? — дип уйлады ул. — Куышлар борынча йөрергә чыгармы, басуга игенчеләр янына барырмы, әллә соң

аксакалларын җыеп берәр нәрсә турында киңәш-табыш ясармы?» Бу арада берәрсенең кыек эшен тикшерәсе, кемне дә булса хөкем итәсе юк шикелле. Аксакаллар киңәше булса, алар алдында әйтеп булмаячак. Басуга яисә көтүчеләр янына барырга исәпләсә, анда әле юл озын...

Чыннан да пир ата бүген озаграк утырды. Тезендә йоклаган Бәләкәчне уятасы килмичә онытылып китте, ахрысы. Шул чакны ул башын калкыткандай итте һәм үз тирәсендәге кешеләрнең күптән инде ашап туйган булуларын һәм бары тик аның кузгалуын гына көтеп утыруларын шәйләп алды. Шуннан соң ул йоклаган баланы кочаклап күкрәгенә алды да, икенче кулына буш күбәтәсен тотып, аягүрә басты. «Мине дә шулай йоклаган килеш күтәрәләр иде» дип уйлады Кәбир.

Пир ата, Бәләкәчне күтәреп, ут-учак янына килде, иелә төшеп, кулындагы таш күбәтәнең эчке ягын бераз вакыт ялкын өстендә тотты. Ашагач, табак-савытны суда юарга ярамый иде. Ашаганнан соң табак-савытка йогып калган азыкны суга салу ул Ту ата Минне хурлау белән бер иде. Аллаларга азыкның калдыгыннан түгел, беренчесеннән, яхшырагыннан өлеш чыгаралар иде.

Пир атадан соң башкалар да утырган урыннарыннан торып, бер-бер артлы ут янына килә тордылар һәм таш күбәтәләренең эчке ягын ут өстендә тота тордылар.

Шулай итеп ашап, туеп, кузгалып китәргә генә торганда, капка ягыннан якынлашып килүче Кәттин күренде. Ашарга килә микәнни? Ләкин янына алмаш килеп җитмичә торып ул капка яныннан китмәскә тиеш иде. Нәрсә булган аңа?

— Турадан кеше килгән, Изге ата, — диде капка каравылчысы, пир атага баш иеп.

— Нинди кеше? — диде Мәҗит ата, берни аңламыйча. — Керергә сорыймыни?

— Керергә сорый, — диде Кәттин. — Турадан, изге сарайдан, пир ата. Мака сарның үзеннән.

— Мака сардан?! — диде пир ата, каушагандай итеп. — Йомышы ни, сорамадыңмы?

— Сорадым, — диде Кәттин, казан ягына караштырып.

Пир ата әле һаман йокысыннан уянмаган Бәләкәчне җиргә бастырды да аркасыннан сөеп куйды. «Әйдәгез әле, барып карыйк» дигән сыман, янындагы яшьрәк ирләргә күз төшереп алды һәм капкага таба юнәлде. Бер-ике адым калышып, аның артыннан Кәбир дә иярде.

Юан таш баганалы, җиз күгәнле авыр имән капканың аркылы агачы шудырып куелган, шуңа күрә җәяү-

леләр кереп-чыгып йөри торган, кечерәк ягы эчке яктан ачык калдырылган иде. «Ачыгавыз!» дип уйлады пир ата Кәттин турында, яратмыйча. Кояш чыгышыннан алып кояш батышына кадәр көне буе кече капка ачык тора һәм, күптән килә торган тәртип нигезендә, Актауга теләсә нинди юлчы, теләсә нинди саилче, теләсә нинди мохтаҗ кеше керә ала иде. Монда аяк басу белән, ул атабыз Миннең сөекле колына әверелә һәм монда аңа каршы беркем бернинди көч куллана алмый иде. Элегрәк ул шулай булган. Ләкин заманалар үзгәрде, күз алдында үзгәрә бара. Илдә, җирдә бозыклык күбәйде. Чын мохтаҗлар, чын саилчеләр, авырулар арасында бозык юлга басканнар, ялганчылар, угрылар очрый. Җитмәсә, якында гына, текә кыя астында гына иксез-чиксез диңгез җәйрәп ята. Диңгезнең киртәсе юк. Төн ягыннан әледәнәле ят кәмәләрдә ят кешеләр, комсызлыктан, явызлыктан күзе-зиһене томаланган юлбасарлар килеп чыга.

Шулай да тар капканың ачык калдырылуы әллә ни язык эш булмаса да, пир атага хәзер капка каравылчысының алдын-артын карамыйча казан ягына китеп баруы ярамаган эш булып тоелды. Хәер, Кәттиннең гамьсезлегеннән бигрәк аның эчен көтелмәгән кунак пошырды, ахрысы. Теләсә нинди юлчыга, саилчегә капка ябылырга тиеш булмаган кебек, мака сардан килгән кешегә дә капка ачык булырга тиеш иде, әлбәттә. Ләкин бүген пир ата исәпләгәнчә, бу тар капка нәкъ менә мака сар кешесе алдында гына ябылырга тиеш тә иде кебек. Ни генә булмасын, аның һич тә мака сар кешесе белән очрашасы килми иде. Ул кеше хәтта угры, юлбасар булмаса да!

Алар теге якта, капкадан бер ун адым чамасы читтәрәк очраштылар. Таш баганалы имән капкага килә торган таш юл буенда куе яфраклы биек агачлар күләгәсендә яхшы атлар җигелгән берничә кәрендәс туктап калган. Матур итеп бизәлгән биек һәм ике тәгәрмәчле кәрендәсләрнең берсендә, иң алдагысында, кызыл күнле йомшак утыргычта йокымсыраган кыяфәттә өлкәнрәк яшьтәге бер кеше утыра иде. Туктале, кем соң бу? Таныш та сыман, түгел дә сыман. Ба... Бабул дисәң, артык карт күренә, Бабул димәсәң, йөзе-кыяфәте, килеш-килбәте, күзен йомыбрак утыруы — барысы да аңа охшаган. Кыска сакал-мыек җибәргән, чәче дә кыска итеп алынган, ләкин мондагыларныкы, Актаудагыларныкы кебек такыр итеп алынмаган. Иңбашына бөркәнгән җиләне дә зәңгәр төстә, кызыл тасмалы. Атларының маңгаенда, күкрәкчәләрендә, камытларында, кәрендәс алдында, кырыенда, хәтта тәгәрмәч тәпилә-

рендә, тугымда — һәркайда ялт итеп торган җиз, алтын-көмеш балкый. Алай гына да түгел, туктап калган, ләкин ерак юлдан килгәннән соң да тынычлана алмаган, баскан урыннарында биеп торган атлардан, кешеләрдән, кәрендәсләрдән еракта калган шау-шулы тура исе, затлы сарайлар, затлы, көләч, чибәр кешеләр исе килеп бәрелгәндәй булды, бер генә мизгелгә андагы ыгызыгы, ягымлы тавышлар ишетелеп киткәндәй булды. Шул ук вакытта пир ата Мәҗитнең күз аллары томаланып калды, аяк астында җир күренмәс булды. Алдагы кәрендәскә килеп җитәр-җитмәс, ул туктап калды.

— Илгә иминлек, Изге ата! — диде бик еракта калган Бабулга охшаш кеше, Актауның Изге атасын алкышлап.

Аның тавышы каяндыр читтән, таулар арасыннан ишетелгәндәй булды. Шулай да пир ата аны тотып алды, аңлап алды һәм, җавап итеп:

— Амин! — диде дә, — илгә иминлек, сарга тынычлык бирсен, тәңрем, — дип өстәп куйды.

Бабулга охшаган кеше кәрендәстән төште, атны бер читтән әйләнеп, пир ата янына килде һәм күрешү өчен җитез генә кулын сузды. Пир ата Мәҗит, мака сар кешесе алдында буйсыну белдергән сыман, зур такыр башын ия төшеп, ак киндер җилән капланган киң иңбашын бөгә төшеп, түбәнрәк карап тора иде. Бабулга охшаган кеше, теләр-теләмәс кенә сузылган зур, таза кулны ике куллап кысты да, изге атаның йөзенә сынабрак карап:

— Син... Таҗит түгелме, Изге ата? — диде.

— Мин пир ата — Мәҗит, — диде ак киндер җилән кигән кеше, турадан килгән кешенең йөзенә туры карап.

— Шулайдыр дип уйлаган идем мин аны, — диде Бабулга охшаган кеше, үзалдына сөйләнеп.

Пир ата, билгеле, аның нәрсә дип уйлаганлыгын белә алмады. Хәер, ул аның уе белән кызыксынмады да бугай. Хәзер аны барыннан да бигрәк икенче нәрсә борчыды: ник килгән бу Бабулга охшаган... Бабул... Мака сар йомышчысы монда? Беркадәр аптырашып, бер-берсенә карашып торгандай иткәч, пир ата шулай да үзенең каушавын җыңә алды һәм, тавышын мөмкин кадәр тыныч, ягымлы итәргә тырышып:

— Шулкадәр ерак җирдән килгәнсез икән, бер-бер йомышыгыз бардыр, ахрысы, Актауда? — диде ул мака сар илчесенә.

— Йомыш бар! Зур йомыш! — диде илче.

— Алайса әйдә керик, иркенләп сөйләшик, — диде пир ата. — Ашыйсың киләдер, сыйланып та чыгарсың. Юлдашларыңны да чакыр.

— Сезнең сый, сый микән инде ул?.. — диде Бабулга охшаган кеше, мондагы азыкны күрәләтә санга сукмыйча. — Без болай итик — мин үзем генә керermen. Мондагылар монда калыр. Безгә икәүдән-икәү генә сөйләшергә туры киләчәк.

— Минем туганнарымнан яшерен сүзем юк, — диде пир ата. — Теләсәң, икәүдән-икәү генә, теләмәсәң...

— Икәүдән-икәү генә! — диде мака сар илчесе, түземсезләнеп.

— Икәүләп икән икәүләп, — диде Мәҗит ата, артык каршылык күрсәтмичә.

— Үзем белән берәр нәрсә алып керергә ярыймы соң сезгә? — диде илче, кузгалып китәргә әзерләнгәч кенә.

— Ярый. Тик бездә чагыр эчү тыела, — диде пир ата.

— Әйттем бит! Сездәге сый сый түгел инде ул, — диде илче, кулын селтәп.

Пир ата эндәшми калуны яхшырак күрде һәм киттекме дигән сыман кунагына бер күтәрелеп карады да капкага таба юнәлде. Капкадан керү белән, ул мака сар илчесен үзенең чишмә буендагы куышына алып китте. Шул чакны казан ягыннан итле ботка исе килеп бәрелгәндәй булды. Илче Бабул, борынын тарткалап, тәмле аш исе килгән якка карап-карап алды. Пир ата, берни күрмәгәнгә, сизмәгәнгә салышып, үз юлында булды. Куыш янына килеп җитәрәк, илче түзмәде, болай гына кызыксынган кебек сорап куйды:

— Анда нидер пешә бугай? — диде.

— Пешүен пешә дә, сиңа ярарлык сый юк анда, — диде пир ата, теләр-теләмәс кенә.

Илче Бабул эндәшмәде, шулай да тар һәм тәбәнәк куышка кергәч, җир өстенә җәелгән арыслан тиресенә аякларын сузып утыргач, тагын тынычсызлана башлады. Пир ата исә, берни күрмәгән, ишетмәгән сыман, кунакның каршысына утырды да, тыйнак кына:

— Сөйләшик алайса, — диде.

Илче, симез битләрен, итләч калын иреннәрен салындырып, үпкәләгән сыман тик утырды.

— Алып керим дигәч, кертмәдең, үзең ашарга чакырмадың, — диде ул, чын-чынлап үпкәләп. — Ач карынга нинди сөйләшү ди ул?!

— Минем аштан баш тартмаган булсаң, мин сине туры казан янына алып барган булыр идем, — диде пир ата, кунагына каш астыннан гына карап алып.

— Әле дә соң түгел! — диде Бабул, шундук урыныннан торып.

— Барып карыйк алайса, — диде пир ата.

Куыштан чыкканда, ул үзенә дә, кунакка да таш күбәтә алды. Ашчылар да, казан тирәсендә калган башкалар да пир атага килгән олы кунакны ерактан ук күреп тордылар һәм аларның һәр адымын күздән кичерергә тырыштылар.

— Менә күрерсез, барыбер монда киләчәкләр алар! — диде Шәүкат, остарып.

Кунак белән пир ата казан янына килгәч, яшь ашчы масаюдан, сөенеченнән кая басканын белми йөрде. Кәбир аның һәр кыланышын яратмыйча, үртәлеп күзәтеп торды.

Казан янына килеп җиткәч, пир ата, ашчыларга карап:

— Турадан, мака сардан илче килгән. Илченең безнең ашны татып карыйсы килә, — диде.

Алар җиргә аякларын бөкләп утыру белән, яшь ашчы елмаеп җитез генә килеп җитте һәм сузылган буш күбәтәләргә берәр чүмеч баллы җылы сөт салды. Сөтне илче бер күтәрүдә эчеп җибәрде, эчкәч авыз читләрен сөртеп куйды.

— Бал кортының сөтеме соң бу, сыерның балымы соң бу? — диде үзенчә шаяртмакчы булып.

— Безнең кортлар сөт бирә, сыерлар бал бирә, — диде пир ата, җавап итеп.

Сөттән соң ашчы башкаларга биргән кебек, илчегә дә зур итеп бер өлеш итле ботка салды. Ачыккан илче Бабул талымлап тормады — тиз арада анысын да ялт иттереп куйды. Кунагының тамагын туйдыргач, алар яңадан куышка киттеләр. Тире өстенә утыргач, пир ата ерактан килгән кунакка күтәрелеп карады да:

— Сөйләшик алайса, — диде.

Ләкин ул шулай дип әйтеп тә бетермәде, аның күз алдында гаҗәеп бер күренеш булды. Күрәсең, ерак юл килеп арыган-талчыккан Бабул, тамагы тую белән, күз алдында авыраеп калды һәм як-якка чайкалгандай итеп утырды да, тәкатьсез калып йомшак урынга арты белән авып төште һәм кулларын, аякларын сузып җибәргән килеш, шундук гырлап йокларга да тотынды.

Пир ата аны уятырга да, уятмаска да белмичә, беравык урынында утырды да тышка чыкты, ишек чыптасын төшереп куйды.

Кая барырга да, нишләргә дә белмичә, куыш янында Кәбир басып тора иде.

— Менә шулай, — диде пир ата, Кәбиргә эндәшкән сыман, ләкин чынында үз-үзе белән сөйләнеп. — Капка

янында унлап юлдашы калды. Алар да арыгандыр, ачыккандыр. Атларын да, үзләрен дә кертергә, ашатырга-эчертергә туры килә. Менә шулай. Бик зур сүз алып килгән. Мака сар сүзен. Нинди сүз? Мака сарның Актау изгеләренә нинди сүзе булырга мөмкин? Табышмак бу әлегә, Кәбир. Шулай да без аны чишәргә тиеш. Илче йокыдан торганчы. Башкача ярамый. Менә шулай, балам.

## XI

Борынгылар ташка язып калдырган кануннардан читләшү кайчан башлангандыр — төгәлен генә беркем дә белми. Кайберәүләр әйтә, элекке заманда борынгылар сүзеннән чыгу булмаган, читләшү ул әлерәк кенә башланган, ди. Мондый чакта гадәттә мака сар Карунга төртеп күрсәтәләр, мака сар Карунның тетмәсен тетәләр. Мака сар Карунның тетмәсен тетми дә булмый. Аклан иленә Карун сар китергән зыянны, талауны, кыланышны берни белән дә чагыштырып булырлык түгел. Тигез таш җәелгән туры юллар салдырып, әле анда, әле монда алтынланган биек сарайлар, манаралар утыртып, туктаусыз зур-зур кәмәләр, сугыш кораллары ясатып, Карун бөтен илнең җелеген корытты. Үз кешеләре белән, үз алтыны-көмеше белән ясатса, билгеле, беркем аңа бер сүз әйтмәс иде, рәхмәт әйтеп читтән генә карап торыр иде. Юк шул! Мака сар Карун бөтен илне аякка бастырды, көлле кешенең амбарына кулын тыкты, көлле кешенең байлыгына кулын сузды, иң яманы шул булды. Шуңа күрә дә Карун эшләгән барлык эшләр бик күпләргә беренче мәртәбә борынгылар сүзеннән читкә чыгу булып тоелды. Әллә кырык, әллә утыз ел буена ул туктаусыз җир асты сарайлары, амбарлар салдырган. Салым түләү, ясак җыю исәбенә җыелган, казып алынган, талап алынган, урлап алынган бар байлыгын менә шул җир асты сарайларын, амбарларын бизәүгә тотып барган. Сарайлар, амбарлар бизәлгәч исә, калган барлык алтын-көмешне, энҗе-мәрҗәнне, кием-салымнарны шунда тутыра башлаган. Карун, имеш, шул дәрәҗәдә саран, катмыш булган — мака сар булса да үзе көтүчеләр, каралар кебек көн дә сыра эчкән, арпа боткасы ашаган, әче алма кимергән һәм биленә таушалып беткән алъяпкыч бәйләгән, шәрә йөргән. Юк, кулында, имеш, алтын башлы шома таягы да булган. Сарлык билгесе. Үзе, имеш, агачтан салынган кечкенә йортта яшәгән, көн дә, имеш, бакчада казынган. Хатыны да, имеш, бер генә,

балалары күп бүлган. Янында бернинди кораллы сакчысы булмаган, кая тели шунда тәпи-тәпи җәяү йөргән.

Чынында ничек булгандыр, ансын инде беркем белми. Шулай да, тиле-милерәк булса да, Карунны гел хурлап, гаепләп тә булмый. Борынгылар ташка язып калдырган кануннар арасында «алтын җыймаска», «җир астына сарайлар салмаска»дигән бернинди сүз юк. Ул язулы ташларны да, башка борынгы язуларны да Таҗит ага кат-кат укып карады, ләкин аларда мака сарның эшләгән эшләрен юкка чыгарырдай берни тапмады. Эшләрен алай җиңел генә юкка да чыгарып булырлык түгел, чөнки Карунның җир асты сарайларының, алтын-көмеш тутырылган амбарларның кайда икәнлеген беркем белми.

Каруннан соң аның урынына килеп киткән мака сарлар да, угры-караклар да әз тырышмаганнар ул җир асты байлыкларының эзенә төшәргә. Акланның, тураның казып каралмаган, актарып каралмаган бер төшен калдырмаганнар, борынгы сарайлар астына, коймалар астына төшкәннәр, кеше күп җыела торган теләсә кайда ишетелә торган һәр яңа имеш-мимешкә колак салганнар, иске йорт урыннарын тикшереп чыкканнар.

Изге тауда сарай өстендә сарай, таш амбар өстендә таш амбар дигәндәй. Анда җирнең һәр карышы изге. Шуңа күрә анда тора салып казый да алмыйсың, кирәкмәгәнгә нинди дә булса яңа корылма да кора алмыйсың. Шулай да анда да туктаусыз эш бара. Тура халкына сиздермәскә тырышып әле анда, әле монда тирәнтирән коелар казып карыйлар. Җир асты юллары салалар. Карун байлыгы турындагы имеш-мимешкә ышанмаучылар да булган. Буш хыял белән шөгыльләнмичә, ничек тә үзләре нинди дә булса зур эшләр башкарырга һәм шул рәвешчә үз исемнәрен мәңгеләштерергә тырышканнар.

Төзүче Таҗит яхшы белгән мака сар Карман да Карун байлыгына кызыкмады, үзең тапкан мал кадерлерәк дип исәпләде. Егерме биш ел буена Таҗит ата Карман сарның иң ышанычлы яраны булды, егерме биш ел буена аңа турылыклы хезмәт итте. Мака сарның теләгенә туры китереп, ул яңа сарайлар, корылмалар салдырды, сугыш кәмәләре ясатты, елгалар, тар үзәннәр аша күперләр күтәреп, тау-ташларны кистереп, туры юллар салдырды. Аклан иленең, Аклан утравының көньягыннан төньягына сузылган, чакрым саен таш багана утыртылган туры юлны да Таҗит төзүче салдырды. Бу аның да, мака сар Карманның да үз гомерләрендә соңгы зур эш-

ләре булды. Аклан утравын көньяктан төньякка таба урталай ярып үтәргә тиешле туры юл Актауга җитеп беркадәр җир киткәч тә, төгәлләнмичә тукталып калды. Моннан тугыз ел элек тә, нәкъ бүгенге сыман ул көнне турадан көтмәгәндә чапкын килеп төште һәм «Мака сар Карман күчте»дигән күңелсез хәбәр әйтте. Таҗит төзүчегә бу хәбәр аяз көнне яшен яшьнәгән кебек тәэсир итте. Мака сар Карман әле яшь иде... Карман саканың бер агасы Типкә бине мака сар Карун сөргенгә сөрде. Яшь, чибәр хатыны Фалияне үзенә алып калды. Карунның икенче энесе ниндидер яуда үлеп калды. Шул сәбәпле япь-яшь Карман мака сар булып калды. Менә ул да күчте... Әллә...

Ил башлыгы мака сар күчкән көннән башлап бөтен илдә өч көнгә эш туктатыла, кырык көнгә һәртөрле уен-көлке, күңел ачу тыела иде. Монда да кинәт бөтен нәрсә тынып калды. Урман кисүчеләр урманнан чыктылар, таш кисүчеләр тау арасыннан чыктылар. Таш түшәүчеләр, түшәлмәгән ташларын, коралларын калдырып шулай ук читкәрәк киттеләр, ачыктан-ачык сөенә башладылар. Иртә таңнан кичкә кадәр баш күтәрми бил бөккән коллар, каралар гына түгел, кораллы сакчылар, күзәтчеләр дә күңелсез хәбәрдән соң ничектер туарылып, бушанып калгандай булдылар. Күпчелек шулай исенә-акылына килә алмаганда, кайбер усалраклар, яшьрәкләр тизрәк моннан ычкыну ягын карадылар. Соңыннан, тикшереп карагач, утызлап кешенең качып киткәнлеге билгеле булды.

Юл төзүдәге каралар да, сакчылар да тулысынча Таҗит агага буйсыналар. Ул үзе турыдан-туры мака сар Карманга гына буйсына иде. Менә хәзер ул юк. Ул инде ерак юлга чыккан. Аны куып җитү, аның белән сөйләшүаңлашу мөмкин түгел. Моңарчы ул үзенең сөекле яранын теләсә кемнән, теләсә нинди көтелмәгән хәлдән яклап-саклап килде. Кояш артык кыздырганда ул аның өчен җиләс күләгә, өстән яңгыр койганда ышанычлы түбә булды. Ачыкканда ул аның тамагын туйдырды, сусаганда су бирде. Инде аны хәзер кем яклар да, кем саклар?

Чапкын авызыннан күңелсез хәбәр ишеткәч тә, Таҗит ата иң элек үзе турында, үзенең турадагы ике катлы таш йорты, анда калган җәмәгате, кызлары, балалары, коллары турында уйлады. Аннан да бигрәк ул шул турыда борчылды: Карман сар урынына кемне сайлап куярлар мака сар итеп? Ул, билгеле, бу турыда да белмәде түгел, белде. Моны бөтен ил халкы белеп торды. Аклан

иленең башы булып Карманнан кечерәк, ләкин калган өч туган арасында өлкәнрәк булган Аланча сака гына кала ала иде. Ләкин бозыклыгы, җиңел акыллылыгы белән бөтен илгә, бөтен тирә-якка даны таралган Аланчаны һич тә Акланның мака сары итеп күрәсе килми иде.

Мака сар Карман илнең көньягыннан төньягына туры таш юлны тикмәгә генә салдырмады, билгеле. Аклан утравының иң төньяк төбәгендә, кәмәләр туктап тору өчен җайлы, яр буе булган Саба авылы янында ул моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән эшләр башлап җибәрергә исәпләде. Саба авылы янында ул кимендә икеөч мең кешелек яңа тура корырга, шунда ук яр буендагы кыяларны кисеп, сугыш кәмәләре өчен иркен куыш ясатырга булды. Алай-болай диңгез юлбасарлары яисә анда ерактагы күршеләр көтмәгәндә килеп басмасыннар өчен, төньяктагы яр буйларында җитәрлек кадәр көч тотарга кирәк иде. Моңарчы бер-ике мәртәбә төньяктан акайлар шул ук Саба янында төшеп яр буен талап киткәннәр иде инде. Мака сар Карманның юл салдыруын күпчелек игенчеләр, терлекчеләр якламаса да, аның кирәклеген аксөякләр аңламый булдыра алмадылар. Илне саклау өчен сугыш кәмәләре дә, тауга уеп ясалган тау куышлары да, яңа тура да, туры юл да — барысы да, әлбәттә, кирәк иде. Ләкин икенче төрле фикер йөртүчеләр дә булды. Шулай фикер йөртүчеләр арасында Акланның дин башлыгы пир ата Мәнзүм дә бар иде. Ул, билгеле, мака сар теләгенә дә каршы килә алмады, ул шулай ук Аклан илендә туры юллар салуга да каршы түгел иде. Ул бары туры юлның Актау капкасына тия язып, якыннан гына узып китүенә каршы иде. Тигез юл салынса, бөтен илдән монда ярлы-ябагай агылыр. Актау тормышында кирәкмәгән борчулар башланыр дип курыкты ул. Аның исә соңгы көннәрен тыныч кына зекер әйтеп, келәү әйтеп, һәр туар көнне алкышлап тыныч кына уздырасы килә иде. Таҗит төзүче Мәнзүм атаның борчуларын, куркуларын бик яхшы аңлады. Шуңа күрә ул аның үзе белән сөйләшеп карамакчы, юлның ил өчен бик кирәк булуын аңлатмакчы булды. Ләкин ул чакта аның белән бернинди яхшылап сөйләшү була алмады. Пир ата Мәнзүм аны, мака сарның ышанычлы яранын, куштанын, колын тыңларга да теләмәде. Шулай да әйтте:

— Ил кайгысын мин генә кайгыртам икән дип ялгыша күрмә, ил кайгысын без дә кайгыртабыз. Төнне Кара кыяда янган утны күрәсеңме? Күрсәң, шул: ул ут безнең Акланның сере. Аның серен белергә, аны сүндерергә,

кыяны җимерергә тырышып караучылар әз булмаган. Туры юлыгызны диңгез ярына илтеп чыгарсагыз, диңгез ягыннан да тагын ут белән кызыксынучылар килеп чыкмас дип кем әйтә ала?

— Анда, диңгез буенда, көчле сак булачак, Изге ата, — диде ул чакта төзүче Таҗит пир ата Мәнзүмгә. — Угрыдан куркып юллар салдырмыйча да булмый, Изге ата, — дип тә өстәде ул.

Ул чакта алар арасындагы сөйләшү шуның белән тукталып калды. Икенче мәртәбә Таҗит төзүче пир ата Мәнзүм белән башкачарак шартларда сөйләште. Чапкын турадан күңелсез хәбәр алып килгәч, ул киңәшергә дип туры Мәнзүм ата янына юнәлде. Бу дөньяда хәзер аның үзеннән һәм Мәнзүм атадан башка киңәшерлек беркеме юк иде. Кеше үлеменә сөенергә ярамаганлыгын белсә дә, яңа хәбәрне әйткәч, Мәнзүм атаның йөзендә сөенеч сыман бернәрсә чагылып калды. Ул хәтта ишетелерлек итеп җиңел сулап куйды һәм, тиз арада кыяфәтен үзгәртеп, кайгырган булып:

— Барыбыз да шунда барачакбыз, — диде. — Мака сар Карманның илгә-көнгә бик күп изгелеге тиде... Изге җаны авырлыксыз күккә ашсын, Атабыз катына барып ирешсен, түмән еллар, йолдыз булып, адашканнарга юл күрсәтеп балкып торсын, — диде.

Капка төбенә килеп җиткән юл эшенең тукталып калуына ул чын күңелдән сөенеч белдерде. Соңыннан, башын иебрәк нидер әйтергә әзерләнеп торган Таҗиткә күтәрелеп карады да ничектер көтмәгәндә әйтеп куйды:

— Синең эшләр шәптән түгел, улым, — диде.

— Ник? — диде Таҗит төзүче, бик авырлык белән.

— Ник икәнен син үзең дә беләсең, — диде пир ата Мәнзүм. —Белмәгән булсаң, минем янга килеп тормас идең.

— Мин, бәлки, саубуллашырга килгәнмендер, — диде Таҗит, туры сүздән читләшергә тырышып.

— Юк, сиңа саубуллашырга ярамый, сиңа монда келәүлектә калырга кирәк, — диде пир ата. — Анда кайтсаң, сине...

— Минем бер языгым да юк! — диде Таҗит, үз-үзен яклагандай итеп.

— Синең языклы булуың кирәкми дә, — диде пир ата. — Аланча сака мака сар булса, Карман сака яклы һәркемне йә илдән сөрәчәк, яисә базар уртасында башын чаптырачак. Син аны да беләсең.

— Беләм! Ләкин минем анда йортым, җәмәгатем, балаларым. Мин аларны күрергә тиеш.

Пир ата Мәнзүм башка сүз озайтып тормады. Ул аны капкага кадәр озата килде.

— Алай-болай... Кайчан килсәң дә, синең өчен капка ачык булыр, — диде ул.

Туктатылган эшне, туктаган, туарылган караларны һәм сакчыларны үзенең булышчысы карамагына калдырып, Таҗит төзүче турага кайтып китте. Өендә аны дүрт күз белән көтеп торганнар. Бик нык кайгырып, борчылып көтеп торганнар. Ул кайтып кергәч, барысының да йөзе ачылып китте. Җәмәгате елый-елый муенына килеп сарылды, чыр-чу килеп, эти-эти дип балалары урап алды, күрше бүлмәдән кызлар, асраулар, каралар йөгерешеп чыкты. «Исән икән әле! Исән икән! — диде җәмәгате, бер үк сүзне кабатлап. — Хәзер инде үлсәк тә, калсак та бергә», — диде. Әйе, ул кайткан көнне өйдә чын-чынлап бәйрәм булды — тәмлерәк, ятрак ашлар пеште, кешеләрнең сөйләшүендә, үзара мөнәсәбәтендә көн дә булмый торган бер күтәренкелек хөкем сөрде. Шул ук вакытта алар кайгы көненең бетеп җитмәвен дә тоймый, аңламый булдыра алмадылар — ул көннәрдә урамнарда кычкырып көлгән, сөйләшкән тавышлар ишетелмәде. Турада, бистәдә бары ниндидер тотып, аерып булмый торган гүелдек кенә тирбәнеп торды да, диңгез ягында су кошларының чыелдык, кыска тавышлары гына ишетелеп-ишетелеп китте.

Ул көннәр Таҗит атаның хәтерендә шулайрак уелып калган. Аннан соң шунысы да истә: үз йортында, үзенең икенче катында, аулак бүлмәсендә берне куну белән, икенче көнне яңа хәбәр килеп җитте: мака сар итеп Аланча саканы билгеләгәннәр!

— Уяндыгызмы? Торыгыз, тор! —дип кычкырды әниләре, инәлеп, яшь аралаш, бар көченә сөякчел куллары белән бүлмә ишеген шакылдатып.

Беренче булып урыныннан Нәфисә сикереп торды, аны-моны аңлашмыйча, өстенә дә киенмичә, ишеккә ташланды.

— Ни булган, әни, ни булган, ут чыкканмы әллә?! — диде йокылы тавыш белән, куркып та, ачуланып та.

— Оятсызлар! Шул гомер йоклап яталармы?! — диде карт ана, күрәсең, килененең шәрәлеген өнәмичә. Ачудан ул хәтта төкереп куйды.

Таҗит ул көнне юри эндәшми ятты. Эндәшмәсә дә, күз кырые белән генә ярым ачык ишек төбендәге тамашаны күзәтмичә булдыра алмады. Нәфисәнең озын кара чәчләре полтыранган, бер өлеше алдына, бер өлеше артына салынып төшкән, үзе чытырдатып бер кулы белән

ишекнең җиз тоткасына тотынган, икенче кулы белән ишек яңагына тотынган. Арттан ул шундый сылу, күркәм. Бар җире төгәл, йомры. Нишләп алар затын алла шулай йомры да, тулы да, нәфис тә итеп яраткандыр, нишләп ир кеше генә тупас та каты гынадыр. Яшьрәк чагында Таҗит гел шул турыда уйлана иде. Үзе төзегән, салган сарайларга, манараларга, койма-капкаларга да ул һәрвакыт хатын-кызга хас күркәмлек, төгәллек бирергә тырыша һәм шул чагында һәрвакыт үзенең җәмәгатен, кызын — яңа буй җиткереп килгән Лиясен күз алдына китерә торган иде. Әнисенең тупаслыгын, әрсезлеген исә ул беркайчан аңлый алмады. Менә шушылай таң тишегеннән улының, килененең ятак бүлмәсенә бәреп керүен гомумән күралмады. Ләкин ул көнне, ул иртәдә Таҗит бернигә кысылмыйча тавышсыз-тынсыз һаман ята бирде — шулкадәр сагынып яратышудан соң, дөньяда инде барлык ямьсез нәрсәләр беткәндер сыман тоела иде.

Ләкин алай ук булмаган икән шул. Җебегән, булдыксыз улының әле һаман тыныч ятуына үч иткән сыман, карт ана килененең яшь тәнен этеп-төртеп, чәрелдәп бүлмәгә үк басып керде һәм бар нәрсәнең ямен, тәмен җибәреп:

— Аланча мака сар булган! — дип кычкырып җибәрде.

Шуннан соң бөтен нәрсә баш-аяк килде. Бәхетле ирнең күз аллары томаланып калды, җылы, татлы ятагы-ние белән, җиз тоткалы ишекләре, шәрә Нәфисәсе һәм карга тавышыдай ямьсез, бозык тавышлы анасы белән мәтәлеп, буталып ул каядыр упкынга ыргытылгандай булды.

— Алар килеп алып киткәнче, төялергә, китәргә кирәк! — диде әнисе.

— Кая? Ник? — диде Таҗит, ниһаять, урыныннан торып.

— Кая булсын — ил читенә! — дип кычкырды карт ана. — Кая булса да барыбер түгелмени?! Кәмәче белән сөйләштем, ул риза, кирәк булса, ун кәмә дә бирә алам, диде.

— Чынлап сөйлисеңме син, әни? — диде Таҗит, нәрсә турында сүз барганын яңа төшенә башлап. — Көпә-көндезме, хәзер үкме? Кем чыгарсын безне турадан? Бүген, кайгы көнендәме?!

— Көн булмаса, төн бар! — диде әнисе.

— Уйлап карармын, — диде Таҗит, әнисенең тизрәк бүлмәдән чыгып китүен теләп.

Ул чыннан да уйлады, теләр-теләмәс кенә уйлады. Ул иртәдә аңа нишләптер бернинди кайгырыр нәрсә юк сыманрак тоелды. Йокыдан торгач, аның тизрәк балаларын, асрауларын, караларын күрәсе, өй араны чыгып карыйсы, кайбер нәрсәләрне карап беләсе килә иде. Шулай иренеп кенә таш сукмактан урам як капкага таба китеп барганда, тышта, урамда якыннан гына узып китеп баручы арба тавышы ишетелде. Пар ат җигелгән җиңел арба туп-туры аларның капкасы янында туктап калды һәм Таҗит төзүче эчке яктан капкага килеп җиткәндә, тышкы яктан да кемдер килеп җитте һәм түземсезләнеп, бар көченә шакылдатырга тотынды. Хуҗа кеше, аны-моны уйларга өлгермичә, ашыгып барып капканы ачты һәм каршысында сарай йомышчысы Бабулны күреп аптырап китте. Ул чакта да Бабул кыскарак буйлы һәм таза, карап торышка җитез, тынгысыз бер кеше иде. Өстенә ул сугышчы ирләрнеке кебек бизәкле, кыска һәм җиңсез күн күкрәкчә кигән, аягында кызыл күннән тегелгән җиңел башмак. Уң кулында кыска саплы җиз сөңге, билендә — хәнҗәр. Озын, кара чәчләре толымлап үрелгән, майланган — елкылдап тора.

Хәзер дә ул әнә чәчләрен матурлап үргән, майлаган. Ләкин чәчләре инде сирәкләнә төшкән, төсе дә карга канатыдай чем-кара түгел, арада чал кергән бөртекләр күренгәли. Шулай да төсе-кыяфәте әйтерсең тамчы да үзгәрмәгән — үз-үзеннән канәгать, үз-үзенә ышанган, үзен батыр да, кыю да итеп күрсәтергә тырыша. Хәер, җентекләбрәк карасаң, хәзер инде анда арыганлык, таушалганлык та күренә. Күз төпләре шешенке, бит тиресе сәлперәйгәнрәк. Күрәсең, күп эчә, рәтләп йокламый...

Әйе, теге көнне Бабул хәзергегә караганда да кыюрак, батыррак иде бугай. Шулай булмыйча! Яшь вакытта кем генә шулай булмады икән?! Масаюы да, тәкәбберлеге дә баштан ашкан иде бугай.

Ярым ачык капкада күзгә-күз очрашкач, Бабул, кычкырып:

— Бу йортта Таҗит төзүче торамы? — диде. Бабул аның Таҗит икәнлеген дә, бу йортта торганлыгын да бик яхшы белергә тиеш иде, чөнки алар бер-берсен ишетеп тә, күреп тә беләләр, еш кына очрашып бер-ике сүз сөйләшеп тә алалар иде.

— Мин ул... Таҗит... әллә танымадың? — диде Таҗит, аптырагандай итеп.

Бабул хуҗа кешене этеп-төртеп дигәндәй ачык капкадан эчкәрәк үтте һәм, һәрбер сүзен ап-ачык итеп:

— Сине мака сар Аланча үз катына чакыра. Әйдә, киттек! — диде.

— Хәзер үкме?! — диде Таҗит, каушап.

— Хәзер үк! — диде Бабул, кистереп.

— Ни... ыы... мин әле ашамаган-эчмәгән, юынмаган да, — диде Таҗит, карышкандай итеп, ни әйтергә дә белмичә.

— Ашарсың да, эчәрсең дә... баргач! — диде Бабул, кырт кисеп.

— Туктале, нишләп болай кисәк кенә? — диде Таҗит. — Мака сар катына болай бару килешми ич — киемнәремне алыштырыйм.

— Бар, тиз бул, — диде түземсез Бабул, ләкин Таҗит борылып китә башлаган иде, шундук аның артыннан иярде.

Таҗит өйгә кереп тиз генә киемнәрен алыштырды, үзен чорнап алган, мыс-мыс елаша, кайгырыша башлаган хатын-кызларга, балаларына юатып бер-ике сүз әйтеп-әйтеп алды. Шул чакны ул Лиясен күреп алды. Күңеленнән генә «Нинди чибәр булып үсеп килә! Яшь чактагы Нәфисә — суйган да каплаган» дип уйларга да өлгерде, яратып, кызының аркасыннан сөйде. Лиянең күзләрендә яшь бөртеге күренеп китте. Каяндыр биш яшьлек улы килеп чыкты. «Әти!»дип шундук аягына сарылды. Улын кулына күтәрергә туры килде. Ул чактагы улы нәкъ бүгенге Бәләкәч сыман иде. Улын капкага кадәр күтәреп барырга туры килде — муеныннан ул ике куллап шундый нык итеп тоткан иде, елатмыйча, күңелен кырмыйча аны һич аерырлык түгел иде. Капкадан чыкканда улын көчкә Нәфисәгә бирә алды. Шулай итеп аерылды ул... улыннан, Нәфисәдән, Лиядән — барлык якын, кадерле кешеләреннән, йортыннан-җиреннән. Шуннан соңмы? Шуннан соң тиз арада алтын манаралары, биек таш корылмалары белән ерактан ук күзнең явын алып, берәүләрдә сөенеч, берәүләрдә көенеч тойгысы өстәп торган Изге тауга, мака сарлар һәм аларның якыннары гына яши торган сарайларга алып бардылар. Кайгы көне әле яңа башланса да, кайгы көнендә нинди дә булса эш эшләү язык саналса да, тәхеткә утыруының беренче көнендә үк күптән килгән изге тәртипләрне бозып, мака сар Аланча аның белән эш турында, бары эш турында гына сөйләште.

Таш коймалар, сулы боҗралар белән әйләндереп алынган түгәрәк тураның уртасындагы изге турага алар булдыра алган кадәр турыдан бардылар, булдыра алган кадәр тизрәк бардылар. Кичләрен, көндезләрен җәяү-

ләләр, атлылар өзлексез йөреп торган таш урамнарда урам себерүче каралардан башка, җирән ишәккә атланып каяндыр кайтып килүче чурадан һәм биек таш капкалар, таш күперләр янындагы кораллы торгаклардан башка беркем очрамады. Таш урамнар, таш күперләр кызу чапкан ат-арбалар тавышыннан гүләп торды. Соңгы берничә аен башкаладан читтә урман-таулар арасында уздырганга, Таҗит туган йортын, җәмәгатен, балаларын гына түгел, туган турасын да сагынган иде. Биек таш күперләргә, куе яшел агачлар арасында күмелеп утырган матур таш йортлар, сарайларга, яр буйлары ташка төрелгән су өстенә — бөтен тирә-якка ул беренче мәртәбә күргән сыман, тансыклап карап барды. Шул ук вакытта аңа ул боларны соңгы кат күрә сыман да тоелды. Шуңа күрә ул аеруча матур тоелган күренешләргә, таш, агач һәм җиз-бакыр катнашкан корылмаларга аеруча җентекләп һәм сокланып карады. Аның, билгеле, «соңгы кат» дигән фикергә ышанасы килмәде. Ләкин тук, симез атларның туктаусыз чабуына, тәгәрмәчләрнең туктаусыз дөбердәвенә һәм күз алдындагы күренешләрнең туктаусыз үзгәреп торуына ышанмаска мөмкин булмаган кебек, бүген менә хәзер, тиздән, озакламый язмышта кинәт ниндидер үзгәреш булу мөмкинлегенә дә ышанмыйча булмый иде.

Юл буена аны билгесезлек һәм шомлану тойгысы газаплады. Ник алып баралар аны Изге тауга? Нишләп шулай ашыгыч рәвештә? Мәрхүм Карманны җирләүдә, төрбәгә урнаштыруда берәр төрле киңәш-табыш кирәк булганмы, әллә бөтенләй башка нәрсәме? Карман җирләнәчәк төрбә күптән әзер — эчке-тышкы бизәкләре ясалган, алтын-көмеш саркатибы шулай ук күптән әзер. Аны инде төзәтеп тә, яхшыртып та, баетып та булмый. Әллә соң яңа мака сар мәрхүмнең гәүдәсен үзе төзеткән төрбәгә куймыйча тиз арада яңа төрбә, яңа саркатип ясатырга ниятләнә микән? Булмас димә. Әллә нинди көтелмәгән нәрсәләр уйлап табарга мөмкин ул.

Изге тауга алар шау-шу куптармыйча, тавыш чыгармыйча, атларын атлатып кына менделәр. Аларга күпсанлы алтын-көмеш бизәкле биек, авыр капкалар җиңел генә ике якка ачыла торды, ябыла торды. Шомартылган таш аралаш шакмаклап җиз-бакыр җәелгән юлларның ике ягына тезелгән эре сөякле, таза, тук сакчылар тавыш-тынсыз озатып калдылар. Болдырда, ишек катында, биек баскычлар янында аларны шулай ук тавыш-тынсыз һәм бераз гына йокылары ачылып җитмәгән тук, чибәр ирләр, хатын-кызлар каршы алып, оза-

тып калдылар. Анда ишек түбе бүлмәләрендә, аралыкларда, баскыч төпләрендә — һәркайда муллык, байлык һәм изгелек бөркелеп тора. Анда ниндидер ят җиңел исләр килә, идәндә, түшәмдә, эстинәдә бизәкле, затлы ташлар, алтын-көмешләр ялт-йолт килә. Анда кызлар, асраулар барысы да яшь, барысы да күзнең явын алырлык чибәр. Алар ягымлы һәм алар матур итеп көлә, елмая беләләр. Хәтта бөтен илдә кайгы көне булганда да көлә-елмая беләләр. Бәлки, алар шуңа да ул көнне ныграк көлгән-елмайганнардыр әле.

Аланча саканың эчәргә, күңел ачарга, яшьләр белән төрле тамашалар корырга яратуын белмәгән кеше юк. Төне буе шау-шу килеп, утлар яндырып, җырлап-көлеп Изге тау тирәли кәмәләрдә йөрү дисеңме, гимнас өйләрендә таза яшьләрнең үзара көрәшләрен, ат чабышлары, йодрык сугышлары оештыру дисеңме — аннан берни калмый, бернидән тайчынмый. Үзе йөри, үзе оештыра һәм үзе катнаша. Яшьрәк чагында ул хәтта җырлаганбиегән һәм ким кызлар кебек әргәндә уйнаган дип сөйлиләр. Аннан соң аның турында шунысын да сөйлиләр: төне буе күңел ача, төшкә кадәр йоклый, диләр.

Сакадан кинәт мака сарга — ил башына әверелгәч кенә, Аланча көндәлек гадәтләрен тиз генә үзгәртә алмаган, ахрысы. Ак, кызыл, кара ташларны матур итеп аралаштырып төзелгән, тышкы ягыннан да, эчке ягыннан да алтын-көмеш һәм фил сөякләре белән араландырып бизәлгән кечерәк бер бүлмәгә җиткәч, пышылдап кына сөйләшә торган асраулар аңа бераз көтеп торырга куштылар. Ул күрсәтелгән урында туктап калды, көтә башлады. Аңа шактый көтәргә туры килде. Карлыкканрак тавышы белән, пышылдабрак сөйләшә торган, күз төпләре салыныбрак торган кара узып барышлый гына сөйләнгән кебек «торды!» диде дә китеп тә барды. Анысы күздән югалырга өлгермәде, икенчесе, килеп, «коена!»диде. Икенче хезмәтче китеп бераз торгач, якындагы биек терәкләр арасындагы аралыктан өченче хезмәтче килеп чыкты. Монысы яшьрәк, җитезрәк иде, ләкин монысының да йөзе йокылы-уяулырак иде.

— Мака сар сине үз янына чакыра, — диде яшьрәк, җитезрәк хезмәтче һәм үз артыннан барырга ишарәләп баш какты.

Таҗит төзүче хезмәтче артыннан иярде. Мака сарның коену бүлмәсенең ишеге ачык килеш калган иде. Коену бүлмәсеннән үтә нәфис һәм хуш исле май исе килеп бәрелде. Мондый ят исле майны да, үсемлекләрне дә бик ерактан, җир читеннән, көньяк-көнчыгыш якта-

гы диңгез буендагы Дарцин иленнән китертәләр. Мондый хуш исле майларда бары тик мака сарлар да аның хатыннары гына коена ала. Коену бүлмәсеннән шакмаклы таш идәнгә майлы аяк эзе чыккан һәм тоташ ак, кара ташлардан аралаштырып салынган баскыч буйлап, югарыга, икенче катка менеп киткән иде. Ярым шәрә бер-ике ир, кулларына чүпрәк тотып, майлы тапларны сөртеп азапланалар иде. Яшь, җитез хезмәтче белән Таҗит идән сөртүче ирләргә дә, майлы аяк эзләренә дә якын килмәскә тырышып читтәнрәк бардылар. Киң баскычтан югары менгәч, Таҗитнең борынына җиңел, тәмле аш исләре килеп бәрелде. Хезмәтче туры аны мака сарның аш бүлмәсенә алып керде. Бай җиһазланган биек, иркен бүлмәдә ашаучылар күп түгел иде. Ләкин ашаучыларның барысы да ирләр һәм барысы да Аланчаның иң якын кешеләре иде. Ике күнлек мака сар төзүче Таҗитне ерактан ук күреп алды, каршылау өчен урыннан торды һәм, ягымлы итеп:

— Килдеңме? Әйдә, утыр, безнең белән тамак ялгап алырсың, — диде.

Мондый ягымлылык күреп Таҗитнең күңелендәге авыр таш кинәт юкка чыкты. Аңа җиңел һәм иркен булып китте. Юкка бетеренгәнмен. Бу мине үзенә якынайтырга исәпли, ахрысы, дип уйлап алды ул яңа ил башы турында. Тартынмыйча, каушамыйча күрсәтелгән урынга утырды һәм, артык комсызланмыйча, әдәпсезләнмичә, үз өендәге кебек, башкалар кебек, алдындагы азыкларны ашарга тотынды. Ашаганда беркем берни сөйләшмәде, бары мака сар, табын хуҗасы буларак, күршеләренә яисә аш ташучыларга берәр сүз әйткәләп, тамагын кыргалап алды. Таҗит яхшы белгән Аланча сака бераз гына симерә башлаган, киң күкрәкле һәм көр тавышлы алып ир иде. Кычкырып сөйләшә, кычкырып көлә, кемнең кем булуына карамастан, теләсә кемнең сүзен бүлдереп, бары үз сүзен генә өстен чыгарырга тырыша. Еш кына ул юмарт һәм киң күңелле була ала, ләкин бер киреләнсә, аны инде берни белән урыныннан кузгатып булмый.

Ул көнне табын янында башка вакыттагы кебек алай кычкырып та көлмәде, кем белән дә булса сүз дә көрәштермәде. Таҗиткә бу баштарак гаҗәп тоелды, ләкин әле һаман кайгы көне икәнлеген исенә төшергәч, монда бер дә гаҗәпләнерлек нәрсә юклыгы беленде.

Гаҗәп нәрсә соңыннан, ашап туйгач булды. Ашап туйгач, табын янындагы ирләр таралышкач, Аланча аны сарайның өченче катына алып менеп китте. Монда як-

тырак та, иркенрәк тә иде. Ачык тәрәзәдән талгын гына булып саф һава агылып тора, еракта башкала йортлары, бакчалар, түгәрәк коймалар һәм арыклар шәйләнә, колак төбендә өзлексез гүелдек булып, беркайчан тына белми торган тура шау-шуы ишетелеп тора.

— Беләсеңме, ник чакырдым мин сине? — диде мака сар Аланча, беренче сүзе итеп.

Ул моны йомшак, ягымлы итеп әйтәм дип уйлады, ахрысы, ләкин аның тавышы тупасрак һәм күтәренкерәк булып чыкты.

— Юк, әлегә белмим, мака сар, — диде Таҗит, мөмкин кадәр буйсынучан итеп.

— Мака сар! Миңа әле беркемнең дә «мака сар»дип олылап эндәшкәне юк, — диде кинәт Аланча, куанычтан елмайгандай итеп. — Рәхмәт. Изге атам-анам белән ант итеп әйтәм, килешә алсак, гел түремдә утырырсың, уң кулым булырсың, төзүче Таҗит.

Таҗит инде җиңелчә кармакка каба торган кеше түгел иде, шулай да, кармакка капканда да, нинди кармакка кабуыңны белеп, алдыңны-артыңны уйлап эшләргә кирәк иде. Сүзнең кай таба баруын чамалый алмыйча озак кына эндәшми утырды.

— Ил башлыгы мака сар белән килешмәү язык булыр иде, — диде ул, ашыкмыйча гына, — ләкин иң элек нәрсә турында килешү кирәклеген белү кирәкми микән?

— Шуның өчен чакырдым да мин сине, — диде Аланча сар.

Никадәр туры сүзле тупас кеше булса да, шулай да ул да чак-чак кына каушый һәм икеләнә иде бугай. Ул да тиешле сүз әйтә алмыйча, беравык тынып, як-ягына карангалап утырды.

— Сине, Таҗит, Акланда белмәгән кеше юк. Агам мәрхүм Карманның барлык төзү-кору эшләрен син башкардың. Аның төрбәсен, сарайларын син салдырдың, юллар төзеттең. Бар байлыгын агам мәрхүм үзенең шул төрбәсенә, сарайларына, күперләренә тотып бетерде. Син аны беләсең...

— Беләм, — диде Таҗит, теләр-теләмәс кенә.

— Миңа ул коры таяктан башка берни калдырмады. Амбарлар буш, сандыклар буш, чүлмәкләр буш. Җир асты базларында, ашлык чокырларында тычканнар гына чабышып йөри. Кораллы ирләргә, сакчыларга, торгакларга, алыпларга түләргә түгел, аларның тамагын туйдырырга да берни юк. Үзең беләсең, мәрхүм агамның күп эшен илнең аксөякләре дә, каралар да... беркем ярат-

мады. Ил-көннең күңелен күрү өчен, Акландагы һәркем үзен бәхетле итеп тойсын, үзенчә яшәсен өчен, минемчә, салымнарны, түләүләрне бетерергә кирәк булачак. Ләкин, салымнарны, түләүләрне бетерсәк, илне саклаучы кораллы ирләргә, чиргүгә, сакчыларга, торгакларга... акчаны каян алырга?

Аңлашылды. Барысы да аңлашылды. Акча мәрхүм Карманга да кирәк иде, яңа сар Аланчага да кирәк икән. Аланча сар сүзләрен уйлап, сайлап сөйләде, бераз гына үртәлеп, бераз гына мескенләнеп сөйләде. Акча кирәк, акча! Ләкин акча, байлык, алтын-көмеш һәм көч-куәт Таҗиттә түгел, киресенчә, мака сар Аланчаның үзендә бит! Кичәдән башлап барысы да анда, аның кулында. Нишләп төзүче Таҗиттән акча өмет итә әле бу?

Аланча сака булса, яки анда сугышчымы, кәмәчеме булса, Таҗит, билгеле, аңа шулайрак дип җавап кайтарган булыр иде, ләкин бу юлы Таҗит тыелып калды һәм беркадәр вакыттан соң:

— Мин әлегә берни аңламадым, мака сар, — диде.

Мака сар Аланча аскы азау тешенә кысылган ит кисәген тартып чыгарды да, тел очына куеп читкә төкерде, зур, авыр гәүдәсе белән җайлабрак Таҗит ягына якынрак килде һәм пышылдыйм дип уйлап:

— Сине... теге... Карунның яшерелгән хәзинәсен белә, диләр. Миңа шул байлык кирәк! — дип кычкырды.

Мондый сүз ишетеп, Таҗит катты да калды. Монда килгәндә ул үзе өчен, йорты-иле өчен әллә нинди үлем төрләре уйлап табып газапланган иде, ләкин һич тә мондый төр үлем күңеленә килмәгән иде. Карун байлыгы. Кем әйткән аны? Үз гомерендә беркемгә аның Карун байлыгы турында сүз әйткәне юк. Моңарчы аннан андый байлык турында сорашучы да булмады. Байлыкны аны башка юл белән таптылар, эшләп, сату-алу итеп, көч түгеп.

— Мин... андый байлыкның кайдалыгын белмим, мака сар, — диде ул, Аланчаның симерә башлаган майлы, тупас һәм әшәке йөзенә туры карап. — Илдә Карун байлыгы турында төрле имеш-мимеш сөйләнә — анысын ишеткәнем бар. Бик күпләр аны эзләп тә караганнар, анысын да ишеткәнем бар.

— Изгеләр тавында, турада син күп эшләр эшләттең, базлар, җир асты юллары казыттың... — диде Аланча, түземсезләнеп.

— Барысы да булды, мака сар — базлар да, җир асты юллары да казыттым, — диде Таҗит. — Шул чагында минем Карун байлыгына тап булуымны күргән кеше булса, хәзер ул менә килсен дә әйтсен аның кайдалы-

гын! Мин, бәлки, күрми киткәнмендер. Икәүләшеп, өчәүләшеп яңадан эзләп карарбыз.

Шул чакны Аланчаның йөзе караңгыланып калды. Атаклы төзүченең түгел, үзенең кармакка кабуын күреп, ул озак кына иренен чәйнәп утырды.

— Алайса белмисең? — диде ул шуннан соң.

Бу юлы аның тавышы коры һәм ямьсез ишетелде.

— Белмим, мака сар, — диде Таҗит. — Белсәм, шундук йөгереп килеп әйтермен.

— Бар, кайтып тор, кирәк булсаң, чакыртырмын, — диде мака сар.

Ул көнне алар арасында шундыйрак сөйләшү булды. Өенә кадәр аны ат-арбада Бабул кайтарып куйды. Кайтып җитәрәк, аның күңеленә бер уй килде: мака сар белән икәүдән-икәү генә сөйләшүдән файдаланып, аңа бер сүз әйтергә кирәк булган. «Чын хәзинә Карун байлыгы түгел, чын хәзинә менә шул!» дип әйтәсе калган. Менә шушы сөйләшүдән соң ул гел шул турыда уйлады. Ни өчен Изге таудагы сарлар өчен чын хәзинәнең ниндидер имеш-мимеш Карун байлыгы түгел, аллалар сүзе икәнлеген әйтә алмавына ул гомере буе үкенү кичерде.

Ике көннән күмү булды. Якын илләрдән, утраулардан бик күп кунаклар — карлар, кәмиләр, мислар, шырданнар, туршалар, киликалар, сабалылар һәм башкалар килде. Арыклар, яр буйлары, диңгез култыклары ул көннәрдә кәмәләр, каеклар, бораннар белән, кешеләр белән тулды. Изгеләр тавының көнбатыш ярындагы Авалаш утравында иртәннән башлап кичкә кадәр мәрхүм мака сарга багышланган уеннар, ярышлар һәм кан коюлар булды. Яшьләр көч сынаштылар — йөгерделәр, ук аттылар, атта чабыштылар, ярсу үгез белән сөзештеләр — көрәштеләр. Иң ахырда коллар сугышты. Ике төркемгә бүленгән йөзәр-йөзәр кеше, анадан тума шәрә килеш, кыяктай үткер җиз кылычлар белән, ярсып-ярсып берберсен турakladылар. Күмү уеннарының иң куркынычы, иң тәэсирлесе шушы иде. Меңләгән, ун меңләгән таза, исән ирләр, чибәр кызлар, хатыннарның күз алдында очлы хәнҗәр, котырынган ерткыч сыман, тере тәнне ботарлады. Меңләгән, ун меңләгән күзләр алдында куллар, башлар киселеп төште, күкрәкләр, корсаклар тишелеп, эчәгеләр акты. Кайгы дип, дәһшәттән шашынган тере кеше белән тулы болын уртасында, түгәрәктә, елга булып кызыл кан акты. Төрле тавышлар белән кычкырган, шыңшыган, ыңгырашкан, гаргылдаган авазлар яңгырап торды. Шул авазлар арасында,

шакы-шокы килеп, чыкы-чыкы килеп, җиз хәнҗәрләр чәкәшкәне ишетелеп-ишетелеп китте. Коллар башта күмәкләшеп, бер зур төркем булып сугыштылар, соңыннан олы төркем кечерәк төркемнәргә бүленде. Бераздан кечерәк төркемнәр дә юкка чыга башлады һәм иң ахырда мәетләр арасында чабышып-куышып йөргән өч-дүрт кеше генә калды. Аларның кайберләре, яклау эзләп, якындагы лелегләр — таза, яшь, ирекле кешеләр ягына омтылды, кайберләре мәетләр арасында качып калмакчы булды. Болынны әйләндереп алган кораллы сакчылар куалап аларны кире уртага керттеләр, кемнәрдер ерактан таш ыргытты. Бернинди котылу чарасы юклыгын күреп, коллар янә уртага ташландылар, бер-берсе артыннан куыша башладылар. Ләкин шул чакны сакчылар боҗрасы кысыла төште, куышучы коллар беравык тын алып торгандай иттеләр дә бушрак, тигезрәк урынга чыгып янә бер-берсенә якын килделәр. Уртада ике, аннан соң бер генә кеше калганчы шактый вакыт узды. Ун меңләгән кеше әле давыл кебек, диңгез кебек гүләп, шаулап алды, әле шул ук диңгез кебек кинәт тынып-тынып калды. Аксыл чәчле җитез акай колы иң ахырда үзенең иң соңгы дошманын кадап үтерде дә, җиңүче буларак, коралын югары күтәрде һәм шашкан кебек, мәетләр өстеннән сикерә-сикерә, түгәрәк әйләнеп йөгерә башлады. Җыелган халык, күк күкрәтеп, аңа алкышлар яудырды. Ләкин шулай да акай колы түгәрәкне әйләнеп чыга алмады. Ул инде берничә җирдән яраланган иде, аның кулы, боты, күкрәге, бөтен җире кызыл канга буялып, тапланып беткән иде. Соңгы дошманын үтергән җиргә килеп җитәрәк, ул, нәрсәгәдер абынып, йөзтүбән капланды һәм шуннан соң инде кузгала алмады. Мәетләрне җыеп якындагы таш күпердән ташлы ярларына бәрелеп, ашкынып аккан елгага ташладылар. Тиз арада уртага таудай итеп коры-сары утын-агач өелде, өем өстенә мәрхүм мака сарның кабыгы куелды. Утынга утны кичке якта төрттеләр. Таудай коры-сары утын агач янып беткәнче Авалаштан халык таралмады. Мәрхүм мака сарның көлен, янган сөякләрен җыеп алтын савытка салдылар да әзер төрбәсенә алып киттеләр.

Таҗит турыдан-туры күмүдә катнашмады. Ләкин ул сарайга якынрак кешеләрдән булганга, калкурак урында, аксөякләр яныдарак булды һәм уртада, түгәрәктә булган бар нәрсәне үз күзе белән карап-күреп торды. Моңарчы әле аның мондый тамашаны күргәне юк иде. Ул көнне, ул төнне бик күпләр кайгыдан маңгайларын, битләрен, колакларын җәрәхәтләп кан чыгардылар, баш-

каларга ияреп кычкырып-кычкырып еладылар. Кайбер чибәр кызлар, тәэсиргә бирелеп, чәчләрен кистеләр, икенче берәүләр исә битләренә корым үкәделәр.

Кайгы кырык көнгә сузылды. Ул көннәрдә урамнарда, ишегалларында, бакчаларда, койма башларында әледән-әле үкереп-үкереп елаган тавышлар ишетелде, көпә-көндез урам уртасыннан чәче-башы полтыраган, тәне җәрәхәтле яисә бите карага буялган шәрә ирләрнең, хатыннарның йөгереп узып киткәннәре күренеп калды. Кайбер өйләргә, капка баганаларына ак киндерләр чыгарып элделәр. Үзе исән чагында усал булып тоелган мака сар өчен бу кадәр кайгы белдерү бик үк аңлашылмый сыман иде. Ләкин Таҗит тә, башкалар да моны бик яхшы аңладылар — бетмәс-төкәнмәс бу елау, сыкрау, үкерүләр, ямьсез итеп кычкырулар, үз-үзеңне камчылау яисә үз-үзеңне җәрәхәтләп, ямьсезләп йөрүләр, үлгән мака сар өчен кайгырудан бигрәк, исән, тере мака сарга каршы юнәлдерелгән иде, әлбәттә. Моның шулай икәнлеген беркем дә яшереп азапланырга тырышмый да иде, ахрысы. Шул ук урамнарда, базарларда чит ил кәмәләре, диңгезчеләре күп җыела торган яр буйларында, тамгалыкларда — һәркайда мака сар Аланчаны тозлап-борычлап сүккән сүзләр, аңа карата чыгарылган табышмаклар ишетелде. Кайгы көннәрендә авыз күтәреп җырлау, такмак әйтү тыелган булса да, ул көннәрдә беркем беркемне тыймады. Анда-монда ялт-йолт каранып, аңдышып, колак салып шымчылар йөрсә дә, әүвәлгечә базарларда, урамнарда, яр буйларында, капкаларда төнге торгаклар, сакчылар, каравыллар торса да, беркемгә бер кыек сүз әйтмәделәр, беркемне тотып кулга алмадылар. Ул көннәрдә Изгеләр тавы ягыннан сөрәнчеләр дә килмәде, йомышчылар да йөрмәде. Мака сар Карман үлү белән Изгеләр тавында, турада, бөтен илдә әйтерсең тормыш туктап калды.

Мака сар Карманны җирләп җиде көн үткәч, сигезенче көнне Таҗит төзүчене алырга дип турадан тагын сар йомышчысы Бабул килде. Алар мака сар Аланча сараена барып җиткәндә, төш вакыты якынлашып килә иде. Мака сар Аланча исә әлерәк кенә йокыдан торган, кайнар суда коенган, тәненә хуш исле майлар үкәгән, чәчләрен тараткан, үрдергән. Сабый балалардай мәмрәп, кайгысыз һәм канәгать бер кыяфәттә ашарга китерүләрен көтеп утыра иде. Таҗит төзүчене туп-туры сарның табыны янына алып керделәр, табын янына ашаргаэчәргә утырттылар. Шунда ук ике арада ачыктан-ачык сөйләшү булды. Мака сар Аланча Таҗит төзүче белән үз итеп, якын итеп сөйләште.

Сөйләшә торгач шул нәрсә ачыкланды: мака сар Аланча бүгеннән үк сөекле хатыны Нурлы бикәнең алтын сынын ясатмакчы икән, Нурлы бикәнең алтын сыны алтын койма эчендәге барлык сыннардан биегрәк тә, күркәмрәк тә булырга тиеш икән. Аннан соң Нурлы бикәнең алтын сыны тураның кайсы төшеннән карасаң да ерактан ук балкып, нурлар сибеп торырга тиеш икән.

Яңа мака сар йомшак күңелле, сүз тыңлаучан һәм сабыйларча теләсә нәрсәгә, теләсә кемгә ышанучан беркатлырак кеше иде. Таҗит төзүче аның холкын шактый яхшы белә, ләкин ул әле аның мака сар булгач башка кешегә әйләнү ихтималын гына чамалап җиткерми иде. Тиз ышанучан, тиз ризалашучан булганга күрә дә тәхеткә утыруының беренче адымыннан ук менә шундый нәрсәгә риза булгандыр да инде ул. Нурлы бикә гел чибәр күренергә тырышучы, холыксыз, урта яшьләрдәге хатын иде. Алтын сын, имеш! Аңа таш сын да күбрәк булмас микән?

Таҗит төзүче үзалдына шулайрак дип уйлады, ләкин бу турыда кычкырып әйтүдән тыелып калды.

— Алтын сыннарны элекке мака сарлар иң элек үзләренекен ясатканнар, — диде ул шулай ук, бераздан сүзгә башлап.

— Мин Нурлы бикәнекен ясатырга булдым, — диде мака сар.

— Мин әле аңлап җитмәдем: ни өчен мин? — диде Таҗит төзүче, сорауны турыдан-туры куеп. — Бездә атаклы сынчылар, коючылар да бар бит.

— Син алардан да атаклырак, Таҗит, — диде Аланча, мактау һәм... боеру белән.

Таҗит төзүче тынып калды. Ләкин ул барыбер «риза» сүзен әйтергә ашыкмады. Аның әле ачыклыйсы нәрсәләре бар иде.

— Болай булгач юлны нишләтербез икән соң? — диде ул.

— Мин сиңа ышанам, Таҗит, — диде Аланча, ягымлы елмаеп, ап-ак йомшак чүпрәк белән авыз читен сөрткәләп. — Син юлны да, сынны да — икесен дә башкара алырсың.

— Синең теләк минем өчен изге, — диде Таҗит, килешеп.

— Шуны да бел, Таҗит. Нурлы бикәнең дә теләге бу! — диде мака сар Аланча, җитди итеп.

— Синең теләккә, Нурлы бикә теләгенә мин бик теләп риза, — диде Таҗит, баштагы сүзен төзәтеп. — Нурлы бикәнең алтын сыны моңарчы куелган барлык сыннардан

зуррак, биегрәк, күркәмрәк булыр. Бөтен сарайда, бөтен Акланда Нурлы бикә — иң чибәр, иң акыллы хатун.

— Мака сар Аланча хатуны Нурлы бикәнең алтын сынына киләчәк буын кешеләре дә таң калырлык булсын! — диде Аланча, шактый тантаналы итеп.

Ашап туйгач, төз гәүдәле, чем-кара чәчле, кара кашлы чибәр Аланча, Таҗитнең аркасына аталарча кулын куеп, атаклы төзүчене табын бүлмәсенең ишегенә кадәр озата куйды. Аны ишектән чыгарып җибәргәндә ул аеруча якын һәм ягымлы булып тоелды. Иң кирәкле серен әйткән кебек ул Таҗит төзүченең колагына иелә төште һәм, тавышын әкренәйтеп:

— Барысы турында да моннан соң Нурлы бикә белән киңәшерсең, — диде.

— Киңәшермен, — диде Таҗит.

Шуннан соң ул туры Нурлы бикә бүлмәсенә юнәлде. Аңа бераз гына көтеп торырга куштылар — бикә, күрәсең, йокыдан торгач киенеп, ясанып, төзәнеп бетмәгән иде. «Бераз гына» дигәне озак кына булып чыкты. Илнең иң гүзәл, иң акыллы хатыны Таҗит төзүчегә ямьсез булып күренергә теләми иде, ахрысы.

Югарыдан, түшәмнән төшкән яктылыкта каршыдагы киң, биек ишекнең көмешле, бизәкле яңаклары аеруча матур булып, балкып күренде. Ишекнең ике ягында да таш савытларда яшел яфраклы ал, кызыл чәчкәле гөлләр балкып утырды. Фил сөягеннән кырып, сырлап һәм шакмак-шакмак бүлгәләнгән биек түшәмне тотып торучы кызыл терәкләр артында, почмактарак, алтын читлектә, каяндыр чит илләрдән китерелгән кечкенә кошлар сайрады. Кызыл күн белән тышланган һәм аяклары арыслан аягы сыман итеп эшләнгән йомшак кәнәфидә утырып торучы Таҗит яныннан, алтын белән аралаштырып көмеш калайлар түшәлгән тигез идәннән йомшак кына атлап, бикәнең асраулары — кара тәнле, калын иренле, йә булмаса, киресенчә, ап-ак тәнле, җитен сыман аксыл чәчле йончыган кыяфәтле кызлар узып китте. Таҗитнең янында гына диярлек, тышкы ишеккә якын җирдә, йокымсырап әзмәвердәй зур гәүдәле, сакал-мыексыз печмән сакчы басып торды. Тик торудан арып, авызын ачып иснәп-иснәп алды, аякларын, кулларын бер урыннан икенче урынга алыштырды, үтепсүтеп йөргән асрауларга ахмакларча елмаеп калган булды. Ике ягында кызыл терәкләр тезелгән, киңлеге бишалты адым булган якты аралык уң якта каядыр ары сузылды. Аннан кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне, табак-савыт шылтыраганы ишетелде. Асрау кызлар шул

яктан килеп сулга борылдылар да киң, иркен баскычтан югарыгы катка менеп киттеләр. Икесе ике яктан килүче ике асрау бер мәртәбә туп-туры бер берсенә килеп бәрелделәр дә, чак-чак кына куркып, җиңелчә кычкырып җибәрделәр, аннан соң көлешеп, бер-ике сүз әйтешеп аерылып киттеләр.

Таҗит төзүче урыныннан кымшанмыйча, як-якка күзләрен йөртеп, тыныч кына юк-бар нәрсә күзәткәләп утырды. Бер ярты сәгать чамасы үткәч сул яктагы баскычтан кара чәчләре күпереп торган, нечкә билле, ачык муенлы, киң, озын итәкле, аллы-гөлле күлмәге җилфердәп торган чибәр кыз ашыгып түбән төште, елмаеп Таҗит янына килде дә хуш исле нәфис бармаклары белән Таҗит төзүченең кулына кагылды.

— Бикә чакыра, — диде ул, күгәрчендәй гөрләп.

— Бигрәк ягымлы икәнсең. Исемең ничек? — дигән булды Таҗит, түгәрәк битле, кара кашлы чибәр кызга сүз кушып.

— Әлфия булабыз! — диде кыз, ярым шаяртып, ярым җитди итеп. — Әйдә тизрәк, бикә сине күптән көтә. Ашагач гимнас өенә барасыбыз бар. Бүген анда ярыш!

— Бикә түгел, мин көтәм, — диде Таҗит, җавапсыз каласы килмичә генә.

Чыннан да Нурлы бикә каядыр китәргә ашыга иде бугай. Ул инде тиешенчә төзәнгән, бизәнгән, ясанган һәм яхшылап таралган, майланган, күпертелгән чәчләрен бозарга, аяк очына чаклы төшереп торган озын итәкле күлмәген бөгәрләргә, җыерчыкландырырга теләмәгәндәй, калку урында таш сындай тын гына көтеп утыра иде.

Таҗит килеп керү белән, ул, матур ак тешләрен күрсәтеп, ясалма елмаеп, аңа якынрак килергә кушты. Шуннан соң, Таҗит якынрак килеп, түбәнчелек белән баш игәч һәм өч-дүрт адым чамасы аның каршында туктап калгач, беренче булып сүзгә башлады.

— Мака сар Аланча минем алтын сынымны ясатырга булды, — диде ул, көлемсерәп һәм сөрмәле матур күзләрен уйнатып. — Минем алтын сыным моңарчы Түгәрәк тауда булган барлык сыннардан зуррак, шәбрәк булырга тиеш. Акланның кай төшеннән карасаң да, ул ерактан ук күренеп торырга тиеш. Чит илдән килгән теләсә кем, аны күреп шаккатырга тиеш. Аннан соң... ул минем үзем кебек... булырга тиеш! — диде Нурлы бикә һәм үзенең тапкыр сүзеннән үзе үк көлеп куйды.

Аңа ияреп Таҗит тә көлде.

— Теләгең үтәлер, бикә, — диде ул, баш иеп.

— Ярар, үтәрсең, Таҗит төзүче, — диде бикә мәрхә-

мәтле елмаеп һәм сүзнең тәмам икәнлеген аңлатып урыныннан торды.

— Минем сиңа бер-ике сүзем бар, бикә, — диде Таҗит, ашыгып.

— Әйт, — диде Нурлы бикә, ясалма елмаеп.

— Синең алтын сының барлык сыннардан зуррак буласы булгач, аны ачыграк, калкурак җиргә утыртырга кирәк булыр иде, — диде Таҗит. — Ләкин Түгәрәк тауда андый җир юк — сарай өстендә сарай дигәндәй. Син кая киңәш итәрсең икән?

— Мин инде уйладым аны, — диде бикә, күзләрен кыса төшеп. Түгәрәк тауның диңгез ягында, көнчыгышында бушрак урын бар...

— Төпсез чүлмәк дип йөртелә торган ташландык җирме?! — диде Таҗит, коты алынып.

— Шулай дисәң дә була, — диде Нурлы бикә, теләртеләмәс кенә. — Анда теге Дикә дигән уйнашчы хатын күмелгән, диләр.

— Дикә?! — диде Таҗит, үзе дә сизмәстән.

— Дикә инде, Дикә! — диде Нурлы бикә, яратмыйча. — Шундагы буш урынны төбеннән алып ташларга да коймадан, таудан биегрәк итеп таш багана утыртырга. Шуның өстендә минем сын! Мин аны шулайрак күз алдына китерәм, Таҗит төзүче.

— Аңлашылды, — диде Таҗит, уйланып, һәм торараташтай катып тик торды.

— Мин ашыгам, — диде бикә, түземсезләнеп. — Уйла, кара, тикшер. Бер-ике атнадан килерсең.

— Килермен, — диде Таҗит төзүче, төштәге сыман, артына чигенеп.

Нурлы бикә яныннан чыгу белән ул туп-туры Төпсез чүлмәк чүплегенә юнәлде. Күзенә ак-кара күренмичә ашыгып китеп барганда, тигез таш җәелгән, ике ягында да хуш исле куе куаклар үсеп утырган тар сукмакта ул сынчы Әүфил белән очрашты. Сынчы Әүфил дә ашыгып каядыр китеп бара иде. Сынчы Әүфил Таҗитнең Түгәрәк таудагы иң якын танышларыннан берсе иде. Нурлы бикәнең бөтен дөньяны таң калдырырга тиешле алтын сыны турында сүз чыккач та, ул иң элек менә шушы Әүфилне исенә төшерде. Әүфил, бөтен Акланда иң остасы саналмаса да, аның башкаларда булмаган яхшы яклары бар иде. Ул кешенең бит төзелешен, күз карашын җанлы итеп бирә ала иде. Дөрес, тәнне, аяккулларны, күкрәкләрне ул бик үк төгәл итеп бирә алмый, аның гәүдә сыннары җансызрак, килешсезрәк була. Аннан соң ул бераз ашыгучанрак, шапшаграк та. Ул

ясаган сыннарның эшләнеп беткәч тә төгәлләнмәгән, онытып калдырган, күрмичә калдырылган берәр кимчелеге табыла. Кайчан карама, аның кулы, беләге ак балчыкка, кызыл балчыкка буялган булыр яисә битендә, муенында берәр төрле майлы тап ялтырап торыр. Билендә исә таушалып, иләнеп, пычрап һәм утлы куз төшеп көеп, тишкәләнеп беткән күн алъяпкыч булыр. Хәзер ул иске алъяпкычын салып, яңасын, кыскарагын кигән, битен-кулын да яхшылап юган сыман. Шулай да сул як терсәгендә майлы ак балчык табы торып калган.

Тар сукмактагы бу көтелмәгән очрашудан Таҗит белән Әүфил аптырап киттеләр, көлеп җибәрделәр һәм бер-берсенә юл биреп, читкә тайпылдылар. Икесе дә берьюлы диярлек бер-берсенә:

— Кая киттең болай? — диделәр.

— Нурлы бикә чакыра! — диде Әүфил, бик зур сер әйткән кебек күз кысып.

Уң кулының кыска, юан бармагы белән Таҗитнең күкрәгенә дусларча төртеп алды да үз сүзеннән үзе кызык табып көлгәндәй итеп алды. Сынчы Әүфил эчәргә ярата һәм шапшак, гамьсез кеше буларак, теләсә нәрсә ашый, теләсә кайда ятып йоклый иде. Шунда тамагына әллә балык кылчыгы, әллә икмәк кибәге кадалып калган, әллә салкын җил өргән — инде ничә ел менә кешечә ачык итеп түгел, ничектер гыжылдап сөйләшә. Шуңа күрә аның көлүе дә кыска-кыска бер гыжылдавык кына булып чыкты.

— Көпә-көндезме?! — дигән булды Таҗит тә, Әүфилнең тупас шаяруына ярарга тырышып.

— Ишетмәдеңмени әле, үзенең сынын ясатмакчы була! — диде ташчы тишек авыз Әүфил, чишелеп.

— Ишетмәгәнием шул, — дигән булды Таҗит. — Син соң ишеттеңме әле, Ту анабыз Дикәнең чишмәсе Төпсез чүлмәк чүплеге астында икән бит!

Әүфилнең шат, гамьсез йөзе үзгәреп китте. Гаҗәпләнеп, коты алынып ул хәтта артына чигенгәндәй итеп куйды.

— Каян белдең? — диде ул, очлы күз карашы белән Таҗитнең йөзен тишәрдәй булып.

— Нурлы бикә әйтте! — диде Таҗит, пышылдап, үзе дә сизмәстән.

— Син дә анда булдыңмыни? — диде Әүфил, Дикә турындагы хәбәрне ишеткәндәгегә караганда да гаҗәпләнебрәк.

— Булдым, — диде Таҗит. — Мака сар Аланча янында да булдым. Төпсез чүлмәк чүплеген алып ташлап,

шунда биек таш багана утыртып, башына Нурлы бикәнең сынын...

— Миңа да әйтте ул аны! — диде Әүфил, ашыгып, Таҗитнең сүзен бүлдереп.

— Нурлы бикәме? — диде Таҗит.

— Нурлы бикә, — диде Әүфил, күзен читкә борып.

Аның хәзер тизрәк аерылып китәсе килә иде, ахрысы. Шулай да үзеннән өлкәнрәк һәм үзеннән атаклырак Таҗит яныннан ул беренче булып кузгалып китә алмый иде. Бу, билгеле, әдәпсезлек булачак иде. Ул чакта Таҗит Әүфилдәге эчке үзгәрешне сизмичәрәк калды. Бөтен игътибарын аның Дикә турындагы хәбәр биләп алган иде. Ул әле аны аңлап-төшенеп тә җитмәгән иде бугай, шуңа күрә аның бу хакта Әүфил белән фикер дә алышасы, эчен дә бушатасы килә иде бугай.

— Анда ниндидер чокырмы, тау куышымы бар дип сөйлиләр, караганың юкмы? — диде ул, сүзне һаман Төпсез чүлмәк чүплегенә бормакчы булып.

— Кайда, нинди чокыр? — диде Әүфил, берни аңламыйча.

— Төпсез чүлмәк чүплегендә инде! — диде Таҗит.

— Нишләп мин чүплектә актарыныйм?! — диде Әүфил, хәтере калган сыман, борынын җыерып. — Минем эш болай да муеннан. Әле менә Әлфи сака кызының сынын ясап бетереп киләм. Тагын менә монысы, Нурлы бикә...

— Нишләп алай соң әле ул? — диде Таҗит, аптырабрак, Төпсез чүлмәк чүплеген беразга исеннән чыгарып. Мака сар да, Нурлы бикә дә иң элек минем белән сөйләштеләр. Бөтен эшне башкарып чыгуны миңа йөкләделәр. Мин шулай аңладым.

— Мин әлегә берни аңламадым, — диде сынчы Әүфил, ясалма көлеп. — Кулым эштән курыкмый. Күзем яхшы күрә. Ни кушсалар, шуны эшлим. Миннән каршылык юк. Менә тагын чакырганнар. Барып килим инде, соңыннан иркенләп сөйләшербез.

Китәргә рөхсәт сораган сыман ул шулай ашык-пошык кына сөйләнде дә кузгалып китте. Таҗит аңа каршы килмәде.

— Мин шунда булырмын — чүплек тирәсендә, — диде ул, аерылышканда.

Ашыгып ул Төпсез чүлмәк чүплеге ягына китеп барды. Түгәрәк тауда төрле эш белән, йомыш белән еш булырга туры килсә дә, Түгәрәк таудагы, бигрәк тә алтын койма эчендәге, үзәктәге биек, бай сарайларны, каравыл өйләрен, матур биналарны һәм берсеннән-берсе матуррак,

гүзәлрәк бакчаларны биш бармагы кебек белсә дә, Таҗит төзүченең беркайчан Төпсез чүлмәк чүплеге янында булганы юк иде. Ул якка барса, шул чүп-чар түгүче каралар, коллар йөри дә Түгәрәк таудагы су, бакча, урам караучылары һәм эше төшкән кайбер багалар килеп чыга.

Таш җәелгән тар сукмак куе куаклар арасыннан барды-барды да көтмәгәндә түгәрәк ачыклыкка барып чыкты. Як-ягында гөлләр, хуш исле куаклар үсеп утырган түгәрәк болында кояштан янган таза битле ярым шәрә малайлар чыркылдап, уйнап, тыз-быз йөгереп йөри иде. Түгәрәк болыннан соң сукмак сулга каерылды һәм үр менә башлады. Монда инде аяк астына бернинди таш җәелмәгән, шулай да сукмак күп йөргәнлектән шомарып, тапталып беткән иде. Биек, куе агачлар арасыннан чыккач, Таҗит ниндидер таш корылмалар янына килеп җитте. Бу мал-туар, кош-корт ябып куя торган каралты-кураларның арткы ягы булып чыкты. Якында гына этләр өрде, әтәчләр кычкырды. Абзарлар ягыннан бик үк тәмле булмаган төрле әче-төче исләр килеп китте.

Кәҗә сукмагы бераз җир текә яр буйлап барды да бераздан иркенрәк төшкә барып чыкты.

Таҗит туктап калды. Тау монда сөзәк кенә булып түбән таба төшә дә, астагы, тау итәгендәге түгәрәк таш коймага төртелеп кала. Тау өстендә берән-сәрән вак куаклардан башка якында бернинди агач-фәлән үсми. Сулда, тау өстендә, үзәктәге алтын коймага таба куе булып, биек булып мәңге яшел урман калкып утыра. Еракта, коймалар һәм астагы, үзәндәге төрле корылмалар, агачлар артында, зәңгәрләнеп диңгез күренә. Диңгез ягыннан талгын гына җил исә. Ләкин диңгез җиле белән бергә, таудан астагы чүплек өеменнән бозык, тәмсез исләр килеп-килеп китә. Чүплектә бер-ике эт нидер иснәнеп йөри.

Таҗит, чүплек ягыннан килгән исләргә игътибар итмәскә тырышып, сулгарак, ачыграк җиргә чыкты. Биек агачлар янына барып якын тирәне, диңгез, тура якларын карады. Аннан соң ниндидер сукмактан сакланып кына аска таба төшә башлады. Аяк астыннан түбәнгә вак ташлар тәгәрәп төшеп китте, кояшта кызынып яткан кәлтәләр куркып читкә тайпылдылар. Ул тау астына төшеп җиткәндә, ниндидер үләксә белән туенып яткан козгыннар, ямьсез каркылдап, дәррәү кузгалып киттеләр. Этләр дә, кеше килүен күреп, теләртеләмәс кенә читкә тайпылып китеп бардылар.

Таҗит төзүче тау буендагы чүп-чар өеменә, чүп-чар өеме астыннан төртелеп чыгып торган ниндидер таш кисәкләренә карый-карый түбән төште һәм, чүплекне

бар яктан да тикшермәкче булып, койма буенча уңга борылды. Ләкин коймага якын килү белән, ул мондый уеннан кире кайтырга булды. Монда нидер аңа барысы да чиркангыч тоелды. Еллар буена төрле чүп-чар түгүдәнме, башка сәбәптәнме, аяк асты монда сазлы җирдәге кебек селкенеп һәм лычкылдап тора иде. Димәк, чыннан да монда кайдадыр чишмә чыгып ята булса кирәк. Әллә соң җир астыннан берәр төрле юынтык сулары төшә микән? Хәер, монда бит коры чүп-чар гына ташламыйлар, пычрак юынтык суларын да китереп каплыйлар.

Ул төшкән җиреннән кире менде дә, чүплекнең икенче ягына чыкты һәм янә тау астына төште. Монда да шул ук хәл иде — таш койма янына якынаю белән, аяк асты шикле рәвештә тирбәнә, селкенә, бата башлады, аяк баткан төштән исә лычкылдап пычрак су килеп чыкты. Чүплек астыннан бернинди тау куышына яисә баз авызына охшаган нәрсә күренмәде. Бөтен нәрсәне чүп-чар, иске-москы каплап киткән. Монда бөтен нәрсә бар: агач, таш, чүлмәк калдыклары да, вак ташлар да, тукыма, чыпта, салам һәм иске-москы тире, күн калдыклары да, коелган иске яфраклар да, балчык, сөяксанаклар һәм төрле үләксәләр дә...

Карана торгач, Таҗит шуңа да игътибар итте: Түгәрәк тауны астан әйләндереп алган һәм тигез җирдән сузыла торган түгәрәк койма кайчандыр элеккерәк заманнарда хәзерге чүплек өеменең урта бер җиреннән узган, ахрысы. Чөнки чүплекнең ике ягында да, тау итәгеннән чак кына өстәрәк, әле дә иске койма нигезе аермачык булып беленеп тора. Әле дә анда, аяк астында, эре-эре таш кисәкләре, яндырылган кирпеч ватыклары аунап ята. Аннан соң, койманың иске өлеше белән яңа өлеше килеп тоташкан төшләре дә ерактан ук күренеп тора. Димәк, хәзерге чүплек астындагы җирнең яртысы элегрәк койма тышында булган. Шул койма тышындагы калкурак урыннан, күрәсең, Изгеләр чишмәсе агып яткан, Ту анабыз Дикәнең сыны да, күрәсең, менә шунда булган. Шулаймы? Бик мөмкин. Ләкин моның чынында шулаймы-түгелме икәнлеген белү өчен иң элек җиз койманың эчке ягына кереп тагын тикшереп карарга кирәк, аннан да бигрәк, бу чүплекне юк итеп, чистартып аның астынданиләр барын үз күзең белән күрергә кирәк. Әгәр чыннан да шунда Изгеләр чишмәсе, ту анабыз Дикәнең изге сыны табылса, нинди бәхет, нинди зур куаныч булыр иде бу! Таҗитнең үзе өчен генә түгел, бөтен тура өчен, Аклан иле өчен бу искиткеч шатлык булыр иде! Изгелек кире кайту дигән сүз булыр иде. Шатлык кынамы соң?

Бу яңадан бөтен илдә тәртип, иминлек урнашу, яңадан аллалар сүзенең өстен чыгуы, бозыклыкның, җәбер-золымның, кайгы-хәсрәтнең юкка чыгуы булыр иде.

Туктале, Аланча да, Нурлы бикә дә түгел, аллалар чуалтты микән соң бу эшне? Кем генә булмасын, чуалды эш, чуалттылар. Бөтен нәрсә баш-аяк килде. Очлы кыя башындагы утка гына берни булмаган. Ул һаман яна да яна. Ул — мәңгелек, аның белән чагыштырганда, кеше гомере — күз ачып йомган ара.

Тик менә Нурлы бикәнең Ту анабыз Дикә турында ямьсез итеп сөйләнүе генә эчне пошыра. Белеп сөйләнәме ул, белмичәме? Ни генә булмасын, аңа да, аларга да яхшылап аңлатсаң, аңламый калмаслар. Бит алар үзләре иң элек шул аллалар нәселеннән! Шушы төшкә биек багана утыртып, алтын сынын багана башына бастырып кую турында хыяллана икән, аңа да каршы килеп булмый. Монда хәтта Нурлы бикәнең үзенә әйтмичә генә хәйлә корырга да була. Синең сының — иң югарыда, Изге анабыз Дикәнең сыны, чишмәсе синең аяк астында кала дияргә була. Масаеп, кукраеп тик йөрсен. Җиз кояманы исә яңадан элекке эзенә күчереп, чишмәне яңадан тышкы якка калдырасың. Ерактан караганда Алтын бикәнең аягы астында нәрсә барлыгы күренмәячәк тә. Биек койма янындагы чишмәгә исә элеккечә халык агылачак, келәү әйтеп, зекер әйтеп, изге аталарыбызны, аналарыбызны искә төшерәчәк. Яңадан халыкның күзе ачылачак, аңы ачылачак. Иң кирәге бүген шул түгелмени?!

Үзалдына хыялланып Таҗит кире мака сар Аланча сарае ягына юнәлде. Бик кыска гына вакыт эчендә дә бөтенесен аермачык итеп күз алдына китерде — сигез кырлы таш бағананы да, аның өстендә балкып торачак алтын сынны да һәм аннан астарак, читтәрәк яңадан челтерәп ага башлаячак Изгеләр чишмәсен дә — барысын да аермачык итеп күз алдына китерде. Күңеленнән ул бу чүплек башын Түгәрәк тауның үзәгенә әйләндерде. Җиз койма тышында ул төрле яктан килгән каралар өчен яшел болыннар ясады, болыннарга гөлләр, вак куаклар утыртып чыкты. Шунда ук читтән килүчеләр өчен бик борынгы заманнардагыча куышлар утыртып куйды, аксөякләр өчен ак, кара, кызыл ташлардан җыйнак кына матур-матур йортлар салырга да онытмады. Яшел болында сыерлар, сарыклар утлап йөрде. Таякларына таянып гамьсез генә көтүчеләр басып торды.

Өч катлы биек сарайга якынлашканда, ул беркадәр сүрелә төште. Усал чынбарлык күңел күзенә капланган алдавыч элпәне искәрмәстән төртеп тишкән кебек бул-

ды. «Бернинди чишмә дә юктыр әле анда» диде ул үзүзенә, ямьсез, сасы чүплекне күз алдына китереп. Юк, шулай да койманың теге ягына чыгып караганда начар булмас иде. Нииндирәк җир ул? Йортлар, каралтылар, бакчалар нииндирәк, суы койма аша чыгамы, әллә шунда гына җыелып ятамы? Ләкин хәзер генә ничек итеп анда барасың? Турыдан, койма өстеннән чыгып булмый, әйләнгеч юл ерак. Аннан соң бит әле ул бүген үзенең Карлы тау ягындагы эшчеләре янына да өлгерергә тиеш.

Кайту ягына борылгач, Таҗит, өч катлы биек сарай яныннан узкәндә, кояшлы, ачык ишегалдына кермәс өчен, юри читләтеп күләгәле куаклар арасыннан китмәкче булды. Ләкин сарай турысыннан барганда Таҗит шулай да ул якка карамыйча булдыра алмады. Шул чакны ул ишектән сынчы Әүфилнең чыгып килүен күреп калды. Ул да, ахрысы, аны күрде — Таҗиткә шулай тоелды. Ул, күләгәдән чыгып, сынчыны көтеп торырга мәҗбүр булды. Алар яңадан очраштылар. Сынчы Әүфилнең йөзе бик шат күренде.

— Ни булды? Ник чакырган? — диде Таҗит, беренче сүзе итеп.

— Сорама да. Булды инде, — диде бәхетле сынчы кул селтәп һәм туктап торасы килмәгәнлеген сиздереп, ашыгып китеп барды.

— Эш күп. Ашыгам, — дигән булды соңлап булса да.

Шул чагында Таҗиткә Әүфил сынчының сүзе дә, йөзекыяфәте дә Төпсез чүлмәк чүплегендәге селкенчәк җир кебек бик-бик шикле һәм ышанычсыз тоелды.

Аның ни өчен шикле булуы соңыннан, бик соңлап аңлашылды.

Ләкин бу билгесезлек, аңлаешсыз, хәтта шомлы тынлык кырык көн генә сузылды. Карманның кырыгы үткәрелгәч, урамнар, базарлар, яр буйлары яңадан халык белән, ыгы-зыгы һәм яшьләр, балалар чыр-чуы белән күмелде. Шул ук вакытта Изгеләр тавында да әкренләп хәрәкәт башланды. Хәрәкәткә килүнең икенче көнендә үк диярлек чүлмәкче бистәсенә, ике ат җигелгән биек кәрендәсенә утырып, Аланчаның йомышчысы Бабул килеп җитте.

Капка шакыган тавышка Таҗит үзе чыкты. Ярым ачык капкада ул тагын түгәрәк йөзле, симерә башлаган, ләкин тынгысыз кыяфәтле Бабул белән күзгә-күз очрашты.

— Бу йортта Таҗит төзүче торамы? — диде Бабул, тагын кычкырып.

— Мин ул Таҗит төзүче, — диде Таҗит, тыелып кына.

— Сине мака сар Аланча үз янына чакыра, әйдә, киттек, — диде Бабул, көр тавыш белән.

— Хәзер үкме?! — диде Таҗит янә.

— Хәзер үк! — диде Бабул.

Бу юлы аны көттереп тә тормадылар, ашарга да чакырмадылар. Бу юлы туры аны мака сар Аланча янына алып керделәр. Бу юлы каралар да, мака сар үзе дә ягымлы, йомшак күңелле булып күренмәде. Килеп керү белән, күзен күтәреп Таҗитнең йөзенә карау белән, мака сар аның маңгаендагы яңа төзәлеп килә торган ярасына игътибар итте һәм, чыраен сыткандай итеп:

— Мәрхүм Карман өчен син дә бик кайгыргансың икән, — дип куйды.

Аланчаның нәрсәгә ишарәләвен Таҗит төзүче, билгеле, аңламый булдыра алмады. Тик ул аның ни өчен моны шелтә белән әйтүен генә аңлый алмады.

— Гомерем буена мин мака сарларның колы булдым, — диде төзүче Таҗит, бер агарып, бер кызарып. — Карунга, Карманга турылыклы булган кебек, мин сиңа да турылыклы, мака сар!

— Шулай микән?.. — диде Аланча коры гына.

— Шулай, мака сар! — диде төзүче Таҗит. — Актауда бүленгән эшем көтеп тора. Миңа хәзер үк шунда китәргә боерсаң иде.

— Китәрсең, — диде мака сар Аланча, уйланып. — Тик син миңа әйтмәдең: Карун хәзинәсе кайда?

Шулай диде дә, күзләрен акайтып, ашардай булып, каршысындагы кешегә күтәрелеп карады. Таҗит коелды да төште. Аның әле беркайчан мондый куркыныч кыяфәтне күргәне юк иде бугай. Ул шундук йөзтүбән идәнгә егылды. Бөтен өй эче кинәт тып-тын булып калды. Колакта бары кан шаулады да, колак төбендә дәһшәтле кешенең мыш-мыш тын алганы ишетелде.

— Миңа җиткерделәр... син беләсең! — диде Аланча, усал чыжылдап.

— Белгән булсам, бик сөенеп әйтер идем, — диде Таҗит, башын калкыткандай итеп.

— Белмәсәң бел! Эзлә, тап! — диде мака сар Аланча, йомшагандай итеп.

Ул аңа торырга кушты. Таҗит торды һәм ни әйтергә белмичә, беравык бер сүз дә әйталмады. Ул, билгеле, «эзләрмен» дип җиңел генә сүз биреп чыгып та китә алган булыр иде, ләкин сүз биргәч бит әле аны үтисе дә бар! Сүзеңдә тора алмасаң, соңыннан ни дип җавап бирерсең? Моның ташы кызган, моның түзәр әмәле калмаган, моңа хәзер үк Карун малы кирәк!

— Мин барысын да аңлыйм, мака сар, — диде Таҗит, исен җыя башлап. — Амбарлар бушап калган, чокырлар бушап калган. Илнең иминлеген, көч-куәтен саклап калу өчен сиңа тиз арада бик күп акча кирәк. Тик шулай да илнең иминлеге, көче-куәте байлыкта гына түгел.

— Тагын нидә? — диде мака сар Аланча, сагаеп.

— Ата-ананы олылауда, мака сар! — диде Таҗит, шешенке йөзле мака сарның йөзенә туры карап.

— Беренче мәртәбә ишетәм! — диде мака сар Аланча, күрәләтә мыскыл белән.

Таҗит аның мыскыллы сүзләрен игътибарсыз калдырды һәм, бар батырлыгын җыеп:

— Минем сиңа бер сүзем бар, мака сар! — диде.

— Әйтеп кара, — диде Аланча, теләр-теләмәс кенә, симез аяк астын кашыштырып.

— Булмаган Карун хәзинәсен эзләгәнче, безгә иң элек анабыз Дикәнең югалган сынын, югалган чишмәсен эзләп табарга, йөгәнсезләнгән караларны туры юлга өндәргә, илдәге бозыклыкны бетерергә кирәк.

— Кирәк!.. Бигрәк күп «кирәк». Әле мин тәхеткә утырырга да өлгермәдем — кирәк тә кирәк... — диде мака сар, чыраен сытып, үчекләгән сыман сөйләшеп.

«Юкка әйттем!» — дип уйлады Таҗит, үзалдына, эче пошып.

Күренеп тора, тыңламый, аңламый. Кирәге юк.

Шуннан соң ул чыгып китте. Чykканда шулай да сорады:

— Юл салуны нишләтергә? Актауга китсәм, каршылык булмасмы? — диде.

— Кайтып тор, кирәк булсаң, чакырырмын, — диде мака сар, ачык кына җавап бирми.

Бер-ике көннән иртән-иртүк мака сар йомышчысы Бабул тагын килеп җитте. Тагын аңа Таҗит капка ачты, тагын алар капка төбендә кычкырып үзара сөйләшеп-аңлашып алдылар һәм иң ахырда Бабул, кәрендәскә үз янындагы буш урынга ымлап, «Әйдә, киттек!» диде. Аны тагын ярым йокылы урамнардан, ярым буш күперләрдән, куе күләгәле биек агачлар арасыннан тураның уртасына — алтын-көмеш манаралары, биек ак сарайлары балкып торган Изгеләр тавына алып киттеләр. Алар тагын бизәлгән, җиз белән тышланган биек капкаларга керделәр һәм ике ягында да тигез булып яшел куаклар үскән, яфрагы саен нәфис кошлар сайраган сихри юллардан каядыр ары бардылар, ләкин бу юлы аны мака сар сараена түгел, каядыр ярым караңгы җир асты базына алып керделәр. Аяк табаннары ашап шомарып

беткән ташлы юлның кайсы якка борылуын күргәч, ул шундук барысын да аңлап алды. Бу юлы аны мака сар янына түгел, хөкемчеләр янына алып бардылар. Өч көн буе аннан сорау алдылар. «Кайгы туе көнендә мака сар Аланчаны сүктеңме, үзегезнең урамда такмаклап аны мыскыллап җырулар әйттеңме?» — диделәр. Кирәкле җавапны ала алмагач, башка яктан кыса башладылар. «Карунның яшерелгән хәзинәсен беләсең икән, ник әйтмисең? Карун байлыгы — сарлар байлыгы ул, Аланча мака сарга тиешле байлыкны йомып калмакчы буласыңмыни?» — диделәр.

Өченче көнне хөкем чыгардылар. Хөкем бик кыска булды: мака сарга каршы баш күтәргән өчен башын чаптырырга, кулларын-аякларын кисәргә, диделәр. Хөкем карары мака сарга җиткерелде. Изгеләр тавындагы язулы ташта «Аксөякләрнең каны чыгарылмаска тиеш» дигән сүзләр бар иде. Мака сар Аланча хөкем карарын мәңгелек сөргенгә алыштырды. Мәңгелек сөргенгә озатылган кеше, үзенең барлык караларын, малын-туарын алып, турадан, Акланнан читкә китәргә, җир ачарга һәм яңа җирдә мәңге төпләнеп калырга тиеш иде.

Җыенырга, күченергә аңа ун көн вакыт бирелде. Иң элек аңа кешеләрен, мал-туарын, азык-төлеген, барлык кирәк-ярагын төяп юлга чыгу өчен унлап кәмә табарга кирәк иде. Турада күренекле кеше булганлыктан, аның кәмәчеләр, балтачылар арасында да, сатучылар һәм башкалар арасында да таныш-белешләре шактый күп иде. Уйлана торгач ул иң элек Әүхәт белән сөйләшеп карарга булды. Бөтен турада сатучыларның иң бае, көчлесе, иң булдыклысы шул Әүхәт иде. Аның кәмәләре дә күп, кешеләре дә күп. Аның йөрмәгән җире, күрмәгән иле калмагандыр. Ул инде кайнар комлы Кәми якларында да, җир чите Тартөш якларында да, кыш көнендә җиргә күктән ак мамык ява торган салкын якларда да булган. Яшь чакларында аны диңгез юлбасары булган, чит җирләрдә, сагалап торып, үтеп-сүтеп йөргән кәмәләрне талаган, яр буйларындагы авыл-тураларга басып кереп, кем туры килә шуны коллап алып китә торган булган һәм әсирләрен соңыннан олы базарларда кол итеп сата торган булган дип, шундый юллар белән баеп киткән дип сөйлиләр. Дөрес, бу инде күптән булган, хәзер ул — тураның иң атаклы уңган сатучысы.

Ни генә булмасын, кайсы якка китәргә, кайда төпләнергә кирәклеген ул яхшырак белергә тиеш.

Әүхәтнең җимеш агачлары арасында күмелеп утырган ике катлы таш йорты олы арык буена, диңгез кап-

касына якын җиргә, тышкы зур койма янынарак урнашкан иде. Моннан бер ай элек кенә Әүхәт көнчыгыштагы Дарчин иле якларыннан кайтып төшкән һәм хәзер, аннан кайткан хуш исле ят кабыкларын, майларын, җимешләрен сатып бетергәч, монда, үз йортында эшләрен җайга салу белән мәшгуль иде.

Таҗитнең ни өчен килүен ул әйтмичә дә чамалап алды. Таҗитне үлемгә хөкем иткәннәр икән дә, үлем җәзасын мәңге сөргенгә алыштырганнар икән дигән хәбәр инде бөтен турага таралып өлгергән иде. Зур башлы, зур куллы һәм төртелеп торган зур корсаклы Әүхәт килүчене ачык йөз белән каршылады. Ишегалдында артык сүз озайтып тормыйча ул икәүдән-икәү генә сөйләшү өчен ике катлы йортның аскы катындагы аулаграк, караңгырак һәм җиләсрәк бүлмәсенә алып керде. Киң, иркен бүлмәнең ишек төбеннән алып түренә кадәр — әле уңда, әле сулда, әле бер почмакта, әле икенче почмакта төрле зурлыктагы төргәкләр, коелган җиз-бакыр, тимер кисәкләре аунап ята. Һавада нииндидер ят, җиңел һәм ачы-төче исләр килә иде.

Әүхәт чүлмәкләр, капчыклар арасыннан боргаланып түргә узды, идән уртасындагы ачыграк урында туктады да артына борылды.

— Әйдә, утырыйк шушында,— диде, тәбәнәк өстәл янындагы йомшак, калку урынга күрсәтеп.

Беренче булып ул үзе утырды, Таҗит тә утыргач, кулын сузып якыннан гына нечкә муенлы чүлмәкне эләктереп алды һәм өстәл өстендәге бердәнбер көмеш касәгә борла агызды.

— Сүзне иң элек шуннан башлыйк, — диде ул, борла тулы касәне авызына якын китереп.

Бераз тынып утыргач, Әүхәт янә үзенең кунагына күтәрелеп карады.

— Әйтеп кара, ни йомыш? — диде.

Таҗит бер-ике сүз белән үзенең йомышын әйтте.

— Кайчан, кайсы якка китәргә? — диде Әүхәт, бик үк аңлап җитмичә.

— Андый сүз булмады, — диде Таҗит, авыр сулап. — Мин, бәлки ишетмәгәнмендер. Башыма суккандай булды. Сөргенгә, мәңгегә! Мин аңа әзер түгел. Минем беркая китәсем килми.

— Мин ник кирәк сиңа? — диде Әүхәт, гөрелдәп, сорауны турыдан-туры куеп.

— Кәмә кирәк, кәмә, — диде Таҗит, эчке бер газап белән. Вакытында китеп өлгермәсәм, алар мине көчләп берәр җиргә озатырга мөмкиннәр. Аңлыйсыңмы?

— Аңлавын аңлыйм да, — диде Әүхәт теләр-теләмәс кенә. — Шулай да син бик үк аңлата алмадың әле. Кайчан, кайсы якка китәргә?

— Миңа хәзер барыбер, — диде Таҗит, әле һаман туры гына җавап бирмичә. — Миңа хәзер кайда да бер кояш...

— Юк, кайда да бер кояш түгел, — диде Әүхәт. — Җырда гына шулай — кайда да бер кояш. Кояш ул төрле җирдә төрлечә. Бер җирдә ул сиңа көлеп карый, икенче җирдә чыраен сытып карый, өченче җирдә ул сине күрми дә.

— Бармы син йөргән җирләрдә миңа елмаеп карый торган кояш? — диде Таҗит.

— Бар! — диде Әүхәт. — Минем булмаган җирем, күрмәгән илем юк. Сиңа яраклы кояш та... төн ягында.

— Төн ягында? Анда бик салкын диләр бит, — диде Таҗит.

— Салкын диләр... Куркытыр өчен шулай диләр аны, — диде Әүхәт. — Төньяк — иксез-чиксез. Анда буш җирләр, тау-ташлар, урман-сулар — барысы да бар. Ярты ай чамасы барасың да күл сыман бер диңгезгә килеп керәсең. Без аны Мәрмәр диңгезе дип йөртәбез. Тар бугазны үткәч, икенче диңгезгә барып чыгасың. Суы зәп-зәңгәр. Җаның кая тели — шунда туктыйсың. Култыклар, куеннар күп. Туктау өчен, төпләнү өчен җайлы урыннар күп.

— Кыргыйлар да күпме? — диде Таҗит.

— Кыргый булмаган җир юк, — диде Әүхәт. — Алардан куркып торасы юк. Алар көтү кебек. Иген икмиләр, җимеш үстермиләр. Урманда, аяк астында нәрсә табалар, нәрсә аулап алалар — шуның белән туенып торалар. Таурлар иле дип атала.

— Безнекеләр, лелегләр беркем дә юкмы ул якларда? — диде Таҗит.

— Нишләп булмасын! — диде Әүхәт. — Тау башларында, су буйларында кечерәк кенә таш туралар, авыллар бар. Заманында Карун энесе Типкә бине шунда сөргән булган. Ул анда тура салдырып, таулардан бакыр чыгарттырып, Карунны баетып яткан, дип сөйлиләр. Иген игәләр, мал асрыйлар. Аралары ерак, шулай да бер-берсенә барышып-килешеп йөриләрдер. Яр буйларында кәмәләр күренә.

— Сугышалар да микән? — диде Таҗит.

— Ишеткәнем булмады, — диде Әүхәт. — Мин алар ягына өч мәртәбә бардым. Ул Төньяк диңгезнең яр буйларына аяк басмаган җирем юк.

— Кояш кыздырган якларга никтер күңелем тартмый, — диде Таҗит. Күрәсең шунда... төньякка юл тотарбыз, ахрысы.

— Кайчан? — диде Әүхәт, кунагының күзенә туры карап. — Бер ун көннән Әвер җиле исә башлаячак. Шуңа кадәр кузгалып өлгерергә кирәк.

— Шулай ук азмыни? — диде Таҗит ыңгырашып. — Ул йортны-җирне, каралты-кураны, бакчаларны, иген кырларын... нишләтермен соң мин аны? Ах! Ул арада ничек итеп сатып өлгермәк кирәк.

— Әмҗе бистәсендәге йортыңны да, койма буендагы өйләреңне дә, барысын да үзем алырмын, — диде Әүхәт.

— Син?! — диде Таҗит, аптырап. Ул монда килгәндә никтер бу сәүдәгәрне бары кәмәләр белән чит җирләргә генә йөри дип уйлый иде.

— Мондагы йортың шәп. Нык, таза.

— Аерым-аерым торырсың микәнни? —диде Таҗит беркатлы гаҗәпләнү белән.

Әүхәт көлеп куйды.

— Беркөнне синекендә, беркөнне үземнекендә торырмын... килешсәк, — диде Әүхәт.

— Килешсәк, — диде Таҗит үзалдына. Калын иренле, зур йодрыклы һәм зур корсаклы Әүхәтнең шулай күз алдында аның йортына баш булып калган кебек сөйләшүе Таҗитне ничектер өшетеп җибәрде. Беренче мәртәбә аңа үзенең ирене түгел, үзенең монда калачак йорты-җире, күнегелгән шундый өйләре, бүлмәләре, бакчалары бик-бик кызганыч булып тоелды. Башын иеп ул озак кына эндәшми утырды.

— Без әле килешмәдек, — диде Әүхәт гөрелдәп, аны күңелсез уйларыннан бүлдереп.

— Килешмәдек шул, — диде Таҗит, күндәм генә. — Син мине Төньяк диңгез буендагы берәр җиргә илтеп куймакчы булдың...

— Мин әле алай димәдем. Мин бары сиңа әйтеп кенә күрсәттем, — диде Әүхәт. — Беләсеңме, безгә иң элек синең мондагы йортың-җирең турында килешергә кирәк. Килешсәк, мин сиңа барлык кешеләреңне, малың-туарыңны, азык-төлегеңне күчерергә җитәрлек кәмә бирермен, ишкәкчеләр бирермен.

— Башта минем йорт-җир турында килешәбез, соңыннан кәмә турындамыни? — диде Таҗит, Әүхәтнең сөйләшүне каядыр читкә боруын чамалап.

— Кайсысыннан башласак та ярый, — диде шундук Әүхәт, күндәмлек белән. — Алайса кәмә турында сөй-

ләшик. Мин сиңа кәмә бирәм. Күпме кирәк, шулкадәр. Йөгең күпме булса, бәясе дә шулча булыр.

— Булды. Килештек, — диде Таҗит.

— Йорт-җир бәясен кәмә өчен суктырырбыз, — диде Әүхәт иплән кенә.

— Тулысынчамы?! — диде Таҗит, ашыгыбрак.

— Нишләп тулысынча булсын? — диде Әүхәт күндәмлек белән. — Кәмә өчен — аерым, йорт-җир өчен аерым килешәбез.

— Булды, килештек, — диде Таҗит һәм үзе дә сизмәстән өстәлдәге касәгә үрелде.

Әүхәт тиз арада касәгә борла агызды һәм алар ике арадагы килешүне беркетеп янә ант эчтеләр.

— Үзең илтеп куячаксыңмы яңа җиргә, Таурга? — диде Таҗит иң ахырда.

— Мин үзем бара алмам. Бу арада бик авыртынам, — диде Әүхәт.

Таҗит өчен монсы бөтенләй көтелмәгәнчәрәк булды. Әүхәтнең оста кәмәче, диңгезче булуын турада белмәгән кеше юк.

— Син бармагач, кем генә алып барыр икән соң безне ул Таурга? — диде Таҗит аптырап.

— Өлкән улым Мизан алып барыр, — диде Әүхәт. — Кая барырга, ничек барырга — барысын да белә. Ун яшеннән минем белән йөрде. Әүхәт шулай диде. Ахырда, күрәсең, үзе дә сизмәстән өстәп куйды: — Синең йорт-җирең аңа булачак... килешкәч. Башкаландырам. Бәясен дә үзе түләсен.

Шул ук көнне кичке якта Әүхәт Таҗитларга килде. Атасына ияреп малае Мизан да килгән иде. Малае кәрендәс җиккән, атасын коллар күтәргән. Атаклы диңгезченең күтәрәмгә утырып йөрүе гаҗәбрәк иде, әлбәттә. Диңгезче Әүхәт үзе дә шулайрак дип уйлады микән, аягына басу белән, акланган сыман, җиңелчә генә ыңгырашып алды.

— Кәрендәстә эчне селкетә. Эчәкләрем актарылгандай була, — диде.

Таҗит эндәшмәде, шулай да күңеленнән уйлап куйды,«юри кылана, миңа үзенең авырганлыгын күрсәтмәкче була»диде. Әүхәтләрдә сөйләшкәннән соң аның күңеленә инде шикле бер уй килеп өлгергән иде. Моңарчы таза булган һәм бер җире дә авыртынмаган Әүхәтнең аңа ерак юлга чыгарга кирәк булгач кына авыртына башлавы сәеррәк тоелган иде. Аннан да бигрәк аның бит бөтен җаваплылыкны малае Мизанга ышанып тапшырырга ниятләве күңелне тырнап тора иде. Малае

Мизанның яхшы диңгезче булуына, яшь һәм кыю, батыр булуына Таҗит әз генә дә шикләнмәде. Ләкин никтер менә хәзер Таҗитне бөтен иле-көне, малы-туары белән тиешле җиргә алып барып җиткерә алмас шикелле тоелды. Аннан соң, Таҗитнең йортын-җирен, каралтыларын юл исәбенә суктырып, малае Мизанны яңа йортта баш итеп калдырырга исәпләве дә Әүхәтнең бары үз кайгысын, ягъни малаен башкаландыру өчен генә эшләнгән эш булып тоелды.

Ни булса булды, Әүхәтне дә, малаен да ул якты йөз белән каршылады, икесен дә капкадан уздырып җибәрде. Бергәләп алар иң элек ишегалдын, бакча якларын карап чыктылар, абзарга, каралты-курага күз ташладылар, бакча уртасында челтерәп аккан кайнар сулы, салкын сулы җиз көпшәләр янында туктап карап тордылар. Таҗитнең йорты Изгеләр тавыннан ерак түгел, шунлыктан аннан килә торган кайнар һәм салкын суы да тулыбрак, көчлерәк булып ага. Чүлмәкчеләр бистәсендә, Әүхәт өендә чишмә суы теләр-теләмәс кенә ага. Таҗит моңа шундук игътибар иткән иде. «Һи, боларның чишмәсе үләр-үлмәс кенә ага икән»дип уйлаган иде ул. Таҗит ишегалдындагы чишмәләргә Әүхәт белән малае да игътибар иттеләр. Соклануларын яшермичә, туктап, чишмә тавышына колак салып тордылар. Малае түзмәде, хәтта салкын суны учына алып эчеп тә карады. «Монда тәмлерәк, безнең суда ниндидер ят тәм бар», — диде.

Шуннан Таҗит аларны ике катлы таш өенә алып керде, бүлмәләрне күрсәтеп йөрде. Алар килгәндә инде бөтен өйнең, бөтен ишегалдының асты өскә килгән иде. Анда-монда әрҗәләр, савыт-сабалар, чүлмәкләр тезеп куелган, ашыгып, ары-бире килеп каралар, эшчеләр йөренә — әле бер нәрсәне, әле икенче нәрсәне урыныннан күчерәләр. Капчыкларга, чүлмәкләргә ашлык, киптерелгән җимеш, орлык тутыралар. Икенче берәүләр май тулы чүлмәкләрнең авызларын балавызлап-томалап булашалар. Каралты-кура ягында кешеләрнең, атларның, мал-туарның тавышлары ишетелеп-ишетелеп китә.

Кунакларны Таҗит үзенең өске каттагы иркен, якты бүлмәсенә алып керде. Ачык тәрәзә аша дугаланып борылган киң арык ягына, еррактан күренгән биек таш йортларга, манараларга карап, хозурланып торгач, алар, идән уртасына, йомшак калку урынга утырып, түгәрәк өстәлдәге көмеш савыттан шәраб ант эчеп, эш турында сөйләштеләр.

Шунда йорт-җирнең дә, кәмәнең дә бәясен килештеләр, кайчан, каян кузгалып китү турында да килештеләр.

Ул көнне сүз күп булды. Борласы да күп эчелде. Кунаклар караңгы төшә башлаганда гына аякларына бастылар һәм китәргә җыендылар. Шул чакны алар арасында бөтенләй уйламаган, күз алдына китерелмәгән сүз ялганып китте. Өлкәннәр эш турында, бәяләр турында сөйләшкәндә, Әүхәтнең малае Мизан сүзгә катышмыйча күбрәк тыңлап кына утырды. Үзен каядыр чит җиргә, күз күрмәгән, колак ишетмәгән җиргә алып барачак яшь диңгезчегә Таҗит әледән-әле сынап карап-карап алды. Атасы кебек эре сөякле, буйчан һәм зур куллы иде ул сәүдәгәр малае Мизан. Күкрәк киң, беләкләр таза, муен нык, диңгездә үскәне, бик иртәләй ишкәк ишә башлаганы әллә каян күренеп тора. Чем-кара чәчләре озын, алты үремгә үрелгән. Йөзе ачык, ягымлы, күз карашы дәртле. Борыны туры, матур. Тик менә ирене генә бераз калынрак сыман. Анысы атасыныкына охшаганрак. Аннан соң ир кеше өчен тешләре ваграк сыман.

Лия белән алар, капкадан кереп ишегалды карап йөргәндә очраштылар. Үз өендә булганга Лия өстенә җиңелчә генә киенгән иде. Яшь муены, яшь беләкләре ачык, өстенә кигән бизәксез генә күлмәге дә артык озын түгел иде бугай.

Үзе яраткан кызыллы-каралы чүлмәге белән ул чишмәгә суга чыккан иде. Алар шунда, чишмә янындарак очраштылар. Күзгә-күз очраштылар. Мизан каршысында сихри гүзәл чибәр кыз күреп, искәрмәстән, кинәт туктап калды. Лия, үз каршысында ят кешеләр, ят ир кешеләр күреп, җиңелчә генә «аһ» итеп җибәрде. Сөрмәле күзләре белән бер күтәрелеп карады да оялуыннан кып-кызыл булды, оялуын яшермәкче булып көлеп җибәрде һәм тиз генә читкә борылып китеп тә барды. Әүхәтнең малае, туктаган җиреннән кузгала алмыйча, аның артыннан борылып карап калды. Аның да йөзе тынычсыз иде.

Боларның барысы да аталары күз алдында булды. Яшьләрнең шундый көтелмәгән очрашуларына, оялуларына өлкәннәр дә татлы бер тынычсызлану кичерделәр һәм елмайгандай итеп, мәгънәле генә бер-берсенә карашып алдылар. Ике арада бу хакта бер сүз булмады — барысы да күз карашыннан аңлашылды.

Барысы турында да килешеп, кайтып китәр алдыннан Әүхәт сакланып кына әйтеп куйды:

— Тел очында бер сүз калды, әйтсәм, үпкәләмәссеңме? — диде.

Тажит аның нәрсә әйтәчәген сизенеп алды, шундук аның күз карашы яшь егетнең йөзенә төште. Яшь егет тә тынып, сагаеп хуҗаның сүзен көтте.

— Шулай аягөсте генә әйтә торган сүзмени? — диде Тажит.

— Юк, юк, — диде Әүхәт.

— Алайса, әйдәгез, өйгә керик, — диде хуҗа, кунакларны өенә чакырып.

— Бер кузгалгач кире борылсак, юлыбыз уңмас, — диде Әүхәт, икеле-микеле итеп.

— Алайса, иртәгә килегез, — диде Тажит.

— Әти, иртәгә килерсең, — диде шул чакны яшь егет тә, түземсезләнеп.

Икенче көнне Әүхәт үзе генә килде һәм кичәгенәк әйтелми калган сүзне әйтте.

Аның нинди сүз булырга тиешлеген белсә дә, Тажит ул төнне рәтләп йоклый алмады — үзенчә төрлечә чамалап, уйланып чыкты. Лия аның иң яраткан кызы иде. Барлык туганнары, барлык апалары-сеңелләре арасында Лия иң чибәре, иң күркәме һәм иң ягымлысы иде. Аннан соң, ул инде кечкенәдән үк сарайдагы Һабил улы Юныска ярәшелгән иде. Үзенең язмышы кинәт кире якка борылгач, ата кеше күбрәк менә шул Һабил Юнысы турында уйлый иде. Сөргенгә озатылган ата кешенең кызына өйләнергә теләрме Һабилның Юнысы, әллә соң аннан баш тартырмы? Өйләнсә дә, өйләнмәсә дә, шушы арада, шушы көннәрдә Һабилның Юнысы аңа хәбәр бирергә тиеш иде кебек. Тажит шулай дип уйлады. Шулай булуын теләде. Чөнки мондый чакта аның тәртибе шундый иде. Ләкин Һабил Юнысыннан әлегә бернинди хәбәр алынмады. «Күрәсең, үземә барырга туры килер. Ялынып, йөземны ертып, түбәнсенеп», — дип уйлады ул, эче пошып. Бәлки, барып та торырга кирәкмидер. Килми, димәк, баш тарта. Килмәде, килмәс тә.

Әүхәткә ул, билгеле, мондый нәрсәләр турында берни әйтмәде.

— Кызыма ундүрт тулмаган, — диде ул Әүхәткә, уйчан гына. — Чынлап минем белән туганлашырга теләсәң, җәрингә улың килеп алыр... Таур иле дигән яңа җирдән.

Әүхәтнең йөзе үзгәреп китте. Күрәсең, ул мондый сүз ишетермен дип уйламаган иде.

— Ундүрт тулмаган, имеш!.. Тулмасын. Кем аны тикшереп тора? Икәү килешсәк, җитмәгәнмени? — диде ул аптырап.

— Мин синең белән туганлашырга каршы түгел, Әүхәт, — диде Тажит, нык итеп. — Лиянең ундүрт яше

тулганмы, юкмы икәнен беркем тикшермәс, бәлки. Ләкин аңа әле ундүрт юклыгын әнисе белә, күрше-күлән белә, Изге анабыз Дикә белеп тора. Ничек итеп мин изгеләргә, анабыз Дикәгә каршы килеп, бозык юлга аяк басыйм? Андый эшне эшләсәк, сиңа да, миңа да күктән рәхмәт яумас.

— Шулай шул, — диде Әүхәт, көрсенеп. — Син миңа караганда динлерәк. Ярар, синеңчә булсын. Шулай да айык эчәбезме, калым турында сөйләшәбезме соң?

— Анысына каршылык юк, — диде Таҗит.

Моннан тугыз ел элек бөтен Акланда атаклы диңгезче Әүхәт белән менә шушындыйрак сөйләшү булды. Айык эчелде, калым турында сүз булды. Түрәгә барып сату-алу турында килешү төзеделәр. Ашык-пошык әзерләнделәр, ашык-пошык төялделәр дә, яр буенда беркадәр көтеп тордылар да, иртәгә унынчы көн була дигәндә, кузгалып киттеләр. Кырыйдан диңгез өсте шактый тигез иде. Айдан артык эшсез ятып хәл җыйган ишкәкчеләр яшьләр, тазалар иде. Көчсез җилгә ишкәкләр дә булышкач, җиз кагылган калку борынлы авыр кәмәләр, вак дулкыннарны ярып, су өстеннән шактый җиңел йөгерделәр.

Акланнан кузгалып бер тәүлек тулып килгәндә, караеп, Тирәү утравы күренде. Кояш су өстеннән аерылып, күктә асылынып торганда, Тирәү утравын уңда калдырып узып киттеләр. Кичкә чаклы тагын уңда, сулда таулы утраулар күренде, каршыга йөзгән берничә малтуар кәмәсе күренеп калды. Караңгы төшкәнче алар бардылар да бардылар, әледән-әле алга, як-якка карандылар, шул ук вакытта артны да онытмадылар. Акланның биек таулары, таулардан да биегрәк булып утырган сарайлары, алтынланган манаралары, коймалары балкып, нурлар сибеп бик озак аларны озатып калды.

Кичкә таба җил тынып калырга тиеш сыман иде, ләкин көтмәгәндә ул көчәя башлады һәм каршыдан, төн ягыннан исә башлады. Ишкәкчеләр арасында «Әвер!» дигән шомлы сүз ишетелеп китте. Алар инде арыган, ачыккан булсалар да, тагын да ныграк көч куеп, тырышып-тырышып ишәргә тотындылар. Тик кәмәләр генә кызулый алмадылар. Кәмәдәгеләрнең эченә курку йөгерде. Кешеләр изге аталарын, аналарын, изге иярләрне исләренә төшерделәр, кычкырып-кычкырып келәүләрен әйттеләр. Шул чакны Таҗит тә юлга чыккач беренче мәртәбә атабыз Минне, анабыз Дикәне исенә төшерде һәм шундук эче жу итеп китте. Юлга чыгу алдыннан ыгы-зыгыда ул су ияләренә, атабыз Мингә багышлап корбан бирергә оныткан иде!

Шул турыда яшь капитанга әйткәч, егет кычкырып көлде генә. Юлга чыккач яшь капитанның үз-үзен тотышы да, өзек-өзек сүзләре дә Таҗиткә бөтенләй ошамады. Ул үзен кирәгеннән артык хуҗа итеп, бар нәрсәдән өстен итеп тотты. Билгеле, кәмәдәге һәркем берсүзсез аңа буйсынырга, аның гына сүзен тыңларга тиеш иде — Таҗит инде монысын гына белә. Ләкин корбан турында әйткән сүздән соң капитанның, булачак киявенең шулай кычкырып көлүе бөтенләй ошамады Таҗиткә. Шулай да ул бу турыда әйтеп тормады. Тиз генә түбәнгә төшеп китте һәм ит өчен дип алынган бер кара бәрәннең тиз-тиз генә аякларын бәйләде дә, кычкыртып аны югарыга алып менде, багышлау сүзләре әйтте, тынычсыз чайкалган караңгыда диңгезгә ташлады.

Аның бу эшен барысы да күреп тордылар. Беркем берни эндәшмәде. Бары яшь капитан гына көлеп куйды һәм:

— Соң инде, соң! — диде.

— Нәрсә «соң»? — диде Таҗит капитан янына килеп, ачу белән.

— Корбанны аны яхшылап, йоласын туры китереп бирергә кирәк, — диде капитан, аңлатырга кирәк табып. Моннан өченче елны да без шундый хәлгә тарыдык. Бу әле Әвер җиле түгел. Бер-ике сәгатьтән Корыкыя утравына барып җитәрбез, шунда төн кунарбыз.

Таҗитне ул шулай дип тынычландырырга тырышты, ләкин аның мондый аңлатуыннан соң да, озакламый туктап ярга чыгу, ял итү турындагы сүзләреннән соң да Таҗит әз генә дә тынычланмады.

Ул арада җил көчәйгәннән-көчәйде, кәмәләр бик авырлык белән генә шуыштылар. Кайчагында аларның алга баралармы, әллә бер урында торалармы икәнлеген дә аерырлык түгел иде — колак төбендә бары тик шомлы итеп җил шаулаганы ишетелде дә, шыгыр-шыгыр килеп, шап-шоп килеп ишкәкләр ишкәне генә ишетелде. Берзаман ачы чыелдап сыек караңгылыктан акчарлаклар килеп чыкты. Кычкырышып, кәмәләр тирәсендә очып йөрделәр-йөрделәр дә, каядыр юкка чыктылар һәм бераз вакыттан, артка төшеп, чи-чи килеп, кәмәләрне озатып килә башладылар.

— Әнә, акчарлаклар каршыларга килгән. Ярга җитәбез! — диде яшь капитан, кешеләрнең күңелен күтәреп.

Бераздан еракта, бик еракта кара судан да карарак булып, биек булып, күтәлгән Корыкыя утравы күренде. Кешеләрнең эченә җылы йөгерде. Барысы да, каршы искән җилдән сакланырга тырышып, төньяктагы Корыкыя утравына карап бара башладылар.

Ләкин аларга Корыкыя утравына барып җитәргә насыйп булмады. Каршы җил көчәйгәннән-көчәйде һәм берзаман тирә яктагы караңгылыкны ярып, ялт-йолт килеп яшькелт яшен яшьнәде, дөбер-шатыр килеп күк күкрәде. Каршы искән җил белән яңгыр сибәли башлады. Куркып кычкырган тавышлар ишетелде. Кешеләр, яңгырдан, җилдән качып киндер түбә астына керергә тырыштылар. Кайберәүләр куркып тар баскычтан түбән төшеп китте.

Көн яктысында кәмәләр бер-берсеннән ерагаймыйча, су өстендә йөзгән казлар кебек, әле бер-бер артлы тезелеп, әле төркемләшеп бардылар. Яшь капитан утырган кәмә, юл күрсәтүче буларак, барысыннан алда барды. Җил көчәеп, күк күкрәп, яшен яшьни башлагач, тәртип бозылды, якын-тирәдәге кәмәләрнең барысын да берьюлы күрерлек булмый башлады. Ыгы-зыгы вакытында якында гына кинәт күк күкрәвенә охшамаган шакылдау, сыну һәм кот алынып кычкыру тавышлары ишетелеп китте. Сул якта, койрыкларын тиешенчә тота алмаган ике кәмә бер-берсенә килеп бәрелгән иде. Ул якта кычкырыш, елаш аеруча көчле булып ишетелде. Кәмәләргә зыян килгәнме-юкмы, әлегә белерлек түгел иде, ләкин бәрелешкән ике кәмәнең дә күпмедер ишкәкләре сынган булырга тиеш иде.

Монысы әле аның баласы гына булган. Анасы соңыннанрак булды. Беренче күк күкрәүдән соң икенче күк күкрәү булды. Бөтен күкне, суны икегә ярып, коточкыч тавыш чыгарып чатнады да, бөтен дөньяны яктыртып яшен яшьнәде. Күп тә үтмәде, коеп яңгыр яварга тотынды. Таҗит утырган кәмәне дә берзаман икенче бер кәмәгә китереп бәрде. Нидер шартлап сынды, ватылды.

Кемнәрдер кычкырды, кемнәрдер аллага ялварды. Бөтен нәрсә кинәт баш-аяк килде. Яшь капитан Мизан янында, борындагы сикедә карап барган Таҗит, ниндидер көчкә буйсынып, искәрмәстән упкынга ыргытылганда, нәрсәгәдер тотынып калды. Ул бик таныш тоелган нәрсә шома да, каты да һәм җансыз да иде. Бер-ике мәртәбә суга чумып, текә дулкын өстенә килеп чыккач ул әлеге каты һәм җансыз нәрсәнең кәмә борыны икәнлеген аңлап алды. Кәмәнең каз муены сыман алгарак чыгып торган борыны ат башы кебек итеп ясалган, «баш»ның маңгай тирәсе ныклык өчен җиз калай белән тышланган иде. Юан имән агачыннан ясалганга һәм һәрвакыт суда, су өстендә булганга ул инде муртайган, авырайган иде. Шунлыктан ул үзен ике куллап тотып алган ир кешене бик авырлык белән генә күтәрде. Ат

башы белән бергәләп Таҗит әле суга чумды, әле калкып чыкты. Су өстенә чыгу белән, аякларын селтәп, каядыр йөзәргә дә тырышып карады, ләкин болай тыпырчынып аның бары хәле генә бетте. Ул йөзәргә азаплануыннан туктап калырга мәҗбүр булды. Шаулап, гүләп, үкереп торган диңгез аны каядыр агызып алып китте.

Үзенең хәле шәптән булмаса да, ул тирә-якка күз ташларга да онытмады. Бермәлне ул як-ягында дулкыннар белән көрәшкән кәмә сыман кара-моралар күрде. «Ярый әле алар исән икән»дип уйлады ул. Беркадәр вакыттан соң яңадан диңгез өстенә күз төшерде, кара-моралар юкка чыккан, тирә-якта берни аерырлык түгел иде. Шул чакны, аның күңелен сызлатып, ачыттырып, чиксез бер әрнү тойгысы өтеп алды. «Барысы да... су төбенә китте микәнни?» дип уйлады.

Күпмедер вакыттан соң диңгез аны ниндидер яр буена китереп чыгарды. Җил тынган, көн яктырган, дулкыннар юашланып калган. Аяк астында, якында, тирә якта... каты җир. Су буенда комлырак, судан читтә вак таш, тагын да арырак тәбәнәк калкулык, калкулыкта куе куаклар. Аннан да арырак, бөтен күкне каплап, тоташ бер караңгылык булып, текә таулар, кыялар калкып утыра. Берни селкенми, берни чайкалмый. Дөнья яратылганда ничек куелган булса, кымшанмыйча, баш-аяк килмичә шул көенчә утырып торалар. Нинди рәхәт, нинди тыныч! Ләкин нинди җир, нинди утрау икән соң бу?

Артык пошынмыйча, кайгырмыйча Таҗит шул турыда уйлады һәм мәкерле куркыныч судан, диңгездән ничек тә ераграк булырга тырышып, каршыдагы куаклар ягына китеп барды. Барып җитә алмады — аягында хәлсезлек тоеп, тигез җирдә сөрлегеп китте, егылды һәм кулларын-аякларын як-якка ташлап, егылган җирдә тынып калды.

Ул комлы, ташлы яр буена килеп чыкканда, вакыт кич иде, ахрысы. Караңгыда, төн урталарында ул уянып китте, күзләрен ачты. Уяну белән иң элек ачлык тойгысы баш калкытты. Ачлык тойгысыннан соң туңу, салкынлык тойгысы барлыкка килде. Ул үзенең соңгы мәртәбә кайчан, нәрсә ашаганын да хәтерли алмады. Аңа хәзер үк нәрсәдер табарга, нидер капкалап алырга, һичьюгы чишмәгә ятып су эчәргә кирәк иде. Ләкин кая барырга, кемне күрергә — ул моны аермачык кына күз алдына китерә алмады. Күз алдында, аңда, зиһендә бары бер генә нәрсә торып калган — ул да булса диңгез, яшен, күк күкрәү һәм кәмәдәге ыгы-зыгы гына иде. Аннан соң имән агачыннан юнып эшләнгән ат башы. Ләкин

боларның барысы да чын түгел иде. Боларны ул төштә генә күргән иде бугай. Җил-давыл, диңгез турында олылар төрле куркыныч нәрсәләр турында сөйләгәч, бала чагында ул шулай йокыдан саташып, коты алынып уянып китә торган иде.

Бәлки, хәзер дә ул шулай куркыныч төш кенә күргәндер? Өндә шундый нәрсә булырга мөмкин түгел. Барлык йортың-ниең белән төялеп чыгып кит тә, искәрмәстән җил-давылга юлык та!.. Кинәт, тора салып бөтенесе су төбенә китсен, имеш! Юк-юк, булырга мөмкин түгел! Изге Мин атам, Изге Дикә анам! Мөмкинме шундый нәрсә? Мин — исән. Димәк, алар да исән булырга тиеш. Җәмәгатем, балаларым, караларым. Кайда икән алар, Диңгез, әйтче яшермичә?..

Аның шулай дип әйтәсе килде, аның кычкырасы, бөтен җирне-күкне дер селкетеп аһ орасы килде.

Ул кычкыра алмады. Яр буенда ул ниндидер кара нәрсә күреп алды. Бу аңа диңгез чыгарып ташлаган кешедер сыман тоелды. Ашыгып әлеге үзе кебек үк үлемнән котылган кеше янына килде. Аның кеше дигәне юеш комда ятып торып калган ат башы булып чыкты. Ул шундук айнып китте. Бөтен нәрсә ап-ачык булып, яңадан күз алдына килде. Шул ук мәлдә диярлек ул бөтен күкне каплап, диңгезгә үк терәлеп торган биек таулар, кыялар ягында кайдадыр бик югарыда өзлексез янып торган, каядыр галәмгә ашарга тырышкан сыман туктаусыз ыргылып, бәргәләнеп янган җанлы, тере ут күреп алды.

Шулай итеп, барысы да аңлашылды. Дулкын аны Акланга, изге утрауга китереп ташлаган. Нәкъ Саба авылы янына диярлек. Анда аның танышлары бар. Анда аның хәтта төн уртасында барып капкасын кагарлык якын кешесе дә бар. Ерак түгел. Шушы килеш, хәлсез килеш алпан-тилпән барганда да, таң атуга барып җитәргә, таныш капканы кагарга мөмкин булачак. Чынлап та ул кузгалып китте. Ләкин Саба ягына түгел, биектә, югарыда туктаусыз бәргәләнеп, өндәп, чакырып янган ут ягына таба китте. Ул мондагы тауларны, таулардагы сукмакларны белә иде. Белмәскә, турадан килә торган туры юлны ул диңгез буена кадәр нәкъ шушы төштән уздырырга тиеш иде ләбаса. Текә таулар арасыннан ул аны диңгез ярына сөзәк итеп, шул ук вакытта туры итеп төшерергә тиеш иде. Моның өчен берничә җирдән калкулык сыртларын кисеп алырга, берничә җирдән тирән аралыкларга таш-балчык өяргә, озын бер күпер салырга кирәк булачак иде. Аннан соң ул сугыш

кәмәләре туктап тору өчен иркен куен ясарга, яр буенда исә нгытылган таш кала салырга тиеш иде.

Ләкин менә булмады. Аның да, мәрхүм Карманның да хыялы тормышка ашмады. Белексез, булдыксыз мака сар бөтен эшне чуалтты да ташлады. Туктале, әллә соң мака сар Аланча түгел, аллалар чуалтты микән соң бу эшне?

Кем генә булмасын, чуалды эш. Чуалттылар, башаяк китерделәр. Очлы кыя башындагы серле утка әнә берни булмаган. Ул һаман да яна да яна.

Таҗит туры утка таба карап барды һәм таң алдыннан таныш капканың җиз дүңгәләгенә барып тотынды. Эчке якта башта кыңгырау шылтыраган тавыш ишетелде, аннан соң йокылы каравылчының нидер мыгырданганы ишетелде. Аягында көчкә басып торган, берничә көн эчендә танымаслык булып ябыккан, суырылган, яңакларын, ияк очларын сакал-мыек төкләре каплап киткән Таҗит, тын алырга да куркып, капка ачылуын көтте. Аның өчен бу тормыштагы барлык газаплардан, кайгы-борчулардан котылу капкасы иде. Яр буенда, тауда, урманда тотып алсалар, аны яңадан көчләп читкә озатачаклар яисә, хәтта кол итеп сатачаклар иде. Аны менә тотып алмадылар. Исән-имин ул менә бу капка янына килеп җитте. Ләкин, капкадан кереп, биек таш койма белән әйләндереп алынган шушы изге җиргә аяк бастымы, ул инде беркайчан да моннан кире чыга алмаячак иде. Үзе теләп, үзен-үзе ул монда төрмәгә ябып куячак иде. Ләкин бу дөньяда аның өчен хәзер бердәнбер котылу урыны шушы төрмә иде.

Капканы ачарга бик үк ашыкмадылар. Башта сорадылар: кем син, нишләп йөрисең? диделәр. Белеп килдеңме, белми килдеңме? диделәр. Коралың юкмы, юлдашларың юкмы? диделәр. Сорауларга кыска-кыска итеп җавап бирде ул. Кайбер җавапларны ишетеп җиткермәделәр, ахрысы, кат-кат сорадылар. Шул ук вакытта кемдер югарыдан, капка баганасы биеклегендә эшләнгән биек басмадан аны күзәтеп торды сыман. Таҗит башын күтәреп карамады — ул аны бөтен күңеле белән сизептоеп торды.

Күпмедер көттереп торгач, капканы ачтылар. Таҗит, уң аягын атлап, изге җиргә, тыелган җиргә басты. Кергәч, ул кыска гына итеп яңадан үзенең һәлакәткә юлыгуын, күпмедер диңгездә булуын сөйләп бирде. Ул бары аларга үзенең кемлеген әйтмәде дә, исемен генә әйтмәде. Капка сакчылары аңа үзләренең кичтән калган каты-коты икмәкләрен бирделәр, эчәренә су бирделәр. Шуннан соң

тар, кысан куыш идәнендәге изелеп, әвәләнеп беткән саламга күрсәтеп, кояш чыкканчы йоклап, ял итеп алырга куштылар. Ул шундук сузылып ятты да йокыга китте.

Нәкъ менә мака сар йомышчысы Бабул кебек, аякларын, кулларын як-якка ташлап, дөньясын онытып йоклады.

Икенче көнне аны Мәнзүм ата белән очраштырдылар. Никадәр танымаслык булмасын, Мәнзүм ата аны таныды һәм озак кына исенә-акылына килә алмый утырды. Мәнзүм атага Таҗит барысын да сөйләп бирде. Үзен бирелеп, теләктәшлек белдереп тыңлаучыга аның күңелендәге иң зур кайгысын да әйтәсе килде.

— Җәмәгатем, балаларым... оныта алмыйм. Алар алдында үземне гаепле саныйм, — диде ул, күз яшен күрсәтмәс өчен битен каплап.

— Мин Алла аларны корбан итеп алган, — диде Мәнзүм ата, дәртсез бер салкынлык белән.

— Барысын да микәнни?! — диде Таҗит, коты алынып. — Инде беркайчан да мин аларны күрә алмам микәнни?

— Монда аяк баскач... күрә алмассың, — диде Мәнзүм ата.

— Исән булсалар дамы?! — диде Таҗит, ышанасы килмичә.

Мәнзүм ата җавап кайтармады.

— Син, Таҗит, тау-ташны кисеп туры юл салмакчы булдың. Инде аңладыңмы — туры юл анда түгел, монда, — диде Мәнзүм ата. — Мин сиңа әйтеп карадым — тыңламадың. Ул вакытта мин сине ышандыра алмадым. Хәзер син минем... алмашым булырсың. Сизеп торам — озакламый тыным киселәчәк. Сине миңа алла үзе җибәргән. Исемеңне алыштырырсың... Заманында Сабир ата миңа Мәсәви исемен онытырга кушты. Мин Мәнзүмгә әйләндем. Сиңа да үзеңнең Таҗит икәнеңне онытырга туры килер. Пир ата Мәҗит булырсың..

Мака сар илчесе Бабул көннең кызуы сүрелеп, күләгәләр озыная башлагач кына уянды. Урыныннан сикереп торды да, үзенең кайдалыгын төшенә алмыйча, ары бәрелде, бире бәрелде — кулын, тезен авырттырды, маңгаен авырттырды һәм коты алынып кинәт бар көченә кычкырырга тотынды. Тавышка шундук Кәбир килеп җитте. Аңа моннан ерак китмәскә, куышка, олы кунакка күз-колак булып торырга кушылган иде.

— Кем кирәк? Нәрсә кирәк? — диде ул, Бабул каршысында калкып.

— Ник яптыгыз мине монда? — дип кычкырды Бабул. — Беләсезме, мин кем? Мака сар Аланча илчесе мин!

Куркудан аның аяк-куллары калтырады, тавышы өзек-өзек булып, колакка ятышсыз булып чыкты.

Кәбир чыпта ишекне күтәреп куйды.

— Чыгасың килсә, әйдә, менә моннан... — диде ул.

Бабул атылып тышка чыкты, авызын ачып, ашыгып тын алды һәм якты көнне, таныш күкне, тауларны-урманнарны күреп, берьюлы тынычланып калды.

— Уф! Җир астына... базга ташлаганнар дип торам, — диде елмайгандай итеп.

— Мин хәзер килермен, — диде Кәбир, каядыр китмәкче булып.

Бабул аның кулыннан тотып алды.

— Тукта! Тамагым кипте, — диде.

Кәбир аны чишмә янына алып килде.

— Менә, ятасың да эчәсең, — диде, челтерәп аккан чишмәгә күрсәтеп.

— Чагыр кирәк, чагыр, бер генә тамчы, — диде Бабул, чыраен сытып.

— Хәзер, хәзер, көтеп тор! — диде Кәбир һәм, Бабул нәрсә дә булса аңлап өлгергәнче, ашыгып каядыр китеп тә барды.

Бабулның көтеп торыр тәкате калмаган иде, ахрысы, Кәбир әйткәнчә ул җиргә сузылып ятты да, чишмә өстенә иелеп, эт кебек лач-лоч китереп су эчәргә тотынды. Эчеп туйгач аягына баскан иде, каршысында таныш сыман бер кеше күреп катты да калды. Бу кеше тап-такыр итеп кырылган ялан башлы, ялан аяклы иде, өстенә исә озын итәкле җилән-күлмәк киеп куйган иде.

— Уянгансың икән. Әйдә, куышка керәбезме? — диде пир ата Мәҗит, тораташтай тынып калган илчегә эндәшеп.

— Нинди куыш?! — диде Бабул, берни аңламаган сыман. — Минем бит сине каядыр күргәнем бар!

— Син инде әйттең аны миңа, — диде пир ата.

— Турада сине барысы да үлгәнгә саный, — диде Бабул, пир атаны тыңламыйча.

— Үлгән Таҗитне мин белмим. Без шулай бер-беребезгә охшаганбыз икән, димәк, ул изге җан булган. Карлы тау келәүлегендә изге булмаган кеше юк, — диде Таҗит-Мәҗит, мөмкин кадәр тыныч, дәрәҗәле булырга тырышып. — Син үзеңне мака сар илчесе дип белдердең. Мин сиңа берсүзсез ышандым, капкамны ачтым. Кердең, ял иттең — инде сөйлә: нинди йомышы төште мака сарның безгә?

— Менә кызык! Охшагач та охшар икән кеше бер-берсенә! Тавышы да шул ук, төсе-бите дә... Чәче генә юк, киеме башкача, — диде Бабул, төштәге сыман сөйләнеп.

— Син чыннан да мака сар илчесеме соң? — диде пир ата, җиңелчә үртәлеп.

Бабул сул кулын югары күтәргәндәй итте, йодрыгын йомарлап, пир атаның күзенә якынрак китерде.

— Менә! — диде горурлык сизелеп торган катгыйлык белән.

Сул кулының урта бармагындагы алтын йөзеккә түгәрәкләнеп бөгәрләнгән елан төшерелгән иде. Бабулның тышкы якта калган кәрендәсләрендә, атларының маңгайларындагы, күкрәкләрендәге җиз, көмеш калайларда, кешеләрнең бил каешларында, коралларында — һәркайда шундый тамгалар бар иде һәм еракта ук алар «Менә ул — без!» дип кычкырып торалар иде сыман. Пир ата аның кем тамгасы, нинди тамга икәнлеген бик яхшы белә иде, әлбәттә. Хәзер менә аның шулай берни белмәгән сыман сорап торуын Бабул чынга алды, ахрысы. Пир ата Мәҗитнең турадагы ниндидер төзүче Таҗиткә охшаган булуы белән кызыксынуы шундук кими төште.

— Кайда сөйләшәбез соң? Шулай аягөсте генә түгелдер ич? — диде ул, баштагы уйларыннан бүленеп.

Пир ата, ишарәләп, якындагы куышка күрсәтте.

— Менә минем сараем. Әйдә, түрдән уз, — диде.

— Карлы тау keләүлегендәге изгеләр бик иркен яшиләр, ашаганнары бал да май дип сөйләгән булалар тагын, — диде Бабул, куышка керергә ашыкмыйча. — Мака сар илчесе белән сөйләшергә рәтле бер сараең да юкмыни? Миңа ул куышта тын җитми, башыма таш төшәр кебек.

— Алайса, сарайда утырырбыз, — диде пир ата, килешеп. — Карлы тау келәүлегеннән иркен сарай юк! Түшәме күккә терәлгән, идәненә болыннар, урманнар сыя, челтерәп чишмәләр агып ята.

— Алай икән, — диде Бабул, пир атаның тел төбен аңлап. — Син мине чишмә суы белән генә сыйлап җибәрмәкче буласың, ахрысы.

— Әйдә алайса, иң элек ашап-эчеп алыйк.

Олы кунакны пир ата өч имән янына алып килде. Көн кичкә авышканлыктан, имән төбендәге күләгә дә икенче якка — кыялар ягына күченгән, иртән ашап утырган таш ачылып, яктырып калган иде. Пир ата уртанчы имән янында туктап, мака сар илчесенә үзеннән уң кул яктагы урынны күрсәтте. Беренче булып үзе

утырды, шуннан соң илче утырды. Аларның килүен көтеп торган аксакаллар шулай ук үзләренең урыннарына утырдылар. Өлкәннәрдән читтәрәк, күләгәле якта торган яраннар бернинди шау-шусыз, шулай да бик җитез кыланып, ашаучылар алдына калын чыпталар, чыпталар өстенә көмеш табаклар, көмеш пычаклар куеп чыктылар. Чыпталарның зуррагы, бизәклесе пир ата белән илче алдына куелды.

Шуннан соң ашчылар эшкә тотынды. Капкачлы, ике тоткалы таш табакларда ашчылар томалап пешерелгән каз китерделәр. Беренче табак пир ата алдына куелды. Табактагы бербөтен казны көмеш табакка алып салдылар да, авыр кайнар табакны, капкачын ябып, сак кына күтәреп, илче Бабул алдына китереп куйдылар.

Яхшылап йолкынган, мәмрәп, тәмле исләр таратып яткан симез казны күрү белән, Бабул елмаеп җибәрде, иреннәрен ялмап куйды һәм «башлыйбызмы?» дигән сыман, пир ата ягына карап алды. Пир ата исә тагын бер-ике табак килгәнен көтебрәк торды да, көмеш пычагы белән казның беркадәр тиресен кисеп, артына, имән төбенә ташлады. Шуннан соң, барысына да ишетелерлек итеп: «Әтекәмә-инәмә!» диде.

Пир атадан соң Бабул да пычагына тотынды, «Әтекәмә-инәмә!» дип садака бирде һәм тәмләп, ләззәтләнеп ашарга тотынды. Пир ата аның кебек үк ачыкмаган иде, аннан соң аның хәзер бик үк ашыйсы да килми иде кебек. Мака сар илчесе килеп төшкәннән бирле ул үзендә тыелгысыз бер киеренкелек, тынычсызлык тойды. Бу тынычсызлыкны берни белән дә томалап, онытып, юкка чыгарып булмый сыман иде. Бабулның үзен тануы, йөзне ертып, күзгә карап кирәкмәгән сораулар бирүе генә түгел, гомумән, аның монда булуы, үзендә ниндидер серле сүз саклавы аның өзлексез эчен пошырды, саруын кайнатты. Аңа карата монда беркем көч куллана алмаячак, беркем аны яңадан түрә катына, мака сар катына алып бара алмаячак. Шулай да... ах, шулай да!

Ни хәл итәсең, менә шундый тәмле аш янында да ул тулысынча онытыла, тынычлана алмады, хәтта авызына капкан майлы казы да сөяк булып тамагына аркылы утыргандай булды. Кисеп алган боттан ул бер-ике генә капты да, артына борылып, Кәбиргә ым какты.

Үзенә сузылган кисәкне Кәбир эләктереп кенә алды.

— Оһо! — диде аның янындагы Әлзәм, искәрмәстән.

Аның «оһо»сын пир ата ишетеп калды. Шуннан соң икенче ботны да кисеп алды, аны да бер-ике мәртәбә тешләде дә, борылып «оһо»га тоттырды. Пир

атаның кирәгеннән артык юмартлануын башкалар да күреп алдылар. Алар да, билгеле, үзләренең яраннарына шундый тәмле кисәктән өлеш чыгара алган булырлар иде. Ләкин беркем дә андый хәрәкәт ясарга ашыкмады — Карлы тау keләүлегенә көн дә илчеләр килеп тормый һәм мондый майлы казлар да көн саен пешеп тормый. Һәркем үз табагына иелеп, бирелеп ашавында булды. Ләкин никадәр тамаксау булмасыннар, алар инде хәзер элекке яшь чагындагы аучылар да, балыкчылар да, диңгезчеләр, юлбасарлар да түгел иде. Көн дә ике мәртәбә туйганчы ашап, эшсез-хәрәкәтсез ятып, күптән инде аларның карыны тараеп, кысылып беткән — анда хәзер бербөтен каз түгел, аның яртысы да сыярлык түгел иде. Ашап туйгач, аксакаллар майлы иреннәрен, кулларын сөртештереп, иттән аерылып, шәрәләнеп калган сөяк-санакларны, ашалмаган кисәкләрне көмеш табагында калдырып, барысын бергә яраннарга бирделәр.

Ул арада ашчыларның берсе озын муенлы, очлаебрак торган тар авызлы авыр чүлмәк күтәреп килде. Чүлмәкне ул пир атаның сул ягына утыртып куйды. Карап торышка иске, борынгы тоелган, шулай да ак, зәңгәр, кара, кызыл буяулар белән төшерелгән бизәкләре уңмаган юан корсаклы чүлмәк авызы балавызлап томаланган, балавызга батырып аркылы-торкылы җеп сузылган, җепнең очы балавыз шарга батырып, шарга тамга сугылган иде.

— Карлы тау келәүлегенең изгеләре чагыр эчми, табада томаланган кош ите ашамыйлар дигән булалар тагын, — диде илче Бабул, үзалдына сөйләнгән сыман, тулы чүлмәк ягына караштырып.

Ул моны, билгеле, шаяртып әйтте, ләкин мондый шаяртуларга күнекмәгән кайберәүләргә бу нindидер киная булып тоелды.

— Олуг илчеләрне сыйлаганда чагыры да, кош ите дә изгеләргә язык түгел, — диде пир ата, уңайсыз тынлыкны йомшартып.

Балавызның шарын тартып, ул башта җепнең очын алды, аннары җепне тартып, чүлмәк авызындагы балавызын ватты да алтын савытка кара-кучкылланып торган утлы чагырны агызды. Уты сүрелә төшсен өчен савытка су өстәде, болгатты да, шуннан соң алтын касәгә салды. Башта үзе авыз итте, аннан соң илчегә бирде. Бабул шулай ук, алтын касәдәге чагырны беркадәр авыз иткәч, аны үз янындагы күршесенә сузды. Чагырлы алтын касә аксакалларның барысын да йөреп чыгып,

яңадан пир атага әйләнеп кайткач, мака сар Аланча илчесе Бабул, ике кулын симез корсагында кушырып тоткан килеш, изге картларга күз йөртеп чыкты да, күптән көтелгән сүзен әйтте.

— Карлы тау келәүлегенә Аклан иленең баш мака сары Аланча киләчәк. Миңа менә шуны әйтергә кушылды, — диде ул.

Бу хәбәрне ишетеп барысы да тынып калдылар. Аксакаллар бер-берсенә карадылар, пир атага карадылар. Пир ата Мәҗит беркемгә дә карамады — күз алдына туры килгән чыптага, чыпта өстендәге алтын касәгә, беренче кат күргән кебек, текәлеп тик утырды. Илчедән соң ни дә булса әйтергә тиешлеген ул бик яхшы аңлады, ләкин кирәкле сүз нишләптер тел очына килмәде.

— Карлы тау келәүлегенә... мака сар киләчәк... — диде ул, илче сүзләрен кабатлап. — Кайчан килерен белеп булмыйммы?

— Сезгә кайчан җайлы — шунда, — диде илче. — Сезнең белән киңәшергә кушылды. Шушы бер ай төшендә... бер айдан да соңармастан....

— Ник килә? Анысын да белеп булмыймы? — диде пир ата, тавышын әкренәйтә төшеп.

— Ник килә дисеңме? — диде илче, чиктән тыш гаҗәпләнеп. — Шуны да белмисезмени?!

— Турадагы яңалыклар безгә бик соңлап ирешә. Белмәвебез дә бар, — диде пир ата.

— Бөтен ил, бөтен Аклан шау-гөр килеп тора. Көллесе шуны сөйли, — диде илче, җанланып, кулларын бутап.— Илгә яңа юсык кирәк. Мака сарлар, түрәләр, аксөякләр аллалар язып калдырган юсыкка буйсынмыйлар. Кая карама бозыклык, азгынлык! Ата — улны, ана кызны белми...

— Анысын беләбез, — диде пир ата, тыелып кына.

— Белгәч?! — диде Бабул.— Илгә яңа юсык кирәк, тәртип кирәк! Борынгы мака сарлар, тугыз ел тәхеттә утыргач, Карлы тауга килеп, тау куышына кереп аллалардан киңәш сораган, юсык сараган. Кырык ел тәхеттә утырган Карун бер мәртәбә дә Өрәк белән киңәшмәгән. Аннан элегрәк утыз елга якын утырган Арысби киңәшмәгән, Селәүтин киңәшмәгән. Белекле галимнәр әйткәннәр — йөз дә ике ел инде мака сарлар Карлы тау келәүлегенә аяк басмаганнар, изгеләр белән дә, аллабыз Өрәк белән киңәшмәгәннәр. Белекле галимнәр әйткәч, мака сар Аланча Карлы тауга килергә булды. Нурлы бикә дә каршы түгел. Шаулашкан караларның, аксөякләрнең авызын томалау өчен генә булса да, мака сар

Аланча сезнең янга килеп, тау куышында торып... сездән, аллалардан изге сүз ишетмәкче була.

Пир ата Мәҗит төшенеп алды, җиңел сулап куйды һәм, башын калкытып, аксакалларга, тирә-ягына карап алды.

— Мака сар Аланчаның тәхеткә утыруына быел... менә шушы муллык аенда тугыз ел тула, — диде ул, сакланып кына сүзгә башлап.

— Дөрес, тугыз ел!

— Шулай шул! — диештеләр аксакаллар да, телләре чишелеп.

Ләкин шуннан ары беркем берни әйтә алмады. Илче белән, билгеле, пир ата гына сөйләшергә тиеш иде. Аннан соң, монда алай сөйләшеп тә торасы нәрсә юк — килә икән килә. Тик менә ул ничек килер, кемнәр белән килер, ул килгәч монданиләр булыр, әлегә беркем дә күз алдына китерә алмады. Ни өчен дигәндә, кайчандыр элекке заманнарда Карлы тауга тугыз ел саен мака сарлар килүе турында имеш-мимештән күп нәрсә ишетеп белсәләр дә, чынлыкта моның ничек булганлыгын рәтләп белмиләр, күз алдына китермиләр иде. Белсә, пир ата Мәҗит беләдер. Кам-каталыкны да, үзенең серләрен дә пир ата Мәнзүм аңа калдырды. Барлык изгеләр арасында иң изгесе, иң санаклысы ул пир ата Мәҗит.

Аксакаллар, киңәш-табыш һәм акыллы сүз өмет итеп, пир ата Мәҗиткә карадылар. Ләкин пир ата Мәҗит тә чынында берни белми иде. Күп кенә серләр, тәртипләр турада гына түгел, монда Карлы тау келәүлегенең үзендә дә онытылып беткән иде. Ләкин мака сар илчесе алдында, боларның берсен дә сиздерергә ярамый иде. Бу мизгелдә пир ата Мәҗит шуны гына чамалый алды һәм Бабул әйткәннәргә җавапсыз калмас өчен өчен генә, болай гына сорап куйды.

— Ту анабыз Дикәнең чишмәсе табылмадымы, ишетелмиме? — диде.

— Һи-и! Монда бикләнеп ятып сез чыннан да берни ишетмәгәнсез, — диде илче. — Тапканнар бит ул чишмәне!

— Йа алла, — диде пир ата, балкып, башын, иелгән гәүдәсен турайтып.

Аксакаллар да күңелле генә гөрләшеп алдылар.

— Куанышырга ашыкмагыз, — диде илче, утлы кузга су сипкән сыман. Бөтен шау-шу шул чишмәдән башланды да инде. Кемдер әйткән: чишмә югалмаган, җиз койма буендагы чүплек астында күмелеп калган, дигән. Каралар ышанган. Шуннан китте дә китте! Сөйләсәң,

сөйләп бетерерлек түгел. Кыскасы шул: чүплекне юкка чыгарып Нурлы бикә шунда зур багана утыртырга, багана башына үзенең алтын сынын мендереп бастырырга уйлаган. Меңләгән колларны китереп чүплекне әрчеделәр, тау буен кистеләр. Карасалар, борынгы чишмә дә, ниндидер кызның таш сыны да чыккан, ди. Нурлы бикә чишмә суын җир астыннан арыкка борып җибәрергә, шул төшне таш белән төреп алып багана утыртырга кушкан. Юк, ул кушмаган, аны аңа теге атаклы сынчы Әүфил шулай киңәш иткән.

— Сынчы?! — диде кинәт пир ата Мәҗит, кызарынып, ярсып.

Кайберәүләр аның шулай кинәт сорап куюына аптырап калдылар. Кызып-кызып тура хәлләре турында сөйләүче Бабул исә андагы үзгәрешкә бөтенләй игътибар итмәде.

— Чишмә таш сын багана төбендә, куышта торып калган, — диде ул, аңлатып, сүзен дәвам итеп. — Баганаы биш ел өйделәр. Мең кеше бер ай эшли дә, бер ай ял итә, алары урынына икенче меңе эшли, алары ял иткәндә, өченче меңе эшли.

— Алай икән, — диде Мәҗит тагын үзалдына ярсып һәм, үзенең йөзен башкалар күрмәсен дигәндәй, иелеп касәгә тагын чагыр агызырга тотынды.

— Быел менә багана салынып бетте, диләр. Озынлыгы йөз колач, — диде Бабул. — Андый бағананың дөньяда булганы юк, диләр. Йөз чакрымнан күренеп тора, ди. Хәзер менә Нурлы бикәнең алтын сынын бастырып куясы гына калды. Анысы авыррак.

— Ник? — диде тагын да Мәҗит.

— Ул аны саф алтыннан койдырмакчы. Койдырырга җитәрлек алтын юк. Казна буш. Халык арыды, җиләде ул бетмәс-төкәнмәс эшләрдән. Теге багана төбендә калган сынны кайберәүләр анабыз Дикә сыны икән, диләр. Шуңа халыкның тынычланганы юк. Менә шундый чакта келәүлеккә килеп, алладан тынычландыргыч сүз ишетәсе килә мака сарның.

«Болай булгач, төшендек, барысын да сөйләп бирде» дип уйлады Мәҗит, һәм алтын касәне илчегә сузды да әйтеп куйды:

— Ил-көн белән, изгеләр белән киңәшмичә, мин сиңа бер сүз дә әйтә алмыйм. Җавабын өч көннән әйтербез, — диде.

*1987–1992 еллар, Казан*

Литературно-художественное издание

**Фаттах** Нурихан
(**Фаттахов** Нурихан Садрильманович)

**АТЛАНТИДА**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Фәттах** Нурихан
(**Фәттахов** Нурихан Садрилмән улы)

**АКЛАН**

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 04.08.2009.
Форматы 84×108 1/32. Шартлы басма табагы 21,00.
Тиражы 2000 д. Заказ Т-1666.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.